# Ркаил Зәйдулла



# Ташка ордым башны

Татарстан китап нәшрияты

РКАИЛ
ЗӘЙДУЛЛА




Хикәяләр, эсселар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
З-87

**Зәйдулла Р.Р.**

З-87 Ташка ордым башны: хикәяләр, эсселар / Ркаил Зәйдулла. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 399 б. — 3000 д. ISBN 978-5-298-01724-4

Ркаил Зәйдулланың прозасына кыскалык, сурәтлелек, шагыйранә тел хас. Шул ук вакытта ул кырыс реалистик алымда яза. Хикәяләрдә сурәтләнгән гади кешенең гамьнәре, өметләре укучыны битараф калдырмас. Эсселарында исә шагыйрь халкыбызның каршылыклы язмышы турында уйлана.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01724-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Зәйдулла Р.Р. 2008

# ХИКӘЯЛӘР



# ЙОРТ ИЯСЕ

*Әхсән Фәтхетдингә*

«Йорт иясе»нең уң күзе бераз кылыйрак иде. Әллә нинди сәер нәмәстәкәй булды әле бу. Аның фикеренә-хисенә буйсынмый, һәрбер орынуын карышып каршы ала. Әлеге чатлы, чабыр ботакны ул Рәифә урманының бер чытырманыннан табып кайткан иде. Әллә кайдан күреп алды ул аны. Рәссамның күзе — ыргак! Бу чатын киссәң, бусын бераз кыскартсаң... Моңлы, мәэсүс карашлы йорт иясе килә дә чыга... Сөенә-сөенә алып кайткан иде...

Кемдер чырышланып һаман ишекне шакый. Ул пәке очы белән «йорт иясе»нең күз кабагына кагылып алды да, сукрана-сукрана, ишеккә таба китте.

Аның остаханәсе биш катлы йортның чарлагына урнашкан. Бер почмакта чуар чыбылдыклы агач ятак. Хәер, ул агачтан бүтән әшьяны кабул да итми, кешеләрнең котсызлануын таш-бетон арасында, пластмас, пыяла катырылган җилемгә чолганып яшәүдән дип уйлый иде. Остаханәнең уртасындагы имән бүкән, меңләгән касәләрнең эзен саклап, исән калган дусларны әле дә сирәк-мирәк үз тирәсенә җыйгалый. Ә болай... Белмәгән кеше бу ярым караңгы бүлмәгә килеп керсә, шыр җибәреп тә алыр иде, мөгаен. Бөтен җирдә ботак-чатакларын сузган шүрәлеләр, йорт ияләре, су аналары... түшәм почмагындагы тыгыз пәрәвез оясыннан ниндидер серле дөньяның сихри бер җан иясе күзләрен елтыратып карап тора сыман.

Ул, йонлач күкрәген кашый-кашый, кәгазь кисәгенә карашын батырды. Телеграмма китергәннәр икән. Әтисе аңа кичекмәстән авылга кайтырга кушкан. Ул, сулышын кысып, ишек төбендә торган тәбәнәк тәңгәлгә чүкте. «Телеграмма» сүзен ишеткәч үк нигәдер шулай югалып, каушап кала... Йөрәге дә, урыныннан кубып, бугазына тыгыла төсле, тын алуы кыенлаша. Әнисе кинәт вафат булганнан соң да шулай телеграмма сукканнар иде бит. Телеграммалар аңа сөенеч, шатлык түгел, гел хәсрәт, көтелмәгән кайгы ташый.

Бу юлы нәрсә булды икән инде? Әллә этисе белән бер-бер хәл чыгып, күршеләре, аны кинәттән хәсрәт дәрьясына салырга теләмичә, шундый алак-шалак телеграмма сукканнармы... Юктыр, алай ук борчылырлык нәрсә юктыр. Әнисе үлгәннән соң этисе бик нык үзгәрде югыйсә, күңеле исекләнеп, гәүдәгә дә шактый бетәште, чатан аягы тагын да кыскарып, маятлавы көчәйде. Иң гаҗәбе — нечкәрде карт, гомер күз яше күрсәтмәгән төксе, төмсә этисенең беркөнне лапас эчендә елап торганын күрде ул. Битен-күзен капламыйча, тораташ калып елап тора! Күз яшьләре, бернинди каршылык күрмичә, бер атна кырынмаган сакал-мыегын чылата, картның бугазында ара-тирә нииндидер өзек-төтек авазлар сулкылдап ала иде.

Сыңар канаты сынган кошене ничек юатасың? Монда инде вакытка гына өмет итәсе, вакыт — табиб, тормыш мәшәкатьләре, көнкүреш мәтавыклары җилкәгә басып олы хәсрәтне җаннан сыгып чыгара, күңел яралары җөйләнә, кеше янә аксап-туксап дөнья куа башлый — менә шундый дәвалау үзенчәлекләре бар вакыт галиҗәнапларының.

Билгеле, ялгызы гына яшәү авыр иде картка. Бер кайтуында, тирә-яктагы агач ботакларыннан күзен аерып, йорт эченә, ихатага караса, бөтен нәрсәне чарасызлык, гаҗизлек биләп алган: ындыр яктагы койма авып төшкән, лапас ишегенең сыңар канаты каерылган, әрсез җил түбәдәге урыныннан кузгалган калайны кыйнап җанга нииндидер хәвеф өсти... Өй эче тагын!.. Идәнгә бармак илле балчык каткан, ятактагы урын-җир керләнгән, эскәтерсез өстәлдә суган кабыклары, каткан ипи кисәкләре... Тәрәзәләр дә урамны күрергә тилмереп ыңгыраша иде төсле.

Әтисе дә улының күзләрендәге мәгънәне тиз чамалап алды, кыенсынып башын читкә борды, гырык-гырык йөткерде: «Бернигә дә күңел ятмый, улым...»

— Монда сиңа яшәве кыен шул, — диде улы. — Әллә соң миңа күчеп киләсеңме? Шәһәрдә җайлы ич, уты-суы кергән...

— Анысы шулай, — диде карт. — Тик кеше өстендә була инде ул барыбер. Килен, балаларың дигәндәй...

Рәссамның хатыны шәһәр кызы иде, каенатасының күчеп килүен кочак җәеп каршы алуына өметләнерлек түгел... Хәер, шәһәр кызы булмаса да, кайсы киленнең каената-каенана белән яшисе килә?

Авылы да бик караңгы якта өстәвенә. Юллар юк, яңгырлы көзләрдә, буранлы кышларда зур дөнья белән бәйләнеш бөтенләй өзелә, урман ерак, кышлык утын әзерләү — тотса дөньяның билен сындырырлык ирләргә дә кыен, ә ялгыз, ярдәмсез картка нишләргә? Әле үзе бер кәҗә дә асрап ята, аңа да күпмедер курмы кирәк.

— Әллә, дим... — Карт ыжылдап урыныннан торды, чатанлап өстәл тирәсен әйләнеп чыкты, кипшенеп, кечерәеп калган кулы белән суган кабыкларын бер читкәрәк сыпырды. Дулкынланган, каушаган вакытларда ул шулай гел кулына нинди дә булса шөгыль эзли иде. Әле дә озак кына сүзен әйтә алмыйча торды. — Әллә, дим, әйләнеп караргамы?

— Күз уңында берәр нәстә бар мәллә? — диде улы.

— Тол карчыклар бар инде ул, — дип мыгырданды әтисе, — тик влачы бит аның ялгыз хатыннарны пенсе биреп бозды. Мин кайберләренең кылларын тартып караган идем, йә балалары риза түгел, йә... Кияүгә чыкмый калганнары инде аның, үзең беләсең, өметсез... Җүнле булсалар, яшьтән үк кемдер алган булыр иде. Безнең авылда кулга тотарлык берәү дә юк... — Ул кулын селтәде.

Рәссам шаккатып, авызын ачып әтисен тыңлады. Аз сүзле, бүтән чакта бер-ике җөмләдән күп сүз катмаган кеше әнә ничек җәелеп сөйләп ташлады. Иң гаҗәбе — сайлана ич карт. Зөфаф кичәсенә ашыккан яшь кияү кебек әнә ничек тураеп басты, ботакта килеш көзге кырауларга калган алма төсле җыерылган бите язылып, күз төпләренә кадәр сүрән кызыллык йөгерде. Рәссам чыраена таралырга торган көлемсерәвен мыегына яшерергә ашыкты, авызыннан фәлсәфилек тотененә уралып бер генә аваз чыкты:

— Да-а...

— Нәрсә далыйсың, — диде әтисе, рәнҗеп. — Күрәсең ич, тормышның бөтенләй рәте китте...

— Мин ни... каршы түгел түгелен... — Улы аклангандай йөткереп куйды. — Үзеңә ошаган бер-бер карчык булса...

— Карабиктә берәү бар, диләр. Әллә соң бүген шунда барып киләбезме?

Рәссам тәрәзәгә карап алды. Тузанлы пыялага теге яктан көзге яңгыр чирткәләп маташа иде.

— Шулай уптым илаһимы? Яңгыр да сибәләп тора, — диде ул. Шундый шыксыз көндә һич тә билгесезлеккә чыгып китәсе килми иде.

— Тимерне кызуында сугарга кирәк, — диде карт. — Аннары син әле тагын кайчан кайтасың...

«Миннән башка да өйләнеп була ла...» — дип үртәлеп уйлады улы.

— Күрше Хәтмуллага әйтсәм, тракторын хәзер кабыза... — Әтисе кожанын киеп ишеккә кузгалды.

Алар нәселендә әти кешегә каршы килү гадәте юк, рәссам, үзалдына сукрана-сукрана, җыена башлады. «Әти хаклы да, — дип уйлады ул бераздан, — кыз алырга барганда янәшәдә якын кешең булу шарт. «Нинди кыз?» — дип янә

үз уйларын үзе бүлде ул. Кыз түгел, чурт булсын, андый чакта барыбер атага терәк кирәк. Ә ул әле тагын кайчан кайта? Кыш узгачмы? Тик кышны әтисе ялгыз башы чыга алырмы әле? Әмма дә ләкин теге тол хатынмы, кем, шулай кинәт кубарылып, белер-белмәс көе кеше арбасына чыгып утырыр микән? Алдан сүз кушып, кылларын тартып карадымы икән соң...

Әтисе әйләнеп кергәндә, ул инде җыенып беткән иде.

— Хәтмулла тракторын кабыза калды, — дип хәбәр итте карт, — үзе исерек, кәнишне. Ну зыян юк, исергәч ул тракторын тагын да остарак йөртә.

Аның кыяфәте рәссамның күз алдында әле дә ачык саклана: башында изелгән эшләпә, кожанының итәгеннән идәнгә тып-тып тамчылар тама. Үзе, уңайсызлануын сиздермәс өчен, һаман сөйли. Иртән бик тырышып кырынган иде, сандыктан нафталин исе килеп торган саргылт күлмәген алып киде. Шулай купшылануның сере менә нидә икән! Ә ул, юләр, әтисенең бәйрәмчәк йөрүен күреп горурланып та куйган иде. Улының кайтуын бәйрәмгә тиңли, янәсе.

Карт, койрыгын таратып җибәргән тавис кошы сыман, ишек төбендә таптана. Түземсезләнеп улын ашыктыра.

— Нигә аны иртән үк әйтмәдең соң?

— Һәрнәрсәнең җае бар.

Ул арада Хәтмулланың тракторы өй каршына килеп туктады.

— Син ул хатынны beləсең. Безнең түбән очта үсте Нәфисә. Карабик егетенә ябышып чыккан иде уналты яшьтә. Тол калганына бер алты-җиде ел бардыр инде. Ире салган килеш кар өстенә ятып йоклаган да туңып үлгән, дип сөйләделәр.

— Ул бит миннән өч яшькә генә олы!

— Суң... Хатын яшь булырга тиеш инде ул, — дип кырт кисте әтисе. — Җылысы калмаган кәмпер миңа нәстәгә?

Алар, ишекне дә бикләп тормыйча, Хәтмулла тракторына ашыктылар. Әтисе Хәтмулла янына кабинага чумды, рәссам пычрак арбага үрмәләде.

Киттеләр.

Юл юеш, пычрак, арба әле уңга, әле сулга салулый, тик батып ятарлык түгел, моңарчы чалт аяз көннәр торды, җир өсте сагышлы сазлыкка әверелергә әзерләнеп кенә ята иде. Тик яңгыр һаман сибәли бит, каһәр. Алар әйләнеп кайтканчы нәрсә булыр? Ул кәпчен батырыбрак киде. Еракта яңгыр тоҗымнары аша җиңелчә өрфияләнеп торган зәңгәрсу урманнар тәбәнәгәеп калган сыман. Киң басуда салам эскертләре каракучкылланып күренә. Төш вакыты гына булса да, ниндидер төмсә йонлач җанвар дөньяны изрәткеч кочагына

алырга маташа. Моңсу иде, ямансу иде... Әнисе искә төште. Шундый яңгырлы көннәрдә алар мунча ягалар иде бит... Менә аны әнисе мунчага озата, сөлге суза, чиста эчке киемнәр бирә... Бераздан мунча алдына корымлы чәйнек белән чәй кертеп чыга. Стена буендагы эскәмиягә чәйнекне юри каты куя. Аңа каршы улы тамагын кыра. Бу андый-мондый гына авазлар түгел, бу — мәгънәле сөйләшү: «Йә, ничек, улым, — ди әнисе, — әйбәт кенәме, эссесе бармы, ис-фәлән тимәдеме?» — «Әйбәт, әни, эссесе колакны пешерә, ис-фәлән дә юк...»

«Хәзер менә яңа әни алып кайтырга барам», — дип уйлады ул, нигәдер көләсе килде. Әле кемне диген, Кылый Нәфисәне. Кылый дип кушамат таксалар да, Нәфисә кылый түгел, күзләре генә нигәдер икесе ике төстә иде. Берсе — соры, берсе — яшькелт... Шул күзләр егет-малайларның һушын ала, төн йокыларын качыра иде дә инде. Әллә нинди тылсым, ымсындыргыч сер бар иде ул күзләрдә. Берсе өметләндереп үзенә чакырса, икенчесе салкын кибарьлек белән читкә этәрә... Карабикнең кызыл башлы егете генә икенче күзгә игътибар итеп маташмады, бер кышны Нәфисәне чанага салды да һай-һулап атын йолдызлы төнгә таба куды. Иртән кое янына чыккан җиңгиләр «Нәфисәне урлаганнар» дип сөйләнсә дә, белгәнрәкләр мәгънәле итеп тел генә шартлаттылар. Менә әтисе дә «ябышып чыккан иде» дип сөйләде. Кыз урлау гадәте бу якларда борын-борыннан килсә дә, хәзер күбрәк кызны үз теләге белән «урлыйлар» шул. Аның каравы соңыннан иптәш егетләр каршында сөйләнеп торуы ни тора: «Төнәгенәк кенә җиңгәгезне чанага егып салып, урлап кайттым бит, әй!»

Көзге кичнең чабуын өстерәп урманга якынлаштылар. Тик аңарчы Көлкерәү инешен үтәсе бар әле... Инеш аркылы салынган ике бүрәнәне күргәч, рәссамның аркасына тир бәреп чыкты. «Хәзер аска мәтәләбез!» Ул учы белән кабина түбәсенә сукты. Тик исерек Хәтмулла мондый сугуларны гына ишетәме соң инде?! Ыжгырып килде дә, акрынаеп та тормыйча, көпчәкләрне ике бүрәнәгә туры китереп теге якка сузылып та чыкты. Юеш бүрәнәләрнең артта ни турындадыр әрләшеп алганы гына ишетелде.

Урман эченнән рәссамны йөзләрчә шүрәле күзәтеп тора сыман. Ул да аларны күрә, мөгезләренә кадәр барлап бара. Сирәк агачлар арасыннан Хуҗаның зәгыйфь кенә офтануы саркылып ала. Урманны чыкканда көчле җил исеп куйды, юл читендәге чегән хатыны кебек чүгәләгән килеш кулын сузып торучы өрәңге агачының кызыл-сары итәге чак кына өскә күтәрелеп алды. Моннан Карабик авылы уч төбендәгедәй күренә — үр генә төшәсе.

Яңгырда җебегән авыл мыш-мыш сулап йокымсырап ята иде. Хәтмулла тракторы, шул рәхәт мунча тынлыгын урталай ярып, кырый йорт каршына килеп туктады.

Зур ырыс капкадан берәү каршы чыкты. Баш очына күтәргән таяк очына арыш капчыгы бәйләгән. Үзенчә зонтик итеп файдалануыдыр, күрәсең. Төсе нindirәк икәнен аныклавы кыенрак булган җиләненең якалары арасында йодрык кадәр галстук төене дә күзгә ташланды. Рәссамның күз хәтере көчле иде — кайдадыр күргәне бар ул бу абзыйны... Тик кайда? Абзый, аңа печтек кенә дә игътибар итмичә, кабинадан яшьләрчә җәлт итеп сикереп төшкән кордашына кул бирде: «Килеп җиттеңме, кияү!»

Һо-һо... Атасы ордым-бәрдем чыгып китмәгән икән... Әзерлек булган, һәммәсе дә яхшы ук оештырылган бугай, әлеге абзыйның галстук бәйләп каршы алуы да юкка түгел, димәк...

Кияү карт сүзне кыска тотты: «Әйдә!» — «Бәй, — дип гаҗәпләнгән булды хуҗа, — бигрәк ташың кызган икән. Әүвәл чәйләп алыйк, кодагыең коймак та пешереп калды». «Өлгерербез, башта күрик тегене...» Галстуклы бабай үзенең сәер зонтигын селкеп көлде: «Һый-й... Килешенгән бит инде, мәгәриче-калымы дигәндәй. Бүген кәләш куенында йоклыйсың инде, һый-һый... Ничек дигән әле Габделҗаббар әбзәй: «Иланһи, ошбу матурга насыйп ит бергә ятарга, үбеп агъзыны татырга, ки куйнында булып гаувас!»

Кияү карт сизелер-сизелмәс кенә арбадагы улына ымлады. Хуҗа өстә бөрешеп торган рәссамны яңа гына күргәндәй кыланды: «Һә-әй, олан да кайткан икән. Кайтмыйча... мондый зур эш... шуткы-муткы тигел...» Атасы исә ачуланган тавыш белән коры-сары сүзләрен арбага ыргытты: «Төш, ни дип атлы казак кебек катып торасың...» Аның бу ачуланган сымак кылануы уңайсызланганын яшерер өчен иде, улы моны аңлый иде, күндәм бала шикелле арбадан көзге пычракка сикерде. Шунда гына хуҗа кешене кайда күргәнен искә төшерде. Ул мәктәптә укыганда «Белем» җәмгыятеннән нindider лекция укырга килгән иде әлеге абзый. Галстугының төенен дә нәкъ хәзерге кебек юан итеп бәйләгән иде.

— Киттек! — диде атасы, кыска гына.

— Моннан өч йорт аша гына яши ул... — Элекке лектор рәссамны юаткандай аркасыннан кагып куйды.

Рәссам борылып трактор кабинасына таба карады — Хәтмулла, рульгә башын салып, рәхәтләнеп йоклый иде.

Җилкапкадан ишегалдына уздылар. Каршыда түбәсе кыйшайган лапас мескенәеп тора. Трактор арбасында килеп өшегән рәссам туп-туры шунда атлады. Элекке лектор кыю гына өй ишегенең келәсен күтәрде.

Лапаста борын эчләрен кытыклап тәмле тирес исе килми, мал-туарны тол хатын күптән асрамый бугай инде. Ничек яши? Авылда, сыерың йә һич югы кәҗәң дә булмаса, тамак туйдыру да мөмкин түгел ләбаса. Тик аны асрар өчен печән-фәлән, икмәк, фураж кирәк шул... Ялгыз хатын ничек булдыра алсын... Хәер, берәр кантур тирәсендә эшләсә, үз тамагын үзе туйдырырлык кына акча бирәләрдер әле.

Ул, чалбар төймәсен төймәләп, өйгә таба атлады. Эчтән гөлдер-гөлдер тавышлар килә иде. Ишекне ачканчы, туктап шул тавышларга колак салды. Сәяси вазгыять нинди икән? Лектор сөйли иде: «Син алай әтмә, килен... Ул олы башын кече итеп килгән... Холкы әйбәт, йорт-курасы төзек... Лапасында кечкенә сыеры күшәп тора. Әле ат сатып алырга да исәбе бар. Безнең якта атсыз булмый... Ат үзен-үзе ашата ул...» Аны бүлеп яңгыравыклы хатын-кыз тавышы ишетелде: «Кире уйладым мин...» Тагын элекке лектор сүз алды: «Җитди мәсьәлә, кәнишне... Пәйгамбәребез дә ашыгырга кушмаган... Әмма дә ләкин вәгъдәне бозу да зур гөнаһ... Вәгъдә — иман, дигәннәр безнең бабайлар. Димәк ки, иманны бозу кебек килеп чыга, Нәфисә килен...»

Рәссам акрын гына ишекне ачты. Шауламаска тырышып бусага төбенә кереп басты. Түрдәрәк бер урындыкка чүгеп Нәфисә утыра. Мичкә сыланып диярлек яшь кияү буласы атасы баскан. Идән уртасында элекке лектор вәгазен дәвам итә: «Шул вәгъдәгә ышанып килде бит инде Сарим әбзәй. Ялгызлык беркемгә дә язмасын. Озын төннәрдә бер-береңнең аркасын җылытып җату гына да саваплы эшләрдән санала безнең шәригатьтә».

Рәссамга игътибар итүче булмады. Элекке лекторның нотыгын ишеткәч, аның кычкырып көләсе килде. Репертуары төптән үзгәргән моның! Элек ул сөйләгәндә Маркс, Лениннарны искә ала иде. Тик көләргә ярамый... Сәяси вазгыять шактый четерекле иде монда.

«Ни әйтергә дә белмим инде», — диде Нәфисә.

Өй эченә күз йөртеп чыккач, рәссам аның нигә икеләнеп торуын аңламады. Стена буендагы пружиналы караваттан, кечкенә генә өстәлдән, иске бер шкафтан башка берни дә юк иде өйдә... Гаҗизлек, ярлылык исе куерып тамакка тыгыла. Качарга кирәк, форсат барда, бу бәхетсез нигездән. Әллә юри генә үз кадерен үзе күтәреп азапланамы Нәфисә? Хатын-кыз бит ул да. Әле чибәрлеге дә уңып бетмәгән. Күзләре һаман шул. Берсе чакырып тора, икенчесе дә яшьлектәге кебек алай кистереп кире какмый... Гәүдәсе дә сылу гына... «Медпунктта эшлим, үз эшләгәнем үземә җитә», — дип куйды ул тагын.

Элекке лектор үзенең нотыгын сөйләп бетергән иде, ахрысы: «Менә малае да кайткан, ягъни мәсәлән...» — дип тынып калды.

Нәфисә, рәссамны әле яңа гына күргәндәй, ияген кагып исәнләште: «Исәнмесез... Юл бик авыр булмадымы?»

Рәссам башын иде... Монда барысы да аңа абсурд театрын хәтерләтә иде.

Тик... тик нигә аркадан шаулап кайнар дулкын йөгерде соң әле? Ул башын күтәреп тагын Нәфисәгә карады. Нәфисәнең күзләре елмая, ирен читләре нигәдер ара-тирә дерелдәп ала иде. Рәссам бит алмаларына кызыллык таралганын тойды. Күңелен сызландырыпниндидер бер рәхәт юксыну кан тамырларына саркыды. Ул бит малай чагында бер кичне Нәфисәне клубтан озата кайткан иде. Уникe яшь булдымы икән аңа, унөчме? Нәкъ менә озата кайткан иде, чөнки Нәфисә алдан атлый, ә аңардан ун-унбиш адымнар артта — ул... Нәфисә инде җитеп килгән кыз, күкрәкләре дә бөреләнгән, сыны уйнап тора... Ул үзе артыннан күрше малаеның кайтканын белә. Тик әйләнеп карамый...

Турларына килеп җиткәч тә тиз генә капкадан кереп китмәде кыз, бакча рәшәткәсе буенда яткан бүрәнә өстенә килеп утырды.

Малай янәшәдән сызгыра-сызгыра үтеп китмәкче булды. Нигә сызгырмасын, өенә кайта бит ул. Әнә генә ич аларның өе...

— Кил монда, — дип чакырды аны кыз.

Битараф кына атларга тырышып, малай күрше кызы янына килде.

— Нәстә?

— Утыр янымa...

Ул бер читкәрәк чүмәшмәкче иде дә, кыз аның кулыннан тотып янәшәсенә утыртты. Учы кытыршы иде Нәфисәнең, кайнар иде, нәни кош сыман талпынып алгандай булды.

— Мине кочаклыйсың киләме? — дип пышылдады кыз. Малайның авызы кипте, теле аңкавына ябышкан иде, аңардан ниндидер сәер авазлар гына чыкты.

Нәфисә аны кочаклап алды да сусыл иреннәре белән ыкы-мыкы килеп торган авызны эзләп тапты.

Малай аңына килгәндә, күрше кызы урамда юк иде инде.

...Ниһаять, әтисе чатанлый-чатанлый түргә узды, анда туктап тормыйча, бүлмәне, әйләнеп чыкты.

— Карагыз моңа! — дип, Нәфисәгә төртеп күрсәтте. — Нәрсә сөйләп тора, ә? Шыртлака... Олы башын кече итеп аңа дастуин кеше килгән... — Рәссам үз әтисен әйбәт белә иде, гаҗәпләнмәде. — Бик ачуны китерсәгез, минем әле кире уйлавым да бар!

— Кире уйлагач соң... Сине беркем дә тоткарламый, — диде Нәфисә...

— Күпме кешене бимазаладым, — дип тагын бүлмә буйлап йөреп китте әтисе...

— Бәлки, язмышыңа шулай язылгандыр. Киреләнеп торма, килен, — дип элекке лектор тагын сүзгә кушылды. — Әйдәгез, абыстай анда коймаклар өлгертте, чәй кайнаган...

— Синең күңелең яхшыда инде, мулла абзый, белəм анысын... — Нәфисәнең тавышы шактый ук эрегән иде. Әллә кияүнең чын ирләрчә идәнгә каты басып атлавы, үзенчә «ультиматум»ы эреттеме бу тавышны?

Рәссам да сүз кыстыруны кирәк тапты:

— Яшәп карагыз, Нәфисә... Аннары күз күрер...

— Шулай дисеңме? — Нәфисә көтмәгәндә көлеп җибәрде. — Шулай дисеңме... — дип янә кабатлады ул. Күзләре көлми иде.

— Минем малай башлы ул! — Әтисе горурланып малаен мактап алды.

— Ярар алайса, — дип, Нәфисә мич арасыннан зур гына букча күтәреп чыкты. Алсу шакмаклы бу букчаларны базар хатыннарында еш күрә иде рәссам.

Нәфисә, димәк, алар белән китәргә алдан әзерләнгән. Бу карышулары да юри генә булган. Хәер, хатын-кыз бөтен җаны-тәне белән сине теләгәндә дә үзен итагатьле итеп күрсәтү өчен «юк» дип карыша.

Бик тиз бирелгән очракта: «Мин сине әллә кайчаннан белəм сыман», — дип, үз тотрыксызлыгын психологик сылтау белән урап куярга ярата ул. Шулай булмый ни, ир-ат үз теләгенә ирешер өчен күңелен шәрран ярып ташлаган була, янә бер рәхәтләнеп актарынырга анда хатын-кыз өчен бернинди яңа әйбер дә калмый. Күп ирләрнең күңеле катлаулы булмый шул, шып-шыр бүлмәне мамыклагандай, хатынкыз гына аны кирәксә-кирәкмәгән җиһазлар белән тутыра... Шул чакта инде анда үзең дә адашырга мөмкин...

Чыгып китәр алдыннан әтисе кулын җәеп өй эченә күрсәтте:

— Ә болар?

— Калсын, — диде улы.

— Син яшь әле, аягыңа сыер басмаган. Хуҗалыкта бернәстә дә артык түгел...

Өйдәге өстәл-караватны, иске шкафны, ике урындыкны трактор әрҗәсенә ташыдылар. Караватның тутыккан пружинасы, соңгы юлга чыккандай, моңсу гына зеңләп алды.

— Сезгә кереп тормыйк инде, мулла абзый, — диде Нәфисә.

— Ярамый, килен. Никахсыз ярамый, — дип йомшак кына бүлде аны элекке лектор, хәзерге мулла.

Түгәрәк кенә алчак абыстай аларны ишек ачып ук каршы алды. «Бик яхшы булган, бик яхшы булган, — дип кабатлады ул. — Алдагы гомерләрегез бәхетле үтсен». Абыстайның бит урталары алсуланып чыккан. Әллә озак мич алдында торганга шулай, әллә Нәфисәнең кинәт иргә чыгуы тәэсир иткән. Хатын-кызларны чит кешеләрнең тиздән кавышачагы шулай дулкынландырып, терелтеп җибәрә...

Керә-керешкә үк абыстай кунакларны өстәл янына чакырды. Ул инде, күрәсең, табынны күптән әзерләгән, һәм табын шактый ук бай иде.

Мулла никахны тиз тотты. Алдына абыстай ак тастымал җәеп, тоз савыты куйгач, ул тантаналы чыраен кияүгә таба борды. Мулла булып кешеләрнең язмышындагы үзгәрешне шәригатьчә канунлаштыру аңа ошый иде булса кирәк.

— Фәсхетдин улы Сарим, син Тимергали кызы Нәфисәне хәләл җефет итеп алырга ризамы?

— Риза, хәзрәт... — Кияү вәкарь белән генә авызын сөртеп куйды.

— Тимергали кызы Нәфисә, син Фәсхетдин улы Саримга хәләл җефет булып барырга ризамы?

Нәфисә елмаеп куйды, аннары, беренче тапкыр кияүгә чыгучы яшь кыз сыман, керфекләрен түбән төшерде:

— Риза...

Мулла эскәтер астыннан кәгазьләр тартып чыгарды. Аннары, иренен кыймылдата-кыймылдата, кирәкле битне эзләп тапты. Гөнаһсыз елмайды, гафу үтенгәндәй:

— Никахны бик сирәк укырга туры килә, — диде. — Яшьләр бик аз калды авылда...

Нәфисә нигәдер кисәк кенә көлеп куйды, бал савытын рәссамга таба этәреп, әкрен генә:

— Авыз ит, улым, — диде.

Ләкин мулла җитди иде. Кәгазьгә урыс хәрефләре белән язылган никах хөтбәсен кычкырып укый башлады: «Әлхәмделилла, әлхәмделилла, әлхәмделилләзи, әнникаха сөннәти...» «Тавышы әйбәт, — дип уйлады рәссам, — тик көе юк. Коръән укыр өчен музыкаль колаклы булырга кирәк шул».

Мулланың тавышы тынгач, әтисе кесәсен капшый башлады. Тик бераздан гына түш кесәсеннән ике бармак арасына кыстырып илле сумлык акча тартып чыгарды. Өйләнгән көнне егетләр юмарт була!

Рәссам да кесәсен актарып ун сумны хәзрәтнең учына сонды.

Сәдакаларны җитез генә эскәтер астына шудыргач, мулла бик озак дога кылды.

Алар чыкканда Хәтмулла һаман йоклый иде әле. Рәссам кабина ишеген ачып, кабыргасына төрткәч, ул, кызыл күзләре белән алан-ялан каранып: «Мин кайда?» — дип сорады.

— Карабиктә, атайга катын алып кайтабыз, — диде рәссам.

— Ә мәгәрич кайда?

— Кайткач, кайткач, — дип, әтисе аны юатырга ашыкты.

— «Ягулык»сыз кайтмыйм!

Әтисе киң кожаныңың кайсы кесәсеннәндер бер шешә алып Хәтмуллага сузды. Тегесе дәү кулы белән шешәнең бөкесен умырып алды да «ягулык»ны авызына каплады.

— Пәрәдек...

Трактор гөрләп эшли иде.

Кияү кәләшкә таба борылды:

— Син кабинага утыр.

— Ю-ук, өлкән кешедән узып... Без улым белән арбага менәбез. — Нәфисә җитез генә арба үрәчәсенә килеп тотынды.

— Мәйлең, — дип, кияү аның артыннан этте.

Хатынның ачылып киткән якты балтырларына карамас өчен, рәссам читкә борылды. Караңгы төшеп килә иде инде.

Арба үрле-кырлы сикереп алга йөгерә. Нәфисә култык астындагы брезентын аска җәйде: «Утырыйк!» — дип кычкырды ул рәссамның колагына.

Болай җайлы икән, җил артык борчымый. Сикертә инде сикертүен. Кайчагында яшь килен көлә-көлә бөтенләй аның алдына ава. Рәссам читкә тайпылмакчы була. Үги әни бит! Тик арбадан төшеп каласыңмы?

Көлкерәү инеше каршында трактор туктап калды. Кабинасыннан сикереп төшкән Хәтмулла, башын кашып, аркылы салынган ике бүрәнәгә карап торды.

— Без моннан чыктыкмы? — диде ул, гаҗәпләнеп.

— Туктап та тормадык!

— Андый нәрсә гел кабатланмый ул! — Хәтмулла, арба төбендә аунап яткан балтасын алып, ботак-чатаклар чабарга урманга кереп китте. Рәссам да аңа иярде.

Караңгы төшкән иде. Фара яктысында урман әкияти бер сихер чытырманы булып күренә. Чү, нәрсә бу? Йорт иясе, билләһи... Тик ул моңарчы очраган йорт ияләренә охшамаган — карашында нииндидер җорлык, хәйләкәрлек. Пәке тидерсәң, авызы менә-менә ерылып китәчәк. Кулларында нииндидер чакыру ишарәсе... Һәрвакыт кесәсендә йөри торган нәни пычкысын алып, рәссам йорт иясен берегеп үскән карамасыннан аерды.

— Ботакларны инешкә ташы! Нәстә мыштырдыйсың анда?! — Хәтмулланың тупас тавышы рәссамны бу гөнаһлы җиргә кайтарды.

Тик ботак-чатакларның кирәге дә булмаган икән, Хәтмулла, трактор тәгәрмәчләрен ике бүрәнәгә туры китереп, исәнаман гына икенче ярга күчеп тә куйды.

— Бәхетең бар, Нәфисә! — дип, рәссам чын күңелдән сөенгәндәй булды.

— Өченче көн синең турыда радиодан сөйләделәр, — диде Нәфисә.

— Радио тыңламыйм...

— Исәр... Үзең турында радиодан сөйләгәннәрен тыңлау күңелледер ул... Шуның кадерен белмисең, улым, — дип шелтәләде үги ана.

Мондый мөгамәлә рәссамга ошамый иде. Ул кулындагы йорт иясенә карады:

— Аннан кисәсең, моннан кыскартасың, биредә пәке тидерәсең...

— Әшең җиңел икән, — диде Нәфисә. — Адәм көлкесе. Ботак кисеп ала да шуңа исем ябыштыра. Шуның өчен акча да бирәләрме?

— Сатып алсалар...

— Бардыр... Акчасын кая куярга белмәгән кешеләр күп хәзер...

Рәссам тынды. Үрле-кырлы сикереп барган трактор арбасында сәнгатьнең ни икәнен аңлатсынмы ул аңа? Менә тагын көлә-көлә Нәфисә аның куенына ауды. Борынга яңа сауган сөт исе килеп бәрелгәндәй булды. Нигәдер... Югыйсә Нәфисәнең сыеры юк бит дип аптырап уйланды ул...

Алар кайтып җиткәндә тәмам төн җиткән иде. Ашыгып кына Нәфисәнең әйберләрен ишегалдына керттеләр. Кияү кулыннан тагын бер шешәне алгач, Хәтмулла, саубуллашырга да онытып, өенә ашыкты.

Капкадан кергәч, рәссам ак келәткә таба атлады. Әнисе исән чакта анда җәен аш-су әзерлиләр иде. Сәкегә сузылып үзен генә борчыган татлы уйларга чумасы килә иде аның... Тормышындагы үзгәрешне ул әле генә ачык итеп аңлагандай булды. Бала чагы үткән бу йортта ул инде хуҗа булып йөри алмас бүтән. Бәгыренең кайсыдыр төшендә нәрсәдер өзелгән сыман иде.

— Чәй эчеп алмыйбызмы? — Күренеп тора, әтисенең чәй эчәсе килми иде...

— Юк ла, йокларга вакыт, — дип, рәссам ак келәткә кереп китте.

Кияү белән кәләш өйгә үттеләр. Майланмаган ызба ишеге, кемнедер үчекләргә теләгәндәй, сызгырып куйды.

Тик ул йоклый алмады. Өтергә, пычак, тагын әллә нәмәстәкәйләр алып, Көлкерәүдән алып кайткан йорт иясен

игә китерә башлады. Йорт иясенең женесе буламы икән? Юктыр... Тик рәссам кулындагы чатлы ботак пычак тигән саен гел хатын-кызга охшый бара иде. Чү, күзләре дә икесе ике төсле түгелме соң... Кинаяле елмаю бөркелгән иреннәре җәелеп китәр дә колак төбендә шаркылдап көлгән тавыш ишетелер сыман. Каһкаһәле көлү белән бергә ниндидер аваз да ишетелә түгелме соң:

— Ботагың булганчы, улым...

...Ә бу кем тукылдый тагын... Әтисе балта белән ботакларны тапап йөри түгелме соң? Менә йорт иясенең муенына китереп орды. Үзе: «Кияү мунчасына шәп булды әле», — дип шатлана, имеш.

Рәссам дерт итеп сәкедән сикереп торды. Келәт ишегеп шакыйлар икән... Йорт иясе дә исән, әнә, елмаеп, сынчысына иртәнге сәламен бирә...

— Коймагым пеште, чәй кайнаган, өйгә кер, — диде яшь килен. — Ай-яй, каты да йоклыйсың икән...

Рәссам киштәдәге йорт иясен алып Нәфисәгә сузды.

— Мә, туй бүләгем булсын...

— Рәхмә-әт... — Хатын бүләкне әйләндерә-әйләндерә карады. Тик әллә ни исе китмәде. — Шүрәлеме бу?

Рәссамның күңелен үкенү хисе кисеп үтте.

— Йорт иясе... — Әсәрен шулай кинәт кенә бүләк итеп кадерсезләвенә ачуы килде. — Өй иминлеген саклый ул...

Нәфисә уенчак елмайды.

— Өй иминлеген бүтән нәрсә саклый, улым...

Әтисе лапас ишегенең каерылган канатын элеп маташа иде.

— Һе-һе, — дип көлде ул бер сәбәпсез. — Шәһәрдә озак йокларга өйрәнгән син...

— Төнлә йокламадым. — Улы, аклангандай, Нәфисәнең кулындагы йорт иясенә ымлады.

— Курчак ясадыңмыни...

Нәфисә керт-керт көлде:

— Йорт иясе, ди ул аны...

— Э-эх, — дип кул селтәде әтисе. — Йортта умырып эшли торган малай үстереп булмады. Иясе дә булыр иде, биясе дә...

Өй эче җыештырылган, идән кыргычлап юылган — түшәмгә кадәр саргылт яктылык сирпеп тора. Табында самавыр гөрләп утыра, өстәл уртасында яңа гына коелган коймаклар пышылдаша, табак тулы бәрәңгедән пар бөркелә, өйгә яңа сауган кәҗә сөте исе таралган. Әтисе түр башына урнашты, рәссам белән Нәфисә кара-каршы утырдылар.

— Әле бераз торасыңдыр ич? — Кияү агач кашык белән ярмалы бәрәңгене авызына китерде, сөт уртлап куйды.

— Бүген китәм...

— Йортта эшләр күп, бер иркенләп кайтыр идең...
— Хәзер еш кайтып йөриячәк ул, шулай бит, улым, — дип, Нәфисә аңа карап елмайды.
Рәссам мич кашагасындагы йорт иясенә карашын күчерде, тик ул да ниндидер мәгънә белән елмая сыман иде.
Чәй эчкәч, әтисе, кәҗәгә печән салырга дип, тышка чыгып китте.
Нәфисә җылы учын рәссамның беләгенә куйды.
— Хатыныңнан уңмадың мәллә? — Тавышы бик якын кешенеке кебек иде...
— Анысы синең эш түгел... — Рәссам кинәт кенә урыныннан торып китәргә җыена башлады...
— Мин хәзер синең әниең...
— Юкны сөйләмә, Нәфисә, без синең белән бергә уйнап үстек...
Чатанлап әтисе килеп керде. Кәефе шәп, очып кына йөри.
— Кәҗә тынычсызланып тора, бүген фермага алып барып духтырга күрсәтмичә булмас...
Рәссам күңеле белән авылның мондый мәшәкатьләреннән ерак иде инде. Ул, күчтәнәчләрдән бушаган букчасын култык астына кыстырып, югары очта туктаячак автобуска таба атлады. Әтисе белән яшь хатын аны капка төбендә озатып калдылар.

Телеграмманы тотып шулай байтак кына аңгыраеп торгач, рәссам тәрәзә төбендәге телефонга таба атлады. Дуслар шундый чакта кирәктер инде... Ул да бер журналның мөхәррире булып эшләүче дустына чылтыратырга булды.
Исәнлек-саулык сорашканнан соң, бераз тынып тордылар.
— Авылдан телеграмма килде әле, — дип, төп сүзгә күчте рәссам. — Чакырганнар... Әти белән бер-бер хәл булмады микән дип борчылам.
— Кичекмәстән кайтып китәргә кирәк, — диде мөхәррир. Ул кайчагында шулай өзеп сөйләшергә ярата иде.
— Машинаңны биреп торсаң, әйбәт булыр иде... — Әлеге мизгелдә ул дустының кыяфәтен күз алдына китерде. Иреннәр кысылган, җитди кыяфәт, сул кулы кулъяулык белән пеләшендәге тирне сөртә.
Рәссам дустын борчуына уңайсызланып та куйды. Редакция машинасын шоферы-ние белән кешегә биреп җибәрү җиңел эш түгел иде мөхәррир өчен дә... Нинди эш килеп чыкмас? Тавык чүпләп бетермәслек мәшәкатьләр туып кына тора редакциядә... Өстәвенә баланы мәктәпкә илтәсе бар, хатынны эштән алып кайтасы дигәндәй...
Рәссам үз үтенеченә үзе үкенеп куйды.
— Бүген үк китерәсеңләр бит? — диде мөхәррир.

— Яхшы булыр иде дә...
— Бер сәгатьтән машина синең ишек төбендә булыр. — Мөхәррир бераз тынып торды. — Нык бул! — Аннары: — Бүген шофер авылыгызда кунар инде, иртәгә җибәрерсең...
— Хуп... — Дустының шулай өзеп сөйләшүе бу юлы ошады рәссамга...

Бер сәгатьтән инде алар Чирмешәнгә таба җилдерә иделәр. Шофер сөйләшергә яратмый икән — анысы яхшы булды. Алайса, аларның кайберләре ләчтит сатып, арзанлы анекдотлар сөйләп теңкәгә тия. Ә рәссамның бүген үз эченә бикләнеп кайтасы килә иде. Чыннан да авырып китте микән әтисе... Аның чатанлап өй эчен әйләнүе искә төште. Кыхкых көлүе... Инде күптән ата белән улның күңелләре берберсеннән ераклашкан, бигрәк тә улның — бала күңеле далада! Тик күкрәкне ачытып бер тойгы хәзер бугазга менде: ярата икән бит ул әтисен, кадерле икән бит ул аңа! Бала чактагы кебек чарасыз һәм гаҗиз булып күкрәгенә башны куясы, кытыршы яңагына яңакны ышкып җанны басып торган сагыштан арынасы килә.

Әллә соң яшь хатын белән яши башлавы өзлектердеме? Өлкән яштәге ир-ат яшь хатын алса, җан-фәрман үзе дә яшәрергә тырыша бит. Ритм үзгәрә... Шул үзгәреш сәламәтлеккә дә китереп суга...

Хәер, яшь хатын аркасында чыннан да яшәреп китүчеләрне дә белә рәссам. Әллә бу бер күз алдану гынамы?

Авылга килеп җитәрәк, яңгыр ява башлады. Ул гасабиланып куйды. Болай яуса, алар урамына үтеп булмаячак. «Бәхетеңне керпе чәнчесә шулай инде» дип үртәлеп уйлады ул. Терсәкне әз генә тәрәзәдән чыгарып, «Волга» машинасында өй турына килеп туктавыңны күршеләр тел шартлатып, кайсысы үтен сытып карап торсын иде, ә... Булмаса булмый шул...

Машина авыл очында туктап калды. Шоферның сүзе кыска булды: «Авыл эченә керә алмыйм».

— Хуҗаң кунып китәргә кушкан иде дә...
— Һи, мондый гына араны... Өч сәгатьтә Казанда булам мин... — Күренеп тора, аның тизрәк моннан сыпыртасы килә иде. Шоферлар мондый сәфәрләрдән ничек тә файдаланып калырга ашыгалар.

Рәссам, юл пычрагына тая-тая, букчасын баш очына күтәреп үз урамына таба атлады. Яңгыр пәрдәсе аша каракучкылланып аларның өй түбәсе күренә, алгысытып тора.

Ул кайтып җиткәндә, яңгыр туктаган иде инде. Бар дөньяга алма исе таралган. Яңгырдан соң һаваны, кем әйтмешли, ипигә ягып ашарлык... Юл да алай ук батып ятарлык сазламык түгел... Ашыкты шофер, ашыкты...

Өй ишеген хәвефләнеп ачты ул... Мичкә аркасын терәп әтисе бәрәңге әрчеп утыра иде. Улын күргәч, пычагын куеп, каршыга килде. Кочаклаштылар. Рәссам әтисенең кырынмаган яңагына битен тидерде, аркасын каккалады. Ябыккан карт, калак сөякләре төртеп тора.

— Авырмыйсыңдыр бит, атай?

— Ни булсын миңа, шайтан таягына... Кых-кых...

— Телеграмма...

— Тилиграм җибәрмәсәң, сине кузгатып буламыни? Ачуланма, бик күрәсем килде.

— Нәфисә... — Әни дип әйтмәс бит инде! — өйдә юкмыни?

Әтисе чатанлап өстәл тирәсен әйләнеп чыкты, кипшенеп, кечерәеп калган кулы белән андагы суган кабыкларын бер читкәрәк сыпырды. Аннары, акрын гына: «Китте ул», — диде.

Улы өй эченә күзен йөртте. Өй шыксызланып калган, соңгы көннәрдә хатын-кыз кулы тимәгәне күренеп тора. Чү, ул бүләк итеп калдырган йорт иясе кайда соң? Тик теле бүтән сорауны бирде:

— Кая китте?

— Аерылып китте. Карабиккә. Инде ун көн булды.

— Сүзгә килдегезмени?

Әтисенең ярсу холыклы булуын белә иде рәссам. Ярсыган чакта әллә нинди сүзләр әйтергә мөмкин. Кулга да җиңел... Тик тиз кайтып төшә. Коры дары кебек гөлт итеп кабына да кинәт сүнә... Күңеле әйбәт. Тик аны ныклап белмәгән, белергә өлгермәгән ят хатынга ничек аңлатасың? Сабырсыз шул хәзер хатыннар да, тиз арада гына ирне бөгәрләп олтан астына тыгуны кулайрак күрәләр. Карышып маташсаң, үзеңә үпкәлә! Кечкенә генә бүлмә эчендә дә власть өчен көрәш бара...

— Көйсез булып чыкты катын, — дип, атасы чатанлап ишекле-түрле йөри башлады. — Күңелем яткан иде югыйсә...

Рәссам өстәл янына утырды.

— Холкы начар мәллә?

— Һи, син кайта-кайта ачыккансыңдыр. Хәзер бәрәңге пешерергә куям. Әле чәй эчә тор. — Әтисе корымлы чәйнекне өстәл уртасына китереп куйды. Рәссам да букчадан күчтәнәчләр чыгарды: «Әйдә, үзең дә утыр. Бәрәңгене соңрак пешерербез».

Әтисе, шул сүзне генә көткәндәй, өстәл янына килеп утырды.

— Көнчел булып чыкты катын... Верандада урам якка каратып тәрәз тишкән идем, син анда үткән-сүткән кыз-

кыркыннарны күзәтер өчен тәрәз куйдың, дип жаныма тиде... — Аннары, башын читкә борып, әйтеп куйды: — Бик дәртле дә... Минем бит инде, үзең беләсең, учак сүрелә төшкән...

Мондый чакта ата кешегә нинди киңәш бирәсең?.. «Борчылма, атай, жае чыгар әле», — дигәләп, рәссам ишегалдына чыгып китте. Лапаска кереп чыкты, утын сараена сугылды. Монда аяк басуга ул имәнеп китте. Әрдәнә өстендә ботын күтәреп йорт иясе ята иде. Рәссам аны сак кына кулына алды, өстенә кунган тузанын сөртте. Йорт иясе гадәтенчә елмая иде. Урынны шушында билгеләделәр әле дип елмая жаныкачкаем...

Үзенең хезмәтенә карата мондый мөнәсәбәт табигый иде рәссамга... Беренче тапкыр күргәзмә оештыргач та гәжитләрдә әлләниләр язып чыктылар. Имеш, рәссам ислам динен инкяр итә, мәжүсилеккә чакыра. Мәжүсилек тә халыкның тарихы түгелме соң дип үз-үзен юатты ул. Әле аның кайбер төсмерләре дин белән бергә үрелеп безнең көннәргә дә килеп житкән. «Су анасы»н язган өчен Тукайга да бәйләнергә кирәк алайса... Хәер, аңа да бәйләнәләр бугай хәзер. Олугларга өреп кенә ничектер үзеңне танытып була.

Бик тә динигә әверелде кайберәүләр. Кичәге фахишә, бүген ак яулык бөркәнеп, исемен мөселманча алмаштырган булып, телевизордан «бисмилла» укып утыра. Бәлки, бу хәлгә гажәпләнәсе дә түгелдер. Адашкан жаннарның туры юлга төшүе, гомер буе тәкъва булганнарга караганда, Аллаһы Тәгалә өчен кадерлерәк ди түгелме соң?

Улы кулындагы йорт иясен күргәч, карт, күзен яшереп, сөйләнеп куйды:

— Нәфисәгә ошамады ул нәмәстәкәй... Гел миннән көлеп тора сыман, ди. Йә мичкә ягар дип, утын сараена үзем чыгарып куйдым. Ачуланма, улым...

— Мин аны шәһәргә алып китәм.

Шактый гына сөйләшмичә утырдылар. Бераздан әтисе янә сүз башлады:

— Күреп торасыңдыр, улым, тормышның тагын көе китте. Ир-атка ялгыз башы гына яшәве кыен... Бетә ул ялгыз башы. Кых-кых...

Рәссам сүзсез генә әтисен күзәтте. Кабат өйләнеп караргa ниятли, ахрысы.

— Сүз кушкан кешең бармы соң?

— Тилиграм суга-суга сине зерәгә чакырдым дисең мәллә... Чөнки дә әгәр... синсез булмый. Зур эш бит, жаваплы эш...

Картайган көнендә сүзчәнгә әйләнгән әтисенә карап, рәссам елмаеп куйды...

— Мин Хәтмулла белән сөйләштем инде. Хәзер килеп җитә...

— Кайсы тирәгә кармак салдың соң?

Әтисе күзен алартып улына карады. Җитди эшләр турында сүз барганда шаяртып сөйләшүне җене сөйми иде аның...

— Карабиккә барабыз, — диде ул, өзеп. — Хәтмулла хәзер килеп җитә.

— Мулла абзый кемне димләде тагын...

— Нәфисәне апкайтабыз...

Менә сиңа мә! Рәссамның битенә шаулап кызыллык йөгерде. Һич тә Карабиккә барып әтисенә Нәфисәне янәдән яулап йөрисе килми иде. Агымсуга ике тапкыр кереп булмый, диганнәр борынгылар. Яшь хатынга тәкатен тотмаган әтисенә ачуы килде. Кистереп әйтте:

— Мин анда бармыйм! Үзең генә бар.

— Өч тапкыр бардым. Кайтмыйм дип ыржалум тора... Кемдер боздырганмы... — Әтисенең тавышына ялвару төсмерләре үтеп керде. — Синең белән барсак, баш тартмас ул. Әллә ничә тапкыр сөйләде, хурмәт итә ул сине. — Салпы якка салам да кыстырырга онытмады: — Син бит безнең ише каткан авыл түгел. Сөйләшә беләсең... Ә кыз-катын матур сүзгә үлеп китә.

Рәссам башын учлап утыра бирде. Карабиккә Нәфисә каршына яучы булып барасы да килми, бармыйча да ярамый. Газиз атасы ласа...

— Аягың да җиңел, яшьтән үк шулай иде, — дип, әтисе үгетләвен дәвам итте.

Ул, әлбәттә, малайның үз сүзенә каршы төшмәсен яхшы белә. Тик мондый четерекле эштә каты сүз белән ниятен ямьсезлисе килми иде. Сүз көрәштерүдән башланса, ниятнең уңышсыз да чыгуы бар бит.

Ул арада Хәтмулла да килеп керде. Бүген ул нигәдер аек иде.

— Кузгалабызмы, җизни? — дип кычкырып көлде. Рәссам белән дә килеп күреште: — Әһә, художник та кайткан икән туй мәҗлесенә. Безнең авылда мондый еш өйләнүче бер Сарим әбзәй генә, — дип үчекләп күршесен мактады. — Хатыннарның телендә ул гына хәзер...

Рәссам әтисен кызганып куйды. Бөтен кеше аның артыннан бармак төртеп көләдер сыман тоелды. Аны шундый көлке хәлдә калдырган Нәфисәгә ачуы килде.

— Киттек, — диде ул, көр тавыш белән. — Карышса, кул-аягын бәйләп апкайтырбыз.

Әтисе шатланып көлде, Хәтмулла шәһәр кунагына шикләнеп карап куйды.

— Әйдәгез, алайса, тизрәк, — диде ул. — Озакламый караңгы төшәр...

Алар, ишекне дә бикләп тормыйча, Хәтмулла тракторына ашыктылар. Әтисе Хәтмулла янына кабинага чумды, рәссам пычрак арбага үрмәләде.

Киттеләр...

# КАТЫ КҮЗЛЕ ХАТЫН

Шәкүр абзыйның яңа атын күргән кешеләр өч көн аңга килә алмыйча йөрделәр. Аңардагы, Әптерәхмән мулла әйтмешли, сәмави матурлык моңарчы без күргән, күз төшергән бер генә атта да юк иде. Юыртып киткәндә аның селәүсендәй суырылып куюы, тоякларының сыйпаган кебек кенә җиргә кагылып-кагылып алуы безнең малайшак күңелдә үзебез дә аңлап бетермәгән әллә нинди тойгылар уята иде. Аны күрүгә, тамырларда кан да кызурак аккан шикелле!

Атның исеме дә зәһәр — куптәнге әбиләр әкиятен искә төшереп тора, күз алдына кылыч таккан баһадирлар, җиде башлы аждаһалар килә, Шәкүр абзый аңа иркәләп эндәшкәндә дә, безнең күкрәк тирәсендә нәрсәдер кайнарланып куя. Фәрхад исемле иде ул.

Безнең оч малай-шалайлары гел Шәкүр абзый ихатасы тирәсендә буталды. Ат торган араталы пает* астына якын килергә без, әлбәттә, шүрли идек. Шүрләрсең дә, бер ят кеше якынлаша башласа, ат борын канатларын киереп кешни башлый, тояклары белән шап-шоп идәнгә бәрә... Шәкүр абзый килгәндә генә ул тик үзе белгән ләззәттән муенын сузып күзләрен йома, тегесе исә аңа шикәр каптыра, иркәләп тамак төбен кашый. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе дә юк — Шәкүр абзый атның хуҗасы. Шунысы да бар: бу уртача гына буйлы, киңчә битле, ияк очында гына кечкенә сакалы булган киң җилкәле абзыйны күрүгә, һичкемгә баш бирмәгән, бер урында тыпыр-тыпыр биеп торучы кайнар сулышлы өер айгырлары да тынып кала, ул кулын сузуга, эреп китәләр. Тикмәгә генә «ат җене кагылган» дип сөйләмиләр иде шул Шәкүр абзый турында.

Аның малае Сабир да нәкъ атасы кебек, ат күрде исә дөньясын оныта. Атлар да аны ярата, көтүлектә аның кояшта янып кара-кучкыланган чырае пәйда булуга, койрык-

* *Пает* — лапас.

ларын чәнчеп аңа таба чабалар. Кичләрен ул әтисенең атларын елга буена сугарырга алып төшә. Төшкәндә-менгәндә атка атланып түгел, ә ат өстендә аягүрә генә йөри. «Күрегез, янәсе, Шәкүрнең улы Сабирны, алма агачыннан ерак тәгәрәмәгән...» Елгага алар ихатасыннан түбән оч буйлап төшәргә җайлы булса да, Сабир әйләнгеч юлдан — югары очка таба киткәннән соң Чабата тавын урап йөри иде.

Моның сәбәбе дә бар: түбән очта, авыл читендә үк җиргә сеңеп торган ихата-каралтысыз йортта бер хатын яши иде. Аның чыгып-кереп йөргәнен беркем күрмәс, хәтта әбрәкәйгә дә чыкмый иде, ахрысы, ул. Хәер, йорт тирәсендә андый нәрсә күренми дә иде. Без — малайлар, туры юлдан елгага ашыкканда, сыңар тәрәзәдә аның шомлы чыраен гына шәйләп алгандай булабыз. Авыл кешеләре бу тирәдә йөрергә яратмый. Кичектергесез эш-фәлән булмаганда, әлеге төшне һәммәсе урап үтәргә тырыша иде. Хикмәт шунда: биредә җан асраган ялгыз хатынның күзе коточкыч каты дип сөйлиләр иде.

Ул сокланып караса, кешеме, хайванмы, шунда ук сырхауга авыша, кайсысы, урынга авып, җан тәслим кыла икән.

Сәбәбен белеп өшкерүче табылмаса, үлеп китүчеләр дә бар икән шул, мәтәлеп китим менә...

Шуңа күрә ул шыксыз йорт янына җитүгә үк без йөгерә башлыйбыз, үкчәләр генә ялтырап кала!

Дустым Хәйрүш кенә моңа ышанмый, әбиләр уйлап чыгарган әкият дип көлә. «Алайса, нигә өлкәннәр бу тирәгә килеп йөрергә яратмый соң?» — дим. «Нигә алар монда килсен, алар суда коенмый, комда кызынып ятмый», — дип җавабын да таба. Чыны да шул, каты күзле хатынның йорты авылның аулак, ташландык төшенә урнашкан, кешеләрнең бу тирәгә айлар буена юлы төшми.

«Бәлки, ул йортта беркем яшәмидер дә әле, — ди Хәйрүш, — бәлки, аңа җен ияләшкәндер... Әйдә берәр төнне барып карыйбыз...»

Эһе, аның эше җүләрләр бар ди...

Менә беркөнне Сабир Фәрхадны сугарырга түбән очтан гына төште.

Күрәчәк үзе тартып китерә, дия иде минем бабай.

Ни генә димә, картлар язмышның ничек языласын алдан чамалый.

Әле беркөнне генә, гадәттәгечә, Шәкүр абзыйның ихатасы тирәсендә ышкынабыз. Бакча кырындагы эскәмиядә Шәкүр абзый берничә ир-ат белән сөйләшеп утыра. Үзе әле мунча гына кереп чыккан, тирләгән кызыл чыраен муен аша салынган чуклы сөлгесе белән сөртеп ала, изүләре ачык, аннан керпенекедәй каты, чал төшкән күкрәк йоннары төртеп

тора. Ул бәхетле — абзарда ара-тирә Фәрхад кешнәп куя, аңа Шәкүр абзыйның тамак төбе белән генә көлеп куюы кушыла. Ә тирә-юньдә алма исе аңкый.

Сүз шул һаман да Фәрхад тирәсендә бөтерелә инде.

— Киләсе сабан туена өлгереп житә бу, — ди Сәфәр абзый. Уч төбе белән маңгаен ышкып ала, күңләшүле карашын сыпырып төшерә. — Безнең як малы түгел шул, затлы... Әллә кайдан күренеп тора.

Шәкүр абзый Фәрхадны Казан тирәсендәге Шәйми байдан урлап кайткан, дип сөйлиләр иде. Ә ул байга атны төрекмән солтаны бүләк иткән, имеш. Булса да булыр, белгән кешеләр әйтте: ниндидер асыл ахалтәкин ыруыннан икән бу аргамак.

Сәфәр абзый үзе дә әллә кайлардан куып шәп атлар алып кайта, аларның ниндилеген ул күзен йомып таный. Аның сүзе кыйбат. Шуңа Шәкүр абзый тамак төбе белән генә тагын көлеп куя.

Эскәмиянең кырыена гына чүмәшкән Шәшәм абзый аваз бирә шулчак:

— Исеме ни диде, әле, Шәкүретдин? — Шәшәм абзый ябык, урты уртка кергән, йөзенә сары йөгергән, житмәсә, куллары бертуктамый дерелдәп тора. Яшьрәк чакта кайдандыр ат урлап кайтырга чыккач, аның эзенә төшкәннәр, Шәшәм абзый язгы ташу аша йөзеп чыккан, диләр. Котылуын котылган, әмма куллары калтырый торган булып калган.

— Фәрхад! — Шәкүр абзый тавышындагы тантаналы горурлыкны хәтта без дә сизәбез.

— Кеше исемле атның бәхете булмый... — Шәшәм абзый, торып, кулларын дерелдәтә-дерелдәтә, кыйшаеп торган өенә таба атлый.

— Һи, карт чуаш, — ди Шәкүр абзый, артык азапланмый гына. — Тузга язмаган сүз синнән чыгар инде, әҗәткана...

Тик Шәшәм карт хаклы иде шул. Дөнья аның хаклы икәнлеген бик тиз күрсәтте. Ә Шәкүр абзый, никадәр генә акыллы булмасын, хаклы түгел иде. Ялгышты ул. Шәшәм карт хаклы иде.

Беркөнне Сабир Фәрхадны сугарырга түбән очтан гына төшеп китте. Чебиләп беткән аяклары белән атның биленә басып, сызгыра-сызгыра түбән очны узып, туп-туры елга ярына килеп чыкты ул. Без дә аңа иярдек.

Фәрхад урамда күренүгә үк, безне үзенә суырып китерә иде.

Тырык-тырык без Сабир менгән затлы аргамак артыннан йөгердек.

Ахалтәкин!

Шул чагында Хәйрүш минем чабудан тартты. Теге каты

күзле хатынның өе каршысыннан узып барабыз икән. Соргылт тәрәзә пәрдәсе тартылып куйгандай булды.

— Әх, Фәрхадны күрде, ахрысы, — дип, Хәйрүш ачынып ботына сугып алды.

Мин ул вакытта аның сүзләренә колак салмадым.

Колак салсам да, ни үзгәрер иде. Буласы булган иде инде.

Шәфәкъ яктысы елгага төшкән — аңа ут үрләткәннәрмени! Шул кызыл суда кап-кара Фәрхад елкылдап күренә. Сабир аның белән нидер сөйләшә, ат исә, килешкәндәй, башын чайкап ала.

...Икенче көнне авыл өстенә яман хәбәр бик тиз таралды: Фәрхад аяктан калган...

Без бу хәбәрне ишетүгә үк, Хәйрүш белән җан-фәрманга Шәкүр абзыйларга йөгердек.

Алар каршына инде кешеләр җыелган. Тирә-юнь мәет чыккан вакыттагы кебек тып-тын. Кысыла-кысыла без кереп җиткәндә, Фәрхадның ирен читләреннән шәфәкъ кызыллыгы саркып беткән иде инде.

— Шул мәләвеннең күзе тигән, башкача түгел, — диде Шәшәм бабай.

— Авылдан куарга кирәк аны, — диде кемдер.

Тик Шәкүр абзый гына эндәшмәде. Берничә ир-ат белән алар Фәрхадны арбага салып мур базына алып киттеләр. Әле кайчан гына бөтен авылның горурлыгы булган аргамакны хәзер мескен генә җирән алаша соңгы юлдан тартып бара. Ахалтәкин...

Юеш койма күләгәсенә барып каз үләне өстенә сузылып яттык.

— Шәкүр абзый ул катынны болай гына калдырмас... — Хәйрүш саргылт түгәрәккә әйләнгән авыз тирәләрен аксыл теле белән ялап алды. — Башына җитәр кричнең.

Ихата тирәсендә дә, урамда да Сабир күренмәде. Икенче көнне алар каршына тарантаслы ат килеп туктады. Аннан күзлекле, җыйнак кына сакаллы, озын буйлы берәү төште. Кулына ул нindидер сәер букча тоткан иде.

«Саквояж... Доктор...» — дип пышылдады Хәйрүш. Белмәгәне юк шуның, мөгаллим малае шул. Белмәгәне юк, мәтәлеп китим...

— Хуш киләсез, Антон Павлович, — дип күреште аның белән Шәкүр абзый. Баш иде. Ә Шәкүр абзый теләсә кемгә баш ими ул...

«Доктор Сабирны карарга килгән» дип уйладык без. Аны туганнары «акылдан шашмасын» дип курка калганнар икән. Авызына бер тәгам ризык капмыйча, бер кәлимә сүз әйтмичә түшәмгә карап тик ята, ди, бичара. Фәрхадның үлеменә үзен гаепле санаган инде ул. Кем кушкан аңа түбән

очтан төшәргә? «Шайтан котырткан аны», — ди Хәйрүш. Әйтәм ич, белмәгәне юк аның.

Докторның да зәһәрен чакырткан икән Шәкүр абзый. Беразданябыгып, озынаеп калган Сабир урамга чыкты. Гадәттәгечә, безгә сәлам биреп маташмады инде. Күзләрен кысып бик озак түбән очка таба карап торды.

— Нәрсәдер мәтәштерә бу... — Хәйрүшнең бу сүзләреннән тәнемне калтырау алды.

Шаккатмалы хәлләр булырга тора бит әле, менәтерәк...

Һава тыгызланып күз бәйләнә башлагач, култык астына нидер кыстырып Шәкүр абзый түбән очка таба төшеп китте.

Хәйрүш белән бер-беребезгә карашып алдык. Авыз ачып берни әйтмәсәк тә, икебез дә белә идек: каты күзле хатын өенә юнәлде бу...

Култык астында ни икән?

Үзебез дә сизмичә Шәкүр абзый артыннан иярдек.

Өйнең ишеге сыек кына тавыш чыгарып ачылды да, караңгы йорт Шәкүр абзыйны үзенә йотты.

— Әйдә тәрәзәгә, — дип, Хәйрүш минем җиңемнән тартты.

— Әем лә... — Мин Шәшәм бабайның кулы кебек дерелдәп куйдым. Аның кулы гына дерелди, ә минем бөтен гәүдә!

— Куркак син, Әбләз! — диде Хәйрүш, җитди генә, һәм караңгылыкка уралып сыңар тәрәзәгә таба китте.

Куркырсың да... Каты күзле хатын сизеп алса... Тик дустым каршында куркак булып күренәсе килми бит, шайтан алгыры. Аннары, Шәкүр абзыйның ул өйдә нәрсә майтарганын да беләсе килә. Түзеп тормаслык белге кели.

Мин дә тәрәзәнең бер нүешенә килеп сыландым.

Шәкүр абзый белән каты күзле хатын кара-каршы өстәл янына утырганнар. Тавышлары да ишетелә. Хәер, бер Шәкүр абзый гына сөйли иде.

— Ничә еллар инде сине оныта алмыйм... — Ул алдында яткан төргәген сүтте. Аннан елкылдап торган кызыл ефәк күлмәклек килеп чыкты. — Менә... алып килгән идем. Яшьлегебезнең төсе булсын...

Каты күзле хатын эндәшмәде.

— Синең зифа сының менә ничә ел инде төшләремә кереп йөдәтә, — дип сүзен дәвам итте Шәкүр абзый. — Үзең белмисеңдер дә, бик чибәр бит син. Авылда сиңа тиң юк... Каләм кебек сызылган кашларың, йолдызларны көнләштерердәй күзләрең, җиләк кебек тулган иреннәрең... Көзгегә генә бак, үзең дә ышанырсың... — Ул җилкә аша борылып чебен эзләре төшкән тонык көзгегә карады. — Үзеңнең шундый матурлыгыңны кешеләрдән яшереп яшәп ятасың...

Каты күзле хатын җавап бирмәде.

Шәкүр абзый, урыныннан торып, ишеккә таба атлады.

Бусагада борылып әллә нинди эчтән чыккан саңгырау тавыш белән:

— Мин сине мәңге оныта алмам, — диде дә кулын селтәп чыгып китте.

Ул китүгә үк, хатын көзге каршына килеп басты, күлмәклекне туздырып иңнәренә салды, чәчләрен таратып җибәрде.

Без тын да алмый пәрдә бераз күтәрелгән төштән аны күзәтеп торабыз. Инде Шәкүр абзыйның да аяк тавышлары тынды.

Хатын кычкырып көлде. Әллә нинди яшерен тантана да, каһкаһә дә бар иде бу көлүдә. Эчкә суык кереп тулды. Без тиз генә тәрәзәдән коелып үзебезнең өйләргә элдерттек.

— Шәкүр абзый шул котсызны яратып йөри микәнни? — дидем мин, бераз сулу алгач.

Хәйрүш борынын тартып куйды.

— Нindидер хәйлә бар монда, — диде бераздан. — Шәкүр ул тиктән генә саламны да аркылы алып ташламый.

Нинди салам да нинди хәйлә? Шәкүр абзыйның мәхәббәт аңлатканын үз колагыбыз белән ишеттек ич...

Икенче көнне дә гел шул турыда гына уйладык. Шәкүр абзый без белмәгән бөтенләй бүтән ягы белән ачылып китте бит әле. Кешегә сөйләсәң, беркем ышанмас.

— Нindидер сер бар монда, — диде Хәйрүш. Ул һәрвакыт шулай һәрнәрсәнең төбенә тоз коярга ярата иде.

Караңгы төшүгә, сүз куешкандай, тагын түбән очка төшеп киттек. Фәрхадның үлемен дә онyттырып куйды бит әле бу мажара. Без инде бер хәл, Шәкүр абзый ничек шулай тиз генә онытты икән затлы аргамагын. Әле бит шул хатынның күзе тиеп кенә харап булды диделәр, бахырны...

Без тагын, ике ярканат кебек, каты күзле хатынның сыңар тәрәз нуешенә элендек.

Хатын... һәмишә көзге каршында иде. Үзе авыз эченнән нидер җырлыймы шунда... Иңендә кып-кызыл, елкылдап торган ефәк күлмәклек...

Шунда нидер булды — хатынның йөзе бәзгә әверелде, куллары аска ишелеп төште.

Ул гөрселдәп идәнгә егылды да тыпырчына башлады. Аннары тынды. Ирен читләреннән кызыл ефәк саркылып чыкты.

Без, куркудан телсез калып, Әптерахман мулланың өенә йөгердек.

Икенче көнне берничә карт, каты күзле хатынны, кабыкка салып, зиратка илтә киттеләр. Җеназада Шәкүр абзый юк иде.

Ахалтәкин!

# ТӘРЕ

Төнне ерып алга ыргылган поездда ул гына йокламый, ахры. Кулын ияк очына терәп дымлы тәрәзәгә текәлгән. Югыйсә нәрсә бар анда тышта? Ул аңламаган ниндидер сәер дөнья, катлаулы мөнәсәбәтләр, хыянәт, нәфрәт, күз яшьләре, мәңге төкәнмәс әшәке уен...

Поезд нидидер станциягә килеп туктады. Юеш, шыксыз вокзал каршында бер җан иясе юк. Инде төн уртасы авышты, яңгыр сибәләп тора, хәчтерүш җил аптыраганнан юл читендә ялгыз гына үсеп утырган әмерикә чаганын йолыккалый.

Утлары сүнгән вокзал, диңгезгә ымсынган кораб шикелле, кымшанып куя сыман. Поезд әкрен генә кузгалып китте. Поездларга гына төнне ерып алга ыргылырга язган. Вокзаллар мәәсүс гаҗизләнеп үз урыннарында калырга мәҗбүр... Алар тик каршылый һәм озатып кына кала. Мәңге шулай, каршылыйлар һәм озатып калалар.

Поездның кая ашыкканын белә ул. Дөрес, командирлардан беркем дә аларга кайсы ноктага кадәр баруларын әйтмәде. Ләкин китәргә ике атна кала ук кая җибәрәселәре билгеле иде инде... «Моздокка, аннары Чечняга», — дип бер-берсенә «хәрби серне» чишеп йөрделәр. Кайберәүләр әти-әнисенә телеграмма сукты... Шуның нәтиҗәсендәме, икеөч солдатны бүтән частьларга күчерделәр. Хәйрүш беркемгә дә хәбәр итеп тормады. Тикмәгә нигә борчырга? Әтисе укытучы, әнисе колхозчы, туганнары да гади кешеләр, калталары буш — барыбер Чечнядан йолып кала алмаячаклар. Хәлләреннән килсә, армиягә җибәрмәгән дә булырлар иде.

Ленинның хыялы тормышка ашты: чын эшче-крестьян армиясе хәзер Рәсәйдә... Акчалы кеше үз кулы белән улын бу мәхшәргә тере килеш биреп җибәрми... Ватанны сакларга кирәк дип лыгырдаучылар да шулар бит... Аның авылда калган әнисе, бөрчәйгән бармаклы кулын йөзенә китереп, нидидер ватан турында уйлыймы? Ул бердәнбер улының исән-сау кайтуын теләп Алладан ялвара. Шома битле байгураларның ватанын нишләп әле мин сакларга тиеш дип үртәлеп уйлады ул. Кемнән сакларга? Әле беркемнең дә Рәсәйгә бәреп кергәне юк. Бәреп кермичә генә күптән яуладылар аны. Һәм армиянең аларга бернинди катнашы юк...

Ватан... Менә чеченнар үз ватаннарын яклап сугыша. Ә без кем? Нигә ул, гади татар малае, әллә кайдагы Кавказда корал күтәреп йөрергә тиеш? Ни катнашы бар аның мондагы хәлләргә?

Астагы сәкедә Сундуков дигән сержант яман гырлый башлады. Хәйрүш чыраен сытты. Частьта да теңкәгә тиде

ул сержант чистый... Теңкәгә геңәме, җанга тиде... Төн уртасында уятып строевой атлату дисеңме, теш щеткасы белән унитаз чистарттырумы... Каршы килеп кара... Сундуков үзе дә зур гәүдәле, кирәксә, бер ым белән әшнәләрен дә чакырып ала. Аннары инде каптеркада яисә бәдрәфтә измәңне изәләр. Үзенә ят мохиткә эләккән һәр авыл баласы кебек юаш, кундәм иде Хәйрүш. Шуңа күрә аңа тимәделәр, әмма карышканнарның ничек казармага кайтып авуларын бер мәртәбә генә күрмәде. Каралган, биртелгән җирләре юк үзләренең, күрәсең, оста кыйныйлар. Шуннан соң бик «блатной» булып кыланган салагалар да, арата арасында печтерелгән яшь айгыр кебек, юашланып, алашаланып калалар иде.

Янәшәдә мыш-мыш килеп Мусин йоклап ята. Ирен читеннән нечкә генә булып мендәренә селәгәе агып төшкән. Уянгач, селәгәен яшерә ул... Бик үткен булып кыланмакчы... Анда барып кысыла, монда килеп ышкыла... Сержантка ярарга тырыша. Үз ишеләренә өстенрәк карый. Шәһәрдә туып үскән малай Екатеринбургтан. Татар булса да, аңа таянып булмый. Хәер, фамилиясе генә татар, исеме Вадим...

Хәйрүш кесәсеннән ак өстенә алсу шакмаклар төшкән кульяулыкны алып борын төбенә китерде. Иснәде. Кульяулыктан җиңелчә генә хушбуй исе килә иде. Тагын ниндидер ис. Ләйсән исе. Ул кульяулык белән битен сыпырды. Ләйсән аңа аны аерылышу кичендә биргән иде. Элек кызлар егетләренә үзләре чиккән кульяулык биргәннәр, имеш. Хәзер кем кульяулык чигеп утырсын...

Алар озак кына авыл урамын әйләнделәр. Кулга-кул тотынышып... Хәйрүш инде шуңардан күбрәген өмет тә итми. Ләйсән дә артык якын җибәрми.

Хәйрүшләр өендә аңарчы солдатка озату мәҗлесе булган иде. Ләйсән белән әй биеделәр дә соң... Музыка тавышын бөтен авыл ишеткәндер... Рәхәтләнеп татарча да тыпырдадылар. Күңелле булды. Хәйрүш беренче тапкыр шунда шәраб эчте. Әле хәзер дә баш әйләнеп торган сыман. Күңел күтәренке, ниндидер бер кеше шаккатырлык эш майтарып ташлыйсы килә. Бүген Хәйрүш үзенең шактый ук әйбәт кеше икәнлеген белде. Барысы да аны мактадылар. Исән-сау әйләнеп кайтуын теләделәр.

— Көтәрсеңме мине, Ләйсән? — Әллә ничә тапкыр шуны кабатлады Хәйрүш. Әллә бүтән сүзе юк, әллә бераз исерә төшкән.

— Ике ел күп вакыт түгел бит, — ди Ләйсән. — Нигә көтмәскә? Күз ачып йомганчы үтә дә китә ул...

— Башка малайларны якын китермә, — дип кыйммәтле киңәшен бирә Хәйрүш.

Авыл очына җитәрәк алар бер ялгыз карчыкның капкасы кырындагы урындыкка борылдылар. Һәр кичне диярлек алар шушында утырырга яраталар иде. Бер-берсенә сыенып...

Ләйсән дә хәзер авыл кызы түгел инде... Чабаксарда ниндидер университетта укый. Информатика бүлегендә диме... Аның нинди нәмәрсәкәй икәнен Хәйрүш аңламый. Ләйсән үзе дә җүнләп аңлатып бирә алмады. Ләйсәннең әтисе Ульян юлындагы бензоколонкалар хуҗасы. Акчасы күп, теләсә, кызын Казан университетына да кертә ала.

Хәйрүш югыйсә үзе Казан университетына барып караган иде. Татар факультетына. Ул әдәбият ярата, кешеләрдән яшереп кенә үзе дә шигырьләр язып маташа. Керә алмады. Әллә нинди сораулар белән башны бутады бер укытучы. «Баттал чит илдә нинди әсәрләр язган?» — ди. Хәйрүшнең Баттал шигырьләрен укыганы бар иде — бик советча шигырьләр... Чит илдә советча шигырь язып ятарга аңгыра түгелдер ич! Баксаң, чит илдәгесе бүтән Баттал икән. Кайдан белсен аны Хәйрүш? Бу җыйнак кына гәүдәле, төмсә йөзле, күзләре йөгереп торган укытучының аны батырасы килә иде — менә Батталны искә төшерде. Ә күрше егеттән Муса Җәлил турында сорый...

Катыргы чемоданын кочаклап авылына кайтып китте Хәйрүш. Әтисе ул чемоданны чормадан алып төшеп тузаннан чистарткан, тимерләрен тутыктан тазарткан иде. Армиядән шуның белән кайткан булган... Бик кадерләп кенә кулга тоттырды. Казанга килгәч, бүтәннәр бик сәерсенеп карадылар чемоданга... Белем кимерергә җыенучылар үзләре бик модный сумкалар асканнар иде иңнәренә... Алай гынамы, шактые университет каршына үз машиналары белән килеп туктыйлар иде.

Аларны күргәч, Хәйрүш үзен аккошлар арасына эләккән шыксыз үрдәк бәбкәсе итеп тойды. Күкрәгендә нидер өзелгәндәй булды. Юк, керә алмый ул монда, өметләнәсе дә түгел...

Гарьлегеннән өч көн өеннән чыкмады ул. Кайткан кичне йоклар алдыннан башын мендәр белән томалап елап та алды. Нигә кешеләрнең әтиләре бай да, аныкы укытучы гына? Беренче тапкыр уңышсызлыкка очраган үсмернең бу гаделсезлек белән килешәсе килми иде.

— Баш бәласе түгел, кайгырма, — дип юатты аны әтисе.

Ул әле алар йортына нәкъ менә баш бәласе килгәнлеген белми иде. Беркем дә белми иде.

— Әти синең белән йөрмәскә куша, — дип, Ләйсән башын Хәйрүшнең җилкәсенә куйды.

Хәйрүш гаҗәпләнде. Нинди начарлыгы тигәне бар Арәф

абыйга? Нигә яратмый ул Хәйрүшне? Очраганда да исәнләшми, каш астыннан гына карап үтә. Югыйсә Хәйрүш аның районда ниндидер инженер булып эшләп йөргәнен дә хәтерли әле. Бер дә мондый түгел иде. Ягымлы гына бер кеше иде. Авыл очында автобустан төшеп калгач, шундагы бала-чага белән юк-барны сөйләшеп алырга ярата иде. Хәзер ул «джип»та гына үтеп китә, машина көтүчене күрсә дә туктамый... Эше тыгыз, ашыга.

Инде кызына Хәйрүшне ташларга куша икән.

— Аның ни эше бар бездә?

— Безгә тиң түгел ул, ди...

— Минме? — дип тагын да гаҗәпләнде Хәйрүш. — Миңа ни булган? Дүрт саным төгәл... Университетка армиядән кайткач керәм мин...

Ләйсән, Хәйрүшнең наивлыгына кинәнеп, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Бай ул, бай, аңлыйсыңмы? Шуңа күрә сезне үзенә тиң күрми. Мине бер министр малае белән таныштырмакчы була. Район главасының да малае бар икән. Тик ул үзе безне тиң күрми, ахрысы...

— Син ни диден?

— Безнең арага кысылма, дидем. — Ләйсән чәчен бармаклары белән аралады, күзенә төшкәнен артка селтәп атты. — Мине тыңлый ул.

— Ул нәрсә диде?

— Берни дә әйтмәде. Елмаеп кына куйды.

Хәйрүшнең күкрәгендә нидер әрнеде. Арәф абыйның елмаеп куюы нидер әйтүеннән дә куркынычрак, анысын гына белә ул.

Егет Ләйсәнне кочаклап үзенә кысты. Иренённән үбәргә маташты. Тик туры китерә алмады...

— Кит әле, юләр мәллә син...

— Үбим инде, иртәгә китәм бит...

Ләйсән читкә тайпылып бармагын селекте:

— Ярамый...

Хәйрүш нәүмиз булып читкә борылды. Мондый чакта һөҗүмне гел көчәйтергә кирәк икәнне ул әле белми иде.

Кыз да аның хәлен аңлады. Китә бит, кайчан күрешәләр әле... Күрешерләрме?.. Чечняга җибәрсәләр... Аннары кыз да әтисенең елмаеп куюын дөрес аңлаган иде. Әтисенә каршы торып булмаячагын да эчтән төшенә иде ул.

— Кил инде, юашым, — дип, Ләйсән үзе Хәйрүшне кочаклап, тулышкан иреннәрен аңа таба сузды. Хәйрүш каядыр кайнар упкынга очты, югалды, онытылды...

Һәр көнне шулай армиягә китәсе килде...

Алар ярты төнгә кадәр үбештеләр. Бу үзе бер һөнәр икән

ләбаса! Хәйрүш әле яңа гына өйрәнчек бер малай иде, төн уртасында Ләйсән ярдәме белән остага әйләнде. Һәрхәлдә, үзенә шулай тоелды, әмма Ләйсәннең фикерен сорарга кыенсынды...

— Көн саен хат язып торырмын, — дип, Ләйсән өенә кереп китте.

Тик ике генә хаты килде. Нигә язмый, әллә хатлары юлда югала микән? Хәзер бит почтаның да рәте юк... Башбаштаклык бөтен дөньясында.

Моздокка барып урнашу белән тагын хат язарга булыр. «Ләйсән, — дип язар, — исәнме, кадерлем. Кайнар солдат сәламнәремне күндерәм. Чуктин-чук, күптин-күп... Бер минут истән чыкмыйсың, сандугачым...» Монысы арттыру инде, әлбәттә. Кызларга хат язганда бераз арттырырга ярый, анысын гына Хәйрүш яхшы белә иде.

Иртә таңда поезд Моздок шәһәренә килеп туктады. Поездан төшүгә үк аларны сафларга тезеп казармага алып киттеләр. Монда солдатларга беркемнең дә исе китми — бала-чагалар да авыз ачып карап калмый, хатын-кызлар да адымнарын акрынайтмый. Әлеге шәһәр-гарнизон Рәсәй солдатлары белән шыплап тулган. Һавада ниндидер шыпырт хәвеф тулгана. Фронт сызыгыннан ерак булмаган шәһәрләрдә шундый халәт буладыр. Хәер, фронт сызыгы монда һәммә җирдән үтә һәм еш кына йөрәкләрне тишеп үтә иде.

Грозныйда чеченнар аның исемен һәлак булган юлбашчылары истәлегенә Җәүһәр дип үзгәрткәннәр икән — каты сугышлар барганын Хәйрүш инде белә иде. Аларның да частен тиздән Чечняга куачаклар. Бәлки, иртәгә, бәлки, бүген кичкә үк...

— Куркасыңмы, татарчонок? — дип, Сундуков саргылт тешләрен ыржайтып көлде. — Чехлар* алар, о-го! — һәм кулы белән муенын сызып күрсәтте. — Секир башка!

Хәйрүш, күңел болгануын басмасмы дип, тәмәке кабызды.

Сундуков күзләрен кыса төшеп аны күзәтә иде. Нигәдер Хәйрүшне яратмады ул. Гел аңа гына бәйләнергә тора.

Хәйрүш бер читтә чүгәләп торган Мусин янына китте. Бер-ике сүз алышып булса да эчен бушатасы килде. Куркуы да басылыр, бәлки... Кеше бит бер җылы сүздән дә канатланып китә.

Әмма Мусин, Сундуковның үзләрен күзәтеп торуын күргәч, читкә тайпылды. Хәйрүшкә күзләрен алартып карады, черт итеп җиргә төкерде. Бу минем белән түгел, янәсе... Мин — үземә-үзем, ул — үзенә-үзе...

Ул арада казармалар алдындагы мәйданга тезелеп ба-

---

* *Чехлар* — чеченнарны урыс солдатлары шулай атый.

сарга куштылар. Каршыга бер майор чыгып басты. Аны элеккечә замполит дип йөртәләр икән. Уртада бүтән офицерлар укмашып баскан. Алар кырында зур гәүдәле симез поп та бар. «Анысы нишләп йөри икән?» — дип гаҗәпләнеп уйлады Хәйрүш. Җитмәсә, кулына зур тәре дә тоткан.

Майор солдатларны сугышка рухландырыр өчен сүз алган икән. Кып-кызыл чырайлы, олы бүксәле бу кешенең тавышы калын — еракка ишетелә, аяк очына баса-баса кычкырып сөйли, һәр җөмлә, камчы кебек һаваны кисеп, баш миенә үтеп керә:

— Чечен бандитлары Россияне таркатырга маташа. Сез шуны онытмаска тиеш: Россия бердәм һәм бүленмәс. Бандитларны кызганып тормагыз. Коралын ташламаган дошманны юк итәләр. Урыс солдаты беркайчан да җиңелми!

Тагын әллә ниләр сөйләде әле бу юан майор. Хәйрүшнең ике яктан чигәсе кысып авырта башлады. Янәшәдә күкрәген дугадай киереп Сундуков басып тора. Күзендә нәфрәт чаткылары уйный. Ул хәзер үк чеченнарга каршы ыргылырга әзер.

Аннары поп нидер сөйләде. Хәйрүшнең колагында тик бер сүз чыңлап торды: Россия... Россия... Россия...

Поп солдатлар өстенә су бөркеде. Әлеге су изге икән дә, аларга исән-сау калырга ярдәм итәчәк икән. Сипмәгәе, исән-сау калырга ярдәм итсә, бу суда колачлап йөзәргә дә әзер Хәйрүш. Тик менә ниндидер кыенсыну хисе генә күңелне кымырҗытып тора, нәгаләт... Ул бит урыс-керәшен түгел, аңа попның нинди ярдәме тисен? Хәйрүш, бүтәннәргә ишеттермичә генә, әбисе өйрәткән «бисмилла»ны пышылдады.

Хәер, кычкырыбрак әйтсә дә, беркем ишетмәс иде, попның бугазы киң, тавышы андый гына бытылдауларны басып китә, менә ул сафлар буенча Хәйрүшкә якынлаша. «С вами бог», — дия-дия кечкенә бакыр тәре өләшеп йөри икән. Хәйрүш аны алмаска уйлаган иде дә, Сундуковның җан өшеткеч карашын лепкәсе белән тоеп, калтыранган кулын попка сузды. Өметсезлек кебек саргылт тәре Хәйрүш учында йомылды.

Сафлар таралгач, Сундуков аның җилкәсенә сугып мыскыллы елмайды:

— Менә син дә христиан булдың, татарчонок. Мөселманнарны бергә манчырбыз. Кара аны, тәрене югалтма! Һәр кичне тикшерермен...

Тәрене бәдрәф тишегенә ташларга ниятләп торган Хәйрүшнең эченә салкын йөгерде. Бу Сундуков бер бәйләнсә, җиңел генә котылырмын димә. Кич саен тикшереп торачак, билләһи... «Чукынмадым бит әле, — дип үзен юатып уйлады ул. — Урыс алласына ышанмыйсың икән, тәредән нинди зыян? Мәктәптә укыганда аны миллион тапкыр плюс итеп кәгазьгә дә төшердек...»

Икенче көнне алар Ведено шәһәренә килеп керделәр. Хәрабәләрне карап төп урамнан уздылар. Гади халыкның күбесе качкан, ә чечен сугышчылары бу каланы ике көн үк ташлап киткәннәр икән. Алайса, нигә шулкадәр бомбага тотканнар?

Хәйрүшнең моңа исе китмәде, сугышның булмый калуына сөенә иде ул.

Аларның колоннасы зур бер таш йорт каршында туктап калды. Солдатлар, чебеннәр кебек, БМПлардан* җиргә коелды. Бер танк, тимер капканы җимереп, ишегалдына ук кереп туктаган. Янәшәдә ябык кузовлы «Урал» машинасы тора. Солдатлар аңа өйдән төрле затлы әйберләр — япон телевизорлары, видеомагнитофоннар, күз явыңны алырлык келәмнәр ташыйлар. Өч-дүрт солдат көчәнә-көчәнә инкрустацияләп ясалган биек кәнәфине ишектән чыгарып маташа...

— Шамил Басаевның тәхете! — дип кычкырды Сундуков. Машина кырында солдатларның гамәлен күзәтеп торган полковник аңа күзен алартып карады.

— Быстрее! — дип кычкырды ул кәнәфи күтәргән солдатларга.

— Авыр, — диде бите корымланган яшь бер сержант. — Әллә алтыннан эшләнгән инде... — Һәм мышкылдатып борынын сеңгерде.

— Кулыңны сөрт! Кәнәфине пычратасың... — Полковник гасабиланып бер урында таптанып алды.

Бераздан «Шамил тәхете» дә «Урал» әрҗәсенең алагаем зур авызына чумып юк булды.

Хәйрүшнең шунда гына башына барып җитте — бу Шамил Басаевның йорты икән. Булган...

— Бай яшәгән бандит, — дип, Сундуков аяк астына төкерде. — Шартлатырга кирәк бу елан оясын...

— Җәл бит, — диде Хәйрүш. Аннары, Сундуковның мыскыллы карашын күтәрә алмыйча, ник әйткәненә үкенеп, йөзен читкә борды...

— Гитлерның да бөтен бункерларын шартлатканнар... — Мусин тәмәке төтенен Хәйрүшнең күзенә өрде... — Фашистның эзе дә калмаска тиеш...

— Молодец, Мусин, — дип Сундуков аны мактап алды.

Ишектән бер юан корсаклы майор йөгереп чыкты.

— Кулга тотарлык әйбер калмады, — диде ул полковникка. — Кузгалыйк тизрәк...

Полковник аңа ышанмыйча карады.

— Яхшы тикшердеңме? Идән астын карадыңмы? Стеналарында берәр тайник калмадымы?

---

* *БМП* — боевая машина пехоты.

— Миллиметрына кадәр шакып чыктык. Юк...

— Вот сволочь, җыен хлам калдырган, — дип сүгенде полковник. — Ну без аны алтын костырачакбыз әле, — дия-дия кабинага утырды. Майор да аның янына үрмәләде. «Урал» ухылдап ишегалдыннан чыгып китте.

— Әйдә кереп карыйбыз, — дип, Мусин Сундуковтан рөхсәт сорагандай кыланды.

— Анда берни дә юк инде хәзер... — Сундуков, хуҗаларча киң-киң атлап, йорт артындагы ихатага таба китте. Хәйрүш белән Мусин да аңа иярде.

Анда биш-алты солдат нәрсә турындадыр бәхәсләшеп торалар иде. Сундуков аларны аралап эчкә үтте.

— О чем базар, братцы?

— Шамил атларын калдырган, — диде җирән чәчле, кызыл чырайлы берәү. — Күренеп тора, простой атлар түгел...

Эчтә, колакларын шомрайтып, чем-кара ике ат басып тора иде.

— Һе, абзарында Шамил простой атлар тотмас, — дип тагын берсе сүзгә кушылды. — Токымнары ниндидер...

— Гарәп аргамаклары!.. — Сундуков сыйпарга дип үрелгән иде, ат куркып башын өскә чөйде. — Шамилгә Иордания короле үзе бүләк иткән...

Солдатлар сокланып Сундуковка карадылар. Үзенә хөрмәт уята белә иде ул.

— Син татар бит әле? — дип, Сундуков Хәйрүшкә борылды. Хәйрүш, аңардан һәрвакыт берәр этлек көткәнгә, ни дип җавап бирергә дә аптырап калды. — Сез ат яратасыз инде... Безнең Пенза ягында ат асрамаган татар юк...

Хәйрүш солдатларның кызыксынучан карашларыннан оялып, йөзенә кызыллык таралганын сизде. Пенза ягында ничектер, үзе ул, авылдан булса да, ат күреп үсмәде. Алар авылында тегермәнче Шәкүрнең җирән алашасыннан кала атлар юк иде. Шәкүр көн саен шул алашасын җигеп тегермәнгә бара, кайтканда исә түбән очта яшәүче тол хатынның җиргә сеңеп бара торган өе кырына туктый. Кайчагында арба төбендә бер капчык он да агарып күренә иде.

Ул тол хатын турында авылда төрле имеш-мимешләр сөйлиләр. Имеш, ул сихерче икән, фәлән икән, дип, капка төбенә кич утырырга җыелган хатын-кызлар үзара рәхәтләнеп ләчтит сата, әнә Шәкүр абзыйны да сихерләгән, янәсе, һич шуңардан аерыла алмый... Хатыны ничек түзә икән, Ходаем...

Хатын-кызлар тирәсендә үз уеннары белән мәш килгән малай-шалай колагына да бу пышылдашулар керә, бугаз тирәсенә әллә нинди шом урләгәндәй була. Бигрәк тә Хәйрүшнең дусты Әбләзнең күңеле иләсләнә иде.

— Шул тол хатын өенә кергәч, сихер йоктырган Шәкүр

абзый, кәҗәгә әверелеп, өстәл тирәсендә сикергәләп йөри икән, — диде ул беркөнне.

— Гел тузга язмаганны сөйлисең, — дип ачуланды аны Хәйрүш. — Каян шундый юк-бар башыңа килә...

— Ышанмасаң, әйдә барып карыйбыз... — Әбләз түбән очка ымлады. — Тәрәзәсеннән...

Караңгы төшкән иде, өй каршында Шәкүрнең җирән алашасы каралып күренә.

— Аның алашасы да сихерле, — дип пышылдады Әбләз. — Чынында ул төрекмән солтанының аргамагы. Ахалтәкин!

Хәйрүш көлеп җибәрде.

— Чын. Исемен генә кара, гади алашага шундый исем кушалармы?

Хәйрүш ирексездән башын кашып куйды, әйе шул, Шәкүр алашасының исеме сәер, моңарчы колакка чалынмаган сүз иде. Шәкүр аңа, иркәләп, «Ширин» дип эндәшә...

Әбләз Хәйрүшнең икеләнгәнен сизде:

— Әйдә, тәрәзәсеннән бер генә күз салабыз...

Хәйрүш, кеше тәрәзәсеннән карап йөрергә ярамаганын белсә дә, кызыксынуын җиңә алмады, Әбләзгә иярде. Алар түбән очка йөгерделәр.

Тик тәрәзәдән берни дә күренми иде. Шәкүр абзый да күренми, кәҗә дә... Хатын гына күлмәклек тукыманы өстенә ябып көзгегә карап тора... Әллә ул Шәкүр абзыйны, сихерләп, күренмәс иткәнме?

Шулчак Әбләз әче итеп кычкырып җибәрде. Хәйрүш борылып караса, артта Шәкүр абзый басып тора, һәм ул Әбләзнең колагын умырып тоткан.

Хәйрүшнең аякларына җил дә иярмәгән иде ул чакта.

— Йә? Шыр җибәрдең мәллә?

Хәйрүш үзенә төбәлгән карашлардан куырылып китте. Татлы хатирәләреннән бүлдергәнгә рәнҗеп, Сундуковка карады.

— Нәрсә?

— Шушы аргамакка атланып ишегалдын әйләнәсеңме, дим, чучмек?

Сөлек кебек шундый сылу атларын нигә биредә калдырды икән Шамил? Нигә үзе белән алып китмәде икән? Оныткинмы? Юктыр, мондый гүзәлләрне истән чыгарып буламыни... Күр әле, бер урында ничек биеп торалар... Киң күкрәкле үзләре, озын муенлы, нәзек сыйраклы... Бу атларның бәясен Шамил белгән, әлбәттә. Дошман кулына эләкмәсен дип атып та калдырмаган. Җәлләгәндер... Фәрештәдәй аргамакларга аның да кулы күтәрелмәгән...

Теге мародер полковник ничек искәрмәде икән болар-

ны? Әллә искәреп тә, урларга курыкканмы? Бу атлар йорттагы вак-төяк кенә түгел шул... Боларны ул, бәлки, берәр генералга дип калдыргандыр...

Аргамакның берсе башын чөеп кешнәп алды. Хәйрүш, уйларыннан бүленеп, сискәнеп китте. Аякларын җирдән кубарып читкә китмәкче булды. Атлану түгел, бу аргамакка якын килергә дә курка ул... Ләкин читкә дә китә алмый. Сундуковтан өркү түгел, шушы атлардан килгән нindидер дулкыннар аны биредә тота, шушылардан килгән серле ис кымырҗып башын әйләндерә.

Шәкүрнең алашасына булса да бер атланып карыйсы калган авылда... Элек бит, имеш, атка менмәгән татарны кешегә дә санамаганнар... Әнә хәзер чеченнар ат өстендә...

Тагын Сундуковның калын тавышы ишетелде:

— Куркак татар!

Шул чакта әллә ни булды Хәйрүшкә... Йөрәге суырылып бугазына тыгылды. Ул, үз-үзен белештермәстән, Шамил аргамагына таба атлады. Җирән чәчле солдат атка инде йөгән кидереп тора иде.

Бер мизгелдән инде Хәйрүш аргамакның яурынын ботлары белән кысып утыра иде. Кемдер аратаны алып атты.

Аргамак арт санын чөеп тышка ыргылды.

Хәйрүш савылып һавага күтәрелгәнен тойды. Аттан аерылды...

Солдатлар йөгереп янына килгәндә, ул суламый иде инде. Йөзе качкан Сундуков аның муен тамырын капшап маташты, беләзегендәге пульсны эзләде. Шул чакта җирдә ул теге бакыр тәрене күреп алды. Күрәсең, егылганда чылбыры өзелгәндер дип уйлады, ике бармагы белән сак кына тотып, тәрене татар малаеның күкрәк кесәсенә шудырды.

Солдатлар, Сундуковка карамаска тырышып, урамга таба кузгалдылар.

Ихатадан чыгып киткән аргамак, ялларын җилфердәтеп, тауларга таба чапты...

## ЯҢГЫР АСТЫНДАГЫ ЯБАЛАК

Кесә телефоным чылтыраганда мин күпердән Казан суына карап тора идем. Офыкта чыгып килгән кояш, канатларын җәеп, корбанына ташланырга әзерләнгән сәер бер кошны хәтерләтә, җил искәндә аңардагы кызыл каурыйлар елга өстенә коелып, су кансыл-кучкылланып ага төсле. Аңа караган саен күңел өшегәндәй була, ул үзенең салкын гамь-

сезлеге белән үзенә тарта, гүя жанны үзенә суыра. Мин кулымдагы кара пакетны елгага ташладым.

Кесә телефоны чылтырады.

Төрепкәдә апаның сулкылдаганы ишетелде. Юеш аваз-лар арасыннан мин: «Җизнәң, җизнәң...» — дигән сүзләрне аралап алдым. «Җизнәңне капка төбендә атып үтер-гәннәр...»

Апа белән җизни шәһәр читендә үзләренең кызыл кир-печтән салынган ике катлы йортларында яшиләр иде. Ан-дый йортлар берничә ел эчендә биредәге җирләргә кан тамчы-лары кебек сибелде. Алар белән бергә телгә яңа сүз дә ки-леп керде — коттедж! Ихатаны әйләндереп алган койма да шундый кызыл кирпечтән. Капка — тимердән! Эчтә нинди тормыш, кемнәр тора — чурт та белә алмый. Янәшәдән үтеп-сүтеп киткән кешеләр көнләшеп тел шартлата инде: нинди бәхетле кешеләр яши бит дөньяда... Иртән тимер капка ачы-лып китә — аннан «күзләрен кыскалап» чит илдә ясалган машина килеп чыга. Ишегалды түрендә бозау кадәр этнең шомлы шәүләсе күренеп китә. Террасада ап-ак урындык-лар күзгә ташлана. Бакчасында чәчәкләр арасында су атып утырган фонтан бүтәннәрнең дә, ягъни әлегә бетон-пыяла арасында җан асраучыларның да бик тиздән оҗмахка тиенә-сен искәртә сыман. Шул хис күңелне тынычландыра: кыла-ныгыз әйдә, кыланыгыз, тегендә нишләрсез менә... Без туп-туры оҗмахка чиратсыз үтеп киткәндә, бөялеп каласыгыз бар әле ишек төпләрендә. Шушы коттеджларга кереп, аның хуҗаларын башларыннан сыйпап юатып та чыгасы килә, хәтта кайбер моңсу көннәрдә. Тик тимер капкалар ябык, ачылсалар да, эчтә бозау кадәр эт шәүләсе... Чылбыр тавышы...

Менә шундый йортта яши иде апа белән җизни. Апа дип эндәшәм инде, ул үзе миннән өч яшькә генә өлкән.

Мин үзем, әлбәттә, апага туганнан туган энекәш, җизнигә каениш буларак, аларга еш килеп йөри идем. Артыграк та еш килгәләдем бугай, бер кичне шактый кызмача кайткан җизни миңа бик озак карап торды да, зәп-зәңгәр күзләрен кыса төшеп, җирәнсу мыегын сыпырып әйтеп куйды:

— Син берәр җирдә эшлисеңме соң, каениш?

Мин, бәдрәф ишегенең элгечен эләргә онытып, малайлык гөнаһы өстендә тотылгандай, эчке калтыравымны басып мыгырдадым: «Җүнле эш табуы кыен бит хәзер, җизни... Студент кешегә бигрәк тә...»

— Син монда күч, — диде ул. — Безнең өй зур, вак-төяк эшне тавык чүпләп бетермәслек. Шәвәлигә булышырсың, алҗый, өлгерми башлады картлач... Әлегә айга йөз доллар түләрмен. Ашау-эчү, торак — минем өстән, кәнишне...

Апа да елмаеп тора. Күрәсең, җизнигә бу акыллы фи-

керне ул биргән инде. «Әйбәт тәкъдим бит, Илгиз», — ди. Нигә әйбәт булмасын... Йөз доллар безнең өчен кечкенә акча түгел. Әйтер идем, зур акча хәтта. Әлбәттә, җизни күбрәк тә бирә ала иде. Черегән бай бит ул. Үзенең зур фирмасы бар... Тик бераз кысмыррак шул... «Яңа байлар» гадәттә шулай кысмыррак була.

Хәер, монысына да шөкер итәргә кирәк. Аяк керсә, башкасы да шуңа иярер әле. Җизнинең күңеленә хуш килсәм... Менә шундый татлы хыяллар белән мин дә ярты ел элек кызыл кирпеч койма артында яши башлаган идем. Читләр бу йортларда бәхетле кешеләр генә яши дип уйлый инде. Анда бай хуҗаларның ярлы туганнары да, ялчылар да көн итә!

Шәвәли мине башта ук өнәмәде. Үзенә көндәш дип уйлады булса кирәк. Ул инде бирегә ныклап урнашкан. Җайлы урнашкан. Үзен чын хуҗа итеп сизә. Үзе генә калганда, билгеле. Ә болай, күзенә генә карап тора җизнинең. Алар бер авылдан. Чыбык очы туганнар да бугай әле. Җизни аңа ышана. Бу да, шул ышанычны аклар өчен, хуҗасының аяк астында тузан булырга әзер. Горурлана җизни белән. Беренче көнне үк миңа хуҗалыкны күрсәтеп йөргәндә, тавышы бөердән чыга, минсиңайтим. Әйтерсең мөлкәт аның исеменә язылган... Шалиш, Шәвәли! Монда барысы да минем апа исемендә... Әйе, туганнан туган апа ия шушы һуш китмәле байлыкка... Әлбәттә, кәгазьдә генә инде. «Яңа байлар» ышанмыйлар хөкүмәткә, чөнки куллары ару түгел, малларын хатыннары, туганнары исеменә яздыралар... Бер-бер хәл булса, алай гына коткарырсың байлыгыңны Рәсәйдә, көт, яме... Ә Рәсәйдә һәрвакыт бер-бер хәл булып тора.

Шәвәли үзен җизни өчен бик җаваплы сизә иде. Яшь барчукны химаягә алган карт лакей сыман еш кына сукранып та йөри, хуҗасын саксызлыкта, зерәгә мал туздыруда битәрли. Җизнине! Кемне-кемне, аны мондый житешсезлектә гаепләп булмый. Куншылык, затлылык, ялтыравыкны ярата инде. коттеджын гына кара! Аңа акча кызганмый, тик берәр хәерчегә бер сум акча биргәне бар микән? Юктыр, юктыр...

Җизни белән Шәвәлинең кыяфәтләре дә охшаш иде. Арча ягында шундый җирәнсу чәчле, сипкелле кешеләр еш очрый. Бик чос бәндәләр...

— Төп эшең монда булыр, — диде Шәвәли, бассейнга күрсәтеп. — Суын алмаштырасың, чистартасың матур гына итеп... — Ул чалбарын күтәреп куйды. — Җаваплы эш... Бирегә кунаклар еш килә, барысының да су коенасы килә матур гына итеп...

Бассейнда яшел су чайкала иде. Зур бассейн... Әйе, икмәкне бай бушка ашатмас...

— Нәрсә терәлеп каттың, әйдә, — дип, Шәвәли чалбарын янә күтәреп куйды. Бил каешы алырга акча жәлләсә, нигә бау гына бәйләми икән соң... Болай азапланганчы...

Бильярд залына кердек, мунчаны карап чыктык. Кышкы бакчаны да күрсәтте Шәвәли. Ул кулында ачкыч бәйләмен әйләндерә-әйләндерә алдан бара, минем алда хуҗасының байлыгын барлый. Күзгә яфракны хәтерләтеп торган йөзенә сыек алсулык йөгергән, күзләре сәер елтырый, борыны йомшаган. Мин аңа ярарга тырыштым:

— Хан сарае да мондый ук булмагандыр, — дидем.

Шәвәли, мыскыллы елмаеп, кулын селтәде.

— Хан сарае пүчтәк. Әле монда шаккатырлык нәрсәләр бар...

Аннары, артыгын әйттем бугай дигән төсле, кисәк кенә кузгалып, биегәндәй адымнар белән хуш исле юкәләр томалап торган күләгәле аллеядан алга юнәлде. Бераз баргач, без кызыл кирпечтән тирмә кебек түгәрәкләп салынган җыйнак кына бер бина янына килеп чыктык. Аны үрмәләп үсә торган ниндидер куаклар чорнап алган иде.

— Бу җорт җанына беркайчан да җакын килмә, — дип, Шәвәли сары бармаклары белән беләгемнән кысып тотты. — Хуҗа җаныңны алыр...

— Нигә? — Мин Шәвәлинең тәртибенә дә, хуҗаның серле таләбенә дә нык гаҗәпләнгән идем.

— Үзем дә белмим, — диде Шәвәли, нигәдер калтыранып. — Төнлә аннан әллә нинди тавышлар ишетелә. — Һәм ул авыр гына атлап коттеджга таба китте. Аңа ияргәнче мин янә теге тирмәгә борылып карадым. Түбә астындагы уемтыдан кемдер миңа карап тора сыман иде.

Ишегалдында безне апа каршы алды.

— Менә егеткә хуҗалыкны күрсәттем, — диде Шәвәли, аклангандай.

— Кухняда сезгә ашарга әзерләнгән, кереп ашагыз, — диде дә апа капкага таба китте.

Турга аксыл «Ауди» килеп туктаган иде. Аннан киң кырлы эшләпә кигән бер хатын-кыз төште. Апаны күргәч, кочагын җәеп алга омтылды.

— Ная, подруга, хәлләрең ничек? Белсәң иде, мин сине шундый сагындым...

— Гуля! Ахирәтем! Ничек шулай килеп чыгасы иттең? Әле генә сине уйлап торган идем. Озын гомерле булырсың, малай...

Алар кочаклаштылар. Гуля, сыңар кулы белән киң кырлы эшләпәсен тотып, апаның яңагыннан чут-чут итеп үбеп алырга да өлгерде.

Шәвәли, үзалдына нидер мыгырдана-мыгырдана, кухня-

га кереп китте. Мин, аяк савытының бауларын чишкән булып, бераз тоткарландым. Кунак хатынны, апаның ахирәтен, якыннанрак күрәсе килде. Нинди «кош» икән?

Алар житәкләшеп миңа таба килә башладылар.

— Әле мин салоннан киләм... — дип бытылдап бара иде кунак хатын, мине күргәч туктап калды:

— Ная! Яңа хезмәтче алдыгыз мәллә? Авылдан китерттең?

Ная, мулла кушкан исеме Нәфисә инде аның, ягъни минем апа (туганнан туган...), кыенсынгандай башын кырынайтып, борын аша назланып чыккан тавыш белән:

— Нинди хезмәтче булсын инде, Гулечка... Энекәш ул минем. Двоюродный... Студент. Айдар бик кыстагач, бездә яшәп алырга булды.

Гуля миңа күзләрен тутырып карады. Хәер, аңа күзләрен тутырасы да юк, алар болай да түм-түгәрәк. Кәкерерәк борынлы, түгәрәк йөзен каймалап торган сумаладай чем-кара чәчле бу хатын гаҗәеп рәвештә ябалакны хәтерләтә иде. Бәбәк төпкелендә уйнаган кара ялкын мине өтеп алгандай булды.

— Айдар үзе чакырдымыни? Бассейнны чистартып торырга кеше кирәк, дип сөйләнгән иде шул. Аның шундый берәр тумача булуы әйбәт тә әле... — Хатын миңа карап елмайды. — Бик аппетитный туган. Мускулистый.

Апаның йөзенә кан йөгерде, ул ахирәтен террасага, ак урындыкларга әйдәде...

— Юлда бик сусамадыңмы, Гуля, чәй эчеп алыйкмы?

Тик кунак хатын кузгалырга ашыкмый иде булса кирәк, һаман мине күзе белән ашады.

— Оялма син, Ная. Дело житейское. Шундый энекәшең белән мактанырга кирәк. Ә син аны бездән качырып яткырасың... Авылдан килеп туп-туры укырга кердеңме? — дип миннән сорады ул.

— Армиядән соң... — дидем мин, сүзне теш арасыннан сыгып.

— Чечняда булгансыңдыр әле, бик боевой күренәсең...

Мин аяк савытларыннан котылган идем, ишеккә атладым, алар террасага юнәлделәр. Үзара ни турындадыр сөйләшәләр, көлеп куялар, әлбәттә, борылуга ук минем турында онытканнар иде... дип уйлап ялгышканмын мин. Болар заты берни турында да оныта торганнардан түгел икән. Моны аңлар өчен миңа күп вакыт кирәк булмады.

Мин кергәндә, тирләгән чыраен кызыл тастымал белән сөртә-сөртә, авызы белән шаулап, Шәвәли кайнар шурба чөмереп утыра иде. Урман кисеп кайтканмыни! Ул мине искәрмәде дә, күзләре мие эченә үк кереп киткән кебек тоелды. Бер кырыйга чүмәшеп, кашыгымны авызыма китергәндә,

минем босс, шурбадан бушаган тәлинкәсен ялап куеп, кыздырылган сарык итенә ябышкан иде.

— Менә шулай, — диде ул бераздан, суынган чәен уртлап куйды. — Аузым билләһи... — Аннары тәмләп кикерде, урындык аркасына кырын төшеп, миңа кызыксынып карады. — Җылы җиргә урнаштым диген, ә... матур гына итеп.

Мин, берни дә эндәшмичә, кайнар шурбаны болгаттым.

— Ә теге хатын, Гөлсинәне әйтүем, көнаралаш килмичә калмый ул... матур гына итеп... Чибәр, каһәр, ә... Нәфисәнең сердәше. Ну хуҗа аның монда килүен бер дә яратмый. Бүген тагын тавыш чыга инде матур гына итеп... Хуҗа кызганда син аның күзенә күренмә инде. Алла сакласын... — Ул, өстәл янынннан торып, ишеккә таба китте. — Савыт-сабалар шунда калсын. Апаң җыештырыр.

Апаң дигәне аның хатыны иде булса кирәк. Тик әлегә кадәр минем аны күргәнем булмады. Чыгып киткәндә, Шәвәли башын минем якка бормыйча гына боерыгын бирде:

— Ике сәгатьтән бассейнның суын алмаштырырсың матур гына итеп.

— Баш өсте, командир, — дидем мин аңа. Ул ыштанын күтәреп куйды да, бүтән сүз әрәм итмичә, үз юлы белән китеп барды.

Әппәр итеп урыннан кузгалган идем, ак яулыгын җәеп бәйләгән, гади генә ак ситса күлмәк кигән бер хатын, тавышсыз гына әллә кайдан пәйда булып, өстәлне җыештыра башлады. Үзе әледән-әле миңа карап ала. Әллә кызганып карый шунда, шайтан белсен... Карчыклар шулай үз балаларын искә төшерүчән. Булганнарын да, булмаганнарын да...

— Улым, үз теләгең белән килеп каптыңмы монда? — дип капылт кына сорап куйды ул.

Ни әйтергә дә белмичә, мин нидер мыгырдап куйдым. Әллә «әлбәттә» дидем, әллә «кәнишне» белән генә котылдым.

Шәвәлинең хатыны шушы буладыр инде, мөгаен. Бу дөнья кешесе түгел иде ул, күренеп тора. «И дөнья» дип уфтанды да миңа җылы күрән карашын төбәп катып калды. Ул караштан котылырга теләп, кузгалмакчы булдым, әмма аягым тотмады. Бераздан ул кайдандыр намазлык алып җәйде дә сәҗдәгә басты, ачы тавыш белән ниятен белдерде: «Илаһи, ният кылдым икенде намазының дүрт рәкәгать фарызын укымакка, йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына, халисан лилләһи тәгалә...»

Кайдан мондый үтеңне сытарлык тавыш арык кына гәүдәдә? Ниһаять, мин, аякланып, тамагыма бөялгән шом койкасын тизрәк йотарга теләп, һава суларга ашыктым.

Ә анда исә апа, үзенең кунагы белән җитәкләшеп, юкәләр күләгәсеннән бакча түренә таба китеп бара. Алар нидер сөйләшәләр, көлешәләр... Бик бәхетле күренәләр иде.

Эшемне тәмамлап, бүлмәмә кереп ятканда, караңгы төшә башлаган иде инде. Бүлмә кечкенә, җыйнак — икенче катка менә торган баскыч астына урнашкан, мондагы барлык җиһаз — карават та өстәл, бер урындык. Шулай да үз почмагың булу рәхәт ул. Сөякләрне шыгырдатып, караватыма сузылдым. Өстәлдәге бер китапны алып, битләрен генә актара башлаган идем, кайсы төштән укып китсәм кызыграк булыр икән, янәсе — өстә ниндидер тавышлар ишетеп, әлеге нияттән баш тартырга туры килде. Билләһи газим, талашалар түгелме? Талашу гына түгел, кыйнашалар да шикелле — нәрсәдер стенага бәрелеп чәлпәрәмә килде. Кемнәр шулай гауга куптара? Кемнәр дип, анда — өстә апа белән җизни генә булырга тиеш инде. Димәк, тату тормыйлар. Әчеп кайтып, җегетлеген күрсәтүчеләрдән түгелдер ич җизни дигән кешебез? Менә, әптери, ыштанымның ычкыры да өзелде, дип әйткән, имеш, чарасыз калган бер хатын... Миңа нишләргә? Ишетмәмешкә салышып, йоклаган кешедәй ятаргамы, әллә апаны аралаган кыяфәт ясаргамы? Мин монда кем? Бернинди хокуксыз хезмәтче генә бит инде, уйласаң... Аннары, ир белән хатын арасына керергә Ходай язмасын. Алар төнлә дуслашырлар, төн дуслаштыра! Ә мин икесенә дә дошман булып калырмын. Аягың кергәнче үк бу йорттан очып чыгуың да бик тиз ул чагында.

Йоклый торган бүлмәләренә генә сыясы итмәделәр — әллә ишек шәрран ачылды, әллә үзләре дә чәчрәп чыкты, җизнинең чатнаган тавышы колак төбендә үк ишетелгән сымак: «Ничә әйттем икегезгә дә, мин юкта аның эзе дә булмасын дип монда!» Апаның сулкылдап елаганы ишетелә иде. «Йөрәгемә тиеп елап тормасана...» — һәм нидер чалт итте. Әллә яңагына сукты инде? Ул арада бөтен өйгә апаның ачыргаланып кычкыруы яңгырады: «Ах син, иблис! Әҗәткана! Тагын кул күтәрәсеңме? Милициягә барып, бүтән тырнагым белән дә чиртмәм, дип кул куеп кайтканыңны оныттыңмы? Мин сине... мин сине... аяк-кулларыңны да җыеп алмаслык итәм әле...» Тагын нәрсәдер пыран-заран килде... «Нишләтерсең? — дип кычкырды җизни. — Миңа кул күтәрәсе кеше әле тумаган. Тагын шул ябалагың котыртамы миңа каршы? Агулы телен кай төшләреңә тыга?» — Апа иренә очып кунып битен тырнады, ахрысы, җизни балачагадай чинап җибәрде.

Ишек артында аяк тавышын ишетеп, тиз генә стенага таба борылып яттым. Мине борчымагыз, янәсе, пажалысты,

мин күптән инде матур төшләр күреп ятам. Бердәнбер урындыкка килеп утыруга ук, апа кесә телефоныннан номер җыя башлады. Әллә милициягә чылтырата инде, нәгаләт. Юк икән, «Гуля, Гуля! — дип кычкырды ул төрепкәгә. — Тагын теге буза куптарды. Кул күтәрә. Нишлим, җаным, түзәрлегем калмады бит... Кемнәргә генә барып сыеныйм. Синнән башка бер якын кешем дә юк бит бу шәһәрдә. Әйт бер сүз, иркәм... Хәзер киләсеңме? Ю-у-ук, үз-үзен белештерми ул, йә икебезне дә сугып үтерер... Ә? Ярар, алайса...»

— Йокламыйсың ич, ник кыланып ятасың, — диде апа. Тавышы тып-тыныч иде, әйтерсең лә әле генә ире белән пыр тузып кыйнашмаган да, әле генә ахирәтенә тормышыннан зарланып, җан авазын саркытып ярдәм сорагандай чылтыратмаган...

— Армиядән дә җегет булып кайтмагансың, — дип сүзен дәвам итте ул. — Кыз туганыңны үтерә яздылар, ә син үз почмагыңда дерелдәп ятасың...

Мин, уңайсызланып, караватымнан күтәрелдем. Апа өстәлгә терсәге белән таянган да яшел күзләрен миңа батырган. Җирән чәче тузгыган, халатының уң җиңе умырылып чыккан, аскы төймәсе йолкынган, итәге арасыннан шәрә ботлары күренеп тора — алтын тарагын эзләргә чыккан су анасы диярсең үзен! Чибәр иде апа!

— Чынлап та йоклаган идем, — дип ялкау гына ялганладым мин. Сүземне җөпләп күземне дә угалап куйдым.

— Шундый тавышта да йоклый алгач, нервыларың әйбәт икән...

— Нинди тавыш? — дигән булдым.

— Гуляның безгә килүен бер дә яратмый җизнәң. Үзәккә үтте инде тәмам. Мин дә кеше ләбаса, монашка мәллә мин берүзем монда ябылып ятарга?

— Берәр эшкә урнаш.

— Рөхсәт итми. Аннары... минем бит бернинди белгечлегем юк.

— Һи, аптырагансың... — Мин караваттан аякларны салындырдым. — Хәзер яхшы эшкә урнашыр өчен бернинди белгечлек кирәкми. Арттан тәртүче булса...

— Холкы тәмам бозылды, — дип, апа йомшаган борынын тартып куйды. — Гуляга нинди ачуы бар инде, йә?

— Нинди хатын соң ул?

— Бик яхшы кеше. Мин аның янында бөтен дөньямны онытам. Ансыз яшәвем яшәү түгел.

— Син бигрәк инде... Бәлки, җизнидә дә хаклык бардыр...

— Артык узынса, атып китәрләр әле...

Күзем маңгаемдагы чәч бөртекләрен капшап алгандай булды.

— Җүләрләндең мәллә?

— Соң... аптыраганнан әйтәм инде. Аларны кәнараланп чүкеп торалар бит. — Ул минем кыяфәткә карап усал елмайды. — Шыр җибәрмә, егетем, аның кебекләргә бук та булмый, — диде. — Әле үзе ул мине кабергә тыгачак. Шәвәлигә кушса...

Шул чакта ишек ачылды да, бусагада җизни күренде. Ул минем якка карамады да, — гүяки каенише аның өчен дөньяда бөтенләй юк! — эчке бер калтыравык аваз белән әйтте:

— Йә, нишләп монда җәелеп утырасың? Әйдә үзебезнең бүлмәгә!

Апа башын читкә борды.

— Хәзер Гуля килә. Аңлашырсыз...

Җизнинең ясалма елмаюы агарган йөзенә ябышып калды. Һич көтмәгәндә ул апа каршында идәнгә тезләнде, симез куллары белән хатынының ботларын кочты.

— Иблис ул синең ябалагың! Бәла китерәчәк ул безгә, әйтте диярсең менә... Әйдә, җаным, әйдә өскә... Оныт барысын да...

— Җүләр син, Айдар...

Мин инде чыгып китәргә дип кузгалган идем, ишекне каерып ачып бүлмәгә Гуля килеп керде. Апа белән җизнине күргәч, пычак ярасы кебек кызыл авызы бер якка кыйшайды:

— Ә монда полная гармония!

— Син? — Җизни торып тезләрен каккалаган арада, мин бүлмәдән чыгып, тизрәк тышка ашыктым. Нигә сулыш җитми бу йортта? Капка төбенә чыгып, бүген үзем әтмәлләгән эскәмиягә утырып, күккә карадым. Анда бетчәләр кебек аксыл башлы йолдызлар сибелгән иде.

Апаның сүзләре канымны кузгатып җибәрде. Ная... Менә бит күңелендә нинди уйлар йөртә икән ул... Кызхатын, ирен үтерергә ниятләп, төн буена җиде кат уяна, дип әлгәреләр юкка гына әйтмәгәннәрдер...

Ятак бүлешкән, бергә ризык җыйган ирең турында авыз тутырып шундый сүз әйт инде, йә... Гуляның килүен яратмый, янәсе. Яратмаса да хакы бар. Сиңа ир кадерлерәкме, теге ябалакмы? Шайтан алгыры, үз-үзем белән сөйләшә башладым түгелме соң?

Һы... Менә нинди кеше икән ул минем апа. Ная!

Хәер, хатын-кыз ни сөйләмәс, яши-яши күрербез.

Миңа таба кемнәрдер йөгерә-атлый килә иде, капкага сеңебрәк утырдым. Монда караңгы, искәрмәсләр. Урамга ике шәүлә суырылып чыкты. Җизни белән Гуля бит бу!

— Тукта, Гуля. Аңларга тырыш мине, — диде җизни гыжылдап. Җәяү йөрүдән сулышы капкан, ахрысы.

Гуляның тавышы янаулы чыкты:

— Наяга тагын бер кагылсаң... Ты знаешь мои возможности...

— Көнләшәм бит, Гуля. Син һаман Ная белән... Кешеләрдән оят...

— Шымчыңны азрак тыңла. Мин сине кисәттем.

Җизни, Гуляны кочаклап, битеннән, кулыннан үбә башлады.

— Кичер, кичер, Гуля. Әйләндердең башымны... Синең өчен үләргә әзер...

Гуля тавышсыз гына көлде:

— Үләрсең дә... Исәр... Мин дә сине яратам бит... Үземчә сөям...

Алар чупыл-чупыл үбешә башладылар. Бераздан:

— Җитәр, — диде Гуля. Нигәдер киемнәрен кагып алды да агарып күренгән машинасына таба китте.

— Наяга сиздерәсе булма! — диде ул, борылып.

Җизнинең бугазыннан ыңгырашкан аваз гына чыкты. Машина төн караңгысына сеңде, җизни капкадан кереп югалды. Бераз көтеп торгач, мин дә йортка таба киттем. Каршыма Шәвәли килә иде. Ышкылып диярлек үтсә дә, ул мине күрмәде.

Аякларым үзеннән-үзе мине юкәләр арасыннан бакча түренә алып китте. Түгәрәк таш бинага җитәрәк мин туктап калдым. Бу юлы ул борынгы бер төрбәгә охшап калган иде. Түбә астындагы уемтысында кемнеңдер ап-ак чырае чагылып киткәндәй булды.

...Мин коттедж янына килеп җиткәндә, җизнинең мәетен алып киткәннәр иде инде. Асфальтта тикшерүчеләр акбур белән сызган гәүдә контурын күргәч, сискәнеп киттем — ул каядыр очарга ымсынган сәер бер кош сурәтен хәтерләтә иде.

Яшь кенә бер егет миңа борылды:

— Сез кем буласыз?..

— Каенише.

Ул бүтән берни дә әйтмичә мине сынап карады да тагын бер иптәше белән эчкә үтте. Мин дә аларга иярдем. Бакча түрендәге түгәрәк бина янына ничек килеп җитүебезне мин хәзер анык кына хәтерләмим дә. Дөресрәге, нindидер ябышкак төш кебек истә калган ул.

Йорт тирәсенә нindидер кошның исәпсез каурые сибелгән, ә тупсасыннан каерылган ишек төбендә Шәвәли чалкан ята иде. Аның баш тирәсенә җыелган канны күргәч, мин, укшуымны тыеп, читкә борылдым.

— Яра лепкәсендә, — диде тикшерүче. — Әйтерсең нидер чукып алган... Сәер...
— Болай чукыр өчен тимер томшык кирәк, — дип, иптәше бинага кереп китте. Ниндидер көч мине дә шунда этте.
Без икебез дә бусагада туктап калдык. Ярым караңгы өй эчендә ниндидер яу үткән сыман иде — өстәлләр, урындыклар ауган, ниндидер калын китапларның битләрен умырып почмакка ташлаганнар. Идәндә чәлпәрәмә килгән ярымайлар, йолдызлар, сынган тәреләр ауный. Аяк астындагы урталай ярылган саргылт бозау сынын бер читкә этәреп, тикшерүче сызгырып куйды.
— Музей булганмы соң бу?
Бер сүз дә әйтмичә, мин әлеге сәер бинадан чыгып киттем. Апаны юатырга кирәк иде.
Кичкә таба Шәвәли хатынының эзсез-нисез югалуын белделәр.

...Көннәр көзгә авышты. Бүген иртәдән үк яңгыр сибәләп тора менә. Сибәли дә сибәли. Кызгылт-сары яфракларның шыбырдавы күңелдә әллә нинди моңсулык уята. Шәвәли үлгәч, мин инде монда чын хезмәтчегә әверелдем. Ихтыярымнан тыш кыл да селкенми. Хатын-кызларга буйсыну сәләте бар икән миндә... Азрак сөйләп, күбрәк тыңлап йөрсәң, хуҗаларның күңеленә хуш киләсең... Ная да, Гуля да санга сугалар үземне...
Яратам шундый көзге мәлҗерек көннәрне. Коелган яфракларны яндырырга дип учак ягып җибәрдем. Төтеннең, яңгыр исенә кушылып, борын эчен кытыклавы рәхәт. Апага да ошый сибәләп яуган яңгыр астындагы төтенләп торган учак. Уты күренми, ә төтене бөтен бакчага тарала!
Әнә зонтик тотып үзе дә килеп чыкты. Кызыл курткасы, сыланып торган джинсы чалбары нинди килешеп тора...
— Гуля бүген килми, — диде ул. — Ә без хәзер зиратка барабыз. — Минем сораулы карашымны искәргәч, өстәп куйды: — Җизнәңнең дуслары чылтыратты, каберенә таш куйганнар. Барып карарга кирәк.
Мин, кулымдагы тырманы ташлап, кием алмаштырыр өчен, өйгә кереп киттем.
Гуляның бүген килмәве сәер әле. Ул көн саен монда, апа янында кайнаша. Булса да булыр икән дөнья йөзләрендә шундый кайнар дуслык...
Җизнине бик кадерләп озаттык без соңгы юлга. Яратып күмделәр. Җеназасында сиксән ике машина санадым. Әле нинди машиналар диген! Җизни, тере булса, үз үлеменә үзе горурланыр иде.
Кабере дә бик уңайлы урында. Зиратның төп капкасын-

нан кергәч, сул якка гына борыласы. Анда вакытсыз гомере өзелгән «братва» бер-бер артлы тезелеп киткән.

Без килеп җиткәндә яңгыр сибәли иде әле. Кемнеңдер мәете тирәсендә биш-алты кеше кайнаша. Бәхәсләшәләр бугай: зиратка кергәндә мәетнең башы алда булырга тиешме, аягымы? Наданнар өчен мәңгелек бәхәс.

Җизни каберенә җитәрәк, апа капыл туктап калды. Минем дә гаҗәпләнүдән авызым ачылды бугай. Таш зур иде. Янәшәдәгеләрдән бер башка калкып тора. Ә таш янындагы эскәмиядә, канатларын салындырган иләмсез кош сыман, Гуля утыра... Үзе тавышсыз гына үкси иде сыман.

Апаның битенә кызыл тимгелләр җәелде. Ул, нәрсәдер әйтергә теләп, авызын ачкан иде дә, кире уйлады булса кирәк, борылып, йөгерә-атлый зират капкасына таба китте. Мин аны куып җитеп, зонтикны баш өстенә күтәрдем.

Яңгыр көчәйде, көрсенгәндәй нindидер сырхау җил исеп куйды. Капкадан чыгар алдыннан мин янә каберлеккә күз ташладым. Зират өянкеләренә соры канаты белән кагылып шыксыз ябалак күккә күтәрелде.

## ҮКСЕЗ

Вокзал каршындагы скверда кеше бик күп түгел иде. Фәния шундагы бер эскәмиягә килеп утырды. Кочагындагы сабыена тагын бер яратып карап алды. Кызгылт чыраен дөньяга сузып изрәп йоклый нарасый. Ара-тирә тешсез авызын бөрештереп ала. Хәер, алда ике теш чыгып та килә инде. Үсә, үсә балакай. Күп тә үтмәс аякланыр, нәни тәпиләре белән теркел-теркел йөгереп китәр әле, Алла боерса... Исән генә була күрсен берүк.

Каршыдагы эскәмиягә яшькелтләнә башлаган, өстәвенә күптән кайчы да күрмәгән сакал-мыеклы, пеләш башлы бер карт килеп чүмәште. Ул төсе анык булмаган плащтан, киң якалы күлмәге өстеннән зур төене каешланып беткән галстук та тагып куйган әле, җитмәсә. Фәниягә игътибар итми генә карт чүпрәк букчасыннан — кара! букчалары аларның бер үк төсле икән бит! — ипи кисәге алып өстенә арзанлы сыр каплады, тоз сипте, шул ярлылар ризыгын гәҗит өстенә куеп, — ә гәҗит «Ватаным Татарстан»! димәк, әлеге карт та, кыяфәтенә карамастан, үз татарымыз булырга тиеш... — букчадан, әфсен-төфсен әйткәндәй, кызыл шәраб шешәсе тартып чыгарды. Карт бәхетле иде! — шешәне авызына китергәнче үк күзге кояшта калган бәрәңгедәй бит алмалары

шәмәхәләнеп чыкты, күзеннән нур чәчрәгәндәй булды, шәраб тамагына коелганда исә бугаз төеренең биеп алуы абзыйның бөтенләй җиденче кат күккә күчеп алуын аңлата иде. Кешегә бәхетле булыр өчен күп кирәкмени? Ярты шешәне бераз бүлтәеп торган бүксәсенә урнаштырып куйгач, карт сыр каплаган ипине тәмләп ашый башлады.

Фәния авызына җыелган селәгәен йотты. Үзе дә сизмәстән янәшәсендәге букчаны капшады. Әллә ул селкенгәнгә, әллә тамагы ачып, — мөгаен, шулайдыр, баланың кендеге өзелеп бетми, ахрысы, ниндидер күренмәс җепселләр аны анасына тоташтырып тора, — сабый да аваз бирде. Аваз бирү генәме соң, җете кызыл аңкауларын күрсәтеп елап та җибәрде. Ачыргалана бәгырь кисәге... Каршыдагы сукбайга бала тавышы ошамады булса кирәк, тиз-тиз генә ризыгын җыеп, ул каядыр китеп тә югалды.

Фәния, марляга төрелгән ипи кисәген төкереге белән чылатып, сабыеның авызына каптырды. Тегесе башта бик теләмәсә дә, — чыраен сыткан була бит әле чын кеше кебек! — ачлык үзенекен итә, чупыл-чупыл итеп ипине суыра башлады. Нишләсен Фәния, сөте аз шул, җитми имезергә көн буена...

Үзе дә бер телем икмәк алып авызына капты. Ипи дымлы иде, әчкелтем иде...

Күк йөзен иртәдән бирле соры болыт баскан, түбәнәеп калган гөмбәз җанны изеп тора сыман. Яңгыр да юк; яуса хет бушанган болытлар бер-берсен куып каядыр китеп югалыр иде. Ә болай... томалап алдылар бит дөньясын, кояшсыз калдырдылар.

Әледән-әле поездлар үтеп тора. Еракка бара торган поездлар... тәрәзәләреннән бәхетле чырайлар күренеп калган сыман. Һәрхәлдә, Фәниягә шулай тоела. Андый поездларга бәхетле кешеләр генә утыра торгандыр, каядыр китәргә, каядыр ашыгырга лаек кешеләр.

Хәер, Фәния дә Арча поездын көтә. Авылына кайтып китмәкче ул да... Арча ягына электричкалар сәгать саен диярлек йөреп тора да, Фәния генә сәфәрен һаман суза... аягы тартмый.

Йә, кем янына кайта инде ул? Кем аны сагынып, тансыклап көтеп тора? Шул бердәнбер юл — үги анасы янына кайтып егылса гына, бер якын туганы да юк бит аның авылда. Ятимә, тома ятимә... Иш өстенә куш дигәндәй, тагын бер ярты ятим куенында...

Бусагасыннан атлатырмы әле үги ана... Ике ел элек шуның агулы теленнән, келәшчә кебек тимер бармакларыннан котылыйм дип килгән иде ич Фәния Казанга. Дөресрәге, үги ана үзе бер юмалап, бер төрткәләп җибәрде аны Казан

тарафларына. Янәсе, аның чыбык очы туганын бандитлар үтергән, ә шул туганның хатыны ялгызлыктан интегеп, кайгыдан саргаеп зар-интизар булып яшәп ята, шуның хәленә керердәй бер җан иясе кирәк икән. Шундый җан иясе булырга Фәниядән дә кулай кем бар тагын? Гомер буе ашатып ятмас бит инде аны үги анасы. Үз көнен үзе күрергә вакыт. Әлбәттә, тол хатынның хәленә керер өчен ике катлы йортны җыештырып, керләрен юып, тагын кырыкмаса-кырык мәшәкатькә ия булып торачагын әйтеп тормады үги ана. Әйтмәсә дә, унҗиде яшьлек кыз аңларга тиеш иде — кайгы уртаклашыр өчен генә кем авылдан кеше алдыра? Әй, болар турында уйлап тордымы соң инде Фәния. Булсын, әллә нинди михнәт булсын, нәни чагыннан ук кулыннан эш төшмәде бит аның...

Әнисен бөтенләй хәтерләми Фәния. Әтисе дә ниндидер томанлы төш сыман гына истә калган. Аны урманда агач басканда, кызга әле дүрт яшьләр генә иде. Җеназасында авыл халкы тома ятимә калган Фәнияне кызганып елады. Ул ике яшьлек сеңлесен — үги әнисенең үз кызы! — җитәкләп капка төбенә чыгып баскан иде. Соңрак ул сеңел белән җык күргәннәре Фәниянең... Еладылар кызганып... еларга безнекеләргә куш... аннан һәркем үз эше белән кайсы кая таралды. Фәния калды күзгә-күз үги ана белән...

Бардыр, бардыр шәфкатьле үги аналар да, дөньяның әллә кемнәре бар. Тик Фәниягә андые тәтемәде шул. Фәниягә әкиятләрдә сөйләнгән явызы эләкте. Һи, хәзер аның нәрсәсен искә төшереп торасың инде. Тик менә хәзер шунда кире кайтасы ич. Әтисеннән калган йортка да... әмма сыяр микән? Үзе генә дә түгел бит... Атасыз бала белән...

Хатынның колагы чыңлап китте. Үги әнисенең: «Уйнаш! Уйнаш...» — дип ачы тавыш белән кычкырганы ишетелгәндәй булды. Кычкырып кына калса әле... Сеңлесе дә һич кыенсынмыйча мыскыл итәчәк. Фәниянең кулында үссә дә, санга сукмады ул аны... Үз өендә дә хезмәтче генә иде шул үги кыз.

Казанда аны ачык чырай белән каршыладылар анысы. Кызыл кирпеч койма белән әйләндереп алынган йортны күргәч, моңарчы авылдан читкә чыкмаган кыз артына авып китә язды... Шулай да яшәп була икән, малакаем. Ул хуҗа хатынның кыяфәте... Төз гәүдә, ачык яшел күз, әз генә чөенке нәни борын... Сары-җирән толымнары баш түбәсенә бөҗра булып җыелган... Үзе ачык шундый — кулына сыңар төенчек кенә тоткан аксыл ситса күлмәкле ятимәне ярым кочаклап ишеккә таба алып китте.

— Каушама, наным, борчылма берүк, бик әйбәт яшәрсең бездә... Мин Нәфисә апаң булам.

һич көтмәгәндә юкәләр арасыннан бер ир-егет килеп чыкты. Ап-ак тигез тешләрен җемелдәтеп елмайды:

— Нигә борчылсын... Ашау — байдан, үлем — Ходайдан монда... Хуш киләсең, сылукай.

— Илгиз, оялтма яшь кызны, — диде Нәфисә апасы, юри ачулангандай.

Чыннан да, Фәниянең йөзе кып-кызыл булып чыккан иде — артык ак тәнле шул ул, ак тәнлеләрнең кызаруы да бөтен дөньяга кычкыра. Борын өстендәге сипкелләре дә зурайган сыман булды егетнең күз карашыннан. Шул ук вакытта кыз тулышкан ими очларының кытыкланып куюын да искәрде.

Илгиз уртача буйлы, кара-кучкыл чырайлы, кәкрерәк борынлы егет иде. Ә күзе утлы күмер кебек көйрәп тора. Кызның йөреше алмашынды хәтта. Ярый әле Нәфисә апасы җитәкләгән...

Әйе, әйе, егетнең күз карашында шайтаннар сикерешеп уйный иде. Нигә шулай тиктомалдан сикерешкәннәрен дә Фәния аңлый иде... аңламыйча... Бөтенләй үк томана түгел ич ул. Кинәт күз алдына шыксыз булып, әкияттәге дию пәриедәй зураеп күршеләре Хәмит килде. Фәниянең әтисе үлеп күпмедер вакыт үткәч ияләште ул алар йортына. Төн җитүгә килеп җитә — кызлар йоклаган дип уйлыйдыр инде! Аннары чаршау артында үги анасы белән ах-ух, чупыр-чупыр киләләр... Үсә төшкәч аңлады Фәния дә әлеге авазларның ни аңлатканын, тыңлап ятуы хәтта күңелле дә иде бераздан. Җитмәсә, урамдагы дусы-дошманы да Хәмитнең аларга бөтенләй үк ят кеше булмавын искәртергә генә тора. Нишли ала Фәния? Әлбәттә, эчтән күралмый ул Хәмит кабахәтне... Бөтен ир бәндәсен күралмый. Алар барысы да берәмләп мәрхүм әтисенең урынын яулап алганнар сыман гүяки... алар әнә йөри җиргә нык басып, төн җитүгә капка кага... Ә әтисе юк, юк мәңгегә!

Хәмитнең адымнары белән атлый иде Илгиз дә. Шундый ук сак, шундый ук ышанычлы, шундый ук куркыныч бөркелә иде ул адымнардан — аучыныкы! Илгиз аңа таба якынлашканда, Фәния әлеге куркынычны аерата сизә иде: аның аяк буыннары йомшара, сулышы ешая, йөрәк кайядыр корсак төбенә төшеп тибә башлый... дәһшәт... тик ул беркая да кача алмый, алай гына да түгел, шушы халәт нииндидер ләззәт тә бирә сыман.

Илгиз дә бу җирдә яшәргә яратылган җан иясе, яшәргә, бүтәннәр белән идарә итәргә, үзенә дигәнне беркемнән сорамый гына алырга... Алар, алар хуҗа бу сәер җир йөзендә, бу дөньяның куласасы алар өчен әйләнә, һәм ул куласаның ничектер адашып әлеге арбачыларны басачагы, юк, күз ал-

дына килми иде. Хәмитләр, Илгизләр монда, алар канаты астындагы үги әни, Нәфисәләр биредә, ә аны яклый алырлык әтисе сыя алмады дөньяга...

Ә Фәниянең әле яшисе бар... кешечә бераз җан асрыйсы килә иде... тик бит ул берьялгызы — гаҗәпмени, шул каты куллы, төмсә күзле идарәчеләрдән күпме генә качарга тырышма, ирексездән шуларга ук тартыласың: алар — дөнья тоткалары!

Хатын-кыз шул аерым гына, җайлап кына яши алмый үз башына бүгенге көндә, җиле бар, зилзиләсе бар дигәндәй, үсентегә дә, хәтта авып харап булмас өчен янәшәдә бер терәү кирәк.

Икенче катка менә торган баскыч астындагы нәни генә бүлмәдә тора иде Илгиз. Югыйсә ул әлеге зур йортның теләсә кайсы — Нәфисәнекеннән башкасында, әлбәттә, — бүлмәсендә корсак киереп яши ала. Кеше сәер бит ул, күрәсең, ние беләндер кадерле булгандыр әлеге бүлмә Илгизгә. Шулайдыр. Хәер, кайбер кеше бер урынга күнегә дә, шуннан һич күчәсе килми. Шулай да була...

Икенче катка нигә менәсе итте икән ул көнне Фәния? Көне буе анда-монда йөгерәсең — зур йортта кырыкмасакырык эш, тавык чүпләп бетермәслек... Әлбәттә, баскыч астындагы бүлмә кырыннан да йөз тапкыр узасыңдыр көненә. Ә болай Фәния йортның икенче ягында — аерым ишектән керә торган түшендә куна иде.

— Кер әле монда, — дип, аны Илгиз үз бүлмәсенә алып керде. Күзе сәер ялтырый, авызыннан ниндидер затлы коньяк исе — ә Фәния андый исләрне аера башлаган иде!

— Юк, юк, юк... — дип үрсәләнде кыз. — Зинһар, харап итмә, Илгиз абый... Илгиз...

— Мин сине бәхетле итәм, юләр, — диде егет.

Соңыннан, киемнәрен рәтләгәч, Фәния аңа карап утыруында булды. Аныңча, егет аңа ниндидер мөһим сүз әйтергә тиеш иде кебек. Илгиз исә трусиктан гына... калак сөяге өстендә ниндидер сәер шәмәхә рәсем бар... тәрәзәгә карап тора.

Шактый озак шулай тордылар тәсле.

— Йә, нәрсә терәлеп каттың, — диде Илгиз бераздан, ачусыз гына. — Эшеңдә бул.

Фәния дәшми-тынмый гына чыгып китте. Шуннан соң ул, көн саен диярлек, Нәфисә апасына сиздермичә генә, баскыч астындагы бүлмәгә кереп чыга башлады.

Шулай бер керүендә ул башын Илгизнең күкрәгенә куеп елап җибәрде...

— Чү... — Илгиз аның башын читкә этәрде.

— Безнең балабыз булачак...

Илгиз чәчрәп урыныннан торды.

— Ахмак! Хәзерге заманда... Саклана да белмәдеңме... — Аннары ул тынычланып урынына утырды. — Ярар, балабыз сыкма. Хәл итмәслек проблема түгел.

— Мин аборт ясатмыйм.

— Нәрсә? Син әллә нинди сүзләр беләсең... — Илгиз хахылдап көлде. — Прогресс! Алайса, үз проблемаң, үзең хәл итәрсең. — Һәм ул бармагы белән ишеккә күрсәтте.

— Илгиз!

— Аттыр моннан! Әгәр дә минем исем белән авыз чайкасаң, башыңны өзеп күтеңә тыгармын.

Фәния ышанды — Илгизнең күзләре алдамый иде.

Берничә көннән аны Нәфисә чакырды. Исәнлек-саулык та сорамыйча:

— Ишеттем, ишеттем, — диде. — Ышанычымны акламадың, наным. — Нидер әйтергә теләгән Фәнияне ишарәсе белән туктатты. — Менә сиңа юллык акча... Бүген үк авылыңа кайт. Арча поездына әле өлгерәсең... — Ул, сул беләген матур бөгеп, нәни алтын сәгатенә карап алды: — Әйе, өлгерәсең... Миңа лишни проблема кирәкми.

Фәния инде бу сүзне көн дәвамында ишетә иде, башын иеп ишеккә таба кузгалды.

Кабан буеннанмы, каяндыр килгән азан тавышы яңгырады. Фәния иреексездән күккә күтәрелеп карады, тик анда болыт кисәкләреннән башка берни дә күренмәде.

— Сиңа ялгызыңа бала үстерү авыр булыр, — диде Илгиз. — Без гомер юлын бергә үтәргә тиеш.

— Мин көттем, көттем, — дип шатланды Фәния. — Мин ышандым, синең ташламавыңа ышандым.

— Мине беләсең... Мин сүземдә торам...

— Балабыз шундый сиңа охшаган!

— Кемгә охшасын тагын... Әтисенә охшамыйча... — Илгиз көлде.

— Арча поезды хәзер килә. Әйдә, башта авылга кайтып килик. Авылдашлар да баламның әтисен күрсеннәр.

Илгизнең тавышы кинәт үзгәрде. Тоныкланды:

— Гражданка!

Фәния дерт итеп башын күтәрде. Аның өстенә үк иелеп өтер күзле, бетчәле бер мент тора иде.

— Здесь спать нельзя!

— Хәзер, хәзер... — диде Фәния. Баласы әле изрәп йоклый иде. — Сичас пуез килә...

— Понаехали тут... бля... деревня... — дип бетчәле мент китеп барды.

Бала авызын чупылдатып куйды. Фәния иренеп кенә янә күк йөзенә күз салды. Анда өзек-төтек болытлар арасыннан кемдер аңа елмаеп карый сыман иде.

# ЯШЕЛ ЧИРӘМДӘ САРЫ КЛИНДЕР

Мин район үзәгенә кайтып төшкәндә, яңгыр инде явасын яуган, ләкин шулай да, нәфсесен тыялмагандай, ара-тирә сибәләп ала иде әле. Өлгереп булмады, авыл аша үтәсе соңгы автобус, зәңгәр төтен чыгарып, пошкыра-пошкыра, чаттан борылды. Төкереп куйдым да, ачудан шулай черт итеп төкерәсем килә минем, бәбкә үләннәргә басарга тырышып асфальт юлга таба киттем. Җәяүләп бара торыйм әле, берәр узгынчы машина очрар, бәлки...

Озак та атламадым, дөрестән дә, арттан көмешсу төстәге машина килгәне күренде. Юлдан читкәрәк чыгып — «яңа байлар» пычрак суга коендырып китәргә дә күп сорамыйлар! — өметсез генә кулны күтәрдем.

Туктады бит, әй...

Тәрәзәсе караңгы, эчтә кем утыруын күрерлек түгел, ишеген ачсам... балачактан бергә аунап үскән Камил утыра. Үз кабинетында гына кабул итәргә күнеккән кибарь түрә кебек башын кагып куйды, керергә ишарәләп, уң кулын саран гына изәде, юеш туфлиләремне дә күздән кичерергә онытмады — пычрак алып кермиме, янәсе, минем затлы машинама?

— Кайтасың? — диде ул, үз соравын үзе үк җөпләп.

Камилне, бензин салу станциясенә урнашып, шактый «мамыкланган» дип сөйләгәннәр иде. Бәхете мәтәлчек аткан, диделәр. Кызыгу белән көнчелек иде, әлбәттә, сүзләрендә. Кеше бәхетенә чын күңелдән сөенүче бармы икән ул дөньяда? Бардыр, нигә булмасын икән... Минем генә күргәнем юктыр...

Камил янә миңа сөзеп кенә карады.

— Машина белән кайтмадыңмыни? Ә?

Машинам юклыгы турында әйтергә авыз гына ачкан идем, ул:

— Бензин кыйбат шул хәзер, — дип иренен ялап алды.

Балачакта ук шундый гадәте бар иде аның, ташламаган икән. Хәзер ничектер үзенә килешеп тә тора. Мондый машинаны иярләгән кешегә, колагын яласа да, афәрин, дип, ләббәйкәләнеп торырсың, ант әгәр...

— Машинаң шәп! — дидем мин. Бу сүз аңа ошарга тиеш! Мондыйларны беләм мин... Чыннан да, Камилнең авызы ерылып китте, күзенә дыңгычлап шатлык тулды.

— Һе, шәп булмый ни... — диде ул. — Америкадан алып кайткан кешенең үзеннән алдым. Мәскәүдә. Танышлар аша. Ышанычлы. Ә?

— Әйбә-әт...

— Беркөннәре сине телевизордан күрдем. Ял көне иде, ахрысы. Болай минем вакыт юк телевизор карап утырырга. Еш күренәсеңме? Теге юлы ак куртка кигән идең...

— Сирәк, — дидем мин, аннары өстәдем: — Онытканда бер.

Шактый гына сөйләшмичә бардык. Бераздан Камил тагын миңа борылды:

— Иномаркамы? Ә?

— Нәрсә?

— Машинаң, дим, иномаркамы?

— Машинам юк...

— Ә? — Камил миңа ышанмыйча карады. — Ялганлама... Язучының ничек машинасы булмасын? Әле телевизордан да күрсәтәләр үзеңне. Мин генә түгел, Канаштагы туганнар да караганнар. Тавышы әтисенә охшаган, диделәр. Чын... Әтиең нәкъ шулай дәрестә безгә нидер сөйли иде бит. Географияме укыта иде әле ул, ә?

— Әйе...

— Саддам Хөсәен турында ни уйлыйсың?

Мин җилкәмне сикерттем.

— Берни дә уйламыйм.

— Хәйләкәр... Атарлар микән? Ә?

— Белмим шул...

— Барыбер төрмәдә йомдырырлар. Сәлмән Радуев кебек...

— Андыйлар гадәттә үз үлеме белән үлми, — дидем мин. Андый чакта юлдашыңның сүзен ничек тә җөпләргә тырышасың...

— Ә бу кулдагысы аның двойнигы гына түгел микән? Ә? Гитлер да бит әнә кайдадыр Америкада яшәп ята, диләр...

— Әлегәчәме?

— Андыйлар озак яши. Сталин да, Берия йомдырмаса, һаман безне лыкып ятар иде әле. Ә? Памушниклары бит әнә йөзгә җитә язды.

— Телевизорны еш карыйсың, ахрысы, вакытың булмаса да, — дип елмайдым мин. Телевизор, шул шайтан әрҗәсе, эшкәртә бүген татарны. Намазга утырасы әби-чәбиләр дә, хәтта селәгәйләрен агызып мәгънәсез сериаллар караганда инде сүнгән нәфес-дәртләрен кузгатып кинәнәләр. Без телевизорга мөкиббән киткәндәй, кяфер үзенең иконасын да ул кадәр кадерләми...

Машина кинәт туктап калды. Әллә үпкәләде инде Камил. Төшереп калдыруы да бар. Әллә кем булган бит әнә, күренеп тора: бармакларыннан, бармаклары салмакланган... тук хәрәкәтләнәләр.

— Сәмигулланың үлгәнен ишеткәнсеңдер?

— Кайсы Сәмигулла?

— Безнең класста бер генә Сәмигулла...

Әйе шул. Һем... Белгән кешеңнең үлеме турында кинәт ишеткәч, күңел тиз генә ышанмый никтер. Югыйсә олыгая-олыгая таныш-белешләрнең арадан югалуына күнегә барасың... Чит үлемнәр гадәти нәрсәгә әверелә. Ишетүгә, яисә белешең кабер якасында торганда, җанны бер сагыш теш сызлагандай әрнетеп ала да үзеңнең дә әлеге җирдә бик вакытлы гына бук изеп йөрүеңне искә төшереп, күңел айкалып куя куюын... Аннары тагын бу турыда онытасың, тагын тормыш мәрәкәсе башлана, инде битлек йөзгә ябышкан, анда чабасың, монда алдыйсың, алданасың. Бер кат отасың, ун кат отыласың. Ахырдан иң зур отылыш гомер икәне ачыклана. Шул бит инде, шул — безнең яшәеш дигән нәмәрсәкәебез. Шул мәгънәсез. Уйлап баксаң!.. Кеше кадерен белмибез, үз кадеребезне онытабыз. Бер түгәрәк эчендә мәш килүебезне аңлап, тормыш ул — көрәш дигән булабыз әле. Кем белән көрәш? Ни өчен? Ни хакына? Ниһаять, түгәрәкнең кыршавы сына...

Сәмигулла... Ятим үсте ул... әбисе карап үстерде. Ни исемле иде соң әле... Озын, какча гәүдәле, коргаксыган ботактай кулларын гел селкеп йөри. Кара төсе уңып бетмәгән төртке күзләре янәшә урнашкан, кешегә чәнчеп карый, дәү борыны аңа ниндидер чуалып беткән тамырлар аша көньяк каны да кушылганын искәртеп тора. Башына нигәдер гел кара яулык бөркәнеп йөри иде ул. Шөлли идек без аңардан. Сәмигулланы исә, әбисен күрүгә, бөтенләй калтырау ала иде. Каты тота иде әби... кем әле исеме... онытгын. Авыр яшиләр иде алар, мохтаҗлыкта дисәң дә ярый. Әнисе Сәмигулланы тапканнан соң ук үлеп киткән... Әйе, Сәмигулла сәбәпче булган әнисенең бу дөнья белән хушлашуына... Әтисе булмаган да бугай, юк, булган, әлбәттә, ансыз, бик теләсә дә, Сәмигулла яралмас иде. Очучы булган, диделәр... Самолеты белән шартлаган. Шундый очучы балалары безнең авылда тагын берничәү бар иде әле.

— Менә шушында, — диде Камил.

— Нәрсә... шушында?

— Ә? — Камил үзен үртәмиме дигәндәй, миңа шикләнеп карап алды. — Син соң берни дә ишетмәгән идеңмени?

— Юк шул... — Мин, уңайсызланып, урынымда борсаланып куйдым.

— Менә шушы баганага машинасы белән бәрелде ул...

Юл кырыйлап бетоннан коелган электр баганалары тезелеп киткән, безнең кырдагысы исә бераз янтайган, яньчелгән төше дә бар шикелле. Бетон баганаиы янтайтырлык булгач, нинди тизлек белән килгәндер ул...

— Машинасы бар идемени аның?

— Алган гына булган. «Девятка»... Кызыл... — Камил авыр сулады. — Бәрелгәнен бит мин үз күзем белән күрдем. Артыннан кайта идем...

— Күрештегезмени?

— Районда Нәби белән сөйләшеп торабыз. Яшьти. Хәзер ул урман сата, джип алды, беләсеңдер... Казанга барып... Мәскәүгә барырлык урысчасы юк. Мәктәпне бетергәнче укырга өйрәнә алмады, хәтерлисеңдер... Ә? Кызыл «девятка» килеп туктады. Карасак... Сәмигулла салмак кына чыгып маташа. Елмая инде, кәнишне. Колак авызга җиткән. Һы... Нәбинең күзе карга оясы булды да калды. Сәмигулла... и машина... Кызыл... Ул бит, беләсең, ничек үсте. Аягыннан тотып селексәң, бет тә коелмый иде, ә? Казанга урнашкач та әллә кем түгел, диделәр. Сантехник булып эшләгәнме шунда...

— Үзе генә идеме?

— Анысы яхшы... Хатыны, балалары кәлҗемә булырлар иде. Ну, без шаккаттык инде. Котларга кирәк, дибез, арбаны. Үзебез берсәк котланган, тәк, эчтәге шайтан ялманырлык кына...

— Сәмигулла эчми иде бит ул? Аның йөрәге авырта иде!

— Ну... Нәби чәер белән бер, исеңдәдер... Аңа эләксәң... Кердек хәрчәүнәгә. Юдык инде бераз машинаны... Шәп иде бит машинасы... кызыл... әрәм булды. Кәлҗемә...

— Шактый салдыгызмы?

Камил машинадан чыкты, мин дә аңа иярдем. Сытылган, майгамы, корымгамы буялган чирәмгә басып баганага якынрак килдек.

— Ун көн инде Сәмигулланы күмгәнгә... Ул алдан китте, без Нәби белән аның артыннан... яшьтиләр колоннасы. Караңгы төшкән иде инде. Карыйм — Сәмигулланың машинасы уңга-сулга салулый. Шуннан кырт кына борылды да шушы баганага... мәч!

Башым әйләнеп китте, мин үзем дә сизмәстән баганага таяндым. Дүрт-биш адым гына читтә күзем ниндидер сары әйбергә төште. Якынрак барсам, клиндер сыныгы.

— Нәрсә таптың? — диде Камил.

Учымны сузып аңа клиндер сыныгын күрсәттем.

— Ә-ә... әбисенә күчтәнәчкә клиндер алган иде шул. Әби, чәйгә манып, клиндер ашарга ярата, дип сөйләп тә торды.

...Ун еллар элек булдымы икән, Сәмигулла Канаштагы ниндидер һөнәр мәктәбендә укып йөри иде. Мин, Казаннан төнге поезд белән төшеп, кая бәрелергә белмәгәч, ул яшәгән тулай торакка киттем.

Сәмигулла, йокысыннан бүлүгә карамастан, мине куанып каршы алды. Гел елмая иде ул, мескен. Безнең мәктәптән

киткәннән бирле күрешкән юк, аның куануына мин дә кушылдым.

Нәрсәләр сөйләштек икән? Өйләнмәгән ике яшь егет нәрсә турында сөйләшә?

— Һәй, Ыркаел, синең белән мин дә кайтам иртәгә, — диде Сәмигулла. Озын керфекләре калгынып алды. — Менә... әбигә дип клиндерләр дә алган идем. — Мин борылып карадым: савыт-сабалар куелган шүрлек янындагы кадакта клиндер бәйләме эленеп тора иде.

— Иртәгә бит әле атнарасы гына, укыйсыңдыр... Сүз әйтмәсләрме соң?

Сәмигулла кулын селтәде.

— Сагынды-ым...

Әбисен — исеме кем соң әле? — шулкадәр ярата микәнни? Буй җиткән егетләрдә мондый туганый хисләр шактый саеккан була бу вакытларда... бүтән мәшәкатьләр өстәлә... борынга тирә-юньдәге кызлар исе керә.

Сәмигулла, минем уйны сизгәндәй, әйтеп куйды:

— Әби, үзең беләсең, миңа каты куллы булды. Әле дә таяк күтәрергә күп сорамый. Тик бит... миннән дә якын кешесе юк бит аның... дөнья йөзләрендә. Минем дә... Атна саен кайтырга тырышам. Туйдырды да... Шәһәр малайлары бәйләнә. Акча таптыралар. — Ул башын кыңгырайтып елмайды: — Мин бит юаш... үзең беләсең.

Чыннан да, бик карусыз малай иде ул Сәмигулла. Кибеткә кәнфит-прәннек алырга барыбыз да аны йөгертә идек. Кеше ул шундый — хәтта якын кешең дә, кан туганың да! — йомшаклыгыңны сизеп алса, хәзер муеныңа атланырга тора.

Мин, әлбәттә, аның хәленә кереп файдасызга сөйләнеп тормадым. Юатудан ни мәгънә? Кешенең ярасына тоз сибү генә...

— Сагынуның сәбәбе әби генә түгелдер әле...

Сәмигулла, кызарып, башын түбән иде.

— Иртәгә Алияләрдә аулак өе...

Ә-һә! Менә бит хикмәт нидә... Сәмигулланың өметсез мәхәббәте турында белә идем мин, әлбәттә. Авылыбызның Гөлчәчәк исемле бер чибәр кызына күзе төшеп йөри иде аның... Күзе генәме... Баш-аягы белән гашыйк иде ул! Борынгы шагыйрьләрчә...

Аулак өйләрдә төрле уеннар — йөзек салыш, тагын әллә нәрсәләр... инде онытылып та беткән, — уйнап туйгач, җырлап-биеп арыгач, егетләр күз төшкән «сүгәннәрне» хуҗаның юеш борынлы малае яисә чәчби кызлары аша тышка «сөйләтергә» чакыралар. Берсендә шулай Сәмигулла да Гөлчәчәкне дәштергән иде... «Сөйләтү» дигәне дә кызык була иде ул аулак өйләрдә. Көн дә күрешеп йөргән кыз белән нәрсә сөйләшәсең? Элегрәк әле такта ярыгыннан гына сөй-

ләшкәннәр. Кыз — болдырда, егет — тышта. Без егет булган чакларда инде кызлар кара-каршы «сөйләштерәләр» иде... кулларын тоттырмасалар да. Телевизордан ул вакытта күбрәк немецлар белән булган сугыш турында кинолар күрсәтәләр, башкасын без кайдан белик? Хәзер генә ул... нишләргә икәнен маңка малайлар да әнәсеннән җебенә кадәр белә.

Сәмигулла бик озак көткән, дип сөйләделәр. «Сөйләтүче» егетләр чакырган кызларының абзарларында ничә бозау барлыгын, чуар тавыкларының күпме йомырка салуларын ачыклап, инде өйләренә — горурланып, күкрәк киереп!.. алар, һе, юк-бар малайлар түгел, кызлар белән басып тордылар, сиздермичә генә иңнәренә дә кагылдылар! — таралышканнар, ә Сәмигулла, үҗәтләнеп, һаман ишегалдында басып калган.

Икенче көнне Гөлчәчәкнең сүзе дә авыл өстенә таралды. «Нишләп әле мин шул мескен ятим-йотама янына чыгыйм», — дигән, имеш, өй нүешенә күзен терәп...

Сәмигулла да бу сүзне ишеткәндер. Ишеттергәннәрдер...

Ул гүя шушы кичтә минем уйларымны укый, салмак кына башын күтәреп:

— Күңелемнән чыгарып ташлый алмыйм шуны. Үзем дә аптырыйм инде... — диде.

...Камил машинасына таба атлады: «Соңыннан әйттеләр, бәрелгәнче үк йөрәге тотып үлгән булган ул...»

— Аулак өйләрдә хәзер дә җыелалармы әле? — дип сорадым мин.

Камил миңа тилегә караган кебек карады. Аннары ямьсез генә көлеп җибәрде:

— Авыл хәзер шәһәреңне орып бирә! Сез Казанда ятканда авыл һаман шул килеш калган дип уйлыйсыз инде, ә? Сәмигулла да... Кайтканда гел Гөлчәчәкне сорашты...

— Шуннан?

— Утырган да шуган... Гөлчәчәкнең инде чәчәге коелганга бишбылтыр. Аркылысы буена тигез. Ә? Итәгендә ике бала, ире шабашкада йөри. Казан байларына йорт сала. — Ул машинасының көпчәгенә тибеп алды, иренен ялады.

— Шә-әп! — дип, мин янә машинага соклануымны белдердем.

— Какжы... Аргамак!

Алга җилдерде Камил машинасы. Авылга...

Авыл башында кашагасына «Юлдаш» дип язылган таш келәт сыман бер бина каршына туктадык.

— Тәмәке аласы бар, — диде Камил.

Мин дә аңа иярдем.

— Бездә мондый кибетләр хәзер унлап...

Буш кибеттә бер шыксыз хатын йокымсырап утыра иде. Киштәләр төрле сулар, аракы шешәләре белән тулган.

— Клиндерләр бармы? — дип сорадым мин.

Сатучы хатын бик тере булып чыкты, мул түше белән күземә керә язып:

— Бездә бөтен нәрсә бар. Акчаң гына булсын, — диде. Камил миңа сәерсенеп күз ташлап алды.

— Мин өйгә кереп калам, син теләсәң нишлә, — диде ул.

— Кәнишне, — дидем мин, һәм Котылдык урамыннан борылдым да клиндер бәйләмен иңемә асып түбән очка — Сәмигулланың әбисе — исеме ничек соң әле? — яшәп яткан йортка таба киттем.

Йорт ерактан янәшәсендәге инешкә чумарга әзерләнгән ялгыз каз бәбкәсен хәтерләтеп тора иде. Җилкапкадан үтеп, кармаланып өйгә уздым. Түрдән:

— Кем ул? — дигән хәлсез тавыш ишетелде.

Ишек кырындагы кабызгычка кулым тиеп китүгә, гөлт итеп ут кабынды. Шыр ялангач өйнең түренә куелган агач караватта аягын бөкләп Сәмигулланың әбисе утыра иде.

— Сәмигулла?..

— Мин әле бу... әби. Сәмигулланың дусты. Менә беразкүчтәнәч алып килгән идем, — дип, клиндерләрне аңа суздым.

— Сәмигулла-а...

— Юк, ул түгел. Мин...

— Кайда йөрисең син моңарчы, малай актыгы? — Әби озын тырнаклы кара бармакларын миңа таба сузды: — Кил, әҗәткана, колагыңны борыйм әле. Колагыңны-ы... Кәҗәм ачтан үлә әнә. Акча апкайттыңмы?

Мин, үзем дә сизмәстән, артка чигендем.

— Таякны бир, таякны бир... Менә аркаңа бер тамызыйм әле, җирбит! — Һәм ул, тешсез авызы белән «эм-эм» килеп, клиндер чәйни башлады. Шул чакта аларны бәйләгән бау өзелде, ахрысы, клиндерләр, тук аяклы сабыйлар төсле, идән буйлап тәгәрәште... тәгәрәште... тәгәрәште...

Мин, утны сүндереп, ишектән чыгып киттем, артта әбинең — исеме ничек соң әле, ә? — «Сәмигулла-а» дигән калтыравык тавышы ишетелеп калды.

## КЫЗ-ХАТЫН

Ул аяк очына гына басып кабинетына чыкты. Чыгар алдыннан борылып йокы бүлмәсенә күз салды. Тәрәзәдән төшкән электр яктысы мондагы караңгылык белән буталып, бар нәрсә әйле-шәйле күренә иде. Киң караватның бер ягында хатыны мыш-мыш килеп йоклап ята. Янәшәдәге тумбоч-

ка өстендәге кырлы стаканга ясалма теш казналыгын салып куйган. Ул аның хәтта саргылт төсен дә аергандай булды. Миллион ел элек үлгән мамонт тешенең кыйпылчыгымыни...

Кабинетта да утны кабызып тормады. Ул монда күзне йомган килеш тә йөри ала. Менә стенаны каплаган китап киштәләре, менә зур өстәл, култыксалы урындык... телефон...

«Соңдыр инде хәзер, — дип уйлады ул. — Унмы икән, унбер үкме...» Шулай да имән бармагы гасабиланып телефон төймәләренә баскалады. Озын-озак гудок...

Колагында чыңлады: озак-озак-озак...

Ул аксыл сирәк чәчен артка сыпырды. Уч төбе юпьюеш иде.

Ниһаять, төрепкәдә хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Алло?..

— Венера...

— Кем бу?

— Альберт... — Тамак төбендәге төерне йотып җибәрергә теләде... тавышы өзелде. Алай да үз-үзен тиз кулга алды. — Марленович, — дигәндә тавыш элекке халәтенә кайтып, шактый ук көр яңгырады. — Мин бу, Венера, Альберт Марленович... Гафу ит шулай соң борчыганга...

Төрепкә эндәшмәде.

— Венера!

Кайдадыр шәһәрнең теге ягындагы хатын тиз-тиз берничә җөмлә ыргытты:

— Мин әйттем бит инде сезгә. Иртә дә, соң да борчымагыз. Неужели сез берни дә аңламадыгыз?!

Кыска-кыска гудоклар нәни чүкеч кебек гүя баш миен чүки. Альберт Марленович өстәл өстендәге күзлеген алып киде. Култыксадагы агарып күренгән бармакларына сәерсенеп карап торды. Эчтәге ниндидер кайнар дулкын муен тамырларын бүрттереп башына менеп җитте.

Ул... Ул... Кем дип белә ул аны? Аны — Альберт Марленович Нагаевны! Профессор Нагаевны! Кем ул, ә, аның белән шулай тәкәллефсез сөйләшергә? Шлюха! Сөйрәлчек...

Моңарчы бер генә кыз-хатын да шулай дорфа рәвештә Альберт Марленовичның сүзен җиргә екканы юк иде әле.

«Картайдым микәнни? Гомер үтте дәме?» Эче өшеп китте. Кыз-хатын мәче белән бер бит ул — андыйны бик тиз сизә.

Корсак тирәсендә янә кайнар дулкын пәйда булды. Юк... Ул әле дулкын түгел... гүя бер йомарлам ут... Хәзер аңардан өскә таба дулкыннар тарала башлар. Нагаев, үзе дә аңламастан, кулына каләм алды. Аннары, корт чаккандай, аны өстәлгә ташлады. Каләм чыңк итте, өстәл өстендәге калын пыяла зеңләп куйгандай булды.

Венера бүләк иткән иде бит аны.

— Алтын каләм... — диде. — Язганнарың да алтын бәһасенә торсын.

— Минем язганнарым бәһасез, — диде Нагаев.

Ияген өскә чөеп — ә ияге аның шундый йомры, матур! — нинди көлгән иде Венера.

— Нигә көләсең?

— Ирләр үзләре турында бик югары фикердә...

— Үзебез мактанмасак, безне кем мактар?

— Мин сине мактыйм... — Венера тагын бер сәбәпсез көлде.

Нагаев аңа игътибар белән карады. Сумаладай кара чәченең чугы үсмерләрнекечә маңгаена төшкән, кыйгач кашлары каядыр ике якка ашкына... чем-кара күзләренең төпкеленә сизелер-сизелмәс көлемсерәү яшеренгән. Курнос борынының яфраклары дерелдәп куйганда, Нагаевның карт йөрәге әллә нишләп китә, шайтан алгыры! Кечкенә авыз, сусыл иреннәр, гүя ул салам кабып затлы коктейль йотарга гына яратылган... ни белә Нагаев бу кыз-хатын турында?

Сораштырып караган иде ул, әлбәттә... кылларын тарткалап, кем әйтмешли.

Венера тагын чыркылдады гына.

— Казна эшендә түгел... — дип куйды. — Минем дә сезнеке кебек иҗади эш... Кешеләрнең психологиясе белән кызыксынам.

— Син Зоя Космодемьянская сыман икән... — Нагаев үпкәләгән сыман кыланды. — Ул да бит, немецларга чын исемен әйтмичә, үзен Таня дип атый. Аны асарга җыеналар, ул исемен яшереп маташа...

— Хатын-кыз үләр алдыннан да серле булып калырга тиеш.

— Исеме кем булса да, ул немецлар өчен авыл йортларын яндырып йөрүче, — диде Нагаев. Эрудициясен күрсәтеп алсын әле бу кыланчыкка. — Совет кешеләре аны үзләре тотып биргән. Кыш уртасында кемнең чатнама суык урамда каласы килсен? Ярый әле тотуга ук кыйнап үтермәгәннәр, югыйсә бер геройдан коры калыр идек.

— Ә нигә өйләрне яндырып йөргән соң ул?

— Фашистларга нәфрәт уятыр өчен...

Мондый мантыйкны Венера аңлап бетермәде. Гомумән, әллә кайчан үлгән ниндидер марҗа кызы турында сөйләшү аны туйдырган иде. Сугыш турында, геройлар турында, безнең аларга үлгәнче бурычыбыз барлыгын мәктәптә дә күпме башка тукыдылар инде.

Нагаев телен тешләде. Венера ише ымсындыргыч кызхатын белән кем шундый темага сөйләшә? Ә нәрсә сөй-

ләшергә? Менә шундый тет-а-тет, интим шартларда, чибәр җан иясе борын яфракларын ара-тирә дерелдәтеп алганда ни хакында сүз куертырга?

Ул моны белми иде. Егет чагында кызлар белән сәгатьләр дәвамында ни-нәрсә сөйләштеләр икән? Төн узуы сизелми дә иде бит. Хикмәт сүздә булмаган, күрәсең...

Кемгә дә мәгълүм, юк-бар сөйләшкән саен син кыз-хатынга кызыграк тоеласың. Чөнки сүз ул прелюдия генә... Сандугач та үз сайравына фәлсәфи мәгънәләр салмый, аның максаты анык: ул былбыл кызын кавышырга чакыра... Максатына ирешкәч тынып та кала. Хәер, ояда бала кошлар пәйда булгач, сайрау кайгысы каламыни? Аларга җим ташырга кирәк!

Ләкин юк-бар сүзләрне табуның ничаклы кыен икәнен белмәгән икән Нагаев. Гел бит «мин сине яратам» дип торып булмый.

Гашыйклар сүзсез дә аңлаша, диләр дә... Юктыр, дөрес сүз түгелдер ул. Мәхәббәт поэмалары, җырлар язылмас иде юкса. Утын пүләне мичтә мәхәббәттән янса да, аның кемгә кызыгы бар... җылысыннан башка...

— Нигә тынып калдың? — диде Венера. — Гәүдәң монда, ә үзең...

— Үзем дә монда.

— Юк, син әллә кайда, үз уйларың белән. Синең өчен үзеңнән башка кызыклырак кеше юк. Мин моны беренче күрүдә үк аңладым.

Нагаев кызарды.

— Нигәдер каушыйм, — дип ялганлады ул. — Тәүге мәртәбә кыз кулын тоткан яшүсмер кебек. Валлаһи менә...

Венера бу юлы көлмәде.

— Артык борчылма, — диде. — Син инде яшүсмер түгел.

Нагаевның сыны катты: «Минем яшькә төрттерә инде бу...»

Шулайдыр... шулайдыр. Кыз-хатын астыртын, явыз була бит ул, нәгаләт. Астан чеметеп алырга ярата. Нагаев монда да үзенә юаныч тапты: чеметкәч, димәк, битараф түгел! Анысы да сөенеч олыгайган кешегә.

Исендә тотмаса да, хәтерли, хәтерли Нагаев үз яшен. Дошманнары исә гел истә тоталардыр. Кайчан пенсия яшенә чыгасын бармак белән саныйлардыр әле, хәсисләр. Санамый ни, зур бер институтның директоры ла Альберт Марленович. Юк-бар кеше түгел, әлбәттә. Сизә ул үзеннән яшьрәкләрнең мыш-мыш килеп үкчәсенә басып килгәнен. Басып килә-килә үзләре дә пенсия яшенә җитәчәкләр тиздән, ничава! Кемнең директор кәнәфиендә утырасын алар түгел, өстәгеләр хәл итә. Өстәгеләрнең исә үзләренең дә яше... ну, бик яшь түгел дип әйтик инде.

Хезмәткәрләренең сабырсыз карашын күреп ләззәт ала иде Нагаев. Алар бит үзләрен әллә кем дип саный. Генийлар, янәсе... Югыйсә житди галим аның институтында чалбар төбе туздырамы?

Венераның гүя каяндыр ерактан, томан эченнән яңгырагандай тавышы ишетелде.

— Алло, алло! Кайда югалдың син?

— Ә?

— Чык, чык үз эчеңнән.

Нагаев көлгән атлы булды.

— Вәт рәхмәт төшкере, — диде. — Чынлап уйга батканмын шул.

— Мине дә онытырлык булгач, нинди уй инде ул?

— Минем яшьтә шулай онытылып китәсең икән... — Нагаев үзенчә ышандырырлык итеп күрсенеп куйды. — Нинди уй керсен инде бездәйләргә?.. — Аннары, гади генә итеп: — Эш турында уйладым, — диде.

— Мин синең хакта бөтенләй белмим... — Венераның чем-кара күзендә якты чаткылар биешеп алды. — Сөйлә әле — кайда эшлисең, кайда торасың, гаилә хәлең ничек?

Нагаев теләмичә генә көлде.

— Галим мин... — Аннары хатын аңламас дип өстәп куйды: — Ученый...

— Әллә профессор? — Венера кулларын чәбәкләде. Бит алмаларына алсу төс йөгерде.

Аh, нинди чибәрләнеп китте ул шушы мәлдә. Нагаев аның җыйнак гәүдәсен кочагына кысудан чак тыелып калды... шунда ук... урам уртасында... үтеп-сүтеп йөргән кешеләрнең аяк астында... бераз гына беленеп торган имиләрен учка кысып...

Ул мәрттән уянгандай башын чайкап куйды.

— Әйе, профессор да... — диде ул. Фәнни эшчәнлеге турында сөйләшергә яратмый иде. Хәер, нинди эшчәнлек инде? Җитәкченең фән белән шөгыльләнергә вакыты каламы? Аннары ул үз фәнен дә, аның галимнәрен дә җене сөйми, аларны бушбугазларга, эшлексез бәндәләргә саный иде.

Әйе, шулар белән әвәрә килеп гомере узды менә! Югыйсә бит ул зур эшләргә, биек кәнәфиләргә лаек шәхес иде. Ары китә алмады, күтәрмәделәр.

Чыннан да, шәм кебек төз гәүдәле, кырыс чырайлы Нагаевның кыяфәте һич тә министрларныкыннан ким түгел иде. Кыска буе да үзенә килешеп тора. Шуңамы хезмәткәрләре аны артында «Наполеон» дип атый, бу кушаматын ул үзе дә белә, әз генә горурлана да иде әле.

— Фатирым үзәктә — Щапов урамында, — дип сүзен дәвам итте ул. — Ике балам бар, аерым яшиләр.

Аларга нинди юллар белән фатир юнәтүен сөйләп тормады. Ә бит мактанасы килгән иде! Нигәдер шушы ярым таныш хатын алдында үзен зур итеп, әһәмиятле кеше итеп күрсәтәсе килде. Чыны да шулай бит!

— Ах, син нинди важный! — диде Венера, йомшак учы белән аның яңагын яратып кына чәбәкләп алды. — Сез, ирләр, үзегезне дөньяның кендеге итеп тоясыз инде.

— Ә син? Син дә үзең турында сөйлә әле?

— Гап-гади хатын-кыз мин, — диде Венера. — Әмәттә яшим. Үз йортыбыз белән... Ирем юк... Кияүгә чыккан идем үзе... тик... ничек диләр әле... характерлар килешмәде. Сиңа кызык түгел инде болар.

«Дөресе дә шул», — дип уйлады Нагаев, тик:

— Нигә кызык булмасын, — диде. — Синең турыда һәр информация кызыклы миңа...

— Культура институтында укыдым... — Венера сынап Нагаевка карап алды, әмма сүзен бүтән озайтмады. — Менә отельгә дә кайтып җиттек.

— Кичке ашка кадәр вакыт бар әле. Диңгез буенда йөреп килмибезме?

— Юк. Мин алҗыдым, бераз ял итеп алам.

Нагаев аның артыннан карап калды: сыгылмалы гәүдәсе — әйтерсең лә һавадан йөзеп бара! — нәфесне кузгата, яшь үгездәй селәгәйне агызып аңа иярәсе килә! Карт канны да кузгата торган, аңны җуйдырырдай нииндидер дулкыннар тарала иде аңардан.

Шул дулкыннарга күрәме, ашханәгә кергәндә күз кырые белән үк күреп алды ул Венераны. Фойеның бер почмагында ыспай киенгән бер төрек егете белән сөйләшеп тора иде. Венера көлә — нәкъ аның белән йөргәндәге көлү! — әледән-әле кулы белән төрекнең күкрәгенә кагыла... бик иркен сөйләшәләр!.. Якын кешеләрчә. Күренеп тора... бер-берсенә ят түгелләр... Нагаевның йөрәге чәнчеп куйды.

Шул чәнчү хәзер — ярым караңгы кабинетында утырганда — тагын кабатланды.

— Сөйрәлчек! С... сөйрәлчек... — дип үзалдына пышылдады ул.

Өстәл лампасын кабызды. Кәгазь кисәкләренә ашыгып яза башлады: «Венера — сөйрәлчек!», «Венера — шлюха!» Шлюха! Шлюха! Шлюха!

Әйе, белсеннәр, белсеннәр аның кем икәнен. Туган-тумачалары, күршеләре белсен.

Шул! Шул аны — Нагаевны, аны — Альберт Марленовичның үзен! — кире кагамы?

Ул еш-еш сулый иде, гаҗәпләнеп язуыннан туктап калды, түбән карады, йонлач халатының итәге гашыйклар шалашы-

дай өскә калыккан иде. Аһ! Венераның теге серле дулкыннары монда — аның аулак кабинетына үтеп кергән түгелме?

Нагаев ашыгып өстәл яныннан торды, халатын салып ташлап тиз-тиз киенде, кесәсенә өстәлдәге язылган кәгазь кисәкләрен тутырды, келәй шешәсен алып тыкты...

Аяк очына гына басып, шауламаска тырышып өеннән чыкты, югыйсә хатыны барыбер ишетмәс иде — ул инде биш-алты ел чукраклыгыннан зарлана, өстәвенә йоклаганда колагын мамык белән томалый.

Машинасы ишегалдында гына тора аның. Нагаев аны башка ишләре арасыннан җай гына алып чыкты да буш урамнар буйлап Әмәткә таба куды.

Олы юлга чыккач, чатта басып торучы ике кызны күреп алды ул. Кул күтәрделәр. Тик Нагаевның кемне дә булса утыртырга бөтенләй нияте юк иде. Үтеп киткәч кенә аңлады: урам фахишәләре бит болар! Төн күбәләкләре. Чү, берсе Венерага охшаган иде түгелме? Әллә шулмы? Ул тормозга басты. Шактый ук артта калган «күбәләкләр» аңа кул болгыйлар иде.

Юк ла инде... Нагаев көлемсерәп куйды. Төнге урамга ук чыкмыйдыр ла Венера. Ул тагын кузгалып китте. Шунда бер ачыш ясады Нагаев: үз-үзенә дә сиздермәскә тырышып урам чатында калган теге кыска итәкле, җәтмә оек кигән фахишәнең Венера булуын тели ләбаса ул! Бернинди кыенсынусыз килер иде дә аның янына... шул чакта үзара мөнәсәбәтләр бөтенләй ачыкланыр иде. Һәркем үз урынын, үз вазифасын белә! Бернинди уйнау да, әллә кем булып кылану да кирәкми.

Әнә тагын берәү кул күтәреп тора. Кара, бу да кыска итәкле, җәтмә оеклы... Чәче иңенә ишелеп төшкән...

Юк, Венерага охшамаган бу... Охшаган да кебек...

Машинасы әлеге кызның каршысына килеп туктады.

Ачык тәрәзәдә иң әүвәл кып-кызыл иреннәр күренде.

— Утыртасызмы? — Бик яшь түгелме соң бу?

— Кая?

— Кая алып барасыз инде, абзыкай, — дип чытлыкланып көлде кыз.

Аның нинди һөнәр иясе булуына хәзер шик юк иде, Нагаев ишекне ачты.

— Хәзер Әмәткә генә барып килик, — диде ул. — Мин сиңа өстәп түләрмен.

Кыз яшь иде. Унсигездәме? Егерме үкме? Нагаев өчен оныкъ яшендә... «Иртәрәк өйләнгән булсам», — дип ачы көлемсерәде ул.

Кыз борсаланып куйды.

— Ә нигә Әмәткә барабыз?

— Бер эшем бар... — Нагаев җентекләп кызның чыраена күз салды. — Берьялгызың төнге урамда басып торуы куркыныч түгелме?.. Венера...

Кыз аңа гаҗәпсенеп карады.

— Мин — Ленария... Хотя, теләсәгез, Венера дип тә атый аласыз.

— Көндезләрен ни белән шөгыльләнәсең инде?

— Көндезләрен йоклыйм... — Кыз көлгән сымак итте. — Сораулар бирергә яратасың икән, абзыкай.

Шактый гына эндәшмичә бардылар.

— Студентка мин, — диде кыз бераздан. — Университетта укыйм.

«Кайсы университетта?» — дип сорарга җыенган иде дә Нагаев, тыелып калды. Барыбер түгелмени? Мондый әңгәмәләр өчен легенданы бу кызлар алдан ук иҗат итеп куя.

Венера яши торган кыска гына урамга керер алдыннан машинасын туктатты Нагаев. Ачкычны, оясыннан суырып алып, кесәсенә тыкты да кызга: «Мин хәзер киләм, шушында гына утыр», — дип караңгы урамга ашыкты.

Фонарьлар янмый иде, яхшы булды әле. Тик салкынайткан. Нагаевның өстендә җиңел куртка гына иде — ул калтыранып алды... тик эчендәге үч ялкыны тагын дөрләп китеп, шунда ук бөтен тәне кызыша башлады. Күзгә төн үзе дә куерып битне эссе сулышы белән куырып алгандай тоелды. Җәй быел озак торса да, көз барыбер килә шул, килә. Бер нишләтеп булмый...

Әнә ике йорт аша гына Венералар өе. Бер тәрәзәсендә ут яна түгелме? Бәлки анда — җылы бүлмәдә — Венера кем беләндер чөкердәшеп утырадыр? Ә ул — Альберт Марленович — кара төндә, карак сыман качып-посып, кесәсендәге кәгазь кисәкләрен урам баганаларына ябыштырып йөри. «Венера — шлюха!» Менә аларның туры. Монда ул белдерүнең татарчасын ябыштырачак: «Венера — сөйрәлчек!» Белсеннәр әле аның да кем икәнен!

Ул шулай йөгерә-чаба кыска урамны әйләнеп тә чыкты. Йөрәк атылып тибә, кан кызган... күзләре дә төн эчендә утлы күмер кебек кызарып күренә сыман...

Машина ишеген ачкач, теге кызның саңгырау тавышы ишетелде:

— Син кайда йөрдең?

— Киттек! — Ачкыч ярсып оясына ыргылды.

Күпмедер баргач, «күбәләк» тагын тавыш бирде:

— Мин курыктым...

— Һәр һөнәрнең үз куркынычы бар.

Кайтып җитәр алдыннан гына ул машинасын аулак тыкрыкка борды.

Кысан иде, тик Альберт Марленович аны сизмәде.

— Венера! Венера. Венера... — дип кабатлады ул, бүтән сүз дә, бүтән исем дә аның теленә килмәде.

— Ашыкма, ашыкма... — диде кыз, аңа яраклаша алмыйча.

— Венера-а...

Хәтта машина да, бер урында торудан гаҗизләнеп, аватүнә аулак тыкрык буйлап каядыр кузгалып китте...

Алар Анталиядә таныштылар.

Таныш-белешләре бик мактагач, шунда ял итәргә барган иде Нагаев. Табигать манзарасына сокланып — аңардан да бигрәк үз-үзенә! — кутәренке күңел белән отеленә кайтып барганда, бер-бер артлы куелган эскәмияләрнең берсендә кесә телефоныннан сөйләшеп утыручы каратут йөзле яшь ханымны — әйе, әйе ханым, аның һәр хәрәкәтендә инде шактый тәҗрибәле ханымнарда гына була торган нәзакәт сизелеп тора иде... — күреп кинәт туктап калды ул. Бер караштан гашыйк булу дигән сүздән көлеп йөри иде югыйсә. Аның яшендә...

Хәер...

Нәкъ аның яшьләрендә кайбер ир-атның тилереп, дөньясын онытып мәхәббәт диңгезенә чумуын, инде батам дигәндә шыңшый-шыңшый көч-хәл белән ышанычлы ярга үрмәләп чыгуын белә иде ул. Бәгъзеләрнең бөтенләй батып калуын да яхшы белә иде.

Каршында шундый сылу хатын торганда — ул юан да, бик артык ябык та түгел, нәкъ Альберт Марленович зәвыгында иде, — әллә кемнәрнең мәхәббәт илендәге тәҗрибәләре турында уйлап маташасыңмы? Нинди тәҗрибә? Юк ул монда... Үлем тәҗрибәсе булмаган кебек...

Хатынның бөтен барлыгыннан татарлык аңкып тора иде. Юкса менә бу татар! — дип әйтерлек аерым бер чырай юк бит бездә. Нинди генә кыяфәтлеләр очрамый арада. Тик күп очракта үз сөягеңне әллә кайдан аерып, танып аласың икән! Шуңа да бу ханымның татар булуына тамчы да шикләнмәде Нагаев.

Якынлашкач, сөенеп куйды — чынлап та ялгышмаган икән бит!

Хатын кесә телефоныннан татарча сөйләшә иде.

— Рәхәтләнеп ял итәм, сөйләмә миңа алар турында! — Хатын үз янәшәсенә килеп утырган ир-атка бөтенләй игътибар итмәде, күз кырые белән дә карап алмады! — Монда минем җаным тыныч... Туйдырганнар иде барысы да... А ему не скажи минем кайда икәнне...

Урыныннан кузгалган хатынга ашыгып сүз кушты Нагаев:

— Гафу итегез...

— Итмим! — диде хатын һәм бу нинди җан иясе соң әле дигәндәй кызыксыну катыш сынаулы карашын Нагаевка төшерде. — Сез кем?

— Ә-әйе... Таныш булыйк — Альберт Марленович. Казаннан.

— Венера. — Хатын аңа гади генә итеп кулын сузды.

— Сезнең сөйләшкәнне колак очы белән генә ишеткәч, Казанга кайткандай булдым, — дип сайрый башлаган иде дә Нагаев, хатын аны коры гына туктатты.

— Нәрсә бар анда — Казанда?

— Соң, нәрсә дип... Ватан... туган ил, так сказать...

— Алай бик тиз сагынырлык булгач, нигә монда килдегез соң?

Нагаев, җавапны тиз табуына сөенеп:

— Сагынырга! — диде.

— Алайса Казанны бик еш искә төшерерсез. Мондагыларның яртысы диярлек Казаннан.

— Сез дәме?

— Күренмимени? — дип көлде хатын.

— Ужиннан соң, бәлки, бергә-бергә сөйләшеп утырырбыз?

Венера тагын аңа сынап карады... керфекләре аша...

Һай, кыз-хатынның шул карашыннан үлә иде Нагаев.

— Утырып торасым килми, абы-ы-ый, — дип сузды Венера. — Дискотекага чакырсагыз инде... бәлки, риза да булырмын. Төнге клублар бик классный монда... Тик... — Тагын керфек арасыннан караш...

«Тит-тит-тит... Картсына», — дип рәнҗеп уйлады Нагаев. «Белми әле... әле... әле ул... әле...»

— Пажалысты, — диде Нагаев, көр тавыш белән. — Биербез кара яндырып.

Хәзерге музыкага үрле-кырлы сикерүен күз алдына китереп үзалдына көлеп куйды ул. Тик юкка курыккан икән. Әби яшендәгеләрнең дә биеп маташуларын күргәч, эченә җылы керде. Һи, болар арасында әле ул...

Шулай да биергә ашыкмады.

Үз яшен онытып кыланучылардан да көлке һәм кызганыч кем бар тагын? Картаясы килми беркемнең дә, тик табигатьне алдап булмый шул... булмый...

Ә Венера очынып биеде дә биеде.

Нагаев, ара-тирә шәраб йота-йота, сокланып аңа карап утырды. Кулыннан тартып диярлек торгызгач, биергә дә чыкты әле. Бию дип... бер урында таптанып кулларын селеккәләде бугай. Институттагы хезмәткәрләре күрсә, эчләре катып көләрләр иде, мөгаен. Юк, аның алдында түгел, әлбәттә, бәдрәфкә чыгып бии-бии шаркылдарлар иде.

Өметең төшкән кыз-хатынның күңелен күрәм дип, бию генә түгел, әллә ниләр эшләргә риза инде җүләр ир-ат. Андый чакта исем-дәрәҗәләр дә истән чыга, асылыңны яшерә торган битлек тә онытыла.

Венера аның гына түгел, бүтәннәрнең дә күзен кыздыра иде, күрәсең: чәчен арттан учламга җыеп бәйләгән кәкре борынлы егет бигрәк тә бөтерелде инде шул тирәдә.

Һәм юкка гына бөтерелмәгән икән!

Официант белән исәп-хисап ясаган чагы булгандырмы, Венераның югалуын искәрмичә калды ул.

Башта көтте әле, бәлки, бәдрәфкә генә чыккандыр дип үз-үзен юатты. Инде өмете бөтенләй киселгәч тә — клубта бер кеше калмады, официантлар гына өстәлләрне җыештырып йөри... — тиз генә урыныннан кузгала алмады. Һавага чыккач та озак кына аңгы-миңге булып торды ул. Ни инде бу? Ничек шулай кешедән көлеп була? Рәнҗү катышкан ачу борын тишекләреннән ургып чыккандай булды, күз төпләре әчетте. Оятсыз рәвештә аны файдаландылар ич! Уенчык итеп... Юк, савым сыеры урынына... Лох! Карт юләр... Әгәр шушы мизгелдә каршысында Венера пәйда булса, ул аны ботарлап атар шикелле иде.

Пәйда булмады.

Иртәгесен кич белән берни булмагандай аның бүлмәсенә килеп керде ул.

Нагаев иртән үк температурасы күтәрелгәнен сизде. Кан басымы да уйный бугай. Кимсенүдән, гарьлектән килгән авыру иде бу. Ул ашханәгә дә төшмичә көн буе бүлмәсендә генә ятты. Әче яна иде аның — су эчте дә су эчте. Эчте дә укшыды.

Наивлыгы өчен үзен сүкте, эттән алып эткә салды: аңгыра... ахмак... дур-рак... Шулай кызык итәләр синдәй азгын картларны. Теге оятсыз кыз-хатынны әллә нишләтәсе килде. Тик нишләтә ала ул аны?

Менә килеп керде. Елмайды. Маңгаен җыерып куйды.

— Сез күренмәгәч борчылдым, — диде. — Авырдыгызмы әллә, — диде.

Бөтен ачуы, рәнҗүе, кимсенүләре онытылды Нагаевның. Әйтерсең лә җил чәчәк тузанын алып китте каядыр. Ул аның теләсә нинди гамәлен кичерергә әзер икән ич! Бары тик янәшәдә генә басып торсын, бераз чатнаган тавышы колакны гына иркәләсен...

— Син кичә кая югалдың?

Венера нәни генә салкынча кулын аның маңгаена куйды.

— Янасың бит, җаныкаем. Дару эчтеңме?

Ул шулай... әле сез, әле син дип сөйләшә иде.

Нагаев тавышын күтәрде:

— Бер сүз әйтмичә... җавап бир!
Венера маңгайдан кулын алды, бер адым артка чигенде.
— Абау! Мондый тонда сөйләшсәгез, мин чыгып китәм.
Нагаев үзе дә сизмәстән урыныннан чәчрәп торды, Венераны күкрәгенә кысты.
— Юк, юк. Китмә. Алайса мин үләм. — Тавышы шундый ялварулы, мәэсүс иде.
Мондый тавыш әллә нинди кальгаларның капкасын ачтыра ала, әмма Венераның керфеге дә селкенмәде. Ул аны ике кулы белән читкә этте дә:
— Тынычланыгыз, зинһар, — диде, салкын тавыш белән. — Сез бит интеллигентный кеше. Зерә борчылгансыз. Я же по-английски ушла.
Шулайдыр... инглизләр шулай сүз әйтми генә юкка чыгалардыр. Ләкин ул бит инглиз түгел! Ир-ат кыз-хатын хушлашмый гына гаип булсын өчен сыйланырга чакырмый.
Венера исә кыз-хатын иде. Мондыйлар олыгаеп карчык булгач та кызлык чалымнарын җуймый. Уйнаш күңелле кыз-хатыннар сине теләгәнчә алдый, ялангач калдыра, хыянәт итә, аяк астындагы тузанга әверелдерә — тик син барыбер аларга озак ачу да сакламыйсың, нәфрәтең дә дәвамлы булмый, иблис котырыгы инде бөтен җаныңны, җәсәдеңне яулап ала, яман чир кебек метастазалары бөтен әгъзаларыңа тарала. Котылу юк! Һәм котыласы да килми, шайтан алгыры!
Гажизләнеп басып торган Нагаевка карап Венера көлеп җибәрде.
— Юк өчен кайгырма, — диде. — Менә бит мин, каршыңда басып торам. Йә, нишлибез? Төнге клубка чакырмыйм инде бүген...
Нагаев, аңга килеп, суыткычка ташланды — аннан җиләк-җимешләр тартып чыгарды, аларны тәбәнәк өстәлгә урнаштырды. Казаннан ук алып килгән «Һенесси» коньягын уртага утыртты.
Талгын музыка... ярым караңгы бүлмә... иңенә орынып утыручы кыз-хатын... Йә, ни кирәк тагын мәхәббәткә сусаган ир-атка?
— Кем ул теге кәкре борынлы егет? — дип сорады ул инде куенында яткан Венерадан. — Син шуның белән киттеңме?
Венера исә җавап биргәнче аның куеныннан суырылып чыкты да тиз-тиз киенә башлады.
— Сез ир-атлар барыгыз да бер чыбыктан сөрелгән... Хуҗа буласыгыз килә. Ә мин — ирекле. Кая телим — шунда барам, кем белән телим — шуның белән... Буйсыну таләп итәргә мин бит синең секретаршаң түгел!

— Үзем дә аңламыйм... — Нагаев шәрә йонлач аякларын идәнгә салындырып утырды. — Көнләшәм, ахрысы. Димәк, яратам!

— Үзеңне яратасың син, җаныкаем. Күзең төшкән һәрнәрсә, һәркем синеке булырга тиеш.

— Һәм син минеке булырсың!

— Нәчәлник икәнең әллә кайдан күренеп тора. — Йөзендә чалыш елмаю пәйда булды. — Киләчәк күрсәтер. Үзең минеке булмагаең!

— Мин риза! — Шулай диде инде. Үзе эчтән ирәеп уйлап куйды: «Нагаевны үзенеке итүчеләр җирдә тумаган әле». Ул үз сүзен генә сүз итүче кеше... дөнья аныңча гына барсын! Мондый кыз-хатынны гына иярли алыр ул...

Өстенлек хисе аның канына сеңгән. Тик кайчакта бу хис артка чигенә. Оясына качып күзен генә ялтыратып ятучы эт сыман! Шунда Альберт Марленович үзен самими бала сыман сизә, кыз-хатынга сыенасы, итәгенә башын куеп иркәләнәсе килә, аның һәр әйткән сүзен җөпләп, ияреп йөрергә дә риза ул. Тик аңына килгәч оядан теге эт атылып чыга да, Нагаев тагын үз кыяфәтенә кайта — битлеген җайлап кия, сынын турайта, тавышы кибарьләнә.

Кайтышлый Истанбулга туктаганда да үзенең шул күнегелгән халәтендә иде ул.

Казанга әле иртәгә генә очасы булганга, алар Солтан Әхмәт мәчетенә янәшәдә генә, Ат мәйданының түрендәге затлы кунакханәнең иркен бүлмәсенә урнаштылар.

Тәрәзәдән Айя-Суфия, биредәрәк төрек солтаны кайчандыр Мисырдан кайтарттырган фиргавен баганасы күренеп тора.

— Византия вакытында монда ипподром булган, — дип аңлатты Нагаев киярга күлмәк сайлап торган Венерага — алар шәһәргә чыгарга әзерләнәләр иде. — Шуңа төрекләр моны Ат мәйданы дип йөртә. Берничә гасыр элек кайсыдыр төрек солтаны баш күтәрүдә катнашкан дистәләрчә мең янычарны үтертә. Биредә Кызыл мәйдандагы кебек үк кан күп түгелгән.

— И күп белә дә инде минем профессор... — Ниһаять, Венера күңелгә ятышлы күлмәк тапты бугай, канәгать елмаеп куйды. — Әйдә, әйдә киен тизрәк. Капалы Чаршыны айкап кайтыйк әле.

Истанбулның атаклы базарына бер дә барасы килми иде Нагаевның. Гомумән ул, ир-атларның күбесе кебек, кибетләрдә, базарларда йөрергә яратмый. Әмма кыз-хатын белән булгач, нишләмәк кирәк... Ә кыз-хатын саткан-алган төштә үзен судагы балык кебек хис итә. Хәтта берни сатып алмаса да...

Баязит мәчете яныннан үтеп, алар Капалы Чаршыга юл тоттылар. Ни генә юк монда! Чын-чынлап шәрекъ базары. Чит ил кешесе икәнең әллә маңгайга язылган инде, әледән-әле сине малай-шалай төркеме урап ала, штампланган вак чебен кебек күзгә генә кермиләр.

Адым саен диярлек урысча сөйләшкән тавышлар ишетелә. Әллә ярты Рәсәй монда күчкән инде... Гүя элгәреге урыс сәясәтчеләренең хыялы тормышка ашкан — алар бит Петр патша вакытыннан бирле Истанбулны, янәсе, Царьградны яулап алырга хыялланган. Хәер, хәзергеләренең дә күңелендә ул яшерен өмет сүрелеп бетмәгән, ахрысы.

Дәрманга караганда, дәрт озаграк яшәүчән шул!

Алтын кибетләре тезелеп киткән урамда — әллә кайларга сузылган рәтне урам дими ни дисең?! — Венера әллә нишләде: сулышы ешайды, йөзе кызарып чыкты, маңгаенда тир тамчылары җемелдәде. Беренче кибеттә үк ул бар дөньясын онытты, йотылды! Гаҗәп тә түгел — монда кайчакта хатын-кызлар аңнарын да җуеп егыла, имеш. Шундый ул алтынның кодрәте: «Мең дә бер кичә» әкиятендәге кебек, хәзинә тулы мәгарәгә кергәч, ишекне ачтыра торган тылсымлы сүзне истән чыгарган мәгълүм каһарманга да әверелүең бар...

Венера сатулашкан арада, Нагаев каршы як кибеттән аңа дип муенса алды.

И сөенде инде Венера... Бүләкне кем яратмый?

— Күпмегә алдың инде? — дип сорады бераздан.

— Бүләкнең бәясен сорамыйлар.

Тик барыбер әйттерде.

— И, профессорым, бигрәк беркатлы икәнсең, — дип борчылды Венера. — Өч бәясен түләгәнсең ләбаса. Төрек ул сатулашырга ярата. Сатулашмаганны кешегә дә санамый ул...

— Өйләнгән елны егетләр юмарт була, — дип, таныш рәссамыннан ишеткән әйтемне искә төшерде Нагаев.

Венера, кызарып, оялчан үсмер кыз кыяфәтенә кереп, керфекләрен түбән төшерде.

Яраттыра белә иде ул үзен, чукынчык!

Нагаев сәгатенә карап алды. Истанбулга килеп төшкәч үк ул күптәнге танышы профессор Туран Язган белән телефоннан сөйләшеп алган иде. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, Казан сәламнәрен — алар инде Анталиядә ятып шактый искергән... — кабул итеп алгач, Туран бәй беравык тынлыктан соң сорап куйды:

— Кичен сезнең вакытыгыз булырмы? Бүген без Әзәрбайҗаннан килгән кардәшләр хөрмәтенә мәҗлес җыя идек. Сез дә шунда рәхим итә алмассызмы?

— Бик рәхәтләнеп, — дип сөенде Нагаев. — Әмма бән бир кадын илә...

Туран бәйнең, үзләре әйтмешли, күзәй төркләре шивәсендә әйбәт аңлашуын белә Нагаев, тик үзенең дә төрекчәдә төшеп калганнардан түгел икәнен искәртергә шул җөмләне әвәләп чыгарды инде. Янәшәсендә басып торган Венера да шаккатсын әле. Төрек банкетында катнашырга теләве дә нәкъ менә Венера өчен, аның алдында янә бер кат үзенең зурлыгын күрсәтү өчен иде.

— Әвәт, кичке алтыда вакыфка килегез, — диде Туран бәй.

Аның вакыфы базардан ерак түгел иде, алар җәяүләп кенә киттеләр.

Мәҗлес Таксим мәйданындагы бер ресторанда буласы икән, Туран бәйнең машинасында барганда Нагаев сиздерми генә Венерага күз салгалады: менә бит, төрекләр дә «аның профессорын» ничаклы хөрмәт итә, күтәреп кенә алмадылар, Нугай бәй дип кенә торалар! Һәм дөрес әйтәләр. Ярлы колхозчы гаиләсендә туса да, үзенең бәкләр нәселеннән булуына ышана ул.

Тостларга да колак салмады Нагаев — андый чакта ниләр сөйләнгән белә иде, аңа Венераның тән җылысын тоеп утыру рәхәт! Венера алдында үзен зур кеше итеп тоюы рәхәт. Белсен бу горур Казан кызы кем белән утыруын... Әнә Әзәрбайҗан илчесе. Ак сакаллы, ак чырайлы сымбат кеше. Әнә төрек министры. Әнә...

Нагаев та торып тост сөйләде татарча. Бәлки, һәр сүзен аңламаганнардыр да... Ләкин Төркияне мактавы һәммәсенә барып җитте, кул чаптылар.

Менә дәртле төрек музыкасы яңгырады. Түрдәге кечкенә сәхнәгә төрек кызы йөгереп чыкты: күкрәгендә алсу бюстгальтер, кара шифонга кызыл розалар төшкән итәк кигән. Корсак биюен башкарамы соң? Музыка кызган саен өстәл кырындагы ирләрнең дә күзләренә дәрт тула, иреннәре юешләнә иде. Ә кыз бии — еландай боргалана, колындай каядыр ашкына.

Нагаев инде үзен бәк кенә итеп түгел, хан итеп тоя иде. Татар ханнары да кайчандыр шулай кызларның биюен карап ләззәтләнгәннәрдер. Үз чатырларында... Ә ул монда — Истанбулның үзәгендә — төрек сылуының биюен карап соклана.

Кыз инде һәркемнең алдына килеп бии башлады. Шул бәхеткә лаек булган кеше шаккатудан тел шартлата һәм кызга акча сона иде. Нагаевның соклануы шунда ук юкка чыкты. Аңарда бит вак акча юк. Вак дигәне дә йөз доллар. Безнең акча белән ул буладыр... буладыр... Кыскасы, артык күп була! Ә кыз котылгысыз рәвештә аңа якынлаша. Акча бирмәсәң, оятын кая куярсың. Татарларны саран, мәнсез дип калырлар. Аннары, янәшәдә Венера да бар бит әле.

һәм ул елмаюын ничек тә киңрәк итәргә тырышып, йөз долларны бераз җәебрәк — күрсеннәр! — биюче кызның ике ими арасына кыстырды. «Менә мин нинди!» — дип күз кырые белән генә Венерага карап алган иде дә, аның чытык чыраен күргәч, болай да беткән кәефе бөтенләй кырылды. Бәяләмәделәр! Сизмәделәр дә... юмарт икәнен дә күрсәтә алмады, йөз доллардан да колак какты.

Кайтканда бер сүз катмады Венера. Нагаев та гаепле кешедәй эндәшмичә барды. Отельгә керер алдыннан гына Венера аңа борылып:

— Биюче кызны күзең белән ашый яздың бит, профессор иптәш, — диде. — Йөз долларыңны да җәлләмәдең. — Бераздан соң өстәп куйды: — Бичара студенткалар...

Нагаев аптырады: студент кызларның монда ни катнашы бар?

— Бер таныш булмаган чит ил кызына шулай ымсынгач, сиңа бәйле студенткаларны нишләтәсеңдер син...

— Мин сәнгать әсәренә сокландым, — диде Нагаев, коры гына.

Үзенең күңеле күл булды — җәелде, ташыды. Көнләшә түгелме соң бу тәкәббер кыз-хатын? Димәк, Нагаевның көнләшерлеге бар әле!

Һава аланында очкыч көткәндә, Венера, аның кулын тотып: «Рәхмәт сиңа, профессорым, — диде. — Бу сәфәрдән искиткеч хатирәләр калды». Ул бераз гына дулкынлана иде төсле.

— Минем сиңа нәни генә бүләгем бар... — һәм бизәкле тартмага салынган алтын каләм сузды.

— Алтын каләм... — диде. — Язганнарың да алтын бәһасенә торсын.

— Минем язганнарым бәһасез, — диде Нагаев.

Ияген өскә чөеп — ә ияге аның шундый йомры, матур! — нинди көлгән иде Венера.

— Нигә көләсең?

— Ирләр үзләре турында бик югары фикердә...

— Үзебез мактанмасак, безне кем мактар?

— Мин сине мактыйм... — Венера тагын бер сәбәпсез көлде.

— Казанда да гел очрашып торырбыз бит?

— Ә хатының? Балаларың? Синдәй зур кешеләргә имиджны сакларга кирәк, шаярма, иптәш профессор.

— Шундый чибәр кыз-хатын белән... дус булу имиджны бизи генә.

Тик тиз генә очрашырга язмаган икән. Казанга кайтуга, һич көтмәгән матавыклар, борчулар бөтереп алды Нагаевны.

Матавык кынамы... Аның тез астына китереп суктылар һич көтмәгәндә.

Ялдан кайтып бер атна үтте микән, аны Министрлар Кабинетына чакырдылар.

Түрә, аңардан шактый ук яшь кеше, бик төксе каршы алды. Исәнлек-саулык та сорашып тормыйча — дөрес тә, Нагаевның исәнлеге аңа ниемә кирәк?! — үгезнең мөгезенә ябышты ул:

— Институт эшендә житди кимчелекләр бар, — диде. — Серьезные недостатки... Без житәкчелекнең эшеннән риза түгел.

— Нинди кимчелекләр? Сез конкрет сөйләгез, — диде Нагаев, шактый ук аптырап.

— Смена поколений, Альберт Марленович, — диде түрә, өзеп. — Яшьләргә юл бирергә кирәк.

Нагаевның күз аллары караңгыланды... ә чырае агаргандыр, түрә аңа сулы стакан тоттырды.

— Борчылмагыз сез ул кадәр. Без бит сезне эштән кумыйбыз. Сектор мөдире булырсыз.

— Миңа пенсиягә кадәр биш ай вакыт калды. Шуңарчы көтә алмадыгызмы?

— А что это меняет?

— Мин президентка керәм.

Түрә елмаеп ике кулын җәйде:

— Пожалуйста!

Хәер, мәсьәлә иң өстә хәл ителмәсә, бу егет аның белән болай сөйләшер идеме?

— Кем инде ул?

— Сез аны беләсез. Бездә эшли... — һәм ул таныш исемне атады. — Шаулап йөрмәскә киңәш итәм, — диде ул, Нагаевның кузгалуын күреп. — Персональный машинагыз сезгә калачак... О деталях поговорим еще... Бергә-бергә яшисе бар бит әле, Альберт Марленович... — Түрә аның хәленә кереп елмайды. — Юбилеегызны зурлап уздырырбыз. Орденны лично үзем обещаю.

— Рәхмәт инде... — дип мыгырдады Нагаев.

Түрә янындан ул туп-туры өенә кайтты. Тынычланырга, үз хәле турында ныклап уйланырга кирәк иде. Ишекне ачуга ук борынга корвалол исе килеп бәрелде. Хатынының еламсыраган тавышы ишетелде:

— Кайттыңмы? Кайда йөрисең син? Эшеңдә юк, кесә телефоның алмый...

— Ни булды?

— Үләм, ахрысы. Йөрәгем чәнчи... кан басымы күтәрелгән...

— «Скорый» чакырырга иде.

— Алар ни белә?

— Ни эшләргә соң? — Нагаев хәле китеп урындыкка утырды, тел астына волидол салды. Берәү әйтмешли: «Эшләргә-то нәрсә?»

— Син минем үлүемне телисең инде-е... — дип елап җибәрде хатын. — Ял итәргә дә берәр кәнтәең белән баргансыңдыр әле.

— Тынычлан, зинһар. Үз хәлем хәл...

— Гомер буе эгоист булдың син...

Нагаев ачыргаланып кычкырды:

— Җитте, дим, ниһаять!

Шул чакта телефон чылтырады. Беркем белән дә сөйләшәсе килми иде Нагаевның. Ә телефон чылтырый да чылтырый.

— Әйе?

— Исәнме, профессоркайгынам... Син кая югалдың? — Төрепкәдә Венераның шат тавышы ишетелде. — Бөтенләй югалдың ич син! Кайтканнан бирле хәбәрең юк. Очрашабызмы?

— Юк... Гафу итегез...

Телефон тагын чылтырады.

— Син... шаяртасыңмы? Альберт...

— Юк, шаяртмыйм. Ишетәсезме, мин серьезно! Серьезно!

Кыска-кыска гудоклар...

Ул обойдагы бер ноктага карап утырды да утырды. Караңгы төште, хатыны күләгәдәй шуып йокы бүлмәсенә кереп китте. Ә Нагаев урыныннан кузгалмады.

Юкка шулай авыр кичергән икән ул кәнәфиеннән төшүне. Кәнәфидән төшү түгел, иңнән авыр йөкне төшерүгә булган! Вакыты күп хәзер, җаваплылык аз, машина да кул астында гына, елгыр шоферы чакыруга ук подъезд төбенә килеп туктый. Институт хезмәткәрләре аны кәнәфисез килеш тә хөрмәт итәләр икән. Ни кирәк тагын кешегә? Йөрәге генә менә, сыкрап, нәрсәдер җитмәүне искәртә шул. Нәрсә түгел, Венера җитми икән аңа... кыз-хатын!

Директор вазифаларын тапшыргач ук аңа чылтыраткан иде югыйсә. Тавышын көрәйтергә тырышып:

— Венера, мине гафу ит, зинһар, — дип сүзне башлаган иде.

— Кем бу?

— Инде танымыйсың дамы? Альберт Марленович мин. Синең профессоркаең...

— Мин андый кешене белмим. Һәм вообще... бүтән звонить итеп борчымагыз.

— Венера! — Ләкин элемтә өзелгән иде инде.

Инде моңа бер ай вакыт үтте. Нагаев атна саен төнлә

Әмәткә бара, таныш урамны әйләнә, баганаларга Венераны фаш иткән кәгазьләрен ябыштыра. Бер атнага шулай тынычланып кала. Тик бер атна узуга кимсенүе, гарьлеге, үче тагын кузгала, төн уртасында ул машинасын Әмәткә куа, кача-поса баганаларга белдерүләр ябыштырып йөри: «Венера — сөйрәлчек!», «Венера — шлюха!»

Менә хәзер дә ул төнне ертып Әмәт ягына җилдерә. Тик бу юлы урам чатларында «төн күбәләкләре» күренми, урамнар буп-буш диярлек, тик ара-тирә соңарган машиналар гына үтеп китә.

Беренче баганага кәгазен ябыштыруга ук, җир астыннан чыккандай, аны ике кеше ике ягыннан эләктереп алды.

— Күптән көтәбез инде сине, урод, — диде берсе.

Икенчесе сугарга кизәнмәкче иде дә, Нагаевның кыяфәтен күргәч, никтер кире уйлады.

Нагаев үзе бернәрсә аңларлык хәлдә түгел иде.

Милиция бүлегендә аны күрергә кизү торучы барлык милиционер җыелды.

— Ә мин профессорларны акыллы кешегә чутлап йөри идем, — диде тәбәнәк буйлы бер сержант.

— Аларның күбесе мондый, — дип бармагы белән маңгаена төртеп күрсәтте берсе. — Күп укыганнан...

— Утыр, — диде капитан. — Хәзер беркетмә тутырабыз. Исем-фамилия?

— «Сез» дип сөйләшүегезне үтенәм.

Капитан гаҗәпләнеп калды:

— Да? Культурный, значит... Исем-фамилиягез, атагызның исеме?

— Альберт Марленович Нагаев!

Беркетмәне тутыргач, капитан аның алдына кәгазь шудырды.

— Аңлатма языгыз.

— Нәрсә язарга?

— Нигә кешегә яла яккан листовкалар таратасыз? Нинди мөнәсәбәттә сез Венера... тәк... Ибатова белән? Барысын да языгыз. Сезне өйрәтәсе юк.

— Мин бернинди листовкалар таратмадым.

— Әһе... Безнең хезмәткәрләр тоткарлаганда, багана төбенә пес итәргә тукталган идегез инде, әйеме?

— Әйе!

— Төн уртасында пес итәр өчен Әмәткә килдегез, әйеме?

— Әйе!

— Ну, языгыз шул турыда...

Язды Нагаев өйдә бәвеле килмичә интегүен дә, бары тик төн уртасында Әмәттәге бер багана төбендә генә бушана алуын да...

Капитан аңлатманы укып чыккач туйганчы көлде. Күзеннән эре яшьләр атылып чыкты хәтта!

— Ну, умора... Үләм... — Ул тагын «син»гә күчте: — Под дурачка косишь, профессор? Справкаң бармы соң?

— Нинди справка?

— Шизофреник булуың турында...

— Юк.

— Табарсың. Сез, кирәксә, әллә нинди документлар да юнәтәсез. — Капитанның ике күзе тулы нәфрәт иде. — Барыгыз. Иртәгә сәгать унбергә тикшерүче янына килерсез. Унбишенче кабинетка.

— Сау булыгыз.

Капитан эндәшмәде.

Әлбәттә, икенче көнне бу йортка килгәндә, Нагаевның кесәсендә шизофрениедән авыруы турында белешмә бар иде инде.

Тиешле кешеләргә чылтыратылган иде. Тик барыбер Нагаевның җаны, сытылган күңеле шыңшып елый иде. Бетте бит ул! Гомер буе бөртекләп җыелган дәрәҗә коелды да төште. Репутация чәлпәрәмә!.. Гомерен шулай хурлыкта, үлгәнче җуелмас «шизофреник» тамгасы белән төгәлләрме инде ул?

Бөтен Казан аңардан көлә сыман тоелды. Институтка бармас инде ул бүтән. Чукынып китсеннәр. Ә Венера? Аның күзенә ничек карар?

Ә Венера тикшерүче бүлмәсендә утыра иде.

— Исәнмесез, — дип авыз эчендә ботка пешерде Нагаев. Ул Венерага күтәрелеп карарга да кыймады. Аның болай беркайчан да шулкадәр югалып калганы, үзен бер шакшы бөҗәк итеп тойганы юк иде әле!

— Утырыгыз, Альберт Марленович. — Тикшерүче өстәлдән башын күтәрмичә генә урындыкка ымлады.

Нагаев аның алдына бүген генә алган белешмәне китереп салды.

— Нәрсә бу?

— Мин — шизофреник...

— Да? Без үзебез дә шикләнгән идек аны. Тик махсус тикшермичә ярамый.

Шул чакта Венераның тавышы ишетелде:

— Махсус тикшерүнең кирәге булмас.

Тикшерүче аңа аптырап карады.

— Минем аңа бернинди дәгъвам юк. Гаризамны кире алам.

— Ялгышмыйсызмы? — Тикшерүче папкасыннан кәгазь алып Венерага сузды. — Бу бәндә исемегезне тагын пычратып йөрмәсме?

— Йөрмәс!

Нагаев бүртенгән чыраен кайда яшерергә белмәде.

— Алайса… — дип урыныннан торды тикшерүче, — мин сезне тоткарламыйм. Безнең бүтән эшләребез дә баштан ашкан…

Урамга чыккач, Венера Нагаевны култыклап алды.

— Әйдә, әнә теге кафега кереп утырыйк әле. Сөйләшәсе сүзләр күп җыелган, — диде ул.

Нагаев, туктап, кыз-хатынның күзләрен эзләде. Тапты. Тик анда кызганудан башка берни дә күрә алмады.

— Мин аңламыйм… Син ничек… болай… булдыра аласың…

Кыз-хатын моңсу елмайды:

— Син әле бик күп нәрсәне аңламыйсың, җаныкаем… — Һәм йоп-йомшак учы белән аның юеш яңагын сыйпады.

# ЫЧТАПАН

*Казан шагыйре Сергей Малышев истәлегенә*

Якшәмбе көнне иртәнге якта Степан Петровичны зәхмәт сукты. Бу хәлне алдан белсә, ул, әлбәттә, кибеткә дип чыгып китмәгән булыр иде. Җиде кат үлчәп, бер кат кисә торган кеше югыйсә Степан Петрович.

Иде…

Юк, үлмәде ул. Исән дип тә әйтүе кыен. Ята әнә кысан бүлмәдәге пружиналы караватта. Селкенгән саен пружиналар ыңгыраша… Шуңа да Степан Петрович селкенми. Степан Петрович диярлеге дә юк — тануы кыен — авызы кыек, бер күзе, сикереп чыгарга теләгән кәҗә бәтиедәй, маңгайга таба күчкән. Берәр нәрсә кирәксә, ике ирен арасыннан ниндидер мөгрәгән авазлар гына чыга.

Шундый көнгә калыр дип кем уйлаган аны… Әле кичә генә ничек вәкарь белән атлап йөри иде. Гәүдә төз… Йөз кызыл… Гөрләп көлеп җибәргәндә бераз бөкре зур борыны урында утырган түрә кебек күккә ашкынып ала. Груздев урамындагы лепердек тупыллар арасында изрәп утырган йортның ишегалдында шактый күрекле кеше иде Степан Петрович. Йорт панельдән биш катлы итеп салынган, халык телендә андыйларны «хрущевка» да диләр, монда яшәүчеләр бер-берсен яхшы таный, ул гынамы, кемнең ничек сулаганын да белеп торалар монда. Шулай да Степан Петровичның якшәмбе көнне иртәнге якта кибеттән ипи белән сөт

алып кайтканда, подъезд каршында авып төшүен беркем дә күтмәгән иде. Ишек төбенә чыгып утыра торган әбиләргә көне буе сөйләргә яңалык булды аның шулай кинәт җиргә егылуы. Күрер күзгә таза карт иде шул Степан Петрович. Имән инде, имән! Тәмәке тартмый, эчкәндә дә мүк җиләгеннән үзе төнәтеп ясаган куе шәрабны бер касә генә тотып куя... Кәеф өчен генә. Үз исәбе белән дә сәламәт килеш бик озак яшәргә тиеш иде әле ул.

Шундый кеше ауды. Якшәмбе көнне иртәнге якта. Төш җитәрәк «ашыгыч ярдәм» машинасы аны сызгыртып хастаханәгә алып китте. Инсульт диделәр.

Йөрәк таза иде, күрәсең, бирешергә теләмәде. Атна-ун көн хастаханәдә аунаганнан соң, аны өйгә алып кайттылар. Степан Петрович кызында яши иде. Кияве дә бар, әлбәттә. Кияве дә яхшы, самими күңелле. Үзара бик килештереп яшиләр. Дусларча дип тә әйтеп буладыр, мөгаен. Шимбә көн икәүләп Иптәшләр урамындагы мунчага баралар. Һәр атна саен. Анда берничә мәртәбә саунага кереп, ике сәгатьләп чабынганнан, юынганнан соң җай белән кайтырга чыгалар. Сөйләшә-сөйләшә җәяү кайталар. Егерме минут тирәсе. Мунча якын, анысы әйбәт. Кияү дә, Степан Петровичның үзе кебек, мунча ярата торган кеше булып чыкты. Пошкыра-пошкыра чабына, аннан йөгереп чыга да башына бер таз салкын су коя.

Степан Петрович муенындагы тәресен эссегә кергәндә дә салмый. Күкрәгендәге калын йон арасында ул күренми дә, тик муенындагы каешланып беткән бавы гына аның барлыгын һәрдаим искәртеп тора.

Кияве дә бабасыннан күреп тәресен салмыйча кергән иде дә... бүтән алай итмәде. Тәре эсседә кызып тәнне пешерә чөнки. Һи-и, хәзерге яшьләр ни, буыннары сыек, тәннәре нәзберек...

«Безгә тигән нужа боларга тисәме?» — дип уйлый Степан Петрович. Хе-хе-хе... Күңелдән генә көлә ул. Борын эченнән. Исән-сау чагында шулай көләргә ярата иде. Рәхәтләнеп. Кешнәмичә генә. Тәртипле кеше авызын каплап көләргә тиеш, дия иде мәрхүмә әнисе... Әнисе... Нәчтүк түтәй...

«Авызыңны ачканда кулың белән капла, үпкәң күренмәсен», — дия иде әнисе. Шулай бик нык арык булды микәнни ул? Ләкин эре сөякле иде. Өтек малай булса, Иделдәге крушниклар* үз араларына алмаслар иде. Бик яшьли чыгып китте бит ул авылдан. Унбиш яшь булдымы икән, уналты-

---

* *Крушниклар* — йөкчеләр.

мы? Әллә унҗиде үкме? «Чәчүгә төшәр алдыннан тудың», — дия иде әнисе.

Авылдан киткәндә егет иде инде ул. Борын астында сары мыегы сызылып тора... Киң җилкәле, беләк мускуллары исә күлмәген ертып каядыр йөгерергә теләгәндәй уйнап тора.

Казан алар авылына ерак түгел иде.

— Ычтапаныма уңыш бир, Кодаем, — дип теләде әнисе, улы юлга чыкканда. — Ычтапаным яхшы минем, беркатлы. Дөнҗаны белми, кешенең — яхшысын, начарын аермый. Кодаем, Ычтапанга бераз усаллык бир, — дип келәү әйтте.

Аңа юаш булырга ярамый иде. Ычтапан моны Казанга килү белән үк аңлады.

Кемнең юаш буласы килсен? Тик безнең теләктән торамыни ул? Ычтапан исә юаш кеше түгел иде, аны берничек тә җебегән дип атап булмый иде. Киресенчә, үҗәт, кирәбеткән керәшен иде ул.

Ерак бабасы урынында булса, мөгаен, керәшен дә булмас иде. Андый үз киресенә каткан әдәмнәр, үлсә дә, диннәрен алмаштырмый.

Хәер, монысы башка мәсьәлә. Алла һәркемгә дә бер инде ул. Бер дип... Ычтапан калага килгәндә, аны бөтенләй юк дип игълан иткәннәр иде. Юк, вәссәлам. Әйтерсең Ходайны кемдер үтергән иде. Мәчет манаралары киселгән, чиркәү гөмбәзләреннән тәреләр бәреп төшерелгән.

Тик Ычтапанның муенындагы тәресе генә исән-сау. Әнисе кидергән тәре... Ул аны беркайчан да салмады.

Күрсәтеп тә йөрмәде, билгеле. Күрсәләр, баштан сыйпамаслар иде. «Комсомол башың белән, фәлән-төгән», — дип тотып сүгәрләр иде. Сүгеп кенә калсалар... Шул ук комсомол дигәннәреннән куып та чыгарырлар иде. Аннары кая барасың? Бу илдә бәдрәф чистартыр өчен дә комсомол булу кирәк.

Эш эзләп Усиягә төшеп китте Ычтапан. Алла бармы, юкмы, ә елга буенда, пароходлар килеп туктаган төштә, йөкчеләр, үзләренчә әйтсәң, крушниклар кирәк булуын ул белә иде инде.

Яр буендагы ике катлы йортта кечкенә генә түрә булып аның әтисе ягыннан чыбык очы туганы Григорий Васильевич утыра иде. Туп-туры шуның янына китте Ычтапан.

Шактый җәфаланганнан соң тапты Гөргөри дәдәсен. Ул аны икенче каттан эзләп йөргән, ә дәдәсе беренче катта, ишектән килеп кергән хутта ук утыра икән.

Ычтапанның кем икәнен белгәч, гозерен тыңлап бетерербетермәс үк тәрәзәдән башын тыгып кычкырды:

— Галиулла! Бире кил әле...

Йорттан ерак та түгел кояшта кызынып яткан бер төркем ирләр арасыннан җыйнак гәүдәле, чәченә чал төшкән бер агай күтәрелеп, кулын каш өстенә куйды. Гөргөрине таныгач, урынына кире утырды.

— Үзең кил.

Гөргөринең болай да кызыл киң тупсалы йөзен ялкын ялмап алгандай булды. Авыз эченнән «сбулычлар» дип сүгенде. Үзе генә булса бер хәл. Янәшәсендә авылдан аны зур нәчәлниккә санап эш сорарга килгән Ычтапан басып тора ласа. Тик ул крушникларга закон бармыни? Социалистик бригада дип аталсалар да, инкыйлабка кадәрге әртилләрдән бер аермалары юк. Менә бу Галиулланың бригадасы да тулысы белән диярлек Кәче авылыннан килгән мажиклардан тора. Алар араларына чит кешене кертергә атлыгып тормый, әлбәттә. Ләкин Григорий Васильевичның да гозерен аяк астына салып таптарга җөрьәт итмәсләр. Элекке заман түгел. Ул аларны җайга салырлык юлны белә. Ул юл чөнки социализм төзү аша коммунизмга таба бара.

— Безгә кеше кирәкми, — дип шаулашты әртилдәге егетләр.

— Ә егет болай нык күренә, — диде Озын Вәли дигәннәре. — Көрәшчеләр затыннан. Мин үзебезнекеләрне тиз таныйм.

Озын Вәлинең сүзе монда шактый ук саллы яңгырый икән, егетләр тынып калды.

Галиулла Ычтапанның беләкләрен капшады.

— Егет таза...

Бу инде үз араларына алырга ризалык билгесе иде. Тик Галиулла карарын бүтәнчә сипләп куйды:

— Безгә кеше кирәкми, Гөргөри. Тем более чит кеше. Без монда кәчеләр генә диярлек. Тик синең хакка гына алабыз без малайны. Син дә, хәлдән килгәнчә, безне тибәрмәссең...

— Килештек, — дип, Гөргөри үзенә генә хас ямьсез матур көлү белән шаркылдап алды.

— Хе-хе-хе, — дип Ычтапан да аңа кушылды. Ул малай чагыннан ук шулай көлә иде.

Гөргөри дәдәсе киткәч, кулларын кая куярга белмичә басып торган Ычтапанны оныткандай, крушниклар бүленгән сүзләрен дәвам иттеләр.

— Һи-и, егетләр, элекке заманда-а, — дип сөйли башлады Галиулла, ул инде истәлекләргә бирелә торган яшькә кергән иде. — Эше дә бар иде, ашы да... Ә син утыр, — диде ул Ычтапанга сүз арасында гына. — Ни атлы диден әле?

Хәлбуки Ычтапаннан моңарчы исем-фәлән сораучы булмады.

— Ычтапан.

— Керәшен! — диде Рәфыйк исемле сәер йөзле егет. Ул нигәдер кеше белән читкә карап сөйләшә иде. Ычтапан соңыннан белде: бу егет Кәче авылы мулласының малае икән. Ата-анасын бәлшәвикләр Себергә сөргәндә ничектер бирегә качып котыла алган.

— Муенына тавык тәпие дә аскандыр әле, — диде Фәтхи дигәне.

Күкрәгендәге хачы Ычтапанның йөрәген яндырып алгандай булды.

Озын Вәли бу сүзләргә чик куйды:

— Ташлагыз әле, егетләр, — диде. — Керәшенме-чуртмы, барыбер кеше инде ул.

Егетләр моңа килештеләр.

— Йә, Галиулла абзый, элгәре бүгенгедән яхшы идемени, — дип, Фәтхи яңадан иске эзгә төште.

— Эш ул заманда, энекәшләр... Ул заманда эше дә күп иде, ашарга да житәрлек иде. Бакалтай хәрчәүникләрендә сыер түшләре тулып ята торган иде. Хәзер нәрсә, бер туйганчы ашар өчен бер атна буе эшләргә кирәк.

— Хе-хе-хе, — дип нәкъ Ычтапанча теләмичә генә көлде Озын Вәли. — Револются булганнан бирле туйганчы ашаган юк инде.

— Син чамалап сөйлә, — диде Фәтхи һәм сизелер-сизелмәс кенә Ычтапанга ымлады.

— Менә безнең белән бераз бил бөксен әле, үзе дә ышаныр, — диде Озын Вәли. — Егет ышанычлы күренә, капчыгын селки торганнардан түгел. — Һәм ул Ычтапанга күз кысып алды.

— Алай димә, — дип, Фәтхи аңа каршы төште. — Керәшеннең акылы керәле дә чыгалы, дип юкка әйтмәгәннәрдер.

Ычтапанның йодрыклары кысылды, тик авыз ачып һични әйтмәде.

— Бүлдермәгез әле Галиулла абзыйны! — диде Рәфыйк.

— Шулай... көзнең актык көннәре иде. Күп пароходлар затонга киткән. Бакалтайда ике тоз баржасы, бер күмер баржасы, шулар янына Горбатовның ике пыяла баркасы килеп туктаган. Пароходлар затонга китәргә ашыга. Эшчеләр юк. Крушник әртилләре кайтып беткән, карамзиннардан* берәү дә калмаган. Бөтен Бакалтайда шәлеләр белән кәчеләр генә калган. Кәчеләр ул елны сайлап җыелган шикелле тазалар, барысы да кызарып торалар. Чын круш-

---

* *Карамзино* — Идел буендагы бер урыс авылы. Бу авыл, Кәче авылы кебек үк, атаклы крушниклары белән данлыклы була (Фатих Сәйфи-Казанлы искәрмәсе).

никлар: көнен эшлиләр, төнен җырлап эчәләр дә иртә белән тагын эшкә тотыналар.
— Э-эх, егетләр! — дип, Фәтхи, көлмәк итәген күтәреп, корсагын кашып алды.
— Бакалтай ярындагы баржаларны ике-өч көн эчендә бушатып бетерергә кирәк. Шәлеләр шул көннәрдә генә Любимовның ике тоз баржасын бушатып бетергәннәр. Арыганнар, җитмәсә, шул төнне кеше башына икешәр полштуф җибәреп, эт булганнар. Кубесенең башы авыртa, эшкә чыга алмыйлар, кәчеләрдән бүтән эшкә ярарлык әртил юк.
Галиулланың сүзе бетәсе түгел иде дә, кемдер:
— Әһә, пароход чыкты! — дип кычкырды.
Крушниклар, урыннарыннан кузгалып, пристаньга ашыктылар. Ычтапан да аларга иярде.
— Алар гади кешеләр иде, — диде Степан Петрович.
— Что, что? — дип аның авызына иелде кызы. — Сергей, иди сюда! Он заговорил... — Ул каударланып ирен чакырды. — Заговорил на непонятном языке. Может, это санскрит? — Инсульттан соң кемнәрнеңдер әллә кайчан юкка чыккан борынгы телләрдә сөйләшә башлавы турында ул кайчандыр укыган иде.
— Аеруча Озын Вәли... — диде Степан Петрович. — Ул ничектер мине яклый сыман иде. Ә Галиулланың кызы? Миңсылу... Аны онытып буламыни...
— Нет, это по-татарски, Надежда Степановна, — диде кияве. Ләкин аның ни әйткәнен Степан Петрович аңламады. Кызы белән кияве ул аңламый торган бөтенләй бүтән телдә сөйләшәләр иде!
— Но мы же все равно ничего не понимаем, — дип, кызы елап җибәрде. — Ты-то, может, что-нибудь понимаешь? С татарами же работаешь.
Сергей җилкәсен генә җыерды.
Беркөнне, Ычтапан кибеттән кайтып килгәндә, алар торган баракка җитәрәк, аны бер кыз туктатты.
— Син әтием бригадасыннан бит әле, Галиулланыкыннан? — дип сорады ул. — Күреп калган идем. Ычтапан, әйеме?
— Ычтапан, — диде Ычтапан.
— Әти каядыр киткән, — диде кыз. — Ә мин аңа күчтәнәчләр алып килгән идем. Бәлеш төпләре... Бик ярата ул аларны... — Кыз Ычтапанга төенчек сузды. — Тапшыра алмассыңмы? Бергәләп чәй эчәр идегез. Анда бераз өрек җимешләре дә бар...
— Нигә тапшырмаска? — Ычтапан елмайды. — Шундый чибәр кызлар кулыннан... утлы күмер дә алып була.
— Пешәрсең! — дип көлде кыз. Инде ул китсә дә була

иде, тик китми, Ычтапан каршында буй уйнатып тора. Чибәр үзе, чукынчык: чем-кара күзләр, сызылып киткән кара каш, чеменнән өзелеп тамарга торган кып-кызыл чиядәй ирен... нәни генә туры борын, елмайганда ияк очында мәхәббәт чокырлары пәйда була. Ычтапанның йөрәк тибешен ешлатып үзе гел елмаеп тора бит җитмәсә.

Ниһаять, кыз да болай торырга ярамаганын аңлады.

— Ә минем исемем Миңсылу, — дип, нәп-нәни, кып-кызу учын Ычтапанның дәү кулына сонды. — Ашыгам, — диде.

Ул кайсыдыр халык комиссарының асравы икән. Комиссарга пешерә, керләрен уа, өен җыештырып тора, нәни баласын карый. Хуҗабикә аның азга гына өйдән китеп торуын белсә дә, куып чыгару белән яный икән. Хәзер Казанда җүнле эш табуы, ай-һай, авыр.

Шуннан соң пристаньга Миңсылуның юлы суынмады. Һәм ул нигәдер гел Ычтапанныкы белән кисешә иде.

Пароход көтеп ятканда, кәчеләрнең кайчандыр шәлеләр белән тарихи кыйнашуы турында Галиулла инде ничәнче мәртәбә сөйли башлаган иде, Фәтхи дорфа гына аның сүзен бүлде:

— Ә асылкош тирәсендә тилгән әйләнә башлаган...

Барысы да, сүзнең кем турында икәнен аңлап, Галиуллага текәлде.

— Кем белә, бәлки, асылкош тилгән тирәсендә әйләнәдер, — диде Рәфыйк.

Галиулла яңа гына шәһәрдә йөреп кайткан, һәм зерәгә генә йөрмәгәнгә дә охшый — бите кызарган, күзе гайре табигый ялтырый, шул күзен алартып ул Ычтапанга карады.

— Минем керәшенгә дигән кызым юк! — диде, теш арасыннан ысылдап. — Үз ишен табар. Минем Миңсылуым шырдый-бырдый кыз түгел, — ата кеше горурланып имән бармагын тырпайтты, — сам наркомның памушнигы!

Моңа ни диясең? Ычтапан да берни әйтмәде. Калтыранган бармаклары белән тәмәке төрә башлады.

— Алай кистереп әйтмә син, Галиулла абзый, — дип елмаеп Ычтапанның җилкәсен какты Озын Вәли. — Сез, кәчеләр, без дә без дип мактанырга яратасыз. Ычтапаннан башка керәшен күргәнегез бармыни сезнең?! Ычтапан яхшы егет ул... — Озын Вәли тагын аның аркасына шапылдатып алды. — Әмма дә ләкин керәшеннең дә төрлесе була. Әйбәт, җакшы керәшеннәр муре!

Яклау өмет итеп Ычтапан Озын Вәлигә текәлде. Бүтәннәрнең дә күзе аңарда, тик алар көлүләрен чак тыеп торалар сыман иде.

— Менә безнең авылда керәшеннәр бар иде. Өч-дүрт гаилә. Җакшы кешеләр, һич сүзем юк, иплеләр. Дөрес, алар

керәшен булсалар да, чукынмыйлар иде, — дип өстәде ул нигәдер.

— Чукынмагач керәшен буламыни ул? — диде Фәтхи.

— Нигә, Ычтапан чукынамыни?

— Әсез, мөселманнар, бисмилла әйткәнегез бармы соң? — диде Рәфыйк. — Хәзер барыбыз да сәвитскиләр...

— Менә шул... — Озын Вәли сүз дилбегәсенең ычкынуын сизеп тавышын көрәйтте: — Безнең керәшеннәр авыл байларында ялчы булып тора иде. Шулай беркөнне, печән эше беткәч, бай артыграк сыйлаганмы, керәшен ялчы капкадан чыгуга ук ауган да йокыга киткән. Нәкъ шул вакыт байга күршесе кереп бара икән. Йоклап яткан керәшенне күргәч: «Байның байларча шул инде, аяк сөртергә дә капка төбенә керәшен җәеп куйган», — дип гаҗәпләнеп торган, имеш.

Егетләр шартлады. Кайсы эчен тотып бөгелеп төште, кайсысы баскан килеш кенә калтырый иде.

Ычтапан гарьлегеннән куллары белән битен каплады. Әйтерсең аңа, аның йөзенә учлап-учлап пычрак ыргыталар. Галиулланың сүзенә түзгән дә булыр иде әле, кызмача кеше ни әйтмәс. Ә менә Озын Вәлинең, яклаучым булыр дип өметләнеп йөргән кешенең мондый гамәле Ычтапанны исәнгерәткән иде. Елмаеп, кочакларга килгән кешең искәрмәстән күкрәк авызына суккан кебек... Хикмәт исерек керәшендәмени, ул бит аны мыскыл итә! Ә болар сөенә... бәхетлеләр...

Ычтапанның акрын гына китеп баруын беркем дә искәрмәде.

— Яшь чак шул, күңелемә бик авыр алганмын, күрәсең, — диде Степан Петрович.

— Что, что, — дип ачыргаланды кызы, — Сергей, послушай, может он очень важное говорит.

— Ну не до такой же степени я понимаю, — дип гаҗизләнде кияү.

Китте Ычтапан татарлыгыннан ваз кичеп Казаннан ук китеп барды. Гел урыс арасында яшәргә тырышты, бер авыз да татарча сөйләшмәскә дип үзенә сүз бирде. Егерме еллап читтә йөргәннән соң Казанга кайтканда аның тамчы да татарлыгы калмаган иде инде. Аны искәртүче дә юк — якын туганнары күптән гүр иясе, ераклары кайсы кая таралып беткән.

— Улым... — Каяндыр әнисе килеп чыкты. — Мин сине озак көттем. Ә син Казанга киттең дә югалдың. Аннары тагын каядыр киткән, диделәр. Кайтыр әле дип озак көттем... — Нәчтүк түтәй алъяпкыч итәге белән күзен сөртте. — Мин ышандым, иртәме-соңмы кайтачак Ычтапаным

дип күз нурларын түгеп сине көттем. Менә кайттың ич... — Бичара ана елап җибәрде.

— Әнием! Кайттым мин... — дип кычкырды Ычтапан.

— Вот это слово я понимаю, — диде кияү. — Маму свою он зовет...

Ычтапан исә киявенең сүзен ишетмәде. Әнисенең кечкенә гәүдәсен кочаклап, балачактан ук таныш нindидер татлы исен иснәп онытылды.

Өзелде.

## ДАРУ

Бу хатын, мөгаен, берничә төнен йокысыз үткәргәндер: күз төпләрендә күләгәләр. Бүлмәгә бик ашыгып килеп керде ул, аның белән дә бик ашыгып һәм кыю исәнләште:

— Исәнме, Ирхан!

— Исәнмесез... — Ирхан гаҗәпләнеп хатынга текәлде. Кайдадыр күргәне дә бар сыман... Бәлки, берәр мәҗлестә танышканнардыр? Тиктомалдан гына шулай үз итеп исәнләшмәс бит инде. Ләкин һич тә искә төшми шул, шайтан алгыры...

Кайчан күрде соң ул бу сабыр, моңсу карашлы соры күзләрне? Юк, үтерсәң дә хәтерләми.

— Әллә танымыйсың инде?

Ирханның кашы өскә сикереп куйды. Нидәндер канәгать булмаса, кашы шулай тик тормый башлый аның. Бу дөньяда шактый яшәлгән, кырык яшь инде ул гомернең яртысы гына түгел. Күпме кеше очрамагандыр шул вакыт эчендә, һәммәсен ничек хәтердә саклыйсың...

Әмма таныш, бик таныш иде бу хатынның йөз чалымнары.

— Адилә бит мин, Адилә...

— Адилә?..

Ирхан, авыр гына кузгалып, күрешергә ике кулын сузды.

— Гафу ит, танымый тордым. Син шундый үзгәргәнсең.

Әлбәттә, ул аны онытырга тиеш түгел иде. Беренче мәхәббәт гомер буе йөрәктә саклана, диләр ич. Бу исем аңа яшен суккандай тәэсир итәргә тиеш иде. Мәхәббәт турындагы романнарда мондый очрашулар шулай тасвирлана бугай.

Ә Ирхан тыныч кына килеп күреште. Чыраенда дулкынлануның әсәре дә сизелмәде. Сузылган куллары гына бераз кыенсына иде, ахрысы. «Ун ел бергә укы да, җитмәсә, яратып йөр! — һәм менә сиңа... Таныма! Әйе, бу инде бер-

нинди киртәгә дә сыймый», — дип татар телендә урысча уйлады ул.

Адилә тыйнак кына киенгән, күксел кофтасы тәненә сыланып тора, күкрәкләренең сулыш алган саен хәрәкәтләнүе шуңа да аермачык күзгә ташлана иде. Нигә соң аның бармаклары җиңелчә дерелди, йөзендә мескен елмаю талпына?

Ирхан борчылып куйды. Хатын-кызны белә ул, хатирәләргә бирелә күрмәсен тагын... Ул үзе үткәннәрне искә төшерергә яратмый, моны эшсез кешеләргә генә хас шөгыль дип исәпли иде. Бүгенге белән яшәргә кирәк. Нәрсә булган — үткән, һәм аны берничек тә кире кайтарып булмый. Кирәкми дә. Тормыш үзе белгәнчә ага бирә. Без фәкыйрьләр генә түгел, әллә нинди бөек затлар аның агышын үзгәртергә маташкан, тик бар да искечә, элеккечә...

Шулай да хатирәләргә боерык биреп булмый, алар тышкы тәэсирдән гөлт итеп кабынды да Ирханның мәктәп елларын яктыртып алды.

Беренче класста аларны бер юан апа укытты. Кара инде, беренче укытучының исеме дә гомер буе күңелдә саклана, диләр, ә ул оныткан... Искә төшереп тормасаң, барысы да онытыла.

Күрәсең, ул апа балалардан туеп беткән булгандыр, шуңа аларга бөтенләй игътибар итми иде. Укырга-язарга һәркем үзлегеннән өйрәнде. Ләкин арада шулкадәр киребеткән малайлар да бар иде (Ирхан хәтерли әле): кайберләре җиденче класста да укырга өйрәнә алмады. Хәер, бу аларга кирәк тә түгел иде.

Укытучы апа аларга ошый, демократия кемгә ошамасын?! Апа да канәгать, рәхәтләнеп черем итә. Тик черем иткәндә дә аның күз кабагы ябылып бетми, шуңа малайлар артык онытылып китмиләр. Бу юан апа утыз ел эчендә акбурны шулкадәр төз атарга өйрәнгән ки, ул нәкъ маңгайга килеп тия иде. Акбур ату буенча дөнья чемпионаты үткәрелсә, бу апа, һичшиксез, авылга чемпион булып кайтасы... Ирханның дус малае, бик тә шаян һәм башлы малай, маңгаена беркөнне юри мәрәй ясап килде. Укытучы апа бу юлы да ышанычны аклады, маңгайдагы түгәрәкнең нәкъ үзәгендә кызыл эз пәйда булды.

Өченче класста, ахрысы, аларга яңа укытучы керә башлады. Ул яңа гына педучилище бетереп кайткан һәм, табигый ки, аның укыту ысуллары бөтенләй башкача иде. Беренче эш итеп ул: «Малайлар белән кызлар бер партада утырырга тиеш!» — диде. Мәктәптә моңарчы күрелмәгән хәл иде бу. Кызлар белән янәшә утырырга? Мәсхәрә... Гарьчел малайлар төрлечә баш күтәреп карады: дәрестән качтылар, хәтта елап та күрсәттеләр. Тик яңа укытучының

таш бәгырен күз яшьләре генә йомшартырлык түгел иде шул.

Укытучы Ирханны Адилә исемле кыз янына утыртты. Ирхан баш күтәреп маташмады. Кушалар икән, димәк, шулай кирәк дип уйлады ул. Малай һәрнәрсәнең файдалы якларын күрә белә иде. Кыз яхшы гына укый, өй эшен һәр көнне эшләп килә. Ирхан исә, караңгы төшкәнче җил куып йөреп, күп вакыт дәреслекләрне кулына да алмый. Өйгә керү белән ястыкка аву ягын карый. Зыян юк дип уйлый ул, мәктәпкә баргач, Адиләдән рәхәтләнеп күчерермен әле.

Кыз башта каршы килеп маташты маташуын. Ләкин Ирхан усал иде, аңа каршы торуның файдасыз икәнен кыз бик тиз аңлап алды.

Беренче дәрестә үк, бөтен классны сискәндереп, кычкырып җибәрде Адилә һәм, партага капланып, мышык-мышык елый башлады. Укытучы, билгеле, шунда ук килеп җитте. «Нәрсә булды?» — диде ул, Ирханга карап. Малайның йөзе тыныч һәм салкын иде: «Эчем авырта, ди...» Кыз эндәшмәде. Ирхан ботымнан чеметте дип әйтергә оялды. «Бар, алайса, өеңә кайт», — диде укытучы. Адилә сумкасын күтәреп елыйелый өенә кайтып китте.

Бу беренче җиңүеннән соң Ирхан кызның тулы хокуклы хуҗасына әверелде. Тәнәфестән кергәндә китап-дәфтәре парта өстенә алып куелган була, дәрес беткәч тә ул аларны букчага салып мәшәкатьләнми, барысын да Адилә башкара.

Бүтән малайлар аңардан көнләшәләр. Әмма берсенең дә үзен шундый дәрәҗәгә куярга усаллыгы җитми. Хәер, алар шунысын да белә: Ирхан белән янәшә утырсалар, үзләре дә Адилә хәлендә калачаклар... Шуңамы, Ирхан мәктәпне соңыннан берүзе бер партада утырып тәмамлады.

Икенче елны реформатор укытучы аларга керми иде инде. Моңа иң шатланган кеше Адилә булгандыр. Ул, ниһаять, Ирхан тираниясеннән котылды.

Ә мәхәббәт соңрак килде. Алар бу вакытта тугызынчы класста укыйлар, Ирхан озын буйлы, киң җилкәле егет, мәктәпнең иң яхшы футболчысы. Көчне дә табигать җәлләп бирмәгән, гер күтәрү буенча да мәктәптә аңа җиткерүче юк иде.

Ул һәрдаим үзендә Адиләнең карашын сизә башлады. Ләкин карашлар очрашса, кыз кызарып күзләрен читкә ала. Ирханның да андый чакта башына шаулап кан йөгерә. Йә, мәхәббәт дими нәрсә дисең моны? Кыз инде аның тираниясен оныткан. Бәлки, онытмагандыр да, кеше элеккә тираннарга мәрхәмәтле була бит, тора-бара аларны хыялында яңадан пьедесталга менгерә. Кызның мәхәббәте дә шушы омтылыштан үсеп китмәде микән әле?

Югалткан хакимлеген торгызу Ирханның уенда да юк иде. Кыз өстеннән андый басымчылык итү егет кешене бизәми, һәм кыз да элеккеге роленә риза булмас иде тәгаен.

Нинди хакимлек ди ул, Ирхан үзе хәзер рәхәтләнеп кызның вак-төяк йомышларына йөгерер иде әле. Һәр сүзенә буйсыныр иде, шул мизгелләрдә үзен бәхетле санар иде!

Тамырларында шундый гаҗәеп хис уянуын ул яз көне сизде бугай. Гаҗәп тә түгел, яз табигатьнең уянган, суларның кар астыннан тибеп чыккан чагы, бөреләрнең шартлап ярылган вакыты. Кайсыбыз гына ул чорда гашыйк булмаган да, сөйгәненең күзләренә карап дөньясын онытмаган. Ирхан соңыннан күп кыз-хатын күрде, тик тойгыларының шулай рәхәт итеп йөрәген кымырҗытуын бүтән бер тапкыр да татый алмады. Мөгаен, аңарда мәхәббәт өчен талант та юктыр, бу беренче хисләре дә табигатьнең аның белән шаярып алуы гына булгандыр... Ирхан моңа борчылмый, билгеле, аның кебек талантсыз кешеләр бик күп бит җирдә, хәтта кирәгеннән артык күп.

Озын тәнәфестә алар мәктәп каршына футбол уйнарга чыгалар. Тәрәзәләр ачык, Ирхан үзен Адилә күзәтеп торганын белә, андый чакта ничектер капкага да төгәлрәк тибә иде.

Алар бер тапкыр да хисләрен бер-берсенә белдермәделәр. Беренче сүзне Ирхан әйтергә тиеш иде, ул булдыра алмады, кыюлыгы җитмәде. Югыйсә аларның яшерен мәхәббәте беркем өчен дә сер түгел иде бит.

Кыз көтте, озак көтте. Гадәттә, андый чакта кыз-хатын мәхәббәте нәфрәткә әверелә.

Чын-чынлап гашыйк идеме соң аңа Ирхан? Мәктәптән кайтканда ул аның эзләренә карап сокланып кайта иде. Әлбәттә, бу эзләр бүтән шундый ук эзләрдән берни белән дә аерылып тормагандыр, ә Ирхан аларның аерымлыгын таба, алар Адиләнеке, шуңа күрә бөтенләй башкача, бөтенләй үзгә иде. Ярата идеме соң ул аны чын-чынлап? Ирхан, билгеле, Фәрхад та, Таһир да түгел, тормышта андый кешеләрнең булуына ышанмый да ул. Болар барысы да әкият, хатыннар елап тыңласын өчен шагыйрьләр уйлап тапкан аларны.

Ә ул яраттымы соң? Чын идеме соң аның яратуы? Шәһәргә укырга килгәч тә, Адилә турында бик еш уйлады бит ул... Аннары сирәгрәк уйлый башлады. Бераздан Адилә ерагайды, ерагайды, ерагайды...

Кем белә, бәлки, шагыйрьләргә ышанырга кирәктер? Юк, үзе ярата алмаган кеше ышана алмый. Талант белән талантсызлык икесе ике якта...

Ирханның ышанасы килә. Ул уйлый, төшенергә тырыша. Юк, мөмкин түгел. Барысы да әкият, синтементаль әки-

ятләр. Аларга хәзер мәктәп баласын да ышандырып булмый. Алар да хәзер мәхәббәтнең ни-нәмәрсә икәнен күреп беләр.

Илаһым, әкиятнең чынлыгына акыл белән ирешеп буламы соң?! Бәлки, кечкенә генә булса да йөрәк кирәктер аңа...

Язмыш булган икән, Ирхан барыбер классташына өйләнде. Мәктәптә укыганда ул аңа югыйсә игътибар да итми иде. Аны чибәр дип әйтеп булмый, Адиләдә булган тыйнак матурлык та юк иде аңарда.

Ир хатынының кыяфәте башка ир-атлар күзенә бәрелеп торырга тиеш түгел. Ирханның дуслары чибәр хатыннар белән яшәп карады. Җүнле булмады аларның тормышлары. Авылда, бәлки, мондый куркыныч янамыйдыр да... Анда барысы да күз алдында. Ә монда — шәһәрдә — теленә шайтан төкергән ир-егетләр шундый күп... Алар фәрештәңне дә юлдан яздырыр...

Аның өйләнүе дә гади булды. Ул мәхәббәттә аңлашып, кәләшенә чәчәкләр ташып йөрмәде. Вакыты юк иде. Өйләнергә кирәк, яше җитте. Шуны аңлаган егет ипи заводында эшләп йөрүче сабыр һәм астыртын кызга үзенең тәкъдимен әйтте. Сүзенә колак сала торган, уңган хатын кирәк иде аңа. Ул ялгышмады. Ирхан беркайчан да ялгышмый иде.

Адиләнең шулай кинәт кенә килеп керүе аны күнегелгән халәтеннән чыгара алмады. Аның дөньясы җиде йозак белән бикләнгән, аңа болай гына үтеп кереп булмый. Ул бу дөньяга үзе генә хуҗа, вак-төяк йомышларны үтәргә хәтта өченче класстагы Адилә дә кирәк түгел иде инде аңа...

— Хәлләр ничек соң?

Ирхан, игътибарлы булырга тырышып, Адиләгә текәлде. «Нигә мин болай соң? — дип гаҗәпләнеп уйлады ул. — Күңелдә бирәр сөенечме шунда, ниме булырга тиеш бит инде. Мин дә кеше ләбаса. Без бит аның белән бөтенләй үк ят кешеләр түгел».

— Сөйлә әле, Адилә, синең турыда бик тә беләсем килә...

Бернәрсә дә беләсе килми иде аның. Һәм шул чакта гына ул аңлап алды: яратмаган ул аны... Беркайчан да яратмаган...

Ирхан бу уен башыннан куарга теләде. Күп сулар акса да, кайчандыр кемнедер ярата идем дип уйлау рәхәт бит! Ул аны оныткан гына... Вакыт дәвалый, вакыт үтерә. Эзләренә кадәр соклана иде ич. Бөтенләй үк боз җанлы түгел бит инде ул. Аннары, теге чактагы Адилә искитәрлек бүтән иде дип уйлады ул, акланганлай. Хәзер аның каршында башка Адилә утыра инде. Ят, чит... Бу ике Адилә арасында аерма җир белән күк арасы.

— Синең үтенеч белән килгән идем, Ирхан.

Шулай инде дип үртәлде Ирхан. Үтенеч белән! Башкача беркем беркемне беркайчан искә алмый.

— Ирем бик каты авырып ята. Импортный дару кирәк. Менә... — Адилә аңа латинча нидер язылган кәгазь кисәге сузды. — Беркайдан табып булмый... Ярдәм итә алмассыңмы?

Ирхан, әлбәттә, гафу ит, бер дә андый мөмкинлегем юк, дип әйтә ала иде. Һәм бу дөреслеккә дә туры килә, кайдан андый дефицит даруны тапсын ул, медицинага берничнди катнашы юк ич аның...

Адилә, аның уйларын сизгәндәй, ашыга-ашыга сүзен дәвам итте:

— Танышларың булса гына инде. Аптыраганнан килдем. Бик тә авыр ята бит.

Хәзер мышык-мышык елап алачак дип уйлады Ирхан. Тагын балачагы искә төште. Чеметкәч ничек өзгәләнеп елаган иде бит...

— Тырышып карармын... — Тавышы үзгәреп китте. Үзе дә сизмәстән борынын тартып куйды. Малай чактагы төсле... Халәтен Адиләгә сиздермәс өчен, тиз генә урыныннан күтәрелде.

— Әйдә, андый эшне телефоннан сөйләшмиләр. Киттек.

Дару сорап ни өчендер телефоннан сөйләшергә ярамаганны Адилә аңламады булса кирәк. Әмма Ирханнан сорарга уңайсызланды.

Ул шоферга Бутлеров урамына борылырга кушты.

— Бу яңа дару... — диде аңа танышы Рәүф абзый. — Белмим, табып булыр микән... Моны көндез чыра яндырып эзлиләр. Маде ин Япан!

— Бик кирәк иде бит.

Танышы көлемсерәде.

— Даруны бик кирәк булганга гына эзлиләр дә инде, дустым. Хәзер, Марк Абрамовичка шылтыратып карыйм әле.

Трубканы куйгач, ул кәгазьгә ашыгып нидер яза башлады.

— Мә, шушы адрес буенча бар. Синең өчен генә...

— Рәхмәт, туган, коткардың... — Ирхан хисләнеп Рәүф абзыйның кулын кысты. — Очрашырбыз әле.

Машинага утыргач, танышы язып биргән кәгазьне шактый озак өйрәнергә туры килде аңа.

— Нигәдер бу врачларның язулары бик алама була... — диде ул, Адиләгә борылып... һәм елмаеп куйды. Бу хатынга ярдәм итә алуына сөенгән иде ул...

Адилә машинада утырып калды. Даруны алып чыгып биргәч, ул кечкенә сумкасында казына башлады.

— Күпме?
— Юкны сөйләмә, Адилә...
— Юк, шулай да? Алай булмый...
— Әйттем бит инде. — Ирхан ачуланган кыяфәт чыгарды, һәм Адилә, өченче класста укыган вакыттагы кебек, тынып калды. — Озатып куям...
— Горкига, — диде хатын, җансыз тавыш белән.
Машина тугыз катлы йорт янына килеп туктады.
— Әйдә, күреп чык, Ирхан.
Ирханның аларга керергә нияте юк иде, ләкин ул, үзе дә сизмәстән, Адиләгә иярде.
— Үзен генә калдырып киткән идем, үпкәләп ятадыр инде... — дип сөйләнде хатын.
Ирхан эндәшмәде. Авыр тынлыкта лифтның ыңгырашып күтәрелгәне ишетелә иде. Чирле кеше янында Ирханны һәрвакыт күңелсез уйлар биләп ала. Һәр кеше дә шулайдыр инде. Каты авыру кырына әҗәл елышкан була бит, салкын сулышы синең дә йөзеңә килеп кагыла шикелле. Ирексездән үзеңнең дә киләчәктә шундый хәлдә каласыңны, дөнья белән иртәме-соңмы бәхилләшергә мәҗбүр буласыңны искә төшерәсең...
Адилә озак кына ишекне ача алмыйча интекте.
— Менә кайтып та җиттек.
Фатирда үле тынлык иде.
Борынга авыр ис килеп бәрелде. Авыру озак яткан бүлмәдә шулай була. Монда дару исе, бәвел исе, тагын әллә нинди исләр бергә кушылган иде.
Ирхан түрдә яткан авыруның гадәттән тыш сары йөзенә игътибар итте. Ул ябык, борыны очлаеп калган, иягендәге төкләр сәер булып тырпаеп тора. Күзе йомык, тирән булып чокырайган...
— Атасы... — Адилә кулы белән иренең маңгаена орынды. — Атасы...
Идәнгә сыгылып төшкән хатынны күреп, Ирхан аңгырап китте.
Шулай да бер мизгелдән аңа үз акылы кайтты. Нишләргә? Китәргәме? Килешмәс. Юатыргамы? Мондый чакта нәрсә дип юатасың? Мондый чакта су алып киләләр бугай.
— Авызыңа су да сала алмадым бит... — Адилә илереп елый иде.
— Адилә, үз-үзеңне бетермә... Мә, су...
Хатын сулы стаканны этеп җибәрде:
— Кит!
— Үлгән артыннан үлеп булмый, Адилә, тынычлан... — «Нинди ахмак сүзләр», — дип уйлады Ирхан. Ә тагы нәрсә әйтсен соң ул? Башка сүзләрне Ирхан белми иде.

— Су да сала алмадым... Берьялгызың бит... Соңгы сулышыңда... А-а-а...

Адилә учындагы даруны Ирханга ыргытты:

— Кит! Кит! Нәрсә сузаеп торасың монда?! Калдыр безне...

Ирхан акрын-акрын артка чигенде.

— Бүген нигәдер соңга калдың... — диде хатыны.

— Җыелыш булды.

Ашап алганнан соң, ул озак кына телевизор карады. Соңгы яңалыкларны тыңлаганда, йокы бүлмәсеннән хатынының тавышы ишетелде:

— Ят инде... Иртәгә иртә торасы ич...

Әйе шул, иртәгә ял, дачага барырга сөйләшкәннәр иде. Ирхан чишенә башлады.

— Бүген Адиләне күрдем, — диде ул хатынына.

— Нинди Адилә тагын?

— Безнең белән укыды. Классташ...

— Шулаймыни? Нәрсә сөйли?

— Ире үлгән... — Ирхан юрган астына чумды.

— Бәхете булмады инде аның да... — Хатын, учы белән авызын каплап, иснәп куйды. — Телевизорны сүндерергә оныттыңмы?

# БАЛА

Тулай торакның ишегеннән килеп керүгә үк борынга мәче сидеге катыш әллә нинди әчкелтем-төчкелтем авыр ис килеп бәрелде. Стеналардагы штукатур кубып төшкән, күптән юылмаган идәндә чүп-чар өелеп ята. Тәрәзәсе ватык кечкенә бүлемтәдә вахтер әби сохари җебетеп чәй эчеп утыра, ул керүчегә төксе күз карашын ташлады да янә кара-кучкыл стаканын авызына китерде. Икенче катка күтәрелгән тештә зур итеп урысларның яраткан өч хәрефле сүзе язылган иде. Бүлмәсенә килеп җиткәч, ул кечкенә сумкасыннан ачкычын эзли башлады. Гаҗәп хәл — ир-атлар, үз ишекләренә җитәргә байтак ара калгач ук, ачкычларын барлап учларына алалар, ә хатын-кыз кайтып җиткәч кенә букчасында яисә кесәсендә актарына башлый.

Коридор очында, бәдрәфкә каршы, аның күршесе тәмәке тартып тора иде. Кинчә йөзенә гадәттәгечә кызыл төс йөгергән, андый чакта ул үткән-сүткән хатын-кызга сүз кушарга, хәтта кайчакта, җае туры килсә, кулы белән йомшак җирен ә

орынып алырга да ярата иде. Ләкин бу юлы эндәшмәде, тәмәке көлен идәнгә чиртеп төшерде дә тәрәзәгә борылды.

Хатын болай күз төшмәслек түгел түгелен. Арча ягындагы чирмеш кушылган авылларда туучыларга хас булганча, җирән чәчле, яшькелт күзле, почык борыны тирәсенә сирәкмирәк сипкелләр сибелгән. Бераз кәкрерәк булса да, аяклары да матур, гәүдәсе дә төз.

Әмма күрше егет тәрәзәдән башын алмады.

Ниһаять, кыйшайган ишек ыңгырашып кына ачылды. Бүлмә пөхтә итеп җыештырылган, ишек төбендәге ике шкаф арасына бау сузып чаршау эленгән. Түрдә — тәрәзә буенда — читәнле бала караваты тора. Аның баш очында Филипп Киркоровның зур сурәте эленгән.

Үз тизәгенә буялган бала торырга азапланып ята, быдыр-быдыр килә, бияләй кебек асылынып төшкән аскы иреннән селәгәй ага иде, ул әнисе кайтканны төшенә иде, ахрысы.

Хатын имәнеп китте, һәрвакыт шулай, инде биш ел узуга карамастан, ул үз баласының кыяфәтенә күнегә алмый, кайтып керүгә, аны күргәч имәнеп китә.

Өстен дә салып тормыйча коридорга чыгып китте, табак белән җылы су алып керде, баласын чишендереп шунда утыртты, үзе плитәгә манный боткасы пешерергә куйды.

Баласын юындырган вакытта күз чокырына җыелган яше пылт-пылт итеп табактагы суга тамды. Көн саен күз яше катыш суда юынган гарип баласы савыгырга, аякланырга, күзе, теле ачылырга тиеш югыйсә... Юк шул, юк шул... Баланың аңы үзе генә белгән караңгылыкта адашып йөри, бу дөньяда алыш-биреше юк иде.

Тапкач та табиблар аны күпме үгетләделәр, туган-тумачасы да сүзгә килеп бетте: «Калдырып чык, бу беркайчан да кеше булмаячак, гомерлек бәла, мәшәкать белән тормышыңны әрәм итәчәксең», — диделәр. Тыңламады. Ничек инде үз балаңны, бәгырь җимешеңне, үз кулың белән чит-ят кулларга биреп калдырасың? Алып кайткач та, авылдан килгән әнисе — үзе дә яшьтән тол калган хатын — караватка капланып елады. «Ирең дә юк, бу гарибеңне ничек кенә карап тәрбияли алырсың, и бәхетсе-ез...» — дип такмаклады. Кыя кебек торды ул вакытта яшь ана, илдә чыпчык үлми, янәсе.

«Бәлки, чыпчык үлмидер дә, — дип уйлана ул хәзер, — әкеше үлә, үлә, җанкисәгем. Әнә теге атнада гына өченче катта яшәүче ялгыз карт, түзәрлеге калмагач, тәрәзәдән ташланып үлде». Соңгы вакытта аны гел чүп савытлары тирәсендә күрәләр иде, ул шуннан калдык икмәк кисәкләре, бәрәңге кабыклары җыеп алып кергән икән. И юләр баш,

дөнья күрмәгән бәндә, шул чакта табибларның, әнисенең сүзен тыңлаган булса соң... Соңрак аңлады ул аларның хаклыгын, берәр балалар йортына-фәләнгә тапшырырга дип йөреп тә карады. Аны ишектән үк кире бордылар. Андый төшләр гарип балалар белән шыплап тулган иде. «Алай гына булмый, баланны алып калсын дисәң, детдом нәчәлнигенә төртергә кирәк, жаным». Ә кайдан алып төртәсең? Ул үзе дә шул баласына дип бирелгән пенсиягә җан асрап ята. Инде менә ярты ел эш эзли, кая гына җитмәде, яшь баласы барын белүгә үк ишектән кире боралар.

Ул баласын итәгенә алып, манный боткасы ашата башлады, кашыктагы ботканың яртысы гына авызга керә, яртысы ирен читләреннән аска агып бара иде.

Баланы ул инде утызга килеп җиткәндә, ялгызы калудан куркып, картлыгында бер терәк булыр, ичмасам, дип тапкан иде. Төс-кыяфәте мөлаем гына булса да, егетләр аңа ябышмыйлар, күзендәге салкынлык, йөзендәге җитдилекме аларны якын җибәрми иде. Егетләр бит чыркылдык, җиңел холыклы кыз-кыркынны ярата, өйләнгәнче алар белән шаярып алгаларга җайлы сыман тоела. Ә өйләнгәндә, әлбәттә, җитди, якын җибәрми торган кызларны карарга кирәк. Әмма, ни хикмәт, алар, төннәрен кунгалап-нитеп йөри торгач, шул уйнак кызларга күнегеп китәләр, үзләре дә сизмәстән шуларга өйләнеп тә куялар иде.

Ул кичне ахирәт кызының туган көне гадәттәгечә башланды. Табын мул иде, көне буе алар кышкы салат, «шуба», винегрет әзерләделәр, токмачлы-итле аш пешерделәр. Өстәл уртасында аракы, шәраб шешәләре тырпаеп утыра. Кара озын чәчле, йөзен куе сакал баскан егет касәләргә шампан койды, ниндидер тост әйтте. Ул каядыр Казан читендәге бер хастаханәдә баш табиб булып эшли икән.

— Как в лучших домах Лондона и Парижа, — диде ул, винегретны сакалы арасына батырып алдыннан.

Бераз кыза төшкәч, бу сакаллы тагын сикереп торды: «Милләт өчен! — дип кычкырды. — Торып басып эчик».

Ахирәт кыз янына килеп йөри торган аксыл чырайлы, сары чәчле егет хатын-кызларны мактап ниндидер тост әйтеп маташты. «Дөньяда ямьсез хатын-кызлар булмый, исергәнче эчәргә кирәк», — дип янә сүзгә кушылды сакаллы табиб. Кызлар, аның ни әйтергә теләгәнен аңлап бетермәсәләр дә, хахылдап көлеп куйгандай иттеләр.

— Син нишләп күңелсез? — дип ахирәтенә ябырылды туган көнен үткәрүче кыз. — Яле, күтәреп куй берне.

— Әйе, нигә алай аерымланып утырасың? — дип, сакаллы табиб та аның янына елыша төште. Кыстый-кыстый бер чәркә аракы эчерделәр.

Дөнья үзгәреп китте! Кыз юк сәбәптән дә көлә башлады. Табында яңгыраган һәр исерек сүз үткен, зирәк булып тоела иде.

Мәҗлес таралгач, кара сакал аны бүлмәсенә кадәр озата барды. Чайкалып киткәндә ул кызның иңенә таянгалап ала, үзе: «Менә бу кулларны күрәсеңме? Алтын куллар... Миндәй врач табып карагыз Татарстанда», — дип сөйләнә иде. Бүлмәгә кергәч тә йодрыгын төйнәп нигәдер «Азатлык!» дип кычкырып маташты.

Кыз аны кумады. Кая куу — төннәр буе ялгызлыктан интеккән тәне белән куе тир исе килеп торган иргә сыланып ятты. Иртән торып киткәндә:

— Татарны арттырырга кирәк. Ату урыс басты дөньяны, — дип мыгырдады ир.

Шуннан соң хатын аны күрмәде. Бала тудыру йортына да аны ахирәт кызы гына озатып куйды.

Караңгы төшеп килә иде инде. Тәрәзә каршында үскән кырыкмыш өянке канатсыз кош кебек күккә тотына, чарасызлыктан ыңгыраша сыман иде. Хатын тумбочка өстендә яткан кәгазь тартманы кулына алды. Бүген иртән аны ахирәте кертеп чыккан иде. Ул инде кияүдә, өч бүлмәле фатирда рәхәтләнеп тормыш итә, ике бала үстерә. Затлы тунын җилбәгәй җибәреп бик тиз генә әйләнде ул. «Вакытым юк, кунакка ашыгам, — диде. — Менә сиңа ампула. Бик зур блат белән генә таптым. Бер укол җитә. Ул бит барыбер кеше түгел. Нигә үз-үзеңне җәфалап яшисең? Син аңа бит яхшылык кына кыласың — туп-туры оҗмахка керә инде ул, гөнаһсыз җан... Ул да бу тәмугтан котыла, син дә... Тик телеңне генә тик тот, юкса бу гарипнең нидән үлгәнен кем тикшереп торсын. Сиңа яхшы булсын дип тырышам ич, юләр...» — Һәм ул бүлмәдә затлы хушбуй исләре калдырып чыгып та китте.

Алар бу хакта ничәмә-ничә тапкыр сөйләшкәннәр иде инде. Хатын хәтта төш тә күрде: баласы канат җилпеп фәрештәләр белән очып йөри, имеш. Тирә-юньдә кошлар сайрый, чишмәләр челтери, җимешләр пешеп утыра. Оҗмах инде, оҗмах... Анда аңа әйбәт булачак, анда Аллаһы Тәгалә аның дүрт санын төгәл итәчәк...

Укол кадаганда бала еламады. Ул, мөгаен, авыртуны да сизми иде. Бармакларсыз кулын гына каядыр сузгандай итте.

Хатын утны кабызмады. Караңгы сарган тәрәзәгә карап кымшанмый утыра бирде.

Өченче көн аңа училищеда бергә укыган егет очраган иде. Якында гына яшәгәнен белгәч, бүлмәсенә кереп чыгарга рөхсәт сорады. Тиз генә кибеткә кереп шәраб, шоколад

ише әйберләр алды. Егет кызмача, хатын ягыннан зуррак нәрсәгә өмет иткәне дә күренеп тора. Кибетләргә кереп шулай өтәләнеп йөрүе кайчандыр бергә укыган кызны сагынудан түгел ич инде. Ул чакта егет аңа игътибар да итми иде.

Хатын ачкычны бик озак тишегенә туры китерә алмыйча азапланды. Балам бар дигәч, аеруча сөенеп киткән егет түземсезләнеп янәшәдә таптанып торды. Ләкин кереп баланы күрүгә, аның йөзе агарынып китте. Өстәл тирәсендә бераз урынлы-урынсыз сөйләшеп утыргач, шәрабны да эчеп бетермичә, егет чыгып китте. «Киләм әле, киләм», — диде ул киткәндә. Аның бүтән монда килмәячәге икесенә дә ачык иде югыйсә.

Инде ир заты күрмичә картаячагына ул үзе дә ризалашкан иде. Дөрес, аңа әрмәннәр белән сугыштан качкан бер малай сымак әзәрбайҗан килгәләп йөрде. Аның шәһәрдә ике ларегы бар, анда ялланган кызлар утыра, үзе исә базардан шуларга һәр иртәне җиләк-җимеш китерә иде. Әзәри саран түгел, бозыла башлаган җимешләрне аңа шактый мул ташыды. Баланы күрүгә дә чирканмый иде. Тик соңгы вакытта ул да килүдән туктады.

Бала сәер авазлар чыгарып караватында ята, ә болай бүлмәдә тынлык, шомлы тынлык. Хатынның бугазына төер тыгылды да, ул акылдан шашынган төсле ишеккә ташланды.

Урамда яз сулышы, корымлы пычрак карлар йортлар күләгәсендә генә калган — эреп бетә алмыйча интегәләр.

Ул үзенең кая барасын белмичә атлады да атлады, караңгы урамнардан узды, шыксыз ишегаллары аша үтте, анда җыелып торган үсмерләр аның артыннан ямьсез сүзләр әйтеп көлешеп калдылар.

Кире кайтканда, тулай торак ишеге эчтән бикләнгән иде инде. Бик озак шакып торгач кына теге якта гадәти мыштырдау ишетелде. Вахтер карчык сукрана-сукрана ишекне ачты, хатынга иксез-чиксез нәфрәт белән карап читкә борылды. «Йөриләр төне буе өстерәлеп...»

Хатын аңа каршы сүз әйтеп маташмады, бусаганы үтүгә икенче катка йөгерде. Бүлмәгә кергәч, утны кабызды, кинәт күзенә ыргылган яктылыктан башта берни дә күрми торды. Күргәч ахылдап куйды: «Бала-ам...» Ә баласы караватның читенә тотынып баскан, елмая, иреннәрен бөрештереп: «Әни!» — ди.

Хатын, газиз баласына, бәгырь җимешенә таба ике кулын сузып, язгы тәрәзәгә таба атлады. Анда — тәрәзәнең теге ягында — дөнья матур, дөнья киң иде.

# ИТЕК

— Әй, булмый болай, — диде хатын, — үзем өскә меним.

— Җайдак... — Ир ятакка чалкан килеп төште. Урамдагы утлардан төшкән яктылыкта аның вак йөз сызыклары аермачык булып күренә, уч төбедәй ак чырай кечкенә башка ябыштырып куелган кебек тоела иде. Күзлеген салгач ул шулкадәр чарасыз, баласымак кыяфәткә кергән иде ки, хатынның аңа карата җәлләүле мәхәббәте тагын да тулышып, мөлдерәгән имиләреннән ирнең тар, йонсыз күкрәгенә тамчылап тамар төсле иде.

Караваг бөтен тутыклары белән көчәнеп ыңгыраша башлады.

Юка стенаның теге ягында кемнеңдер шаркылдап көлгәне ишетелде.

Бүлмә давылда калган иске көймә кебек шыгырдап чайкала иде.

Тәрәзәләр капшанып пәрдә эзләделәр.

Тулай торак, ерак галәмнәргә омтылган кораб сыман, космик тизлек белән күккә ыргылды.

Шул вакыт каты итеп ишек шакыдылар. Хатын, сулышын тигезләргә тырышып: «Ачма», — дип пышылдады. Ир аңа сыенып бетте, бу дөньялыктан качып, аның тәненә сеңәсе, бөтенләй моннан югаласы килә иде.

Ишекне йодрык белән төйделәр.

— Ач, сез өйдә бит, беләбез, — дип кычкырды кемдер.

Тормыйча булмый иде. Ир ыштанын киде дә өметсез адымнар белән ишеккә таба китте. Коридорга чыкты, күзенә сикергән әрсез яктылыктан беравык сукыраеп торды.

— Нигә ачмыйсың, авызыңны фәлән...

Ул тавыштан таныды: бу — күрше бүлмәдә торучы богыл гәүдәле егет иде.

— Йокларга яткан идек, — дип гаепле төстә мыгырдандЫ ир.

— Мишәйтләдек мәллә, Кандала? — дип авызын җәеп көлде күршесе, калын иреннәре табак биткә генә сыешмыйча, яңгырдан соң шыткан суалчаннар сыман, колагына таба шуышты. — Төн озын әле... Безнең җитмәде, синең алып куйган «чистай малаең» юкмы? Акча бар...

Бу егет автобус йөртә — чып-чын гегемон. Шулай да күршесенең институтта Кандалый иҗатына карата фәнни хезмәт язуын кайдандыр ишетеп калган, хәзер очрашкан чакта аны «Кандала» дип кенә атый иде.

— Кайдан килеп...

— Бәлки, хатыныңда бардыр?

— Юк инде, булса кызганыч түгел...

Хезмәт хакы очын-очка ялгарга җитмәгәч, ул өенә аракы алып кайтып куя, аны төнлә тугарылып киткән егетләргә кыйбатрак бәягә сата иде. Нишлисең, чәй-шикәргә булса да ярап тора. Ләкин соңгы арада ул тәмам корыды, мондый «бизнес» белән шөгыльләнерлек тә рәте калмады.

Күршесе, хәлнең өметсез икәненә ышанып, кулын селтәде дә шаулап торган бүлмәсенә таба китте, авыз эченнән: «Интеллигент сраный», — дип сүгенгәне ишетелеп калды.

Хатыны янына ире килеп ятканда аның дәрте дә беткән, йокысы да качкан иде.

— Бер сүз әйтсәм, ачуланмыйсыңмы? — диде хатыны, шактый гына яткач.

— Нигә ачуланыйм, әйт...

— Итегем бик тузган бит, яңасын алырга иде...

— Күптән алырга кирәк иде дә... — Ир авыр сулады. — Тик на какие шиши?

— Мин бергә эшли торган хатыннан биш йөз тәңкә алып тордым. Ачуланмыйсыңмы?

— Юк, нигә ачуланыйм... Тик... кайчан түли алырбыз икән соң ул әҗәтне?..

Хатын иренең битеннән үбеп алды:

— И-и, әйбәт тә кеше инде син.

Ир читкәрәк авышкан булды, үзенең йөз мускуллары язылып китте. Нииндидер яхшы гамәл эшләгәненнне аңлаганнан соң шулай була.

— Итек сиңа да кирәк инде ул... — Хатыны тагын аңа елыша төште. Алар селкенгән саен, пружиналы караваат эчне пошырып шыгырдап куя иде.

— Бу кышны, бәлки, чыгып булыр...

— Бүрек тә кирәк, — диде хатыны, аны тыңламыйча.

Ир студент вакытта алган арзанлы бүрек киеп йөри иде.

Башта алар кооператив фатир алырга дип, тамакны кысып, акча җыйдылар. Ләкин җитәрлек акча тупланып бетте дигәндә, инфляция аркасында, ул бернигә ярамаслык булып калды. Аннан соң инде аларга җыярлык та, рәтле бүрек алырлык та акча кермәде.

— Алайса, иртәгә мин базарга чыгам... — Ире аркасы белән борылып ятты.

— Йоклыйк, вакыт соң инде... Сиңа бит анда таң тишеgennнән торып барырга кирәк.

Хатын нәкъ иртәнге биштә урыныннан сикереп торды. Чәй кайнатып маташмады, кичәгесен генә берничә мәртәбә уртлап куйды, салкын тары боткасы капкалады.

Ишек төбендәге шкаф артына куелган аш өстәле кечкенә генә, җыйнак кына иде. Түшәмдәге зәгыйфь утның

яктылыгы «зал ягына» да төшә, анда караватта җәйрәп яткан ирнең чырае аксылланып күренә иде. Хатын килеп аңа берара карап торды. Ирнең авызы ярым ачык, шул төштә мендәре бераз юешләнгән. Авыз сулары бүленерлек нинди төшләр күреп ята икән ул?

...Әле яктырмаса да, базар тулы кеше иде. Моңарчы андый төшләрдә йөргәне булмаганга, хатын аптырап, миңгерәеп калды, кая барып бәрелергә белмичә, бер читтәрәк таптанды. Ләкин озак торырга туры килмәде аңа, кинәт алдында, җир астыннан чыккандай, кечкенә буйлы, каратут йөзле бер егет кисәге пәйда булды.

— Нәрсә кирәк чибәр ханымга? — диде ул, чәтелдәп, утлы күмердәй күзе белән хатынның өстен-башын капшап чыгарга да өлгерде. — Күгәрчен сөте дә табып бирә алам!

Хатын каушады, тавышы әллә чыкты, әллә эчкә йотылды:

— Кышкы сапожки...

— Сапожки? Ничәнче размер? Утыз сигезме?

Хатын, «әйе» дигәндәй, башын селкеп куйды. «Хәзер, җанкисәгем», — дип, егет каядыр китеп тә барды. Аның соңгы сүзләре хатынга нигәдер «җан көеге» булып ишетелде. Менә нинди була икән ул кала базары! Аның үз авылларындагы базардан башканы күргәне юк иде. Анда һәр чәршәмбе көнне мәйданга кешеләр җыела, күрше-тирә яктан чуашлар сыердыр, бозаудыр, сарыктыр алып килә, иң шаулап торганда да йөздән артык кеше булмый иде.

Бер-ике минуттан егет, эттән туган нәмәстә икән, кәгазь тартма күтәреп килеп тә җитте.

— Мәгез, карагыз. Чын күннән, итальянский!

Итек, чыннан да, әйбәт, күне шыгырдап тора, эчендәге куе мехы кулны иркәләп рәхәтләндерә иде. Хатын аны киеп тә карады, үлчәп теккәндәй тап-таман!

— Алам, — диде ул. — Күпме тора?

— Дүрт йөз.

— Ярар, — дип, иңенә аскан ридикюлен кулына алды. Ридикюль затлы, әллә ничә кесәле, күп акча сыйдырышлы иде. Егетнең йөзенә «моңардан күбрәк сорыйсы калган икән» дигәндәй үкенү галәмәте чыкты. Шунда аның башына тәвәккәл уй килде бугай, ул хатын кулыннан ридикюльне тартып алды да йөгерә-атлый гөжләп торган халык арасына кереп югалды. Хатын башына суккандай аңгыраеп калды, кычкыра да, селкенә дә алмады. Култык астына кыстырылган тартма җиргә төшкәч кенә аңына килде. Ярдәм сорап кычкырыргамы, милициягә йөгерергәме? Бу тикле кеше диңгезе эчендә ул каһәр сукканны ничек тапмак кирәк?

Хатын авыр гына атлап автобус тукталышына китте. Гарьлектән, чарасызлыктан йөзе буйлап аккан күз яшьлә-

рен дә сөртмичә атлады да атлады. Йөз тәңкә акчасын күз алдында суга салды бит... Нигә шулкадәр пешмәгән бәрәңге кәлҗемәсе икән ул? Кемгә генә охшап шулай җебегән булды икән... Бүтән туганнары бит баскан җирдә ут чыгаралар. Йөз тәңкә... Аны аңа ярты ай эшләргә кирәк. Ридикюль дә жәл. Әллә ничә кесәле, эченә бәләкәй генә көзге дә беркетелгән. Өченче ел аны туган көненә абыйсы бүләк итеп биргән иде. Абыйсының төсе... Быелтыр ул юл фаҗигасенә эләгеп һәлак булды.

Иремә ни әйтермен, дип уйлады ул. Аңа әйтмәсәң дә була инде югыйсә. Төпченеп, һәр әйберенне, гамәленне тикшерә торган кеше түгел. Шул ук вакытта ул аңардан бу талауны яшереп калдырмаячагын да белә иде. Иреннән ул бернәрсәне дә яшерми...

Автобустан төшеп, Иптәшләр урамына борылгач, хатын туктап күзен сөртте, тынычланырга тырышты. Ярар инде дип үз-үзен юатты, баш бәласе түгел әле. Йөз тәңкә кем өчендер вак-төяк кенә дә инде ул. Безнең өчен зур шул.

Ул, ике тулай торакны үтеп, үзе торганына җитте. Бу урамда тулай тораклар күп, шуңа исеме җисеменә туры килеп тора.

Ире инде уянган, юынып йөри иде.

— Әһә, кайтып та җиттеңме? — дип кычкырды ул, хатынын күрүгә. — И башсыз, башсыз.

Хатын аптырап аңа карады. Кайдан белгән бу? Аның ридикюлен угры тартып алганны кем җиткергән?

— Соң, син бит акчаңны тәрәзә төбендә онытып калдыргансың, — дип көлде ире. — Менә бит... — Ул тәрәзә төбеннән резинкага кыстырылган кәгазь акчаларны үрелеп алды.

Хатынның култык астындагы бәлале тартма шапылдап идәнгә төште дә ачылып китте, эченнән чүпрәк-чапрак, төрле чүп-чар коелды.

Ире гаҗәпләнеп аягы белән тартмага төртте:

— Нәрсә бу? Нинди чүп-чар күтәреп йөрисең?

— Карак... Угры талады мине, ридикюлемне тартып алып, халык арасына качты. Ә мин анда акча бар дип торам. — Хатын, урындыкка утырып, чатнаган тавыш белән көлеп җибәрде. — Ну, көлкегә калды инде үзе дә... Ачып җибәрә, ә анда берни юк, хи-хи-хи... — Ул тагын чүп-чар тулы тартмага карады. — Ә мин тагын итек үземдә дип сөенеп кайтам... Итальянский итек дигәне күз буу гына булды микәнни?

— Һе, бирерләр сиңа итек... Акчаны онытып калдыруыңа шөкер ит.

— Ридикюль кызганыч инде барыбер. Абый төсе иде, — дип уфтанды хатын.

Ире, арттан килеп, ике аксыл кулын аның җилкәсенә салды.

— Кайгырма, иртәгә базарга бергә барырбыз. Итекнең дә синә иң кәттәсе булыр! — диде ул.

Үзенең куллары җип-җиңел һәм алар җиңелчә дерелди иде.

## МЫЛТЫК

Чолан эче ярым караңгы иде. Муртайган такта ярыкларыннан саркып кергән чапраш кояш нурлары гына, тыгыз караңгылыкны телеп алып, яктылык тамчыларын чәчрәтә. Түшәмгә эленгән мәтрүшкәләр, дүркәләр, төрле дару үләннәренең исе аның чыраен сыйпады, борын канатларын кытыклады. Ул, былтыргы миннекләрне аралап, почмак якны капшады, анда аның ике көпшәле мылтыгы эленеп торырга тиеш иде. Учы шуның салкынча шома түтәсенә килеп орынгач, ниндидер алҗыткыч рәхәтлек бөтен тәненә таралды. Аның инде күптән кулына мылтык алганы юк иде. Ул инде аның барлыгын да оныткан иде.

Гаҗәп, заманында ул шәп аучы санала иде бит.

Ниһаять, пәрәвезләргә чорналып, каен яфракларына тиенеп кояш күзенә чыкты, ишегалдына төшәлгән сары-кызгылт яфракларны ерып җилкапка кырындагы эскәмиягә таба атлады. Күз житте дип уйлады ул иренеп, аны раслагандай, иске эскәмия шыгырдап ыңгырашып алды. Өстенә аварга торган сап-сары урманда ымсындыргыч тынлык хөкем сөрә иде. Шул чакта урман үз эченнән иңенә көянтә аскан яшь хатынны этеп чыгарды. Ул балдызын танып елмаеп куйды. Кер чайкап кайта. Инде өченче катлый. Күп җыелган кер... Хатын, җизнәсен күреп, балкып елмайды. «Ауга чыгарга җыендың мәллә, җизни?» — «Әйе шул, берәр асылкош эләкмәсме миңа да...»

Ул, үзенең шаяртуыннан кыенсынып, кинәт тынып калды, куе кашлары җыерылып килде, саңгырау тавыш белән: «Күптән инде кулга мылтык алган юк иде», — дип мыгырданды. Хатын исә үзе кер чайкаган урман чишмәсе тавышын чыгарып челтерәп көлде: «Сиңа да асылкош эләкмәгәч инде, җизни...»

Ишегалды буйлап сузылган бауга кер элеп йөрүче балдызына ара-тирә күз ташлап, ул мылтык көпшәсен чистартып утырды. Хатынның чыланган күлмәген тәртеп торучы имиләре, ачык таза беләкләре, җыерылган итәге астыннан

ялтырап күренгән шома ботлары күз карашын өстери дә китерә, өстери дә китерә иде.

Балдызы моңарчы шәһәрдә торды. Анда кияүгә дә чыккан иде. Туйга аларны чакырдылар бугай, әмма барып булмады. Ул хатынының туганнары белән аралашмый иде. Дөресрәге, алар үзләре аны тиң күрмәде. Хатынын да аңа кияүгә чыккан өчен гафу итмәделәр. Кызының гади урман каравылчысын, кешеләр белән аралашмый торган, үз эченә бикләнгән сәер адәмне сайлавын кичермәде атасы. Киявенә дә кул бирмәде, сыңар сүз катмады, өенә алдырмады. Карт тайгач йомшарыр әле дип баштарак хатыны өметләнгән иде, әмма юк, боз эремәде. Карт бик киребеткән булып чыкты.

Ләкин кияүнең дә моңа бик исе китмәде. Урманда хатыны белән акрын гына гомер кичерделәр. Бәхетлеләр дә иде төсле... Тик балалар сөенечен генә татый алмадылар...

Әйе, балдыз аерылып кайткан. «Урыстан да битәр әчә», — дип ире турында апасына сөйләп торганын колак очы белән генә ишетеп калган иде ул.

Ачык чырайлы, көр күңелле хатын... Менә аларга да кер уарга, өй җыештырырга, булышырга килгән. Әтисе ничек җибәрде икән? Әллә аңа сиздермичә генә чыгып киткәнме? Ул мылтыкны коймага терәде дә үзе өйгә таба атлады. Аяк астына сары-кызгылт юрган булып түшәлгән яфраклар, үзара серләшүдән туктап, аяк табанына сырпаландылар.

Идәнне шыгырдатмаска тырышып, ул түрдәге чаршауланган ятакка якынлашты. Кыргычлап юып чыгарылган сайгаклар үзләренең табигый саргылт төсен кайтарырга азапланып яталар иде.

Ул, чаршауны аралап, ятак кырындагы тәңгәлгә килеп утырды. Юрган астындагы ябык гәүдә аны күрүгә кымшанып куйды, пәрәвезләр сарган сары йөзендә елмаю чалымы сизелде.

— Хәлең ничек? — дип сорады ир. Җавап таләп итми торган гаҗиз сорау иде бу. Мең тапкыр кабатлаудан мәгънәсен югалткан әлеге ике сүзнең иреннәре арасыннан ыскылып чыгуына аның инде ничәнче кат ачуы килеп куйды. — Бүген көн чалт аяз тора... — диде ул бераздан. Аннары нигәдер өстәде: — Яфраклар коела...

— Туңып торам әле, — диде хатыны. — Җеп өзәр дәрманым юк. Авызым кипте.

Ир, янәшәдәге урындыктан чынаякны алып, хатынына суынган чәй йоттырды. Чабуы тиеп киттеме, андагы бер дару шешәсе идәнгә төшеп, ишеккә таба тәгәрәде.

— И-и, бигрәк җайсыз инде син... — дип хатыны зарланган сыман сөйләнеп алды.

— Шушы көннәрдә сары бия колынларга тиеш, — диде ир, гаепле тавыш белән.

— Эчемдә нидер өзелгән... Казанда Минкаев дигән бер табиб бар икән, Кукмарадан торып Кара диңгез астындагы җир тетрәвен туктата, ди. Шуңа күренәсе иде. — Хатын кипшенгән ирennәренә юеш кульяулыгын тидереп алды. — Күктәге болытларны ары-бире куып йөртә, имеш. Мине генә терелтә инде ул...

Хатынының йөзенә кызыл таплар йөгерүен күзәтеп утырган ир кузгалып куйды.

— Бүген ауга чыкмакчы булам әле. Берәр киек эләксә...

— Кем алып барсын соң мине ул табиб янына? — дип еламсырады хатын.

— Бераз рәтләм, барырбыз. Ә бәлки, аның үзен алып килермен әле...

— Алмакай кайда? — Хатыны сеңлесенә нигәдер шулай эндәшә иде.

— Керләр элеп йөри...

— Шәһәрдә нинди чибәрләнгән... Умырып эшли. Әле тагын өч-дүрт көн торам дигәние дә, бездә эш бетмәс, тоткарланма, мәйтәм... Әти белсә...

Ир чистарып, яктырып киткән өй эчен карашы белән айкап алды. Һава да үзгәргән, дару исе алай ук борынны ярып керми иде. Анысы тиз генә бетмәс инде, ун ел буе стеналарга сеңгән ис ич.

— Торасы килгәч, торсын... Нигә куарга?

— Иреннән уңмаган, мескен... — диде хатыны өзек-өзек. — Әтидән сорамыйча гына килгән ул.

— Алайса кайтсын...

— Миннән туйгансыңдыр инде... Сөйләшүеңнең рәтечираты юк. — Хатыны тагын еламсырап алды.

— Мылтыкны күптән тоткан юк иде, — диде ир. — Барлыгын да онытканмын. Менә бүген чоланнан алып чыктым әле.

— Шул табибның сурәтен эчкә куеп торсаң да чирне ялап ала икән. Алмакай сөйләп торды әнә, Аю Шәвәли хатынының, шул фотоны куеп йоклагач, чәче яңадан карала башлаган, ди. Авылга төшеп, шул фотоны апкайтыр идең.

— Иртәгә барырмын. Бүген урманга чыгам. Киек шулпасының сихәте тимәсме...

— Юк инде, үләрмен, ахрысы... Котылырсың инде... Кырыгымны уздырмас борын өйләнәсе булма түлке...

— Тузга язмаганны сөйләмә! — Ир авыр гына урыныннан кузгалды. — Тиздән йөгереп йөрерсең әле.

— Алмакайга рәхмәт, күпме дару гына алып килгән...

— Сыерга печән төшерергә кирәк. Бераздан сөтен кал-

дырыр инде, бозауларга ике ай гына калып бара, — диде ир, үзалдына сөйләнгәндәй.

Көз дә җитте дип уйлады ул янә кояш күзенә чыккач. Тик нигәдер җанда моңсулык юк, йөрәк кенә үз урынында түгел сыман. Ауга чыгасы булганга шулайдыр.

Балдызы ишегалдында күренми иде. Ул, мылтыгын җилкәсенә асып, урманга таба атлады. Шул чагында артта көләч тавыш ишетелде: «Асылкошсыз кайта күрмә, җизни!» Ир борылып елмайды, аннары, шул елмаюыннан уңайсызлангандай, тәвәккәл адымнар белән юлын дәвам итте.

Урманга керер алдыннан, ниндидер тонык авазлардан әсәренеп, ул күккә карады. Анда, биектә, киек кошлар төркеме чылбыр булып тезелеп каядыр еракка, ул белмәгән якларга очып бара иде.

## АЛЛА

Лапаста яңа чапкан печән исе, ат тизәге исе аңкый. Ахияр тирән итеп сулыш алды, күкрәгенә шушы җанга тансык исләр белән кинәнү, рәхәтлек, канәгатьлек, тел белән әйтеп булмый торган әллә нинди хисләр кереп тулды. Хуҗасын танып, аранда ат пошкырды. Ахияр, арата аша үрелеп, атның муенын сыйпады, бирчәйгән бармакларын аның калын ялына батырды. Ниндидер рәхәт дулкыннар, бер-берсен куыша-куыша, гәүдәсе буйлап таралдылар. Ахияр сөенеченнән көлеп җибәрде. Алла да (байталының исеме шулай сәер иде) аның бу сөенечен аңлый иде, ахрысы, үзенең дә мәхәббәтен, тугрылыгын белгертергә теләп, йомшак җылы иреннәрен хуҗасының кырынмаган йөзенә тидерде.

Ахияр Алланың акыллы күзләренә карады, ир белән атның күзләре очрашты. Ирнең күкрәге җылынып китте, ул уңайсызланып йөзен читкә борды. Бөтен дөньяда хәзер аңа иң якын, иң газиз, аны иң аңлаган зат шушы ат иде, ахрысы...

Ахияр яшәгән Тиресле авылында гына түгел (Тиресле исеме, кайбер туган якны өйрәнүче акыллы башлар фикеренчә, җир ашлый торган тирес сүзеннән түгел, ә бу төбәктә кире, үҗәт мәгънәсендә кулланыла торган «тирес» сүзеннән килеп чыккан. Бередәге халык тирә-юньдәгеләрдән гадәттән тыш кирелек белән аерылып тора иде. Шуңа күрә аларны еш кына, яратмыйча, Тиресле чуашлары дип тә мыскыл итәләр иде), гомумән, мишәрләр яшәгән бөтен җирләрдә элек-электән атны бүтән хайваннардан аерып карыйлар. Утызынчы ел-

ларда көчләп колхозлар оештырганда, Тиресленең чуаш кебек кире, мукшы кебек төмсә ирләре башка малны түгел, ә җаннарыннан да артыграк күреп атларын, затлы дирбиясбруйларын кызганып еладылар. Атсыз ир — канатсыз кош! Күпләре, авылга кулларын селтәп, төрле якка таралды. Шулай да байтагы Мәскәүгә юл алды шикелле, анда алар дворник булып, вокзалда йөк ташучы булып урнашты. Колхоздан качып килгән бу авыл агайлары кара эштән курыкмыйлар, хәер, курыксаң да кая барасың? Рәсәйдә кара эш махсус татарлар өчен кебек бит ул...

Тиреследә дә, чын мишәр авылындагы кебек, борын-борыннан сугымга елкы чалганнар. Ләкин Совет влачы көчәйгән саен, алмагачы булган өчен дә салым түли башлагач, авыл халкы кышкылыкка ат түгел, сарык та суя алмый башлады. Сугыш вакытында инде ит дигән сүзне дә оныттылар диярлек, алабута, үлән-чүлән белән юандылар. Елкы итеннән казылыктыр, фәләндер кебек төрле нигъмәтләр әзерләү дә онытылды. Ниндидер мәгънәсезе «торгынлык» дип атаган елларда авыл кешесенең бераз хәле рәтләнгәч, Тиресленең ир-атлары, балта-пычкыларын тотып, урыс якларына шабашкага таралды. Анда йортлар салып, абзарлар корып (урыс үзе йорт салмый, салганны көтеп ята, һәм дөрес эшли, татар Рәсәйгә ни өчен кирәк?), акча эшләделәр. Көз көне аларга атлар ияреп кайта. Эш шартларын сөйләшкәндә сүз үзәгендә ат булмый калмый. Ат алырлык түгел икән, чын мишәр эшкә тотынып та тормый иде.

Дөнья — куласа шул, бер көе генә тормый, әйләнә дә бер баса, диләрме әле, менә хәзер ат асрарга да рөхсәт иттеләр. Тиреследә хәзер һәр аранда ат пошкыра, малайлар аларны төнлеккә урманга алып китәләр, юлда тояк тавышлары ишетелә, капка төбенә чыккан агайлар җитди чырай белән, эндәшми генә тәмәке пыскыталар, шатлыкның эчтә тып-тын тантана итүе үзе бер өстәмә сөенеч бит ул!

Ахияр да Пермьнең Урда авылыннан, үзе эшләгән җирдән ат алып кайтты. Атны бик озак сайлаган иде, ялгышмаган икән, акыллы, җайлы булып чыкты Алла. Ахияр ел буе шул ат белән мәш килде. Арба ясады (үзе җиңел, үзе нык), тугым бөкте, ияр, камыт эзләп Казанга чапты.

Аның үзен авылда өнәп бетермиләр иде. Үз эченә бикләнеп яши, тел күтәреп беркемгә бер сүз эндәшкәне юк, исәнләшкәндә дә башын селкеп кенә үтә. Байталының нинди исемдә икәнен белгәч тә, әбиләр як-якка төкеренеп куйды, хатыннар бот чабып көлде. Ирләр дә күпмедер вакыт теш агартып алгалады. Бу исемне, билгеле, Пермь өлкәсендә үк кушканнар, елкычы, мөгаен, Алла Пугачевага мөкиббән берәр кеше булгандыр. Исемдә басым да беренче иҗеккә

төшә, тик татар урыс теле законнарын санга сугамыни ул? Ахияр әбиләр теленә керүдән курыкмый иде куркуын, «кяфер» димәгәйләре, чурт дисеннәр, тәһарәтсез кәмперләр ни сөйләмәс? Тик авыл тилесе Дерминең кибет каршында: «Ахияр Алласын айгырдан каплатып кайтты», — дип сөйләнүен ишеткәч кенә әллә нишләп китте ул. Шуннан соң байталның исемен дә үзгәртеп карады. «Милка, Милка» дип көнгә йөз мәртәбә генә кабатламагандыр, әмма мал иясенә охшый, дип дөрес әйтәләр икән, ат, Алла дип эндәшмәсәң, борылып та карамый иде.

Аяк белән этүгә, ярым караңгы лапасның ишеге салмак кына мөгрәп ачылып китте дә, Ахияр, кояшны аралап, көн күзенә чыкты.

Ишегалдындагы йомшак бәбкә үләннәренә басып ул өйгә керде. Ачыккан иде, өстәл янына утырды, ипи валчыкларын терсәк белән читкәрәк сыпырып куйды, зур баш суганны кабыгыннан арындырып, эре тозга манып, калын икмәк телеме белән умырып чәйнәргә кереште.

Күзе түр почмактагы пәрәвезгә төште, анда, кара нокталар арасында, бер чебен эленеп калган, ул җан-фәрманга аякларына сарылган җепселләрдән котылырга маташа, бәргәләнә, бәргәләнгән саен тагын да ныграк чәбәләнә иде. Үлем белән яшәү арасындагы әлеге көрәшне битараф кына карап торды Ахияр.

Өстәл яныннан торганда аягы буш шешәләргә тиеп китте, алар, бер-берсенә бәрелеп, мескен генә тавыш биреп куйдылар.

Ул мич янындагы җыештырылмаган ятагына килеп ауды, керләнеп каешлана башлаган мендәрен калкытыбрак куйды.

Марҗасы киткәннән бирле кулыннан эш төште аның. Тиресле ирләре елның күп өлешен читтә, урыс арасында уздыралар. Шуңа күрә күбесе анда ялгыз марҗаларга йортка кереп, семья корып диярлек яши, кайсысының инде идәндә тәгәрәшеп балалары да йөгереп йөри. Алай да ирләр авылдагы төп гаиләләрен онытмыйлар, ай саен акча җибәрәләр, бәрәңге утыртканда, бәрәңге алганда ялт итеп кайтып төшәләр, кышын да газиз хатыннары янында уздыралар. Ягадагы марҗалар аларга исәпкә бар, санга юк сыманрак төсле иде. Ләкин яшь, өйләнмәгән егетләрнең байтагы шунда ябышып та кала, һәм нигәдер калучылар авылның иң чибәр, эре гәүдәле, озын буйлы оланнары була иде. Ахияр да Урда авылының Валя исемле бер кызына иялэште. Марҗаның куены нигә шундый да тирән, шундый да кайнар икән ул? Ахияр да башаягы белән йотылды, иңеп бетте анда. Иртәнге биштә торып эшкә барганда ул уянып җитми иде әле, шулай аягөсте йоклап атлаганда, юлдан тайпылып, койма-капкаларга килеп бәрелгән чаклары да булды.

— Өйләнешик, — диде беркөнне Валя. — Иптәшләреңнән аерылырсың, Петр Степанович сине иртәгә үк машинага утыртырга вәгъдә бирде. Югыйсә тире дә сөяккә калдың ич инде. Коллар бит сез! Кеше шулкадәр ватылып эшли димени... Өйләнешик. Безнең кебек яшәрсең.

Ахиярның әти-әнисе инде вафат, марҗага өйләнмә, дип мыгырдаучы юк, үз авылында күзе төшкән кызы да күренми, җаны бик үк тартмаса да, ул Валяга өйләнергә ризалык бирде.

— Тик безгә кайтабыз, — диде ул. — Мин нигезне ташламыйм, анда дум совет кебек йортым бар.

— Кайтырбыз, кайтырбыз, — дип елмайды Валя. — Берберебезне яраткач, кайда да яхшы булыр. Анда да бит шул ук Россия...

Сүзенә каршы килмәгәнгә и сөенде шулчак Ахияр, марҗасының мул гәүдәсен кочагына кысты, эчке күлмәк авызыннан бүселеп чыккан имиләренә изрәп киткән йөзен яшереп, хатынының әчкелтем исен озак иснәп ятты.

Туйны гөрләтеп үткәрделәр. «Эчләре янсын, — диде Валя, — кияве татар гына дип пышылдамасыннар әле, от души гүләйт итәбез». Туйга Петр Степанович та килде. Аны кадерләп түргә утырттылар. Беренче тостны да ул әйтте, Валяны мактады, Ахиярны да онытмады: «Саша кебек егетләр безгә бик кирәк, — диде ул. — Ызба тотырып бала үстерсеннәр, калхузда эшче көчләр күп булсын». Сөйләп кенә калмады, калхуз исеменнән ике чучка баласы да бүләк итте.

Ахияр авылына кайтырга вәгъдәләшсәләр дә, тиз генә кузгала алмадылар. Анда кайтып та нишлисең? Эш юк, калхузда селкенеп йөргән өчен тиеннәр түлиләр. «Бераз түл җыйгач кайтырбыз, — дип уйлады Ахияр. — Акча кайда да юл ача».

Туй иткәч ул бригадага кайтмады, колхозда машина йөртә башлады. Эш хакын әйбәт түлиләр, кузовта да анысы-монысы ияреп кайта. Бераздан тупылдап малайлары да туды. Ахияр аны Тимур дип атарга ясканып караса да, Валя якын да килмәде. «Петр дип кушабыз! — диде ул. — Петр Степанович хөрмәтенә... Күңеле булыр персидәтелнең... Крестный булырга да риза булыр. Яши белергә кирәк, Саша...» Ахияр Валяның барыбер үз сүзен сүз итәчәгенә күнегеп килә иде инде, эндәшмәде. Юкса бит Тимурны урысы да, татары да куша, икесенең дә күңеле почмакланырга тиеш иде дә кана... «Үзебезгә кайткач, шулай үзгәртермен дә әле, — дип үз-үзен юатты ул. — Валя да анда артык чыгымлый алмас».

Петя инде йөгереп йөри, ә Валяның Ахияр авылына кай-

ту турында авыз да ачканы юк. Ул гына да түгел, Ахиярның авылдашлары яңа гына салган йортны алырга йөри башлады, көн дә Петр Степанович янына чаба... Петяның крестные белән бигрәк тә дуслашып киттеләр соңгы вакытта, авызны авызга куеп серләшәләр, ара-тирә персидәтел өйгә дә сугыла, кечкенә Петяга йә күлмәк, йә ыштан кыстырып килә. Шундый ярдәмчел булгач, малаеңны чукындырганга да сүз әйтеп булмый инде. Ахиярның андый вак-төяккә исе китми иде. Кайткач аш пешкән, ыштан төшкән булса, дөньясы нигә чукынып китми шунда!

Шулай сыман иде... Ләкин тора-бара Валяның һаман үз ягына каеруына, аның сүзенә колак салмавына ачуы да килә башлады. Ул ачу акрын-акрын эчкә җыела килде. Мәрхүмә әнисенең «йортка кергәнче, утка кер» дигән сүзе дә ешрак искә төшә иде.

Авылдашлары белән ул хәзер сирәк очраша. Шуңа да эче пошып тора иде, тегеләрнең ял көнен чамалап, беркөнне алар янына китте. Чүпрәк букчасында ике «урыс малае» да бар иде. Рәхәтләнеп утырдылар үзләренчә цөкердәшеп. Али карт — ул бригадада аксөяк, ишек ясый, тәрәзә куя, бүтән эшләргә катнашмый, — бераз исереп киткән иде, калтыравык тавыш белән җырлады:

Ат җибәрдем үзәнгә,
Үлән тамырын өзәргә;
Үзем үлсәм, сүзем калсын
Үзәгеңне өзәргә...

Ахиярның күзе дымланды, бугазыннан нindидер аваз тырналып чыкты. Ул үлеп китсә, сүзе дә калмаячак бит... Исеме дә... Саша бит ул монда, Саша...

— Петр Степанович сезгә бик ешлады, — диде бригадир Рафаким. — Валя белән серләре килешә, ахрысы...

Ахияр, бригадирның мыскыллы елмаю кунган йөзенә текәлеп, сүзнең дәвамын көтте. Тик тегесе тел чарларга җыенмый иде, сәгатенә карап алды:

— Ятарга вакыт, иртәгә урыс празднигы тигел... — Рафакимның бу сүзе дә Ахиярга мыскыл итү булып тоелды, кара янып, китәргә кузгалды.

— Кайда йөрисең син?! — дип кычкырды аңа хатыны, тик иренең акайган күзләрен күргәч, телен тешләде. Акыллы хатын иде Валя, кайчан уларга, кайчан юлларга икәнен яхшы белә иде. Сыер дуласа, аттан яман, диләр, сөялен бассаң, әллә нәрсә майтарып ташлар бу үшән татар...

— Минем авылга яшәргә кайтабыз! — диде Ахияр.

— Ярар, ярар, — дип килешергә ашыкты хатын.

Иртән ул аны гадәтенчә мыштым гына эшкә китәр, бу

турыда бүтән авыз ачмас дип уйлаган иде дә, иртән Ахияр бер тустаган салкын су эчеп, караватына кире барып яткач, мөлдерәп торган зәһәреннән бер мәлгә хәтта катып калды…

— Баста! — диде ир. — Бүтән эшкә чыкмыйм. Җыена башларга кирәк, минем авылга кайтабыз.

Хатын елап та карады, ялварды да, тузынды да, тик Ахиярны сүзеннән кире кайтара алмады, киребеткән мишәр акрын гына җыенырга булды. Кичкә таба аны идарәгә — Петр Степанович хозурына чакырдылар.

— Ташлап китмәкче буласың икән безне, кум, — диде персидәтел. — Тагын бер кат уйла әле. Анда бит сезнең эшсезлек. Мужикларыгыз бит безгә килеп бил бөгә. Сиңа ни җитми? Живешь как у бога за пазухой. Ну что тебе надо? Хочешь, я тебя снабженцем назначу? По всяким командировкам будешь ездить, мир повидать…

Тик Ахияр да Тиресле мужигы иде шул. Тоткан җирдән өзә торган җыктан. Ниһаять, кум да моны аңлады, йөзен чытып кулын селтәде: «Дурак!» — диде. Бүрене бүреккә салсаң да урманга карый, янәсе.

Нишләсен, иренә ияреpгә мәҗбүр булды Валя. Персидәтел машинасына төялеп, Верещагин шәһәренә — тимер юл стансасына чыктылар. Соликамски поездының калтырча вагоннары, ыңгыраша-ыңгыраша, туган илгә тәгәрәде.

Валя авылга ияләшә алмады, башта марҗа белән аралашырга атлыгып торган күрше-тирә хатыннарның да Ахияр өенә эзе суынды. Валя алардан үзен ничектер өстен куя, тегеләр дә аның белән уртак сүз таба алмыйлар, мәктәптә өйрәнеп тә инде онытыла башлаган урыс сүзләре җәелеп китеп сөйләшерлек түгел иде. Марҗаны чөгендер китмәнләргә, бәрәңге чүбен утарга чакырып карадылар. Ә ул, кибаранә елмаеп: «Мин бит колхозница түгел. Мин — медсестра!» — диде. Ахияр аптырап кулын гына җәйде, авыл медпунктында ул урын буш түгел иде шул.

Беркөнне Ахияр каяндыр кайтып кергәндә, хатын кеч-кенә малайны киендергән, чемоданга кирәк нәрсәләрен тутырып, ишек төбендә ирен көтеп утыра иде.

— Син теләсәң нишлә, без монда кала алмыйбыз, — диде ул, елый-елый. — Мин инде сине күпме кыстадым, китик дип…

Чыннан да, төн буе сүз шул турыда гына була иде, или, или иде Валя ирен, мыш-мыш сулап бер сүз эндәшми ята иде Ахияр! Юкса бит төнлә ирләрнең колагы бөтенләй ачылып бетә…

Ахияр аларны Канашка кадәр озатып куйды. Иске автобус пошкыра-пошкыра алга юырта. Валя инде үгетләп арыган, бер сүз дә чыгармыйча, тәрәзәгә капланган. Купе-

реп утырган урманнар ямьсез, офыкка тоташкан кырлар шыксыз булып күренә аңа. Алай да, поездга утырганда: «Әйдә безнең белән», — дип әйтеп карады. Ахияр йөзен читкә борды.

— Ну и живи среди своих вонючих татар, — дип ачыргаланып кычкырды хатын. — Неблагодарный чучмяк!

Моны ук көтмәгән иде Ахияр, җаны өшеп вокзалга таба китте. Тик борылып карамыйча булдыра алмады: вагон тәрәзәсеннән нәзек кулларын сузып малае Петя сыек тавышы белән: «Папа!» — дип кычкыра иде.

Менә хәзер шул күренеш аның төшенә кереп йөдәтә. Валя да бик еш искә төшә. Ямьсез сүзләрне бик ачуы килгәнгә генә кычкырды бит ул. Яратмаса аңа ияреп кайтыр идемени?.. Чыннан да, өстерәлеп нигә монда кайттылар алар? Туган ил, имеш. Кемгә кирәк ул биредә?

Ахияр, ятагыннан торып, түр тәрәзәгә килде, кесәсеннән бөгәрләнеп беткән тәмәке кабы чыгарды. Тик анда тәмәке беткән иде.

Акча да юк.

Кире китәргә булды Ахияр. Тик китәр өчен дә акча кирәк. Эчтән сыктаса да, үзен-үзе җиңде — байталын сатарга уйлады. Әмма авылда беркем дә атны алырга теләми иде. Хәтта ата карак, исерек Атай да кулын гына селтәде, андый кушаматлы ат алып языклы булыр хәлем юк әле, янәсе.

Атны суярга да кулы күтәрелмәде аның. Суйсаң да, итен авылда алмаячаклар иде.

Күрше авыллардагы чуашларга сатар иде, чуашның атка исе китәмени аның?

Атын ышанычлы кулларга тапшырасы иде дә бит... Бәлки, ул бөтенләйгә китмидер? Әйләнеп кайтса, байталны кире үзенә сатып алыр иде.

Капкага таба кемдер якынлаша иде. Таныш түгел кеше — авылда мондый адәмне Ахиярның күргәне юк. Теге дә тәрәзә янында торган хуҗаны шәйләп алды, ахрысы, тук йөзенә елмаю җәелде, нидер кычкырып кул изәп куйды.

— Ахиярмы буласың? — диде ул, кул биреп күрешкәч. — Синме ат сатасың?

— Ә син кем?

— Шыгырданнан мин. Сатсаң, атыңны хәзер үк алып китәм. — Шыгырданнар күрше-тирә яктан мал җыялар, аларны суеп, итен Казан базарына ташыйлар иде.

— Аның исеме бит Алла, — диде Ахияр, нәрсәдер өметләнгәндәй. Хәлиткеч минутны һаман сузасы килә иде.

— Һи, безгә Алла ни, мулла ни, — диде шыгырданлы, көлеп. — Бисмилла әйтеп суйгач, мөселман ризыгы була

инде ул. Йә, әт сүзеңне. Без живой весын алты тәңкәдән алабыз. Акцасын хәзер үк түлим. — Адәм кабарып торган кесәсенә сугып алды.

Ахияр аңа керфеген дә селкетмичә карап торуын белде.

— Әбзәй, нәстә, телеңне йоттың мәллә?

— Ат аранда, — дип пышылдады ул.

Алладан аерылгач, Ахияр үз-үзенә урын таба алмый йөрде. Тик мал абзарына — паетка керергә җөрьәт итмәде. Анда сугылды, монда сугылды да, кибеттән аракы алып кайтты. Ярым караңгы өйдә ул берүзе эчеп утырды. Хәер, берүзе генә түгел, күз алдына нәзек кулларын сузып әле Петя килә, әле Валя тыела алмыйча көлә, әле Алла башын чайкый, пошкыра, үзенең эренле күзләреннән бертуктаусыз яшь ага иде.

Икенче көнне ул таң тишегеннән үк юлга чыкты. Автобус Шыгырданнан китә иде, ара өч чакрымнан артык түгел, шуңа машина-мазар көтеп тормыйча, җәяү генә атлады. Автобус тукталышында берничә кеше басып тора, шулар арасында Ахияр төнә аның Алласын алып киткән шома чырайлы бәндәне танып алды. Күкрәгендә ниндидер кайнарлык пәйда булды, шул акрын гына бугазына таба шуыша иде. Ахиярның бәндә белән исәнләшәсе дә, хәл-әхвәл сорашасы да килми иде... Тик тегесе үзе үк аны искәрде, иске танышын очратуына сөенгәндәй, елмаеп янына килде.

— Атыңны насиля алып катьтык, — дип сүз башлады ул. — Каерыла да артка карый, каерыла да артка карый. Үзе җылый, мескен. Сиңа нык ияләшкән икән.

Ахиярның Аллага тагын бер күз ташлыйсы, соңгы мәртәбә хушлашасы килде.

— Әле суеп өлгермәгәнсездер, — диде ул, шома бәндәнең җиңеннән эләктереп.

— Суймыйца... — диде тегесе, черт итеп җиргә төкерде. — Ите инде Казанга барып җиткәндер.

Ахиярның кулы бушаган дилбегә сыман салынып төште.

— Колыны цыкты бит аның. — Бәндә ничектер уңайсызланыбрак киткәндәй булды. — Буаз икәнен ник әтмәдең? Бәлки, колынлаганцы үземдә асраган булыр идем...

Ләкин Ахияр инде аны тыңлап торырлык хәлдә түгел иде, койма артына кереп, сулыга-сулыга укшый башлады. Авызыннан асылынып төшкән селәгәй тасмасы белән бергә аның күңеле дә җиргә тама иде төсле.

# АК ЭТ

Безнең авылдагы Җантай әбине тирә-якта белмәгән кеше юктыр. Аның өеннән кеше өзелми. Урам капкасыннан берәр ят машина яисә җилкәсенә капчык аскан җәяүле күрендеме, шикләнмәгез, ул Җантай әбине эзләп килгән. Мин инде үзем ул юлчыларга ничә тапкыр юл күрсәттем: мәчет чатыннан зиратка таба менеп китәсең дә кырыйдагы салам түбәле йортка туктыйсың. Авылда бердәнбер салам түбә ул. Җантай әби шунда яши. Килүче бераз аңгырарак булса, тәфсилләбрәк тә аңлатырга туры килә. Җантай кортканың салам башлы йорты укытучы Хаҗәтләрдән ике өй аша гына дисең... Ә Хаҗәтнең өен тануы җиңел — кыегында язын да, көзен дә кызыл байрак эленеп тора. Кызыллыгы инде аның ташка үлчим, җилдә ашалып, төсен аныклавы да кыенлаша төшкән, әмма коммунист Хаҗәтнең кызыл байрактан башканы элмәвенә һич шикләнмәскә мөмкин. Җиргә ярты-лаш иңгән хәчтерүш өйгә байрак элеп кую — кәкре аяклы кызның сыланып торган чалбар киюе кебек инде дә, нишлисең, бездә шундый кешеләр яши, агайне...

Дөресен әйтим, Җантай әбине минем күргәнем юк. Безнекеләрдән аны күрүчеләр кемнәр генә икән? Берничә ел элек авыл башлыгы Рауил Галыч күргән, диләр. Әлеге бердәнбер салам түбәле йортка күптән эче пошып йөри аның. Менә шул беркөнне шакыган Җантай кәмпернең ишеген. Бусагадан үтеп йомышын әйтергә дә өлгермәгән, кортка сүзне үзе башлаган: «Синең ниятең яхшы, кем, улым, — дигән. — Тик мин салам түбә белән яшәдем, инде гомеремнең ахырына килеп җиткәндә, аны калай белән алмаштырмыйм. Алла сиңа исәнлек бирсен, тиздән үзеңне кәҗүнни йорт көтә...» — «Соң бит өең авылның төсен бозып тора, без аны сипләп, түбәсен тутыкмас калай белән каплап куйсак, ул көлеп торачак», — дип, Рауил Галыч үзенекен сукалый икән. Тик карчык та киребеткән, тешсез авызын бөрештереп напралум торган: «Калай аша җаныма кояш үтми», — дигән, имеш.

Алдасам, кояш чырае күрмәмен, чистый! Елтырап торган калайдан баш тарткан бит, җүләр карчык.

Шулай да Рауил Галыч моннан сөенеп чыгып киткән. Берничә көн элек район башлыгы ниндидер ым каккандай тоелган иде, үз янына алырга чамалый, янәсе. Ә безнең авыл халкы «кәҗүнни йорт»ны бөтенләй бүтәнчә аңлады. Бүтәнчә аңлап, борын астыннан зәһәр елмаеп йөрүчеләр дә табылды. Алгарак китеп булса да шунысын әйтергә кирәк: ике як та хаклы булып чыкты бугай. Башта Рауил Галыч райондагы зур эшкә күчте, бераздан аны халык «кәҗүнни йорт» дип аңлаган төшкә күчерделәр.

Жантай әбинең йортына көндез генә түгел, төнлә дә киләләр. Кайдан им-том табып бетерәдер... Тик караңгыга яшеренеп килүчеләр им-томга дип кенә шулай озын юлга чыгарлар микән? Кортка әле тагын сөйдерә дә, боздыра да, ди, имеш. Сөйдерүе бер хәл, боздырса бит эшләр яман. Менә минем хатын болай да ыжгырып тора, әгәр дә Жантай корт-ка килеп, пример, араны боздырса, башны алып бөтенләй авылдан качарга кала.

Үзебезнекеләр карчыктан шуңа күрә бераз шүрлиләр дә. Сихерче белән араң ерак булу хәерле. Көнләшүчеләр дә бар инде. Аңа күпме кеше килә, берсе дә буш кул белән йөрми ич. Әнә Минзукның төрмәдән кайткан малае нәрсә уйлап тапкан бит, ташбаш. Кортканың җилкапкасы төбенә утырып, килеп-китүчеләргә налог салган: «Мин әбинең сиклитәре, кергән өчен ун таңкә түләгез», — дип әйтә икән. Озак утыра алмаган, әмма дә ләкин үзе икенче көнне үк нишләптер ике кулы да Хаҗәтнең өй кыегындагы флаг төсле асылынып төшкән. Хәзер кече йомышын үтәргә дә әнисе белән икәү чыгалар, имеш...

Жантай әбигә ничә яшь икәнен берәү дә белми. Ул үзе дә инде яшен оныткандыр. Минем әби әйтә: ул инде без чәчби кыз чакта ук карчык иде, ди. Булса да булыр, кортка, мескен, үлә алмыйча иза чигә икән. Кыз-хатын белми сөйләмәс... Иң шомландырганы — төнлә бу карчык ак эткә әверелә дә урамда берәр кыз-хатынны эзләп йөри икән. Шуның ике аяк арасыннан үтеп китсә, тынычлап түшәгендә җан бирәчәк, имеш. Ә үлемсезлеге, сихере кирәкмәгәндә бот аерган кыз-хатынга күчеп калачак, диләр.

Дөрес, мондый сүзләргә бар кеше дә ышанмый. Әбинең күршесе Хаҗәтнең мондый ышыр-пошырга бигрәк тә ачуы килә. Дурман да фәлән, ди, сез бит камунизм төзисе кешеләр, шундый сафсата белән баш катырасыз, ди. Бервакытны Жантай әби янына үзе кергән бу. Сораша икән: кайчан туган, авылның беренче камунистларын күреп калганмы? «Хырансус сугышы чыгар алдыннан мине староста малаена ярәшкәннәр иде», — дигән кортка. Хаҗәтнең күзләре әлҗәмөлҗе килгән, әмма сиздермәгән. «Безнең авыл монда кайчан килеп утырган, белмисеңме?» — дип сораштыруын дәвам иткән. «Безнекеләр, — дип әйтә ди мәңгелек кортка. — Казанны алырга Жәнәкәй морза белән йөргәннәр иде...» Хаҗәт шуннан соң кулын селтәп чыгып киткән, карчык бөтенләй саташкан, янәсе.

Ә бит төнлә ак этне авылда күрүчеләр бар. Беркөнне сыер савучы Жәмилә үзе сөйләп торды: «Кара таңнан фермага китеп барам, — ди, — шул ак эт килеп чыкмасынмы, нәгаләт. Мин, аякларым томмыйча, лап итеп җиргә утыр-

дым. Елт итеп яннан узып китте». Ярый әле вакытында утырган, ул явыз хатынның мәңге үлмәячәген белсәләр, авылда беркемнең яшисе килми башлар. Ә Җантай әбинең, төннәрен ак эт булмый, әллә нәстәгә әверелсен, тавыш-тыны чыкмый, килгән-киткәннәргә налук салырга йөрмәсән, зыяны тими, тик тагын мең ел яшәсен... Ләкин үзенең генә артык яшисе килмидер, күрәсең. Югыйсә төн буе эт булып әлсерәп йөрмәс иде. Хатын-кызын да әйтим, озак яшәргә нинди чос халык булса да, Җантай әбине алмаштырырга берсе дә атлыгып тормый. Хәер, иртәдән кичкә кадәр чәчең белән җир себерсәң, дөньяда мәңге торасың килмәс, нибуч. Аннары төннәрен эт булу да бик күңелле түгелдер инде.

Сүзнең иясе юк, чәчеп ташлагандай, бик тиз тарала бит ул дөнья йөзләренә... Безнең авылда мәңгелек кортка барын да, төннәрен аның ак эткә әверелеп, сихерен тапшырырга бүтән кыз-хатын эзләп йөрүен дә ишеткәннәр, бу сүз Казанның үзенә үк барып җиткән. Ә Казанда анда әллә нинди ханым-туташлар бар, безнең хатыннар чуты гына түгел. Мәңге яшисең, дисәләр, эткә түгел, еланга әверелергә дә әзерләре күп. Төнгә генә бит ул. Баксаң, андый сихер Җантай әбидә генә түгелдер дә әле. Шәһәргә барсаң, күзләр маңгайга менә ич: чибәр-чибәр кызлар, хатыннар бозау кадәр ата эт җитәкләп йөриләр. Болар безнең Җантай әби түгел, болар җаен тапкан, күрәсең.

Менә берзаман кичләрен безнең авылга, күз күрмәгән машиналарга төялеп, Казаннан хатын-кызлар килә башлады. Үзләре генә түгел, алар белән таза-таза ир-атлар да килә. Чәчләре кыска итеп алдырган, йөзләре бульдук, муеннарына калын алтын чылбыр асканнар. Болар машиналары белән авыл читендә кала, ә хатыннары җәяүләп кенә югары очка, Җантай әбинең йорты тирәсенә атлый. Караңгы төшүгә, андамонда аякларын аерып баскан хатыннарны күрәсең. Тик теге ак эт кенә күренми. Әллә инде кортка үзенең мәңгелек язмышына күнеккән, әллә үзенең сихерен ят хатыннарга бүләк итәргә теләми...

Хатыннар чибәр, затлы киенгәннәр, берсеннән-берсе бай, менә кемнәргә налук салырга иде дә, теге алтын чылбырлы ирләр кулыңны түгел, үзеңне флагка әйләндерерләр, адәм тәганәсе. Без койма ярыгыннан гына карап ятабыз инде, мондый чакта ләң-ләң килүче этләр дә койрыкларын кысып ояларына кереп посалар.

Ул төнне, әллә ни эзләгәндәй, күктә чуен болытлар куышып йөрде. Караңгы төшкәч җил туктады, дөньяны нindидер шомлы тынлык басты. Кыл төн уртасында авыл читендә мылтык шартлаган сыман булды. Котырып яңгыр ява башлады, каладан килгән сәер машиналарның гүләгәне ишетелде.

Иртән, урам буйлап йөгерешкән кешеләрне күреп, мин дә тышка чыктым. «Ак этне атып үтергәннәр!» — дип кычкырды кемдер. Чыннан да, без барганда зират кырыенда ак этнең үләксәсе ята иде. Маңгаенда канлы эз дә бар. Күрәсең, ак этне күргәч, теге мәңге яшәргә җыенган хатыннарны зират янында көтеп торучы ирләрнең берсе түзмәгән, атып җибәргән инде. Бәлки, ул төнлә аны күреп шыр җибәргәндер, бәлки, хатыны инде шул ак эткә әверелгән дип уйлагандыр... Аллә нинди эчпошыргыч сагыш иде көнелдә. Шул чакта зираттан дүрт-биш яшьләрдәге малай йөгереп чыкты да, ак эткә капланып, үзәк өзгеч тавыш белән елап җибәрде. Сары балчыкка буялган нәни куллары белән йөзен ышкып озак елады ул. Мин бу малайны танымадым.

Җантай әбине шул ук көнне җирләдек. Аның да маңгаенда кечкенә генә кызыл нокта бар иде, дип сөйләделәр. Мин монысына бик ышанмадым, кыз-хатын арттырып сөйләргә ярата бит, үзегез беләсез.

Кич белән дәү бульдозер килеп, әбинең салам түбәле өен зират чокырына этеп төшерде.

Йорт нигезендә малайлар озак казындылар әле. Алар бит һәр җирдән хәзинә эзлиләр. Алтын акча тапмасалар да, йорт урынында кылыч сыныгы, ук очлары, чүлмәк китекләре, иске сары кәгазьләр күп чыккан. Ул кәгазьләрдә хәрефләр борынгы, алары да җуелган, укырлык түгел, дип сөйләделәр. Шулай да укытучы Хаҗәт сакланган бер битне Казанга барып тикшертеп кайтты. Бик башлы адәмнәр көчхәл белән берничә сүзне укый алганнар.

Анда: «Әгәр дә ки...» дип язылган булган...

## ШҮРӘЛЕ

Урман безнең авылга кыйшаеп тора. Шуңа күрәме, кышлык утын әзерләп бик мәшәкатьләнмиләр. Әзерләнгән утын кайчакта ярты кышка да җитми. Урман якын булгач кайгырасы юк — ягарга бетсә, тагын бер олау шыгырдап торган каен кайтарып аударасың. Кар ерып урманда йөрергә иренсәң инде, бакча коймасы ни өчен? Җәен өр-яңадан тотып куясың ич аны...

Ә хәзер нәкъ менә җәй уртасы. Бүген күрше Минзук белән урманга барырга сөйләшкән идек. Аның ишегалдында иске «Беларусь» гөрләп утыра. Иртән күзне тырнап ачтым да, хатынның мыдыр-мыдыр сөйләнүен ишетмәс өчен, тиз генә тышка чыгып киттем. Коедан су сосып алырга дип

чиләкне төшергән идем, кире тартканда бавы өзелде... Менә бит көн ничек башланды, каһәр... Табак төбендәге җылымса суда күзне, иренне чылатып алдым да Минзук янына ашыктым.

Хатыны абзарда тавыкларга җим сибә иде, ахрысы, мине күргә, йозен борды. Кичә Минзук белән урманга барасыны шактый гына юган идек, шуңа турсая булыр, хәерсез.

Минзук үзе чоландагы чаршау белән уратып алынган караватында ыңгырашып ята иде. Мине күргәч торып утырды. Андый чакта дус-ишнең килеп керүе сөендерә бит. Бәлки, аның берәр фикере бардыр? Минзук быдыр-быдыр нидер әйтте. Колакны тырпайткач, аңлашылды тагын: «Авызда бер көтү ат кунып чыккан төсле», — диюе икән. Быдырдарсың да шул, нибуч, урманга барасы дигән шатлыктан икебезгә бер чирекне түнтәргәнбез ич. Соңыннан Шәвәли дә килеп кушылды бугай әле.

Кыяфәте куркыныч иде күршенең — шешенке күз кырыйларына эрен укмашкан, иреннәре бер-берсенә ябышып каткан. Һ-и, нәрсә сөйләп торам, һәркемнең башыннан үткән хәл инде. «Әйдә, мәйтәм, тизрәк чыгыйк моннан, ату синең сулышыңнан чебеннәр дә аңгыраеп идәндә мүкәләп йөри...»

Урманга бару исендә дә юк моның! «Андый зур эшкә киткәндә җиңгәң бер ярты кыстырып җибәрә инде», — дигәч, Минзукка бераз җан керде, ахылдап-ухылдап урыныннан кузгалды.

Ярый әле тракторга кичә ягулык тутырып куйганбыз, утыруга кузгалып та китте, малкай... Мин тиз генә балтапычкы, хатын әзерләп куйган букчаны апчыктым. Анда салынган шешә ботка тиеп күңелне кинәндерде инде, валла!

Урманга кул сузымы калган булса да, түзеп торып буламыни, авылны чыккач ук туктаттык тракторны, теге яртыны букчадан алып койдык Минзукның бардачукта йөри торган ыстаканына. Хәер, аның ыстакан икәнен бик кыенлык белән аерып була, беркайчан да юмаганга күрәме, ул, калынаеп, әкәмәт бер кыяфәт алган иде.

Кәефләр күтәрелеп китте, җаный! Трактор тигез генә келтерәп урманга таба йөгерә. Минзукның да башы чатнамый хәзер, эре сары тешләрен күрсәтеп ыржайган була әле, адәм тәганәсе.

Үзебезнең диләнкегә барып җитеп, шешә төбендә калганны җиффәргәч, үлән өстенә тәртәләрне суздык та тәмәке кабызып җибәрдек. Рәхәт! Күк йөзе чалт аяз, кояш нәкъ түбәдә кыздыра. «Кояш басылгач кисә башларбыз, эш бүре түгел, урманга качмый», — ди Минзук. Рас шул. Минзук тәре андый акыллы сүзләрне кайдан беләдер, кичләрен телевизорга капланып утыра, нәгаләт, шуннан отып ала булса кирәк...

Мин күзне ачканда, урманга караңгы төшә башлаган иде инде. Йокым сак минем — янәшәдә генә нидер кыштырдаган төсле тоелды, бак... Борылып карасам, чак телдән язмадым, бездән ике-өч метр гына читтә йонлач бер нәстә — адәм дисәң адәм түгел, шайтан дисәң, шайтанны кем күргән... Күзе ут яна, маңгай турысында кечкенә генә мөгезе дә бар сыман, куллары озын... Иң шаккатмалысы — әптермәне тезенә җитә!

Минзук та уянган икән, чәрелдәп кычкырып та җибәрде: «Шүрәле!» Минем дә мәптектә үк ишеткән әкият искә төште: тучны Шүрәле! Тик әкият әкият бит инде ул, ә монда без, субственны персун дигәндәй... Тик алдында шундый әптермәнле йонлач нәстә басып торса, әкияткә түгел, Аллага да ышанырсың, әкәмәй.

Минзук та төшеп калган җегет түгел икән, тәре, сикереп тә басты, балтасына да ябышты. Мин дә тиз генә Шүрәленең артына төштем. Кулга ничек күсәк килеп эләккәндер, ыстинага терәсеннәр хәзер, һич әйтә алмыйм, тик шунысы ачык хәтердә: куаклар арасына шылырга маташкан Шүрәленең башына чык! берне шуның белән... Мәтәлеп тә китте Шүрәлең...

Утын кайгысы калмады инде бездә. Шул урман сарыгын көч-хәл белән әрҗәгә салдык та элдерттек авылга. Без кайтып җиткәндә, ул һушсыз иде әле.

Минзуклар ындырында әллә кайчаннан инде зур гына читлек аунап ята. Кайдан алып кайткандыр ул аны, кирәксәкирәкмәсә дә, аяк астында нәрсә ята, өенә ташый торган гадәте бар... Дөрес тә шул. Йортта һәрнәрсәнең кирәге чыга. Читлекне абзарга көч-хәл белән кертеп, ишеген рәтләгәч, Шүрәлене шунда яптык. Йозагын шартлатып бикләп тә куйды Минзук.

Ята җәелеп Шүрәле читлек эчендә. Безнең утынсыз кайтканны күргәч, хатын нидер чырылдамакчы иде дә, йонлач җан иясен күргәч тынды тагы...

Нишләргә? Читлектәге нәмәстәкәйнең Шүрәлеме, чуртмы икәнен ничек ачыкларга? Минзукның андый чакта баш эшли аның: «Рауил Галыч янына барыйк, аның белмәгәне юк», — ди. Чыны шул, безнең авылда бердәнбер әфтәрит ул Рауил Галыч. Авылны учында биетеп тора. Шуның өчен Чүпрәледән махсус китергәннәр аны. Бүтән вакытта безнең ише вак маймычларны чутка да кертмәгән кеше, Шүрәле турында әйткәч, хәтта көлеп җибәрде. Без дә кушылып көлгән булдык. Шундый кеше көлгәч, күңелгә рәхәт булып китте. «Эчә-эчә сезнең күзгә Шүрәле күренә башлаган инде, — ди бу. — Ылтыпыга җибәрми булмас сезне». Ә без бу арада эчү турында бөтенләй онытканбыз! Нахак сүзгә үпкәләп тә

куйдык бераз. «Рауил Галыч, — дидем, — валла! Ышанмасаң, Минзуклар абзарына барып кара, шунда читлектә утыра ул».

Без килгәндә читлек тирәсенә күрше-тирәдән әллә күпме кыз-хатын җыелган иде. Минеке дә шунда болгана. Безне күргәч, учларына көлешеп читкәрәк киттеләр. Шүрәле инде аңга килгән, күзләре ялт-йолт, ярсып читлеккә ябышкан. Ябышып нишлисең, бер-берсенә береккән арматур селкенми дә ул. Минзук, лыкы булганда да, ыбыр-чыбыр нәрсәне өенә апкайтырга юләр мәллә...

«Да-а», — дип кенә куйды Рауил Галыч. Шундый адәмне дә шаккатыргач, без тагын да күкрәкне киердек инде. Минзук барып хатынының кабыргасына төртте, тырпаеп торма, янәсе, апчык бер «чистай малаен»...

Кар кешеседер бу, — диде Рауил Галыч. — Ну, җегетләр, чабыгыз Чабаксарга җитә инде хәзер».

Ә теге, Шүрәлеме, кар кешесеме шунда, йонлач нәмәстәкәй гыгы-гыгы килә, озын куллары белән әптермәнен капламакчы була, интегә, мескен, тик кая ул, каплап кына бетерерлекмени... Безнең хатыннар шуңа күрә моннан, магнитка тартылгандай, китә алмый торалар икән!

«Казанның үзенә хәбәр итәргә кирәк, килсеннәр, күрсеннәр», — дип, Рауил Галыч идарәгә таба китте.

Минзукның хатыны алай да бер яртыны алып чыкты. Берәрне җиффәргәч, Минзук әйтә куйды: «Әйдә, малай, — ди, — Шүрәлегә дә бераз тамызабыз». Сусаган булгандыр, бахыр, каплады ыстаканны авызына. Ы-ыйк дип кикереп тә куйды хәтта.

«Бу да безнең ише икән...» — Минзук, канәгать кенә тамак кырып, җилкә чокырын кашыды.

Көне буе урманда йөреп арылган, ашыйсы да килгән икән, без бер яртыны сыткannан соң өйләргә таралдык.

Шуннан шул, әлеге Шүрәле безнең авылда яши башлады. Әллә Рауил Галычның хәбәр итүе шуның кадәр генә булды, әллә анда үз мәшәкатьләре баштан ашкан, Казаннан беркем күренмәде. Һи, Шүрәле-мөрәлегә исләре китәме соң Казан кадәр Казанда, алар аның кем икәнен дә белмидер әле, Пушкин әкиятләрендә Шүрәле юк ди икән бит, имеш...

Хәер, бәлки, килгәннәрдер дә, без белми калганбыздыр. Шүрәлене апкайтканның өченчеме, дүртенчеме көнендә Рауил Галыч безне — мине, Минзукны, Шәвәлине — колхоз диләнкесенә урман кисәргә җибәрде. Нигә һаман без дә без дип тавыш чыгарып та булмый, нәгаләт, бөтен авылына өч-дүрт бөртек ир-ат инде без. Калганнар югары очта, тупыл агачлары артында...

Ике атналап яттык без урманда. Кайтып төшсәк, малай,

авыл ничектер үзгә. Юк, йортлар да шул ук, тупыллар да шулай ук шаулап утыра, әмма нидер, нәрсәдер үзгә. Бераз башны кашып торгач, төшендек тагын: хатыннар үзгәргән безнең! Затлы күлмәкләрен киеп урамнан кәс-кәс атлап үтәләр, минсиңайтим! Авылның һавасы ук бөтенләй бүтән, күкрәккә тулып, йөрәкне кытыклый.

Үземнең хатын да, гомердә булмаганны, капка төбенә ук чыгып каршы алды, адәм тәганәсе. «Ничекләр йөреп кайттың, атасы, бик авыр булмадымы, фәләнме-төгәнме», — дип сораштыра әле үзе. Өстәл мул итеп әзерләнгән, уртада бер ярты да кукыраеп утыра! Аны бил каешына кыстырдым да, шаккатудан әвеш-тәвеш килеп, Минзукларга йөгердем. Керсәм, анда да шул ук хәл. Түрдә авызын җәеп Минзук утыра, инде яртының төбенә үк төшеп җиткән. Тирәсендә хатыны йөзеп кенә йөри, аккош диярсең. Бераз пирәшләп алгач, тәмәке тартырга дип ишегалдына чыктык. «Безнең Шүрәле нишләп ята икән?» — дип, Минзук абзарга ымлый. Бәтәч, без аны бөтенләй онытып җибәргәнбез ич. Ә абзарга керсәк, анда читлекнең ишеге шыр ачык, Шүрәледән җилләр искән!

Безнең арттан Минзукның хатыны да килеп җиткән икән, аптыравыбызны күргәч, учына гына көлештереп, гәүдәсен-сынын уйнаткалап әйтеп куйды: «Аны, — ди, — Сапый Җәмиләсе чәйгә алдырган иде». Беләбез ул теленә тилчә чыккан Җәмиләне, сүгенә башласа, фермадагы сыерлар да йөзләрен печәнгә яшерә. Мәрхүм ире Сапый белән шактый шешәнең башына җиттек. Былтыр исерек килеш ишегалдында адашып, туңып үлгән иде, мескен. Минзук акыра: «Нәрсә, мулла мәллә ул чәйгә алдырырга?» — ди. «Ул да бит кеше кебек, бер килмәгән җире юк, — ди аңа каршы хатыны. — Мәхлук ич, ялгыз... Аны инде ярты авыл чәйгә алдырды. Бүген Җәмиләнең чираты...»

Бераздан үзләре дә күренде. Алдан киң-киң алдырып Шүрәлебез атлый, артыннан теркел-теркел Җәмилә йөгерә. Җен алмаштырган, юк ла, Шүрәле алмаштырган диярсең үзен, йөзенә алсулык йөгергән, балкый. «Саумысыз, абзыйлар», — дип безнең белән исәнләшә! «Әминә апакаем, менә сиңа нәни генә бүләк», — дип, Минзукның хатынына күлмәклек төртеп маташа.

Минзукның йодрыклары йомарланган иде, Шүрәлегә карап алгач, язылды тагын. Хатынын каш астыннан сөзеп: «Хәллә-әр», — дип кенә суздыь.

Җыйнаулашып өйгә кердек. Мин алып кергән ярты әле башланган гына иде, Минзук аны гөрләтеп өч чокырга бүлде. «Әйдә, Шүрәле дус, иптәш, ахир, бажай, — диде. — Доңкик берне».

«Ул бит кеше түгел, аңа ярамый, харап итәсез, фәлән», — дигәләп, арага хатыны кереп маташты маташуын. Минзук бер генә ырлады, ирләр арасына кысылма, янәсе. Шүрәле башта йөзен чытып маташкан иде дә, өченче чәркәдән соң гыгы-гыгы килеп, баш бармагын күтәреп маташа, сасык.

Алардан ничек аерылганны хәтерләмим. Шүрәле җилкәсенә салып апчыгып куйган дисәң инде...

Шул көннән соң үзгәрде ул Шүрәле, нәкъ безгә әверелде, кая барсаң да арттан калмый, ә безнең кая бару билгеле инде, ничек тә өч борынга әтмәлләп булмасмы дип йөрү.

Авыл тагын үз төсенә кайтты. Хатыннарның сөмсере коелды, теге Җәмиләгә хәзер очрый күрмә... Минзукның хатыны Шүрәлене өйдән куып чыгарды, тагын читлектә яши башлады, бахыр. Хәер, анда да озак тормады, «Абзарны сасытып ята», — дип, идарәгә барып чәрелдәгәч, Раушл Галыч безнең дусны яшелчә бакчасына каравылчы итеп куйды. Анда алачык бар, яшелчә муре, яшә рәхәтләнеп. Баш та бар икән Раушл Галычта, нәгаләт, төрле кош-корт яшелчә бакчасын бер чакрымнан әйләнеп уза хәзер. Йоны коелса да, Шүрәле Шүрәле шул! Без килгәнне көтеп, көне буе калтыранып утыра ул шунда. Кулда ярты күрсә, чүт кенә дүрт аякланмый инде, мескен, хәтта кызганыч булып китә. Безгә иярмәсә, балда-майда гына йөзеп яшисе җегет иде бит югыйсә...

Көз көне яшелчәләр бик уңгач, күңеле булган Раушл Галыч Шүрәлегә районнан пачпорт апкайтып бирде, киң төпле ыштан бүләк итте. Шуннан соң нәкъ безнең сыман гап-гади кешегә әйләнде дә калды Шүрәлебез. Аңа инде җүнләп игътибар итүче дә юк, тик кыз-хатыннар гына, аны күргәч, ниндидер кадерле нәрсәләрен искә төшергәндәй, ирен читләре белән сизелер-сизелмәс кенә сагышлы елмаеп куялар.

## АЧКЫЧ ЧЫПТА АСТЫНДА

Кичә алар эшләмәделәр — кичә көне буе яңгыр яуды. Ә бүген, Аллага шөкер, күктә болыт әсәре күренми иде. Басу инде кипшенеп өлгергән. Кояш, саран гына елмаеп, аяз күк гөмбәзендә көндәлек сәфәрен дәвам итә. Егет чөгендер өеменә килеп утырды да тәмәке кабызып җибәрде. Басу кешеләр белән мыжлап тора, бер очтан бер очка зәңгәр кырмыскалар сыман «Беларус»лар үрмәли иде. Ә ул һаман күренми. Алар төшкә кадәр шәп итеп эшләделәр, бераз ял итәргәдер исәбе... Аның белән бер кишәрлеккә эләгү әйбәт булды әле. Ул авылда иң чибәр кыз. Егет янә кызларны

берәм-берәм күз алдыннан үткәрде. Шик юк иде: ул авылда иң чибәр кыз. Кемдә бар тагын андагыдай буй-сын? Юк, бүтән бер кызда да юк. Егет аңа бүген үк өйләнер иде.

Ул тагын басу капкасына күз ташлады. Күренми... Әнә Сәлмән килеп эшкә дә тотынды инде. Әллә ничә ямаулы зур кычыткан капчыгы чөгендер өемендә ята. Сәлмәннәрнең мал-туарлары күп.

— Тамак туйдымы, күрше?

Егет сискәнеп артына борылды, аңардан берничә адым гына читтә аның кызы басып тора иде.

— Ә мин сине бу яктан көтеп утырам, — диде егет, тавышы җиңелчә калтырап чыкканга кыенсынып.

— Мин күптән килгән идем, Халидә белән ләчтит сатып яттык.

Кызның өстендә төссез иске куртка, башында гади аксыл яулык иде. Чалбар балагын ул тезенә кадәр сызганган, бу аңа бик тә ошый иде булса кирәк. Тулы тәнле кызларның һәммәсе дә шушы уникә тәңкәлек зәңгәрсу ыштанны бик яратып кияләр иде авылда.

Кыз кулындагы кара сумканы чөгендер өеме янына китереп куйды.

— Бүген клубта танцы була, — диде егет.

— Ул ике пластинканы тыңлый-тыңлый колаклар авыртып бетте инде, энекәш.

— Сәлмән магнитофонын алып килә...

— Харап икән...

Алар чөгендер ала башладылар.

— Клубка чыкканда мине чакырырсың, яме, Җәмил җаным, — диде кыз бераздан.

— Ә кайтканда?

— Анда күз күрер әле. Тәртибеңә карап... — Кыз серле генә көлде. Аның көлүе шулкадәр серле иде ки, егетнең башына шаулап кан йөгерде, ул бүтән чакта җиңел генә алынасы чөгендерне тартып чыгара алмый интекте.

— Фәхрениса апаларга шәһәрдән кунак егете кайткан икән, — диде кыз. — Исеме ничек, белмисеңме?

Егет иренеп кенә күккә күтәрелеп карады. Баягы кояшны зур гына болыт кисәге каплап киткән иде. Кинәт кенә җил исеп куйды. Көз шул...

— Белмим.

Вак кына яңгыр сибәләргә тотынды. Һич югы чыгарылган чөгендерне тракторга төяп җибәрергә иде дип уйлады егет. Кызның эченә суык үтте, ахры, кулындагы юеш яфракларын өемгә ыргытты да биегән сыман сикеренеп алды.

— Салкын тия күрмәсен тагын...

— Әйе шул. Син минем шәлемне генә алып килә алмассыңмы, Җәмил җаным?

Егетнең башына тагын шаулап кан йөгерде. Алып киләчәк, әлбәттә! Тик өлгерер микән соң? Әнә бит трактор аларга таба шуыша...

— Өйдә бер кеше дә юк безнең, — диде кыз. — Ачкыч ишек төбендәге чыпта астында, ачып керерсең.

— Йөгердем! — Ул, аяк астында яткан чөгендерләрне дә абайламыйча, басу капкасына таба ыргылды.

— Шәл шкаф өстендә, — дип кычкырып калды кыз. Егет йөгерде. Казларын ишегалдына алып керергә дип чыккан Шәвәли абзый урам буйлап җан-фәрманга йөгерүче малайга гаҗәпләнеп карап калды. Трактор килгәнче өлгерергә кирәк дип уйлады егет.

Ихатага кергәч, ул бернигә дә игътибар итмичә ишеккә таба атлады. Әмма чыпта астында ачкыч юк иде. Егет чыптаны күтәреп селкеп тә карады, әмма ачкыч юк иде...

Шул чагында йозак кадәрле генә көчек каяндыр килеп чыкты да болытларны качырырлык әче тавыш белән өрә башлады. Трактор килгәнче өлгерергә кирәк дип уйлады егет һәм аяк астында яткан таякны алып көчеккә атты.

Кире басуга барганда ул никтер йөгермәде. Яңгыр туктаган иде, кояш, болыт тоткынлыгыннан котылып, җиргә саран гына нурларын сибә. Һәрхәлдә, кызыйга суык тимәскә тиеш.

— Нишләп алай ут капкан кебек йөгердең? — Шәвәли абзый малайны кötә-kötә арып беткән иде инде. Егет җавап бирмәде. Үз көенә басуга таба атлый бирде. Анда, бая алар туктаган җирдә, кыз, кулларын селки-селки, Сәлмәнгә нидер сөйли, ә зәңгәр үрмәкүчкә охшаган «Беларус» алар янына якынлашып килә иде.

— Ай-яй озак тордың, — дип каршылады аны кыз. Аннары гына егетнең буш кул белән килүен күреп: — Шәлне тапмадыңмыни? — дип сорады.

Егет дәшми-нитми чөгендер өеменә килеп утырды.

— Юк, рок-музыканы ошатмыйм мин. Колакны тондыра... — дип өзелгән әңгәмәне дәвам итте кыз.

— Ә «Битлз»? Андый группалар мәңгелек. Калганнар бүген бар, иртәгә юк, — диде Сәлмән.

Күк йөзе тәмам ачылган, анда-санда болыт сәләмәләре генә күренә, һәм аларның шәүләсе чөгендер өеменә чүмәшкән егетнең йөзенә төшкән иде.

— Таһир Якупов та шәп! — диде кыз. Һәм алар Сәлмән белән икәү шаркылдап көлеп җибәрделәр. Ике көн генә элек Казан артистләре клубта концерт куеп киткәннәр иде.

Мондый ихлас көлүдән кызның борыны йомшап китте, ахрысы, кулъяулык алырга диптер инде, ул кесәсенә тыгыл-

ды. Хәрәкәтләре шулкадәр дә нәзакәтле иде аның... Әмма егетнең башына бу юлы нигәдер шаулап кан йөгермәде.

Кесәдән чигүле кулъяулыкка ияреп көмеш сыман әйбер җиргә килеп төште. Ачкыч! Егет, үзе дә сизмәстән, алга омтылып куйды. Ә Сәлмән ачкычны әкрен генә иелеп алды да, исе китмәгәндәй, һавага чөйде. Ачкыч яңадан егетнең җәелгән учына килеп төште.

Зәңгәр «Беларусь» алар янына килеп җиткән иде инде. Һәм ул кырмыскага да, үрмәкүчкә дә охшамаган, нәкъ менә үзе кебек — зәңгәр «Беларусь» кебек иде.

## СӨЕМБИКӘ

Тәрәзәдә хатынның чалыш чырае күренде. Мөгаен, ашын өстәлгә куйгандыр да суына дип борчыладыр. Мин ишегалдындагы «КамАЗ»ымны янә әйләнеп чыктым, көпчәкләргә типкәләдем. Барысы да әйбәт шикелле. Иренеп кенә өскә күз салдым — ашлык белән шыплап тулган кузов брезент белән нык капланган, яңгыр-фәлән яуса, тамчысы да үтәрлек түгел. Юл ерак — Каф тавы артына, шуңа машина җырлап торырга тиеш.

Көзнең шушындый чалт аяз көннәрен яратам мин. Һавада йөзгән тоҗымнар адашып йөзгә орынып үтсә, әллә нишләп китәм. Ындыр ягыннан саркылган төтен исе борыннарны кытыклый. Бәрәңге сабагы яндырганда чыккан төтен бөтенләй үзгә ул!

Тамак ачыккан булса да, өйгә керәсе килми иде.

Шул чагында капка шыгырдаганы ишетелде. Анда көтүче Йосыфның бөрешкән гәүдәсе күренде. Ул берара капка төбендә таптанып торды да гаепле кыяфәт белән миңа якынлашты:

— Нихәл, олан...

Мин сүзсез генә башны селкеп куйдым.

— Ерак юлга чыгарга җыенгансыз икән, хе-хе... Әрмәннәрнең иленә диген, ә... — Йосыфның эренле күзләре, кызгылт җыерчыклар эченә чумып, югалып торды.

— Ни йомыш? — дидем мин, тупас кына.

— Йомыш әллә ни юк, хе-хе... Син инде анда Сөембикәне күрерсең, карчык белән мәктүп сырлаган идек, тапшыра алмассыңмы?

— Нигә тапшырмаска... Хатның авырлыгы юк, барып житүгә үк үз кулына бирермен... — Йосыфның үзен өнәмәсәм дә, Сөембикә исемен ишеткәч мин бераз йомшадым.

Ул, тагы нидер әйтергә теләп, таптанып алды.

— Бер-ике тапкыр хат язып, илләренә киткән әрмәннәргә биреп җибәргән идек, әллә тапшырмаганнар, әллә... Җавап-фәлән килмәде.

— Тапшырырмын дидем ич инде. Җавабын да алып кайтырмын.

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, — дип, бер сәбәпсезгә кет-келдәде көтүче. — Әрмәннәр бик бай яши, диләр, күреп кайтырсың инде. Кияүдән дә хәбәр юк. Көннәр чалт аяз тора, йортны күтәрергә иде бит. Син телдән шуларны да аңлатырсың инде, урысчаң яхшы...

Мин чыраемны сытып куйдым:

— Бай кешеләр, Йосыф абзый, ничәмә мең чакрымнан илләренә икмәк ташымый.

— Алай димә, алай димә, — диде көтүче. — Калхуз исәбеннән булгач, нигә алып кайтмаска? Юлы да безнең мажик өстеннән ич аның, әрмән корсагын киереп утырып кына кайта.

Кара әле дип уйладым мин, эчә-эчә мие кибеп бетмәгән икән, дөрес чамалый бит абзый...

Менә ун еллар инде безнең авылда әрмәннәр шабашкада эшли иде. Аларның кайсысы килә, кайсысы китә, ә бригадирлары — Рафик дигәннәре — тәмам безнең авыл кешесе булып беткән иде. Әрмәннәр үзләре салган таш йортта торалар, ә бу Рафик исә Гәүһәр дигән тол хатынга йортка кереп, шунда яши иде. Ул теттереп татарча сөйләшә, безнең авыл кешесеннән аерып та алып булмый дияр идең, үзен бик кибарь тота, хәтта түрәләр кебек, муенына галстук асып йөри иде. Башта алар әйбәт кенә эшләделәр, хәзер әллә колхозның акчасы бетте, әллә төзисе әйбер калмады, әрмәннәр инде вак-төяк эшләрдә генә йөриләр, яртысы район үзәгендә персидәтелгә катижмы, матижмы диләр, өч катлы йорт салып ята иде. Шулай да илләренә кайтырга ашыкмыйлар, нигә ашыксыннар, безнекеләр айлар буе акча алмаганда, болар Ходай бирмеш һәр ай азагында бухгалтер бүлмәсе тирәсендә чуала, елтыраган күзләренә караганда, юкка гына чуалмыйлар да иде төсле. Телевизор һәм радиодан, алар илендә сугыш бара, дип лаф оралар, ә монда, кая башны тыкма, әрмән дә азәри, белмим, үзләрендә кемнәр генә сугыша торгандыр, әллә картлар белән бала-чага буза куптарып ята инде?

Рафик исә тир түгеп маташмый, кайчан карама ул персидәтел эргәсендә, анда чаба, монда йөгерә, Казаннанмы, районнанмы зур кунаклар килсә, ул инде аулак болында: табын әзерли, шашлык кыздыра. Татар сарыгыннан әрмән кыздырган шашлык хәйран да тәмле була, имеш. Кешеләр сөйли, минем үземнең авыз иткәнем юк югын. Янәсе, ул Рафикны район башлыгы безнең персидәтелдән үзенә дә

алмакчы булган, тик безнеке кул-аягы белән каршы килгән: «Җанымны ал, иптәш район башлыгы, тик Рафик җанымнан гына аерма», — диеп ялынган, имеш. Булса да булыр, сезнең шашлык бигрәк тәмле дип, әллә кайлардан, хәтта хатын-кызлары белән машиналарга төялеп киләләр бит.

Әрмәннәр клубта да күз өстендәге кашка әйләнделәр. Сиздек инде, кызларның йөрәгенә ут капты. Болар бит без Шалпы малайлары кебек колак шалпайтып, башны җилкәгә качырып йөрми, гәүдә купырайган, ияк һаваны ертып бара, борын җилле... Менә шунысы бигрәк безнең кызларның һушын алды инде. Хатын-кыз бит чагыштыру юлы белән ялгыш нәтиҗәләр ясарга чос кавем.

Безнең моңа ачу килә инде — минем ул чакта егет чак — куллар кесәдә, тик кесә эчендәге йодрык белән кемне куркытасың? Йөрибез шулай теш кайрап, бер-беребезгә зарланышып. Шулай да әрмәннәр алай ук начар малайлар түгел икән, ара-тирә безнекеләрне җыеп, бер-ике ярты куялар, эчеп алгач инде җегетләрнең авызы җәелә, хет бөтен авыл кызын шыплап төяп машинага салып китсеннәр.

Әрмәннәр мал аера белә икән. Күзләре шунда ук көтүче Йосыфның кызы Сөембикәгә төште. Арсен дигәннәре бигрәкләр дә тирәсендә бөтерелә инде. Шоколадтыр, чикләвектер белән сыйламакчы була, артыннан күләгә кебек ияреп кайта. Сөембикә безнең авыл җегетләреннән дә озаттырмый иде, ут кыз икән, әрмәнне дә якын китерми. Минем үземнең дә аңа күңел яткан иде, тик юаш шул мин, бер сүз кушарга кыймыйча, тик исәнгерәп йөрим.

Инде бөтен авыл әрмән белән Сөембикәне сөйли, әрмән, имеш, бөтенләй ашау-эчүдән калган, янәсе, кайберәүләр кызны мактый, бигрәк тә җегетләр: «Маладис, җүнле кыз теләсә нинди каракүт белән тел пычратамы», — диләр, ә ахирәт кызлары үз артында көнләшүдән буылып гайбәт сата: «Үзен әллә кемгә куйган була бит әле, адәм страмы, көтүче кызы гына түгел, хан кызы диярсең...»

Арсен ым гына каксын, аларның һәрберсе аңа ияреп китәргә әзер иде төсле. Безнең кызлар бит ул джунглидан орангутан килеп чыкса, аңа да ябышырга әзер, тик маймыл татарга гына охшаган булмасын.

Ләкин әрмән дигәнең тоткан җирдән сындыра торган халык икән. Беркөнне Йосыф абзыйны персидәтел кантурга чакырып алган. Шунда ук Рафик белән Арсен да утыралар, ди.

— Нихәлләрдә ятасың, Йосыф абзый? — дип, персидәтел гомер булмаганны елмаеп, көтүчене ишек төбенә үк килеп каршы алган, җилкәсеннән кочкан. — Бер дә күзгә башка күренгәнең юк, авырып китмәгәнсеңдер ич?

Аптырап-каушап калган Йосыф абзый:

— Юк болай, карчык кына ютәлләп тора, — дип мыгырданган.

Өстәлгә ярты менеп утырган, тәлинкәләргә затлы кунаклардан калган шашлык калдыкларын куйганнар. Ул шашлыкның тәмлелеген көтүче Йосыф ярты ел сөйләп авыз суын корытты.

— Синең йортың бик тузган икән, беркөнне карап үттем, — дип, бераз салып алгач, персидәтел сүз башлаган. — Колхозга биш фин йорты кайтты. Берсен сиңа бирим мәллә? Яшә карчыгың, бала-чагаларың белән рәхәтләнеп яңа өйдә.

Иренен җыеп алырга азапланган Йосыфның «ә» дип тә, «җә» дип тә әйтерлек рәте калмаган, тик башын чайкап утыра икән, бичара.

— Тик шунысы бар, Йосыф абзый, — дигән персидәтел, — менә Арсен синең кызга үлеп гашыйк булган икән ич. Пәрәме Мәҗнүн инде, ашаганы — аш, йокысы йокы түгел, тире дә сөяккә калган. Ә безнең колхозга андый кешедән ни файда? Син аңа кызыңны бир, ә без сиңа туй бүләге итеп йорт бирербез.

Тагын берне салып куйгач, Йосыфның бөршәйгән кулы персидәтелнең дәү учына кереп югалган.

— Егет син! — дип мактаган аны персидәтел. — Текущий моментны аңлыйсың.

Вәгъдә билгесе итеп әрмәннәр Йосыф абзыйга нигәдер «аэродром» кепка, карчыгына күлмәклек ситса сонганнар. Әмма көтүче ул кепканы киеп йөрмәде, күрәсең, зуррак булгандыр, әрмән башы татарныкы ише генә түгел бит.

Безнең персидәтел шундый — әйтте икән бетте, икенче көнне Йосыф абзыйның турына фин йортын китереп тә бушаттылар. Җый да куй. Ул хәзер дә шунда ята әле. Тик такталары гына шактый кимегән, чөнки көтүче бик юмарт кеше безнең, сорап килгән кешене, бер ярты да куйса, буш кул белән җибәрә алмый. Ә авылда тактаның һәрвакыт кирәге чыгып тора. Аннары төннәрен бердер, икедер тактаны болай гына, кулга сыланып торганга гына да алып китәләр иде булса кирәк.

Арсен Сөембикәне иленә алып китте. Алар кузгалганда, мин нигәдер кантур каршында утыра идем. Аның яшьле карашы минем йөзне кисеп үтте, күпергән иреннәре нидер әйтергә теләп кыймылдап алды. Мин, бу чарасызлыкны күрмәскә теләп, башны түбән идем. Соңыннан Сөембикәне тәкәбберлектә гаепләгән кыз-хатыннар аны шулай чит илгә алып китүләре турында бәет тә чыгардылар. Безнең халык нигәдер бәхетсезләрне, кимсетелгәннәрне ярата, өзелеп, чын күңелдән шуларны кызгана.

— Шулай да йорт торгызырга жыенуым турында әйт син, — диде көтүче, миңа якын ук килеп. Йөземә төнә эчелгән аракының сасысы килеп бәрелде.

— Ул калдык-постыклардан нинди йорт торгызмакчы буласың?

— Анысы такталар бераз кимеде инде кимүен, җитмәгәнен персидәтелдән сорармын...

— Тоттырыр, — дидем мин, ачы көлемсерәп. — Кыз бит инде тү-тү!

Бу турыда исенә төшерүем ошамады булса кирәк, картның йөзендә пәрәвез селкенеп куйды. Хәзер аты-юлы белән сүгенә дисәм, эчтән тынды тагын, йомыш белән килгән бит. Ә ул сүгенә башласа, туктатам димә инде, эшереп чыгарсаң да, югары очтан түбән очка кадәр ярты сәгать әче тавышы ишетелеп торачак.

— Бирмәсә инде, — диде ул, янә юашланып, — моңарчы яшәдем ич әле, алга таба да шул иске йортымда көн итәрмен. Миңа инде озак калмаган. Ә фин йортын мәчет салырга бирәм. Тирә-юньдә барысы да мәчет өлгертә, ә бездә исе дә юк. Шул турыда кичә Шәриф мулла белән дә сөйләшеп тордык әле. Халык та бераз булышса, ерып чыгабыз аны, пускай Шәриф мәчетле булсын.

Тәрәзәдә тагын хатынның чырае сытылып алды.

— Сау бул, Йосыф абзый, — дидем мин, саруым кайный башлавын тоеп. — Әманәтеңне үтәрмен.

— Тукта әле... — Көтүче янә миңа таба елыша төште. — Бирәр нәрсәң юкмы, юл аягы диюем... — Ул кызганыч елмаеп куйды. — Кичә ныграк киткән.

Мин эндәшмичә генә болдырга таба атладым. Ул бераз таптанып торды да ыңгырашкан адымнар белән капкага юнәлде.

Без авылдан өч «КамАЗ» чыгып киттек. Мин алдан барам, ни әйтсәң дә армияләрдә булып, бераз дөнья күргән кеше. Рафик, әлбәттә, минем машинага утырды. Ул бик сөйләмчәк кеше булып чыкмады, әйбәт. Күп шоферлар руль артында йокымсырап китмәс өчен күршеләренең тел тегермәне тартып баруын яратсалар да, мин үзем лыгырдыкларны җенем сөйми.

Үзалдыңа уйланып баруга ни җитә. Уйларың ялыктырса, музыка җибәрәсең, кәеф!

Күпмедер юл киткәч, кабина идәнендә нидер кыштырдаган төсле булды. Карасам, утыргыч астына таба уч төбе кадәр генә соры күләгә шуып үтте. Тычкан! Күрәсең, иген төягәндә кереп калгандыр. Рафик та игътибар иткән: «Хәзер тотып сытабыз», — ди. «Тимә, — дим, — ул бит безнең авылныкы».

Рафик ирен чите белән генә елмаеп куйды: «Ну син даешь, авылдаш тапкан...»

Юлда бу тычканга мин тәмам ияләштем, утыргыч астына бодай сибәм, ул да үзенә хәерхаһ булуны аңлады, ахрысы, рәхәтләнеп кыштырдавын белә. Чит җирләр аша үткәндә янәшәдә генә синең белән туган иленнән бер җан иясе баруын тою күңелгә нindидер тынычлык өсти икән. Хәтта ул җан иясе гади генә бер тычкан булса да...

Ул да бит синең белән бер җирдә яралган, бер икмәкне ашаган.

Менә без таулардан түбәнгә таба төшә башладык. Аста — тау итәгендә зур гына авыл җәелеп ята иде. Рафикның йөзе үзгәрде, күзләрен яшь элпәсе каплады.

— Безнең авыл, — дип пышылдады ул.

Мин аның дерелдәгән мыегына гаҗәпләнеп күз төшердем, һәркемгә үз җире кадерле шул. Шушындый оҗмахтай җирләрне ташлап болар нигә читкә чыгып китәләр икән? Яшәсен иде туган йортында җиләк-җимеш ашап, шәраб чөмереп. Нигә һәркем үз илендә яшәми, нигә һәр халыкның үз ватаны юк?

Ашлыкны бушатып, тыйнак кына тамак ялгап алгач, мин Рафиктан Сөембикә турында сорадым. Аның елмаюы сүнеп, кашлары җыерылып килде, шикле карашы, ниятемне белергә теләгәндәй, баштанаяк гәүдәмне капшап чыкты.

— Нигә ул сиңа? — диде ул, чатнаган тавыш белән. Мин, ваемсыз күренергә тырышып, авызны җәеп елмайдым.

— Атасы хат җибәргән иде.

— Бир, үзем тапшырырмын.

— Юк инде, Рафик, — дидем мин, кискен генә. — Шулкадәр юл килеп Сөембикәне күрмичә китсәм, атасына ни әйтермен?

Ул миңа беравык кызыксынып карап торды. Малайлар артына салам бөртеге тыгылган «фатыйма»ны шулай дикъкать белән күзәтәләр. Шалпы малае да тешен күрсәтә ала икән дип уйлагандыр, мөгаен.

— Ярый, кичкә барырбыз. Ял итегез әле башта...

— Юк, йортын күрсәт тә, хәзер барып кайтам. — Аның аптырап калуы миңа тагын да кыюлык өстәде. Пычагымны эшли аламы ул миңа, аның да бит Татарстанга кире китәсе бар...

Бәхәсләшеп тормады, җилкәсен сикертеп куйды да урамга таба атлады егет.

Коры көньяк һавасы борын тишекләреннән үтеп, сулыш юлларын кытыклый иде. Рәхәт бөркүлек. Йөзем бакчалары куенына кереп поскан җилнең койрыгыннан тартып чыгарасы килә.

Менә Рафик таш койма белән әйләндереп алынган бер йорт янына килеп туктады. Ишектәге бауны тартты, эчтә

нәни генә кыңгырауның әрсез челтерәгәне ишетелде. Бераздан ишек чинап кына ачылды, бусагада мыеклы бер әрмән карты басып тора иде. Алар үзара тиз-тиз нидер сөйләшә башладылар. Ара-тирә кычкырышып алалар, кулларын бутыйлар. Талашалармы, ярашалармы, Алла белсен. Күпмедер шулай ыгы-зыгы килгәннән соң, карт өенә юыртты.

— Кер, — диде Рафик, — хәзер Сөембикә чыга. Сүзне бик озакка сузма, мин монда көтеп торырмын.

Мин, аякларны буташтырмаска тырышып, ишегалдына үттем.

Кара күлмәктән, башына да кара яулык бөркәнгән хатынны башта танымыйча тордым.

— Сөембикә!

Аның йөзе дә кучкылланып киткән, борыны да озынаеп калган шикелле. Әйе, әйе, Шалпы авылының Сөембикәсе әрмән хатыннарына охшый башлаган иде...

Ул миңа бер метрлар якын килмичә туктап калды. Мин кулны сузып үзем аңа омтылдым, яргаланып беткән кытыршы бармакларын учыма алдым. Бармаклар бераз дерелдәп алдылар да җайсыз гына учтан шуып чыктылар.

— Исәнме...

Нинди дә булса шаян сүз әйтеп бу киеренкелекне таратып җибәрәсем килде.

— Авылда сөйләгән булалар тагын: имеш, синең колакборыннарны кисеп, ябып асрыйлар, дип... Ә менә син! Дүрт саның төгәл, килмәгән төшең юк... — Мин гаҗәеп үткен сүз әйтүемә шикләнмичә көлеп җибәргән булдым.

Сөембикә тавышсыз гына сулкылдап куйды. Мәнсез дә инде мин — шундый шаярту буламыни...

— Әти-әниеңнән хат алып килгән идем... — Ул бөрешеп, таушалып беткән конвертны куенына яшерде.

— Исән-сау яшәп яталармы?

— Аллага шөкер. Йосыф абзый йорт торгызмакчы була. Такталары гына җитеп бетми бугай. Тик колхозда биш ай инде акча биргәннәре юк.

«Нигә боларны сөйлим әле», — дип уйладым мин. Мәңге салынмаячак йортта аның нинди гаме булсын?

— Киткәнеңә өч ел инде, кайтып та күрмисең...

Ул кызганыч кына елмаеп куйды:

— Итәктә ике балам бар, андый озын юлга ничек кузгалыйм?..

— Малайлармы, кызлармы? Исемнәре ничек? — дидем мин, сүз юктан сүз булсын өчен генә.

— Тигран белән Вазген, малайлар. — Сөембикәнең күз төпләренә сөенеч нурлары сызылды. — Әле йоклыйлар, күрсәткән булыр идем.

— Арсен да күренми...

— Карабахта ул. Бер ел инде хәбәр-хәтере юк. — Хатынның борыны мышкылдап алды.

«Кайчан өйгә чакыра соң бу», — дип уйладым мин. Безнең илдә бит капкадан кергән кешене чәйләмичә чыгармыйлар. Ләкин Сөембикәнең андый теләге сизелми иде. Ул гасабиланып кулларын угалый, күзләре ишегалды буйлап йөгерешә иде.

Китәргә кирәк... Башка сөйләр сүз дә юк бугай инде. Әти-әнисенә күчтәнәч биреп җибәрми микәнни?

— Хуш, алайса... Ә-ә... кибетегез кай төштәрәк? Юлга азык-төлек, өйгә күчтәнәч алырга иде.

Ул билгесез тарафка кулын селтәде: «Шунда...» Минем эчтә ниндидер бер тиле ният уянды:

— Әйдә җыен, алып кайтам.

Ул җавап бирергә өлгермәде, ишектә теге әрмән карты күренде, Сөембикәгә кулларын болгап нидер әйтте. Караңгы ишеккә суырылып кергән хатынның соңгы сүзләре бусагага коелып калды:

— Сәлам әйт...

Икенче көнне без илгә кузгалдык. Муфтадан аякны алганда, нидер чи-ик итеп куйды. Инде минем тәмам өйдәшкә әйләнеп беткән теге тычкан ялгыш табаным астына килеп кергән икән. Менә бит ул — меңнәрчә чакрымны исән-сау үт тә аз гына саксызлык аркасында дустының табаны астында сытылып үл. Мин машинаны туктаттым да, терсәгем белән рульгә таянып, йодрыкларымны күземә батырдым. Тик озак утырырга туры килмәде, арттагылар зәһәр итеп кычкырта башладылар. Мин ишекне ачып, канлы тычкан гәүдәсен тузанлы әрмән туфрагына этеп төшердем.

«КамАЗ» ухылдап алга кузгалды. Берәм-берәм тау тезмәләре артта калды, алда мине үксез илем көтә иде.

## КЫЗЫЛ СЫЕР

Бүген көне буе эче пошты Хәлимнең. Күңеле ятмады аның шәһәргә. Күчеп килүләренә ярты ел була, ә ул һаман авылны сагына, авылны юксына. Менә ярты ел шулай эчтән генә сызып йөри Хәлим. Җанын хатынына ачып салмас бит инде тагын... Дөрес, килеп өч көн үткәч, сүз кузгатып та караган иде каравын, әллә кире кайтып китикме, дигән иде. Хатыны күзен дә ачырмады. Шәһәр бик тә ошый иде Хәлимнең хатынына.

— Ни житмидер сиңа, аңламыйм, — дип тезеп китте ул, күзләреннән ут чәчеп. — Урыныңжылыда... Сөйләмә дә авыл турында, тыңламыйм да. Тагын шул зобани анаң янына кайтып, яшьли гүр иясе булыр хәлем юк әле...

Ул төнне Хәлим, хатынының иңбашларына кагылырга да кыймыйча, рәнҗетелгән сабый сыман минут саен борын тарта-тарта, стенага кереп китәрдәй булып йокыга киткән иде. Әле ярый дөньяда йокы дигән нәрсә бар. Йоклаганда, ичмаса, тормыш мәшәкатьләреннән арынып торасың. Ә кайчагында искиткеч матур төшләр керә. Төш дигәннән... шәһәргә килгәннән бирле Хәлим еш кына бер үк төрле төш күрә башлады. Имеш, яшел болында аларның кызыл сыеры утлап йөри, ә чәчәк такыя кигән хатыны йөгерә-йөгерә күбәләк тота. Төшнең ахырында, киленен чәйгә чакырырга дип, болынга әнисе килеп чыга. Нигәдер бу төшендә Хәлим бер тапкыр да үзен күргәне юк, ул шуңа чын-чынлап гаҗәпләнә иде.

Ә эч пошу кич белән тагын да арта төште. Нәрсә генә булды соң бу күңелгә? Көннәре дә матур тора югыйсә, күк йөзе чалт аяз, көне буена бер бөртек тә кар төшмәде.

Хәлим тиз генә эшен бетерде дә (ул урам себерүче булып урнашкан иде) кибеттән ике таңкә дә егерме тиенгә бер «кызыл» алып чыкты. Ул мондый эчемлекләр белән шаяра торган кеше түгел түгелен, бәйрәмнәрдә генә йөз-йөз илле грамм тотканы бар. Нигәдер бүген эчәсе килеп китте шул, ичмаса, бу эч пошуны бетермәсме дип уйлады ул. Кызыл дисәң дә, яхшы ук башка китте үзе, әмма эч пошуы гына бетмәде. Бетмәде, шайтан алгыры!

Шулай да бераздан, үзен зу-ур кеше итеп тойган бу минутларда, Хәлим хатынына бик тә ачулы иде. Семьяда гына булса да аның сүзе сүз булырга тиеш бит, ниһаять! Дөрес, бүген хатыныннан яшереп йөрткән «өчлеге»нә аракы алып эчте ул. Шуннан ни? Дөнья малы — дуңгыз каны, башлар гына исән булсын.

Алар яши торган йорт кибеттән ерак түгел, бер караңгы тыкрыкны гына үтәсе бар иде. Хәлим ярыйсы гына чайкалып өенә юл тотты. Әйе! Ниһаять, аның сүзе дә сүз булырга тиеш гаиләдә. Менә тиздән үзләренең дерматин белән тышланмаган ишекләрен ачып керер дә, тавышын калынайтып, каршы сөйләргә юл калдырмаслык итеп, кырт кисеп әйтер ул:

— Җыен, хатын. Иртәгә авылга кайтып китәбез, — диярӘй җүләр, җүләр, җүләр баш, авылдан гупчим китәсе калмаган сиңа... Җүнле ир-ат хатын сүзенә карый димени?! «Йә анаң, йә мин», — дип акылын чуалтты бит, аңгы-миңге ясады, шул хәлдә авылдан да чыгып китте Хәлим. Каенана белән килен килешә алмадылар шул. Малае өйләнгәч, кинәт кенә үзгәрде Хәлимнең әнисе. Элек тыныч иде, сабыр иде,

йортка килен кергәч, холкы үзгәрде дә куйды, Ходайның хикмәте. Зерә юкка тавыш күтәрә башлады, киленнең юк кына гаепләрен дә күпертеп улына җиткерә иде. Элек бер дә андый вакчыл, мәкерле түгел иде бит, һәрхәлдә, Хәлим аның андый сыйфатларын моңа кадәр сизмәде.

Ул ике ут арасында калды. Хет өйләнәсе калмаган икән... «Картайдым, өйдәге эшләргә кул җитми башлады», — дип әнисе үзе димләде югыйсә. Димләмәсәләр, өйләнү түгел, кызларга бер кәлимә сүз куша торган кеше түгел иде Хәлим. Бала чагыннан ук оялчан, кыюсыз булып, әнисе итәгенә тотынып үсте ул. «Бигрәкләр дә йомшак, ничек тормыш итәр бу», — дип сөйлиләр иде күрше хатыннары. Ничава-а, итә әле, бик шәп итә, кешедән бер дә ким җире юк, беркемнән дә кимсеттерми, Аллага шөкер. Хатыннар әйткәнчә бармый дөнья, аның үз законнары: катыдан әвәләнгән кешеләрне сындырып кына ата ул, дөньяның тоткасы — йомшаклар хәзер, алар бөгеләләр дә, сыгылалар да, әмма сынмыйлар.

Өйләнеп кайткач, Хәлимне кәләш белән үзен генә калдырып, әнисе чыгып китте. Кәләш егылып китәрлек үк булмаса да, чибәр генә иде. Хәлим карашынча, шәп иде! Бик озак күз карашларын очраштырмаска тырышып, дәшмичә утырдылар алар. Хәлим мәхәббәт мәсьәләсендә дөм аңгыра ук түгел, әдәби китаплар да укыштырган кеше, сүзне үзе башларга тиеш икәнне белә, тик теленә ике сүз дә килми, үзенең наданлыгыннан оялып, интегеп утыра иде. Соң, ул кызлар белән сөйләшкән кешеме? Китаптан укыганнары да баштан очкан бит, тфү!.. Шулай да, азаплана торгач, бер җөмләне искә төшерде тагын: «Мин сине яратам, иркәм», — дигәне хәтер чүп-чарлары өстенә калкып чыкты:

— Мин сине яратам... — диде Хәлим, «иркәм»ен әйтергә кыенсынды, бу таныш түгел сүз театрдагы кебек яңгырар сыман тоелды аңа.

Ул төнне алар икесе ике почмакта йокладылар.

Шуннан эшләр тәгәрәде дигәндә генә әнисе чыгырдан чыкты. Хәзер Хәлим аңлый инде: бичара ана малаен көнләгән икән. Ничек инде ул — түбән оч Бүтәкә Сапыйның кәкре аяклы кызы — синең өеңә күчеп килсен дә бердәнбер малаеңны тартып алсын, имеш! Алай гына булмый ул, нибуч! Хәлимнең әнисе дә төшеп калганнардан түгел. Шуннан соң инде... Ул мин сиңайтим, киленне эзәрлекләүләр, ул күз яшьләре, ул төн уртасында мич артындагы караватның ритм белән шыгырдый башлагач, колакны торгызып, газапланып-әрнеп тыңлап ятулар — бөтенесе булды. Яшь хатын моңа озак түзә алмады. Болай да инде ул егерме көнгә кадәр чыдады, егерме көннән соң, ниһаять: «Йә анаң, йә мин», — диде.

Ә «кызыл» әйбәт кенә башка китте. Әй-бәт. Ир-ат кайча-

гында эчеп кайтырга да имеет право. Гаиләдә аның сүзе дә сүз булырга тиеш кайчагында. Менә тиздән үзләренең дерматин белән тышланмаган ишекләрен ачып керер ул һәм әйтер...

Шул вакыт янәшәдәге йорт почмагыннан өч яшүсмер атылып чыктылар да Хәлимне уратып та алдылар. Калган икесенә караганда буйга кыскарагы Хәлимнең изүеннән тотып, йорт стенасына терәде. Нәрсәдер ысылдадылар, әмма ул берни дә ишетмәде, тегеләрнең ни таләп иткәннәрен иреннәре селкенү рәвешенә карап кына чамалады: уң кулын кесә тоткынлыгыннан азат итеп, тирләгән учындагы бакыр акчаларны карсак егеткә сузды.

Шуннан соң ул ни булганын хәтерләми. Аңа кизәнделәр, шуннан... Стенага тотына-тотына аягына басканда, ул яхшы ук айныган иде инде. Күз алдына теге карсак егетнең йөзе килде. Шакмаклы йөз, алга чыгып торган ияклэр, күзләр кара... Ә бәлки, соры булгандыр? «Ничава, барыбер эзеңә төшәрмен, хулиган, — дип уйлады ул. — Күрсәтермен...» Юк, болай булмый, булмый, булмый, кайтырга, әйтергә кирәк хатынга. Аңламый Хәлим шәһәрне, чукынып китсен бу шәһәр, теле башка аның... Яңагындагы яшьне уч төбе белән сөртәсөртә өенә атлады ул. Менә тиздән кайтып җитәр һәм әйтер...

Хатыны аны подвалдагы бүлмәләрендә көтә-көтә арып, инде җир өстенә чыккан иде. Ирен күргәч, нидер кычкырып каршы йөгерде. Тик Хәлим генә аның ни әйткәнен ишетмәде, колаклары түзә алмаслык гөжли иде. Өйгә кергәч, яшь хатын елый-елый ирен чишендерә башлады. Хәлим киреләнде, караватка яткыргач та әле ни өчендер өч мәртәбә урыныннан тормакчы булды, һәр торуында хатыны аның күкрәгенә төртеп яткыра барды. Ниһаять, торырга дигән уеннан кире кайтып, арып-талып йокыга талды Хәлим. Әле дә ярый дөньяда йокы бар, төш бар, йа Рабби... Төн буе авыл артындагы яшел болынны күреп ләззәтләнеп ятасың. Анда аларның кызыл сыеры утлап йөри, такыя кигән хатыны күбәләк куа, тиздән болынга, киленен чәйгә чакырырга дип, Хәлимнең әнисе килер...

## БУ БИШЕНЧЕ КУРС

Тәрәзәдән сентябрь кояшының җылы нурлары саркыла. Һәркем көләч. Беренче көн бит бүген. Бишенче курсның беренче көне.

Группа җыелып беткән диярлек. Рәис кенә күренми. Хәер, моңа берсенең дә исе китми, һәрвакыт соңга калып йөри ул.

Һашимов гадәтенчә акрын гына башын әүвәл уң якка, аннары сул якка борды. Җәй килешкән боларга! Кояшта янып, тазарып килгәннәр, һе-һе... Кышын, сохарига кучкәч, үз кыяфәтегезгә кайтырсыз әле.

Нәзирәгә бак син — көз дип тормаган, ачык изүле күлмәк киеп килгән, әй. Һашимовның назлы карашы кызның күкрәк уентысы буйлап кыюсыз гына шуды да кыенсынып тәрәзәгә сикерде. Ярыйсы ук җылы көн бүген. Хәтта эссе диярлек. Һашимовның сыңар җиерчык төшкән биек маңгаена канәгать елмаю кунды.

Кызларның көлешүен басып, аудиториядә Кенәзнең (аның кушаматы шулай инде, фамилиясе — Мурзин) калын тавышы яңгырады: «Укытучы укучыларыннан кышкы каникулны ничек үткәрүләре турында сорый икән. Ә Вовка каникулда авылга, әбисе янына кайткан, сөйләр сүзе күп...» Анекдот сөйли... Әйтәм аны кызлар дөньяларын онытып чыркылдый.

Кинәт аудитория тынып калды. Бөтен йөзе белән балкып ишектән кураторлары Сәлим Хәлимович күренде. Шулкадәр дә килештереп елмая, шулкадәр ыспай киенгән, кызлар, хәтта үзләре дә сизмәстән, болай да бик пөхтә таралган чәчләрен рәтләштерделәр.

— Исәнмесез, балалар!

Сәлим Хәлимовичның ел саен бик яратып куллана торган шаяруы бу...

«Балалар» рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Бүген шаяруның һәр төрлесе дә кабул ителә шул.

Шулчак ялкау гына ачылган ишектән Рәис килеп керде. Авызын йомып елмая үзе. Черек тешләре күренмәсенгә шулай елмая ул. Сәер егет... Дүрт ел уку дәверендә теш врачына барып була бит инде... Кайда ул! Аудиториягә дә беркайчан укытучыдан алда кермәс. Укытучының кереп киткәнен коридор башында сабыр гына көтеп тора, ахрысы. Быел бу гадәтен ташласа да ярый да. Бала-чага түгел...

Һашимов кесәсеннән ап-ак кулъяулык алып күзлеген сөртте. Кәефе кырыла башласа, һәрчак шулай күзлегенә тотына ул.

Ә Нәзирә, Сәлим Хәлимовичка күз дә салмыйча, ахирәте Асия белән быдыр-быдыр сөйләшүен дәвам итә. Нинди бетмәгән җилбәзәклек инде...

* * *

Һашимов укытучы булырга, кайберәүләр кебек, балачактан ук хыялланмады. Дөресен әйткәндә, унны бетергәндә төгәл генә бер максаты да юк иде аның. Казанга килгәч,

кайда җиңелрәк кереп буласын белеште дә, шушы факультетта бәхетен сынап карарга уйлады.

Менә бүген инде ул бишенче курс студенты! Катыргы тышлы диплом да кул сузымы гына ераклыкта. Өйләнү турында уйлый башласаң да ярыйдыр. Һашимов сиздерми генә Эльмирага карап алды. Вакыты житкән инде анысы, сүз дә юк. Тик менә...

Әйе, өйләнү качмас. Бишенче курста тырышып укырга кирәк. Моңа кадәр, дөресен әйткәндә, белем дәрьясына бик тирән чумып булмады. Күбрәк трай тибеп йөрелгән. Аннары, җәмәгать эшләрендә дә катнашасы иде. Киләчәк язмыш нәкъ менә шушы соңгы курста хәл ителәчәк бит.

Һашимовта ихтыяр көче бар. Үз-үзенә сүз бирә икән, ул аны таш яуса да үти. Сентябрьнең беренче көнендә кабул иткән карарын да ул акрынлап кына тормышка ашыра башлады. Тулай торакның уку залында төннәр буе ут янды. Анда Һашимов, башын өстәлгә бәрә-бәрә, фигыльнең төрле интерпретацияләрен ятлый иде.

Җәмәгать эшләрендә дә бик теләп катнашты ул. Бер үк вакытта янгын сүндерүчеләрнең дә, суда батучыларны коткару җәмгыятенең дә әгъзасы булды. Әлбәттә, аның бу тырышлыгын тиз күреп алдылар. Тиресеннән чыгардай булып тырышкан кеше күләгәдә калмый ул, андыйларны бәһали беләләр бездә.

— Һашимов, — диде декан бер очрашу вакытында. — Без сезне күптән күзәтеп киләбез инде. — Ул йомшап киткән борынын тартып куйды, күзлеген рәтләде. — Аспирантура турында уйлагыз әле. Сезне тәкъдим итмәкче булабыз.

Һашимов колакларына кадәр кызарып рәхмәт әйтте.

Ул көнне тулай торакка очып кайтты егет. Ходаның хикмәте, бер килсә килә бит ул бәхет дигәннәре. Соңгы вакытта Эльмира да Һашимовка мөлаемрак елмая башлаган иде инде.

— Эльмирочка, — диде аңа Һашимов, беркөнне вәкарь белән генә. Ахрысы, кызларга Кенәз шулайрак мөрәҗәгать итә иде... — Бүген синең белән берәр фильм карарга мөмкин булмас микән?

Сылуның куе кара керфекләре түбән төште. Ләкин серле күз карашын егетнең йөрәгенә батырырга өлгерде ул...

Эльмира — шәһәр кызы, нәзакәтле, сөйләшүе дә интеллектуаль, кинодан кайтканда ул күбрәк Камю, Кафка, Зигмунд Фрейд турында сөйли. Ә Һашимов — авыл малае, алай әллә кайларга үрелергә яратмый, аңгәмә әдәбият өлкәсенә күчсә, сүзе Мәһдиев тирәсендә әйләнә, аның «Торналар»ын мактый, Бүре Әскыйның өзелүе хакындагы бүлеккә янә шакката, Һашимов уенча, бу бүлек дөнья әдәбияты шедеврларын бәреп кенә ега иде.

Язгы кояш җылы нурларын сибә башлаганда, киләчәк язмышның контурлары ачыклана башлаган иде инде.

— Фатирның башта бер бүлмәсе дә җитеп торыр, — диде Эльмираның әтисе. — Ә аспирантура, минемчә, берничә елдан соң да өлгерер. Эшләргә кирәк. Мин бер эшне күз алдында тотам болай...

Һашимов сабый күзләре белән булачак бабасына сокланулы караш ташлады. Әйе, укырга кайчан да соң түгел. Тормыш дигәннәрен дә өйрәнергә кирәк бераз.

Эльмира наян елмаеп әтисенең галстугын төзәтеп куйды.

* * *

Диплом эше язылган, җан тыныч, Һашимов, общага бүлмәсенең пәрәвезле почмагына күзен текәп, берсеннән-берсе татлы хыялларга чумып ята иде. Ишекне шакымыйча-нитмичә тибеп кенә ачып бирәү килеп керде. Бу, билгеле, Кенәз инде. Ул гына шулай йөри.

— Нихәл, нәчәлник кияве!

Һашимов иренеп кенә көлеп җибәрде. Юк, Кенәзнең сүзләреннән көлмәде ул, беренче курстагы бер вакыйга исенә төште. Мурзинга «Кенәз» кушаматын шул вакыйгадан соң тактылар.

Ниндидер бәйрәм вакыты идеме икән, группа белән җыелышып чәй эчеп утырдылар. Мурзин, гадәттәгечә, кызыпкызып бер кинофильмның эчтәлеген сөйли.

— Бу Һашимовны әйтәм әле, — диде Рәис, шулчак аның сүзен бүлдереп. Ул шулай уртак сүзгә бернинди катнашы булмаган темага әңгәмә кузгатырга ярата иде. — Мулла малае түгел микән, дим. Аңарда ниндидер мулла тәүфикълылыгы бар.

Барысы да уңайсызланып тынып калды. Нигә бу? Ни өчен?.. Һашимовның да өрәңге яфракларыдай кызарган колаклары селкенеп куйды.

— Шәп бит! — дип кычкырды Мурзин. Ул кинофильм турында инде оныткан иде. — Мулла гаиләсеннән чыгуың белән горурлан син, Һашимов. Тукайны гына ал! Ибраһимовны, әллә кемнәрне. Менә фәкыйрегезнең ни өчен фамилиясе Мурзин? Морза нәселеннән булганга! Морза титулы атадан улга күчеп килә. Димәк, мин дә морза! Кенәз, ягъни мәсәлән.

Барысы да рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Уңайсыз тынлык юкка чыккан иде. Әмма кеше хәленә керү Мурзинга шактыйкыйбатка төште. Тәки шул вакыйгадан соң «Кенәз» кушаматы ябышып калды аңа. Хәер, алама кушамат түгел түгелен...

— Нәрсә көлеп яткан буласың, — дип бәйләнде аңа Ке-

нәз. — Әйдә кызлар янына. Өйләнгәч тә өйдә ятарга өлгерерсең әле.

— Нинди кызлар? — Һашимов караваттан аякларын салындырып утырды.

— Нинди дип, үзебезнең милли кызлар инде. Роторныйда, аяк киеме ясаучыларның общагасы янында... Әле шуннан кайттым, бииләр, җырлыйлар, әкәмәт! Һашимовны да алып чыгыйм әле мәйтәм, сөрсеп ятмасын.

— Бармыйм ла... — диде Һашимов. — «У» авазының амплитудасын өйрәнеп бетерәсе бар. Фәнни доклад...

— Ташла әле! — Кенәз аны өстери үк башлады. — Башыңа ял кирәк синең, агайне. Бер биеп кайтырсың. Шәп биисең ич син.

Ничек күңел йомшартырга белә, шайтан. Үзе бии белмәсә дә, кеше биегәнне карап торырга ярата иде Һашимов.

Чыннан да, тулай торак яны, Кенәз әйткәнчә, шаулап тора иде. Төркем-төркем егетләр-кызлар җыелган, гармун сыздыра, мәйдан уртасына чыгып теттереп бииләр, гаҗәп! Бер кыз бигрәк тә оста бөтерелә.

— Ма-ал, — диде Кенәз, сөзеп кенә. Ул шундый инде, гүзәллекне үзенчәрәк аңлый. — Таныштырыйммы?

Ә нигә танышмаска? Һашимов та әлегә егетләр чутында ла... Кенәзгә ышанырга була, ул кызлар белән, үзе әйтмешли, классный таныша белә. «Мин сезне кайдадыр күргәнем бар шикелле» дип, шаблон сүзләр белән маташмый.

— Туташ! — диде ул, теге биюче кыз янына килеп. — Әйтергә дә уңайсыз, биегәндә синең акчаң төшеп китте бит... Мә, рәхим ит. — Кенәзнең ачылган учында кәгазь акча кыштырдады.

Кыз көлеп куйды. Мондый оригиналь танышу аңа да ошады булса кирәк. Аһ, көлүләре дип уйлады Һашимов, мисле сандугач тавышы!

— Дөресен генә әйткәндә, акчаны мин түгел, минем дустым тапты. Әмма ул синең янга килергә кыймады... Тәкъдим итәм: якын дустым Һашимов. Рыцарь! Киләчәктә фән кандидаты булырлык кеше. Киләсе очрашуларга кадәр, гуд бай! — Кенәз, акчаны... тәкәллефсез генә кызның учына сонып, якындагы шау-шулы төркемгә таба китеп тә барды.

Калды Һашимов кыз янында берүзе сузаеп. Нидән башларга?

— Исемегез ничек инде? — Ул тамагын кырып куйды.

— Исем кушмаганнар миңа... — Кыз челтерәп көлеп җибәрде. Һашимовка аның ни сәбәпле көлүе бик үк аңлашылып бетмәде бетүен, тик сәбәп булганда гына көләргә димәгән ич.

— Дустыгыз бик телгә оста икән, — дип сүз башлады кыз.

— Әһе.
— Сез үзегез кайдан соң? Автобуста эшләмисездер бит?
— Юк.
Озак кына дәшмичә тордылар.
— Ярар, мин керим инде, — диде кыз. — Өшетә дә башлады.
— Сезне озатырга мөмкинме?
— Мин монда гына торам. — Кыз тугыз катлы бинага ымлады.
— Ничәнче бүлмәдә? — дип сорады Һашимов. — Иртәгә дә килергә мөмкинме сезнең янга?
— Теләгегез булса... — диде кыз һәм нигәдер гаҗәпләнеп Һашимовка карады.
...Баягы Һашимов түгел иде бу. Студентларның тулай торагына бөтенләй башка Һашимов кайтып бара иде.
— Булмады мәллә? — Кенәз мыш-мыш килә, куып җитәр өчен арттан йөгергән бугай.
Һашимовның сүзләре өзек-өзек чыкты:
— Иртәгә... янына... барам...
Кенәз көчле куллары белән аның җилкәсенә шапылдатты.
— Менә син дә чын егет булдың!

* * *

Шушы хәлләрдән соң бер-ике атна үткәч, Һашимов урамда Сәлим Хәлимовичны очратты.
— Нишләп күзгә-башка күренмисең? — диде куратор. — Сине аспирантурага тәкъдим иттек, понимаешь... Ә син килеп тә чыкмыйсың.
— Мин бүген деканатка кереп ул тәкъдимнән баш тарттым инде.
Куратор гаҗәпләнүеннән студентның кәчтүм төймәсен бөтерә башлады.
— Сәбәбе бардыр бит?
— Сәбәпләре булды инде... — диде Һашимов, ачылып китмичә.
Алар салкын гына аерылыштылар.
Шул ук көнне кич белән тулай торакка Эльмира да килде. Ул кергәндә, Кенәз тирләп-пешеп диплом эше язып ята иде. Яклауга бер атна гына калган, шуңа күрә егетнең беркем белән дә сөйләшәсе килми иде. Эльмира, аңардан бер сүз дә тартып ала алмыйча, иренен тешләп чыгып китте.
Ә Һашимов бу минутта Гөлчәчәк белән (теге кызның исеме шулай булып чыкты) тәмләп сәйлүн чәе эчеп утыра иде.

— Шәһәрне макта, авылда тор, — диде ул, чәшкесен каплап куйгач.

— Авылга җитми, — диде Гөлчәчәк тә. — Аның бит һавасы гына да дөнья бәясе.

— Безнең өй шар тәгәрәтеп уйнарлык...

* * *

— Сине эзләп килделәр, — диде Кенәз. Ул инде диплом эшенең йомгагын язарга тотынган, шуңа күрә кәефе ярыйсы ук күтәренке иде.

Һашимов гөрселдәп караватына ауды.

— Бик шәп эшкә урнашасың икән. Шәһәрдә калу теләсә кемгә тәтеми инде ул. — Кенәз янә сүз башларга ымсынды. Көне буе беркемгә дә сүз катмау үзен сиздерә, аның үтереп ләчтит сатасы килә иде.

— Әйе...

— Кайда, кем булып инде?

— Авылда, укытучы булып...

Кенәз тилергән кешедәй хихылдап көлеп җибәрде.

— Кит әле!

— Нигә исең китте ул кадәр?..

— Эльмираны авылга апкайталырсың дип башыма да китермәгән идем. — Монысын юри әйтә инде. Һашимовның көн саен кич белән кая барып йөргәнен белмәгән, янәсе.

Һашимов эндәшмәде.

* * *

— Эльмира, минем белән киногa барырга теләмисеңме? — диде Кенәз. Алар икесе дә диплом яклап чыкканнар иде.

Кыз бер сүз дә җавап кайтармыйча лифтка таба китте. Кенәз дә аңа иярде.

— Мин чынлап әйтәм.

— Кит! — диде Эльмира. Аның күзләрен күргәч, Кенәз ике адым артка чигенде. — С меня бер авыл гыйбады да хватит.

Кенәз авызын җаеп елмайды да унынчы каттан йөгерәчаба җәяү генә төшеп китте.

* * *

Бер-ике көннән Һашимов белән Гөлчәчәк авылга кузгалдылар. Арча электричкасы ашыгып алга җилдерде. Һашимов «Татарстан яшьләре»нә капланган. Гөлчәчәк түземсез-

ләнеп кыбырсый, аның да гәҗиттәге төрле гайбәтләрне укыйсы килә иде.

Дөресен әйткәндә, укыганы Һашимовның миенә барып җитми, гәҗитне ул күзлек пыяласының дымланганын күләше күрмәсен дип кенә тотып бара. Күңеле белән әллә кайларда ул бу мизгелдә.

Хушлашып бара ул. Хуш, Казан, шанлы Казан. Хуш, тузанлы-төтенле, шау-шулы шәһәр. Хуш, кадерле... Әйе, әйе, кадерле, чөнки күпме хатирәләр белән бәйле кала син!

Хуш, фәхеш шәһәр... Юк, юк, Һашимов сүзе түгел бу, Такташныкы...

Һашимов синең белән арасын өзде инде. Аспирантура белән дә, бер бүлмәле фатир, Эльмира һәм булачак каената вәгъдә иткән шәп эш белән дә һичбер икеләнүсез хушлашты ул. Калдырды. Укытучы булып авылга китте Һашимов.

Әле күзлек пыяласының дымлануы да үкенүдән түгел, сөенечтән генә...

Бәхетен шәһре Казанда тапты ул, һәм хәзер гап-гади укытучы булып авылына кайта. Кайта!

Ә нигә?

Аның урынында булсагыз, сез дә шулай эшләмәс идегезмени?

# КОРШАУ

## I. Мин – Гайнан

Әти фатирга ордер алып кайткан көнне беребез дә — әни дә, мин дә «ура» кычкырып түшәмгә сикермәдек. Ә бит бу көнне күпме тилмереп көткән идек. Күрәсең, нәкъ шушы мизгелдә актарылып чыгасы шатлык вакыт узу белән саеккан булгандыр инде. Тулай торактан аерылу моңсу да иде хәтта. Минем унбиш ел гомер биредә үткән, әти — унсигез ел, ә әни уналты ел шушында гомер уздырды.

Әлбәттә, моннан китүебезгә бик сөендек инде. Бәлки, иң нык сөенүче мин булганмындыр. Соңгы вакытларда әти белән әнинең чырайлары тәмам туйдырган иде. Әни һәрвакыт әтине эштән бер сорау белән каршы ала: «Йә, ничек?» Тегесенең дә җавабы бертөрле була: «Тиздән, тиздән...» Үзенең чырае тагын да караңгылана. Эчтән янып йөридер инде, мескен. Шуның өстенә өйдә көн дә игәүләп торсыннар әле. Мин аны якламыйм. Шул гомер эчендә фатир алырга да хәленнән килмәсен, имеш. Чәчләренә чал кунган

ич инде, әнә маңгае пеләшләнә башлаган. Фәннәр кандидаты! Хет бер торгаш булсын иде, ичмасам, барысы да җитеш, мул булыр иде. Кайчагында мин бу гаиләдә тууыма үкенеп тә куям. Ә үкенеп нишлисең, әти белән әнине сайлап алып булмый. Кабахәтлек инде, билгеле. Болай мин үзем әтине дә, әнине дә хөрмәт итәм. Хөрмәт иткән кебек яратам. Тырышалар алар үзләренчә, әти эштән кайткач урам себерергә чыгып китә, аңа кадәр төнлә ипи кибетендә йөкче булып эшләде. Әни дә көне буе аяк өстендә.

Беркөнне тыңлап яттым, иртән минем турында сөйләшәләр. Әни әйтә: «Малайны уят, чыксын синең белән урам себерергә, эш рәтенә өйрәнер ичмаса, берни белми, фәлән-төгән, колга кадәр буй үстергән...» — ди. Мин селкенмичә дә ятам. Тагын нәрсә сөйләшерләр? Әти ни дияр? «Безнең хәерчелеккә аның гаебе юк, — ди ул. — Йокласын рәхәтләнеп. Йокы туймаса, дәресне аңлап булмый. Художественная школага да барасы бар әле. Ә анда маңгай тирен түктерәләр». Әни нидер мыгыр-мыгыр килә, янә әтинең тавышы ишетелеп китә: «Ул зур кеше булырга тиеш, шул чакта гына безнең шикелле нужаланмас». Әнинең сүзләре аңа каршы чәрдәкләнеп чыга: «Син дә зур кеше — фәннәр кандидаты! Кечкенә кеше булсын иде ул, әйбәт яшәсен иде».

Әни дә шул әти эшләгән институтта эшли, әмма аның дөньяга карашы бик гади. Ә әти, о-о, ул бөтенләй башка. Интеллектуал! Мине зур кеше итәсе килә. Ул мине киләчәктә, мөгаен, Пикассо итеп күз алдына китерәдер. Ә мин сәнгать мәктәбенә ул мәҗбүр иткәнгә генә йөрим. Күралмыйм шул буяуларны, киндерләрне! Чәнчә бармак кадәр дә талантым юк минем, тәгаен беләм. Кайдан килеп булсын ул, нәселдә рәсем ясарга маһир бер кеше юк ич. Шул ук әтигә алма рәсеме ясарга куш әле, бик тырыша торгач, кәгазьдә тартма сурәте пәйда булыр. Печтек кенә сәләт тә булсын ди... Дөньяда меңләгән рәссам, меңләгән агым. Зур художник булырга безнең заманда, ай-һай! Әтинең наивлыгы инде бу, валлаһи. Тырышканда берәр нәрсә чыгарып та булыр иде, бәлки. Мәсәлән, сыер ясыйсың, аның тирәсендә дәү куллы, ак халатлы хатын-кызлар кайнаша. Рәхим итегез, Гайнан Сәйфетдинов хезмәт кешеләрен сурәтли. Әсәренең исеме — «Савымчылар». Янсә шәһәр тормышыннан бер картина. Завод цехы, станок янында яшь егет. Янәшәдә чал чәчле оста. Әсәрнең исеме — «Яшь алмаш». Йә, кемне шаккатырасың инде шулар белән? Җитмәсә, урта куллар арасында мондый әйберләр белән калкып чыгар өчен коточкыч әрсезлек, оятсызлык кирәк. Ә минем ялкаулык белән сәнгатькә — дөресрәге, сәнгатьсезлеккә — якын да килеп булмый.

Шулай да бер әйберне мәктәп күргәзмәсенә куйдылар. Гади генә натюрморт шунда. Әбигә кунакка кайткач авылда ясап аткан идем. Келәт киштәсендә он тутырган капчык, кәрәзле бал тулы савыт, умартачы битлеге. Алгы планда ике тавык күкәе... Укытучы минем әйберләргә битараф карый иде, бу юлы алгы план ошады бугай, күргәзмәгә куярга лаек тапты. Миңа да бераз күңелле булды, әлбәттә. Әмма иң сөенгәне әти иде. Очына-очына сөенде инде, мескен. Күргәзмәдә минем әйбер яныннан китмәде дә, бер якын килеп карый, бер еракккарак китә. «Еракка китеп карасаң, бөтенләй башка тәэсир икән!» — ди. Миңа малайлардан оят, борылып-борылып карыйлар, берсе хихылдый, күрәсең, Генаның әтисе бераз болайрак икән, дип сөйләшәләрдер. Әтинең җиңеннән тартам, әйдә әле башка әсәрләрне дә карыйк, дим. Кая ул! «Тукта, Гайнан, хәзер аларны да карарбыз, синең натюрмортта тагын бер деталь күрдем бит әле мин», — ди, кабат шуңа күзләре белән йотыла. Искә төшерсәң, көлке инде. Югыйсә мин алда санаган нәрсәләрдән башка чүртым да юк анда. Әти мактый: «Күләгәләрне дөрес төшергәнсең», — ди. Ә мактаганны кем яратмый? Бер мизгелгә генә мин дә үз-үземә шикләнеп куям, әллә соң миндә сәләтфәлән чаткысы бармы? Юләрлек инде, валлаһи. Кайтканда әти сәнгать турында сөйли. Үз юлыңны табу кирәк, ди, Пикассоларга, Кандинскийларга кереп китә, Дали турында ләчтит сата.

Мин дә шулай әтине бер көнгә бәхетле иттем.

Шулчаклы ук самимилеккә ачу да килә, ләкин шуның өчен хөрмәт тә итәм бугай мин аны. Мине атаклы рәссам итәр өчен, фәнен-фәләнен ташлап, гомер буе урам себерергә дә әзер ул. Күрәсең, мине яратадыр инде. Ә ярату сукыр була, диләр бит.

Әнинең минем шөгыльгә үз карашы. Натюрмортларга, пейзажларга исе китми аның. Әти кебек болытларда йөзми ул. «Син плакатлар, лозунглар язарга өйрән, — ди. — Әнә берәү безнең авылга кайтып зур хәрефләр белән «Алга, коммунизмга!» — дип язган өчен колхоздан фәлән сум каерып киткән». Ул минем мөмкинлекләрне шулайрак күрә. Торабара аның киңәшенә колак салмыйча да булмас әле, аңар гына осталык җитәр дип уйлыйм. Ничә ел рәсем ясарга өйрәнәм бит инде. Бу вакыт эчендә аю да, шабашникка әверелеп, колхоздан колхозга акча көрәп йөрер иде. Хәер, аның өчен рәсем ясый белүнең кирәге дә юк, трафарет һәм буяулар гына булсын. Вәссәлам!

Соңгы вакытта әни күзгә күренеп холыксызланды. Һаман әтигә бәйләнә: «Малаең егет булды, өйләнер вакыты җитә, киленне дә шушы тулай торакка төшерәбезмени? — ди. —

Үземнең гомерем шунда узу житмәгән». Аның кебек тагын бер юләр табылыр микән, янәсе.

Менә, ниһаять, тулай торак ишеге төбенә йөк машинасы килеп туктады. Әтинең дүрт хезмәттәше дә шунда: чырайларына караганда, кырыкка житеп киләләрдер, мөгаен. Икесе күзлекле, берсе чатанлый да бугай, ай-һай, болар безнең китап тутырган капчыкларны ташый алырлар микән?

Шаулашып бүлмәгә килеп керделәр. Әнинең акаеп каравына игътибар итмичә, әти аракы шешәсен ачты. Кичә шулар өчен көне буе чиратта торган иде. Сүзсез генә салып куйдылар.

— И-һи, әйберләрне шактый жыйгансың икән, ахры, — диде кечкенә буйлысы, озын чәчлесе.

— Күбесе китап аның...

— Шул инде, хәерче китап жыяр, — дип, сүзгә әни дә кушылды.

Тегеләр, уңайсызланып, тамак кырыштылар.

— Әйдә, булмаса, башлыйк, Бәшир, — диде чатаны. Кечкенә буйлы, озын чәчленең исеме шулай икән.

Һич уйламаган идем, галим-голәма бер сәгать эчендә бүлмәдән әйберләрне ташып машинага төяп тә куйды. Әни минем гажәпләнүне сизгән икән: «Нигә шаккатасың, барысы да авылдан ич алар, барысы да фатирсыз кавем», — ди.

Яңа өйгә күчү гомергә истә калыр инде. Йокыга китә алмыйча интектем. Әти иптәшләре белән төне буе аракы эчеп жырлап утырды. «Ай былбылым»нан алып мин мәңге ишетмәгән жырларга життеләр. Тавышлары карлыкты. Әни сүз әйтмәде, шундый көнне шаулап алырга уңайсызлангандыр. Әй жырладылар да! Әтинең жырлавын аңлыйм мин, сөенечтән жырлыйдыр инде, ә тегеләр соң, тегеләр? Нигә шулкадәр тавыш карлыкканчы бугаз ертырга кеше бәхетенә сөенеп...

Мәктәптән кайтып барганда, өч малай каршыга чыкты. Өчесе дә чәчләрен кыска итеп алдырган, өчесе дә ямьсез. Беренче карашка, алар бер-берсенә шулкадәр охшаган кебек: тар маңгай, каш астына яшеренгән сагаюлы күзләр... Төбәлеп караганда, бер-берсеннән шактый ук аерылалар да... Берсе почык борынлы, сипкелле, икенчесе каратут йөзле, ияге чыгынкы, өченчесенең чыраен тәгаен сурәтләп биреп булмый, бар ич шундый төссез адәмнәр.

— Кайсы урамнан? — дип сорады сипкеллесе.

Мондый хәлләр турында ишеткәләгән бар иде, каушап киттем. Кайсы урамнан диярга? Ә болар бөтенләй башка урамнан булса? Борынны жимерергә дә күп сорамаслар. Ярый әле борын гына жимерелсә. Дөресен әйттем:

— Шушы урамнан...
Каратут йөзлесе шикләнеп карады.
— Нишләптер бер дә күргән юк...
Төссезнең сүзләре теш арасыннан сытылып чыкты:
— Алдыйсың, падла!
— Без әле кичә генә күчеп килдек. — Һәм мин үзебез торасы йортка төртеп күрсәттем.
— Бәхетең бар икән...
Сипкелленең тавышында җылы төсмерләр бар иде:
— Исемең ничек?
— Гайнан.
— Ә-ә, — диде ул, нигәдер елмаеп. — Гайка!
Мин бәхәсләшеп тормадым. Гайка тек гайка, өйгә исән-сау житеп булса, шөреп булырга да риза. Алар тайпылып юл биреп калдылар.
Дөресен әйтергә кирәк, эчкә салкын йөгерде. Биредә сак булырга кирәклеген әни дә кисәтеп куйган иде. Сак булып нишлисең? Күренмәс кеше түгел ич мин. Бәйләнсәләр, нишләргә? Беркайчан да кеше белән сугышкан да юк...
Икенче көнне каршыга сипкелле малай үзе генә чыкты.
— Синең турында Филгә әйттем, — диде ул. — Иртәгә сәгать сигезгә балалар мәйданчыгына килергә кушты.
— Кем соң ул миңа кушарга? — Тавышым дулкынланудан калтыранып чыкты.
Сипкелле теләмичә генә көлеп куйды.
— Килгәч күрерсең. Ә мин Салих атлы. Серый.
Без кул бирештек.
— Кара аны, вакытында кил, — дип кабат кисәтте ул. — Бездә тәртип мондый... — Ул баш бармагын тырпайтты.
— Ярар, килермен, — дидем мин, теләмичә генә.
Салих эре-эре атлап китеп барды. Бераз баргач, борылып бармак янады:
— Шаярма!
Мин гаҗәпләнеп аңа карап калдым.
Бер генә дә болар белән танышасы, бәйләнешәсе килми иде. Кем ул Фил? Башлыкларыдыр, мөгаен. Күз алдына алыптай гәүдәле егет килде. Әгәр дә чакырган җирләренә бармасам? Барыбер тынычлыкта калдырмаслар. Мин нишли алам? Берьялгызым ич монда. Алар күбәү. Каныксалар, тиз генә котылырмын димә.
Кесәләргә суккалап алдым. Тартырга алырга оныткан-мын икән. Кибеттә ни гаҗәптер кеше аз иде. Тәмәке сата торган бүлектә авыр сумка күтәргән бер әби генә тора. Сатучы күренми. Әби артына килеп бастым. Кыяфәте татарныкы төсле. Картларның милләтен кыяфәтләреннән аерып була. Ә карчыкларны бигрәк тә. Нигә алай икән? Югыйсә

яшь кызларга кара, бер кап сигареттан бәхәсләшәм, үлсәң дә татармы, маржамы, йә анда чуашмы икәнен аера алмыйсың. Бәлки, бик каты текәлеп карасаң, төсмерләргә мөмкиндер дә, тик кызларга бакканда, караш чырайга түгел, башка төшләргә тарала. Ә әбиләргә карыйсың да әйтәсең: нәкъ шул... Олыгая-олыгая кан үзен ныграк сиздерәдер. Минем әтинең абыйсы төньякта яши иде. Авылдан яшьтән үк чыгып киткән, татарчаны да минем сымаграк авырлык белән сөйләшә. Урыс кызына өйләнгән, туган җире белән дә, нәселе белән дә бернинди бәйләнеше юк. Шулай да дүрт-биш елга бер авылга кайтып йөри иде. Хатыны күрмәгәндә интегә-интегә татарча сөйләшеп маташа. Соңгы кайтуында мин дә авылда идем. Бераз аракы салып алгач, елый, мескен. Мин бик аптырап карап тордым. Төньякта үз йорты бар, гаиләсе, машинасы, монда кайтып нигә балавыз сыгып утыра? Авылда калган булса, гомерен тирестә казынып үткәрер иде, бичара. Ә ул елый да елый. Ир-атның шулай үксеп-үксеп елаганын күргән юк иде әле. Мич кадәр гәүдәсе белән ишек яңакларына ышкылып бусагадан узучы хатынын күргәч кенә тынды. Соңгы вакытта аларның аралары салкынайган иде, ахрысы. Утыз елга якын яшәгәннән соң! Беркем дә түгел, абый үзе гаепле. Нигәдер динигә әйләнде ул соңгы елларда. Дини дип, намаз укып ураза тота башламады анысы. Бу мәсьәләләрдә, әби әйтмешли, әлифне таяк дип тә белми ул. Коръән укыгыз, дип, кайткан саен карт-корыга акча бирә башлады. Гаилә бюджетыннан тиктомалга акча кимүне нинди хатынкыз күтәрә алсын? Билгеле инде, Валя түти тавышланган. Җитмәсә, ул аның авылда татарча сөйләвен дә кичерми иде. «Бәлки, сез минем турында сөйләшәсездер?» Тегесе әнисе белән чит телдә гәпләшә алмый бит инде. Гәпләшер иде, әнисе бер авыз сүз урысча белми.

Аннары Валя түти үзе дә олыгая-олыгая үз гореф-гадәтләрен кайгырта башлаган. Һәркемнең дә үз зарлары, сагышлары була, ул аны картайган көнендә партия райкомына барып түгә алмый ич, аңа рухани кирәк. Картлар бик кызык бит алар. Дөресен әйткәндә, мин аларны бик аңлап та бетермим. Шуңа күрә алар турында бик җәелеп сөйлисе дә килми. Безнең картлык бөтенләй бүтәнчә булыр. Безнең гореф-гадәт тә, дин дә, чурт та юк. Шулай яхшырак ич. Җыен юк-барга ышанып, алай итсәм ни булыр, болай итсәм ярармы дип газапланганчы, бүген яшәп калырга кирәк. Иртәгәсе өчен ишәк кайгырган. Ә авылныкыларда бөтенләй бүтән холык аларда. Әти дә уфылдый кайчак: «Авыл сагындыра, эх!» — дип күкрәген уа, кайвакыт тик торганда: «Гыйльмулла чишмәсен чистарттылармы икән?» — дип сорап куя. Нигә сагындыра ул авыл, һич башыма сыймый.

Югыйсә әллә кайчан аннан киткәннәр, кендек күптән өзелгән бит инде. Мин шулай Казанны сагынып идемме? Сагынган диярләр! Мондый тузанлы, сасы һавалы таш калалар миллион, агуны кайсы таш стеналар арасында суласаң да барыбер түгелмени?

Әтинең абыйсы соңгы кайтуында юкка гына үксеп елап утырмаган икән. Күңеле сизгән мескеннең. «Үлде», — дигән хәбәр килде күптән түгел. Күмәргә баручы булмады. Әти фатирга ордер алу мәшәкате белән йөри иде. Андый чакта ничек китеп барасың? Үзе юкның күзе юк. Шулай да әти молодец ул, эшләре әйләнгәч барып кайтты. Хет каберен зиярәт кылырмын дип чыгып китте. Кайткач исә берничә көн үз эченә бикләнеп, беребез белән дә ачылып сөйләшмәде. Соңыннан беленде: абыйсы каберенә тәре утыртып куйганнар икән. Һе, тапкан борчылыр әйбер, үзең үлгәч кабереңдә нәрсә торса да барыбер түгелмени?! Үзең белә алмыйсың ич аны... Хәзер мәетләрне яндыралар да әле. Берничә минут — дек! — кешедән берни дә калмый. Тиз генә шулай юкка чыгу яхшырактыр да, бәлки. Ә үзең үлгәч эшең калсын, исемең калсын, дигән сүзләр пүчтәк ул! Ну, калсын да ди, аннан сиңа ни файда? Әле калмый бит ул, менә кайда хикмәт! Исем калдыручылар бармак белән генә санарлык, ә башкалар? Туганнары, дуслары башта хәтерлиләр, искә алалар, каберенә баралар. Күпме дәвам итә бу? Бер ел, биш ел, ун ел, әйдә егерме ел булсын. Аннары онытыла, исем дә, кабер дә... Хәтер мәңгелек түгел. Минем бабайларның кабере кайда? Җир белән тигезләнгән, беткән. Бәлки, ул урында хәзер иген басуыдыр, бәлки, анда сыра заводы салып куйганнардыр. Ә син абыең каберенә тәре утыртканга борчылып йөр, имеш. Ул кабер бүгенге көндә кемгә кирәк? Һәрхәлдә, безгә түгел, без Төньякка барып йөри алмыйбыз. Кабер Валя апага кирәк, ул анда барып утырадыр, бергә узган көннәрне искә төшерәдер, янәшәдә үзенә урын әзерлидер. Тиздән, тиздән ул да Михаил Иваныча янына килеп ятар...

Ә бер татар авылында гади генә карчык һаман үзенең Миңлегалиен уйлый. Аңа кабер кирәкми, аның күңелендә Миңлегали биш яшьлек шаян, шук малай булып яланаяк йөгереп йөри.

...Менә бит, әллә нинди уйларга кереп киттем.

Алдымда торган әби авыр сумкасын идәнгә куйды. Сатучы һаман юк. Мин түземсезләнеп кулымдагы тиеннәр белән прилавкага суккалый башладым. Кортка миңа таба борылып борчулы-сагаюлы караш ташлады. Бу әдәпсезлектә аның да катнашы бар дип уйламасыннар тагы! Алла сакласын, Алла сакласын. Әмма мине кисәтергә дә үзендә кыюлык тапмады, ахрысы, эндәшмәде, ирене генә кысылып куй-

ды, ирен тирәсендәге җыерчыклары тирәнәйде. Ә мин аңа игътибар итмичә, гамьсез генә суккалый бирдем: тек, тек, тек-тек-тек; тек, тек, тек-тек-тек. Әби гасабиланып сумкасын кулына алды; курыкты, бичара, күзләре кечерәйде, күз карасы, алай-болай булса дип, гүя арткарак чигенеп куйды. Ләкин шул чакта түр ишектән, нидер чәйни-чәйни, керләнеп беткән ак халат кигән тулы гәүдәле хатын күренде. Миңа карап җикеренеп алды:

— Чо стучишь?

— А ты где ходишь? — дидем мин, тупас кына.

— Может я в туалете была? Не машина ведь... — диде ул һәм кычкырып көлеп җибәрде. Авызында алтын тешләре балкып алды. Үзен юмористка саный, ахрысы, сасык. Шул гомер бәдрәфтә утырып буламыни? Күренеп тора — иптәшләре белән кемнеңдер гайбәтен сата-сата чәй эчеп утырган. Нәфрәтләнеп аңа карадым. Яратмыйм, менә күралмыйм инде шушы кавемне. Үзенең кыяфәте болай төкереп китеп тә барырлык түгел. Түгәрәк йөзле, бит урталары алсуланып тора, әллә үзе шулай, әллә буянган шунда, хәер, буянгандыр, утыз тирәсендә бит алмасы болай алсуланмый; коңгырт күзле, кара чәчләре күпереп тора. Гәүдәсе юантык, күптән физик эш эшләмәгәнгәме, әллә башкаданмы, тулы күкрәкләре керле халатын ертып чыгып дөньяга баш күрсәтерләр кебек. Казанның һәрбер кибетенә кер — мондый типларны очратмый калмыйсың. Алар ун-унбиш ел элек кайсыдыр Теләчедән килгән, үзләрен инде шәһәрләштек дип уйлыйлар. Кичләрен өчәү-дүртәү җыелып киноларга баралар. Җилкәдә мохер шарф, аякта фин яисә югослав сапожкилары, күттә джинсы, өстә дә кыйммәтле кием, фасылына карап... Болар форсаты барында дөньядан умырып калырга тырыша. Күзләр комсыз, ялт-йолт килә: Бауман урамын көрәп үзләренә тутыралар шикелле. Бер-берсенә нindидер ахмак сүз әйтеп хихылдашып алалар. Ә күзләр эзли, эзли, аларны күрәләрме, тиешенчә бәялиләрме? Алар белә — вакыт узып бара, ничек тә берәр ир сәләмәсе табарга кирәк, ә күбесенең язмышында ялгышулар — берничә аборт, тудыру йортында калдырып чыккан бала, тагын әллә нәрсәләр. Алар шәһәр кешесенә өнәмичә карый, әле яңа гына авылдан килгәннәргә мыскыл белән... Кайберләре инде кооператив фатир алырга өлгергән, күбесе тулай торакларда яшәп шул максат өчен акча туплый.

— Чо надо?

— Балам, ун кап тәмәке бир әле, — диде әби, татарчалап.

Сатучы аның каршында зур кеше иде, шуңа ул аңа пәйгамбәренә эндәшкәндәй эндәште. Йөзенә мөлаем елмаю җәелде, ашыга-ашыга сатучы прилавкага ыргыткан арзанлы «Аст-

ра» капларын сумкасына тутыра башлады. Тегесе тәкәллефсез генә берничә көмеш акча кайтарып бирде. Әби аларны тирләгән бармаклары белән берничә тапкыр санады, әмма акча ул исәпләп куйганча чыкмады, ахры, ул сүзсез генә сатучыга текәлде.

— Нәрсә?

— Тагын ун тиен җитми бит, балам, — диде каушаган әби. Ул аны сорап та тормас иде, күрәсең, тәмәкедән калган тиеннәргә тоз-фәлән алырга ниятләгән булгандыр. Сатучының борчуына шулкадәр уңайсызлана иде әби, күз алдында кечерәеп, бөрешеп куйды. Сатучы, аңа үтергеч караш ташлап, ун тиенне прилавкага атты. Әби татарча сөйләшкәч тә, ул аны акча саный белми дип уйлаган иде, ахрысы. Булдыра алганча тиз-тиз атлап, карчык ишеккә таба китте. Кемгә алды ул тәмәкене? Мөгаен, улынадыр...

Мин аның тормышын күз алдына китерергә тырыштым. Нинди гадәтләр инде, берәр кешегә игътибар итсәм, аның һөнәрен, матди хәлен, уйларын белергә тырышам, фаразларга тотынам. Кызык ич, шайтан алгыры. Шундый кызык җан ияләре ул — кешеләр! Менә бу әбине дә өйдә кызмача улы көтеп ятадыр. Аны берничә ел элек хатыны куып чыгарган, ул берничә көн дусларында, әшнәләрендә кунып каңгыраеп йөргән дә — ә аларда бик озак кунып йөри алмыйсың — бердәнбер юл: әнисе кырына кайтып егылган. Беркайда эшләми яисә ара-тирә генә эшләп ала, ә болай тулаем анасы өстендә, кортканың утыз тәңкә пенсиясенә яшәп ята. Азмы андыйлар Казанда? Хәзер ул әнисен сүгә-сүгә каршы алачак: «Кая шулай югалдың? Сине әҗәл артыннан гына җибәрергә кирәк», — дип сүгенәчәк.

Калтыранган куллары белән капны ертып, тәмәкене авызына кабачак. Озак кына аны кабызалмый азапланачак, берничә шырпыны сындырып, аты-юлы белән: «Анасын сатыйм, фәлән-төгән», — дип җикеренәчәк, ниһаять, тәмәке кабынгач, комсызлана-комсызлана төтенен үпкәсенә тутырачак. Әби, әлбәттә, берни дә әйтмичә, кукәйме-ниме кыздырырга тотыныр. Монда кухня-фәлән юк, барысы да шунда — бер бүлмәдә. Бу бүлмәдә аның гомере үткән, башкарма комитетта аны инде онытканнар, шуңа фатирга чираты да менә егерме ел инде сиксәненче урыннан өскә күтәрелә алмый. Җан биргәч, улы өйдә туры килсә, аны тиз генә Самосырга алып китәрләр һәм берничә кеше нәни генә гәүдә салынган табутны җир куенына салыр. Монда чират юк, көттермәсләр. Икенче көнне улы сандыктагы кәфенлекне, кемнәргәдер бирелергә тиешле сөлге, яулык, тастымалларны сатарга алып чыгар...

Бу әле яхшы. Ә чын тормышта моннан хөртирәк хәлләр

дә муеннан ашкан. Аларны инде алдан фараз кылып та, башка сыйдырып та булмый.

Мин сатучыга тавышны бөердән чыгарып эндәштем:

— Пачка сигарет с фильтром.

Ул миңа хөрмәт белән карап — урысча сөйләшәм бит! — «Родопи» кабын сузды. Яратам шушы сигаретны. Фильтры озын, шуңамы тәме башка. Хәер, тәм фильтрдан түгел инде, чүп-чарны азрак кушалардыр. Кибеттән чыгуга ук кабызып җибәрдем.

Әйе, начаррак хәлләр дә тормышта тулып ята. Минем Нәҗип исемле дустым бар. Рәсемгә бергә йөрибез. Алар шәһәр үзәгендәге хәрабәләрнең берсендә торалар иде. Быел аларга да фатир бирделәр инде. Ялгышмасам, безнең урамнан түгелме әле... Сирәк булса да Нәҗипләргә баргаларга туры килә иде. Рәсемдә ул мин түгел инде. Укытучыбыз әйтмешли, кулы күрә аның...

Сүзем Нәҗип турында түгел. Аларның күршесендә аналы-кызлы икәү — бер әби белән апа яши иде. Әбине миңа күрергә туры килмәде. Аның каруы кызын еш күрә идем. Мөгаен, минем игътибарны аның шәмәхә чырае җәлеп иткәндер. Кояш астында калган яшь бәрәңге шундый төстә була. Бу хатын очрауга, тизрәк читкә олагу ягын карыйсың; аның шул шәмәхә чырае, җимерек борыны, җыелмый торган иреннәре арасыннан күренгән кызгылт аңкавы, күптән алмаштырмаган күлмәгеннәнме, әллә, шайтан белсен, кайдан килгән үзенчәлекле ис җирәнү хисе уята. Тагын бераз тоткарлансаң, укшый башларсың кебек. Анда шушындый ук кыяфәтле ир-атлар да күренгәли. Хәер, бу төркемдәге бәндәләрне ир-ат, хатын-кыз дип бүлү дөрес тә түгелдер, биредә җенес тә юк, кешеләрчә мөнәсәбәтләр дә юк төсле. Бөтен яшәү мәгънәсе, нинди яшәү?! — җан асрау мәгънәсе — нинди дә булса исерткеч эчү... Эчү, эчү, эчү...

Бу хатын һәм аның әшнәләре — үзәк базар янындагы сыраханәнекеләр. Алар көне буе шунда, унике сәгатькә унике тапкыр исереп, унике тапкыр айнып, шул пычрак, балык тәңкәләре, сыр, ипи кисәкләре белән тулган «империя»дә кайнашалар. Җәйге эссе көннәрдә монда озын чират, анда авылдан килгән агайлар, конторларыннан биш минутка дип чыккан хезмәткәрләр, пенсионерлар, спекулянтлар тора. Алар тирләгән, сусау газабыннан инде тудырган аналарын күралмау халәтенә җиткәннәр. Бер төркем таза-таза егетләр сыраны кружка-кружка чиратсыз гына ала, чират гүли, әмма килеп ни дә булса әйтергә берсе дә җөрьәт итми. Беләләр: болар шушы тирә корольләре, ачуларын китерсәң, сөякләреңне букчаңа тутырып Кабан күленә, хан хәзинәләрен карарга җибәрүләре дә бар...

Әнә бер пенсионер карт чиратны сакларга тырышып караган иде дә, берни булдыралмады. Дулкынланудан тавышы калтыранып чыкты: «Совесть-то хоть есть у вас?» Теге алагаем гәүдәле ыржык-ыржык егетләр көлемсерәде генә: «Есть, есть, дед, иди сюда, покажем», — диделәр. Карт черт итеп җиргә төкереп болардан җирәнүен белдерде.

Сыра алырга торганда нинди намус булсын? Монда ахырзаман, этеш-төртеш, ачы итеп, җиде катлы итеп сүгенү, ә син, бабай, ниндидер намус турында сөйлисең. Хәлдән килсә, син үзең дә чиратсыз алыр идең, бер тапкыр килеп тә карадың, әмма сыра кружкалары чыга торган тәрәзчеккә якын килү мөмкин эш түгел иде, синең җиңел гәүдәңне читкәрәк күчереп куйдылар. Ветеран медаленә бирedә беркем игътибар итми. Ә тимер рәшәткәләр янында бәхетле кешеләр сыра эчеп тора! Үзләре юеш мунчалага әйләнгән, лычма күлмәкләреннән төймәләре коелган, ә йөзләре балкый. Чын бәхет шул: боларның кулларында тирләп торган кружкалар, ә кружкаларда күбекләре күпереп торган салкын сыра. Пиво! Күктә кояш кыздыра, утыз градус эсселек, янәшәдә бер авыз сырага тилмергән кешеләр. Ке-ше-дәш-ләр... Ул менә ышыкта, күбекне өреп төшереп кипшенгән иреннәрен салкын эчемлеккә тидерә. Күзләре ялтырый, ничә сәгать сусыз-нисез чүлдән барып, чишмә тапкан юлчыныкы кебек ул күзләр... Бәхетле! Бәхет дигәннәре бик гади, бик чагыштырмача нәмәрсә бит ул.

Нәҗипнең күршесе — монда иң зур авторитетларның берсе. Ул кружка җыя, шуңа күрә теләсә кемгә сыраны чиратсыз алып бирергә хәленнән килә. Ләкин ул теләсә кемгә алып бирми. Аның үзенең әшнәләре, даими клиентлары бар. Әмма иң зур авторитет монда — сыра сатучы. Аңа еш мөрәҗәгать итеп булмый. Зыялы кыяфәтенә алданма, талканы коры, артык тинтерәтсәң, кычкыра: «Пш-шла ты, сука, за-колебала!» Ачуы килгән чак икән, салып та җибәрә. Биредә аңа каршы төшүче юк, биредә ул патша һәм... хан! Биредә генә дип әйтү дөрес түгел, шәһәрдә дә ул шактый ук мәшһүр зат. Аның танышлары арасында бик зур кешеләр бар. Шул мохиттә ул үзе дә төшеп калганнардан саналмый: югары белемле... Тфү! Белемле, имеш, иң мөһиме — бай ул, меңнәр белән эш итә. Менә хикмәт нәрсәдә. Алайса, югары белемле, фәлән-төгән дигән буласыз. Хәзер югары белемлеләр буа буарлык. Егет затлы костюм-чалбардан, галстук таккан, шәп кыяфәт! Үз машинасы белән эшкә килә. Әгәр дә машина пычрак сыраханә янына килеп туктамаса, министр дип уйларсың, билләһи. Ә кем ул министр? Министрың бер читтә торсын, үзенә яхшырак булыр.

Шундый эссегә карамастан кара пинҗәк кигән — йә су-

ытып җибәрер, крәстиян табигатькә ышанып бетми — авыл агае сак кына алга үтә. Кешеләрнең чырайларына карап милләтен билгеләргә тырыша. Менә җөрьәт итеп берәүнең иңенә кагыла.

— Бер генә кружка, туган. Поездга өлгермим...

Тегесе моңа күзләрен акайта:

— Что-о?

Агай ялгышканын аңлый, кабат эндәшми. Икенче чырайны сайлап ала.

— Бер генә кружка, туган. Поездга соңарам...

— Барыбыз да соңара, — ди тегесе.

— Зинһар өчен, бары бер кружка, — дип инәлә агай.

— Барыбызга да бер кружка...

— Соң, алла бәндәсе...

Теге кеше чыгырыннан чыга:

— Мин монда өч сәгать чиратта торам. Бер коры төш калмады, анаңны сатыем! Хе, акыллы табылган... Алланың кашка тәкәсе түгелсеңдер...

Бераз эндәшми торалар. Алай да агай өметен өзмәгән, тегесе сөйләшә бит, ә андыйларда шәфкать хисе була. Бераздан тагын ялвару ишетелә:

— Ярар инде, туган, бер генә кружка. — Һәм агай милли хисләрдә уйнап карый: — Бер-беребезгә урыс-керәшен түгел ич.

— Кемнәр соң?

Агай бу сорауга аптырый, ялгышты мәллә, шайтан алгырысы...

— Соң, мөселманнар, татарлар...

— Тем более дерьмо... — ди тегесе теш арасыннан.

Аларның сөйләшүен тыңлап торган чират шаулап көлеп җибәрә. Агайның көләсе килми, ләкин ул да кушылып көлгән була.

— Туганнар, поездга соңарам бит, валлаһи, — ди. — Арчадан мин, Гөберчәк авылыннан.

— Анда электричка сәгать саен йөри...

— Арчада бит попутныйга чыгасы бар.

— Ярар, бир тиеннәреңне, — ди бая аның белән сүз алышканы. — Чистый сагыз булдың, анаңны сатыем.

Бер кочак буш кружка күтәргән җыючы хатын боларны этә-төртә тәрәзчеккә якынлаша. Алда торучылар аңа юл бирә, карашларында җирәнү һәм хөрмәт. Кемдер бер сәбәпсезгә бу хәрабә-хатынга ялагайланып та ала:

— Тетя Маша свое дело зна-ает...

Ләкин хатынның беркемдә дикъкате юк, ул инде бу сүзләрдән узган, мактауга да, сүгүгә дә, ялагайлануга да, кыйнауга да аның исе китми. Гадәти кешегә хас сыйфатлар аңа

хас түгел. Әгәр дә җан дигән нәрсә булса, ул күптән бу тешсез авыздан чыгып качкандыр шикелле. Бары тик кабырчык кына калган, шул кабырчык кына торалмаска егылганчы бередә селкенеп йөриячәк.

Алай да аның баш сөяге астында да ниндидер уй кебек нәрсә булган икән. Миңа бу хәлне Нәҗип сөйләде.

Беркөнне күршеләренең ишеген почтальон шакыган. Нигә шакыганы билгеле, болар газета-фәлән алмыйлар, хат килми, димәк, пенсия көне, әби карчыкка почтальон пенсия акчасы китергән. Ишекне әлеге дә баягы Маша ача.

— Кая анаң? — ди почтальон һәм нигәдер борынын каплый.

— Пенсия китердеңме? Давай, бир, — ди Маша. — Әни ахирәтләренә киткән иде.

— Юк, үз кулына гына бирәм... — Почтальон кире борылмакчы була.

— Үз акчаң мәллә... — дип гырылдый тегесе. — Кул куям, китер тизрәк...

Почтальон, күрәсең, нидәндер шикләнгәндер, тактиканы үзгәртә.

— Ярар, ярар, әйдә, бүлмәңә үтик, — ди.

Ә Машаның бусагадан уздырасы килми, акчаны ишек төбендә генә алмакчы. Почтальон аны читкә этәреп — сыра белән генә тукланган карачкыга күпме көч кирәк соң? — түргә уза. Мөгаен, аны теге сәер ис шикләндергәндер. Ә бүлмәдә — мәет. Аның инде җан биргәненә биш көн үткән, тәненә яшелсу-зәңгәр тимгелләр йөгергән була. Пенсия акчасын алырга өметләнеп, кызы аның үлемен беркая да белдерми торган икән.

Менә нинди хәлләр дә була дөньяда.

Тәмәкене чүплеккә ташлап өйгә кереп киттем. Анда әни коймак пешереп йөри, яратам шул коймак исен. Юынып кухняга чыктым. Әни еш-еш иснәнә башлады.

— Тартkансың, малай...

Мин башта гаҗәпләндем. Юындым, авызны чайкадым, нинди ис килергә мөмкин? Аннары өйгә коймак исе таралган бит әле.

— Юу-ук, — дидем сузып кына. Тартучы малайлар янында басып торган идем, шулардан сеңгәндер...

— Мине җүләр дип белдеңме әллә? — Әни миңа карап башын селкеп тора. — Үзең өчен әйтәм ич... Бу яшьтән никотин суыру яхшыга илтми. Спорт белән шөгыльләнер идең, ичмаса.

Башлана... Мин дәшми-тынмый залга чыгып китәм. Әнинең вагазен эти дә ишетеп торган икән.

— Ташла, улым, — ди. — Алдашма. Ялганың да бик тапталган, балам. Мин дә әнкәйне шулай тынычландырырга маташа идем.

— Син тарта идеңмени?

— Шаяра идем шунда. Малайчак ахмаклыгы. Кабызып җибәрсәң, янәсе, үзеңне инде олы кеше итеп сизәсең. Начар шөгыль, бик зарарлы, зарарлы шөгыль. Ташла...

Ул әни кебек ачыргаланмый, тыныч кына, кызмыйча гына сөйли. Мин үз-үземә әчтән генә тартмаска сүз бирәп — инде ничәнче кат! — диванга авам.

— Тәмәке белән яз көне шаярып алдым, — дип әти сүзен дәвам итә. — Шул синең яшьләрдә булганмындыр. Тау битләре кардан арчылган чак. Авылның бөтен малай-шалае, кыз-кыркыны шунда була. Ә синең язгы ташуга карап торганың бармы?

Мин: «Юк», — дип баш селкім.

— Юк шул. Хәзер ташу да юк инде. Урманнарны кисеп бетерделәр, карны кырларда ук сеңдерәләр, кайдан килсен ул ташу? Ә син кар суының исен иснәгәнең бармы? Иих... — Әтинең тавышы нечкәрә, күзлек пыяласы парланып чыга. Мин аны тыңлыйм да, тыңламыйм да кебек. Кар суы исе, имеш. Ну и что? — Авылда өйләрне юу вакыты, — дип дәвам итә әти сүзен. — Малай-шалай чиләкчиләк кар суы ташый. Кызлар зур мунчалалар белән өйне юалар, түшәмне, стеналарны, тәрәзәләрне. Тәрәзә юа кызлар! Маллар беренче тапкыр көтүгә чыга. Ашыгалар, кабаланалар, ирек бит, ирек. Сыерлар мөгри: м-му-у, сарыклар бәәлди: бә-ә-ә, кәҗәләр мекелди: мэ-әә... Менә шундый иде ул безнең малайчак язлары. Кайтып булмый инде аларга кабат...

Урынымда борсаланып куям. Күп тыңлаган бар ла мондый хатирәләрне. Өлкәннәрнең барысы да бер: «Менә без малай чакта...», «Менә без яшь чакта...» Алар шәп булган! Эшли дә белгәннәр, ял итә дә белгәннәр. Шаярганнар, шукланганнар да, шул ук вакытта тәртипле дә булганнар. Ул вакытта табигать тә искиткеч, дөньялар да таң калырлык. Кем шушы хәлгә китереп җиткергән соң алайса табигатьне? Нигә Антарктида өстендә озон ертыгы пәйда булды? Кем һаваны суламаслык, суларны эчмәслек итте? Нигә атом электростанцияләре шартлый, танкерлардан океанга нефть түгелә? Нигә шундый акыллы, тәртипле булып үскән кешеләрнең малайлары тимер таяклар белән сугыша, кызлары почмак саен зина кыла?

— Безнең язлар сезгә — безнең малайларга әйләнеп кайтыр, — ди әти, фәлсәфи тонда. — Шулчак сез җаныбызны, омтылышларыбызны аңларсыз...

— Яңа заман, яңа язлар, яңа кошлар, — дим мин, кемнеңдер сүзләрен бераз үзгәртеп.

Әти миңа күзлек өстеннән сәерсенеп карый. Кан сауган күзләре бөтенләй кечерәеп калган. Сәерсенсә соң? Аның сарыклы язлары миңа ерак, мин бөтенләй башка хайван...

Әтинең авырый башлаганын белми идем әле мин. Хәер, ул үзе дә бу чирнең нинди явыз, мәкерле икәнен сиземләми иде.

Укытучы натюрморт ясап килергә кушкан иде. Ә мин ясамадым. Ирендем, ясыйсым килмәде. Ләкин укытучыга алай дип әйтеп булмый бит. Әнә ул акрын гына кешеләрнең эшләрен тикшереп килә. Әлбәттә, Нәҗип өстәле янында озак кына туктап тора. Аннары, аның җилкәсенә кагылып: «Яхшы!» — ди. Ботинкасы шыгырдый. Якынлаша. Авыз эченнән «хе, хе» дип көлгән сыман итә, кемнедер сузып кына: «Не дурно», — дип хуплый. Ни дип акланырга? Илһам килмәде дипме... Ә кайчан килгәне бар соң аның? Эх, Вольф Мессинг булсаң икән ул. Үзендәге талантны бик очраклы ача бит ул. Акчасы булмагач, поездга билетсыз утырган була. Утырмый инде, эскәмия астына кереп ята. Билгеле, контролер билетларны тикшерә башлый. Мессингны да эскәмия астыннан сөйрәп чыгаралар. Малай идәндәге бер кәгазь кисәген алып контролерга суза. Ә күзләрендә шулкадәр ышандырырга теләү хисе. «Билетың булган килеш нигә эскәмия астында барасың?» — ди контролер һәм гап-гади кәгазь кисәген компостерлый.

Бәлки, миндә дә Мессинг таланты бардыр? Шундый авыр моментларда ачыла да инде ул.

— Ә синең эшең кайда, Сәйфетдинов?

Мин аңа чиста кәгазь сузам.

— Ваза, вазада алмалар, янәшәдә тастымалга төрелгән ипи...

Укытучы аптырап миңа карый. Мин аңа төбәләм. Ә күзләремдә шулкадәр ышандырырга теләү хисе. Хәзер укытучы: «Шундый шәп натюрморт ясаган килеш нигә борсаланып утырасың?» — дияр һәм чиста кәгазьгә бишле куяр төсле.

Тик ул ашыкмый. Бер миңа, бер чиста кәгазьгә карый. Аннары хахылдап көлеп җибәрә.

— Ха-ха, ха-ха, ха-ха...

Чиста кәгазьне класска күрсәтә.

— Ваза, вазада алмалар, янәшәдә тастымалга төрелгән ипи... Ха-ха, ха-ха.

Хәзер барысы да көләләр. Укытучы инде сыгылып төшкән.

— Ну, Сәйфетдинов, — ди ул, бераздан күз яшьләрен

сөртә-сөртә. — Мондый ук юморист дип уйламаган идем сине.

Юморист? Кеше үзендә бөек талант ачылмасмы дип өметләнә, тәҗрибә ясый. Ә бу... Хе, юморист, имеш.

Кыскасы, дәрес бик күңелле узды. Кайтырга чыгабыз. Барысы да минем ясалмаган натюрмортның исемен кабатлый.

— Ваза, вазада алмалар, янәшәдә тастымалга төрелгән ипи...

Нәҗип белән үз тукталышыбызда төшеп калабыз. Ул һаман көлүдән туктый алмый әле.

— Ә син чынлапмыни? — дип теңкәгә тия. — Ышаныр дип уйладыңмы?

— Эксперимент, — дим мин, тәкәллефсез генә.

— Әй, җыбыткы!

Без тавыш килгән якка әйләнеп карыйбыз. Анда кулларын кесәгә тыгып миңа таныш өч малай басып тора.

— Гайка, кил монда, — ди сипкелле.

Теләмичә генә алар янына борылам. Нәҗип тә миңа иярмәкче.

— Ә син, очкарик, өеңә кайта тор, — ди каратут йөзле. — Кирәгең чыкса, чакырырбыз.

Нәҗип аптырап миңа карый.

— Бар, кайта тор, — дим. Чебеш кебек Нәҗиптән нинди ярдәм көтәсең?

Малайлар минем белән сөйләшеп тормадылар.

— Әйдә Фил янына, — диде сипкелле.

Без балалар мәйданчыгына юнәлдек. Анда ун-унбиш малай җыелган иде. Кемдер нидер сөйли, калганнар, әледән-әле аның сүзен бүлеп, га-га көлешәләр. Безне күргәч, барысы да тынып калды. Миңа төбәлгән карашларын тоеп куырылып куйдым. Бу карашларда явызлык, кызыксыну, битарафлык, тагын әллә нәрсәләр бар, тик теләктәшлек кенә юк иде.

— Ә, алып килдеңме кошны, Серый... — дип сипкеллегә эндәште кәтүк буйлы, хәчтерүш кенә бер малай. — Бик ялындырып кына йөри, кызлар кебек назлана...

— Назын чыгарырбыз, — диде тагын берсе, усал гына. Ул башкаларга караганда эрерәк, беләк мускуллары футболкасы аша тибеп тора, күзләрендә өмет юк иде.

— Син нигә чакыргач килмәдең? — дип ысылдады кәтүк малай.

— Оныткanмын, — дидем мин, шүрләп. — Дәрескә барасым бар иде.

— Оныттыңмы, әллә дәрескә барасың бар идеме?

— Оныттым. — Дөрестән дә бу чакыру бөтенләй баштан чыккан иде. Хәер, онытмаган булсам да, дәрескә бармый калып, болар янына килмәс идем, мөгаен.

— Боксер! — Кәтүк малай эре гәүдәлегә эндәште. — Искә китер әле егетне...

Боксер дигәне елмая төшеп миңа якынлашты. Бер мизгелдән мин суалчан кебек җыерылып җирдә ята идем инде. Касыкка сукты, кабахәт!

— Тор!

Мин чайкала-чайкала торып бастым. Боксер арык малайга сораулы карашын төбәде.

— Тагын кирәкме, Фил?

— Әлегә җитәр... Йә, бүтән онытмассыңмы инде?

— Онытмам, — дип мыгырдандым мин.

Менә кем икән аларның Фил дигәннәре... Ә мин аны фил гәүдәле бер алпамша дип уйлаган идем.

— Чакырган җиргә таш яуса да килергә, соңга калмаска, — диде ул.

— Минем килү-килмәү сезгә нигә соң? Сугыша белмим, тычкан кебек мыштым мин... Тимәгез, ә?

— Сине кайгыртабыз, дурак. Башка урамныкылар, берьялгызың булсаң, изməңне изеп ташлыйлар юкса. Ә безнең белән йөрсәң, алар сиңа тырнак очы белән дә кагыла алмый. Бергәлектә көч!

Кара син аны, үзенең нинди дер фәлсәфәсе дә бар икән.

— Аннары, — дип сүзен дәвам итте ул, — чәчеңне кыска итеп алдыр, безнең сыман киенеп ал. Аерылып торырга ярамый. Берәр төрле кыйнашу вакытында бер-беребезне танырлык булсын. Акчаң бармы?

— Утыз ике тиен...

Тагын барысы да га-га көлеп җибәрде.

— Взнос, Гайка, взнос... Хәлдән килгән кадәр бирәсең, конечно. Тик ул биш тәңкәдән дә ким булмаска тиеш.

— Ә кая китә соң ул акча? — дип сорарга җөрьәт иттем.

Фил миңа каш астыннан карап куйды. Мондый кызыксынучанлыкны яратып бетермәде булса кирәк.

— Тегендәгеләргә, — диде ул, сузып кына. — Там, где Макар телят не гонит, безнекеләр күп. Әгәр дә син анда эләксәң, кем ярдәм итәр? Без! Калганы үзебез өчен. Иректәгеләргә. — Филнең авызы кыйшайды. — Ул турыда син артык уйланма. Башың авыртыр... — Бераздан:

— Син комсомолмы?

— Әйе.

— Димәк, взнос синең өчен яңа нәрсә түгел. Ә ул акча кая китә? Беләсеңме? — Фил канәгатьләнеп елмайды.

Мин белми идем. Ләкин бит комсомолда мин ике тиен түлим, ә монда биш тәңкәдән ким түгел, ди. Яхшы чагыштыру!

— Һәр совет кешесе взнос түли, — дип сүзен дәвам итте

Фил. — Партия взносы, профсоюз взносы, төрле җәмгыять взнослары — табигать яратучыларныкы, янгын сүндерүчеләрнеке, суда батучыларны коткаручыларныкы, тауга менүчеләрнеке, таудан төшүчеләрнеке... — Ул үзенең сүз куәсенә сокланып иптәшләренә карый, аларның да соклануын көтә. — Ә фондлар? Тынычлык фонды, Культура фонды, Балалар фонды. Без дә совет кешеләре. Безнең белән буласың икән, рәхим итеп взнос китер. Капиталист кебек акча җәлләсәң, үзеңә үпкәлә. Менә син, — дип миңа мөрәҗәгать итте ул, — көн дә туйганчы ашыйсың, кыскасы, урының корыда, өстең җылыда. Менә Вова... Әтисе алкаш, әчеп кайта да сугыша. Кыш дип, көз дип тормый, Вовканы тышка куып чыгара. Аның киеме юк, тамагы ач... Ә? Кайда монда гаделлек? Ә без аңа трико алып бирдек. Шулаймы, Вовка?

Кечкенә буйлы, павиан токымыннан булган маймылныкына охшаш йөзле малай бу сүзләрне раслап башын селкеде.

— Шулай...

— Ә син биш тәңкә җәллисең. Син!.. — Фил ары-бире йөренә башлады. — Син! Җылы бүлмәдә телевизор карап утырасың, ә ул тышта салкын урамда дер-дер килә, тешетешкә тими. Гаделлекме шул? Безгә тигезлек кирәк. Бар кешеләр дә тигез булсын. Без уйлыйбыз ул турыда... — Һәм ул каядыр билгесезлеккә кул изәде. — Андагылар түгел...

— Акча җәлләмим мин... Тик кайдан алырга соң аны?

Фил озак кына миңа карап торды. Нинди аңгыра син, янәсе.

— Анысы синең эш, — дип авыр сулады ул. — Тырышкан табар...

— Фил, кызлар! — диде Серый шул чакта. Аннары якынлашып килүче дүрт кызга кул изәде. — Ә-әй, монда килегез!

— Акырма, — диде кызларның берсе. Ул башкаларга караганда чибәррәк, төз борынлы, зәңгәр күзле иде. Саргылт чәчләрен юри тузгытып куйган. — Болай да киләбез.

— Аһ, Гулечка, шундый сагындык без сине, — дип, Серый аның беленнән кочкан булды.

— Ябышма. — Калган кызлар нигәдер хихылдап көлештеләр. Ә Серый һаман бәйләнде:

— Йә инде, бер генә кочыйм.

Гуля әшәке итеп сүгенде.

— Кит, бәләт, — дип шырык-шырык килде ул. — Танавыңа менеп төшәм хәзер. — Ә Серыйның шулай кылануы аңа ошый иде, ахрысы.

— Ә бу кем тагын, — дип, миңа төртеп күрсәтте калын иренле кыз. — Яңа бәрән?

— Өр-яңа! Гайка исемле...

— Гайка! Мэ-мэ... — Калын иренле миңа таба кулын сузды. Бәрәннәрне шулай чакыралармы әле?

Мин аптырап Филгә карадым. Ул иренен сикертеп кенә елмайды.

— Ярар, бар кайт, — диде ул. — Иртәгә сәгать унга монда килерсең.

— Иртәнгеме?

Тагын барысы да га-галап көлеп җибәрде. Серый бармагын баш тирәсендә уйнатып алды.

— Дурак!

— Боксер, бар, Гайканы бераз озатып куй, — диде Фил.

Яктыга чыктык. Боксер минем беләктән тотты, ирексездән мин кычкырып куйдым. Киләшчә белән кыстылармыни!

— Башыңны җүләргә салма, — дип ысылдады Боксер. — Уеннан уймак чыкмасын. — Аннары аркадан какты. — Давай, иртәгә кадәр чеши...

Әни мине сораулы карашы белән каршы алды.

— Нигә соңардың?

— Малайлар белән киногa кергән идек, — дип ялганладым мин.

— Нинди фильм иде соң?

Бер мизгелгә генә югалып калдым. Нинди булса да барыбер түгелмени?

— Сугыш турында инде. Исеме әллә ничек иде шунда... Истән чыккан.

— Әйдә ашарга...

Әти үз почмагында нәрсәдер язып утыра иде. Ничек шулай бертуктамый язарга, укырга мөмкин? Һич башка сыймый.

Бик ачыккан идем, тәлинкәне ялтыратып кына куйдым.

— Әни, син миңа биш тәңкә акча бир әле?

Әнинең күзләре гаҗәпләнү хисе белән мөлдерәмә тулы иде.

— Нигә шулхәтле?

— Кирәк инде, — дип мыгырдандым мин. — Бүген дә киногa керер өчен кешедән алып торырга туры килде.

— Сиңа киногa керер өчен кирәк, — диде әни. — Менә безнең ун сум акча калды. Ә акча алырга әле тагын биш көн бар.

Беләм инде, алар көчкә очын-очка ялгыйлар. Ә минем хәл? Иртәгә теге бандитларга акча китермәсәм, алар минем урамга чыгарлыгымны калдырмыйлар бит.

— Мин бит бала-чага түгел хәзер, — дип кыздым мин. — Бер тиенсез йөрергә... Малайлардан оят. Аларның кесә тулы акча, фирменный кием. Хәерче булуыбызга мин гаепле түгел ләбаса.

— Нигә миңа кычкырасың? — Әни дә кызды. — Атаңа барып әйт бу сүзләрне...

Әти янына барып зарланырга оят иде, мин тындым. Шулай да миндә дә хаклык бар бит. Бар!

Әнә безнең класста кайберәүләр ничек борыннарын чөйгән була. Безнең ишеләргә мыскыл белән карап, үзара гына сөйләшеп, аралашып йөриләр. Сүзләре бик акыллы, фәлсәфи дип уйлыйсызмы?

— Ой, Аида, боже, кайдан алдың бу күлмәкне?

— Роберт, мин яңа кассета достал. Суперкласс! Тыңларга кил.

— Минем әти Италиядән шәп куртка алып кайтты. Тагын бик күп шмоткалар. Килегез, күрсәтермен.

Аннары бер-берсе белән инглизчә сөйләшеп җәфаланалар тагын. «Гуд монин» да «гуд бай». Хәсрәтләр. Куралмыйм шул пижоннарны.

Минем акылым әллә ни түгел, талант та юк. Ә алар миннән ни белән аерылалар соң? Алар миннән дә аңгырарак! Өстә әйбәт кием, кесәдә акча булгач кына акыллырак күренәләр. Җәмәгать эшендә дә шулар. Барысы да алдан уйланылган, үлчәнгән. Болар югары уку йортларына керәчәк, комсомол лидерлары булачак, кеше бәхете турында гәп сатачак. Әтиләре инде аларга кәнәфиләр әзерләп куйган, баскыч та әзер, тыныч кына югарыга үрмәли бир.

Болар хәйләкәр, астыртын. Телләрендә «мин» дигән сүзне ишетмисең. Без! Безнең планнар шундый, безгә шушы уйны тормышка ашырырга кирәк, фәлән дә төгән. Ә һәрберсе үзе турында сөйли. Тирә-юньдәгеләр бу кеше безнең турыда кайгырта икән дип уйласын өчен «без»не сибәләр генә. Ышаналар бит! Битлеге шулкадәр шәп, чын йөз дип кабул итәсең. Шундый тойгы кала — алар үз ялганнарына үзләре дә ышана кебек. Власть, байлык, дан өчен яшәүләрен үзүзләреннән дә яшерәләр төсле. «Без җәмгыять үсешенең яңа этабына килеп кердек». «Без! Без, Николай Икенче...» Элек патша гына үзен без дип атаган, хәзер ике кешенең берсе без дип сөйли. Һәм һәрберсе бары тик үзен, үзен генә күздә тота.

Менә ул пижоннарның тормыш юлы. Шундый чисталар, пөхтәләр, тәрбиялеләр... Гөмбәләр кебек. Очрый бит урманда шундый мәһабәт гөмбәләр — үзләре ап-ак, дәү, матур... Алып кыссаң, эче буш, сасы ис кенә чыга.

Әгәр дә минем әти бай булса, мин дә шундый пижонга әверелер идемме? Бәлки... Шулай булгач үз хәлеңә — кайчакта бик ачу килсә дә — сөенергә генә кала.

Алда мине нәрсә көтә? Хәзер безне «Кем булырга телисең?» дип тинтерәтәләр. Теләгән берсе шул сорауны бирә,

иншалар яздыралар. Бер иншада мин шофер булам дип яздым, икенчесендә — шахтер, өченчесендә — тагын әллә кем... Ә чынында беркем буласым да килми, шайтан алгыры! Көн дә торып эшкә китәсең, кайтасың, ашыйсың, йоклыйсың, өйләнәсең, хатының белән буласың, бала туа... Бр-р... Кайда монда мәгънә? Тагын шул әти-әни кебек очын-очка ялгап гомер итәргәме, фатирны егерме ел көтеп, хатының белән ызгышып... Кереп сыра эчәргә дә кесәңдә акча булмасын, имеш... Акчаң булса сыра булмый... Кайтып телевизорны ачасың, анда кичәге пижоннар чыгыш ясый, ике меңенче яисә өч меңенче елга җиңел бәхет вәгъдә итә. Ышанырга туры килә, бәлки, чыннан да шулай булыр, бәлки, бәлки, бәлки... Өметсез шайтан, диләр ич.

Ә миңа иртәгә чыраем төзек калсын өчен кимендә биш тәңкә акча кирәк.

Син шулай тыныч кына яшәрмен дип уйлый идеңме? Юк, Гайнан, үз мохитең юк икән, барыбер кайдадыр барып сыенырга туры килә. Сине Робертлар, Аидалар даирәсе кабул итмәячәк, димәк, Филләр, Серыйлар, Гулялар янына елышасың. Башка юл юк, туган. Бардыр да, бәлки, ләкин мин аны күрмим, минем өчен түгел ул. Шундый кешеләр була бит: алар беркем түгел, ихтыярлары камыр, алар барыбер кемнәргәдер барып сыенырга тиеш була.

Мин, мөгаен, шундый кешедер...

Карасам, әти ишек яңагына сөялгән. Кесәсеннән таушалып беткән өчлек чыгарды.

— Өч сум җитәме әлегә?

— Җитеп торыр инде, — дидем мин. Нишлисең, бер дә булмаганга караганда яхшырак.

— Узындың, малай... Беләсеңме, мин синең кебек чакта...

Таныш миңа бу нотык. Минем кебек чакта алар пычрак ерып колхоз эшенә дә йөргән, «пәри күзе» янында — электр әле хыялда да булмаган — дәрескә дә әзерләнгән... Кием дә юк, тамак та ач... Бернәрсә дә юк! Күңелләре генә күтәренке, йөрәкләре генә киләсе көнгә өмет белән тулы. Ә кесә буш, дәресрәге, кесә бөтенләй юк, ыштансызлык... Тоталар да шуның белән мактаналар... Мин синең кебек чакта... Әти хәерче үскән дип мин дә хәерче үсәргә тиешме? Әллә хәерчелек тә нәселдән нәселгә күчеп килә микән?

— Нигә син үзең үскән вакыт белән хәзерге заманны чагыштырасың? Хәзер яхшырак, билгеле. Ә урта гасырлар белән чагыштырсаң, нәтиҗә тагын да әйбәтрәк булыр иде. Феодаллары белән түгел, хәерчеләре белән инде... Россиядә кол биләү строе да узган гасыр ахырында гына бетерелгән. Син, әти, чагыштырсаң, төрле җәмгыятьләрне тиңлә... — дип, әтигә акыл өйрәтә башладым.

— Егерменче гасырда, иң бәхетле илдә ачлы-туклы үскәнсең икән, бик кызганыч...

— Сугыш вакыты, сугыштан соңгы еллар... Маңка! Бернәрсә дә аңламыйсың син... Аңларга да теләмисең... Безнең бөтен куәт дошманны җиңәргә китте. Ач булдык, соңгы сынык икмәкне фронтка җибәрдек.

— Син ач булсаң, кемдер тук яшәгәндер әле. Председатель малае, бригадир кызы. Барысы да синдәй беркатлы булган дип уйлыйсыңмы?

— Корткычлар һәр чорда да табыла...

— Аның каруы алар әйбәт яшәгән... Моның өчен аларны беркем дә хөкем итми.

— Ә намус? Намус хөкеме бар бит әле...

— Намус? Син сөйләгән чулак бригадирның кызы хәзер үз малаена нәкъ шундый ук ләчтит сатадыр әле. Без синең кебек чакта... Авыр заманалар иде... Бөтен кыенлыкларны күрдек, фәлән дә төгән... Һәм дөрес сөйли. Чөнки аңардан да туграк, әйбәтрәк яшәүчеләр булган. Алар белән чагыштырганда бу бригадир кызы начаррак тукланган, начаррак киенгән. Син ул чакта әтиеңнең бригадир яисә склад мөдире булуын теләми идеңме? Ә ул Сталин төрмәсендә... Язмыш, бернишләп тә булмый. Соңгы сынык икмәкне фронтка җибәрдем дип мактана алмыйсың, әти. Җибәрттергәннәр чөнки!

Мин өстәлдә яткан өчлекне кесәгә шудырдым. Әтигә караган идем, чәчләр үрә торды — күзләре зурайган, йөзенә тимгел-тимгел кызыл таплар бәреп чыккан.

— Циник... — Ул кул селтәде дә кухнядан чыгып китте.

Менә бит... Һәр уйлаган нәрсәне сөйләмәскә дип үз-үземә күпме сүз биргәнем бар, юк, тыелып булмый. Әтинең авырткан җиренә кагылдым, ахрысы. Нигә кирәк иде? Горурлансын яшьлеге белән, аннан кемгә зыян? Тик нигә хәерчелек белән һаман да горурланалар, мактаналар соң? Әнә Толстой бай булган, граф, ә кем аны намуссыз, вөҗдансыз дип әйтә ала? Баксаң, янәшәсендә хәерчеләр, йолкышлар җан асраганда аның җитеш яшәве намуссызлык шикелле бит...

— Өчлек? — Фил йөзен җыерды. — Син нәрсә, көләсең мәллә бездән?

— Өйдә артыгын бирмәделәр, — дидем мин. — Үзләренең дә көймәсе комга терәлгән.

— Кайда эшлиләр?

— Әти фәннәр кандидаты.

— Аңлашыла. Интеллигентлар. Ә син акчаны башка җирдән җүнәтү ягын кара.

— Ә кайдан?

— Хы... акчалы кешеләр шәһәр тулы. Нигә алар синең белән бүлешмәскә тиеш әле?
— Кеше таларгамы?
— Талау? Тупас сөйләшәсең, Гайка! — Фил миңа карап озак кына башын чайкап торды. — Үтенергә кирәк. Сораучы белеп сораса, бирүче тәкатен тотмас.
— Бирмәсә, танавына менеп төшәрсең, — диде Боксер.
Йортлар арасыннан Серый килеп чыкты.
— Җыелганнар, — диде ул, еш-еш сулап. Күрәсең, ул шактый араны йөгереп үткән иде. — Әйдәгез тизрәк.
— Дав-вай, — дип сөрән салды Фил. Тимер таяклар тоткан егермеләп малай аның артыннан кузгалды. — Гайкага арматура бирегез! — Кайсыдыр миңа да тимер таяк китереп тоттырды.
Минем дә чәч кыска итеп алдырылган, кием дә аларныкы кебек, бу малайлардан мин берни белән дә аерылмыйм. Кызык икән ул шулай бергәләп, бер көч булып урамнан баруы. Очраган бер кеше шүрләп читкә чыга, юл биреп кала. Карашларында курку, иреннәре дерелди — берәр дога пышылдыйлар микән... Кешеләр күңеленә шом салып баруы рәхәт. Көтүдә куян да үзен арыслан дип хис итәдер. Көтү булып йөрү нәкъ минем ишеләр эше инде ул. Арысланнар көтү белән йөрми, ди әти. Гуманитарий бит, ялгыша. Арысланнар да көтү булып яши.
Караңгы тыкрыкка борылдык. Яңа төзелеп ята торган йорт янына егермеләп малай җыелган иде. Тез буыннары калтырый башлады. Күкрәк читлегендә ниндидер суык нәрсә пәйда булды — бер йомарлам кар тыгып куйганнармыни.
Барыбыз да алар өстенә ябырылдык. Алар безгә таба йөгерде.
— А-а-а...
— А-а-а...
Кычкыру, сызгыру, чинаш. Арматураларның һавада ышылдаган тавышы: ы-шш, ы-шш. Мин башта арттагы рәттә идем, әмма бераздан рәтләр тәмам буталды. Карасам, тимер таягы белән кизәнә-кизәнә миңа бер малай һөҗүм итә. Ул килә, мин кулымдагы таякны селеккәләп артка чигенәм. Аякны көчкә күтәрәм, авыз эче яна, эчтә калтырау. Таякны ташлап качар гына идем, куркудан хәл киткән. Тегенең арматурасы инде борын төбендә ышылдый башлады: ы-шш, ы-шш... Үтерә бит бу, үтерә... Менә нинди була икән ул үлем...
— А-а...
Миңа һөҗүм иткән малай киселгән агач кебек җиргә ауды. Каршыда Серыйның чырае чагылып китте.
— Салют! — диде ул. — Җебемә.
Безнекеләр инде тегеләрне кыса башладылар. Шул чак-

та мәйдан яктырып киткән сыман булды. Фаралардан төшкән яктылык күзне чагылдырды.

— Фараоннар!

— Менты...

Һәр ике як та теләсә кая сибелде. Кайдан көч кергәндер, мин дә бер малай артыннан сыпырдым. Җитез икән, эт, шәп җилдерә. Караңгы тыкрыкларны үтеп ниндидер кечкенә генә агачлыкка килеп кердек. Теге малай аһылдап куак төбенә ауды, мин аның янына. Тын беткән, көчкә сулыш алабыз. Теге бераздан телгә килде.

— Син кем?

— Гайнан.

Ул миңа сагаюлы карап читкәрәк шуды.

— Син безнеке түгел бит?..

Мин безнекеләрне танып бетерми идем әле. Шуңа:

— Белмим, — дидем.

Бу кулын селтәде.

— Әй, хәзер барыбер инде. Тегендә кул астына эләксәң, изеп ташлый идем үзеңне.

— Кем кемне изәр иде әле, — дидем мин, телләнеп.

— Нәрсә? Әйдә сугышабыз.

Минем бер дә сугышасым килми иде.

— Хәл юк...

Күрәсең, ул да сугышырга атлыгып тормый иде, канәгать төстә сөйләнеп куйды:

— Шулай дип котылсаң гына инде. Югыйсә...

— Исемең ничек?

— Ваня. Бүре мин... — Ул башын күтәреп миңа карады. Тәэсир итте микән, янәсе. — Ишеткәнең бармы?

— Юк.

— Э-э, син нәрсә, күктән төштең мәллә? Әллә әниең куеныннан яңа гына чыктыңмы?

— Шулайрак...

— Тартасыңмы?

— Давай.

Көйрәтеп җибәрдек.

— Ментлар килеп эшне бозды. Юкса без сезне изеп ташлый идек, — диде ул тагын.

Мин бәхәсләшеп тормадым. Кем кемне изсә дә барыбер түгелмени? Үзеңнең исән-сау котылуыңа сөенергә кирәк монда. Менә калтырауны гына һич басып булмый, каһәр. Бүре сүзен дәвам итте:

— Кемдер хәбәр итеп өлгергән. Арада стукачлар бар...

Мин эндәшмәдем.

— Кара әле, нигә калтырыйсың? Әллә беренче тапкырмы?

— Әйе.

Бүре рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Беренче тапкыр һәркем шулай шыр җибәрә. — Ул торып басты. — Ярар, кайтырга кирәк. Мә бишне...

Ул минем кулны җибәрмичә торды.

— Бер сыларга иде үзеңә. Ярар инде, башка вакытка калсын. Әле минем йодрыкларның түмен байтак татырсың.

— Төшеп калганнардан түгел, — дип мыгырдандым мин.

— Ну, ну... — Бүре тагын шаркылдап көлде. — Кайтып йөз илле грамм төшер син, калтыравың бетәр. Шок булган сиңа. Шутка ли... — Һәм ул караңгылыкка кереп югалды.

Мин дә машиналар гөрелтесе ишетелгән якка юл алдым.

## II. Килдебеков

Була бит шундый минутлар — җаның тәнгә сыймый, гомереңне каймалап торган шушы дүрт стенаны калдырып каядыр чыгып китәсе килә. Бигрәк тә көннәр җәйгә авышкач шундый халәт еш була. Хәер, калада җәй җәй кебек, кыш кыш кебек түгел, төссез, җенессез көннәр бер-берсенә ияреп ага да ага. Гүя һәммәсенә униформа кидергәннәр.

Бөркү, авызкаена төкерим. Җиләткеч тә һич ярдәм итми. Бу бөркүлек, күрәсең, һавадан гына түгел, ә җанның үз кысалары эчендә бәргәләнеп гасабилануыннандыр да, мөгаен. Ул галстугын бушатты, кесәсеннән волидол алып тел астына ыргытты. Менә шулай, иптәш Килдебеков, бу нәмәрсәкәй синең хәзер аерылмас юлдашыңа әверелде дип уйлады ул моңсу гына. Күкрәкнең сул ягына нидер авыр тәпиен салган да, сулыш алуны авырлаштырып тора кебек.

Ул күзлеген күтәреп сәгатенә карады. Өченче киткән икән ич... Кызыл телефон һаман җансыз... Чылтыраткан булганнар, ул урынында булмады. Менә хәзер күтәргә кала. Көтүдән һәм куып җитүдән дә авыр нәрсә юк, дигән ди бер акыл иясе. Бигрәк тә көтү изә кешене. Һәр түрә яхшы белә моны. Шуңа тиз генә эләгә алмыйсың да аның кабинетына. Кабул ителүне озак көткән кеше рухи яктан шактый ук йомшый, башында әзерләп куелган уй-фикерләр дә чуала башлый. Секретарь ярты сәгатьтәнме, бер сәгатьтәнме эре генә дәү ишеккә ымлагач, ул каударланып шул ишеккә ташлана, үзенә кыюлык өстәргә теләгәндәй, кискен хәрәкәтләр белән авыр, саллы тоткага тотына. Ләкин алай гына түрә янына эләгә алмыйсың әле. Ике ишек арасында калып, караңгыда икенче ишекнең тоткасын эзләп җәфаланасың бар. Ниһаять — и Ходаның хикмәте! — монысы да оҗмах ишекләре кебек ачылып китә, тик бу вакытта инде бәндәбезнең иреннәре комга әверелгән, маңгайдан аккан тир күзен әчет-

терә, мие Чупрәле нефте кебек чайпала, ситуацияне аңлар өчен әле аңа берничә минут вакыт кирәк, әмма шулай да миенең кайсыдыр почмагында исән калган кузәнәк исәнләшергә кирәген искә төшереп сигнал биреп тора. Һәм нәрсәдер сорарга, үтенергә килгән кешебез «Здравствуйте» не әйтәсе урынга «Спасибо» сүзен пышылдап, бусагада басып кала. Ә анда — түрдә — гүя коммунизм офыкларында, керүчегә игътибар да итмичә, галиҗәнап түрә нидер язып утыра...

Килдебеков авыз эченнән генә көлеп куйды. Шушы мизгел өчен генә дә түрәлеккә омтылырга, өстәгеләрнең сүгүенә, сүгенүенә түзәргә мөмкиндер.

Шул чакта түр почмактан кетер-кетер тавыш килә башлады. Әллә кайчангы таныш тавыш. Нидер бик еракта калган, инде онытылып бетә язган нидер искә төшәргә азапланды. Кетер-кетер-кетер. Тычкан ич бу... Кайдан кергән ул монда? Килдебеков идәнгә каты итеп тибеп алды. Тычкан бер мизгелгә туктап тынып алды да, берни дә булмагандай, кетердәвен дәвам итте. Курыкмый да, хәшәрәт. Килдебеков янә идәнгә типте. Янәсе, кем хуҗа бу кабинетка — синме, минме?

Ул өстәл яныннан торып, ишекле-түрле йөренә башлады. Тычканны аяк тавышлары сагайтты, ахрысы, яраткан эшеннән туктады; зур, иркен кабинетта Килдебековның аяк тавышы гына аерымачык ишетелеп торды; тик-так, тик-так...

Әйе, көттерә белгән кеше көтә дә белергә тиеш. Әллә аның кабул итүен көтеп аз тилмерделәрме? Ишек төбендә буыннары сыегайган кешеләрне күреп азмы ләззәтләнде ул? Хәер... Килдебеков чыраен сытып куйды. Бер тапкырында ул теләгәнчә килеп чыкмады шул. Һаман да искә төшеп җенне чыгара бу вакыйга. Биш-алты ел элек бер язучыны чакырткан иде. Ни өчен икәне онытылган, хәер, акыл бирергә, ничек язарга икәнен өйрәтергәдер инде. Аларга һәрвакыт юл күрсәтеп торырга, үзләрен җитәкләп барырга кирәк бит, югыйсә әллә ниләр майтарып куюлары бар. Ә бу язучы белән ул бергә укыды, бер ел хәтта бер бүлмәдә яшәделәр, шуңа күрәме Килдебеков аның өчен үзен аерата җаваплы сизә иде. Дөрес, алар укыганда ук бер-берсен өнәмәделәр. Башкортстаннан булгангамы, йомык, кеше белән аралашырга яратмый иде ул егет. Бәлки, Килдебеков белән генә үзен шулай тоткандыр, бервакыт кемнәргәдер кулын селтәп бик хәтәр нидер аңлатып торганын да күрде ул бу йомыкыйның. Килдебеков, гомумән, язган-сызган кешедән читтәрәк булырга тырышты, яратмады ул аларны. Мөгаен, моңа мәктәптә чагында үзенең дә шигырь-мигырь язып йөрүе сәбәп булгандыр. Кайчандыр үзе язып караган, әмма пычагым да кыралмаган кеше язучыларны куралмый торган була. Ма-

лай чакта Килдебеков та язган нәрсәләрен күтәреп — ул, әлбәттә, урысча яза иде — район газетасына барды. Редакцияне табып кыю гына эчкә узды. Машинкада басып утыручы тулы гәүдәле бер мөлаем апаны күргәч, малай һич икеләнүсез-нисез аңа таба атлады. Машинкасы да булгач, димәк, ул монда иң зур кеше дип уйлады ул. Ләкин бу хатын аның ни йомыш белән килүен белүгә, башка бүлмәгә кертеп җибәрде. Озын чәчле, күзлекле бер йолкыш бәндә Килдебековның беренче әсәрен укуга ук шаркылдап көлеп җибәрде. «Тебе, татарчонок, еще по-русски надо научится», — диде ул. Малай гарьлегеннән елый-елый авылына кайтып китте, кайтышлый шигырьләр тулы дәфтәрен ерткалап елгага ыргытты. Иҗат юлы шулай тәмамланды Килдебековның. Хәзер теге озын чәчле йолкышка рәхмәт әйтәсе килә. Язуын дәвам итсә, бу дәрәҗәгә ирешкән булыр идеме ул? Шиш! Ни галәмәттер, урындагылар язган-сызган кешедән читтәрәк булырга тырышалар. Һәрхәлдә, аларга ышанып бетмиләр.

Нургалинең (чакырган язучының исеме шулай иде) тагын бер сәер гадәте Килдебековны чыгырдан чыгара иде. Теге тумбочкасын һәрвакыт йозак белән бикли иде. Анда ул азык-төлек саклыймы, әллә язганнарынмы, Килдебеков монысын белә алмады. Ризык-фәлән булмагандыр, андый карунга охшамаган иде Нургали. Хәер, белмәссең, хәерче гаиләдән чыккан кеше һәр тиеннең дә кадерен яхшы белә. Инде ул баеп кулында зур акчалар йөртә башлагач та, автоматтан шылтыратырга ике тиенен кызганып тора. Андый кеше зур әйберләргә, гадәттә, вакланып тормый, бүләген дә ала, сыйлый да, ә инде эш тиеннәргә килеп терәлгәч... Юк инде, агайне, гафу итегез, бер тиене дә аның өчен дөнья бәһасе, тәмәкенең дә ул арзанрагын сатып ала (тартса!), ун-ун биш тиен булса да экономияләнсен, янәсе.

Шулай да ризык-фәләнне бикләп тотуына ышанасы килми. Алар болай да аерым ашыйлар иде бит. Тәгаен, язган нәрсәләрен олы байлыкка санап бикләп торгандыр әле. Шунысы да бар, ул чакта студентлар арасында: «Фәләнев «тегеннән» икән, сүзеңне үлчәбрәк сөйлә», — дигән үзара шикләнешүләр киткән иде, Нургалигә шул да тәэсир иткәндер.

Килдебековка тынгы бирмәде ул тумбочка.

Бервакыт, университетны бетереп биш ел узгач, курсташларның очрашуы вакытында тәмәке тартырга чыккач — бераз башка да киткән булгандыр инде — Килдебеков төрттергән иде: «Язучыларны «душа на распашку» диләр дә, ә безнең Нургали хәтта тумбочкасын да бикләп тора иде». Ә ул писака нәрсә диде шунда? «Димәк, янәшәдә шикле кешеләр булган». Сволочь... Тәмәкечеләр мыек астыннан елмаешып таралыштылар, кайсысы табынга узды, кайсысы,

һичнинди хаҗәт булмаса да, чалбар төймәсенә кагылган булып бәдрәфкә олакты. Килдебековның йөзенә тоташ кызыл тимгелләр җәелгән иде. Ул тимгелләр тагын ике сәгать буена табынны яктыртып тордылар әле.

Нургалине өнәмәүнең тагын бер сәбәбе дә бар. Ләкин анысын һич тә исенә төшерәсе килми Килдебековның.

Теге вакытта ни өчен чакырды соң әле ул аны? Әйе, әйе, «Социалистик Татарстан» газетына ниндидер крамольный мәкалә язган иде бугай. Белмим, аны ничек чыгарган булганнардыр, югыйсә анда бик ышанычлы, туң малайлар утыра... Менә шул туң булулары аркасында үтеп киткәндер дә инде, мәгънә тирәнгәрәк яшерелгән иде шул. Ләкин аңы бар кеше аңлый. Авторга «милләтче» ярлыгы ук тагып булмый, фикерен матур сүзләргә яшереп биргән, шулай да каты итеп искәртеп куюның зарары тимәс.

Секретарь кыз язучының килүен хәбәр итте. «Бераздан кабул итәрмен», — диде Килдебеков. Тез буыннары дерелди башлаганчы, иреннәре кипшенгәнче көтсен әле бераз. Аннары инде без аңа язу серләрен аңлатырбыз.

Бер сәгатьтән ул язучыга керергә кушты. Секретарь кыз каушады, тавышы калтырады: «Аның киткәненә ярты сәгать була инде», — диде ул. «Ничек?» — дип чәчрәп торды Килдебеков. — Как он мог?! Немедленно өенә машина җибәрегез. Сию минуту килеп җитсен!»

Машина җибәрделәр җибәрүен, тик язучы кабат килмәде. «Чакырылган сәгатьтә аның вакыты булмады, хәзер инде минем вакытым юк», — дигән, имеш. Йә, нишләргә шул үҗәт белән? Бу бит теге заманда! Хәзер инде аларның кыланышын сөйләп тә торасы түгел.

Килдебеков йөрүдән туктады.

Кетер-кетер-кетер.

Нинди тычкан бу? Ничек бирегә эләккән? Секретарь кызга әйтергә кирәк, юкка чыгарсыннар. Ул тагын ишеклетүрле йөренә башлады: тик-так, тик-так. Һаман чылтыратмыйлар. Нигә генә урынында булмады соң... Тирләгән маңгаен ап-ак кулъяулыгы белән сөртеп алды.

Тик-так, тик-так...

Акылдан язарсың, че-ерт... Ул тәрәзә пәрдәсен күтәреп урамга карады. Сорылык, хәтта агач яфракларын да соры калын тузан сарган, бар җир соры-соры, йокыдан торуга шундый дөнья умырылып күзгә тула төсле. Күрәсең, бу аңа нур иңеп өлгермәгәннән булса кирәк...

Ленин бабайның тузан каплаган пеләшенә күгәрченнәр кунган. Нигә һәйкәлләрне якын итә алар?.. Җаваплы кешесенә төнлә тагын сүгенә-сүгенә чистартасы була. Хәер, нигә сүгенә-сүгенә? Шундый изге зат янында сүгенергә ярый-

мы соң? Ләкин бит ул аңа түгел, күгәрченнәргә сүгенә... Мигә бер оялаган уйны һич кенә дә куып җибәреп булмый. Нигә сүгенергә тиеш әле ул? Бәлки, бу таныш түгел кеше интеллигенттыр, үз эшенең тәмен, ләззәтен, җәмгыятькә нинди файда китерәсен беләдер... Фу-у, че-ерт...

Нигә чылтыраттылар икән? Нигә генә урынында булмады? Ул гасабиланып йодрыгын кысты. Иртән үк кәефе юк иде шул, күңеле сизенгән икән. Шуңа йөгерергә чыгасы да итмәде. Йокы бүлмәсендә генә гимнастика ясап алды да ашханәгә чыкты. Өстәлдәге бәллүр савытларга җиләк-җимеш, яшелчә өелгән. Иртән Килдебеков шуларны гына ашый. Һәр иртә Мәгъфүрә апа аңа шулай әзерләп куя, кофе кайната. Үзе күренми, чөнки белә: хуҗа иртәнге сәгатьләрдә ялгызлыкны ярата, аңа уйланырга, барысын да үлчәргә, бәһаләргә кирәк — аны зур эшләр көтә.

Идәндә кинәт чыштырдаган чүәк тавышына борылса — хатыны. Иртәнге трапезаны бозмаска дип күпме әйтелгән югыйсә... Килдебеков каш астыннан гына хатынына карап алды. Җитмәсә, эчке күлмәктән бит әле, чәчен дә тарамаган бугай. Иренең дәһшәтле карашларына игътибар да итмичә, ул лап итеп кәнәфигә килеп утырды. «Спорт белән шөгыльләнсә дә мишәйт итмәс иде», — дип уйлап куйды Килдебеков. Күз алдында җәелә бара, адәм тәганәсе. Күр, шушы түшкә белән ничек кеше алдына чыгасың, затлы мәҗлесләрдә пәйда буласың инде? Рейганның һәрбер җиргә — визитмы анда, кунак каршылаумы — хатыны белән йөрүе һич гаҗәп түгел. Этикет диярләр кайберәүләр. Этикет үзгәреп тора ул, апаем. Президентлар үзгәртә аны. Нэнси кортка кызлар кебек сылу — менә хикмәт кайда...

— Фәнил бүген кунарга гүпчим кайтмады, — диде хатыны.

Килдебеков акрын гына мандарин әрчүен дәвам итте.

— Бөтенләй бәйдән ычкынды ул малай...

— Тилцә эшең бармы? — Килдебеков кинәт кенә шулай авыл шивәсен хәтерләвенә эчтән сөенеп куйды. — Син тәрбияләргә тиеш идең балаларны! Ә нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты? Кызың — сөйрәлчек, улың — бандит!

Хатынының күзләре зурайды, йөзе бүзәрде. Авызын ачты, ләкин тавышы чыкмады — ул каядыр эчкә кереп югалган иде. Ниһаять телгә килде:

— Үз балаларың турында ничек алай әйтә аласың? Мин генә тәрбияләргә тиеш идемме аларны? Ә син кайда? Уртак ич алар безнең, уртак... — Хатыны да шул ук шивәгә мөрәҗәгать итте: «Бук бит син, Ирхан! Үз балаларың турында...»

— Йә, житәр! — дип бүлде аны Килдебеков. — Селәгәй агызып утырма монда. Син боздың балаларны. Бер сүз әйтеп булмый иде, очынып каршы төшә идең. Синең балалар гына батыр, синекеләр генә матур. Ә хәзер мине гаепләргә маташасың. Алар белән утырырга вакытым булдымы соң? Ә син көне буе өйдә, аларны тәрбияләү төп эшең иде. Менә хәзер җимешләрен таты инде.

— Нишләп мин генә...

— Молчать! Иртәнге сәгатьләрдә борчымаска дип күпме әйттем сезгә... Юк, нәкъ менә шул вакытта керергә кирәк. Беләсеңме минем хәзер нинди вакыт? Күткә кыл сыймый. Син нәрсә, телевизор да карамыйсың, газета да укымыйсың мәллә? Конечно, сезгә «Волга»га утырып каядыр барырга, чәч төзәттерергә, тырнак буятырга гына булсын. Машинага бүтән кагылмаска! Җәяү йөрегез, сәламәтлек өчен файдалы. — Килдебеков хатынының гәүдәсенә тагын күз төшереп алды. — Аеруча сиңа...

Хатыны җүнле вакытка туры килмәгәнен аңлады, лыштыр-лаштыр бүлмәдән чыгып китте.

«Ни хатыннан, ни балалардан уңмадым», — дип уйлады Килдебеков. Кайдадыр хата киткән... Ләкин кайда? Хәер, балалары белән аралашырга да (нинди тәрбияләү?!) вакыты булмады ич аның. Алай дисәң, Минаевның вакыты булганмы? Малае университетның фәнни коммунизм бүлегендә укый, комсомолның факультет комитеты секретаре. Яшьләр лидеры! Ә соң болар? Лилиясе медицина институтында укыган булып йөри бугай. Килдебеков кызы дип кенә кумыйлар инде аны. Вакытын ничек үткәрә ул? Янәшәсендә һәрвакыт озын торыклы егетләр... Берчакны кызының бүлмәсенә керергә туры килгән иде, чәчләре үрә торды: стенада шәрә кызлар, ялангач егетләр рәсеме, урын-җир җыймаган, нәни сумкасы идәндә аунап ята, аннан Килдебеков әле дә исемнәрен белми торган хатын-кыз нәмәрсәкәйләре коелган. Ләкин презервативны таныды... Ул катып калган консерватор түгел, ләкин мондый рәвешле тормыш итүне дә аңлый алмый, үтерсәң дә аңлый алмый. Кем кызы — Килдебеков кызы, шәһәрдә чыш-пыш сүзләр йөрми дисеңме? Халыкның авызын сөлге белән томалап булмый, әле гайбәтне юри таратучылар да бихисап... Белә Килдебеков, дошманнары күп икәнен белә, ауганын гына көтеп торалар, ул гына да түгел, аударырга тырышалар. Хәзер заманы да шундый — торгынлык чоры вәкиле, үзгәртеп коруга комачау итә дип теләсә кемгә бәйләнеп була. Шуңа өстәп, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, Килдебековның кызы секс-бомба дигән сүз дә таралса? Кичекмәстән бу мәсьәлә белән шөгыльләнергә кирәк. Кияү табарга да олактырырга үзен. Ул чакта инде аңа ире җаваплы... Хәер...

Малае да рәтле-җүнле түгел, ичмаса. Ни укып кинәндермәде, ни тәртибе яхшы булмады. Әле күптән түгел ниндидер урам малайлары төркеменә кергән дип хәбәр иткәннәр иде. Анысын нишләтергә? Колониягә озатыргамы? Рәхәтләнеп озатыр иде, ләкин аннан яхшырып, кешегә әверелеп чыкмаганнары билгеле ич... Үзе белән сөйләшергә кирәк, бәлки, аңлар, бөтенләй үк аңгыра малай түгелдер...

Килдебеков сәгатенә карап алды. Кузгалырга вакыт. Ашыкмый гына киенә башлады. Яңа күлмәк тәнне рәхәт итеп кытыклап алды, Килдебеков бервакытта да — бервакытта да дип, зур кеше, зур түрә булгач инде — күлмәген ике көн рәттән кимәде. Гитлер, ахрысы, дәүләт башлыгы булгач, көн дә яңа күлмәк кияр идем, дип, үз-үзенә сүз биргән һәм шул сүзне үтәгән, имеш. Килдебеков андый ук дәрәҗәгә житә алмады, ләкин принцип шул: һәр көнне аңа юылган, үтүкләнгән күлмәк әзер булырга тиеш. Мәгъфүрә апа бу мәсьәләдә пөхтә, күз тимәсен.

Бу урынга менгәч, Килдебеков аны туган авылына кайтып махсус алып килгән иде. Ул аңа чыбык очы туган да тия бугай, һәрхәлдә, Килдебеков хезмәтче тота дип беркем дә авыз чайкый алмый. Киресенчә, ярдәмсез калган карчыкны канат астына алды, һәм Мәгъфүрә апа үзе дә үз тормышыннан бик тә канәгать шикелле. Канәгать булмый дип уйлады Килдебеков һәм көлемсерәп куйды, андый сый-нигъмәтләрне кортканың гомерендә күргәне юк һәм күрәсе дә түгел иде. Шундый затлылыкка лаек иткәнгә Ходай Тәгаләгә мең рәхмәтләр укып ятасы гына инде.

Ишек төбендә аны машинасы көтеп тора иде. Озын буйлы, табак битле шоферы Айдар тавышсыз гына исәнләшеп ишекне ачты. Ләкин Килдебековның нигәдер шушы мәлдә машинага утырасы килмәде, ул әле тынычланып житмәгән иде, андый чакта җәяү йөрү файдалы, өстәвенә эш урыны артык ерак та түгел. Егерме-егерме биш минут соңрак килер, билгеле, әмма, кем әйтмешли, түрә кеше беркайчан да соңармый ул, тоткарлана гына.

Чыннан да, юлда шактый тынычланды ул. Уйларын эшлекле агымга кучерергә тырышты. Бүген шәһәр яшьләре белән очрашырга тиеш иде Килдебеков, күңелдән генә сөйлисе фикерләрен кабатлап чыкты. Шулай да нигәдер җан тыныч түгел иде.

Секретарь кыз Гуля (кызык: әти-әнисе кушкан исеме ничек әле аның — Гөлсемме, Гөлнарамы, әллә Галияме?) аны көндәгечә елмаеп каршы алды.

— Исәнмесез, Ирхан Алиевич? Хәерле иртә...

Килдебеков: «Исәнмесез», — дип коры гына исәнләшеп дәү ишеккә таба атлады.

Әмма Гуляның сүзе бетмәгән икән әле:

— Мәскәүдән чылтыраттылар, Ирхан Алиевич. Үзеннән...

Килдебеков йөрәк түрендә ниндидер кайнар дулкын яралып яшен тизлегендә тез буыннарына йөгерүен тойды.

— Нәрсә диделәр? — Аның тавышы карлыгып чыкты.

— Сезне сорадылар... Килеп җитмәде әле, дидем. Ярар, алайса, соңрак чылтыратырбыз, дип әйттеләр...

Секретарь кызның сынаулы карашы белән очрашмаска тырышып, Килдебеков кабинетына ашыкты. Нигә чылтыратканнар? Шушы сорау һәрдаим аның миен бораулап торды. Алай тиз генә җебеп төшә торганнардан түгел Килдебеков, дөньяның ачысын-төчесен күп күргән, Мәскәү белән дә үз булып, тиң булып, шул ук вакытта үзенең биниһая бәйле икәнен дә сиздереп, сөйләшкәне еш иде. Ләкин соңгы арада үзәктән озак вакыт чылтыратмадылар, җитмәсә, башка өлкәләрдән хәвефле хәбәрләр дә ишетелгәләп торды... Һәм менә кызыл телефонның капыл гына чылтыравы йөрәккә шом салды шул. Конференция алдыннан бит... Ничек бүген җәяү килергә уйлады соң ул? Машинага утырган булса, югыйсә вакытында килеп җитәр иде, Мәскәү белән дә сөйләшер иде...

Зур кабинетта аяк тавышлары аерымачык яңгырап торды: тик-так, тик-так... Үзенең кетердәве белән шушы илаһи тынлыкны бозарга җөрьәт иткән тычкан баласы да шушы кискен аяк тавышыннан өркеп өн-тын чыгармады. Әмма Килдебековның хәтере әйбәт, бу турыда тиешле кешесенә искәртер һәм иртәгә үк һич кичектермичә Килдебеков кабинетында мөстәкыйль тавыш биргән шушы тычканны мәһабәт йорттан чыгарып атарлар. Еракkарак, ераккарак...

Өскә менгән саен егылуы куркынычрак; Килдебеков бөтен кыюлыгын җигеп (кыя түбәсендә торам дип күз алдына китерегез әле!) аска карап ала һәм башы әйләнүдән чайкалып китә. Тотынырга бер терәк тә юк ич янәшәдә! Күзләрен ящереп тирәндә юмакайланып йөргән бәндәләр — шәүләләр генә ич бары...

Ул кәнәфиенә килеп утырды, өстәлдәге газеталарны актара башлады. Күзенә «Социалистик Татарстан» чалынып китте, Килдебеков татарча азмы-күпме укый белә — хезмәттәшләре шуны да булдыра алмый әле! — шуңа чак кына горурлана да иде. Гадәттә ул беренче битне генә караштыра, чөнки анда әчке кинәнү белән еш кына үз фамилиясенә тап була. Кем генә үз исемен яратмый икән?! Бу дөньяның кодрәтле кешеләренә дә хас шул мәхәббәт. Әлбәттә, ярдәмчеләре «кызыклы материал» дип билгеләп керткән нәрсәләрне дә укып чыга Килдебеков, тик аларның кызыгын гына күрми. Һаман да шул бер сафсата!

Менә тагын карашы үз фамилиясенә туктады. «Жые-

лышта И.А. Килдебәков та катнашты». Кил-де-бәк-ов! Тагын үзгәртеп язганнар, мәләвеннәр. Татарча шулай була, имеш. Ә бит редакторга күрсәтмә бирелгән иде: үзгәртмәскә! Юк, сүзенең шулай һавада эленеп калуына илтифат итми булмый. Ул телефон трубкасын алып ашыкмый гына баш редакторның номерын җыйды. Озын-озак гудоктан соң «әйе» дигән мөлаем гына хатын-кыз тавышы ишетелде. Һы, дип уйлады Килдебеков, анда да секретарь бар икән. Менә кайда һич җәлләмичә кадрларны кыскартырга кирәк! Унсигез миллионлы бюрократлар армиясе дип үзләре лаф ора югыйсә. Журналистлар шуңа кермиме? Нәрсә җитештерә соң алар? Халык башын әйләндерү белән шөгыльләнәләр... Бер очрашуда: «Сездә кадрларны азайтачакларымы?» — дип сорыйлар, шул соруны бирергә җөрьәт итәләр бит әле!

— Редактор кирәк, сеңлем, — диде ул, тавышын йомшарта төшеп...

— Ә кем соң әле бу?

— Килдебеков...

Телефоннан урындык шудырган тавыш, ниндидер каударлану ишетелеп калды. Килдебеков ирен читләре белән генә елмаеп куйды. Трубкада баш редакторның каушаган авазы кыштырдады:

— Әйе, Ирхан Алиевич...

— Хәерле көн, Рәис Сафич, исәнмесез...

— Исәнмесез... — Редактор аның нигә чылтыратуын төшенергә тырыша, әмма Килдебеков та культуралы кеше, үгезне мөгезеннән алмый, бер очтан тегенең бу чылтыратуны нәрсәгә дә юрый алмыйча газаплануыннан рәхәт таба иде.

— Саулык-сәламәтлекләр ничек, йөрәк борчымыймы? — Ул юан редакторның лычма юеш кульяулыгы белән маңгаеннан, муеныннан аккан тирне сөртүен күз алдына китерде.

— Әлегә ярыйсы, зарланырлык түгел...

— Менә сезнең газетаны карап утыра идем, — Килдебеков тавышын күтәрә төште: — Мин бит сиңа әйттем, фамилияне үзгәртеп язма, дидем! Газета чыккан саен кабатлап торыйммы, черт побери?! Минем җиде бабамнан бирле килә ул фамилия, понимаете-ли...

Теге очта редакторның акланганы ишетелде:

— Үзем командировкада идем, ә урынбасар яшь әле, яңа гына килде, редакциянең кухнясын белеп бетерми...

Килдебеков аны тыңлап бетермәде:

— Ладно, башка бу мәсьәлә белән сиңа чылтыратырмын дип уйламыйм...

Хәзер пип-пип дип кыска гудоклар биреп торган телефон трубкасын тотып ни уйлый икән редактор? Килдебеков тыйнак кына киерелеп алды. Ни өчен «сиңа чылтыра-

тырмын дип уйламыйм»? Димәк, озакламый бу номер белән башка кешегә чылтыратырга туры киләчәк? Сөйләшү бераз катырак, тупасрак та булды бугай. Әй, бу кавемгә ярый, болар урыннары өчен калтырап тора. Менә язучылары белән эш кыенрак. Хәер, алары да тәртәгә бик тиз керә иде. Китабың чыкмый башласа, балаларың ач килеш кысан фатирда елап утырса, хатының «хәерче!» дип илереп табагач белән каршыңа килсә, тиз тынычланырсың, нибуч! Чын язучылар, фанатиклар берән-сәрән генә алар арасында... Шуларын гына яшерен хөрмәт итеп була да...

Килдебековның кәефе бераз күтәрелде. Җыелган ачуны кемгә дә булса түгәргә кирәк иде. Югыйсә организмда калып кан тамырларына тоз булып утыра, йөрәкне или башлый ул. Кайгы-хәсрәтен, ачу-рәнҗүләрен эченә җыйган кеше озак яши алмый, шул авырлык аны җиргә таба тарта һәм ул бөтен җыелган хис-тойгыларын туфракка тапшырыр өчен фани дөньядан китеп бара. Ә син, акыллы булсаң, ул кайгы-хәсрәтләрне, ачу-рәнҗүләрне кешеләргә бүлеп бир, бергә күтәрү җиңелрәк, күп тапкырлар җиңелрәк ич.

Кызыл телефон һаман тып-тын тора. Билгеле, Килдебеков үзе дә үзәк белән элемтәгә керә ала. Әмма чылтыратсын димәгәннәр бит, чылтыратырбыз, дигәннәр. Аннары нинди сөйләшү әле, бәлки, бик яман хәбәрдер? Табигый ич анысы да, һәм яман хәбәрләр шактый еш ишетелеп тора.

Яшьләр белән очрашу башланырга биш минут кына калган иде, Килдебеков конференц-залга юнәлде. Залның янәшә бүлмәсендә хезмәттәшләре инде җыелган, аны көтеп торалар. Монда һәр церемониянең үз ритуалы бар: залга кем артыннан кем керәсе, кем кайсы урынга утырасы — барысы да алдан уйланылган. Ләкин һәрвакыт нидер килеп чыга — бу юлы да бер урындыкны ким куйганнар: культура министры артык күзгә ташланмаска тырышкандай бөкрәеп ишектән чыкты да урындык алырга йөгерде.

Залда сыек кына кул чабулар ишетелде. Менә бит заманалар, ә? Берничә ел элек кенә шушы маңка малайлар, сытык кызлар белән очрашып йөрермен дип кем уйлаган? Ярый, бу юлы биредә күбрәк комсомол работниклары бугай — җыйнак костюм-чалбарлы, галстук таккан «милый» малайлар шактый күренә. Алар артык сикеренмәс. Үсәселәре бар. Килдебеков үзендә шуларның сокланулы-көнләшүле карашын тойгандай булды. Һәрберсе хыялда үзен аның урынында күрә, чагыштырып карый һәм, әлбәттә, канәгать бер хис тә кичерә — ничава, бер дә артык җире юк моның да, һәр кеше кебек ике куллы, ике аяклы, сөйләве дә ташка үлчим. Димәк, властька менүнең нинди дер бер үз сере, үз хәйләсе бар? Әллә бу да очраклылык нәтиҗәсеме, фәрештә-

нең «амин» дигән чагына туры килүме? Бу малайлар шул турыда уйлыйлар, шул сораулар аларның төшләренә керә. Килдебеков аңлый аларны, хи, үзе шул яшьлек дәверен үтмәдемени ул, шул уйлар-сораулар белән хыялланмады, саташмадымыни?!

Тик Килдебеков нык тора әле. Кайчакта чайкалса да, баскан җире текә, бәдәне таза әле аның. Шулай да ул юләр түгел, иртәме-соңмы, китәсен белә, киләчәктә бирегә әнә шушы залдагы күзләрен елтыратып утырган малайларның берәрсе менәчәк. Кызганычка күрә, берни дә мәңгелек түгел. Ә, бәлки, бу сөенеч кенәдер? Билләһи, шулай... Әйтик, кешеләр үлемсез дип уйлыйк... Ул чакта, димәк, пенсиягә чыгу да, үлем дә, чурт та юк. Алган урынны тик биләп торасың... Ә яшьләр? Алар бит синең тизрәк китүеңне көтә, урыныңны алырга тели... Нәкъ мәкальдәгечә: бирәү үлмичә, бирәү көн күрми... Һәм бу табигый да... Вакытында китә бел инде син, агайне, яшьләр өлешенә кереп, тере мәет булганчы күз көеге булып йөрмә... Бу мәңгелек хакыйкатьне һәр түрә аңлый, тик китәсе килми шул... Властьтан үз теләге белән киткән кемне белә тарих? Хәер, бер Рим императоры булган бугай, ул үз теләге белән китеп кәбестә үстерә башлаган, имеш. Монысы да әкият кенәдер әле, халык властьтан үз ихтыяры белән китүчеләрне көтә-көтә арыгач, үз хыялында тудыргандыр ул императорның кәбестә үстерүе турындагы әкиятне.

Залның арттагы рәтләрендә зур плакат күтәрделәр: «Безгә АЭС кирәкми!» Килдебеков борчылып күршесенә иелде: «Экстремистларны кертмәскә кирәк иде...». «Представители всяких «народных фронтов», «общественных центров», — дип пышылдады тегесе һәм кулларын җәйде: — никак!

Ниһаять, Килдебеков урыныннан калыкты. Залдагы шаушу акрын гына сүнде. Бераздан кешеләр өстендә аның тонык, бераз чатнаганрак тавышы йөзә иде инде: «Наше время — очень напряженное, но и интересное время. Настал самый решающий момент перестройки...» Килдебеков ярты минут чамасы пауза ясап торды. Күп тапкырлар сыналган: шулай итсәң, иң баналь фраза да күзгә күренеп балкып китә, аңа саллылык, олпатлылык өстәлә. Зур кеше авызыннан биек трибунадан әйтелгән гап-гади сүзне дә тыңлаучы хәттин ашкан игътибар белән кабул итә. Аның төрле мәгънә төсмерләрен таба, әгәр андый нәрсә булмый икән, үзе мәгънә өсти. «Ләкин бу барып чыкмас!» — диде бит, димәк, дилбегә тартылачак, дип тексттан үзенә кирәкле җөмләне суырып ала, аңа үзе теләгән фикерне сала һәм якын көннәрдә «каты куллы» хөкемдарны көтеп, киләчәкне күрәзәлек итә башлый.

Аннары ешрак пауза ясаган саен чыгыш та озагракка сузыла. Монысы да Килдебеков өчен кыйммәт иде. Озаграк сөйләгәч, сорауларга вакыт азрак кала бит! Сораулардан югалып кала торган кеше түгел ул, ничек тә ерып чыгар, шулай да залның бик җәелеп китмәве яхшы. Килдебеков озак итеп, тәмләп экономика турында сөйләде, саннар сипте. Промышленностьның төрле тармаклары, авыл хуҗалыгы — монда көне буе сөйләсәң дә сүз бетәрлек түгел иде. Ләкин соңга таба халык тынычсызлана башлады. Президиумга бертуктаусыз сораулар язылган записскалар килә, аларга җавап биргән аты ясарга кирәк, Килдебеков маңгай тирен ап-ак кульяулык белән сөртә-сөртә урынына утырды.

Записскалар күп булса да, сорауларның байтагы уртак иде. Андый сорауларны биреләчәген референтлар (алар инде җәмәгатьчелек фикерен яхшы белә — информацияне китереп торалар!) алдан чамалаган, җаваплар да, җавап бирәсе кешеләр дә алдан якынча әзерләнгән иде. Сорау: «Татар мәктәпләре кирәклеге турында күп сөйләнелә. Яслеләрдә, балалар бакчаларында татар группаларын ачу да зарури. Бу юнәлештә нинди эш алып барыла?»

Килдебеков йөзенә җитдилек чыгарды:

— Гаять кирәкле мәсьәлә, иптәшләр... Иптәш Горбачев та, бер генә аз санлы халык та юкка чыкмаска тиеш, дип әйткән иде. Бу мәсьәләдә безнең җаваплы кешеләребез бар. Менә аларның берсе — мәгариф министры. — Ул борсаланып утыручы министрга борылды: — Рәхим итеп халыкка җавап бирегез әле. Ә без үз чиратыбызда һәр конструктив тәкъдимгә, һәр эшкә хәерхаһ.

Министр, торып, туган телебезнең җәмгыятьтәге ролен искә алды, шулай да ата-аналарның теләгенә колак салу кирәклеге турында хәтергә төшерде. Ул бытырдаган арада, Килдебеков башка сораулар белән таныша башлады. «Мәскәүдә ясаган чыгышларыгыз төссез, кызыксыз була, — дип язган берәү, — ярдәмчеләрегезне алмаштырып, талантлырак кешеләрне алырга теләмисезме?» «Вәт акыллы баш, — дип ачусыз гына уйлады Килдебеков. — Мине тәнкыйтьләве инде моның...»

— Төн караңгы булган саен, йолдыз яктырак күренә. Тик бу мәкаль безгә туры килми. Янәшәңдә зирәк, талантлы кешеләр булса, син дә бер башка югары күтәреләсең. Берәрегез үз кандидатурасын тәкъдим итмидер бит? — Залда көлү тавышлары ишетелде, Килдебеков җавабының ничек тәэсир итүен белергә теләп урындашларына күз сирпеп алды. Аларның йөзендә һәрвакыттагыча җәенке елмаю балкый иде.

Сорау: «Татарстан АЭСын төзү туктатылачакмы?» Бу соруга инде мөмкин кадәр сак, мөмкин кадәр гомумирәк

җавап бирергә кирәк иде. Килдебековның үз-үзенә дә, шушы залга да кинәт кенә ачуы чыкты. Нигә бу молокосослар алдында җавап тотарга тиеш әле ул? С какой стати? Ләкин тимер йодрык белән кысып дигәндәй йөрәген тынычландырды. Төрәләрнең китүен таләп итеп кайбер шәһәрләрдә хәзер демонстрацияләр дә оештыралар. Сылтау гына бир...

— Яшермим, АЭС дигәч, минем үземнең дә аркага тир бәреп чыга, — дип башлады ул сүзен. — Нишлисең, газета-журналлар шактый тырышты шул. Ярый инде, мин өлкән кеше. — Килдебеков йөзенә мөлаем елмаю чыгарды. — Ә сез? Яшьләр! Сез бит киләчәк кешеләре! Карашыгыз еракка карак төбәлгән. Прогрессны аңларга кирәк. Заманында, «шайтан арбасы» дип, автомобильгә дә каршы төшүчеләр булган...

Залда «һәм дөрес эшләгәннәр» дигән тавыш яңгырады, тик Килдебеков аңа игътибар итмичә сүзен дәвам итте: — Тарих тәгәрмәчен кирегә борып булмый. Энергетика иң мөһим тармак хәзер. Кем шәм яктысында яшәргә риза? Беркем дә... Менә сез АЭСлар кирәкми дисез, ә бит ихтыяҗларны киметергә уйламыйсыз да... Киресенчә, һаман күбрәкне, яхшыракны таләп итәсез. Әлбәттә, экология мөһим фактор... табигатьне шулай талкысак, дөньяны экологик үлем көтә. Апокалипсис... Ләкин бит ГЭСлар да табигатьне шулай ук пычрата...

Кемдер «ә җил, ә кояш энергиясе» дип кычкырды.

— Ну, это не серьезно, — диде Килдебеков. — Җил, кояш белән генә еракка китә алмабыз.

Ул, очрашуның шулай шома гына баруына сөенеп, тагын сорауларга җавап бирә башлады.

Сорау: «Казан феномены» — урам төркемнәре белән көрәш ничек тора?»

Килдебековның йөрәге сулкылдап куйды. Улы исенә төште. Көрәш, имеш. Үз балаңны тәртәгә кертеп булмый монда. Хәер, шунысы кыен да инде. «Авылны буйсындыру пүчтәк, менә хатынны буйсындырып булмый», — дип зарланган бит аның атасы да сабырлыгы сынган бер вакытта...

— Бу сорау безнең барыбызга да кагыла, — диде ул. — Үз чиратымда мин аны сезгә дә бирә алам. Менә сез, яшьләр, активистлар, ул төркемнәр янына барганыгыз бармы? Ни белән кызыксына алар, ничек яшиләр, беләсезме? Әйдәгез, иптәшләр, сүздән эшкә күчик. Яшүсмерләр белән эшләүне бер милиция өстенә генә аудармаска кирәк.

Залда бер шаян тавыш ишетелде: «Менә Ирек барган иде дә, кайткач бер ай больницада ятып чыкты».

Шул чакта арттагы рәтләрдән сакаллы, күзлекле бер бәндә тәвәккәл кыяфәт белән алга таба уза башлады.

— Сез, Ирхан Алиевич, матур гына сөйләдегез, — дип башлады ул сүзен, — ләкин... — Залда чыш-пыш тавыш китте, сакаллы нигә тынычсызланганнарын аңлады, башын иеп үзе белән таныштырды: «Гарипов, инженер, «Халык фронты»ннан. Мин һаман шул АЭС турында сөйләмәкче булам. Бу проблемадан алай җиңел генә котылуы мөмкин түгел. Чернобыль фаҗигасе әле дә бәгыребездә сулкылдый. Мәрхүм академик Валерий Легасовның сүзләрен искә төшерегез: «Чернобыль трагедиясенә охшаш хәлләр тагын кабатланырга мөмкин, аннан котылып булмый: бездә Чернобыльдәгечә эшли торган 14 реактор бар...» Шушы авариядән соң ике ел үткәч, намуслы галим үз-үзенә кул салды. Шуңа аның бу сүзләрен без васыять сыман кабул итәргә тиеш: «Барыннан да элек — моңа ведомство «уены»на бирелмәгән галимнәребез берсүзсез риза — Советлар Союзының халык бик тыгыз урнашкан Еврова өлешендә атом станцияләре төзүгә юл куярга ярамый. Биредә яңаларны төзү түгел, ә төзелә башлаганнарын туктату һәм ябу кирәк!»

Хәзер үзебезнең Татарстан АЭСына кайтыйк. Беренчедән, АЭС төзер өчен моңардан да уңайсыз җирне махсус эзләсәң дә табып булмый. Дөрес, читтән килгән галимнәр, гидрогеологик һәм инженер-геологик тикшеренүләр үткәргәннән соң, бу урынны яраклы дип тапканнар. Ләкин соңгы мәгълүматлар буенча, мондагы 1500–1700 метр тирәнлектәге кристаллик эргәдә ике ярык барлыкка килгәне билгеле булды. Шулар нәкъ АЭС төзелгән төштә бергә кисешкәннәр. Биредә тирән җир катламнары яргаланып беткән. Өстәге калкулыклар шуның билгесе. Тектоник хәрәкәт бу җирләрдә дәвам итә. Нәтиҗәдә җир өстендәге бөтен зарарлы калдыклар бернинди тоткарлыксыз эчә торган җир асты суларына төшәчәк. Шулай итеп бу төбәкләрнең сусыз калу куркынычы бар.

Икенчедән, авария булмас дип кем гарантия бирә ала? Юк андый кеше. Ярый, АЭС яхшы гына эшләп тора дип фараз итик. Ә атмосферага чыккан зарарлы матдәләр? Ә радиоактив калдыклар? Аларны кая күмәргә җыеналар? Андый «зират»ның туган як табигатенә зарары булмый калмас.

Өченчедән, әгәр дә җир тетрәсә? — Инженер залдагы шау-шу тынганын көтеп торды. Килдебеков та җиңел сулап елмаеп куйды: «Шизик». Нишлисең, аларның «выходкасына» түзми булмый, психушкалар шыгрым... Шизиклар куркыныч түгел, бу мәсьәләдә аларның чыгыш ясавын безнең тегерменгә су кою, дип уйлады ул. Әмма ялгышкан икән...

— Көлмәгез, көлмә, Татарстанда сейсмик станция төзергә күптән вакыт. Соңгы вакытларда Әлмәт тирәсендә 4–5 балл көч белән җир тетрәү очраклары күзәтелде. Галимнәр анда 1914 елда ук җир тетрәү очрагын теркәп калдырганнар!

Баксаң, Карпаттан Уралга, Кола ярымутравыннан Урта Азиягә таба ике системадагы җир тетрәү зонасы үтә икән. Әлмәт нәкъ шулар кисешкән урынга урнашкан. Күз алдына китерегез: монда җир тетрәде ди... Ул Түбән Кама сусаклагычын селкетәчәк, тегесе үз чиратында грунтка басым ясаячак һәм АЭС блоклары хәрәкәткә киләчәк.

Җыеп кына шуны әйтмәкче булам: әгәр дә анда һәлакәт булса, тфү-тфү, татар халкының бөтен проблемалары «хәл ителәчәк». Теле дә, культурасы да, тарихы да үзе белән юкка чыгачак! Әле Татарстан чигендәге Башкортстан АЭСын истән чыгармагыз. АЭСлар бер-берсенә бик якын урнашканнар түгелме соң? — Инженер сүзен бетереп җитез генә үз урынына юнәлде.

«Бөтен карталарны бутап ташлады бу», — дип гасабиланып уйлады Килдебеков. Ләкин бу телмәр уңаеннан нидер әйтергә кирәк иде.

— Тирән эчтәлекле чыгышыгыз өчен рәхмәт, иптәш Гарипов. Уйлануларга этәрә торган чыгыш булды. Без, әлбәттә, үз чиратыбызда бу мәсьәлә белән шөгыльләнербез. Һәрхәлдә, хәлләр ул кадәр аяныч һәм өметсез дип уйламыйм мин. Иң әүвәл мәһьәләне җентекләп өйрәнергә кирәк, бер деталь дә күз уңыннан төшеп калмасын... — Ну демагог та соң үзем, дип уйлады ул эчтән генә... — Бик кызыклы очрашу булды, миңа калса... Файдасы ике якка да булыр дип ышанам. Йомгаклап, барыгызга да рәхмәт белдерәсем килә...

«Яшьләр хәзер үзгә — гаярь, усал, белдекле», — дип уйлады ул, үз кабинетына менешли. — Шулай ара-тирә парларын чыгарып алырга кирәк. Менә бүген алар зур эш башкарган кешеләр кебек тынычланып өйләренә таралыша... тагын нәрсә кирәк җитәкче кешегә? Димәк, ул үз вазифасын үтәгән дигән сүз.

Тик өйдә, өйдә... теге шельма белән әңгәмә үткәрәсе бар бит әле. Килдебеков, йөзендәге кызыл тимгелләрне сыпырып төшерергә теләгәндәй, ап-ак кульъяулыгы белән битен сөртеп алды.

Ә кабинетта инде галиҗәнап тычкан баласы хакимлек итә иде. Килдебеков бу юлы аңа игътибар итеп тормады, тузан бөртеге дә шуып төшә торган туфлие белән дә идәнгә типмәде — иренде. Алҗыган иде ул, бүген көне буе киеренке торган нервылары ял сорый иде, бөтен буыннарда хәлсезлек, йөрәге дә тимер читлек эчендә бәргәләнгән кошчык кебек бер җилпенеп ала, бер басыла, үзе эчне пошырып сыкрап тора иде. Ә кызыл телефон бүген чылтырамас, соң инде. Ул очрашуда вакытта да тып-тын торган, дәшмәгән, Килдебековның сораулы карашына секретарь кыз «юк» дигәнне аңлатып баш селкеп калды.

Ул кәнәфиенә ишелеп төште дә күзләрен йомды. Тып-тын, тик теге каһәр төшкере тычкан гына кетер-кетер нидер кимерә — дөньяда аның да үз гаме. Тып-тын, әйе, болай тып-тын иде, тик Килдебековның колагына гына еракта, бик еракта ниндидер бер гүләүнең якынлашып килгәне ишетелгән кебек иде...

## III. Мин – Фил

Finita la comedia! Сукыр чебен кебек килеп каптым мин. Югыйсә үз-үземә сүз биргән идем, сугышның эченә кермәскә, беразчиттәрәк торырга иде исәп. Кая ул! Бугаздан ургылып чыккан акыру авазларын ишетүгә үк учакка тартылган күбәләк кебек иң кызган җиргә барып кердем. Кем ничектер, андый чакта мин үземне тыеп тора алмыйм, башны кан томалый, күз алдында кызыл шәүләләр генә селкенә, мин, таякны болгап, дошман өстенә ташланам. Ә аларның икесе аяк сузган... Кем үтергәнен кем белә хәзер... Үзем түгел икәнен мин төгәл беләм, әлбәттә... Бу юлы тәки бер кешегә дә суга алмадым, чын менә... Киресенчә, тегеләрдән берәү — мин аның Ванька-Бүре икәнен шәйләп өлгердем — чүт кенә теге дөньяга озатмады. Әле алдан күреп читкә сикереп калдым, арматура сызгырып төшеп беләгемне сыдырып алды. Ә бит башка төбәгән иде, сволочь. Баш кавын кебек кенә ярылып китәчәк иде.

Ментлар бик тиз килеп җиттеләр. Кисәтелгән булганнар. Тегеләр арасында да, бездә дә стукачлар бар... Машина фараларының яктысы төшүгә үк караңгы тыкрыкка сыпырттым. Башкалар качканда да бер-берсеннән аерыла алмыйлар — көтү психологиясе. Минем уемча, фиргавеннәр шуларны ээрлекләргә тиеш иде. Юк, машиналарын минем якка бордылар. Җитмәсә, миңа Боксер да ияргән икән. Гаҗәп тә түгел инде, аңгыраның да аңгырасы ул. Менә шул — эләктерделәр... Боксер белән икебезгә бер богау җитте, «уазик »ның артындагы кысан урынга кертеп яптылар.

Милиция бүлегендә дежур офицер белән бер старшина утыра иде. Офицеры мөлаем гына күренә — утыз яшьләрдәге капитан. Күрәсең, монда берәр югары уку йортын тәмамлаганнан соң килгән. Юньлерәк урын таба алмагандыр шул, байгыш. Үзе яхшы кешегә дә охшый, әмма миңа төбәлгән күзләрендә бер дә шәфкать хисе юк иде. Теге җан тәслим кылган ике малайны безнең хисапка теркәп куймасыннар тагын...

— Исем-фамилия?

Мин эндәшмәдем. Дөресен әйтергә куркам, ялганлыйсы килми. Авызымнан бер сүз чыкмас — менә шул. Капитан күз карашын Боксерга күчерде:

— Ә синеке ничек?

Боксер да тып-тын гына тора... дебил... Аңа нәрсә инде — өйдә алкоголик әтисе дә үги әнисе генә. Монда эләккәнен ишеткәч, бер тамак кимеде дип сөенерләр генә.

Капитан алдындагы кәгазен читкәрәк этеп куйды.

— Ярар, бераз суынычгыз әле, аннары сөйләшербез.

Сержант безне камерага әйдәде. Алда ике тимер ишек. Әнекәчкәем, төрмә дигәннәре шушы була микәнни... Мыегы яңа гына шыта башлаган сержант шалтыр-шолтыр итеп йозакны ачты. Дөресен әйтим, шүрләтте — йөрәк бугазга килеп тыгылгандай булды, авыз кипте, тел аңкауга ябышты. Шулай да ихтыяр дигән нәмәрсәкәй калган икән әле — шыр җибәрүне бу маңка сержантка сиздермәскә теләп эчкә уздым. Артта авыр гына ыңгырашып тимер ишек ябылды, йозак янә шалтыр-шолтыр килде. Ут яктысында ниндидер бәндәләрнең гәүдәләре күренә. Алар... йоклыйлар иде. Бәхетлерәкләре — түрдәге тар сәкедә, калганнар цемент идәнгә урнашкан. Камераны селкетеп, гырлау авазлары ишетелә, йокы үзенекен итә шул: бу мескеннәр хәзер рәхәтләнеп төш күрәләрдер, төштә алар, әлбәттә, ирекле, азат; ә уянгач менә, мин кайда соң әле, дип беравык аңгыраеп ят түшәмгә карап ятарлар... Хәер, күбесе өчен бу түшәм алай ят та түгелдер, бу бәндәләр биредә «даими» кунаклардыр. Ә бу — тезләрен иягенә кадәр үк җыеп китергән унике-унөч яшьләрдәге малайга монда ни калган? Минем карашны сиздеме, малай төшләнде — ачыргаланып кычкырып җибәрде: «Мама, я больше не буду!» Калган токтыннар канәгатьсез төстә селкенгәләп куйдылар. Сәкедә яткан берәү иренеп кенә сүгенеп алды: «Детсад мәллә бу, анасын фәлән-төгән».

Ятарга урын юк иде — цемент идәнгә сузыласы килмәде — ишек төбенә генә чүгәләп утырдык. Тел белән әйтеп булмый торган ниндидер күңелсезлек. Юк, ирекле кеше тоткын хәлен аңлый алмый. Арчадан килеп безнең компашкада күренгәләп йөргән Расих исемле малайның — аның кликухасы Шайтан иде шикелле — бер җыры искә төште. Гитарада уйнап шул җырны җырларга ярата иде Шайтан:

Их, югалдым мин, егет,
Калтырый куллар...
Үтәдер айлар, үтәдер еллар...

Калган сүзләре истә түгел, болары да кушымта булып кабатланганга күрә генә башка сеңеп калган. Соңгы арада Шайтан күренмәде, берәүләр аны, Арча вокзалында чәнечкәннәр икән, дип сөйләде, берәүләр, төрмәгә эләккән, дип каркылдады. Булыр да, кулы туры түгел иде аның. Бәлки, күрешергә дә насыйп булыр әле. Тәүбә, тәүбә...

Боксер идәнгә янтаеп гырлый да башлады. Минем дә күзләр йомылып-йомылып китә, ләкин чүгәләгән килеш йоклау авыр, буыннар оеган. Түрдәге сәке кызыктыра, каһәр. Анда өчәү ятkан: бая ялкау гына сүгенгән адәм, мескен бүрекле бер абзый, битен җирән сакал баскан озын чәчле бер егет. Мескен бүреклесен өстерәп төшерсәң, әллә нинди тавыш-гауга кузгалмас шикелле. Ул монда баштарак эләгеп, түрдәге урынга иялөнеп калган, ахрысы. Куркыныч затка охшамаган. Акрын гына килеп иңенә кагылдым. Селкенми дә, сволочь, рәхәтләнеп йоклый, социаль гаделлек турында башына да китереп карамый. Кара син аны, нииндидер әтрәк-әләм түр сәкедә борын сызгыртсын — полный комфорт! — ә син, Фил, Фил үзе! — Цемент идәндә ауна... Ачу килсен өчен әчтән үзеңне шулай көйләргә кирәк. Мескен бүреклегә катырак китереп төрттем: «Эй, эй, папаша, подъем!» Торып утырды да бу, ач күзләре белән аңгыраеп миңа карап тора башлады. Ситуацияне аңлап бетермәде бугай әле. «Бераз ятып алыйм әле, син күп йокладың», — дидем. Ә бу күзләрен агартып тик миңа карап тора. Нииндидер мае беткән күзләр... Ниһаять, минем фикер башына барып җитте, ахрысы, ап-ак нечкә иреннәре җәелеп китте, авызда эре сары тешләр күренде. «Хи-ых, хи-ых», — дип хихылдады мескен бүрекле, аннары кинәт кенә иреннәрен җыеп алды: «Пш-шел ты, щенок!» Һәм бернәрсә дә булмаган кебек, тагын сәкегә җәелде. Вот, кабахәт... Гарьлектән күзгә яшь килеп тыгылды һәм мин үзем дә сизмичә мескен бүреклевнең туңкаеп торган күтенә китереп типтем. Мондый җитезлекне көтмәгән идем — абзыкай пружинадай өскә сикерде. Коточкыч авырту миемә килеп җиткәндә, мин ишек төбенә кадәр очып барып, Боксер өстенә килеп ауган идем инде. Кыйнашу мәсьәләсендә Боксерга тиз акыл иңә, ул, күрәсең, шунда ук хәлне чамалап алды, тиз генә торып зур гәүдәсе белән мескен бүрекле өстенә килә башлады. Сытачак бу моны хәзер. Теге егылгач йөзенә тибәргә чамалап, мин дә калкынып куйдым. Ул да булмады, Боксер яман илереп шадра стенага сыланды, стена буйлап ишелеп төште дә идәнгә капланды. Мескен бүрекле моны гына аз санады, ахрысы, йөгереп килеп Боксерның бавырына типте. Аннары миңа борылды. Күзен кан баскан, икебезне дә үтерми торып тынычланмаячак иде бу. «Беттем» дигән салкын уй кереп баш әчен туңдырып җибәргәндәй булды. Ләкин Алла бар икән ул! Шалтыршолтыр килеп йозак ачылды, ишектән теге сыек мыеклы сержантның аксыл чырае күренде. Тик моңа мескен бүреклевнең исе дә китмәде, сарыкка ябышкан бүре кебек минем өскә очып кунды. Малай сымак кына күренсә дә, сержант көчле икән — тегенең кулын артка каерып та алды. Ул булмаса, мескен бүрекле дигәнем ике дә уйламый мине буып үтерәсе икән...

Ишектә капитан белән старшина күренде. Алар кызыксынып камера эченә төбәлделәр. Капитанның йокымсыраган тавышы ишетелде:

— Нинди ыгы-зыгы монда?

— Менә Сорокин шаулый... — диде сержант.

— Ул безне үтерә иде, — дип чәрелдәдем мин.

— Ничего, монда эләккәннәр тиз генә җан бирми... — Старшина авыз эченнән генә мыгырданып алды: — Живучие, гады...

— Шулай да Сорокинны икенче камерагаябыгыз, — диде капитан.

Сорокин инде тынычланган кебек иде, бер сүз эндәшминитми сержант алдыннан ишеккә таба атлады, әмма чыкканда миңа таба борылып эре сары тешләрен шыгырдатып алырга онытмады.

Тоткыннар инде уянган иде. Бая саташкан малай стенага терәлеп тезләрен кочаклап утыра, күзләре челт-челт йомыла — бу көтелмәгән шау-шуның серенә төшенергә чамалый, ахрысы. Мин, эчтәге авыртуны басарга теләп, сәкегә таба атладым. Ни генә булмасын, максатка ирешелде. Өчдүрт сәгать кешечә йокларммын дип уйладым. Кара теге Сорокин дигәннәрен, ничек оста сугыша, ә мин аны ниндидер бичара дип уйлап тагы... Бая йокы аралаш кына сүгенеп алган абзый да торып утырган, эренле күзләре белән миңа ниндидер кызганулы караш ташлап алды.

— Ай-йай, яшьләр кыю... — диде ул. — Шулай да бу кеше белән бүтән очрашмаска тырышыгыз... Ничәмә-ничә җан кыйган Музыкант шушы бит! Кеше үтерү аңа чебенне сытуга да тормый.

Музыкант... Ишеткән бар иде ул рецидивист турында. Ә мин аның күтенә... Шул чакта мин аркага салкын тир тамчысы бәреп чыкканын тойдым.

Ләкин бу камерадагы мажаралар моның белән генә бетмәгән икән әле.

Инде тынычланып йокымсырый гына башлаган идем, ишектән бер озын егетне этеп керттеләр. Бөдрә чәчле чибәр генә егет. Күзләре җансыз — хәер, нормаль күзле кешене күрмәдем мин биредә — «Это недоразумение!» — дип кычкыра. Мөгаен, ул камерага керергә теләмичә тартышкандыр: галстугы кыйшайган, пинжәк төймәсе ите-ние белән умырылып чыккан. Монда эләккәч карышма инде син, агайне. Язмышыңны тәкъдир кулына тапшыр да тынычлан. Ниһаять, сержантлар, егетнең озын кулларыннан котылып, ишектән чыгып киттеләр. Шалтыр-шолтыр килеп йозак тавышы ишетелде. Егет исәр күзләре белән ярым караңгы камераны айкап алды. Аның бөтен кыяфәтенә: «Нишләп

мин монда эләктем әле?» — дигән гаҗәпләнү язылган иде. Шуннан соң ул бер сүз әйтми-нитми генә минем янга килеп утырды. Ачу килеп куйды — бу егет сәламәсе безне санга да сукмый, ахрысы, әйтерсең аның тирә-юнендә бер кеше юк, шушы ярым караңгы камерада гүя ул үзе генә... Менә ул, җиңен сызганып, беләгенә уралган бинтны чишә башлады. Мин, аптырап, аның хәрәкәтләрен күзәтеп утырдым. Нишләмәкче була бу? Бинт сүтелеп бетте дигәндә, аннан егетнең итәгенә бер лезвие килеп төште, бинт ачылып китеп ап-ак тәндә кызгылт нокталар — шприц эзләре күренеп калды.

Егет ашыкмый-кабаланмый гына бинтны кире урады, аннары икенче кулының җиңен сызганып миңа сузды, иягe белән генә лезвиегә ымлады: «Кисә аласыңмы?» Мин тайчанып читкә борылдым... Псих бит бу!

— Үземә кисү авыррак, — диде ул, кыенсынган кебек.

Андый чакта кешегә ярдәм итәргә кирәк, әлбәттә. Бәлки, кешенең үләсе киләдер! Шул чакта аңа комачаулап, тыкшынып, нигә аның тормышында өстәмә кыенлыклар тудырырга? Тик менә...

— Рәхәтләнеп кисәр идем, каннан куркам, — дип ялганладым мин.

Дөресрәге, өстәмә статья чәпәп куюларыннан курка идем. Егет башкаларга күз йөртеп чыкты, әмма кешенең кан тамырын кисәргә атлыгып торучы табылмады. Ярдәмнән өмет өзеп, егет лезвие белән үз беләгенә үзе селтәнергә тотынды, кыс-с, кыс-с дигән тавыш тешкә тия, ирексездән тәнне калтыратып куя иде. Беләктә башта кызыл сызык пәйда була, аннары аннан кан чаптыра башлый — берничә минут эчендә стена, идән-түшәмнәр кып-кызыл канга буялды.

Боксер кинәт сикереп торды да ишеккә ташланды.

— А-ай, — дип кычкырды ул. Тавышы күкрәк төбеннән калтыранып, еламсырап чыкты. Әллә чыннан да каннан курка инде... Үзе чучка баласыдай йодрыгы белән ишекне дөмбәсли: — А-ай... Кеше үлә!

Бераздан, карлыккан аваз чыгарып, тимер ишек ачылды. Сыек мыек белән тагын бер сержант идәндәге канга лач-лач басып эчкә үттеләр. Аларның бернигә исе китми иде, ахрысы.

— Артист... — дип, сыек мыек төкереп куйды.

Бераздан ястыктай күтен сузып ак халатлы бер юан марҗа да килеп керде.

Бөдрә чәчнең беләгенә жгут салгач, сержантлар аны типкәли-типкәли алып чыгып киттеләр.

Сыек мыек бер чиләк су белән чүпрәк кертте. Боксер почмакка борылып укшый башлады.

— Бәдрәфкә чык, ублюдок, — диде сыек мыек.

Мин янәшәдәге малайга карап алдым. Ул тиз генә идәнне юып та чыгарды.

Башымны учларым белән кысып сәкегә сузылдым. Минме соң бу? Синме бу, Фил? Фәнил Ирханович... Күз алдына әти килгәч, аркам янә тирләп чыкты. Шүрлим бит мин аңардан. Үз-үземә сиздермәскә генә тырышам. Кем икәнемне әйтмәгән булдым. Ахмак. Монда эләккән кешеләрнең шәхесен ачыкламыйлармы инде, йә? Минем аркада әтигә дә сүз тиюе мөмкин... Һәрвакыт кеше күзендә бит ул. Аның абынганын көтеп торучылар — легион. Менә бит яхшыдан яман туган нәрсә...

Хәер, ние белән яхшы соң әле ул? Мин аңардан нием белән яманрак? Аның үз мафиясе, минем — үземнеке. Ул, әлбәттә, зур эт... тешләсә өзеп ала... Ә мин көчек кенә әле... тычтым барысына. Телефоннан әти бер генә кычкырыр... бу подоноклар, койрыкларын кысып, минем алдыма килеп егылырлар. Мин аларны әле туңкайтып... Мин әле, мин... Мин!

...Йокыга киткәнмен, ахрысы. Үземне ниндидер коршау әйләндереп алган кебек. Сындырып чыкмакчы булып шуны, кап-кара кырдан йөгерәм. Тик коршау да минем белән хәрәкәт итә... Чурт, горизонт түгелме соң ул... Тик нигә кара соң?

Дерт итеп уянып киттем. Ишек тавышына икән. Иренеп кенә башны күтәрдем. Тагын кемне китерделәр? Тотқындагыларга һәр яңа кеше кызыклы икән. Чөнки ул теге яктан, азат дөньядан килгән. Анда ниләр бар? Бу салага нигә бирегә эләккән? Мин инде үземне шактый тәҗрибәле зэк итеп хис итәм, в натуре! Аркадагы тир дә кипте, әтинең сурәте дә коршауның теге ягына чигенгән сыман. Аның үз коршавы. Гомумән, һәркем үз коршавында яши.

Ни күрим — ишектән безнең Гайканы, безгә яңарак кына кушылган теге өч тәңкәлек маңка малайны кертеп җибәрделәр. Во, фраер...

— Гайка! — дип кычкырды Боксер.

Гайка исә ишек төбендә аптырап басып тора. Күзләрен челт-челт йомгалый. Боксер исә аның иңенә суккалый, сөенә, дебил... Кемнәр арасында мин, ә? Зур түрә малае, үземнең баш та түгәрәк, шушы ыбыр-чыбыр белән милициянең каклаган сәкесендә ятарга тиеш кешеме? Тик шуларны кулда тоту рәхәт шул. Әнә Гайка да карашымнан куырылып китте.

— Нигә соңардың? — дидем мин, каш астыннан карап...

— Мин котылган идем инде, — дип ашыга-ашыга сөйләп китте ул. — Бер җирдә посып торганнан соң, кайтырга чыктым. Үз йортыбыз янына кайтып җитәрәк кенә, янәшәдә милиция машинасы килеп туктады. «Әнә тагын берсе», — дип кычкырдылар да, таяк белән аркага тондырып, үзләре белән алып киттеләр.

— Ә син... берни дә белмим, беркемне күрмәдем, дидеңме соң? — диде Боксер.

— Шулай дидем... — Гайка инде шактый тынычланган иде.

— Исемеңне әйтмәдеңме? — Боксер һаман аңгыра сорауларын бирә иде.

— Әйттем. Мин нәрсә, Зоя Космодемьянская мәллә?

Мин бу малайга текәлебрәк карадым. Чүлмәге әшли бит. Рәт чыгачак моңардан. Боксер кебек туң күчән түгел. Ә-ә, әтисен фән кандидаты, диган иде бит әле. Димәк, интеллигент нәселеннән. Ирекка чыккач, үземә якынайтасы булыр. Башлыраклар белән эш итүе җиңелрәк. Дөрес, Боксер кебекләр дә кирәк. Аларга үзгә эшләр йөкләнер...

— Кил, минем янга чүмәш, — дидем. Боксер гаҗәпләнеп миңа карады. Нигә әле мондый хөрмәт бу салагага, янәсе. Йөзе каралып китте... Шулай... Бер-берсеннән көнләшсеннәр, бер-берсенең һәр адымын күзәтеп, миңа җиткереп торсыннар.

Йокы качкан иде. Сәгать ничә икән инде? Ишек өстендәге уемтыда лампочка саргылт тузанлы яктылыгын сирпи. Стеналар шадраларын каплап тынып калган.

Эренле күз ыңгырашып алды да торып утырды. Сәкенең нидидер ярыгыннан тәмәке тартып чыгарды. Кабызды, ләззәтләнеп суырды. Кемгәдер бәхет — шул...

Юк, кешеләрне тигез яратмаган Ходай. Кемдер өстә, кемдер аста... Мәңгелек шулай... Бүтәнчә дөнья бармас иде. Кемдер аста, ә кемдер өстә булырга тиеш. Шул чакта гына кешелек дәвам итә.

— Сәгать ничәләр икән?

— Хәзер иртәнге дүртләр булырга тиеш, — диде Гайка.

— Борчылма, — дидем аңа. — Сине бөтенләй бүтән җирдә тотып алганнар. Безнең белән булганны исбат итә алмыйлар. Кайдан кайтасың дип сорадылармы соң?

— Дус кыз белән утырдык, дидем.

— Молоток, — дип, Гайканы мактап алдым.

Ул тугрылыклы эт карашы белән миңа карады. Менә бит, кешене мактап та үзеңә бәйләп куеп була. Кемне мактап, кемне куркытып...

Күзне йомдым. Нәни генә түгәрәкләр биешә. Әйе-е, һәркем үз коршавы эчендә бәргәләнә. Кемнеке төрле рәхәтлекләр белән тулган, кемнекендә — бичаралык, хәерчелек. Ләкин рәхәтлек коршавында җайлы дип кем әйтә ала? Барыбер коршаудан сикереп чыга алмыйсың... Бернишләп тә булмый...

— Филнең нервылары тимер кебек, — диде Боксер. Тавышында ялагайлык. Минем ишетеп ятканны белә. Ни-

кадәр аңгыра булса да, ярарга тырыша... Хәер, ярарга тырышу да акыллылык билгесе... Димәк, алай ук ахмак түгел Боксер да... Шулай да ялагайлардан саклану яхшы... Теләсә кайчан аркага пычак кадаулары мөмкин...

Көчсезлегеңне күрсәтмәскә кирәк. Эчеңдә куян кебек бөгәрләнеп курку ятканны... Шуны сизсә, үз өереӊ шунда ук сиңа ташланып, ботарлап атачак... Иң беренче сикерүче синең урынны алачак... Әллә котыртучымы? Әйе, алар беркайчан да үзләре башлап сикерми...

Бу малайлар белән уйнау вакытлы гына хәл... Тәҗрибә бакчасы... Минем максат зурдан... Тик киләчәктә боларның да кирәге чыгуы бар...

Мондый фәлсәфә әтигә ошар иде. Тик ачылып ничек аңлатасың? Минем белән аның беркайчан да җәелеп сөйләшкәне булмады. Дөресен әйткәндә, мин әтисез үсәм. Карьерасы өчен кирәк булса, ул миннән дә баш тартачак.

Көчле кеше!

Мин дә шундый түгелмени? Өскә менгәндә юлда әти торса, мин аны таптап китмәммe?

Зур максатың бар икән, син ялгыз булырга тиеш. Максат һәм син... Бүтән беркемгә янәшәдә урын юк. Башкалар шул максатка ирешү өчен корал гына...

Ә минем максатым нинди? Бүтәннәрне учта биетү... Мин — режиссер. Прокуратор... Яшәүнең үзгә мәгънәсе юк... Калганы тирестә казыну гына. Минем тирестә казынсыннар!

Әтинең дә яшәү фәлсәфәсе шул бит...

Ул мине аңларга тиеш...

Аңа ярарга тырышырга кирәк... Ихтыярына буйсынуны ничек тә самими күрсәтергә. Ул фальшьны тиз сизә.

Әле аңарда көч.

Мин әле артист кына. Ул — режиссер...

Сәхнә серләренә төшенәсем бар.

— Ментлар килмәсә, без аларның тетмәсен тетә идек. — Боксерның миенә кадәр курку сеңгән иде, сөйләшеп, шуны басмакчы була. Мондый типлар берүзләре бернигә дә ярамыйлар, алар өер белән генә, вожак булганда гына көчле. Гайка белән сөйләшеп, әшнәләшеп, үзен күпмедер кеше итеп сизмәкче... Әле үзен Гайкадан өстен күрсәтмәкче... Ләкин монысы андый примитив түгел... Үзе килешкән кыяфәт ясый:

— Һи, без аларны изә идек, — дип Боксерны җөпләи. Ул инде аңа үз бәясен куйган, күрәсең...

— Син инде шыр җибәрдең, ә? — Боксер хихылдап алды. — Беренче кат шулай була ул... Хотя мин беренче сугышта ук берәүне сузып салдым. Калтырамадым да... Фил дә шундый.

— Алайса кайдан беләсең?
— Нәрсәне?
— Беренче тапкырда шыр җибәргәнне...
— Сөйлиләр... Күргәнем дә бар. Син һәр сүзгә бәйләнеп утырма, яме... Олыларны тыңла.
— Ярар.

Шул вакытта ишек ачылды да, сыек мыек кинәт кычкырып җибәрде:
— Килдебеков!

Мин үзем дә сизмәстән өскә калкындым.
— Ха, — диде сержант. — Тел яшергән буласың, ә? Бик тиз раскололся... На выход!

Болай ахмакларча тәбегә кабуыма гарьләнеп, ишеккә атладым. Эзләп тапканнар... Әтинең кара коелган йөзе тагын күз алдымда пәйда булды... Каршына килеп баскач, бөтен баягы фәлсәфәм борчак кебек идәнгә коеласы миңа ачык иде. Аның ачуы чыкканда, иң яхшысы авызга су кабып тору... Башны иеп, муен бөгеп...

Ишеккә җитәрәк туктап калдым. Боксерга ымлап:
— Иптәшемнән башка чыкмыйм, — дидем. Үзем сизелер-сизелмәс кенә Гайкага ымладым, син безнең белән түгел, янәсе. Менә бит нинди конспирация...
— Бу говнюкны синнән башка да күтенә тибеп чыгарырбыз... Бер-ике сәгатьтән соң...
— Юк, ул минем белән эләкте...

Сыек мыек бераз уйлангандай итте.
— Мәйлең...

Боксер да миңа иярде. Чыксам, капитан янында күзен кульъяулык белән сөрткәләп әни утыра... Мине күрүгә урыныннан чак торып кулларын миңа сузды: «Улым...» Кульъяулыгы шакшы идәнгә төшеп китте. Капитан аны иелеп алып селеккәләде, ләкин аны гына җитәрлек дип тапмады булса кирәк, авызына якын китереп өрде дә өстәленә куйды.
— Син бит безне куркыттың... Үтерә яздың... Атаңа инфаркт... була язды...

Әни мине кочакламакчы иде дә кинәт артка чигенде.
— Бу нинди киемнәр синдә? Төрмәнекеме?

Мин нидер әйтергә теләп авызны ачкан идем, әни бармагын Боксерга төбәп чәрелдәп җибәрде:
— Янәшәңдә бу нинди бандит?

Аны хәзер ничек тынычландырасың? Капитан, кабаланып, аның кулына стакан белән су китереп тоттырды. Сержантлар кызык табып безгә карап торалар иде.
— Луиза Максумовна, аның үз киеме шулай иде, — диде капитан, каушап...

Ул арада капитанга маңгай чәчләре коела башлаган, ис-

керәк кәчтүм-чалбар киеп, муенына чуар муенчак аскан күзлекле берәү якынлашты.

— Мин Гайнан Сәйфетдиновның әтисе, — диде ул.

Капитан аңа яратмыйча карады. Әмма шундый зур түрәнең хатыны алдында тугарылып китмәде бугай, сыек мыекка кычкырды:

— Чыгарыгыз теге малайны.

Бераздан коридорда башын игән, бөрешкән Гайка күренде. Әни һаман минем таушалган иске спортивный киемнән күзен алмый иде. Мин сугышырга үз киемем белән бара алмыйм бит инде. Үз киемем Боксерларның чоланында калды. Кайтканда алмаштырасы идем...

— Борчылма, үз киемем исән, — дип, әнине тынычландырырга тырыштым.

Гайканың әтисе ниндидер кәгазьгә кул куеп тора иде.

— Килдебеков, тиешле сабак алгансыңдыр дип уйлыйм, — диде капитан. Күзендә чиксез нәфрәт иде.

Фамилиямне ишеткәч, Гайканың әтисе башын күтәреп миңа кызыксынып карады.

Аңа хәзер бераз җиңел булып киткәндер... Шундый зур кешенең малае да бу хәлгә төшкәч, үз балаңның гаебе шактый кечерәя бит.

Әни, юан гәүдәсен җиңел йөртергә тырышып, минем иңемнән эләктерде.

— Әйдә, әйдә... Тизрәк, башым әйләнә, укшыйм... — Аннары ул зәһәрләнеп капитанга ысылдады: — Бер гөнаһсыз сабыйны каталажкада тоткан өчен җавап бирерсез!

Мин, Гайка белән Боксерга сизелер-сизелмәс кенә ым кагып, әни белән ишеккә атладым.

Гайка әтисе янәшәсендә бетеренеп басып калды, Боксер миңа иярде.

## IV. Эрнест Гайфетдинович

Төн уртасы узгач, Гөлләндәм ханым телефонга ябышты. Үзенең куллары калтырый, күзеннән яшь ага.

Эрнест Гайфетдинович исә, кулын артка кушырып, тәрәзәдән ишегалдына карап тора. Тик анда җан иясе күренми. Көне буе подъезд төбендә утырган әби-апалар күптән өйләренә кереп инде җиденче төшләрен күрәләрдер. Ярты төнгә кадәр шаулашкан яшь-җилкенчәкләр дә үз ояларына таралган. Ә Гайнан күренми... Болай соңга калганы юк иде бит малайның. Эрнест үз улына ышана иде, аның белән тиң итеп сөйләшә, сердәш булырга тырыша. Уйлавынча, шундый мөнәсәбәт белән генә яшь буынны кыңгыр эшләрдән саклап калып була иде.

Әйе, Гайнанның күчеш чоры. Андый чакта проблемалар туууы мөмкин... Ышана: алары гына хәл ителер, Гайнан акыллы малай. Берәр афәт кенә булмасын, аяныч очраклылык. Шуннан өркү йөрәкне сызлатып тора... Соңгы вакытларда җәсәдендәге нindидер хәлсезлек изә иде Эрнест Гайфетдиновичны.

Ишек төбендә Гөлләндәмнең ачыргаланып кычкырганы ишетелә:

— Нәҗип! Нәҗип, бүген син күрмәдеңмени Гайнанны? Нинди малайлар? Безнең микрорайондагы?.. — Төрепкә, чокырына төшеп чинап куйгандай булды. — Эрнест! Гайнан нindидер урам малайлары белән... э-э-э...

Инде чылтыратмаган җир калмады: хастаханәләр, Гайнанны азмы-күпме белгән яшьтәшләре, морг, милиция... Милициядән үзләре чылтыраттылар...

— Сезнең нәрсә анда гел занято, — диде бер ир кеше тавышы. — Капитан Зыятдинов... Сәйфетдинов Гайнан сезнең улыгызмы?

— Әйе, әйе... — диде миңгерәүләнгән Гөлләндәм. — Нигә сездә ул?

— Борчылмагыз, вак хулиганлык кына... Иртән килеп алыгыз.

— Хәзер ярамыймы? Хәзер, хәзер үк, — дип өзгәләнде бичара ана.

— Борчылмагыз сез... Бераз сабак алсын улыгыз, — диде капитан.

Андый чакта ата-ананың хәлен кем аңласын... Сабак, имеш, төрле җинаятьчеләр, наркоманнар арасындамы?

— Ай-яй-яй... — Гөлләндәм учлары белән башын кысып чәрелди башлады. Истерика. — Син генә бездың баланы, янәсе, ата була белмәдең, тавыш күтәргәнең булмады, гел мактау: безнең Гайнан талант, безнең Гайнан фәлән. Әнә мактаулы малаең төрмәдә! Ата кеше үз оланын ара-тирә каеш белән дә тәрбияләргә тиеш.

— Чыгырдан чыкма әле, зинһар... — Эрнест диванга килеп утырды. Йөрәге еш-еш кага иде, маңгаена салкын тир бәреп чыкты. — Борчылмагыз, диде бит милиция. Берәр ялгышудыр. Гайнанга ышанам мин...

— Ышан, ышан... Яхшылыкның кадерен белми ул тәре малай. Без аңа үз авызыбыздан өзеп... И-и, Ходаем...

Хатынының гасабилануы нервыга тия иде, Эрнест җыена башлады. Милиция бүлеге алардан шактый ерактa, җәяүләп барсаң, нәкъ иртәнге сәгатьләрдә барып җитәсең...

Гөлләндәм дә сикереп торды:

— Мин дә синең белән барам.

Юл буе тагын аның ачыргалануын тыңларгамы? Мон-

дый перспективадан Эрнестның хәтта башы әйләнеп китте, тәрәзәләр канәгать төстә учларын уа шикелле тоелды.

— Юк, — диде ул каты гына. — Син бармыйсың... Гайнанга болай да авырдыр... Ә син, аңа ташланып, күңелендә мәңгелек җәрәхәт калдыруың бар.

Гөлләндәм иренең холкын белә иде: юаш, җебегән булып күренсә дә үҗәт, чуаш кебек киребеткән ул. Шуңа күрә:

— И-и, хәсрәт педагог, — диюдән узмады.

Эрнест Гайфетдинович күзлеген төзәтә-төзәтә урамга чыгып китте. Төнге август һавасы аны бераз тынычландырды. Хәер, таң сызылып килә иде инде. Берән-сәрән тәрәзләрдә утлар кабынган. Сыек таң яктысында алагаем йортлар каралып күренә. Алар фантастик бер гаваньдә бөялеп калган, мәңге шушында бер-берсенә терәлешеп таркалырга хөкем ителгән ниндидер гарип корабларны хәтерләтәләр иде. Күз карашы кая юнәлсә дә, барыбер шул блоклардан корылган соргылт стеналарга барып төртелә, капшана, ирекка юл эзли. Коршау! Ишегалларында төзелештән калган ком-таш өемнәре, төшләрендә дә иркен болыннарны сагынып көн күргән, әле дә үзләренең Үлән булуларын онытмаган сыек, йөткерек кыякларның әллә кайдагы урманнардан килгән җилдә үзара нидер шыбырдавы күңелдә әллә нинди аңлатып булмаслык чарасызлык хисе уята. Меңьеллык болытларны үзенә сеңдергән соры стеналардагы тәрәзә белән томаланган күзәнәкләрдә күпме язмышлар үз эчләренә үзләре йомылган; күпме фаҗигаләр, кайгы, кинә-үчләр, шатлык-сөенечләр, сөешүләр, хыянәтләр, нәни тантаналар бәргәләнә анда...

Стеналарга бәрелеп коелган карашларда нинди иман нуры була алсын, офыкларны күрмәгән күзләрдән ничек табигать сулышы бөркелсен? Күңелләргә кемнәр күчерер Урамнар артында калган яшел болынны?

Арматуралар белән ныгытылып, бетон белән тышланган җанының ярыкларын алебастр белән сылаштырып, барырга да барырга шәһәр читендәге сасы сыек төтен чыгарып яткан чүплеккә кадәр... Тик күңел күзе дип аталган чатнаган пыяланың тузанын сөртергә кем чүпрәк бирер шул юлда?

Кайсыгызның кулы җылы...

Капитан аны нигәдер урыныннан торып каршы алды. Кулын сузганда, үз-үзенә әһәмият бирмәгәндәй, хәтта исемен дә әйтте:

— Нурулла...

Түгәрәк йөзле, соры күзеннән ниндидер җылылык бөркелеп торган әлеге кешенең татар җанлы икәне күренеп тора иде. «Гаҗәп, — дип уйлады Эрнест, — милициядә мондый кешеләр дә бар икән!»

— Мин сезне ишетеп беләм, Эрнест Гайфетдинович, —

диде капитан. — Малаегыз урам төркеменә эләккән. Без моны тәгаен ачыкладык. Үзе гаебен танымый, кәнишне. Ничава, сез борчылмагыз, бераз профилакторий булыр үзенә...

— Ай-һай, — диде Эрнест. — Сезнең учреждение тәрбия мәсьәләсендә бик мактана алмый бит. Хәтта киресенчә... Хәзер Гайнанның да иптәшләре алдында янәсе утырып чыгуы белән борын күтәрүе ихтимал. Алар өчен бу романтика бит...

Капитанның дискуссиягә керәсе килми иде, җилкәсен сикертеп куйды:

— Иң зур тәрбия гаиләдә инде...

Ишектән бик затлы киенгән, акшарланган иякләре дерелдәп торган юан гына бер байбичә килеп керде. Капитан үзгәрде. Эрнестка утырып торырга ымлап, бөтен игътибарын әлеге хатынга юнәлтте. Хәер, хәзер Эрнестның игътибары да хәзер аңарда иде. Кайдадыр күргәне бар ич моны. Бергә университетта укымадылар микән... Чалымнары таныш.

— Рәхим итегез, Луиза Максумовна, — диде капитан, тәкәллефсез булырга тырышып.

— Әйтмәгез андый сүзне! — дип, хатын барлык санын җәеп эскәмиягә утырды, кульяулыгын алып күзен сөртте. — На каком основании...

— Улыгыз урам малайлары сугышында кулга алынган, — диде капитан. — Дөресрәге, тоткарланган...

— Немедленно азат итегез!

— Шылтыраттылар инде... — Капитан канәгатьсез генә сыек мыеклы сержантка ымлады. Тегесе иренеп кенә түрдәге коридорга атлады. Уч төбе хәтле генә чыраена мыскыллы елмаю кунган иде. Милициянең үз җәтмәсенә эләккән кешене, кем генә булса да, җиңел генә чыгарып җибәрәсе килми... Шәхси әйберен югалткандай нәүмизләнү кичерә.

Камерадан чыккан кәтүк буйлы үсмернең фамилиясен ишеткәч, Эрнест барысын да аңлады. Ирханның малае бит бу! Ә бу байбичә аның хатыны Луиза...

Бала хәсрәте сайланып килми шул...

Эрнестка күпмедер җиңел булып китте. Әллә кайчан инде юллары аерылган, кайдадыр өстә — болытлар арасында яшәгән авылдашы белән үзенең бер мизгелгә тиңләшеп алуын сизде.

Бер төндә суырылып калган улы белән иртәнге Казан урамнарыннан атлаганда да шул хистән арына алмады.

— Мине йорт турында тотып алдылар, — диде Гайнан.

— Акланма, — диде әтисе. Күзлеген төзәтеп куйды. — Юлдан язып алгансың икән, акланып мескенләнмә...

Гайнан борынын тартты. Сизде атасы: Гайнанга кыен иде, Гайнан үз-үзен ашый иде.

Шактый гына сөйләшмичә бардылар.

— Мин сиңа акыл өйрәтергә җыенмыйм. Син зур инде, үз башың бар... Нәтиҗәне үзең ясарсың...

Гайнан аңа яратмыйча карады. Ул аның шулай җансыз китап сүзе белән сөйләшүен күралмый иде. Нәтиҗәне ясарсың, имеш... Үзең шундый мохиткә эләксәң, ничек сайрар идең икән. Авылда үсүе җиңел ул... Ә монда Филләр, Боксерлар коршавыннан котылып кара...

Фатирга керүгә үк, елаудан шешенеп беткән әнисе, ике нәни йодрыгын күтәреп, начар артисткалар кебек иреннәрен җәеп, Гайнанның өстенә килде:

— Малай актыгы! Хәсрәт... Нәрсә җитми сиңа... Без синең өчен... Тудырдык, үстердек, авыздан өзеп...

— Тудырмаска иде. Гариза бирдем мәллә... — диде Гайнан тупас кына. Әнисе янында тукталып тормыйча кухняга үтепголт-голт краннан гына су эчте.

Гөлләндәм ханым авызын ачкан килеш катып калды. Аннары аңга килеп кухняга ыргылды, йодрыклары белән Гайнанның аркасын дөмбәсли башлады.

— Син... син... — Бүтән вакытта шундый телдәр хатын сүз таба алмый интегә иде.

— Җитте сезгә! — диде Эрнест Гайфетдинович. — Сиңа эшкә китәргә вакыт. Баргач әйтерсең, мин бүген анда бармыйм. Авырып тора, диярсең...

Кинәт юашланып калган хатын, мыш-мыш борынын тарта-тарта, эшкә җыенды.

— Аш суыткычта, җылытып аша, — диде ул чыгып киткәндә. Кемгә мөрәҗәгать иткәне аңлашылмый иде.

— Син йокла, ял ит бераз... — диде Эрнест улына. Үзе иске блокнотын актарып, Ирхан Килдебековның телефон номерын эзләп тапты. Өй телефоны... Шушы микән, үзгәрмәгәнме...

Төрепкәдә саңгырау тавыш ишетелде:

— Слушаю...

Үзе... Ирхан... Ирхан Алиевич...

— Ирхан, исәнме...

— Да... Исәнме. — Тавышта гаҗәпләнү төсмерләре бар иде. Күрәсең, болай гади генә аңа күптән беркемнең дә эндәшкәне юк. — Кем әле бу?

— Эрнест борчый әле сине. Авылдашың... Сәйфетдинов...

Пауза.

— Әйе, Эрнест... Ни йомыш?

— Бүген мине кабул итә алмассың микән, Ирхан...

Пауза.

— Сәгать уникегә кил. Төшке ашка кадәр сөйләшеп алырбыз. — Төрепкәдә кыска-кыска гудоклар ишетелде.

Телефонга карап шактый утырды Эрнест... Уйлары әллә

нинди буталчык иде. Нигә чылтыратты ул Ирханга? Үз иңенә төшкән йөкне аның белән бүлешмәкче була мәллә... Хәсрәт бит уртак... Бәлки, югарыдагы түрәләргә мондый гына хәлләр вак-төяк булып тоеладыр... Алар бит гади кешеләргә охшамаган, мөгаен... Бер өстәлгә сугар да, ефәккә әйләнер малае... мөмкинлекләре зур... Эрнест исе кешеләр белән киңәш-табыш итеп утырамы инде ул... Син белгән, бергә уйнап үскән Ирхан юк бит хәзер, иптәш Килдебеков анда.

Дөрес, урыннарыннан төшкәч, алар синең кебек, минем кебек кешегә әвереләләр яңадан. Бүтәннәрнең тезләрен дерелдәргә мәҗбүр иткән тылсымлы көчләре каядыр эреп юкка чыга. Бөкреләре чыга, ыштан төпләре бушый... Шулай булмыйни — гади кешеләр тормышыннан тәмам бизгән, ялагай карашларда коенырга өйрәнгән олпат зат гадәти көндәлек мәшәкатьләр эчендә калсын әле...

Килдебековлар — дистә еллар буена авылны үз кулларында тотып торган нәсел... Ирханның ерак бабасы йомышлы морза булган, дип сөйли иде картлар. Шул морза, кайдандыр Темников якларыннан килеп, авылга нигез салган да бугай инде. Ә Эрнестның бабалары гомер-гомергә муллامунтагай булып тамак туйдырган. Шуңа исемнәре дә чын мөселманча — Сәйфетдин дә Гайфетдин... Эрнестның укытучы әтисе исә, совет властена карата мөнәсәбәтендә шикләнмәсеннәр өчен, улына шундый исем кушкан. Эрнест Тельман хөрмәтенә булса кирәк. Файдасы тимәгән барыбер... Утыз тугызынчы елны алып киткәннәр. Алатыр төрмәсендә үлгән, дип сөйли иде әнисе... Сталинга каршы халыкны котырта, дип яла якканнар. Ирханның авыл советында сәркәтип булып эшләүче әтисенең кулы уйнаган, имеш. Булыр да... Ул вакытта авыл советына фәлән кадәр халык дошманын фаш итәргә дип разнарядка килеп төшкән бит. Халык дошманы булырга мәхдүм мач килеп тора инде. Бер ай элек кенә туып, бишектә акырып яткан малаемның исеме Эрнест дип котыла алмыйсың...

Утызынчы елларда туып, чит-ят исемнәр йөрткән кешеләрне барласаң, бер дә шикләнмә — аталары укытучы, бабалары мулла булыр... И-и, татарның наивлыгы, аумакайлыгы...

Чыгып китәр алдыннан Эрнест диванда яткан улы янына килде. Гайнан йоклый иде. Аягын бөкләп тезләрен иягенә үк китергән... Менә ул авызын чапылдатып алды. Бөтен җәсәденә тулган яратуны чайпалдырасы килмәгәндәй, ата ирене белән сак кына улының чәчләренә кагылды. Чәчтән әллә нинди әчкелтем төрмә исе килә иде.

Эрнест, көрсенеп, өйдән чыгып китте.

...Зур йортның ишеге төбендә аны яшь кенә лейтенант туктатты. Каушамаска тырышып, Эрнест Гайфетдинович:

— Мин Килдебековка, — диде. — Очрашу билгеләнгән.
Милиционер аңа каш астыннан гына сынап карады:
— Партбилет?
— Мин партийный түгел... Сезгә әйткән булырга тиешләр...
Лейтенант, тычкан күзләрен кыса төшеп, алдындагы кәгазьләрен актарды, кайдадыр чылтыратып алды. Аннары ризасыз кыяфәттә Эрнест Гайфетдиновичка пропуск сузды.
— Лифтка үтегез, — диде.
Таеп егылмыйм дигәндәй, мәрмәр идәннән сак кына атлап, Эрнест лифтка таба юнәлде. Лифт аны зур түрәгә әверелгән авылдашы янына өскә алып китте.
Дулкынлануын басарга теләп, Эрнест тамагын кыргалады, күзлеген төзәтте, гасаби куллары галстук төененнән алып чалбар изүенә кадәр киемен тикшереп чыкты. Барысы да тәртиптә бугай...
Секретарь зур ишектән кертеп җибәргәч тә алагаем иркен кабинет бусагасында таптанып калды Эрнест Гайфетдинович.
Түрдә — әллә кайда озын өстәл артында — Ирхан Алиевич Килдебеков нидер язып утыра иде. Беравыктан ул башын күтәреп карады да кулын изәде:
— Үт әйдә, үт...
Аңа таба шактый озак барды Эрнест. Килдебеков урыныннан тормыйча гына каршыдагы урындыкка ымлады:
— Утыр.
Эрнест, авылдашына кул сузарга кыенсынып, күрсәтелгән урындыкка чүмәште.
— Исәнме... сез...
— Хәлләрең ничек, Эрнест? Күптән күрешкән юк, эш тә эш менә... — дип гади генә сүз башлады түрә.
— Зарланган юк иде дә моңарчы...
— Фатир алгансың икән, котлыйм. Һәркемнең үз түбәсе булырга тиеш бу дөньяда... авылга кайтканың бармы соң?
Эрнест, авылдашының хәбәрдарлыгына шаккатып, башын селеккәләде:
— Рәхмәт, рәхмәт... Авылга кайтып йөрергә тырышам болай... Синең кайтмаганыңа шактый була бугай... Вакыт юктыр инде...
Килдебеков кулын җәеп җибәрде, эш чабудан тотып тора, янәсе.
— Иҗтимагый үзәк оештыргансыз икән, — диде ул бераз тынлыктан соң... — Татар теленең язмышы өчен борчыласыз... Похвально, похвально... Ә үзегез аббревиатурасын урысча атыйсыз — ТОЦ!
— Татарча сәеррәк яңгырый бит... — Эрнест урынында кыбырсынып куйды. — ТИҮ... Мескенрәк, димме...

— Психологик уровеньда без телдән читләшкән шул... — Килдебеков урыныннан торды, стена кырында торган кечкенә өстәл янына Эрнестны әйдәде. — Балабызга исем кушканда да без бит иң элек аның урысча ничек звучаниесен уйлыйбыз. Комплекс неполноценности...

— Менә шул комплексны бетерер өчен үзебезнең үзәк кирәк тә инде, — диде Эрнест, дәртләнеп китеп...

— Да, да... Сездә комплекс житәрлек, — дип, Килдебеков мыскыллы елмайды. — Күбегез партия тарихчылары... Фән кандидатлары, понимаете ли... Генсек алмашкан саен дәреслекләрне үзгәртеп язучылар...

— Милли хисне изеп тордылар бит... — Эрнест ни диярга дә аптыраган иде. — Милләтне бит упкын көтә иде...

Ишек тавышсыз гына ачылып китте дә төз аяклы чибәр кыз чәй кертте.

— Нигә «иде» дисең? Берәр нәрсәне үзгәртә алырбыз дип уйлыйсыңмыни? — Килдебеков көлеп куйды. — Конечно, политикага катнашым бар дип уйлау үз-үзең алдында дәрәжәне күтәрә. Син бер пылинка гына түгел, якобы...

Эрнест гажәпләнеп кашларын сикертте. Аңардан көлеп утыра түгелме соң бу иптәш Килдебеков.

— Тарих тәгәрмәче безнең катнашсыз гына әйләнә ул... Әнә Розанов урысларның атаклы соравына ни дип җавап биргән? Әйдә, әйдә, эч чәеңне...

Бераздан Килдебеков кулындагы сәгатенә күз төшереп алды.

— Вакытыңны алдым, — дип, Эрнест урыныннан күтәрелә башлады. Түрә, кулын селкеп, аңа утырырга кушты.

— Йә, нинди проблемаң бар?

— Киңәшим, дидем... — Эрнест каушады. — Малай начар компаниягә эләккән минем. Бүген иртән милициядән алып чыктым.

Килдебеков аңа сынап карады. Үтәдән-үтә күрә кебек иде ул аны. Аннары сүзләрен сыгып чыгарды:

— Синеке минем малай белән танышмы?

Эрнест башын селекте.

Ирхан урыныннан торып кабинеты буйлап йөренә башлады. Гажәп, дип уйлады Эрнест, ары-бире йөреп торсаң әйбәтрәк уйланыла микән әллә?

— Язгы ташу вакытында Иске йорт тавына менгәнне хәтерлисеңме? — диде Ирхан, көтмәгәндә. — Яңа чирәм шытканы ишетелә, ә тау түбәсендә кар әле эремәгән дә... Яз һавасы. Бозлар актарылып ага... Без аларга учаклар ягып җибәрә идек, хәтерлисеңме?

— Хәтерләмәскә... — диде Эрнест, ничектер авылча гына.

— Малаең ничәнче класста?

— Тугызга керә...

— Иртәгә үк авылга кайтарып җибәрергә кирәк шельмаларны, — диде Ирхан. — Тугызны шунда укысыннар. Синең анда энең бар бит әле? Иң зур тәрбия — мажик хезмәте... Иртәгә үк! Мин бүген позвоню... — Ул урыныннан күтәрелеп Эрнестның кулын кысты. Яңа гына арада яткан үткел өстенә басма салынган сыман иде...

Ирхан аны ишеккә кадәр озата барды.

— Җәен җиләк җыярга, ә кышын, тәрәзәдән карап, шуның вареньесын ашап ятарга кирәк, дигән ул.

— Кем? — Бу кадәр тәэсирләрдән аңгыраеп калган иде Эрнест.

— Розанов! — диде Килдебеков.

## V. Мин – Гайнан

Әти авылга җибәрә, мәтәлеп китим! Менә бит язмыш дигәннәре, андагы әби әйтмешли, куласа — әйләнә дә бер баса. Әбине яратам мин, аңардан гел шундый хикмәтле сүзләр коелып кына тора. Мондагы кайбер акыллы башлар кебек ул аларны махсус да әйтми, үзеннән-үзе шулай килеп чыга. Табигыйлек... Меңәр ел халык телендә чарланган ул сүзләр шулкадәр табигыйләнгән, аларга артык игътибар итүче дә юк... Әгәр дә шул сүзләрне әби Шопенгауэр әйтмешли, Сенека фикеренчә, дип сипләп барса, аны шунда ук Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы итеп сайларлар иде.

Хе-хе, сайларлар, пычагым. Чын философларны анда кем сайласын... Анда бөтенләй бүтән халык...

Миңамы соң бу турыда баш ватарга? Авылга сөрәләр хулиганны! Бабасының утары Кокушкинога сөрелгән яшь Ульянов кебек сизәм үземне... Ул да хулиган булып, университетта буза куптарып йөргән түгелме соң? Уйлап баксаң, сәләмә киенеп, кулга арматур таягы тотып сугышып йөрү үзе үк социаль протест бит инде ул.

Җәмгыятьтәге туклыкка, битарафлыкка, череп таркалган өлкәннәргә каршы протест, шайтан алгыры!

Менә бит, һәрнәрсәне зур сүзләр белән аклап була, хаха... Югыйсә мин эчтән беләм — әтрәк-әләм төркеменә иярергә берниндә протест та түгел, ә Филләрдән курку мәҗбүр итте. Шулай-шулай, курку батырайта кешене...

Мин әтинең энесе Сәфәр абыйларда торып, авыл мәктәбендә укуны дәвам итәргә тиешмен. Дөресен әйтим, мин моңа бер дә борчылмадым. Төгем дә селкенмәде. Авылны яратам мин чөнки... Әти дә, әни дә авылдан, шуңа миннән чыгып бетмәгән әле ул авыллык. Ел саен мин анда кайтып йөрим, малайлары-кызлары белән таныш. Дәрәҗә дә шактый —

ни дисәң дә «шәһәр егете»нә караш бөтенләй бүтән. Сәфәр абый да җайлы, ипле кеше, юкка кыерсытмас, җиңги дә тәмле телле, ачык чырайлы... Мин кайтып тора башлагач та кыек сүз чыгармас, ә эчендәге уйлары миңа нигә кирәк? Аннары мин мал-туар арасында кайнашырга яратам, ант менә...

...Әти ул көнне кайдандыр кайтып керде дә залга узды. Мин телевизордан «В мире животных» тапшыруын карап ята идем. Анда арысланнар турында күрсәтәләр иде. Арысланнар гел көтү белән йөриләр икән, вәт әкәмәт... Ялгыз арыслан күрсәгез, белеп торыгыз — ул көтүдән куылган һәм аның көннәре санаулы... Тик үзегез аңа күренмәскә тырышыгыз.

Шулай да ялгызаклар күңелгә якынрак никтер... Мин көтүдә йөреп карадым инде.

Әти бер сүз әйтми-нитми генә телевизорны сүндерде дә яныма килеп утырды. Гаҗәп, ул мондый тапшыруларны ярата иде югыйсә. Димәк, җитди сүзе бар... Үгет-нәсихәт укыр микәнни...

— Син инде зур малай... Мине аңларсың, — диде ул, көрсенеп... Кучкылланып торган яңагын ышкып алды. Яхшы кырынмаган — ара-тирә төкләр тырпаеп тора. «Нева» лезвиесе шундый инде ул. Әти миңа карады, күзлек пыяласы аша күзләре шундый чарасыз, нарасыйларча күренде, елыйсым килеп китте. Ай, якын ул миңа...

Әтием! Әтием...

— Мин сине авылга җибәрергә уйладым, — диде ул.

— Кайтып килермен, — дидем мин, шатланып...

— Тугызынчыны шунда укырсың... Сәфәр абыеңда торып... Телефоннан сөйләштек, ул риза булды. — Ул минем җилкәдән какты. — Анда эш күп, юк-бар уйларың көзге яфрак кебек коелыр да бетәр...

Әлеге яңа хәбәрне сеңдерер өчен миңа бераз пауза кирәк иде.

Әти салмак кына сүзен дәвам итте:

— Сиңа хәзер мохитне алмаштырырга кирәк. Юлдан язган дусларыңнан арынырга... — Аннары ул кыска гына көлеп куйды, күзлеген төзәтте. — Авылга сөрелүче син генә түгел әле. Синең белән каталажкада яткан Килдебеков та авылга кайтачак. Аның әтисе белән без бер авылдан бит. Обкомда зур кеше...

— Нинди Килдебеков? — дип сорадым мин, аптырап.

— Иптәшләреңнең фамилиясен дә белмисең мәллә? Исеме ничек соң әле... Фәнил...

Күзләремнең маңгайга таба шуышканын тоеп алдым. Филнең үз исеме Фәнил икәнен мин белә идем инде.

Менә сиңа мә! Ишетмәсәң ишет, урман асты кишет, дип әйтә әби андый чакта. Фил нининдидер бер партийный босс-

ның улы, имеш... һай-һай-һай... Шул башы белән җыен урам малае арасында алак-шалак йөрсен әле. Нәрсә җитмәгән? Аның атасы кебекләр, белүемчә, безнең ише микрорайоннарда да тормыйлар. Үзәктән килеп йөри микәнни? Мондагылар белән ниндидер җепләр бәйли торгандыр, күрәсең... Түрә малайларының да үз җеннәре, үз капризлары була торгандыр инде. Әллә романтика эзләп йөриме, ахмак... Бәлки, үз эшләре читкә кагадыр, ә бу Боксерлар, Серыйлар арасында үзен шәхес итеп хис итәдер...

Юк, минем башка сыймый... Кайда, кайчан бүре баласының эткә әйләнгәне бар? Дөрес, этисе минем эти белән авылдаш икән... Әллә кайдан күктән төшмәгән... Бәлки, ул мондагы саяк-сандырак арасында үз асылын тапкандыр. Шулай да сәер, ул бит инде высший светны күргән, Боровое Матюшино һавасын иснәгән... Хәер, шуңа күрә безнең арада үзен шулай хан кебек тотадыр да әле ул... Без кем аңа? Бөҗәк...

Менә аны да атасы авылга сөрә икән. Аның белән бер мәктәптә — бер класста әле! — укып йөрү миңа бер дә ошамый иде. Сөендермәде андый киләчәк... Анда да аның йомышчы малае булып йөрергәме? Дөрес, авылда бик иркенәя алмас... Авыл малайларының бук тибеп йөрергә вакытлары юк... Анда гел эш тә эш... Мал астын кара, малга азык бир... Уйнап керим дигәндә инде караңгы төшкән була. Әле бу кыш көне. Ә җәен исә кырыкмаса кырык мәшәкать... Көзен мәктәпкә кергәч тә укучыларны бәрәңге җыярга, аннары чөгендер чыгарырга алып китәчәкләр. Хәчтерүш кенә, арык кына Фил ничек чыдар икән шунда, карарбыз... Качып китәр ул... Андыйлар гадәттә йомшак буынлы була. Сарыклар арасында гына арыслан булып кылана бит алар.

— Сәнгать мәктәбеннән аерылуың кызганыч, әлбәттә, — диде эти.

Әйтте сүз! Миңа калса, шуның өчен генә булса да, башыңны алып авылга олагуың яхшы. Киндер пычратудан котылам, ниһаять.

Эти үз-үзен юатып әйтеп куйды:

— Хәер, авылда туып-үсеп тә зур рәссам булучылар бар... табигатькә якын булу рәссамның җанын баета гына. Гомерлеккә китмисең бит... Мәсәлән, Бакый Урманче... — Ул яраткан темасына кереп китәргә чамалый иде.

— Алла белә, — дидем мин, башымны тилегә салып. — Бәлкем, гомерлеккә дә калырмын әле. Авылны яратам мин... Ат караучы буласым килә. Конюх...

Эти миңа сәерсенеп карап куйды. Шаярып утыруымны аңлады тагын:

— Бик әйбәт һөнәр... Тик бездә ат фермасы бармы соң?.. Бетерәләр бит атларны, тамырларын корыталар...

— Бар әле, бар. Бакау әбзәй карый анда атларны. Мәктәпне тәмамлагач, шуны алмаштырам. Ул инде күптән пенсиядә...

— Хе-хе-хе... — Әти күңелсез генә көлде. — Ат янына килергә йөрәгең җитәр микән? Монда тел шомартып утыру түгел ул.

— Узган җәйдә әллә ничә кат ат сакларга бардым мин төнлә, — дип мактандым мин... — Малайлар белән атта күпме узыштык.

— Шулай да рәсем ясавыңны онытып җибәрмә, — дип, әти башымнан сыйпады. Кулын алып ата яздым, сабый мәллә мин, валлаһи.

— Рәсем ясау кайгысы булмас анда, — дидем мин, дорфа гына.

— Биби әби борынын беләсең бит, шуны акварель белән язып кайт әле... Мин аны кабинетыма элеп куяр идем...

(Хәзер аның кабинеты бар! Дөрес, ул йокы бүлмәсе дә...)

Биби әби борынын белмәскә... Киң ерганакка борын сыман кереп торган бер җир шунда. Чирәмлек. Атларны без шунда алып бара идек. Тик аның ниен язасың? Күз карашын иркәләрлек сыңар куак та юк анда...

Боларны әтигә әйтеп тормадым инде. Кәефен бозасым килмәде. Ни ары, ни бире сөйләшеп утыруым өчен дә үз-үземә ачуым килде. Кабахәтлек инде, әлбәттә. Ул бит минем өчен кайгыра, миңа яхшылык, игелек кенә тели бит ул!

Хыяллансын әйдә рәхәтләнеп. Улын бөек рәссам итеп күрсен төшләрендә. Аннан кемгә зыян?

Шулай да хәсрәт рәссам булганчы, оста ат караучы булуың мең мәртәбә артык. Дөрес, безнең илдә чыпчык борыны кадәр талантың булмаган килеш тә исем-дәрәҗәләр алып була. Беләм мин шундый бер рәссамны. Республиканың иң атаклы портретисты санала. Атказанган дигән исемнәре бар, әле быел гына халык рәссамы дигән исем бирделәр. Халык бирмәгән инде ул исемне, әлбәттә, ниндидер нәчәлникләр биргән. Бәлки, шул ук Филнең әтисе биргәндер әле. Алар шулай халык исеменнән сөйләргә, халык исеменнән бәяләргә яраталар.

Иң гаҗәбе — рәссам Ленинградтагы Репин исемендәге сәнгать институтында укыган. О-һо-һо... Соңыннан миңа кемдер әйтте, аларны анда милли кадрлар дип разнарядка белән кабул итәләр икән...

Ә абзыйның портретлары күп... Кемнәрне генә ясамаган ул — шагыйрьләрне дә, галимнәрне дә, эшче-крестьянны да, обком секретарен да... Барысы да портретистның үзенә охшаган. Чөнки андый кыяфәтне ясавы җиңел: киң чырай, кечкенә күз, алагаем зур авыз...

һәркемнән үз чалымнарыңны табу өчен дә сәләт кирәк, мөгаен. Ниндидер яңа агым булырга мөмкин әле бу сәнгатьтә... Зерә генә өстәге агайлар әлеге рәсемченең күкрәгеннән калай белән тутырмаганнардыр.

Кемнеңдер затсыз чыраен киндергә күчереп азаплану белән ат өстендә җил иркенә ыргылуны чагыштырып буламыни?!

И-их...

Һәрбер әти кеше, баласының киләчәге хакында уйлаганда, бераз аңгырая, мөгаен...

Икенче көнне иртүк әти мине вокзалга алып китте. Әни озатып калды.

— Анда, — диде ул, акрын гына, — син теге түрә малаеннан читтәрәк йөр. Андыйларны авыл да, чурт та төзәтә алмый. Авылның үзен юлдан яздырып килер әле ул йөзе кара...

— Нигә алай дисең? — дип, әти аңа каршы төште. — Әйбәт кеше баласы, яхшы нәселдән...

— Мокыт булма! — диде әни, зәһәр генә. — Шуның атасы төрмәгә тыккан түгелме соң атаңны... Яхшы нәсел!

Әти кулын гына селтәде. «Әллә кайчангыны...» — дип мыгырдады.

— Тарих кабатлана ул...

Әнинең шул сүзе колагымда гел яңгырап торачак әле. Кабатлана, кабатлана. Һәм бөтенләй яңа бизрәлар хасил итеп, сине дә үзенә бөтереп ала. Чыга алмыйсың шул коршаудан!

Канашка китә торган кызыл поезд беренче юлга килеп баскан иде инде. Менә ул сыер сыман мөгрәп алыр да, акрын гына кузгалып китәр сыман... Авылга мин гел шушы поездга утырып кайтам. Тиздән аңа чуашлар кереп тулар. Поезд исә төрле төшләрдә туктый-туктый, юлда очраган һәр чуашны утыртып, үшән генә алга сөйрәлер.

— Синең белән кайтып китәр идем... — Әти шакмаклы кулъяулыгын чыгарып тирләгән пеләш маңгаен сөртте. Әллә күзе дә яшьләнгән инде... — Акыллы бул, улым.

Мин вокзал ягына ымладым. Безгә таба, ике кулын кесәсенә тыгып, Фил якынлаша иде. Янәшәсендә күтенә сыланып торган джинсы кигән, кызыл кофтасы аша күкрәкләре тырпаеп торган аксыл чәчле бер кыз атлый. Ә артларыннан, һәрберсе зур авыр чемодан күтәреп, Боксер белән Серый ияргән.

Фил, безнең янга җиткәч, туктады. Әтигә кырын гына күз ташлап алды да:

— Привет, Гайнан, — дип, миңа кул сузды. Аннары, бераз икеләнеп, әти белән дә исәнләште: — Исәнмесез. Фәнил булам... Ә бу... — диде ул, миңа борылып, — сестра моя. Лилия исемле.

Аксыл чәчле, зур кара күзле кызның карашы миңа ка-

гылмыйча гына узып китте. Гүя ул мине искәрмәде дә... Үземне мин тумбочка итеп хис иттем шул чакта.

— Ну, всего хорошего, братик, — дип, ул Филнең иңбашына кагылды. — Не грусти. Все будет о'кей...

Боксер белән Серый чемоданнарны поездга керттеләр.

— Болар сезнең белән кайтамы әллә? — дип сорады әти, шикләнеп.

Фил ирен чите белән генә көлемсерәде:

— Юк, алар озата гына төштеләр.

— Ну, пока, братик, — дип, Лилия энесен үпте дә сынын уйнатып китеп тә барды.

Фил миңа күз кысып алды, менә бит минем апа нинди, янәсе.

Поезд инде кузгала башлады. Без тамбурга сикереп мендек.

— Сау бул, әтием! — дип кычкырдым мин. Авазымны сытып, ишек шапылдап ябылды.

— Кара нинди сентиментальный син! — Фил хахылдап көлеп җибәрде.

Мин, аңа каршы бер сүз дә әйтмичә, букчамны күтәреп вагонга уздым.

Поезд тизлеген арттырды. Артта Кремльнең борынгы диварлары агарып күренә иде.

Алда... Алда ни көтәсен кем белә?

Әлегә поезд тәгәрмәчләренең колакны ертып такылдавы гына ишетелә: авылга! авылга!

## ИЛБӘК

*(Тарихи хикәя)*

Ау уңышлы булды. Илбәкнең күңеле күтәренке иде. Авыз эченнән нindидер җыр да мыгырдап алды әле. Кышкы урман һавасы сулыш юлларын кытыклады. Бөтен тәндә җиңеллек, әйтерсең көне буе урманда җәнлек кумаган. Урман авызына җитәрәк ул адымнарын тизләтә төште... Хуҗасының кәефен сизгән алабай алдан йөгерде. Ике ялчысы артына төшеп атлыйлар. Ау уңышлы булды! Биш куян аттылар, ике төлке эләкте. Ләкин куанычы ау уңышлы булганнан гына түгел иде. Биктимернең йортын күргәч, күңеле тагын алгысынып китте. Анда чырага ут элдергәннәр иде инде. Илбәк иелеп бер уч кар алды да кызышкан битенә куйды. Айбикә инде табын әзерләп йөридер. Битендә эрегән кар, елмаюга әверелеп, якасына тамды. Балачакта ук колак тешләштеләр алар Айбикә белән! Киләсе көзгә бергә бу-

лырлар, Тәңре кушса... Унбишенче кышы бит инде Илбәкнең. Казанның асыл егете ул хәзер.

Илбәкне аяк тавышларыннан танып, лапаста җирән айгыры кешнәп куйды.

Ишегалдында Биктимер аларны көтеп тора иде. Кеш бүреген күзенә үк батырып кигән, кыска тунын җилбәгәй җибәргән, кыска аякларын аерып баскан. Илбәкне күргәч, җәлпәк чыраен тагын да җәеп, ияк очындагы сирәк сакалына кагылып алды.

— Авың уң булган, угълан!

Илбәк, далага томырылырга җыенган яшь колындай, башын өскә чөеп куйды. Аннары ялчыларына борылып әмерен җиткерде:

— Тунагыз!

Ялчылар кара өйгә таба киттеләр. Илбәк Биктимер артыннан ак өйгә борылды. Киез белән тышланган ишекне ачуга, борынга җылы әчкелтем һава килеп бәрелде. Күңелне уйната торган ниндидер үлән исе дә бар иде өй эчендә. Биктимер аның тунын салырга булышты, җәясен, садагын бер читкә алып куйды.

— Бик туңмадыңмы?

— Һе, — дип, Илбәк аңкавыннан горур аваз чыгарды. Ләкин җавап биреп тормады... Бәк улы аз сөйләшергә, күп әйтергә тиеш. Аз сөйләшүдә бөтен зирәклек...

Күзе тиз генә өй эчен айкап алды. Чаршау артында беркем сизмәслек серле чыштырдау бар иде.

— Котлы булсын өегез! — диде Илбәк.

— Түргә уз. — Биктимер кадерле кунакны түрдәге киезгә утыртты, таянырга мендәр куйды. Үзе янәшәдән урын алды.

— Йә, дога кылыйк. — Ул авыз эченнән мыдыр-мыдыр ниндидер дога укыды, Илбәк тә берничә тапкыр «Амин!»ны кабатлап, бергә бит сыпырдылар.

Дәстәрхандагы чуен казаннан тәмле исләр бөркелә иде. Бал чүлмәгенең тышында берничә гәрәбә тамчы Илбәккә күз кыскан кебек тоелды. Биктимер түгәрәк ипине күкрәгенә куеп, үрелеп сөяк саплы пычагын алды: «Бисмиллаһи», — дип пышылдады. Илбәк кан тамырларыннан тагын бер дулкынның йөгереп үткәнен тойды. Монда ул үз! Монда ул ят кеше түгел! Нигәдер егетнең күңеле тулды, күзен нидер әчеттереп алды. Киләчәктә ул әлеге кичне бик еш искә төшерер. Гомеренең иң бәхетле мизгелләре итеп хәтерләр...

Чаршау шыпырт кына ачылды да, савыт-саба күтәреп, Айбикә чыкты. Гәүдәсе уйнаклаган саен, озын толымнары селкенеп, чулпылары чыңлый, кара күзләреннән йолдызларның юеш нурлары коелгандай, иреннәре кызыл күбәләктәй каядыр талпынып-талпынып ала... Бәби итәкле житен

күлмәгенең кыштырдавы Илбәкнең җәсәде аша үтеп, ниндидер татлы авыртыну булып касыгында бөялеп калды... Ул тагын битләре кызышканын тойды. Салкыннан кергәч шулай була инде ул!

Биктимер савытларга буы чыгып торган шурба салды.

— Йә, кунак, ризыгыбыздан җитеш!

Илбәк дертләп куйды. Чаршау селкенде. Күз алдында Айбикәнең сизелер-сизелмәс елмаюы иде әле, колакта чулпы чыңы...

Әмма көне буе ауда йөреп ачыккан икән, күз ачып йомганчы савытны ялт иттерде Илбәк.

Биктимер чүмечкә үрелде.

— Юк, җитте. Тукландым. — Илбәк итәгендәге кызыл тастымал белән авызын сөртте. — Тәмле булды. Айбикәнең кулы сызлаусыз булсын.

Биктимер саран гына көлемсерәде. Аннары, шуны да яшерер өчен, ахрысы, учы белән кара-кучкыл йөзен сыпырып куйды. Шулай да кызын мактаганга күңеле булганы күренеп тора иде.

Элгәре Биктимер Идел якасындагы авылда яши иде. Төбе зур, үзе Казан илендә атаклы бәк иде. Алты-җиде ел элек Хуәдер атлы борадәрен Мәскәү кенәзе яу белән җибәргәч, урыслар аның авылын көлгә әйләндереп үттеләр. Кешеләрен кылычтан үткәрделәр, исән калганнарын кол итеп үзләренә алып киттеләр. Биктимер ул чакта хатыны, нәни кызы Айбикә белән калада кунакта иде. Искәрмәстән килгән яу аны шулай ырусыз калдырды. Иске нигезендә яңадан тамыр җибәрергә үзендә көч таба алмыйча, ул мондагы урман авызына килеп төпләнде... Тик хатыны гына кайгыдан тернәкләнә алмады... Соңрак дошман золымыннан качып котыла алган биш-алты карасы да аңа килеп кушылды. Берничәсе, Тау ягына чыгып, үзләренә кыз да урлап кайтты. Авылы шулай акрынлап ишәеп килә иде. Тик Биктимер элекке һавалы бәк түгел иде инде. Казанга да сирәк килә, гел үзенең яңа авылы тирәсендә генә мыштырдый иде...

Менә хәзер булачак кияве Илбәккә карап күңеле үсенгәндәй итә дә... Аның белән ул да торыр, күтәрелер кебек... Әнә нинди асыл егет булып килә Илбәк! Казан бәге Галимбәкнең улы... Нинди атак, нинди олы эшләр көтә аны... Бәлки, ул Болгар җирен аякка бастырып, урыс явына киртә була алыр? Ул чагында Биктимернең дә бүресе улар иде...

Ә хәзер... дошман күп, ә Казан кешеләре таркау, көнчел... Һәр ыру бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер. Бер учка кем җыя алыр аларны? Илбәкнең атасы Галимбәк белекле, баш-

лы кеше, тик каты куллы түгел... Ил әшенә дә бик күңеле ятмый, күбрәк мәдрәсәдә, китап арасында көне үтә... Китап белән беректереп буламыни Казан кешесен, аларны җыярга тимер йодрык кирәк!

Сарайның кулыннан көч киткәнне сизә Мәскәү — иңсәләрен уйната, кулын як-якка ташлый. Ә анда, Сарайда, хан балалары тәхет өчен бер-берсе белән җан талаша. Ата — улны, ана кызны белми... Ил күз алдында таркалып бара. Әнә Олы Мөхәммәдне тәхеттән Кечесе куып җибәргән, диләр. Казаклыкта йөри икән атаклы Олы Мөхәммәд... Үзенең өч мең кешесе белән урыс җиренә үтеп кергән, имеш. Булыр да, Мәскәү кенәзе Бәчлине үзе тәхеткә утырткан иде бит... Яхшылык җирдә ятмас ятуын... Тик Сарайдагы хан бармак янаса, урыслар әле дә шыр җибәрә. Андагы Кече Мөхәммәд белән ачулышлы булырга теләр микән Бәчли... Сарайның ачуын кузгату ул Казан өстенә яу җибәрү генә түгел. Ул бит һәрвакыт: «Мин белмәдем, мин кушмыйча яу йөргәннәр», — дип аклана ала...

Ә Сарайның Казанда кайгысы юк әле... Аның үзендә эт — баш, сыер — аяк...

Күңелен эзәрлекләгән уйларын эченнән куып чыгарырга теләгәндәй, Биктимер уфылдап куйды. Илбәкнең күзе һаман чаршауда иде. Ирен чите белән генә үзалдына елмаеп куйды Биктимер. Аның уйларында ни эше булсын яшьләрнең... Алар икәүдән-икәү сүз алышырга телиләр, мөгаен.

— Арыгансыңдыр, Илбәк, — диде ул. Урыныннан кузгалганда, сөякләре шыгырдагандай булды. «Картаям», — дип битараф кына уйлады. Беравык үз эчен тыңлап торды... Әрни... Инде бер ел бу әрнү гүя аңардан аерым яши сыман. Җиде төн уртасында учакта кыздырылган ташларны чүпрәккә төреп тә куеп карадылар, чирмеш карты әллә нинди үлән төнәтмәләре эчереп карады — китмәде касыгындагы сызлау... Исән чагында кызны ышанычлы кулга тапшырып калдырырга иде.

— Айбикә, Илбәккә урын түшә... — Биктимер кызарынып утырган Илбәккә борылды: — Мин атларны карап керим әле. Син ята тор...

Биктимер чыгып киткәндә, ишектән ургылып салкын һава керде. Чаршау артыннан Айбикә килеп чыкты, сәкегә урын җәя башлады. Үзе иңбашы аша Илбәккә елмаеп алырга да онытмады.

Илбәк аңа таба бер адым атлап куйды. Кулларын кая куярга белмәде. Куллары аңа шулкадәр комачаулый иде!

— Хәлең ничек соң? — Тавышы нигәдер сыекланып чыкты. Ул тагын кызарды. Бала-чага! Үз-үзенә ачуы килеп тамагын кыргалады.

— Әйбәт, — дип пышылдады Айбикә. Юри пышылдады. Илбәктән көлә мәллә? Күзе көлә инде, ап-ак куллары ул ятасы түшәкне йомшарта.

— Айбикә! — Ул, ниһаять, килеп кәләшенең биленә кулын салды. Айбикә борылды, калку күкрәге Илбәккә кагылып... нидер... нидер... Бер мизгелгә егетнең аңы томаланып алды. Төннеге капланган мунча эче кебек караңгылык басты дөньяны, учакта күзлар гына җемелди иде. Айбикә аның кулына сукты. Үзе челтерәп көлде:

— Ай-яй, бигрәк әрсез син... — Аннары тагын пышылдады: — Чү... Эти керә хәзер, җүләр...

— Көз җитә, — дип мыгырдады Илбәк...

Тышта коры кар өстеннән чана сызгырганы, ат пошкырганы ишетелде.

Айбикәнең йөзе агарып китте.

— Кем йөри төнгә каршы?

— Соңга калган берәр юлчыдыр... — Тунын җилкәсенә салып, Илбәк ишеккә атлады.

— Бүрегеңне ки, җүләр... — Айбикә, аны туктатып, башына бүрек кидерде. Сулышы белән Илбәкнең битен иркәләп алды. — Чыгып йөрмәсәң дә ярый, эти үзе урнаштырыр иде юлчыны...

Тышта кызу-кызу сөйләшеп алдылар. Атлының гади юлчы гына түгеллеген Илбәк аңлаган иде инде.

— Кунакны каршыламасам яхшы булмас, — диде. Айбикә янынннан төн караңгысына чыгарга теләми иде ул. Ләкин күкрәгендәге ялкынны басарга салкын урман һавасын да сулыйсы килде. Иләс-миләс иде күңеле...

Бусагадан атлауга, ишегалдында атасыннан килгән атчабарны күрде.

— Әссәламегаләйкүм, бәк улы, — дип, атчабар, башын иеп, аны сәламләде.

— Вәгаләйкүм әссәлам. — Илбәк түшәк-түшәк кар болытлары арасыннан күзен тырнап чыккан айга карап алды. Нишләп йөри бу атчабар? Казанда нәрсә булган?

Менә сиңа дигәндәй, Биктимер ике кулын җәеп җибәрде. Илбәк чәнечкеле карашын атчабарга төбәде.

— Атаң — Казан бәге — сиңа хәзер үк кирмәнгә кайтырга кушты, — диде атчабар.

— Ни булды?

Атчабар Биктимергә карап алды.

— Ул минем кешем, — диде Илбәк.

— Сарайның куылган ханы Мөхәммәд чирүе белән Казанга якынлаша...

Менә сиңа! Ул арада кара өйдән, күзләрен уа-уа, ялчылары да килеп чыкты.

— Җыеныгыз! — дип кычкырды Илбәк. — Кирмәнгә кайтабыз.

— Мин дә синең белән барам, — диде Биктимер. Аннары үз-үзен төзәтте: — Без...

Аның Айбикәне үзеннән беразга да калдырмавын Илбәк белә иде, әйтерсең аның яшәеш җепләре кызына бәйле. «Әйе, кызы аркасында гына дөньяда яши дә бугай ул», — дип уйлады Илбәк. Үзе, Биктимернең кирмәнгә баруына ризалыгын белдереп, башын селекте. Казанның иртәгә, бәлки, язмышы хәл ителәдер, ничек ул булачак хатынын монда калдырсын? Хәер, Биктимер барыбер мондый чакта караңгы авылда ятмас иде. Андый кеше түгел...

Биктимер өйгә кереп зур толып алып чыкты.

Атчабар арыган атын монда калдырып, чанасына Биктимернең бәләкәй бер йонлач атын җикте. Бәләкәй булса да, барысы да аның чыдам, елгыр икәнен беләләр иде. Узган көзне бәк нугай сәүдәгәреннән аны бер күлмәккә алыштырып алды.

Илбәк белән Айбикә, толыпка уранып, бер чанага утырдылар. Егет, шатланып, аның кулын кысты. Айбикәнең күн бияләй эчендәге кулы дерелдәп киткәндәй булды.

Атлар җиңел генә юыртып киттеләр. Күперенке түшәкләр өстенә сикерә-сикерә, аксыл йөзле ай аларны нindидер әкияти дөньяга озата бара сыман тоелды.

* * *

Бәк сараенда йокламыйлар иде. Сарай каршындагы мәйданда учак яна, кызгылт ут шәүләсе тәрәзләргә төшкән. Егермеләп яугир, учак тирәсенә җыелып, ялкау гына ни турындадыр сөйләшәләр иде. Илбәкне күргәч, алар бөтенләй тынып калды.

Суык иде. Ялчылар ашыгып атларны бәк абзарына алып киттеләр. Илбәк белән Биктимер сарайга таба атлады. Аларга берничә адым калып Айбикә иярде.

— Мин бикә кырына керәм, — диде Айбикә.

— Миннән дә сәлам әйт, — диде Биктимер.

Тәхет бүлмәсенә Илбәк атылып дигәндәй килеп керде. Аның адымнарына тулы гәүдәле Биктимер чак өлгерә иде.

Чикләвек агачыннан сырлап ясалган биек урындыкта утырган Галимбәк, улын күргәч, сүзен бүлеп, нигәдер куллары бер-берсенә ышкып алды.

Илбәк, буйсынып, атасына сәлам бирде дә аның каршына түгәрәк ясап утырган кешеләргә борылды:

— Иминлек телим сезгә, Казан олуглары!

Угъланның шулай көтмәгәндә килеп керүен ошатмаган Шәрәфетдин морза йөзен чытып куйды.

— Йәгез, дога кылыйк, — диде Хәсән сәед.

Барысы да мыдыр-мыдыр килеп битләрен сыпырдылар. Илбәк әтисе янына килеп утырды.

— Ишеткәнсеңдер, улым, яман хәбәрне... — Галимбәк каш астыннан гына каршындагы бәк-морзаларга ымлады. — Менә киңәш-табыш итәбез.

— Без киңәш иткән арада, качак хан кирмәнгә якынлаша! — Ишек төбенә чүмәшкән Биктимер торып басты. — Һәрберегез үз чирүен җыйсын!

Шәрәфетдин морзаның тагын йөзе үзгәрде:

— Синнән киңәш сорамадык! — дип ысылдады ул.

— Арча бәгенә, Чаллы бәгенә хәбәр җибәрдек, — диде Галимбәк. — Тик алар барыбер килеп өлгерә алмас.

— Алар кузгалмаячак та... Йортыбыз таркау... Олуг Мөхәммәд ханга каршы тора алмабыз без... — Хәсән сәед бераз тынып торды. — Үзегезгә мәгълүм, хан аз гына чирүе белән Мәскәү кенәзенең бихисап гаскәрен кыйратып ташлаган. Без аңа каршы тора алмабыз, — дип тагын кабатлады ул.

— Ханның чирүе дә тәмам талкынган, шуңа урыс җирендә калмыйча бу якларга юнәлгән дә инде ул, — дип, Биктимер тагын сүз кыстырды.

— Миңа Тәхет иленнән Кече Мөхәммәд ярлык җибәргән... — Галимбәк кырындагы ярлык савытына ымлады. — Ул качак ханны тар-мар итәргә йә куып җибәрергә боерган... Һич югы, аны кирмәнгә кертмәскә хәлебездән килерме?

— Кирмәннең диварлары иске, чирүебез аз... Каршылык күрсәтсәк, ул безне кырып бетерәчәк. — Шәрәфетдин ни өчендер Илбәккә карап сөйли иде. — Барышлык белән эшне бетерергә кирәк. Минемчә, Олуг Мөхәммәд бездә кышламакчы гына була. Аннары ул тәхетен кайтарырга яңадан Сарайга юнәләчәк... Кече Мөхәммәд бездән ерак... Әнә аның әмерен тыңлаган Мәскәү кенәзе ни хәлдә? Арысланның, яраланып егылса да, өч сарыкны бугазларлык көче кала...

— Син ни әйтерсең, улым? — дип, Галимбәк Илбәккә борылды. Илбәк, тавышы калтыраначагын сизенеп, бераз тын торды.

— Олуг Мөхәммәд хәзер безнең хан түгел, — дип сүз башлады. — Өереннән куылган бүре кебек үз-үзенә өн тапмый йөри ул. Без илебезне ач бүредән сакларга тиеш! Һәр морза үз егетләрен җыйсын. Олуг Мөхәммәднең чирүе өшәнгән... Яу! Сүзем шул.

— Угълан әле яшь... — Хәсән сәед Илбәккә көлемсерәп карады. Илбәкнең аркасы өшеп китте. Сәеднең йортта

дәрәҗәсе зур, аның сүзенә беркем дә каршы килмәячәк. — Иелгән башны кылыч кисми, дигәннәр борынгылар. Килмешәк килер дә китәр, ил-йорт калыр. Аннары... — Сәед кулындагы дисбе төймәләрен тарткалады. — Хан хәзрәтләре безгә килмешәк тә түгел. Үзебезнең мөселман. Йортыбыз аның бабасы Җучи олысында... Һәр мөселманга бабаларның йосунына буйсыну фарыз.

Галимбәкнең яңаклары уйнап алды. Ул инде хәзер сәеднең сүзен җәпли генә ала иде. Яу оранын салса, бу морзалар аның үзен үк кул-аякларын бәйләп ханга тапшырырга мөмкиннәр.

— Мин үзем дә сәед хәзрәтләре фикерендә, — дип, өзек-өзек сөйләп китте Казан бәге. — Олуг Мөхәммәднең нинди җиһангир икәнен беләбез. Шанлы Идегәй морзаның да башына ул җиткән, имеш... Без аны кирмәнгә кертербез... Хан канаты астында булсак, урыс-улак та һәр ел җиребезне таламас, кулын тыяр. Хуәдер кенәзнең алты-җиде ел элекке явыннан һаман мантыганыбыз юк әле... Сүзем шул: Шәрәфетдин морзаны илче-киләче итеп ханга каршы җибәрергә кирәк. Кирмән капкасыннан чыгып без үзебез... аны икмәк тотып каршы алырбыз...

Илбәк урыныннан сикереп торды.

— Кем йортын үз кулы белән ягыга* бирә? — дип кычкырды ул... — Бездән бөтен дөнья көләчәк... Мин ханга каршы яу чыгам!

Ишектән йөгереп чыккан угълан артыннан гыж-гыж сулап Биктимер атлады.

— Узынды угълан, — дип, Шәрәфетдин күз агы белән генә Галимбәккә карап алды.

Бер читтә биш-алты морза үзара ни турындадыр бәхәсләшәләр иде. Хәсән сәед Шәрәфетдингә киңәшләрен бирә башлады. Бөкрәеп чыгып барган Галимбәккә беркем игътибар итмәде.

* * *

Олуг Мөхәммәд чирүе Бишбалта авылы янында туктап калды. Хан, Азман атлы ак аргамагына атланган килеш, калкулыктагы кирмәнгә озак карап торды. Казан кешеләре аңа каршы торырга уйласа, кирмәнне яулавы җиңел булмаячак иде. Ул, ышерен шымчылар җибәреп, Казан олугларын юмалады юмалавын... Шушында, бәлки, аңа яңа йорт корырга язгандыр? Югыйсә күпме куылып йөрергә була... Аңа ияргән ил кимегәннән-кими бара. Ул артына борыл-

---

* *Ягы* — чит кеше, дошман.

ды. Анда аның һәр сүзен үтәргә әзер торган өч угъланы басып тора. Алар артында урыс явыннан исән калган меңләп нөгәр ияргә берегеп үскәндәй тынып калган. Бала-чага, картлар, хатын-кызлар уртада... Ул белә — анда өшеп чирләгән балалар шыңшый, кәмперләр зарлана, картлар мыжгый... Тагын да болай эт типкесендә йөрсәң, шушы илдән дә колак кагуың бар... Ул бит урысларның Кырым чигендәге Биләү каласында кышламакчы иде. Мәскәү кенәзе Бәчли, Кече Мөхәммәд әмерен тыңлап, шул кышлакка һөҗүм итте. Ашаган табагына төкергән нәрсә! Ул — Олуг Мөхәммәд! — бөек кенәз ярлыгы бирмәсә, Мәскәү тәхетен үз колагыдай күрә алмый иде бит Бәчли...

Әле дә хәтерли әле Олуг Мөхәммәд — моннан алты еллар элгәре Бәчли Юрий дәдәсе белән бер-бер артлы, ярлык өмет итеп, аның урдасына килделәр. Башта ул ярлыкны, урысларның үз гадәтләре буенча, яшькә олырак Юрийга бирмәкче иде. Шириннәрнең Тигинәсе дә аны яклый иде. Ул кенәзне, кышларга дип, үзе белән хәтта Кырымга да алып китте. Мәскәү даругасы Миңлебулат шул арада башын бутады ханның. Имеш, Тигинә, һәр урынга үз кешеләрен куеп, фетнә күтәрмәкче була. Һәркемдә мәрхүм Идегәй шәүләсен күргән хан икеләнеп калды шул. Бәчли белән килгән бер баяр тәмле теле белән аны бөтенләй үз якларына аударды. Янәсе, Юрий урыс түрәсе белән бөек кенәз булмакчы, ә Бәчли баш-аягы белән хан ихтыярында. Аның өчен иң зур түрә — хан хөкеме, имеш...

Ярлыкны Бәчли кулына тоттырды Олуг Мөхәммәд. Бөтен бәла шул көннән башланды түгелме соң? Гарьләнгән Тигинә морза чиргә белән Кече Мөхәммәд ягына күчте.

Хәер, кенәз ярлыгы Бәчлинең дәдәсенә эләксә дә Татар илендә ни үзгәрер иде икән? Аксак Тимер явыннан соң ул парча-парча таркалды. Һәр бәк үзен дөньяның кендеге дип саный башлады. Идегәйнең һәр баласы, үзләренә хан сайлап, бәкләр бәге урынын дәгъва итте.

Салмак кына кар төшә. Юл читендәге бәс сарган куаклар ап-ак учаклардай күккә талпынырга җыена төсле. Кар бөртекләре Олуг Мөхәммәднең чал сакалына куна. Ул учы белән Азманның муенына суккалады. Хуҗасының иркәләвен сизгән ат, гәүдәсен дерелдәтеп, пошкырып куйды.

Хан кирмәнгә илче булып киткән Кораиш бәкне көтә иде. Ул инде Галимбәкнең аңа каршы сугышмасын белә. Гази диләр тагын үзен... Янәсе, сугышчы... Бәкләре аерылгач, ул берүзе нишли алсын? Олуг Мөхәммәд үзе дә ничә мәртәбә шундый хәлгә калды...

Үткер күзле Мәхмүд угълан кычкырып җибәрде:
— Әнә, киләләр!

Кирмән ягыннан унлап җайдак бирегә таба җилдерә иде. Кораиш бәккә Казанның илче-keләчеләре дә ияргән. Алар инде хан хозурына якынлашып киләләр иде. Казан кешеләренең атлары аерылып тора — озын торыклылар. Тик Кораиш бәкнең карсак буйлы йонлач дала аты аларга юл бирми, янәшәгә чыккан һәр атны тешләргә маташа иде...

Илчеләр, атларыннан төшеп, ханга сыгындылар.

— Сине Казанда көтәләр, олуг хан, — диде Шәрәфетдин аңа. — Галимбәк капкадан чыгып каршы алачак.

Бабалардан калган йосун буенча, бүрегенә салган солысын бәк хан атына ашатырга тиеш иде.

Олуг Мөхәммәд кәефе килеп янә кирмәнгә — үз Казанына! күз салды. Чү, нәрсә бу? Капкадан егермеләп атлы атылып чыкты. Хан сораулы карашын илчегә төбәде.

— Бәк улы синең белән яулашма кели, — диде Шәрәфетдин, башын иеп. — Башы бозык, анасын эт ялагыры!

Хан Мәхмүд улына сизелер-сизелмәс кенә ишарә ясады. Угълан, нөгәрләре белән, үзләренә таба ыргылган җайдагатларга таба юыртып китте. Кирмән яугирләренең башында җилдергән Илбәкне тере килеш кулга төшерергә боерды Мәхмүдәк...

Тик кирмән яугирләренә килеп җитәрәк нөгәрләр төрле якка сибелеп кача башлады...

«Әһә, шыр җибәрдегезме!» — дип уйлады Илбәк. Яу комарыннан йөрәге бугаз төбендә типте. Ул үзе дә тоташ йөрәккә әверелгән иде!

— Ягы качты! — дип кычкырды ул. Алар үзләре дә таркалып дошманны эзәрлекли башладылар. Илбәк үз алдында көбә кигән җайдакны күреп алды. Хан шушы! Угълан аның аркасына төбәп сөңгесен күтәрде. Тик ыргытырга өлгермәде, затлы җайдак кулындагы арканның сызгыруын гына ишетеп калды.

Ләкин ул җирдән тиз сикереп торды. Маңгае сыдырылган, күзен кан томалый, учы белән шуны сөртә-сөртә, Илбәк тирә-ягына карады. Айбикә кая? Янәшәдә башы чабылган Биктимер гәүдәсе...

Әнә бит Айбикә — җәяү генә монда таба йөгерә. Аны көлә-көлә бер җайдак куа... Әнә ул Айбикәнең баш өстенә кылычын күтәрде.

— Тукта!

Әллә Илбәк кычкырды, әллә аның каршында басып торган көбәле егет...

Айбикә Биктимер гәүдәсенә килеп капланды:

— Әтием!

Аны куып килүче дөмбер чырайлы җайдак аптырап атыннан төште, Айбикәгә якынрак килде:

— Вай, кыз ич бу! — Биленнән арканын алды. — Минеке!

— Тимә! Бире китер... — Мәхмүднең кырыс тавышын ишетеп, яугир ризасыз мыгырдана-мыгырдана, кызны угълан кырына алып килде.

Айбикә елап Илбәккә омтылды.

— Илбәк! Әтиемнең башы юк...

Илбәк, битендәге канлы күз яшен сөртеп, читкә борылды...

Инде яраннары белән хан үзе дә алар янына килеп җиткән иде.

— Егет икәнсең, улым, — дип, ул Мәхмүдне саран гына мактап алды. Ләкин егет аны гүя ишетмәде дә, комсыз күзләре Айбикәне капшый иде.

Олуг Мөхәммәд карашын Илбәккә күчерде.

— Синең кәләшме?

Илбәк башын селекте.

Хан Казандагы бөтен хәлдән хәбәрдар иде. Үз шәһәре! Ул монда ныгыр, канат җәяр, иншалла! Мәскәүне үз кул астына алыр, кенәз, аның борынгы хан агаларына түләгән кебек, яңадан аңа ясак түли башлар. Бераздан бөтен Иделйорт аның кулына күчәр... Кырым, Себер, Харәзем... Олысның элекке шанын кайтарыр ул!

— Чабып үтеримме, атам, бу яманны? — Мәхмүд кылычына тотынды. Хан аны кул ишарәсе белән туктатты.

— Нигә атаңның сүзен тотмыйсың? — дип сорады ул Илбәктән.

Илбәк ияген өскә чөйде:

— Ир-егет йортын сакларга тиеш!

Олуг Мөхәммәд Илбәккә карап бераз уйланып торды.

— Батыр егет син! — диде ул. — Мин сине кичерәм.

Кемдер арттан Илбәкнең җилкәсенә басты, егет ирексездән бер аягы белән карга тезләнде.

— Миңа синең кебек яраннар кирәк. Йөз башы итәм сине... — Аннары хан кыска гына көлеп куйды. — Кәләшеңне дә үзеңә бирәм. Үзем туй агасы булырмын!

— Атам! — дип аваз салды Мәхмүд.

— Колың булырмын, — дип пышылдады Илбәк. Ул ханның киң күңеленә шаккатудан аңгыраеп калган иде. Янына Айбикә килеп тезләнде, Илбәкнең кулын тотты. Ул һаман да эчтән сыктый, тик бу дәһшәтле чынбарлыкны әле аңышып бетми, әтисенең үлеме дә аңына барып җитмәгән иде.

— Бәк килә! — дип кычкырды кемдер.

Илбәк авыр гына артына борылды, мулла-мунтагайларын иярткән Галимбәк, ике кулына солы тутырылган кама бүреген тотып, кирмән капкасыннан чыгып килә иде.

# МӘГАРӘ

Көн кичкә авышкан иде инде. Башка кабарлык эссе сүрелгән, талгын һаваны дулкынландырып бераз гына җил дә исеп куйгандай булды. Әтәй кулындагы тустаганны читкә этәрде. Андагы чәй әле суынып бетмәгән — буы чыгып тора, шул бу белән тирә-юньгә мәтрүшкә исе, тагын әллә нинди әтәй генә белгән үләннәрнең исе таралып, борын эчләрен кытыклый иде.

Әтәй чалгысын кулына тотты, янады, аннары кискен генә селтәнеп печән чаба башлады. Әле генә үзара ни турында-дыр пышылдашып утырган кыяклар каерылып киң пакуска ава барды. Ә-әх! — әтәйнең шат, көчле тавышы бөтен болынны яңгыратты, кайтавазы ерак тауларга бәрелеп кире кайтты, үлән арасындагы чикерткәләр өркеп чык тамчылары сыман тирә-якка сибелеште. Әтәй киң алдырып алга бара, кояшта янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман бер-берсенә таба йөгерә иде.

Мин учны җәеп аның артыннан чабам, печән арасыннан сикергән эре-эре җир җиләкләре учыма төшә, битем, кулларым кып-кызыл җиләккә буялган иде.

Без шулай барабыз да барабыз, сызгырып чалгы чала, кыштырдап печән ава,кояш офыкка тәгәри. Алачык артындагы атыбыз койрыгы белән кигәвеннәрне куа, вәкарь белән генә пошкырып куя. Мавыгып-нитеп бик еракка киткәнмәгез, янәсе. Болын киң,иркен, анау кызгылт офыкка ук барып тоташа.

Күз бәйләнә башлагач, әтәй учак тергезеп калды, мин йөгерә-атлый су буена төшеп киттем. Гөлҗимеш, карлыган куакларын, кураларны ера-ера биек ярга килеп чыктым. Аста кара-кучкыл су ашкынып каядыр ага, мине ымсындырып чакырып тора иде. Мин, чишенеп тә тормыйча, түбәнгә томырылдым, агымсуның кара куе яллары мине урап алды, гөрелтесе уйларымны бүлеп кан тамырларына күчте, астан бәргән чишмәләрнең салкыны йөрәгемне учына алды.

Мин шомланып күккә күз салдым, йолдызлар каядыр югалды, тик яңа туган ай гына сиртмәле бишек төсле чайкала-айкала башлады. Җил чыкты, тыгыз дулкыннар мине ярдан читкә, билгесезлеккә өстерәде. Кулларымны ишкәк кебек ян-якка ташлап, мин ишеп тә карадым, тик еллар сыман аяусыз дулкыннар миннән көчлерәк иде шул.

Үзем төшкән ярга, учак янында калган әтәй янына мәңге кайта алмавымны аңлаудан җаным өшеп, кулларым бәйләнде, аягымны көзән җыерды...

Шул чагында суүсемнәрне ера-ера миңа таба ап-ак сакаллы карт якынлашты. Әкәм-төкәмнәрне, яшькелт бака ефәкләрен таягы белән аралап, акрын гына якынлашты ул миңа. Йа Хода, әллә бу әбием сөйләгән Хозыр Ильяс инде?.. Каршыма килеп баскач, җыерчыкларын җәеп елмайды, йомшак учын маңгаема куйды. «Юлың озак, олан, — диде ул, — әле син күп юлларның тузанын суларсың, хәтфә чирәмнәрнең йомшаклыгын арыган аягың тоеп рәхәтләнер. Көнбатышка карап бар да бар. Юлыңның ахырында син мәгарәгә тап булырсың. Эчтә, мәгарәнең нәкъ түрендә, мәңге яшьлеккә кайтара торган даруның сере язылган. Шул даруны ясап син әтәңә алып кайтырсың».

Мин сөзәк ярда чалкан яткан килеш уянып киттем. Елганың теге ягында кояш инде дилбегә буе өскә менгән, бөтен табигать нурда коена, кошлар сайрый, үлән арасында чикерткәләр черелди.

Кесәмнән ипи телеме чыгарып, чәйни-чәйни туп-туры кояш баешына таба киттем. Урманнар аша үттем, поезд юлларын аркылы чыктым, тузанлы, гаугалы шәһәрләр артта калды. Ниһаять, алда бер калкулык күзгә чалынды. Аның итәгендә ат көтүе утлап йөри иде. Калкулык өстендә чишмә тибеп тора, чишмә янында көтүче егет курай уйный.

— Исәнме, көтүче егет! — дип сәламләдем мин аны. Ул җавап бирмәде, курай уйнавын дәвам итте. Сузынкы, сагышлы моң мине изрәтте, талчыккан аякларны сузып җибәреп, көтүче егет янына утырдым. Курай моңы каядыр дәшә, чакыра, нидер искәртә дә, сагайта да иде шикелле.

Ниһаять, көтүче телгә килде:

— Бу курганда Япанчы батыр күмелгән, — диде ул. — Әнә аның аты. — Ул бармагы белән көтүдән читтәрәк утлап йөргән чем-кара атка төртеп күрсәтте. — Беркемне янына җибәрми, хуҗасын көтә...

Аның сүзләрен ишеткәндәй, кара ат башын өскә чөеп, ялларын офыкка таратып кешнәп җибәрде.

— Ерактан киләсеңме, юлчы?

— Ерактан, Елга үзәненнән...

— Юлың кайларга алып бара?

— Кояш баешына... — Мәгарә турында көтүчегә сөйләп тормадым.

— Анда өлгерерсең әле, — диде ул, көлеп. — Бу җәйгә генә булса да син монда кал, көтү зур, берүземә көтүе читен...

Ул, минем җавапны да көтмәстән, казан асып җибәрде, учакка ут тергезде. Бераздан казанда инде быгырдап куй ите кайный, чәйнектә кыр үләннәре белән кушылган чәй пешә иде.

Икенче көнне, мин уянганда, көтүче егет юк иде инде. Атлар тау итәге буйлап таралган, чыбыркы күтәреп аларны бер урынгарак җыя-җыя көн уртасы җитте. Чишмә янына менеп, учакка ут өстәгәндә, мин бик арыган-талчыккан идем. Нигәдер миңа моңсу булып китте. Теге егеттән калган курайны алып иренемә терәдем. Дөнья сәер авазлар белән тулды. Атлар, утлаудан туктап, башларын миңа таба суздылар. Шунда мин тау итәгеннән менеп баручы бер кызны күрдем. Ул, минем янга туктап, курай уйнавымны тыңлап тора башлады.

Аның зәп-зәңгәр карашыннан кыенсынып китеп, кураемны читкә куйдым. Кыз, иңбашыма орынып ук, янәшәмә чүгәләде.

— Оста уйныйсың...

— Беренче тапкыр курайны тотам әле, — дидем мин, үзем дә гаҗәпләнеп.

— Сиңа ашарга китердем, — диде ул. Тырысыннан бер телем икмәк, әрекмән яфрагына төргән куй итен чыгарды.

Без икәү казан астык, анда куй ите быгырдады, корымлы чәйнектә хуш исле чәй пеште.

— Китмә, — дидем мин. — Монда миңа берүземә гenә күңелсез.

— Исемем — Таңсылу, — дип җавап бирде ул.

— Китмә...

Ул елмайды:

— Ялгызга һәркайда сахра, — диде.

Аста, калкулык итәгендә, Япанчы аргамагы кешнәде, чемкара яллары офыкка таралды.

Кызның иреннәреннән җир җиләге тәме килә иде.

— Без беркайчан аерылышмабыз!

Ул челтерәп көлде.

Күктә йолдызлар сикереште, ниһаять, ул хәлсез юрган сыман безнең өскә сыланды.

Төшемә тагын Хозыр Ильяс керде. Ул инде берни дә эндәшми, таягын гына җиргә бәреп-бәреп куя иде.

Таң алдыннан мин уянып киттем. Таңсылуның чәченнән сыйпадым, алсуланып торган яңакларына учымны тидердем. Ул уянмады.

Кояш күтәрелгәндә, мин бу калкулыктан еракта идем инде. Кайдадыр артта дөпелдәп атлар чабып узды, чыбыркы шартлаган тавыш ишетелде.

Мин елмаеп куйдым. Мәгарәгә кадәр юл ерак иде әле.

Кичкә таба давыл чыкты, күктә яшен уйнады, яңгыр камчылары шашынып җирне кыйнады. Якын-тирәдә бер ышыкланыр төш тә булмаганга, мин яшеннәргә уралып, абынасөртенә гел алга бардым.

Үземнең инде кем булуымны, кайда баруымны, нишләп бу җирләрдә йөрүемне дә аңламаслык хәлгә килгән идем, тәмам эштән чыгып җиргә авам дигәндә, бер таш диварга килеп төртелдем. Сыдырылган, кан саркып торган кулларым белән шул салкын диварга тотынып, капшана-капшана ишек эзли башладым. Ниһаять, ниндидер аждаһа итеп коелган тимер тоткага килеп орындым.

Тимергә тимер бәрелгән тавышны ишеткәч, өстә кемнәрдер шыбырдашып йөгерә башлады.

— Мин — бичара юлчы... — дип ыңгыраштым.

Капкадан ниндидер тимер киемле кешеләр чыгып, мине әчкә өстерәп керттеләр.

Җылы өйдә аңыма килдем.

— Баллап, кайнаган сөт эчерегез, — диде бер калын, тупас тавыш.

— Тыңлыйм, морзам, — дип, кемдер аңа җавап бирде.

Бер атнадан мин аякка бастым. Монда ниндидер сәер, кырыс кешеләр кала диварларын ныгытып яталар иде. Мине таш ташырга куйдылар.

Без көне буе диварга таш өябез, ә иртән ул нәкъ элеккеге биеклектә була... Шулай да миңа монда ошады. Ташчылар аз сөйләшә, сорау биреп интектерүче юк, җилкәгә таш салып, үз эчеңә бикләнеп йөрисең дә йөрисең... Дөресен әйткәндә, каядыр барып мәгарә эзлисе дә килми башлады. Мин ул мәгарә турында онытгым да, ахрысы... Көн артыннан көн уза, һәм гаҗәп — син аны сизмисең дә. Бу каланы Вакыт бөтенләй читләтеп уза иде бугай.

Беркөнне мин нәрсәгәдер абынып егылдым, иңемдәге авыр таш тәгәрәп китте. Әллә дәрманым беткән, әллә болай тиз генә торасы итмәдем — озак кына яткач, урам ташының уентыгында җыелып торган суга күзем төште. Калада көзге бөтенләй юк, шуңа минем үз кыяфәтемне күптән күргәнем юк иде. Мин суга карадым, ә аннан миңа чал сакаллы, җитү чәчле бер карт карап тора иде! Һәм ул карт мин идем, ахрысы.

Урам уртасында язмышым ташы аунап калды, мин, чайкала-чайкала атлап, кала капкасына таба киттем. Сәер хәл — беркем дә туктатмады! Гүя мин юк, мине беркем күрми, алар барысы да үз мәшәкате белән мәшгуль. Таш ташыйлар, диварны ныгыталар... Мин шулчакта гына зәгыйфь күзләрем белән шәйләп алдым: бу каланы дошман инде күптән алган икән ич — Зур Манарада алар байрагы җилферди! Ул бик өстә, дивар ныгытучылар аны күрми, аларның каерылып күккә карарга вакытлары юк...

Таулар арасында мәгарәнең авызы ерактан каралып күренә иде. Килеп кергәч тә нindidер сөрсегән, күкшегән ис — караусыз картларның ятагыннан гадәттә шундый ис килә — борынга килеп бәрелде. Мин тизрәк түргә ашыктым. Андагы юешләнеп торган стенага чүкеп нидер язылган иде. Әллә күзләрем тәмам чепиләнгән, әллә вакыт җиле әлеге язуларны тәмам ашаган, әллә мин бу хәрефләрне бөтенләй танымыйм — бернәрсә дә укый алмадым! Яшьлеккә кайтара торган дару! Тик мин аны ничек ясыйм? Миңа бик кирәк иде бит ул... Кипшенгән кулларым өметсезләнеп дымсу ташны капшады, мин түзмәдем, тавышсыз гына сулкылдадым.

Иртән мине бизгәк тота иде инде. Калтырыйм, тешемтешкә тими. Мәгарә дивары бер ерагая, бер убылып өстемә килә. Шул вакытта язуы да ачык укыла сыман... Бер почмакта аунаган өч аяклы нәни казанны алып килдем — ул борынгы илтәбәрнеке иде! — аңа стенадан саркыган суны җыеп салдым. Әлеге бәллүр суга кесәмнән алып имән кайрысы салдым — безнең як имәненнән! Олтанымнан коры тузан җыеп сиптем — безнең юлның тузаны! Учак җылысыннанмы, әллә дулкынлануданмы, мин шулкадәр эсселәгән идем, маңгай тире тып-тып итеп казанга тамды. Мәгарә уртасында таралып үскән сары чәчәкне өзеп, мин шулар өстенә ташладым. Тик бу дару түгел иде әле. Мин чарасыз калып учак янына чүктем. Күземнән яшь сытылып чыкты да кайнап торган шул сихри измәгә төште. Казан эчендә нидер чытлады, өскә таба яшел ялкын суырылып күтәрелә башлады.

Мин, шул казанны күкрәгемә алып, кайтыр юлга чыктым.

...Көн кичкә авышкан иде инде. Башка кабарлык эссе сүрелгән, талгын һаваны дулкынландырып бераз гына җил дә исеп куйгандай булды.

Теге ярда бер ир-ат чалгысын кулга алды, янады, анна-

ры, кискен генә селтәнеп, печән чаба башлады. Әле генә үзара ни турындадыр пышылдашып утырган кыяклар каерылып киң пакуска ава барды. Э-эх! — ир-атның шат, көчле тавышы бөтен болынны яңгыратты, кайтавазы ерак тауларга бәрелеп кире кайтты, үлән арасындагы чикерткәләр өркеп чык тамчылары сыман тирә-якка сибелеште. Ир кеше киң алдырып алга бара, кояшта янган ялангач аркасындагы мускуллар нәни бурсыклар сыман бер-берсенә таба йөгерә иде.

Кәтүк буйлы бер малай учларын җәеп аның артыннан чаба, печән арасыннан сикергән эре-эре җир җиләкләре аның өстенә төшә, малайның бите, куллары кып-кызыл җиләккә буялган...

— Э-эй! — дип кычкырдым мин, тик бу авазны агымсулар йотты, ир кеше белән аның малае, пакус аудара-аудара, кызгылт офыкка кереп югалдылар. Шулай да мин аларны танып калдым — печән чабучы ир — әтәем, аның артыннан җиләкләргә җилдерүче малай мин үзем идем.

# ЭССЕЛАР



## ТАШКА ОРДЫМ БАШНЫ

Үз халкыңны ярату хисе кайдан килә? Кайчан пәйда була ул? Моңа төгәл генә җавап бирү авыр...

Шунысы шөбһәсез, халкыңны яратыр өчен син үз мәдәниятеңнең вәкиле булырга тиеш. Гасырлар дәвамында тупланган рухи байлыкка үзеңне ия итеп тою, мең ел элек яшәгән кан кардәшләрең белән ике арадагы бәйләнешне сиземли алу — күпләргә тәтеми торган бәхет... Һәм сагыш... Йөрәк булып укмашып күкрәк читлегенә кагучы сагыш...

Телеңнең байлыгын, тирәнлеген, тарихилыгын белеп, белеп кенә түгел, аның коралына әверелеп! үзеңнең кирәксезлегеңне тою... чал мәдәниятеңнең юкка чыга баруына шаһит булу бәхетсезлеге.

Шушы хәлгә килешмичә ничек сөрән салмыйсың?!

Ләкин алда салкын таш дивар. Битарафлык дивары.

Күпме генә кычкырма, беркем ишетми, беркем искәрми. Һәркем үзенең көндәлек мәшәкате белән мәшгуль. Һәм аларны гаепләп тә булмый. Димәк, милләтнең умырткасы сынган, үз-үзен саклау инстинкты юкка чыккан.

Хәер, нигә милләт дидем әле? Дәүләт тотучы, һәм шул дәүләтне үз милли мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру чарасы итә алган халыкны гына милләт дип атарга мөмкин.

Тарихлардан килгән рухи мирасын белмәгән, белсә дә, аңа кимсетеп караган, бары тик чит халыкларның мәдәниятенә ирешергә омтылган халык милләт исеме белән аталырга хаклы түгел.

«Татар угълы татармын!» — дип горурланып язган бөек Дәрдемәндне күпләребез кабатлый алмый инде. Хәзер күпчелекне татар угыллары, татар оныклары тәшкил итә... татарлар түгел.

Бала туу йортларына кереп яңа туган нарасыйларны поплар чукындырып чыга — халыкның исе дә китми.

Шулар ук уртак ватан дидекемез Русияне сакларга — кемнән? — килгән егетләребезгә «изге су» бөркеп йөри — без ләм-мим.

Милли һәм төбәк компонентларын мәктәп программасыннан алып ташларга — димәк, татар телен мәктәпләребездән куып чыгарырга! — дигән канун чыгаралар — халыкта ник бер дулкынлану әсәре сизелсен... Ул гынамы, шул канунны гамәлгә кертүче фиркагә сайлауларда сиксән процентка кадәр тавышыбызны бирәбез. Димәк, үзебез үк телебезгә, асылыбызга булган шушы һөҗүмне яклыйбыз...

Пушкин Русиядәге даими вазгыятьне ике сүз белән бик төгәл әйтеп биргән: «Народ безмолвствует».

Ләкин Пушкин яшәгән заманда әлеге билгеләмә безнең халыкка туры килми иде! Октябрь инкыйлабына кадәр татар рухи бәйсезлеген җуймыйча яшәде. Милли-мәдәни кысрыклауга каршы тиешле җавабын да бирә белде. XIX гасырда инде татар милли мәнфәгатьләр өчен канкоешлы фетнәләр белән түгел, төрле прошениеләр язып, судлар аша көрәште. Тарихчылар яхшы белә, архивларда андый хатлар, гаризалар йөзләгән, меңләгән... Дөрес, татар төрле мәктүпләрне Мәскәүгә XX гасырда да күп язды, бүген дә яза... Тик аларның эчтәлеге башка. Бер-берсе өстеннән өлкән туганга җалу яза хәзерге татар угълы.

Чү, сүз башың бит Шүрәле иде, диярләр. Үз халкыңны ярату турында башладың да...

Нәкъ шулай!

Нәфрәтләнә белгән кеше генә ярата ала.

Мөштәри урамында, Язучылар йортына каршы, шактый таушалган борынгы бер йорт бар. Яшь Ульяновны шунда кулга алганнар. Исегездәме, аны мәхбүс итәргә килгән жандарм офицеры гыйсъянчы студентка: «Алдыңда бит стена!» — дип әйткән, имеш. «Стенасын стена, ләкин черек», — дип җавап биргән булачак Ленин. Мондый диалог, әлбәттә, кайсыдыр совет язучысының хыял җимеше генә... Әмма зур мәгънә бар бу сүзләрдә!

Заманында һуннардан саклану өчен Кытайның беренче императоры Шихуанди йөзләрчә чакрымга сузылган бөек дивар өйдергән.

Диварны җимереп була, ләкин аның артында сакланырга да мөмкин.

Һәр халыкның гореф-гадәте, йолалары, җыйнап әйткәндә, мәдәнияте шундый дивар ул. Дөнья җилләренә күңелең ачык булса да, йөрәгеңдә шундый какшамас дивар булырга тиеш.

Даланың кодрәтле хуҗалары һуннар кайда бүген? Кытай дивары күптән инде чик сызыгы түгел, ул бүгенге бөек дәүләтнең эчендә калды. Аның өстендә бүген туристлар йөри. Гыйбрәт дивары!

Һуннарның варислары булган Алтын Урда татарлары үз шәһәрләре тирәли дә дивар кормаганнар. Дала үз бала-

ларын күңел киңлегенә дә тиендерә, күрәсең. Ләкин күңел киңлеге еш кына ачыгавызлык дигән сыйфатка да әверелә. Алтын Урда кодрәтле заманнарда бу якларга килгән бер көнбатыш сәяхәтчесенең язмасы истә калган. «Нигә сез калаларыгызны диварлар белән ныгытмыйсыз?» — дип сорый ул бер морзадан. «Диварны куркаклар гына кора, — дип җавап бирә тәкәббер татар. — Ә без кемнән куркыйк?» Күп вакыт та үтми, илдә үзара ызгыш китә — 1360–1380 елларда тәхеттә 25 хан алышына, урыс елъязмачылары бу чорны «великая замятня» дип атыйлар — шуңардан файдаланып берничә мең урыс ушкуйнигы көймәләр белән Идел буйлап төшеп ханлыкның башкаласы Сарайны талыйлар, хан казнасын тәяп китәләр. Бераздан Аксак Тимер чирүе Алтын Урданың барлык шәһәрләрен тар-мар итә. Татар иле шуннан соң инде күтәрелә алмый, таркала.

Сарай шәһәренең ташлары бөтен Русиягә сибелгән. Әмма алар дивардан түгел, искиткеч гүзәл биналарның, кабер ташларының кыйпылчыклары. Куеныңа салып куй берәрсен, татар угълы татар!

Дивар корырга яратмасак та, без анда-монда ташлар калдырырга маһир халык. Шундыйларның берсенә абынып егыла язган студент гәзиткә хат язып җибәргән. Иелеп кардан чистартса, туксанынчы еллар башында куелган бу ташка «Монда Шиһабетдин Мәрҗанигә һәйкәл булачак» дип язылган икән.

Куелмаган һәйкәл тирәсендәге бәхәсләрне хәтерлим әле мин. Аңа дин әһелләре бик ярсып каршы төшкәннәр иде. Янәсе, шәригатьтә кешегә һәйкәл кую катгый тыела. Алар шулай итеп һәйкәлне пот белән тәңгәлләштерделәр. Хәер, алар каршы төшмәсә дә һәйкәл куярга атлыгып торучы юк иде, ахрысы. Татарның пары бәхәсләшкәндә чыгып бетә аның.

Сәйдәшкә һәйкәл кирәк, дип күпме лаф ордык. Мәдәният фондында (а-у, кайда ул хәзер?) кемнәрдер шул ниятне сылтау итеп халыктан байтак кына акча да җыйды. Ә сынчылар, рәссамнар туктаусыз бәхәсләште, түрәләр бөек аһәңдарга лаеклы ландшафтны таба алмый интекте. Ул арада бернинди тавыш-тынсыз гына Казан үзәгендә Шаляпин һәйкәле калкып чыкты. Шунысы гаҗәп: татар булмаганнар сынлаштырылса, бернинди бәхәскә урын калмый бездә, ландшафт та тиз табыла. Менә шул, Сәйдәш һәйкәлен салырга дип җыелган халык акчасы ничектер бик сәер рәвештә юкка чыкты, инде пар да чыгып беткән иде, рәхмәт Шәймиевкә, ниһаять, Сәйдәш һәйкәлен дә күрүгә ирештек. Тик нигәдер ул ТДГПУның (гуманитар-педагогика университеты, Татар дәүләт университетын ачу урынына педагогия институтының исемен шулай мәгънәле итеп үзгәрттеләр) яңа

бинасы каршына куелды. Аңа тәгаенләнгән урында исә «Бакыр бабай» — империя стилендә эшләнгән Державин һәйкәле утыра. Ландшафт шулай кушкандыр, хәерле булсын.

Шул ук туксанынчы еллар башында берничә мөфти (хәзер ике мулланың берсе мөфти) Екатеринбургның үзәгендә «Монда җәмигъ мәчете булачак» дигән язулы таш куюны оештыра. Сөенә-сөенә халык җыела. Дөрес, мөфтиләрнең аларда гаме булмый. Янәшәдә гарәп илләреннән килгән вәкилләр! Икенче көнне оештыручылар истәлек ташын кай тарафкадыр алып китәләр. Баксаң, шәһәр хакимияте белән килешенмәгән, урын тәгаенләнмәгән, әлеге тамашаны гарәп химаячеләреннән шактый акча каеру максатында уйнаганнар икән...

Кремль дивары янында тагын бер истәлек ташы бар. Казанны саклаганда шәһид киткән бабаларыбызга шул төштә һәйкәл куелачагы турында язылган анда. Хәтеремдә, әлеге мәсьәлә 1992 елда Татарстанның Фәннәр академиясендә, «Мирас» җәмгыятенең (а-у, кайда син?) утырышында тикшерделәр. Шәһәр мэриясе һәйкәл проектына конкурс та игълан иткән иде. Аның берничә турын да үткәрделәр. Гадәттәгечә, бәхәс купты. Әлеге дә баягы ландшафт туры килми дип, аның урынын каршы як дивар кырына билгеләделәр. Хәзер әлеге һәйкәлне салу турында сөйләнгән кеше күренми. Пар чыгып бетте. Сәяси вазгыять тә үзгәрде. Беренче урыс инкыйлабыннан соң татарда «яфрак асты» дигән төшенчә киң кулланышта булган. Бүген бу безгә дә туры килеп тора.

Югыйсә Казанны саклап шәһид китүчеләргә һәйкәл булмавы тарихи гаделсезлек бит! Чөнки аны яулап алганда һәлак булучыларга памятник 1826 елда ук куелган һәм ул әле дә Казан елгасында, Кремльгә каршы кукраеп утыра бирә. Инде аның башына тәре дә утырттылар, ул памятник кына түгел, гыйбадәтханә дә. Кашындагы атамасы да (әлегә акшарланган) мәгълүм: «Победа над татарами» дип язылган анда!

Шунысын да әйтү урынлы булыр, әлеге гаделсезлек татарның бәгырен даими тырнап торган. Инкыйлабтан соң «хөррият» килгәч, 1924 елда Татарстанның Үзәк башкарма комитеты РСФСРның Мәгариф халык комиссариатына тәкъдим белән чыга: «О разрешении переконструировать памятник «Победа над татарами» в «Памятник содружества народов». Мәскәү бу тәкъдимгә каршы төшүен төшми, әмма һәйкәлнең исеме үзгәртелмичә кала. Хәер, исемен үзгәртеп кенә аның асылын алмаштырып буламыни?! Шуңа күрәме, 1935 елда Татарстанның Үзәк башкарма комитеты рәисе Г.Байчурин ВКП(б) өлкә комитетына һәйкәлне юкка чыгарырга тәкъдим итә. Янәсе, ул инде җимерек хәлдә, аны төзәтер өчен кирәк булган 65 мең сум акча бюджетта юк.

Мәскәүдәге тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау комитеты бу тәкъдимне хуплый. Ләкин татарларны җиңү хөрмәтенә салынган һәйкәл үз урынында кала бирә! Димәк, кемнәргәдер аның татар бәгыренә кадалган хәнҗәр сыман тырпаеп торуы кирәк булган. Меңләгән чиркәүләрне, мәчетләрне җимергән заманда колониализмга һәйкәл буларак салынган бинаның сакланып калуын бүтәнчә ничек аңлатасың?

Һәйкәлләрне җимерергә кирәкми. Ватанны яклап соң тамчы каннарына кадәр сугышып һәлак булган бабаларыбызга җыйнак кына бер һәйкәл куярга да мөмкинлегебез юк икән, без халык телендә «Грозный һәйкәле» дип аталган чиркәүгә карап гыйбрәт алыйк. Нинди хәлдә калганлыгыбызны аңларбыз, бәлки.

«Ташка ордым башны!
Йә таш, йә баш ярылыр» дигән сүзләрне мәрхүм шагыйребез Илдар Юзи зинданда үз-үзен һәлак иткән декабрист Булатов авызыннан әйттерә.

Кайсысы ярылачак — монысы һәркемгә анык.

Ләкин ташларның җаны юк дип тә беркем раслый алмас. Ташлар да елый...

Күктүбәдә тау башында җирләнгән урыс шагыйре М.Волошин үз каберенә чәчәкләр түгел, һәркемнең бер таш алып менүен васыять иткән. Хәзер кабер өстендә ташлардан шактый зур калкулык өелгән.

Куендагы ташны Татар диварының нигезенә салыйк. Дивар калыкмаса, татар дигән халыкның кайчандыр бу җирдә яшәвенә ишарә булып, шул ташлардан, бәлки, нәни генә калкулык үсеп чыгар...

*Март, 2008*

## СИН, МИН, МӨХӘММӘТӘМИН...

Язучылар, сәясәтчеләр үзләре яшәгән заманга исем кушарга маһир. Җитмешенче-сиксәненче елларны «торгынлык чоры» дип атадык. Аңарга кадәргесе И.Эренбургның җиңел кулы белән «оттепель» — «җепшек еллар» дип исемләнгән иде. 1985 елдан соң «үзгәртеп кору» башланды. Аны тагын хәбәрдарлык заманы, күчеш чоры дип тә атадылар.

Күчеш чоры шактый озакка сузылды. Әлегә кадәр кая күчәсебезне, кичүнең кай төшендәрәк икәнлегебезне тәгаен белгән кеше юк. Ярлар томанга төренгән...

Каушау, шик-шөбһә кешеләрнең аңын били. Артка да чигенеп булмый, алда да билгесезлек.

Күрәсең, тарихның үз кануннары. Күпмедер вакыт үткәннән соң еллар шулай даими рәвештә болганып аладыр инде. Рәсәй өчен бу бигрәк тә хас күренеш.

Көндәлек тормыш нииндидер куркыныч төшкә охшап калды. Ачлык еллар турындагы иске кинофильмнарда гүяки үзебез катнашабыз — кечкә эңгер-меңгердә соры кешеләр кайнаша, ипигә-сөткә чират, ирләр сүгенә, хатын-кызлар чырылдый, гасабиланып кесәдәге талон-купоннарны актаралар, төргәк-төргәк акчаларны барлыйлар. Ә кибет киштәләрендә җил уйный.

Сәясәтчеләр безне тынычландырырга ашыга: менә бу кышны гына чыгыйк, менә шушыны гына... Ышанабыз, әбибабайлар кебек без дә «якты киләчәк» буласына ышанабыз. Тик шунысы: әби-бабайларны язга чыгуга төрле үләннәр, кычытканы-кузгалагы дигәндәй, көтеп торган, ә хәзер аларын да химик ашламалар белән яндырып бетерделәр. Ярый инде, чит ил ярдәм итәсе, имеш. Тик ул ярдәмнең дә Мәскәү белән Петербургны үтеп безгә килеп җитәчәгенә өметләнү кыен.

Юклык, хәерчелек турында сөйлисе дә, язасы да килми югыйсә. «Хөрмә, хөрмә», — дип тәкрарлаудан авызда хөрмә тәме пәйда булмый.

Тормышлар әйбәтләнер, иншалла. Мәңге шулай дәвам итмәс ич инде? Ышанабыз!

Әмма мин ышанам, ул ышана, Мөхәммәтәмин ышана, ә бик күпләр ышанмый инде. Аларны да аңлыйбыз — түземлекнең, сабырлыкның да чиге бар.

Ышанмый икән ышанмый, бернишли дә алмыйсың. «Бөтен дөньяның ышанмаучылары, берләшегез!» — дип, революция ясарга чакыручы күренми бит әлегә. Чакыручылар булса да, халык алданмас иде, мөгаен. Тарихтан мәгълүм бит: революцияләрдән соң халыкның тормышы тагын да начарая, тик котыртучылар гына (исән калганнары) ил түрәләре булып бай яши башлый.

Эш революцияләргә, фетнәләргә үк барып җитмәде бугай әле. Алла сакласын!

Тик болганчык суда балык тотучылар хәзер дә күп. Моның өчен аларга суны болгатып тору зарури. Мондый кешеләр үзләре нәни генә революция, үзләре нәни генә фетнә, һәм алар җәмгыять өчен зур революцияләр кебек үк куркыныч. Күзгә карап халыкны экспроприацияләү (большевиклар жаргоны, безнеңчә — талау) дәвам итә.

Аларның ничек дип аталуы безгә барыбер. Хәер, исемкушамат мәсьәләсендә алар үзләре дә талымсыз: кичә — коммунист, бүген — демократ, иртәгә — милли патриот... Иң мөһиме — җәмгыять тиз арада кискен итеп икегә бүлен-

де. Бер якта — купшылык, байлык, музыка, икенче якта — хәерчелек, ачлык-ялангачлык, сүгенү-сыкрау авазлары.

Без Көнбатышка карап баш чайкадык, тел шартлаттык, авызда мул итеп селәгәй бүленде. Алар кебек яшисебез килде! Ләкин кеше хокукларын беркайчан да санга сукмаган Рәсәйдә андагы кебек цивилизацияле җәмгыятьне тиз генә төзеп булмый икән. Хәзер инде безнең социализм дигәнебез дә каядыр югалды, капитализмы да күренми. Без хәзер яңадан феодализмга кереп барабыз, ахрысы.

Кемнәргәдер шом салып, кемнәргәдер сөенеч өстәп, янәшәдә яңа диктаторлар борынлый.

Менә шушындый билгесезлек, өметсезлек чорында пьедесталга әхлаксызлык, алйотлык күтәрелә. Җинаятьчелек гадәти бер күренешкә әверелә. Кем-кем, без моны граждан нар сугышы тарихын укып яхшы беләбез. Имансызлык киләсе көнгә ышаныч булмаудан туа.

Әлбәттә, үз заманыңны тәнкыйтьләү, яшь буында әхлаксызлыкның, имансызлыкның артуы турында язу яңалык түгел. Күптән, бик күптән борынгы Мисыр хакиме үк яшьләрнең һаман бозыла баруын пергаментка теркәп калдырган. Кешелек шулай буыннан-буынга череп таркала барса, без, мөгаен, ике меңенче гасырга килеп җитә дә алмаган булыр идек. Ләкин тарих — изгелек белән явызлыкның даими көрәше бит ул. Нindидер бер чорларда явызлыкның тулаем өстенлек алуы беркемгә дә сер түгел. Әйе, кызганычка күрә, ул шактый ук еш өстен булып кала шул...

Кайчагында күңелгә тиле сораулар да килә: без кайсы заманда, кайсы илдә яшибез? Телевизордан нindидер илләрне күрсәтәләр, аларда бәйрәм, кибет киштәләре сыгылып тора, кешеләрнең йөзләрендә бәхетле елмаю балкый. Президентлар очраша, нindидер кәгазьләргә кул куялар, чырайларында хакими ирешү куанычы... Ә син караңгы төшүгә урамга чыгарга шүрләп утырасың... «Татарстан» программасы милиция хәбәрләрен тапшыра: кичә Казанда ундүрт фатирны талаганнар, утыз ике бөрек салдырганнар, өч кешене үтергәннәр, ике кызны көчләгәннәр.

«Минем өем — минем кальгам», — дип, инглизләр генә әйтә ала. Без өйдә дә үзебезне ышанычлы сизмибез. Өйгә бәреп кереп хуҗаны кыйныйлар, әйберләрен талап чыгалар. Дәүләт сине сакламый, ул каядыр еракта — президентлар куенында, ә син монда берүзең вәхшилек белән күзгә-күз.

Караклар байларны талый, дибез. Шул кирәк аларга, дип эчтән генә сөенеп тә куябыз. Большевистик тәрбия. Ләкин байларны тәҗрибәле, оста бандитлар талый. Ә бит аларның әле генә «эшкә» тотынганнары да бар, яшьләре, остарып килә

торганнары, гадәттә, урта хәлле, гадирәк өйләрдән башлауны хуп күрәләр.

Байлар үзләрен саклау, яклау чараларын табарлар. Акча акчаны саклый. Гади халык яклаусыз... Син, мин, Мөхәммәтәмин.

Бандитлар, караклар, бурлар, талаучылар һәрвакыт булган. Сәяси һәм мәдәни шартлар үзгәрү белән аларның саны артырга яки кимергә генә мөмкин. Иң куркынычы — әхлаксызлык, имансызлык киң катлам халыкның — әлеге дә баягы синең, минем, Мөхәммәтәминнең бәгыренә үрмәли.

Ничә дистә еллар дәвамында әдәбият һәм коткы тарату чаралары безне ач-ялангач калганда да кешелек сыйфатларын җуймаска өндәде. Кешенең кеше икәне экстремаль ситуацияләрдә генә күренә, янәсе. Өлешчә, хаклык бардыр бу сүзләрдә дә... Ләкин...

Кешене кеше итәр өчен аңа кешечә шартлар тудырырга кирәк!

Нигә совет кешесен чит илләрдә әллә кайдан танып алалар? Нәрсә, бездән аерым ис бөркелә мәллә? Юк, без анда үзебезне әле кеше дип аталырлык ук дәрәҗәгә җитмәгәнлегебезне аңлап алабыз, купшы сарайга килеп кергән хезмәтче малай кебек колларны кая куярга белми аптырыйбыз, дөньябызны онытып кибеттәге ялтыравык нәрсәләргә ташланабыз.

...Беркөнне шыплап тулган автобуска утырдым. Бераз баргач, бер хатын кинәт кычкырып җибәрде: «Сумкам, сумкам кая?» Билгеле, аның букчасының кайда икәнлеген белүче табылмады. Ул, бичара, талон алырга акча җибәрү өчен, аны идәнгә куеп торган икән. Кешеләрнең сумка урлануга исләре китмәде, елмаеп кына куйдылар, кайсыдыр әле бәхетсез хатынның үзен битәрләп алды, авызын ачып бармасын иде, янәсе.

Кеше әйберенә кул сузу гадәти хәлгә әйләнде. Безнең илдә дәүләт ясисә колхоз милкен өйгә алып кайту беркайчан да караклык саналмый иде. Уртак малны эт ашый... Хәзер, гомуми хәерчелек башланганнан соң, кеше әйберен чәлдерү дә булдыклылык билгесе генә дип санала башлады.

Ә ул букчаны тукталышта алып чыгып киткән кешене сез азау теше чыккан бандит ясисә карак дип уйлыйсызмы? Юк, иманым камил, нәкъ минем, синең һәм Мөхәммәтәмин кебек үк гадәти кеше ул. Барыбыз кебек үк бүген гаиләсен, балаларын ничек туйдырырга дип аптыраган, гаҗизләнгән бер бәндә...

Йә, кайсыгыз аңа әхлак турында үгет-нәсихәт бирергә тели?

Ул инде тыю чиген сикереп узды. Тормыш шушылай барса, әлеге чикне узучылар тагын күпме булыр? Тормыш

итү шушылай начарайган саен, кешеләр эчкәрәк, җинаятьчелек дигән дөньяның түренәрәк үтәчәкләр. Иң гаҗәбе — һәр җинаятькә җәмгыять күнегә барачак. Акланыр өчен сәбәпне тапканда, кеше бик тапкыр була.

Г.Ибраһимовның «Адәмнәр» хикәясен искә төшерегез. Ачлыктан акылын җуйган кеше үз баласын суеп казанга сала. Дөресрәге, ул инде кеше түгел, һәм гаепне без аны кешелектән мәхрүм итүче большевиклар хакимиятеннән эзлибез.

Ачлык бу илдә алыштыргысыз патша булган. Бабайлар ачыккан, әтиләр ачыккан. Алтмышынчы еллардан соң гына халыкның тамагы туя башлады кебек. Ләкин бит ул вакытларда әхлак, әдәп бу кадәр үк кимәлгә төшмәгән иде. Әйе, демократиянең үз кимчелекләре бар. Богаудан яңа гына котылган кол аны теләсә нишләсәң дә ярый дип аңлый. Димәк, демократия безнең эчебезгә килешми?

Борынлап килүче диктаторлар моны бик яхшы аңлый. Алар җәмәгатьчелек мантыйгының шушы ялган хакыйкатькә килеп җитүен көтәләр. Аларга елларның болганчык булуы, әхлакның һаман төшә баруы кирәк.

Большевиклар властьны алганчы сугышны туктатырга каршы булганнар. Сугыш туктаса, халыкка солых вәгъдә итүнең бер мәгънәсе дә калмый ич.

...Туганнан туган сеңлем, Сембердән автобуста кайтып барганда, Шомырша янында аварияга эләккән. Исерек шофер үзенең «КамАЗ»ы белән аларның «Икарус»ына килеп бәрелгән. Берничә кеше һәлак булган, яралнучылар көчхәл белән җиргә чыгып егылган. «КамАЗ» автобусның алгы өлешенә бәрелгәнгә күрә, артта утыручылар әллә ни зарар күрмәгәннәр. Алары инде җәрәхәтләнүчеләргә ярдәмгә ташланган дип уйлыйсыздыр. Әйе, ташланганнар, тик ярдәм итәргә түгел, үлгәннәрнең, һуштан язганнарның бүрекләрен салдырырга... Сугышта мародерларны атып үтергәннәр, ә тыныч тормышта бу хәлгә беркем дә гаҗәпләнми. Үлгәннәргә инде итек тә, бүрек тә кирәкми, ә яраланып хастаханәгә эләгүче, киемнәре өчен борчылудан бигрәк, исән калуына шатлана.

Мин әхлаксызлыкның, имансызлыкның тамырларын эзләмим. Аны инде бик күп акыл ияләре эзләгән. Явызлык кешенең җанына яшеренгән, ул аның канында ага. Кешенең тормыш итү рәвешен үзенә буйсындырыр өчен, иманны, шәфкатьлелекне үтерер өчен һәрдаим җай, форсат көтә ул. Бүген безнең җәмгыятьтә шундый форсат туды.

Еш кына язучылар кешенең психологиясен милләтләргә бүлеп аңлатырга яраталар. Ниндидер аерым төсмерләр бардыр да, бәлки. Ләкин Алла Адәм галәйһиссәламне үзенә охшатып бар иткән икән, димәк, адәм балалары да бер-берсе

белән охшаш, һәрберсенең күңеленә иман орлыгы салынган һәм шул ук вакытта иблис тә салкын сулышын өргән. Җәмгыятьтә катаклизмнар көчәйгән саен, ул сулыш зилзиләгә әверелә бара. Күңелләрдәге бу зилзилә бүген җирдәге бөтен тереклекне себереп түгәргә сәләтле.

Җир тетрәгәннән соң үлгән кардәшләренең кесәсен актарган әрмән, авариядә һәлак булган кешенең бүреген салдырган чуаштан яисә татардан ние белән аерыла соң? Күпмедер вакыт дөньяда типтереп яшәр өчен Тольяттида әтисенәнисен үтергән урыс малае болар белән бер кавемнән түгелмени?

Ә бит алар гомерләрен җинаятьчелеккә багышлаган бандитлар түгел.

Болар әлеге җинаятьләренә кадәр безнең кебек гадәти генә яшәгәннәр.

Эшкә барганнар, эштән кайтканнар, телевизор караганнар. Синең кебек, минем кебек, Мөхәммәтәмин кебек...

...Халыкның бәгыренә үтеп кергән шушы имансызлык, әхлаксызлык, кансызлык, шәфкатьсезлек бик күпләрне борчый. Киләчәккә ышаныч булмау хисе — киләчәккә төбәлгән пуля ул.

Имансызлык...

Әйе, ниһаять, уртак фикергә дә килдек бугай инде: әхлакны безгә тик дин, иман гына кайтара ала. Коръән дә, Инҗил дә Аллага буйсынырга, бер-береңне үтермәскә, бер-береңнән урламаска куша. Һәр диннең нигезендә кешене яхшырак итү нияте ята.

Беркем дә бәхәсләшми — диннең кешене иманлы, берберенә итагатьле, шәфкатьле итүдә әһәмияте гаять зур. Ләкин хәзер дин байрагы күтәрүчеләрнең барысы да аның төп кануннары белән исәпләшәме соң?

Илдә православие дине гаять зур күтәрелеш кичерә. Көн саен поплар телевизордан, радиодан чыгыш ясый, мәктәпләргә барып балаларны (милләтләренә дә карап тормыйча) чукындыралар, бер-беребезгә мәрхәмәтле булырга чакыралар. Ләкин урыс мәктәбендә укучы, әле дөньяның ни икәнен белмәгән татар баласын чукындырып китү мәрхәмәткә, иманлылыкка керәме?

Православие чиркәве безнең халыкка җәберне, мәсхәрәне, мыскыллауны гасырлар дәвамында күп салды. Безнең өчен Торквемада — чукынмаган татар әсирләрен Новгородта җәзалап үтерүче архиепископ Макарий, 418 мәчетне җимергән Лука Канашевич... Аларның Гайса пәйгамбәргә нинди катнашы бар?

Менә Волоколам һәм Юрьев митрополиты Питирим «Советская культура» газетасында Иосиф Волоцкийга мәдхия

укый: «Урыс изгеләре арасында аның аерым урыны бар. Җәмгыятькә хезмәт итү өчен ул даими камиллеккә омтылуны тормышының максаты итеп куйган». Митрополит укучыларны шушы «изге»дән үрнәк алырга чакыра. Ә бу «изге» үз вакытында кешеләрне ересь өчен генә түгел, ересь турында кирәкле төшкә барып әйтмәгән өчен генә дә үтерергә кушкан. Сталиннан яисә Гитлердан кайсы ягы белән «изгерәк» ул һәм аның Гайса пәйгамбәргә ни катнашы бар?

Былтыр җәй тагын бер урыс изгесе Серафим Саровскийның сөякләрен (Ленин гәүдәсенең мавзолейда ятуын юкка гына урыс гореф-гадәтләренә каршы килә дип язалар) Мәскәүдән элеккеге Дивеево монастырендагы Троицкий соборына күчергәннәр иде. Шул бәйрәмдә тоташ карадан киенгән егетләр дә — черная сотня! — катнашкан. Бу кара горуһның хыялы — яһүдләргә погромнар оештыру, урыс җирен басурманнардан чистарту.

Имансызлык бүген үзен иман дип игълан итә.

Югыйсә дин көчәйгән саен безнең күңелләрдә мәхәббәт, мәрхәмәт, шәфкать артырга тиеш иде...

Югыйсә дин ул дини дошманны эзләү түгел, ә үз күңелең белән Аллага якынлашырга омтылу бит...

Ләкин ипи-сөт эзләп кибеттән кибеткә чапканда, кешенең үз күңеле турында да, Алла турында да уйларга вакыты юк, аның баш очында Иблис канат җәйгән, ул үзенең шушы хәлгә төшкәне өчен гаеплене эзли — дин дошманын, тел дошманын. Ачның ачуы яман.

Тормышлар әйбәтләнми торып күңелләргә иман иңмәячәк... Тик шунысы: имансыз килеш тормышны әйбәтләндереп булмый. Ислам дине безне түзем, сабыр булырга чакыра. Сине, мине, Мөхәммәтәминне. Иманлылык, мәрхәмәт, шәфкать, мәхәббәт шул сыйфатлардан башланадыр да, бәлки...

*Февраль, 1992*

# ПРЕМИЯ

Язучыларның сиксән тугызынчы елда булган корылтае бик шау-шулы узды. Гаҗәпләнәсе юк, илдә җылы җилләр исә иде: әһле каләм дә шул шаукымда чынлап торып «демократияле» уйнап алды. Бу ыгы-зыгыга мыек астыннан елмаеп карап торучылар булса булгандыр, мәгәр «Идегәйнең заманы» килүгә без самими рәвештә ышана идек.

Хис адәмнәренә үзгәрешләр көтү, вакытны ашыктыру, шул әверелешләрдә үзләрен мөһим итеп тою хас. Әдәбият ту-

рында әтрафлы сөйләшү, ил язмышы хакында борчулы телмәрләр моннан соң узган җыеннарда бүтән ишетелмәде шикелле. Ахырда идарә әгъзаларын да, рәисен дә яшерен тавыш белән альтернатив рәвештә (ул вакытта бу сүз телләрдә еш кабатлана иде) сайлап куйдык. Биш елга сайланган шул идарә әгъзалары арасында мин дә бар идем.

Ара-тирә узган идарә җыелышлары минем өчен зур мәктәп иде. Алардагы көн тәртибе гадәттә бертөрле була: өлкән язучыларның юбилейларына әзерлек, төрле премияләргә тәкъдим итү, язучылар берлегенә яңа әгъзалар кабул итү, кайдадыр узачак әдәбият көннәренә бару өчен рәис әзерләгән исемлекне раслау. Бүтәннәрнең язмышын хәл итүдә аз гына катнашың булу, исемлекләр белән мәш килү үзеңне шактый гына кирәкле адәм итеп тоярга күнектерә... Башкалардан аерымланып тору алдавычы кемнәрне генә әсир итмәгән. Үздәр кешеләргә шул чәнчи бармак очыдай «хәл итмеш»ләр дә шактый ук кибарьлек өсти ала.

Идарәдә утырганда мин язучыларның нәкъ гап-гадәти кешеләр кебек үк булуын күрдем. Алар арасында да яхшы кешеләр бар, начар кешеләр дә җитәрлек. Киң күңеллеләр шактый, хөсетлеләр дә очрый. Һәм бу сыйфатлар һич тә әдәби талантка бәйле түгел икән.

Туксанынчы елның көзендә уздырылган бер җыелышта комсомолның М.Җәлил исемендәге премиясенә бер кандидат тәкъдим итү каралган иде. Аның кагыйдәсендә кандидатның яше утыз биштән узмаска тиеш булганга, сүзнең нинди исемнәр тирәсендә чуалачагын чамаларга мөмкин иде.

Идарә бер мәлгә тын калды. Мондый чакта гадәттә олпат әдипләрнең сүзен көтәләр. Менә вәкарь белән генә Аяз Гыйләҗев торып басты. «Бу премиягә Ркаилне тәкъдим итәм», — диде ул һәм купайтып минем иҗатны мактый башлады. Аның сүзен тагын кемнәрдер җөпләде. Кул күтәрергә кирәктер дигән кебегрәк һәммәсе рәискә карады. Минем нидер әйтергә теләп кыбырсуымны күреп, ул дәү кулын хәрәкәтләндереп куйды: тыныч кына утыр, янәсе. «Без демократия заманында яшибез, — диде ул. — Ркаил талантлы егет, әлбәттә. Шулай да аңа альтернатив рәвештә мин Зиннур Хөсниярны тәкъдим итәр идем». Ниһаять, мин дә торып бастым. «Бу фикергә кушылам, — дидем. — Зиннурның бик әйбәт китабы да чыкты. Ә миңа премияне комсомол барыбер бирмәс, безнең аралар бик четерекле. Дөресен әйткәндә, комсомол премиясен аласым да килеп тормый...» Тагын Аяз абый торды. «Киемеңә карап каршыласалар, акылыңа карап озаталар, — диде ул. — Яхшы каршылап, яхшы озатсалар начармыни? Премия — кием ул. Аннары бу премия комсомолныкы гына түгел, ул каһарман

Җәлилебезнең дә исемен йөртә. Ркаил яшьлеге белән генә каршы килеп маташа». Әхсән Баян булса кирәк: «Икесен дә тавышка куярга кирәк, — диде. — Үзләренең идарәдән чыгып торуы мәгъкуль булыр...»

Без коридорга чыгып тәмәке кабыздык. Бераздан кире чакырдылар. Күпчелек тавыш белән премиягә мине тәкъдим иткәннәр булып чыкты.

Әлбәттә, комсомол премиясе лауреаты булырга Зиннур миннән лаеграк иде. Заманалар үзгәреп комсомолның дәрәҗәсе төшмәгән булса, әлеге премияне мин төштә дә күрмәс идем. Чөнки мине егерме ике яшьтә үк комсомолдан чыгарып ташладылар.

Бу оешма белән мөнәсәбәтләр баштан ук сәер башланды. Мәгълүм ки, ундүрт яшькә җиткәч, анда һәммә кешене уптым-илаһи кабул итәләр иде. Моңа беркем дә җитди итеп карамый: шулай тиеш, вәссәлам. Безне дә җиденче класста шуның өчен комсомол комитетына чакырып карадылар, әмма без — малайлар — анда бармадык. Классыбыз башбаштаклыгы белән дан алган иде, бүтән чакыручы булмады. Әллә комсомол исемен йөртергә лаек дип тапмадылар, әллә җитәкчеләр үз эшләренә төкереп карыйлар иде — безне оныттылар.

Беспартийный килеш кенә унынчы класска җиттек. Комсомол булмаганнарны югары уку йортына алмаулары (характеристика мәҗбүри) һәркемгә билгеле иде, шуңа күрә мин бер дустым белән, мәктәпне тәмамлар алдыннан гына, ВЛКСМ сафларына бастым.

Казанга килгәч, иң беренче эш итеп «Ялкын» журналына юнәлдем. Анда эшләүче Фәннур Сафин белән инде танышлар идек. Ул мине тулай торакка урнаштырды, университетның кабул итү комиссиясенә документларны тапшырырга булышты. Ярдәмчел кеше иде, мәрхүм.

Шуннан соң без тулай торак янәшәсендәге сыраханәгә кереп ике бокал сыра эчтек. Фәннур абзыйның теле чишелде: «Комсомолның алтмыш еллыгына шигырь бәйгесе үткәрәбез, беләсеңдер, — диде ул. — Юбилей аена комсомолга багышланган шигырь кирәк. Язасыңмы?» Минем теләсә нинди темага шигырь яза ала торган вакыт иде, әлбәттә, ризалаштым. Чыгарабыз дип торганда, нигә язмаска?

Икенче көнне мин аңа «Комсомол билеты» дип аталган шигырь китереп бирдем. Ул Мостай Кәримгә багышланды, сугышта аның күкрәген яралаганнары турында кайдандыр укыган идем, шунда пуля берочтан аның комсомол билетын да тишеп узган, имеш. Көз көне әлеге шигырь ниндидер девиз белән басылып та чыкты (конкурс ябык иде).

Ел ахырында бу шигырь белән «Мәңгәрләрнең йорты зәңгәр» дигән поэма сымак әйбер өчен миңа өченче урынны

бирделәр һәм йөз сум акча белән ВЛКСМ өлкә комитетының грамотасын тапшырдылар. Беренче-икенче урыннарны Мөдәррис Әгъләмов белән Кадыйр Сибгатуллин алган иде.

Шигырьнең автор язмышына ниндидер фаталь тәэсире булуы турында ишетсәм дә, мин моңа ышанмыйчарак карый идем. Бар икән, бар. Шул билет белән киләчәктә никадәр изаланасымны белсәм, «Комсомол билеты» дигән шигырь язу түгел, бу сүзгә мин бөтенләй табу салган булыр идем.

Университетны тәмамлар-тәмамламас «Татарстан яшьләре» гәҗитенә эшкә урнаштым. Берүземә бер өстәл бирделәр! Комсомол билетын шул өстәлнең тартмасына салып куйдым. Ул анда шактый ятты булса кирәк, эш урынында комсомол исәбенә керергә (бездәге таркаулык!) һаман кул җитмәде. Дөресен әйткәндә, бераздан мин бу турыда тәмам онытты да. Ә бит гәҗит — ВЛКСМ өлкә комитеты органы. Без еш кына комсомолның нинди булырга тиешлеген башкаларга өйрәтә идек.

Көзге пыскак яңгырлы көннәрнең берсендә, кич җиткерә алмыйча газапланып утырганда, мине баш мөхәррир Харис Әшрәфҗанов үз бүлмәсенә чакырды: «Сине обкомга чакыралар, — диде ул, нигәдер күзен яшереп. — Морат Гаделшинга кер». «Нигә икән?» — дидем мин, аптырап. Кемнекемне, мине анда җүнлегә чакырмауларын белә идем. Редакторның бәрхет тавышы тимерләнергә маташты: «Баргач белерсең... Комсомол билетыңны да үзең белән ал».

Мин бүлмәмә чыгып өстәл тартмаларын актара башладым. Уч төпләре тирләп чыкты, күз әлҗе-мөлҗе килде, тик башыңны ташка ор, билет кәгазьләр арасында юк иде. Күкрәк авызына кереп оялаган бер йомарлам салкынны укшып чыгарасы килә... Курку хис кенә түгел, матдә дә икән. Шул ачышым белән мин комсомолларның төп йортына йөгердем.

Өлкә комитеты секретаре, өстәленнән төксе чыраен аермыйча, теләр-теләмәс кенә минем мескен комсомол сәламен алды. Янында җирән чәчле тагын бер бәндә утыра иде. Бу ВЛКСМ Үзәк комитетының безнең төбәкләр өчен җаваплы кураторы булып чыкты. Фамилиясе Абрамов иде шикелле.

— Комсомол билетыгыз кайда? — дип, үгезнең мөгезеннән алды ул.

Мин эшне чамалый башлаган идем инде, «өстәл тартмасыннан юкка чыккан» дип мыгырдадым.

— Менә ул сезнең билет, — дип, Мәскәү иптәш каршындагы елтыр өстәлгә ымлады. — Аны һәрвакыт күкрәк кесәсендә, йөрәк янында йөртергә кирәк, ә сез аны тулай торакта дискотека вакытында бөтен халык алдында идәнгә ыргыткансыз, «на... миңа комсомол!» — дип кычкыргансыз. Менә кемдер шул турыда хат язып, билет белән бергә безгә җибәргән.

— Нахак! — дидем мин. — Тулай торакка барып сорашыгыз.

— Без сораштык инде... — Абрамов миңа хатны сузды. — Кем язган икән, кулын танымыйсызмы?

Мин үземне пычракка батырган анонимканы укып чыктым. Кемнеке икәнен кайдан беләсең, бәлки, ул аны әбисеннән яздырып алгандыр?

«На... миңа комсомол!» дип кычкырырга минем башка тай типмәгән ласа, моны болар да аңлый иде, күрәсең. Ә бит юкка ыргытмаганмын шул чакта билетны, җәфасы артык булмас иде, аның каруы хәзер, кайберәүләр кебек, татар диссиденты булып йөрер идем.

— Комсомол билетын югалтуыгызны башлангыч оешмада тикшерерләр, — диде Гаделшин.

Башлангыч оешмада үзебезнең халык — журналистлар, хәлемә керделәр, ниндидер шелтә бирергә кирәк, дип карар чыгардылар. Әмма моның белән генә эш бетми икән. Мәсьәләне райкомол бюросы карый, имеш.

Боларның ит тарткычына бер эләк кенә, ватмыйча, измичә кулдан ычкындырмыйлар. Типкегә әйләнеп, шул бюрога да килеп кердем. Билет югалту кыйссасын мин инде җиде төн уртасында уятып сорасалар да, чатнатып сөйләп бирерлек дәрәҗәдә идем. Теге шигырьне язганда, бу билет дигән нәмәстәкәйнең шундый да әһәмиятле, изге әшья икәнен тамчы да аңламаганмын икән...

Түрдә тоз күзле, ябык чырайлы бер урыс егете утыра. Секретарь. Өстәлнең ике ягына бюро әгъзалары урнашкан. Мин тагын шул кыйссаны сөйлим. Кемдер: «Кемнән шикләнәсез?» — дип сорап куйды.

Шайтанымнан шикләнимме? Эш бүлмәсе ачык, шул тирәдән берәү урлап, Мәскәүгә җибәргән инде ул каһәр төшкән билетны. Димәк, кемнеңдер мине батырасы килгән... Шулай да эчкә җылы керде: мин түгел, урлаган кеше гаепле ич, шуны аңлый башладылар сыман.

— Ә нигә университет тәмамлаганнан соң взнослар түләнмәгән? — диде секретарь.

Менә моңа берничек җавап биреп булмый иде. Сораучы булмагач, аны кемгә түлисең?

Шулчак яшь кенә кыз сикереп торды. Йөрәк кысылып куйды, университеттагы тәҗрибәмнән белә идем: мондыйлардан рәхим-шәфкать көтү урынсыз. Болар зәһәр активистлар, корбаннары егылгач та нечкә җиргә типмичә туктамыйлар. Ул, бик озак әхлак-фәлән турында сөйләгәннән соң, ялкынлы телмәренә нокта куйды: минем ишеләр алар сафында калырга лаек түгел икән.

Секретарь алдындагы әзер кәгазьдән укый башлады:

«Фәлән-фәлән өчен ВЛКСМ сафларыннан чыгарырга». Тфү, шайтан алгыры, карарны алдан ук чыгарып куйганнар бит болар! Фарс ясап утырганнар. Арада мине кызганып караучылар булса да, һәммәсе бердәм рәвештә кулларын өскә күтәрде.

Бу йорттан мин аңгы-миңге килеш чыгып киттем, шыксыз төн үзенең кочагына алды. 1984 елның көзе иде бу — СССР дигән монстрның таралачагын, коммунизм идеологиясенең ишелеп төшәчәген, минем язмышымны хәл итеп утырган бу комсомол вожакларының, оешмалары юкка чыкмас борын ук, күселәр кебек таралышып бетәчәген һәм алыпсатар булып иномаркаларда җилдерәчәген күрәзәлек итү түгел, саташулы төштә күрү ихтималы да юк заман иде.

Шулай итеп, мин Казаннан сөрелдем. Ул чакта югары уку йортларын тәмамлар алдыннан студентларга «распределение» була иде, мине Аксубай районына билгеләделәр. Тәвәккәлләп шунда китәргә уйладым. Монда, билгеле, мине бик гаҗәпләнеп каршы алдылар. Уку елының яртысы тәмамланып килә, дәресләр өләшенгән. «Иске Татар Адәм Суы авылында военрук Чаллыга күчеп китте, шунда барасыңмы?» — диде роно мөдире. Бу кадәр ара килгәч, мин инде кытай телен дә укытырга риза идем. Һәм менә бу сәер атамалы авылда балаларга башлангыч хәрби әзерлек бирә башладым. Автомат сүтеп җыябыз, тирда атабыз. Укучылар да өйрәнә, мин дә хәрби белемемне арттырам.

Беркөнне клубта (клуб — иске мәчет һәм иң гаҗәбе — манарасы да киселмәгән) Хәмзә исемле егет миңа: «Безнең комсомол җыелышы булды, сине бюрога сайладык, стена газите чыгару сиңа йөкләнде», — диде. Ирексездән көлеп җибәрдем: «Мин бит комсомол түгел...» Хәмзәнең исе китмәде: «Иртәгә мин сиңа комсомол билеты апкайтып бирермен», — диде.

Шулай итеп, мин яңадан комсомол булдым, әле гадие генә дә түгел, бюро әгъзасы!

Җәй көне янәдән Казанга кайттым. «Яшь ленинчы» мөхәррире Р.Туфитулова, өлкә комитетын минем яхшы кеше икәнемә ничектер ышандырып, үз газитенә учетчик-исәпче итеп эшкә алды. Учетчик — техник хезмәткәр, килгән хатларны теркәүче икән, хезмәт хакы да иң бәләкәй. Шуңа күрә генә өлкә комитетында бу эшкә урнашуыма ризалашканнар. Роза апа мине пионер бүлегенә утыртты, шунда пионерларның гөрләп торган тормышын газит сәхифәләрендә чагылдырырга тиешмен икән. Хыялы бай кешегә нәрсә тора ул?!

Исәпче генә булуыма карамастан, Морат Гаделшин, өлкә комитетына чакырып, минем белән әңгәмә үткәрде, акыл өйрәтте. «Киңәш кирәксә, безгә кил», — дип, хәерхаһлыгын белдерергә дә онытмады.

Әмма, Ходаның хикмәте, миннән комсомол взносын тагын сораучы булмады. Исемлектә мин юк. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, дип дөрес әйткәннәр икән, бу юлы Гаделшиннар мине комсомолдан тавыш-тынсыз гына чыгарып ыргытканнар. Шулай итеп, бер ел тулар-тулмас бу мөхтәрәм оешмадан ике тапкыр чыгарылдым. Инде үзем дә тындым, чыккан икән чыккан, синең комсомол булу-булмавың кемгә кирәк? Соңыннан мәгълүм булды: сабакташым Ләис Зөлкарнәй дә университеттан соң комсомолда исәптә булмаган икән, аның беспартийный икәнен шайтан да белмәде.

Күпмедер вакыттан соң «Яшь ленинчы»ның нәүбәттәге юбилее җитте, шунда мине комсомол өлкә комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләделәр. Сәхнәгә менеп кулны сузгач, грамоталар өләшеп торучы М.Гаделшинның йөзе сузаеп калды, ләкин елтыр кәгазьне бирмичә булдыра алмый иде инде ул: кулы куелган, мөһер сугылган!

Шундый оешма иде комсомол — эт — баш, сыер — аяк...

Каләм әһелләре гадәттә төрле премия-бүләкләргә, мактаулы исемнәргә ис китмичә карыйлар, һәрхәлдә, үзләрен гади тормыш вак-төякләреннән өстенрәк тотарга, вәхи кабул итүче пәйгамбәр булып күренергә тырышалар. Мәңгелеккә орынган зат көндәлек хакимнәрнең бәяләреннән дә, кара илат алдында очсыз дан казанудан да югары торырга тиеш бит.

Әмма бу кылану гына. Һәр язучы үзенең иҗатына игътибар күрсәткәнне, үз эшен лаеклы бәяләгәнне көтә. Генерал булырга хыялланмаган солдат — начар солдат, диләр. Дөньяның иң дәрәҗәле, иң затлы премиясе саналган Нобель бүләген алырга кайсы язучы хыялланмый? Күренекле француз шагыйре Поль Валери бу премиягә берничә мәртәбә тәкъдим ителә, инде ничәнче тапкырдыр максатына ирешә алмагач, авыруга сабыша. Французлар нечкә күңелле халыктыр шул. Тукай бүләгенә дүрт-биш тапкыр куелып та, мәңгелек кандидат булган кайбер татар шагыйрьләренең исә хасталыклары сизелми, алар ел саен яңа көч белән шигърият Олимпын штурмларга ташланалар. М.Дудин юкка гына безнең поэзияне солдат поэзиясе дип атамаган, күрәсең.

Э.Хемингуэй Нобель премиясен кимсетеп язса да, алгач, аның белән бик горурлануы мәгълүм.

Төрле медальләргә, бүләкләргә кызыгу һәр җан иясенә хас. Медальле этләрне генә карагыз, алар нинди кибарь, нинди шәп! Муеныңдагы шул калайны алырга дип үрелеп кара, ул сине өзгәләп атачак. Кеше дә, миңа калса, эттән әллә ни ерак китмәгән.

Әлбәттә, премияләрне алырга теләмәгән язучылар да бар. Мин Пастернакны күздә тотмыйм, аны Нобель премиясеннән баш тартырга мәҗбүр иткәннәр. Ә Ж.П.Сартр үзе баш тар-

та. Әмма Нобель лауреаты булырга теләмәве белән премияне алуга караганда да зуррак дан казана! Бу инде шөһрәт дигән медальнең икенче ягы гына. Асылы шул ук.

Күптән түгел Г.Маркес испан телендә язучыларга бирелә торган иң зур бүләк — Сервантес премиясеннән баш тарткан иде. «Минем байлыгым житә, бу бүләккә лаек мохтаҗ язучылар да бар», — диде ул. Мондый киң күңеллелек (жест) күрсәтер өчен дә Нобель премиясенә ия булырга кирәктер, бәлки. Хәер, безнең татар язучысы боларның берсеннән дә баш тартмас иде.

Премиянең кызык ягы да шунда, ул мохтаҗ язучыларга бик сирәк бирелә. Тукай премиясен алу өчен, мәсәлән, шәп язу гына җитми, шактый озак яшәргә һәм «солидный» булып күренергә дә кирәк. Дөрес, Р.Фәйзуллин бу абруйлы бүләкне утыз биштә үк алган, ләкин ул башка — Фәйзуллин тирә-юньдә бер әү генә.

Әлбәттә, яшь мәсьәләсе, тышкы кыяфәт һәр илдә дә мөһим роль уйнамый. Р.Альберти, мәсәлән, Испаниянең Милли премиясен егерме яшьләрдә беренче кулъязма китабы өчен ала. Ләкин андагы жюрида бездәгедәй берни укымый торган «мәдәният генераллары» түгел, А.Мачадо сыман бөек шагыйрьләр утырган шул.

Премия алу, язучының нинди җәмгыяви баскычта торуына карамастан, иҗаты өчен зур стимул. Абруйлы зур бүләкләр аны көндәлек ризык өчен казганудан азат итә. Берничә ел элек яңа гына Нобель премиясенә ия булган К.Оэдан беренче тәэсирен сорагач, ул: «Мин баедым», — дигән иде.

Ләкин безнең җөмһүрияттәге премияләр татар язучысын бәйсез дә, бай да итә алмый. Хәтта Дәүләт премиясе булган Тукай бүләге өчен дә бик аз түлиләр. Монда инде түрәләрнең каләм әһеленә мөнәсәбәте ачык күренә. Татар язучысы бәйсез, бай булырга тиеш түгел. Ул мескен хәлдә җан асрарга, түрә авызына карап ләббәйкәләнергә дучар ителгән.

Ниһаять, мин дә гәҗиттән үземнең М.Җәлил премиясенә ия булуымны белдем. Дуслар күп — котлыйлар, Зиннур Хөснияр танышлары аша бүләкнең мең сум күләмендә биреләчәген дә белгән. Шулкадәр акча алып дуслар шәрәфенә ничек табын әзерләмисең? Инде бурычка батып беткәч, нигә премия бирүләренә үкенә башлагач, өлкә комитетына премия акчасы алырга чакырдылар. Кассир кыз кулга 187 сум да фәлән тиен акча сонды. Хөснияр премия бәясен үз исәбе белән билгеләгән икән.

Мәгълүм журналист Марсель Зарипов, Х.Ямашев премиясе белән бүләкләнгәч, әдәби фондка: «Премия алу сәбәпле матди ярдәм күрсәтүегезне үтенәм», — дип, юкка гына гариза язып кертмәгән.

Медаль белән дипломны тантаналы рәвештә тапшырыр өчен комсомолның өлкә конференциясенә чакырдылар. Анда нигәдер барып булмады, комсомол белән партиягә тирән рәхмәтемне җиткерә алмадым. Кызганыч. Юкса бит, Нобель премиясен алучылар дөньяга карашларын тәфсилләп саллы нотыклар сөйләсә, безнекеләр дулкынланудан тотлыга-тотлыга Тукай һәйкәле ышыгындагы эреле-ваклы түрәләргә рәхмәт яудыралар иде. Ул мөнбәрдән мәрхүм М.Мәһдиев кенә рәхмәтләрсез-нисез Тукайның бер шигырен укып төште. Бу вакытта заманалар да үзгәргән, бүләк тә аңа шактый соңарган иде инде.

Шулай да мин Морат Гаделшинга шылтыратырга булдым. Комсомолдагы язмышым белән турыдан-туры шөгыльләнгән кешегә премия өчен ничек рәхмәт әйтмисең? Әмма аны, комсомолдан китеп, бизнес белән шөгыльләнә, диделәр. Комсомол түрәләрнең барысы да алыпсатарлыкка гаҗәеп сәләтле булып чыкты. Анда да, монда да кагыйдәләр шул ук, мөгаен.

Комсомол бетте, аның белән Җәлил премиясе дә юкка чыкты. Ләкин әдәбият калды, аңа аяк баскан яшь иҗатчылар калды. Алар үзләренә игътибар көтә. Заманалар һәрвакыт болай болгавыр тормас, Җәлил бүләге дә янә пәйда булыр. Комсомолсыз-мазарсыз гына...

*Март, 1996*

# ГАСЫР БУСАГАСЫНДА

Һичкем яманның күршесендә булмасын!

*Кол Шәриф*

Туксанынчы еллар ахырында коммунистик режимнарның җимерелүе нәтиҗәсендә безнең халык та бер кымшанып караган иде. Башта союздаш республика статусына дәгъва иттек, аннары, Союз таралгач, халыкара хокук субъекты булырга җыендык. Кайберләребез хәтта, Рәсәйдән котылып, бәйсез дәүләт төзергә дә хыялланып алды. Әмма дәригъ! Империя кулыннан алай гына котылып булса икән... Аю үлеп ятканда да аның әле биш сарыклык көче кала.

Шулай да хыялланып бер яшәп алдык! Күптән инде күңел төпләрендәге өметләрне болай җөрьәт итеп кычкырып әйткән юк иде. Ул вакытта иң популяр сүз безнең өчен шактый ук авыр әйтелешле «суверенитет» дигән сүз иде.

Менә хәзер инде ул сүз дә онытылып бара.

Гасыр бусагасында торабыз.

Нәрсәгә ирештек соң?

Әлбәттә, республика чагыштырмача мөстәкыйльлек алды. Бөтенләй вак-төяк мәсьәләләрне хәл итүне сорап Мәскәүгә чабасы түгел. Шул чагыштырмача мөстәкыйльлектән кемнәр файдаланды соң? Әйе, мәйданнарда «Азатлык» дип кычкырып йөрүчеләргә тирән нәфрәт белән караучы, Мәскәүдән һәр ишарәгә ләббәйкә дип торучы түрә-кара, җөмһүрият байлыгына хуҗа булып, үзләренә таш сарайлар салды, халык икегә — аз санлы морзаларга һәм күп санлы караларга бүленде. Мин монда юкка гына урта гасырлар атамасын кулланмыйм, безнең хәзерге җәмгыятьне бүген хаклы рәвештә «кеше чырайлы феодализм» дип атарга мөмкин.

Шулай. Ләкин бит без үзебез, коммунистик сөремнән котыла бару сөенеченнән, капитализмның ни икәнен белмәгән килеш («Вокруг света» телевизион тапшыруларындагы бай илләрнең кибет киштәләрен күрүдән башка бүтән мәгълүматыбыз да юк иде), романтизмга бирелеп, милли байлар пәйда булуын теләдек. Янәсе, алар Хөсәеновлар, Акчуралар сыман милләт өчен тырыша башлый, мәдәниятебез гасыр башындагы кебек яңа күтәрелеш кичерә! Менә күңелебез кот булды инде — үз байларыбыз да пәйда булды, Шәймиев әйткәнчә, алар салдырган таш пулатларын да үзләре белән теге дөньяга алып китмәячәк, әлеге сарайлар әле озак туган илебезне бизәп торачак. Тик менә милләтнең рухы гына күтәрелгәне сизелми, мәдәниятебез күзгә күренеп сүрелә-сүнә бара, аны тукландырып торучы чишмәләр корый. Хәзер инде безнең күздән дә пәрдә төште: яңа милли байлар дигәнебез элгәреләре төсле буыннан буынга иҗтиһад итеп мал туплаган шәхесләр түгел, ә бер-берсен бай итеп билгеләп куйган шул ук безгә күптән мәгълүм партноменклатура һәм аларның туган-тумачалары икән бит! Болар алдында криминалитет генераллары да бала-чага гына булып кала. Шушыларга синең мәдәниятең кирәкме? Шуларны милләт язмышы борчысынмы? Юк, безнең бай дигән кешеләребез үз кавемнәрен даими кайгырткан яһүд олигархларына һич тә охшамаган шул.

Татарстан мәңге бөтәймәс Рәсәйнең субъекты булып яңа гасырга кереп бара. Без инде үз язмышыбызга ризалашкан мокыт, мескен бер халык. Күтәрелеп Күккә карарга, җилкәләрне турайтырга безнең вакытыбыз да, теләгебез дә юк. Нәрсәнедер җимерәбез, корабыз, тагын җимерәбез. Сугыш кына чыга күрмәсен! Бераз салып алган арада, тиреслек өстенә менеп юк кына нәрсәләр хакында бәхәсләшәбез, мактанышабыз, үзебезнең тыйнаклыгыбыз белән горурланабыз. Борынгы заманнарда тарих битләренә кереп калган татар-

ларның варисымы соң без? Юктыр, ахрысы! Мәгълүм ки, Казан алынганда аның барлык ир-атларын кырып бетерәләр. Хәтта арба көпчәгеннән биегрәк малайларга кадәр кыралар. Хатын-кызларны, бала-чагаларны кол итеп урыс сугышчыларына өләшәләр. Аннан соңгы күтәрелешләрдә татарның иң асыл батырлары һәлак була. Бәс, шулай икән, без бит анда-монда качып калган калдык-постык татарларның токымы. Әле шул токымның күренеклерәк вәкилләре дә XX гасырның репрессияләрендә, сугышларында вәйран булды. Генетик җәһәттән өшәнгән халкыбызның үз хәленнән канәгать булып шыпырт кына җан асравы бик тә табигый икән ич. Әлеге хасиятне истә тотканда, бераз алгарак чыгып, аны азатлыкка, хөр яшәргә өндәгән ул-кызларын тиргәве, хакарәт итүе дә яхшы аңлашыла. Чит милләтнең чабуына тотынып алга бару җиңелдер дә, бәлки. Андый баласымак халык, үзен изеп бер кысада тотсын өчен, үзәк хөкүмәткә рәхәтләнеп, сөенә-сөенә ясак-салым түли. Тик бит без чабуына тотынган милләт кая таба атлаганын үзе дә белми. Шуңа күрә гаепләне эзли, чабуына тотынганнарның башына сугып ала. Янәсе, шулар аркасында гына якты киләчәккә барып җитә алмыйбыз.

Ачлык-ялангачлыкны оныттырыр өчен аз гына мәйданда булса да сугышып алырга кирәк. Хәер, ашыйсы килү теләге ашый башлагач көчәя. Тарихка күз салыйк: Московия дигән нәни генә урыс дәүләте гел «саклану» сугышлары алып барды, шуңа күрә көнбатыш чикләре — Польшага, көнчыгыш чикләре Татар бугазына барып җитте. Көньяктагы геополитик сәясәте Һинд океанына барып терәлә иде шикелле. Урысның күпчелеге хәзер дә шул чикләр турында хыяллана. Кайсыдыр сәяси партия сайлау алды коткысында Октябрьгә кадәрге Рәсәй империясен торгызу турында сүз алып бара. Аңа инде Польша да, Финляндия дә кергән. Әлбәттә, әлеге сәясәтчеләр моның тормышка ашмас хыял икәнен беләләр. Әмма бит аларга урыс халкының иң нечкә кылларында уйнау кирәк. Алар аның психологиясен белә. Урыс үзенең «бөеклеген» сагына. Күтендә ыштан булмаса булмасын, ләкин иле зур булсын да, үзе «бөек» булсын. Аны шул рәвешчә гасырлар дәвамында тәрбияләгәннәр.

Шуңа да «чеченнәргә каршы яңа сугыш башлап җибәргән» премьер-министр В.Путинның рейтингы чүпрә кебек күперә. Инде ул тиздән Рәсәйнең яңа президенты булачак дип фараз итәләр. Булыр да... Урыска каты куллы патша кирәк, үзләрен кыйнаса кыйнасын, тик кемлекләрен оныта башлаган җыен кара күтләрнең, татарванның арт сабагын укытсын. Ә бу күзендә нур булмаган кэгэбешник шуңа охшап тора. Сөйләвен генә карагыз: «Бандитов будем мочить даже

в сортире». «Бандитлар» дигәне чеченнәр була инде. Ә жаргон — төрмәнеке. Рәсәйнең премьер-министры үзе бандитлар жаргонында сөйләшә! Каты куллы хуҗага сусаган көтүгә әлеге белдерү ошады: рейтинг тагын бер башка үсте.

Югыйсә Рәсәй башлыклары гел терминология тирәсендә әвеш-тәвеш киләләр. Урыс бомбаларыннан качкан чеченнәр, янәсе, «беженецлар» түгел, ә «временно перемещенные лица». Анда «сугыш» түгел, ә «антитеррористик операция» үткәрелә, имеш. Фронт авиациясе, авыр артиллерия белән террористларга каршы сугышканны кемнең кайда күргәне бардыр? Бу очракта бер генә фикер туа: димәк, бөтен бер халыкны «террорист» дип игълан иткәннәр. Ул чагында бирәдә бөтенләй бүтән термин кулланырга кирәк. Безнең күз алдында геноцид үткәрелә.

Ике йөз меңнән артык хатын-кызның, карт-корының, бала-чаганың үз илләреннән качуын «гуманитар катастрофа» түгел дип тәкрарлыйлар. Бәлки, Мәскәүдәге илбасарлар өчен бу «гуманитар тантана»дыр, әмма җир йөзеннән юкка чыгу алдында торган чеченнәр өчен бу — чын-чынлап катастрофа.

«Иң зур ялган — яуда һәм ауда» ди халык мәкале. Мәскәүдә һәм бүтән шәһәрләрдә шартлатылган йортларны чеченнәргә каршы сугыш башлауда сылтау иттеләр. Ләкин аларны нәкъ менә чечен террористлары шартлатуын кем исбат итте? Юридик телдә «гаепсезлек презумпциясе» дигән төшенчә бар. Җинаять тикшерелмәгән, хөкем карары чыгарылмаган, ә җинаятьче инде әзер, менә ул — «злой чеченец». Тик һәркем белә: җинаять кемгә файдалы? Чеченнәрнең нәкъ менә сугыш башланыр алдыннан, урыс гаскәре инде һөҗүмгә әзерләнеп беткәч кенә йортлар шартлатып йөрүе сәер.

Мәскәүне 1812 елда французлар яндырды дип әлегә кадәр тарих китапларында язалар. Аны урыслар үзләре яндырып китүен бик сирәк тарихчылар гына белә. 1933 елда фашистлар Рейхстагны яндыралар, аннары бу җинаятьне коммунистларга сылтап, суд эше кузгаталар. Бирәдә мисалларны бик күп китереп булыр иде.

Бу сугыш кемгә кирәк? Әлбәттә, Мәскәүнең сәяси-хәрби элитасына. Беренчедән, әлеге канкоеш сайлаулар алдыннан халыкның игътибарын икътисади бөлгенлектән читкә алып китә. Икенчедән, хәрбиләр өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Җилкәләргә, күкрәкләргә яңа дәрәҗәләр, орден-медальләр тагыла, яу мәйданында яңа кораллар сынала һәм, иң мөһиме, сугыш сылтавы белән болай да хәерче бюджеттан соңгы миллионнарны суырырга мөмкинлек туа, ә ул акчаны бүлгәндә инде аның кайсы учларга йогып калуын күзаллау кыен түгел. «Война все спишет».

Ә бөтен бер халыкның җиңү тәменнән, «бөеклеген», «көчен» күрсәтү ләззәтеннән исерүе турында язып үттем инде. Ләкин сугышны культ иткән халык бәхетле була алмый. Гаскәриләрне милләтнең каймагы дип күрсәтүне табигый юлдан тайпылган кавемдә генә күзәтергә мөмкин. «Гаскәр һәр заманда да вәхшилек коралы булды... Гаскәрнең йөрәк түреннән үзгәрмәс инстинктларның шакшысы күтәрелә. Алар тирания бәрабәренә үтерешне хуплыйлар, нәфрәткә көч бирәләр, комсызлыкны уяталар, зәгыйфьләрне изәләр, түбәннәрне күтәрәләр. Аларның сукыр ярсуы иң яхшы ниятләрне үтерде, иң изге хәрәкәтләрне басты. Даими рәвештә алар тәртипне җимерәләр, пәйгамбәрләрне үлемгә хөкем итәләр». Бу юлларны генерал де Голль яза. Ә ул инде гаскәрнең асылын да, сугышның ни икәнен дә яхшы белгән.

Сугыш юлы милләтне мөнбәргә алып бармый. Әмма сугышта «җиңгән» очракта (чеченнәрне тулаем җиңеп булмый, аларны «җиңәр» өчен соңгы чеченгә кадәр кырып бетерергә кирәк) үзәк хөкүмәтне, аның кулындагы режимны ныгытып була. Ул очракта инде Мәскәүнең «һәрнәрсәне күрә торган күзе» («всевидящее око») милли республикаларга, аерата Татарстан белән Башкортстанга төбәләчәк. «У нас и другие бандистаны есть» — бер телевизион тапшыру вакытында Путинның әйткән сүзләре. Безнең җитәкчеләр моны эндәшми-нитми генә йоттылар. Алар, әлбәттә, аңлый: чечен сугышыннан соң Мәскәү милли республика җитәкчеләрен (сайлаулардан соң властька кем килсә дә) «үз урыннарына» утырта башлаячаклар. Мәскәүнең республикаларны губирналарга әйләндерү мәсләгеннән кире кайтканы юк. Примаков, мәсәлән, премьер вакытында регионнарны эреләндерү фикере белән чыккан иде. Бу фикергә җаны-тәне белән каршы Шәймиев бүген аның көрәштәше булып йөри. Нишлисең, ике явызлыкның җиңелрәген сайларга туры килә.

Гасыр бусагасында торабыз. Милләт буларак ул бусага аша атлап үтә алырбызмы? Моңа, әлбәттә, өздереп кенә җавап биреп булмый. Бусага — биек, без шактый ук тәбәнәкләндек. Мәскәү татарның калкынган башын гел кисә торган. Менә хәзер янә башлар өлгереп җитте. Кылыч та кыныннан кузгалды. «Иелгән башны кылыч кисмәс», — ди татар. Тик баш иеп кенә бу кылычтан котылып булмасын XX гасыр күрсәтте инде.

Мәдәният — һәр халыкның визит карточкасы. Бүтән мәдәниятка ияргән милләтнең киләчәге юк. Бу җәһәттән безнең хәлләр бик аянычлы. Әдәбиятка яңа көчләр килми, сәнгать — авыл клубы дәрәҗәсендә. Мәдәниятне тукландырып торучы авыл үзе хәзер ташландык, болганчык чишмә хәлендә. Без «татар укымышлы халык булган, һәр өйнең

түрендә китап торган» дип шапырынырга яратабыз. Бүген берәр авыл өенә кереп кара, китап түгел, сыңар татар газетасын дә күрмәссең. Дөрес, халыкның акчасы юк, диләр. Ә уйлап баксаң, татар халкы кайчан бай булган соң ул? Монда хикмәт бүтәндә. Китапка мәхәббәтне түрдә торган әрҗә-телевизор алмаштырды. Ә аның кайсы каналына бассаң да — Мәскәү тапшырулары. Татар да, авыз суын корытып, аннан яһүд магнатларының власть бүлгәнен карап утыра. Янәсе, Березовский өстен чыгармы, Гусинскиймы? Кашки, яһүд беркайчан да бер-берсенә каршы көрәшми. Алар халыклар аңын томаларга тиешле галибанә спектакль уйныйлар.

Уен бара. Ул уенны без төшенмибез. Татар башы аңа корылмаган. «Без тынычта аттан артык эшлибез». Нишлисең, бу да үзенә күрә бер юаныч. Тик бер генә үкенеч: эш аты бәйгеләрдә катнаша алмый. Ә халыклар яшәеше — олуг бәйге ул. Анда алдан килгәннәр генә үзенә лаеклы урынны ала.

*Ноябрь, 1999*

## ҮЗЕҢНЕКЕ — ҮЗӘКТӘ

Шагыйребез Роберт Әхмәтҗанның хастаханәдә ятуын ишеткәч, Ләбиб Лерон белән аның хәлен белергә киттек. Без аны коридорда ук очраттык, ул табиб хозурыннан кайтып килә иде. Ябыгып, агарып калган шагыйрь безне палатасына чакырды. Анда тагын өч кеше ята иде. Урыслар икән. Сөйләшеп, боларның тынычлыгын бозмабызмы соң, дигәч, Роберт абый, серлерәк елмаеп: «Зарар юк, зарар юк», — диядия, без килеп керүгә кинәт кенә тараеп киткән палатаның түренәрәк әйдәде. Без бит сөйләшкәндә онытылып китәбез, көлешеп тә куябыз. Хәер, монда бик авыр хәлдәге авырулар юк иде. Шулай да сул яктагы караватта яткан алпамша гәүдәле кешенең чырае караңгылана бара. Тик алай-болай сүз әйтми. Шактый гына сөйләшеп утыргач, без чыгарга кузгалдык. «Радио тавышы ишетелми, бер хәбәрсез ятмыйсыңдыр ич», — ди Ләбиб. «Хәзер бит төш вакыты — татарча тапшырулар». Без аптырап бер-беребезгә карыйбыз. «Радио татарча сөйли башлагач, күршеләр килә дә сүндерә, килә дә сүндерә, — дип аңлатты шагыйрь, — безнең авазны бер дә яратмыйлар инде, мин сезне монда шуның өчен алып кердем, яратмасалар да тыңласыннар әле безнең рәхәтләнеп гәпләшкәнне». — Ул кемгәдер зур этлек эшләгәндәй кетелдәп алды.

Әлеге хастаханә элек партия өлкә комитетыныкы иде, хәзер дә югары статусын югалтмаган. Роберт Әхмәтҗанны да анда, шагыйрь Зөлфәтнең хатыны Фирая апа чабып йөрү аркасында (түрәләр бусагасын таптау буенча тәҗрибәсе зур), «блат» белән генә урнаштырдылар. Күршеләре дә, күренеп тора, безнеңише гади агай-эне түгел. Кайдан килә бу үзгә телгә шундый нәфрәт, куралмау?

Менә хәзер Татарстанның төп Канунын Рәсәй Конституциясенә тәңгәлләштерү эше бара. Бу инде, дөресен әйткәндә, суверенитет кәгазьдә дә калмый дигән сүз. Мәскәү басымыннан файдаланып, үзебездәге «бишенче колонна» да баш күтәрә. Татарстан Дәүләт Советы сессиясендә мәгълүм депутат А.Штанин «Татарстан президенты ике дәүләт телен дә белергә тиеш» дигән маддәгә каршы төште. Янәсе бу — татар телен белмәгән, әмма Президент булырга теләгән гражданнарның хокукына каршы килә. Моны оятсызлык дими, ни дисең? Республикага үз исемен биргән халыкны мыскыл итү түгелме соң бу? Депутатлар «кеше хокукы» дигән коралны өскә күтәрәләр икән, алдан ук белеп торасың, бирeдә татар хокукына хилафлык эшләргә җыеналар. Әллә соң безне кеше итеп тә исәпләмиләрме? Хәер, гади халыкның да татар теленә мыскыллы карашын Казан урамнарында даими тоеп торабыз. Евгений Евтушенко моны «Казанский университет» поэмасының «Татарская песня» бүлегендә бик дөрес тотып алган.

Даже драная шлюха визжит
На седого еврея: «Жид!»
Даже пьяница, падая в грязь,
На татарина: «Эй ты, князь!»
Бедняков, доведенных до скотства,
Научают и власть и кабак
Чувству собственного превосходства:
«Я босяк, ну а все же русак!»

Әйе, татар теленең даирәсен тарайту өстән дә, астан да (власть һәм кабак) алып барылды. Шуның нәтиҗәсендә без үзебез дә туган телебезгә кимсетеп карый башладык, миллионлап үз телен белмәгән «татар дидекемез» пәйда булды. Аларны инде татар дип әйтү дөрес тә булмас, үз телен, мәдәниятен, тарихын белмәгән кеше татар була алмый. Рәсәй паспортыннан «милләт» графасы төшеп калуга бу проблема бөтенләй хәл ителәчәк. Без коточкыч рәвештә упкынга якынлашабыз. Үзгәртеп кору елларында да бу процессны туктата алмадык. Кемнәрдер моңа каршы да төшәр: күпме татар мәктәбе ачылды, балалар бакчаларында татар группалары пәйда булды, хәзер, янәсе, татар балала-

рының илле процентка якыны татарча укый. Кашки, алай түгел шул. Минем үз улым бакчага шундый «татар группасы»на йөри. Ә анда урысча сөйләшәләр. Тәрбиячеләрнең дә тырышуы юкка гына, чөнки бу татар дип аталган балаларның әти-әниләре генә түгел, әби-бабайлары да җүнләп татарча белми.

Мәктәпләрдән, бакчалардан үз теленә, үз мәдәниятенә ия балалар чыкса да (ә бу алай түгел), әллә ни шатланырлык әш юк, чөнки монда сүз Татарстан хакында бара. Ә кече Татарстанда исә, мәгълүм ки, халкыбызның дүрттән бер өлеше генә яши. Рәсәйдәге һәм БДБга кергән илләрдәге татарларның хәле бөтенләй аянычлы. Аларга инде бөтенләй инкыйраз! Хәтта татар телен һәм әдәбиятын атнага берничә мәртәбә предмет буларак өйрәнергә теләүчеләр дә моны булдыра алмый. Чөнки дәреслекләр юк. Казан гына бу мәсьәләне хәл итә алмый. Формаль яктан ул аны хәл итәргә бурычлы да түгел, чөнки Рәсәйдәге татарлар бит салымны Рәсәй бюджетына түлиләр. Гомумән, мондый проблемаларны федераль кимәлдә чишәргә кирәк тә, ләкин Рәсәй, белгәнебезчә, кәгазьдә генә федерация. Чынлыкта исә ул унитар империя булып кала бирә.

Менә ничә ел инде Мәскәү телевидениесендә «Вместе» дигән тапшыру бара. Анда әрмән, молдован, кыргыз һәм башка миллət вәкилләре үз илләре турында сөйлиләр, мәдәниятләре белән таныштыралар. Сорау туа: нигә Федерациянең үзенә кергән халык-җөмһүриятләрнең вәкилләре монда юк? Чөнки Мәскәүдә безне инде күптән урыс дип саныйлар. Ә БДБ илләре Мәскәү геосәясәтенең төп юнәлешен тәшкил итә.

«Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә» диләр.

Мәскәү матбугатында хәзер безгә бик таныш булган гыйбарәләр очрый башлады. «Төрле телләрдә сөйләшүче күпмилләтле илләрдә билингвизм проблемасы яши», — ди Рәсәй хөкүмәте каршындагы урыс теле буенча комиссия рәистәше академик Е.Челышев. — Җиде миллионлы Швейцариядә хәтта өч дәүләт теле. Аурупада кеше хокукларын шулай аңлыйлар («Труд», 7 декабрь, 2000). «Халыкара практика бар, — ди аның әңгәмәдәше, — Финляндия, Швейцария, — анда хәтта җиде процент тәшкил иткән халыкның да мәнфәгатьләре саклана». Мондый мисалларны без күптән язабыз лабаса. Әллә Мәскәүдә безнең чыркылдауны ишеткәннәрме? Татарлар Рәсәйдә ничә процент әле? Наив булмагыз, әфәнделәр! Болар Рәсәйдән читтә яшәүче урысларның телен саклау турында борчылалар. Урыс теленең даирәсе тараю аларны Аурупа мисалы, кеше хокукларын искә төшерергә мәҗбүр иткән. Үзеңнеке — үзәктә! Казакъстан-

дагы бер мәктәпнең директоры шатлыгын болай уртаклаша: «Урыс телен кире кагу чоры (урысчасы: пик контрпродуктивного неприятия. — *Р.З.*) үтте. Һәм күп казакълар инде үз балаларын саф казакъ мәктәпләренә бирергә теләмиләр». Шатлана... Менә бу сүзләрдә урыс холкының, империячел «русаклыкның» асылы ачыла да инде. Син үз телеңне ярат, аны сакларга тырыш, тик бүтән телләрне дә хөрмәт ит...

Дөрес, телләр арасында да көрәш бара. Бер тел һөҗүм итә, үзенең кагыйдәләрен тага, икенчесе чигенә, зәгыйфьләнә һәм бөтенләй юкка чыга. Ләкин, әчке ярыш булса да, аларның үзара дустанә яшәүләре дә мөмкин ич. Монда инде үзара хөрмәтсез мөмкин түгел. Урыс сәясәтчеләре үзләренә кирәк булганда гына искә төшерә торган Аурупа мисалы шул турыда сөйли. Бу җәһәттән шуны да әйтергә кирәк: 2001 елны Аурупа киңәше (Советы) Телләр елы дип игълан итте. Шул уңайдан булса да чит илләрдәге — Рәсәйдәге, Үзбәкстандагы, Казакъстандагы кандашларыбызның хәленә игътибар итик, алар арасында милләттәшләребез күп ич әле. Юкса бер дистә елдан безгә берни дә кирәк булмаячак. Татарга татардан башка ярдәм итүче юк, шуны аңларга вакыт. Хәер, аңласаң да файдасыз: үзара ярдәмләшер өчен безнең кулда берни дә юк бит.

*Декабрь, 2000*

## ИНКЫЙРАЗ

Шәһәрдә кеше күплегеннән тын кысыла башлый. Һәммәсе каядыр ашыга, бәрелә-сугыла үзе генә белгән максатына чаба. Авылда тылы булганнарның бер өстенлеге бар — алар шәһәр ыгы-зыгысына кул селтәп туган нигезгә кайтып китә алалар. Мин дә шулай кешеләрдән туеп, җан тынычлыгы эзләп авылга кузгалам. Күз офыклары киңәйсен бер, ичмасам! Авыл тып-тын. Урамнарда бер кеше юк. Ирексездән Сәгыйть Рәми шигырен кабатлыйсы килә башлый. Тынлык тансык булса да, ул бераздан ялыктыра, ниндидер гайре табигыйлекне сизеп гасабилана башлыйсың... Болай ук булырга тиеш түгел ләбаса! Мин үскәндә, бала-чага тавышыннан урам гөр килеп тора иде бит. Караңгы төшкәч, әни-апалар көчкә өйгә алып керәләр иде. Көндезләрен инде өй бусагасы онытыла — ашарга да вакыт юк, әби шикәр комы сибеп биргән ипи телемен тотып, тагын урамга, үз эшләрең янына ыргыласың...

Хәзер безнең очта берничә бала бар икән... Алары да урамга бик борын күрсәтми, телевизордан мультик карап утыра. Э-эй, кайда сез минем белән уйнап үскән малайлар — Фәрит, Исмәгыйль, Шамил, Фәнил, Мәсгут, Рафик, Рәшит, Нурислам! Билгеле инде, алар булмагач, киң урамнарны тар итеп йөгерүче балалары да юк. Алар иксез-чиксез Рәсәй киңлекләренә сибелгәннәр. Хәер, татар да хәзер элеккечә үк сибелә алмый, белүемчә, минем яшьтиләрнең дә балалары йә берәү, йә икәү...

Тел төбен аңлагансыздыр инде. Әйе, һаман да шул демография дигән четерекле мәсьәләгә килеп төртеләбез... Хәер, «һаман да шул» дию дөрес булмас, бу мәсьәләдә дәүләт күләмендә чаң суга әлегә күренми. Ә бит демографлар күрсәткән саннарга күз салсаң, чәчең үрә торырлык. Без тел дибез, мәдәният, тарих дибез, шуларны саклау, белү турында кайгыртткан булабыз, әмма халкыбызның зур куркыныч — физик яктан да юкка чыгу алдында торуын күрмибез.

Әлбәттә, татар халкының гына демографик процессын өйрәнүче фәнни оешма юк, шуңа күрә Рәсәй демографларының мәгълүматына күз салырга туры килә. Шулардан чыгып, без халкыбызны тиздән чын-чынлап инкыйраз көткәнен аңлыйбыз. Чөнки туу-артым җәһәтеннән дә, үлем-төшем җәһәтеннән дә татарлар урыс белән бер кимәлдә тора. Ләкин урысларның санын безнеке белән чагыштырып булмый бит. Аларның инкыйразы йөз елга сузылса, безнекенең кайчан җитәчәген санап чыгару читен эш түгел.

Әйе, әйе, урысларны да инкыйраз, ягъни тәмам юкка чыгу көтә. Шуны күреп алар дәүләт кимәлендә дә борсалана башладылар шикелле. Рәсәй президентының Федераль җыенга җибәргән мәктүбендә мондый юллар бар: «15 елдан ук инде рәсәйләр 22 миллионга азаерга мөмкин». Бу күзаллау демографларның исәпләүләренә дә тәңгәл килә. Америка демографы Фишбург, мәсәлән, гасыр уртасында Рәсәйдә 75–100 миллион кеше яшәячәк дип исәпли. Әлбәттә, безгә бөтенләй үк борын салындырырга ярамый: шул миллионнар эчендә берничә мең татарның да исән калуы ихтимал.

Билгеле, урыслар яисә татарлар этнос булып юкка чыгудан гына Рәсәй дә, Татарстан да япан кырга әверелмәс, изге җир буш тормый. Ерак Көнчыгышта (Себердә үк булмаса әле) кытайлар хакимлек итәчәк, алар инде аны бүген үк тыныч кына биләп маташа. Безнең тирәләргә Африкадан негрлар күчеп килергә мөмкин. Хәер, Кавказда, Урта Азиядә дә халык саны кирәгеннән артып, алар өчен яшәргә яңа җирләр кирәк булачак.

Бәлки, бу хәл табигыйдер? Халыклар элек-электән җирдә алмашынып торган. Скифларның искиткеч бай культура-

сын өйрәнгән кебек, киләчәктә безнең мәдәният кыйпылчыкларын җир катламнарыннан эзләрләр. Монда күчеп килгән берәр халык, бу җирләргә тарихи хокукын купайтырга теләп, безне әле үзенең бабалары дип тә игълан итәр...

Ләкин, без, урыстан гайре буларак, демографик һәлакәт аркасында гына түгел, табигый ассимиляция аркасында да юкка чыга барабыз. Татарның инкыйразы ике-өч тапкыр тизрәк якынлаша.

Табигый ки, үрчем булсын өчен һәр гаиләдә кимендә өч бала булуы мәҗбүри. Хәзер Татарстанда өч балалы гаилә күп балалы гаиләләр исәбенә керә. Өч бала тапкан ана инде — каһарман! Шуңарга аңа ниндидер өстенлекләр дә бирелә шикелле.

Нигә бүген балаларны аз табалар соң? Моны төрлечә аңлаталар. Иң беренче сәбәп, янәсе, илдә тормыш хәленең начараюы. Ләкин, уйлана калсаң, бу сәбәпнең җитди булуына ышанасы килми. Моннан утыз-кырык ел элек яисә тагын да элгәре, илдә тормыш яхшырак булганмы әллә? Киресенчә... Ул вакытларда, гомумән, ачлы-туклы яшәгәннәр. Бер кием, тәмам тузганчы, олы баладан кечесенә күчә барган. Шулай да күпчелек җиде-сигез бала тапкан. Димәк, хикмәт ярлылыкта гына түгел. Дөрес, аны да бөтенләй читтән төшерергә ярамый. Баланы кеше баласы кебек киендерә, тәрбияли алмыйсың икән, ятканда алны-артны уйлыйсың...

Минемчә, төп сәбәп безнең әхлак бозылуында. Бүген кеше, баланы кайгырту, тәрбияләү урынына үзе яхшырак, иркенрәк яшәп калырга ашыга. Дин тәэсире бетү дә шул әхлак бозыклыгына барып тоташа. Бигрәк тә безнең дин күпләп бала үстерергә куша бит. Чөнки картлыкның матурлыгы балаларның күплегендә, аларның игелегендә... Ә бездә картлар йортына урнашу өчен чират. Киләчәктә ул чират тагын да зураер әле, мөгаен.

Хөкүмәт сәясәте дә халык саны кимүенә китерә. Халык аз булса, аның мәшәкате дә кимрәк... Әмма дәүләткә солдатлар кирәк, шуңа күрә ул бу мәсьәләгә бөтенләй үк битараф була алмый.

Үз традицияләрен югалтмаган бүтән төрки халыкларда аз балалы булу, гомумән, хурлык санала. Мин, мәсәлән, үзем, бер бала атасы буларак, анда бөтенләй күтәрелеп карарга да оялып йөрер идем. Хәер, татарның туксан проценты шундый оялчанга әверелеп иде.

Без шул оятны төрки-мөселман халыкларына хас булган гореф-гадәтләребез белән бергә югалттык. Бездә хәзер урыс менталитеты. Ул менталитетның төп үзенчәлеге нәрсәдә

соң? Эчүчелектә. Без инде «өлкән туганнан» һич тә калышмыйча эчәбез. Хәтта арттырып та җибәрмибезме әле? Менә шушы хәл турыдан-туры әхлакка, ягъни әхлаксызлыкка һәм демографик процесска барып ялгана. Туу-үрчемнән үлем-төшемнең күп булуы, уйлап баксаң, шул ук эчкечелеккә барып тоташа бит. Нәтиҗәдә ир-атларның күбесе пенсия яшенә җиткәнче үк үлә. Юл һәлакәтләрендә, төрле вак ызгышларда сукса тимер өзәрлек ирләр кырыла. Үзүзен үтерүчеләр күпме?! Дөресен әйткәндә, моның төбендә дә эчкечелек ята бит. Хәер, ир-атлар гынамы? Исерек килеш аягүрә сиеп йөргән татар хатыннары да хәзер буа буарлык...

Менә без ун ел инде, мәчетләр саны арта, динебез үсә дип шатланабыз. Ләкин минем бер генә мулла авызыннан да: «Бала табыгыз, бала төшерү зур гөнаһ ул», — дип сөйләнгән вәгазь ишеткәнем юк. Әллә сөйлиләрме, сөйләгәннәре халыкка гына килеп җитмиме?

Хәер, вәгазь белән генә хәлне үзгәртеп тә булмыйдыр инде. Шуңа күрә күп кенә демографлар демографик һәлакәттән аралар өчен кырку чаралар күрергә — абортларны тыярга, бала юклыкка салым түләүне кертергә, хәтта һәр хатын-кызга дәүләт тарафыннан өч баладан да ким тапмаска дигән күрсәтмә бирергә чакыралар. Дәүләт күрсәтмә бирергә ярата инде ул. Әмма, минемчә, күрсәтмә белән бергә балалы гаиләләргә зур социаль ярдәм дә бирелергә тиештер. Һәм бу ярдәмдә тулы гаиләләрнең (әтисе дә, әнисе дә булган) дәүләт өчен зуррак булуын теркәп кую мәгъкуль.

Менә шуларны яздым да үзем дә аптырап куйдым. Бәлки, бу чаралар, вәгазь-фикерләр батканда саламга ябышу гынадыр? Демографик һәлакәтнең сәбәбе, бәлки, бик өстә ятадыр? Мәгълүм ки, һәр халык, аерым кеше кебек үк, туа, үсә, картая, үлә. Татарлар да, урыслар да, һәм, гомумән, ак тәнле раса, картаюның чигенә чыкмады микән? Үрчем бит алга киткән Көнбатыш илләрендә дә юк. Анда әле табигый гомер озынлыгы аркасында гына балласт саклана. Бәлки, тавыш-тынсыз гына китә белергәдер... Яшь, көчле этносларга урын бушатырга?..

Юк, мин язманы бүтәнчә тәмамлыйм: күбрәк бала ясарга кирәк!

*Гыйнвар, 2001*

# ХАН КАПКАСЫ КАЙ ТӨШТӘ?..

Моннан ун ел чамасы элек мин Кырымда булган идем. Кырым татарлары илләреннән куылган көнне искә алу җыенына чакырдылар. Андый чакта гадәттә яңа танышлар белән адреслар алмашасың. Гарифҗанов урамыннан икенемне ишеткәч, Сәрвәр исемлесе сагышлы елмаеп куйды: «Бездә дә кайчан татар исемле урамнар булыр...» Мин үземнең шунда Адоратский яисә Челюскин урамында тормавыма сөенеп куйган идем.

Кырымда урам исемнәрен генә түгел, авыл-калаларның да атамаларын алмаштырып бетергәннәр. Отрадное... Солнечное... Бөтен бер халыкның кояшын сүндереп, Кырым кояшына сөенергә теләгәннәр. Акмәчет Симферопольгә, Карасубазар Белогорскига әверелгән. Колонизаторлар төп халыкны үз җирләреннән куу гына түгел, алар турында хәтерне дә юкка чыгарырга омтылганнар.

Хәзер мин Фучик урамында яшим. Бик озын урам, проспект дияргә дә була. Күршем Фучикның кем булуы турында сораган иде. «Фашистлар үтергән чех журналисты. Безгә «Кешеләр, уяу булыгыз!» дип әйтеп калдырган», — дидем. Һәрхәлдә, урамга исемен бирерлек кеше. Ләкин сораулар да туа: шундый ук фаҗигале язмышка дучар булган Хәйретдин Мөҗәйнең исемен нигә мәңгеләштермибез? Яисә Прагада Муса Җәлил урамы бармы соң?

Кемдер санап чыгарган: Казанда татар исеме бирелгән урамнар өчтән бер өлешне генә тәшкил итә икән. Хәтта аннан да азрак түгелме әле... Гадәттә, татар эшлеклеләренең исемен читтәгерәк, кечкенәрәк, аулаграк урамнарга тагалар. Хәтта Муса Җәлил урамы да берничә йорттан торган кумырык кына... Сәйдәш исеменең Пелатән төрмәсенә терәлгән бер нәни урамга ничек бирелүен дә беләбез... Казан үзәгендәге урамнарга күз салыгыз әле! Бауман, Киров, Толстой, Горький, Маркс, Щапов... Ирексездән аптырарсың — татар башкаласымы соң бу? Әллә безгә, патша заманындагы кебек, Болак аръягында гына урынмы? Ә бу якка — үзәккә — «татарлар һәм этләр кертелми»? Хәер, атаклы Печән базары урынын кисеп үткән урам да Киров исемен йөртә бит. Әле татар дөньясына нининдидер кагылышы булган бер шәхес булса ярар иде. Сталин холуе, сөяркәсенең ире тарафыннан үтерелеп, соңыннан потка әверелгән кеше. Югыйсә бу төштә Казан ханлыгы чорында Кораиш бистәсе булган. Нигә шул исемне яңадан кайтармаска? Ул чорлардан безнең көннәргә килеп җиткән атамалар алай күп түгел ич. (Юк, бу урамга патша вакытындагы Мәскәүски исемен кире кайтардылар. — *Р.З.*)

Инде Казанның меңьеллыгын бәйрәм итәргә уйлыйбыз икән, атамаларда да аның чынлап борынгы шәһәр булуы күренеп торырга тиеш.

Террористларның, башы бозыкларның исеменнән арынырга вакыт бит инде, җәмәгать... Бауман, Халтурин, тагын әллә кемнәр. Төп урамыбыз Бауман исемен йөртә! Революциягә кадәр аны Проломная дип атаганнар. Тарихи һәлакәтне искә төшереп торучы бу атама татар күңеленә якын түгел, әлбәттә. Ханнар заманында бу төш ничек аталды икән? Урамнар тәртибе әллә ни үзгәреш кичермәгән бит. Чөнки урамнар ландшафт тәэсирендә сузыла. Бәхеткә күрә, Казан капкаларының исемнәре безнең көннәргә килеп җиткән. Аларның якынча урыннары да билгеле. Мәсәлән, Болак каршында, хәзерге Бауман урамы буйлап, Түбән, Көбәк, Нугай (Кырым) капкалары урнашкан булган. Бауман урамына шулардан берәрсенең, мәсәлән, Нугай исемен биреп була ич. Күп кенә төрки кардәшләрнең безне нугай дип атауларын да искә алсак... Бүтән капка исемнәре дә җырлап тора: Аталык, Арча, Нургали (атаклы дәүләт эшлеклесе Ширин), Алабуга (яки Илбуга), Хан капкалары. Арча капкасы хәзерге Опера театры тирәсендә була. Нигә К.Маркс урамын Арча урамы дип алмаштырмаска? Шунысы да мәгълүм: Покровская урамын (хәзерге Зур Кызыл) әле XVIII гасырда да Арча урамы дип йөрткәннәр. Ленинград, Волгоград урамнары бар, ни өчен үзебезнең тарихи Арча урамы булмаска тиеш Казанда?

Хан капкасы хәзерге Ленин бакчасы тирәсендә булган. Хан болыннары яңа йортлар астында калган, бакчаны гына булса да, бәлки, ханныкы дип атарга кирәктер... Хәер, «хан» сүзеннән без һаман да шикләнәбез әле. Чөнки ул татарның бәйсез, көчле чагын искә төшереп тора. Мәскәү матбугатының Шәймиевтән хан дип көләргә маташуын искә төшерик. Алар көлкегә чыгарырга теләсә дә, — хәтер кыска! — безгә көлке сүз түгел ул.

Хан дигәннән, нигә Казан дәүләтенә нигез салган Олуг Мөхәммәдкә яисә Мәхмүд ханга һәйкәл юк? Икесен атавымның сәбәбе: тарихчыларның кайберләре ханлыкны Олуг Мөхәммәд оештырган дип санаса, кайсылары аның улы Мәхмүд ягына авыша. Һәйкәл салу хәл ителсә дә, безнең янә ике нарат арасында адашып калуыбыз бар. Болар икесе дә зур тарихи шәхесләр, атаклы яугирләр.

Мин, мәсәлән, һәйкәлдә, атка менгән Мәхмүд хан янәшәсендә тезген тоткан Олуг Мөхәммәдне күрәм. Илбасарлардан сакланыр өчен хан яуга нәкъ менә улларын (аның әле тагын Якуб, Касыйм исемле уллары булган) җибәрә бит.

Президент белән бер очрашу вакытында мин бу турыда

сүз кузгаткан идем: «Татар гомер-гомергә атка мөкиббән халык, сез үзегез дә аңа битараф түгел, ә Татарстанда бер генә дә атка атланган кеше һәйкәле юк. Бәлки, бу Ленин һәйкәлен алып, аның урынына атка менгән Олуг Мөхәммәд сынын куярга кирәктер?» «Иҗтимагый фикерне кузгату — сезнең бурыч, — диде Президент. — Әлегә менә безгә Кол Шәриф мәчетен корып бетерергә иде». Мин һаман үземнекен тукыдым: «Олуг Мөхәммәд шәхесеннән шикләнсәгез, — Мәскәү белән сугышырга мәҗбүр булган! — ат һәйкәлен генә куярга кирәк, җайдагын киләчәк буыннар табар иде әле». Шунда янда утырган Туфан Миңнуллин кырын карап куйды: «Монда да сүзне шаяртуга борма инде...» Ләкин шаярту түгел иде бу, тарихи шәхесләребезгә һәйкәл куярга җөрьәт итмибез икән, атны гына булса да зурларга кирәк. «Ир канаты ат булыр...» Бүген алар да нәкъ безнең хәлдә бит... Аннары тиз генә атның милләтен дә тәгаенләү мөмкин түгел...

Президент шул очрашуда Кол Шәриф мәчетенә кагылышлы гыйбрәтле вакыйганы да сөйләгән иде. Б.Ельцин Казанга килгәч, аңа төзелеп яткан Кол Шәриф мәчетен дә күрсәтәләр. Урыс Президентын нәрсә кызыксындыра дип уйлыйсыз? «Бу Благовещение соборыннан биек булмастыр бит?» — дип сорый ул. Шәймиев аптырап калмый: «Аларның икесеннән дә Сөембикә манарасы биегрәк булачак», — дип җавап бирә. «Сез аңа: бу яктан караганда Кол Шәриф мәчете биек, сезнең яктан караганда — Благовещение соборы, дип җавапларга иде», — дип, Туфан абый да сүзгә кушылды. «Тапкыр җавап тиз генә башка килми бит ул», — дип уфтанды Президент.

Аңарчы ук проектта мәчетнең манараларын кыскартканнар иде югыйсә. Шәһәрнең архитектурасы өчен җаваплы татар хатыны: «Теге вакытта җиңелгән өчен реваншизм булырга тиеш түгел», — дип язып та чыккан иде. Алар уенча, безнең мәчетләр тавык кетәклеге кебек кенә булырга тиештер инде. Реваншизмда гына гаепләмәсеннәр! Бистәдәге мәчетнең манарасы биеклегеннән зарланып Әби патшага килгән Казан урыслары турында тарихи риваять тә бар ич. «Мин җирдә генә патша, — дигән аларга акыллы алман хатыны. — Күк йөзе минем компетенциягә керми».

Президентның «Кол Шәриф мәчетен корып бетерергә иде» дигән сүзләрендә тирән мәгънә бар. Мәчет әле салынып бетмәгән, әмма аның кыяфәтенә Мәскәүдәге кемсәләр гел дә битараф түгел инде. Путин, килгәч тә, Петербургтагы мәчет моңардан барыбер зуррак та, матуррак та, дип, Шәймиев белән бәхәскә кергән. Әлбәттә, безнең Президент та сүзен бирергә теләмәгән (хәзер булса тиз генә ризалашыр иде,

мөгаен). Шуннан соң Путин: «Менә мөфтидән сорыйк, ул алдарга ирек бирмәс. Кайсысы матуррак?» — дип, Госман хәзрәткә мөрәҗәгать иткән. «Сезгә мин моны Мәскәүгә баргач әйтермен», — дигән зирәк мөфти. Татарның дипломатиясе юк, дип моннан соң кем әйтә ала?

Безгә килеп җиткән атамалардан Кремльдәге Таҗик ерынтысын, Утуч (Үтәш?) мәчетен, Таһир мунчасын искә аласы килә. Казанның меңьеллыгын билгеләгәндә бу исемнәрне мәңгеләштерергә иде бит. Сөембикә, Нур Солтан, Сафа һәм Сәхиб Гәрәйләр, Мөхәммәдъяр, Чапкын, тагын бик күп затлы исемнәрне урамнарга, мәйданнарга биреп, бу шәхесләрне киләчәктә яд итәргә тиешбез.

Борынгылык Кремльдә табылган чех акчасы белән генә билгеләнми. Иске йортлар юкка чыга барса яисә реставрация сылтавы белән танып булмаслык үзгәрсә, Казан Чаллыдан яисә Иждаудан нәрсәсе белән генә аерылып торыр соң?

Казанның меңьеллыгын билгеләргә җыену болай да кайберәүләрнең эчен пошыра. Ничек инде, янәсе, Казан башы белән Мәскәүдән дә картрак булсын?! Шуңа күрә Мәскәү үзегендә тагын да борынгырак әйберләр табып алганнар. «Аргументы и факты» гәҗитенең хәбәр итүенчә (№ 6, 2001), анда инде Мәскәүнең 1100 еллыгын билгеләүгә әзерлек тә бара, имеш. Югыйсә 850 еллык бәйрәмне күптән түгел генә үткәргәннәр иде. Шул уңайдан бер иске анекдот искә төшә. Грузиннар Тбилисиның мең ярым еллык юбилеен үткәргәч, имеш, әрмәннәр Ереванның ике мең еллыгын бәйрәм итәләр. Грузиннар ах та ух килә икән, нигә инде башкалабызга башта ук ике мең ярым яшь куймадык, янәсе.

Әлбәттә, шәһәрнең яшен билгеләү — шартлы нәрсә. Иң мөһиме — аның тарихына, язмышына кендегең белән бәйләнгәнне тою.

Кирмәндә археологлар казына. Менә җир катламы астыннан борынгы таш дивар килеп чыга. Кем белә, бәлки ул Сафа Гәрәйнең кул җылысын саклыйдыр, шунда Сөембикәнең күз яше тамгандыр... Бәлки, Мөхәммәдъяр шуңа аркасын терәп Сәхиб Гәрәйгә мәдхия язгандыр... Безнең Казан җир астында. Андагы исемнәрне көн яктысына чыгарырга кирәк. Аларда безнең фаҗигабез, түгелгән каныбыз, өметебез. Сафа Гәрәйләр кеше-урам булып киләчәккә сузылсын, Сөембикәләр кеше-кораб булып безгә сәлам юлласын...

Һи, мин бигрәк наив та инде... Казанның топонимикасы хакында моңарчы да күпме сүз булды. Милли хәрәкәт иң көчәйгән чакта да үзгәрмәгән урам исемнәре киләчәктә дә шул килеш калыр... Моннан соң да Сәйдәш һәйкәленә уңайлы ландшафт табылмас. Кемгә кирәк ул синең Гәрәйләрең, Мөхәммәдъярларың... Татар теленә тоташтан һөҗүм бара.

Аны тагын кысрыклыйлар, типкәлиләр, мыскыл итәләр. Ә Казанның меңьеллыгы? Тагын үзәккә кеше бөялер, фейерверклар төнге күкне яктыртып алыр, бүтән телдә исерек авазлар ишетелер. Юбилейга дигән акчаны әвеш-тәвеш китергән агайлар үзләренең хан сарайларында канәгать елмаер... Хәер, хан сарае кечкенә, «хан» сүзенә урын юк, бу корылмаларны хәзер «яңа урыслар»ның коттеджлары яисә виллалары дип атыйлар бугай...

*Февраль, 2001*

## АВЫЗЛАР ЙОМЫЛГАНДА

Узган ел татар матбугатында чыккан публицистик язмаларны барлап чыктым. Аларга нindидер бәя бирү бик кыен икән. Чөнки публицистика аерым жанр булудан бигрәк, әдәби иҗатның бөтен катламнарына үтеп керә. Мәсәлән, кулга бер повесть-бәянне алып, аның әдәби эшләнешенә, андагы образ-персонажларга сокланырга теләсәң, бераздан аның гап-гади бер публицистик язма булуы ачыклана, ә геройларның һәммәсе «Социалистик Татарстан» гәҗитендә эшләүче гадәти журналист теле белән сөйләшә. Шигырьләрнең дә күбесе шулай — образлылыкны, сурәтләү чараларын онытып, автор еш кына «публицистик» ачыргалана. Монда, әлбәттә, эш таланттан гына тормыйдыр, татар яшәешенең үзенчәлеге дә бу күренештә үзен сиздерәдер. Шулай да, минемчә, публицистика дигәндә мәкаләләрне — нindидер аерым сәяси вакыйгага үз мөнәсәбәтеңне күрсәткән нәни язмалардан алып аналитик мәкаләләргә кадәр булган кишәрлекне үз эченә сыйдырган публикацияләрне күз уңында тотарга кирәктер.

Һәркем күреп тора — соңгы бер ел эчендә генә дә илдә сәяси вазгыять бик нык үзгәрде. Хәер, аның үзгәрә башлавы элегрәк тә сизелә иде инде. Нәкъ менә публицист язучылар үзләренең аналитик мәкаләләрендә Рәсәйнең сәяси истеблишментында унитар-шовинистик көчләрнең уянуын күптән фараз иттеләр. Дөнья сәхнәсендә моңарчы һәр илне шомландырып торган Рәсәйнең тарихи кумырыкта калуына реакция буларак пәйда булган ул көчләрнең сәяси җитәкчелекне үз кулларына алачаклары да күзе ачык кешегә күренә иде. Аларның исә, демократик кыйммәтләр турында сөйләнгән хәлдә, власть вертикален тәгаен игълан итүләре бик күп кешеләргә тарихи сабакны, репрессив ысулларны искә төшерде. Һәм, билгеле, шул җәһәттән 2000 елдагы публицистика туксанынчы елларга караганда сизелерлек үзгәр-

де. Шактый гына иптәшләр, Тукай әйткәнчә, «яфрак астына» постылар, байтак әһелләребез гаҗәп тиз арада үз кыяфәтләренә кайттылар.

Соңгы ун елда татар публицистикасының мәсләген нинди принциплар билгели соң? Һич икеләнмичә әйтеп була: болар — бәйсезлек, мөстәкыйльлек, суверенитет идеяләре. Шул мөкатдәс әшьяларны халыкка җиткерү максатыннан публицистларның күбесе тарихи тәңгәллек ысулыннан файдаланды. Шуңа да язучыларның үзләрендә дә тарих белән кызыксыну көчәйде. Чөнки тарихи хәтер — милләтне милләт итеп саклаучы төп көчләрнең берсе. Без — үткән дәверләрдә үз дәүләтебезне тоткан халык, хәзер дә безнең үз мөстәкыйль дәүләтебез булырга хаклы.

Шушы факторларны истә тоткан хәлдә, татар публицистикасының төп юлы киләчәктә дә үзгәрмәс дип уйлыйм.

Ләкин сүз халыкның йөрәгенә барып җитсен дисәк, ул коры аргументлардан, шәрран ярулардан, фактларга гына нигезләнүдән кала әдәбиятның сәнгати чараларыннан да файдаланырга тиеш. Испан драматургы А.Галаның бер сүзе бар: жанрлар — прозамы, драматургияме, публицистикамы — минем өчен савытлар гына, ди ул, ә аларның эчендә һичшиксез поэзия дигән шәраб булырга тиеш. Поэзия дигәндә ул, әлбәттә, хискә бирелеп сафсата сатуны түгел, ә шигърияттнең бөтен бер арсеналыннан файдалануны күздә тота.

Безнең публицистиканың, кайбер очракларда адресатына барып җитеп тә, йөрәк кылларына кагылмыйча юкка чыгуын мин шул поэзия җитмәү белән бәйләр идем.

Әлбәттә, укучылар даирәсе дә тарайды. Бездә хәзер гомуммилли гәҗит дип атарлык басма да юк. «Татарстан яшьләре»н шулай атарга буладыр да, бәлки... Ләкин аның үзенең аудиториясе бар.

Тиражлары аз басмалар бюджет акчасына бәйле, шуңа күрә аларга алны-артны карап яшәргә туры килә. Билгеле, үз эчебездә утырган цензорны да онытмаска кирәк, шушы чагыштырмача иркен булган ун ел дәвамында да без ул комплекстан котыла алмадык.

Публицистика, нәфис әдәбият әсәрләреннән үзгә буларак, бик тиз арада укучысына яисә тамашачысына барып җитәргә тиеш. Бу җәһәттән радио-телевидениенең әһәмияте бик зур. Татар радиосы әлеге мәсьәләдә, минемчә, оператив эш итә. Татар милләтенә кагылган бер генә сәяси вазгыятькә дә анда үз мөнәсәбәтләрен белдерми калмыйлар. Әмма телевидение турында бу сүзне әйтеп булмый. Татар телевидениесеннән без күбрәк концертлар, спорт ярышлары гына карый алабыз. Үз телебездә информацион-аналитик программалар юк кимәлдә. Булганнары да көн таләпләренә

җавап бирми. Соңгы елларда, гомумән, публицист язучыларның экраннарга чыгуын мин бөтенләй хәтерләмим. Элегрәк вакытларда «Язучы мөнбәре» кебек тапшырулар күзгә чалына иде.

Бу кыска гына күзәтүдә татар басмаларында чыккан барлык язмаларга кагылып үтү мөмкин түгел. Моның кирәге дә юк. Татар газета-журналларына күз салып барган кешеләргә безнең публицистиканың хәле болай да билгеле...

Былтыр әһле каләмне генә түгел, барлык зыялыларны да кузгатып алган язма татар матбугатында түгел, Мәскәү гәҗитендә дөнья күрде. Мин Р.Мөхәммәдиевнең «Новые Известия»дә (17.10.2000) дөнья күргән «Перемены просто необходимы» дигән мәкаләсен күздә тотам. Биредә аңа анализ ясарга да, бәя бирергә дә җыенмыйм, ул мәкалә уңаеннан инде Казанның татар матбугатында да, урысныкында да сүзләр булды. Роберт Миңнуллин аңа җавап хаты да язды. Алар шулай ара-тирә бер-берсенә ачык хат язгалыйлар. Язучыбыз Әхәт Гаффар да боларга карата үзенең мөнәсәбәтен белдергән иде. Тик мөнәсәбәтнең нинди булуын гына аныклап булмады.

Р.Мөхәммәдиевне аңлыйм мин. Ул, депутат булып сайлана алмагач, бик тырышып, Мәскәүдән халык мәнфәгатьләрен кайгырта башлады. Үзгәрешләр кирәклегенә дә ышанам. Р.Мөхәммәдиев М.Шәймиевнең өченче мәртәбә Президент булып сайланырга омтылуын гаепли. Әмма мин бер нәрсәне генә аңламыйм: нигә Р.Мөхәммәдиев, Язучылар союзының Уставын бозып, җан-фәрманга рәис булып калырга тырышканны (зур власть та түгел югыйсә), М.Шәймиев Президент кадәр Президент кәнәфиен саклап калырга теләмәсен әле? Бик табигый теләк. Бу теләкне хәтта бик тырышып Зөлфәт Хәким дә яклады. Хикмәт анда түгел. Хикмәт мәкаләнең башында безнең милли матбугатыбыз турындагы кайбер юлларда: «...Национальная печать больше акцентирует внимание на его (т.е. Шаймиева. — *Р.З.*) подвиги в схватках с главным источником зла — федеральной властью». Һәм менә тагын: «В местной печати еще до сегодняшнего дня встречается широко распространенное в свое время словосочетание, как «соседняя Российская Федерация». Мондый өслүб сезгә берәр нәрсәне хәтерләтәме? Әйе шул, хәтерләтә. Мондый жанрның үз исеме бар.

Ә бит Чехов үләренә бик аз вакыт кала «Мин үз гомеремдә шигырь белән донос кына язмадым» дип сөенгән.

Боларга өстәп кайбер «публицистларның»: «Татар милләтчеләре «Мирас» журналын тартып алмакчы була», — дип тавыш күтәрүләрен, Мәскәүгә язуларын да искә төшерсәк, безне әле алда нинди көткәнен чамалавы авыр түгел.

Хәер, моның өчен тарихка гына борылып карарга кирәк. Барысы да билгеле, ярлыклар әзер — үз телеңне белергә телисең икән, син — милләтче, латин алфавиты дип мөгрәсәң, син — пантюркист, малаеңны сөннәткә бирсәң, син — ислам фундаменталисты.

Күреп торабыз: Мәскәү безнең элекке автономиядә булган хокукларны да тартып алмакчы була. Максатчан рәвештә анда Татарстанны гадәти бер Казан өлкәсенә әйләндерергә маташалар. Авызга су кабып торсак, күп тә үтмәс, яңадан безнең мәктәпләрне дә ябачаклар, рухыбызны сындырачаклар. Хәзер инде Мәскәүнең милли мәсьәләләр буенча кайбер белгечләре Казанны яңадан алу турында да сүз алып бара. Күптән түгел Казанга Федератив багланышлар буенча конференциягә килгән А.Дугин «Завтра» гәҗитендә (№ 21, 2000) менә ничек язган иде: «Сегодня мы имеем шанс реализовать великое прозрение, которое носил в себе наш Царь (И.Грозный) — третьей столице, великой евразийской Казани — быть!»

Ә нигә язмасын, алар бит каршыларына Шаһгалиләр, Камайлар йөгереп киләсен бик яхшы белә.

Публицистиканың торышы турында сөйләшкәндә без иң беренче нәүбәттә менә шуларны истә тотарга тиеш.

Теге чакларда бөтен мәйдан «Азатлык!» дип кабатлаганда аларга кушылып кычкыру җиңел иде, менә хәзер — бөтенесе тып-тын калганда — берүзең шул изге сүзне оран итәр өчен куш йөрәкле булу кирәк...

*Апрель, 2001*

## КАРМАЗИН

Соңгы елларда безнең телгә дә «инаугурация» дигән сүз килеп керде. М.Шәймиевнең өченче тапкыр Президент вазифаларын үтәргә керешкән көнне бәйрәм иткәндә бу сүз телләрдә шактый еш яңгырады.

Юкса элек бу вакыйганы безнең халык «тәхеткә күтәрү» дип атаган. Ханны келәмгә бастырып, дүрт яктан дүрт ил агасы аны өскә күтәргән, өстенә алтын акчалар сипкәннәр. Мулла хөтбә укыган. Соңыннан ярлы-ябагайларга, дәрвишләргә бүләк өләшкәннәр.

Боларны искә төшергәч, Шәймиевкә карата «тәхеткә күтәрү» сүзен кулланып та булмыйдыр, мөгаен. Ул күптән тәхеттә бит инде. Алай дисәң, кайбер Казан ханнары да

тәхеткә берничә мәртәбә менгәннәр. Мәсәлән, Шаһгали дә өч тапкыр Казан белән идарә итеп карый. Турыдан-туры Мәскәү кушуы буенча... Шуңадырмы, озак утыра алмый... Ул вакытта нигәдер Казанда Мәскәү сүзенә колак салмаучы кешеләр дә байтак булган.

Мәскәү дигәннән, әлеге тантанага зур түрәләр аннан да шактый килгән иде. Премьер-министр урынбасары В.Матвиенконың чыгышын аеруча яратып кабул иттеләр. Ватып-җимереп ул берничә сүз татарча әйткән иде. Тукайның да теге мәгълүм юлларын татарча сөйләргә маташты: «...без туган бер җепкә бергә теркәлеп...» Аны инде искә төшермәсәләр дә яхшы беләбез: энә кайда, җеп шунда...

Алга китеш бар: күптәнме әле без үзебезнең обком секретаре залга «Хурьматлы дуслар!» — дип мөрәҗәгать иткәч, авызны җыя алмыйча кул чаба идек, ә монда Мәскәү түрәсе! Хәтта бер журналистыбыз мәдәни гәҗитебездә болай язып чыкты: «...Русия хөкүмәтенең кайбер әгъзалары татар телен өйрәнүне үзләренең намус эше дип саныйлар». Һи-и, татарның наивлыгы, самимилеге. Юк ла, бу авыруны башка исем белән атарга кирәк.

Аның каруы, сәгать бүләк иткәндә, Матвиенко үзенең телләгән чатнатып урысча әйтте. Татарстан вакытын Мәскәү сәгатенә карап дөресләргә кушты.

Югыйсә кояш бездә бер сәгатькә алдан чыга бугай да...

Хәер, безне, иртә торгач, кояшка карап түгел, Мәскәү ягына бөгелеп сәлам бирергә күптән өйрәттеләр инде.

Идел буе округында Рәсәй Президенты вәкиле С.Кириенко Шәймиевкә ияр алып килгән иде. Шаккатып карап утырасың, монда һәр бүләк символ ич! «Йөгән дә алып килгәнсез икән», — дип моңсу гына шаяртты Президент. «Авызлыгы юк аның, авызлык кирәк булмас дип ышанам», — дип юатты аны Мәскәү калгае, Киндер-сюрприз. Нукта бармыюкмы икәнен телевизордан күрсәтмәделәр.

Болай да барысы да аңлашыла иде инде.

«Кеше күмүдән дә күңеллерәк вакыйганы күргәнем юк минем», — дигән Поль Верлен.

Ялгышкан!

Татарстан Президентының инаугурациясе җеназадан күңеллерәк иде.

Конституциягә кулын куеп, Президент Татарстан суверенитетын сакларга ант бирде. Ләкин безнең Конституция һәр хәрефенә кадәр исәпле булган Коръән Кәрим түгел, аны Мәскәүдән ишарә булган саен гел үзгәртеп торалар.

Мондый антның бәясен атлар да белә...

Шул ук Кириенконың штабында Рәсәйне административ-территориаль бүлү хакында проектлар ята. Монда,

әлбәттә, яңа чикләр турында сүз бармый. Татар дигән сүз борчый империячел көчләрне. Эчләрен пошыра. Шушы ук территорияне Казан губернасы дип атау турында сүз бара.

Алар инде безне төрлечә тәрткәләп карадылар. Без бер сүз дә әйтмәдек. Эндәшмәдек. Сугып егасы гына калды.

Кайда соң безнең туксанынчы елларда шаулаган милли хәрәкәт? Юлбашчылар кайда? Һәркем үз калҗасын әләктердә дә тындымы... Пар чыгып бетте. Без үзебезнең ишәк икәнне аңладык. Әле безгә ияр бүләк итәләр! Анысы өчен дә рәхмәт.

Шулай булгач, бу турыда язып торудан ни мәгънә?

Куптән түгел АКШның атаклы советологы (хәзер андый белгечлек юктыр инде ул) Р.Пайпс белән әңгәмә укыган идем. «Чечняны сезгә ирекә җибәрергә кирәк, — дип, Рәсәй сәясәтчеләренә киңәш итә ул. — Башкалар аларга иярер дип куркасы юк. Татарлар белән башкортларның бәйсез буласы килми.»

Моңа өстәп ни әйтәсең? Күп еллар совет халыкларының холык-фигылен өйрәнгән кеше белми әйтмидер.

Инде кабатлый-кабатлый үз мәгънәсен югалткан демократия белән нишләргә? Кюстин хаклы, Рәсәйдә әйбәт кенә сүзләр дә бераздан кире мәгънәгә ия була.

Мәсәлән, Рәсәй дәүләтенең мәсләгенә әверелгән хакимият вертикале демократия принципларына туры киләме? Юк, әлбәттә. Моны Г.Павловский кебек циник сәясмәннәр ачыктан-ачык таный. Хакимиятне үзәкләштергән очракта гына Рәсәй исән калачак, ди алар. Урыс дәүләтчелегенең мең еллык традициясе шуны күрсәтә икән. Моннан мең ел элек, соңрак та, Аурупа илләрендә дә корольләр, вассаллар булган, нигә алар шул традицияләргә ябышып ятмыйдыр, гаҗәп.

Германия дә әнә алты дистә еллар элек кенә нинди үзәкләштерелгән дәүләт иде, беркем дә аны сагынып еламый. Анда сез Һитлерның рәсемен урамда күтәреп йөрүне күз алдына китерә аласызмы? Ә бездәге демонстрацияләрдә Сталин сурәтен рәхәтләнеп күтәреп йөриләр.

Нигә йөрмәсеннәр, Рәсәйдә — демократия!

Үзенчәлекле, урысча демократия...

Рәсәй Дәүләт Думасында, Холокост корбаннарын торып басып яд итик, дигәч, депутатларның шактый өлеше моңа каршы төште. «Бу — урыс парламенты, — диде В.Жириновский. — Һәр бәйрәмдә баса башласак, кайчан эшләрбез». Янәсе, гел басып кына торасы була.

Яһүд яһүдне мыскыл итеп тә сәяси капитал ясый.

Хәер, Холокост яһүдләрнең фаҗигасе генә түгел, үлем мичләрендә ярты миллионлап чегән дә (аларны бөтенләй искә төшермиләр!), башка бик күп халыклар да дөрләп янган.

Менә шундый мөнәсәбәтне бүтән илләрнең парламентында күз алдына китереп карагыз!

Рәсәйдә — үзенчәлекле демократия. Власть вертикале дигән булып яңа структуралар оешты, тагын күпме әрәмтамак чиновниклар артты.

Юкса максат бик изге ич — Рәсәйне саклап калу, таркалудан коткару. Урыслар өчен бу бик мөһим мәсьәлә. Ләкин сәясәттә купшы сүзләр күп сөйләнә икән, аларның асылында бик гади нәрсә — кемнәрнеңдер мәнфәгате ята. Акча! Төрле эреле-ваклы түрәләр, сөлек кебек, дәүләт тәненә ябышканнар, һаман үрчи баралар. Әлбәттә, мондый дәүләтнең киләчәге юк.

Бу тенденция инде тәгаенләнә башлады. Икътисадны глобальләштерү дигән булып, дәүләтләрнең милли хөкүмәтләрен ышыкта калдырып, дөнья белән бер клан идарә итәргә омтыла. Тарихка карагыз, андый омтылышлар һәрвакыт булган. Ләкин хәзерге технологияләр заманында соңгысы уңышлы чыгар төсле. Аларның кармавычыннан Япония белән Кытай гына әлегә азат шикелле.

Тикшеренүчеләрнең исбатлавынча, җанварлар арасында күселәрдә генә тәгаен хакимият вертикале икән. Сүз дә юк, бик акыллы җан ияләре. Аларда бик төгәл иерархия, имеш. Әмма аңа карап әле идән асларыннан, клоакалардан җир өстенә чыкканнары юк. Әллә хакимият вертикале булгач, җир өстендә яшәүнең кирәге дә калмыймы?

Хәзер бик тырышып Татарстан кануннарын Рәсәйнеке белән тәңгәлләштерәләр. Хокукчылар беләдер, дәүләт федератив икән, төрле төбәкләрдә законнар да төрлечә булырга мөмкин. Мәсәлән, урыс сәясәтчеләре авыз суы корытып караган АКШның бер штатында үлем җәзасы бар, икенчесендә юк. Бер штатта юл аша баштүбән чыгарга ярамый дип законга язылган, бүтәннәр бу чиктән тыш вакыйгага нигәдер игътибар бирмәгәннәр. Бер дистә чамасы сәгать поясы булган Рәсәйдә Мәскәү чыгарган законнар белән генә яшәү мөмкинме? Хәер, Рәсәйдә кайчан закон белән яшәгәннәре бар?

Дөресен генә әйткәндә, Татарстанның мөстәкыйльлегенә кизәнүнең сәяси асылы да юк. Мәскәү олигархлары безнең табигый байлыкка кызыгалар. Чамалавымча, әле ул үзебезнең хуҗалар кулында.

Мәскәү чыгарган законнар белән генә яшәгәндә, Татарстанга Дәүләт Советы, ягъни парламент кирәкме соң? Югыйсә умартачылык турында закон чыгарсалар да, астына «Рәсәй законына каршы килми» дип язып куялар. Нәрсәгә мондый бишенче тәгәрмәч?

Юк, юк, мин — үз парламентыбызның патриоты. Ничек горурланмыйсың — күп балалы аналарга бездә «Ана даны»

медале бирү турында закон бар. Рәсәйдә ул юк. Бездә хет күп балалы хатын шул калай кисәген тагып үзен чын кеше дип хис итә ала. Рәсәй хатыннары аңардан мәхрүм. Мәскәүдә әлегә бу турыда уйламаганнар дип, Татарстан хатыннарының шул сөенечен дә тартып алыргамы инде?

Бәйсезлек турындагы бөтен хыяллары чәлпәрәмә килгәч, Гаяз Исхакый «дөньябыз кармазинга калды» дигән. Бу сүз нәрсәне аңлатадыр, белмим. Ләкин Исхакый авызында аның мәгънәсе ачык.

Ярык тагарак каршында калгач, безгә кадәр яшәгән әллә кемнәрнең сүзләре искә килә. Тиктомалдан Бисмарк хәтергә төште менә. «Җиңелгән халыкларның күзен генә исән калдырырга кирәк, — дигән ул. — Елар өчен...»

Ә без авыз ерып маташкан булабыз тагын...

Димәк, өмет бар әле.

*Май, 2001*

## КӨЧЛЕНЕКЕ — ЗАМАНА

Күршем Габделхак карт үлеп китте. Мәетне соңгы юлга әзерләү шактый мәшәкатьле эш, картның ир-ат туганнары юк, шуңа мин дә, күрше буларак, бу моңсу мәрасимдә кайнашып йөрдем. Ачык кабер каршында мулла Коръән укыды. Ахырдан, мәетне ләхеткә иң якын кешеләре төшерергә тиеш, дигәч, бабайның ике үги кызы (карчыгы белән мәрхүм гомер уртасында гына кавышканнар) кабергә таба тартылып куйдылар. Шул чагында мулла уңайсызланып кына әйтеп куйды: «Мәетне ләхеткә ирләр генә иңдерә...»

Зираттан кешеләр төрле уйлар белән тарала. Минем исә күңелемне бер генә фикер бимазалады. Безнең халык, аеруча шәһәрләрдә, гади генә шәригать кануннарын да белми ләбаса! Югыйсә үлем-җитем кеше тормышында гел булып тора. Ә мәетне өйдән алып чыкканда, зиратка алып кергәндә, гел бәхәс уяна: аягы алда булырга тиешме, башымы? Күз алдында безнең йолалар урысныкы белән бутала башлады... Мәрхүмгә ясин чыкканнан соң табынның поминкага әйләнеп китүенә дә күпләр инде гаҗәпләнми.

Иман кайта, мәчетләр арта, дибез, ә үзебез әле диннең көндәлек мәсьәләләргә караган йола-гадәтләрен дә белмибез... Менә ничә ел инде безне ваһһабчылык мәзһәбе белән куркыталар.

Югыйсә XVIII гасырда Согуд Гарәбстанында барлыкка килгән бу юнәлешнең асылын аңлаучы бар микән Татарстан-

да? Бөтен дини белеме «әппәр»гә кайтып калган агай-эне, әби-апалар аны түгел, мөселманнарның ике зур төркемгә — сөнниләр белән шигыйләргә аерылганын да белми...

Иң гаҗәбе, Татарстанда ваһһабчылыкка каршы «көрәш»-нең башында Уфадагы мөфтиебез Тәлгат Таҗетдин тора. Мәскәүнең матбугат чараларында пәйда булу белән, ул, урыс хөкүмәтенә рәхмәтен җиткергәннән соң, Татарстан өстенә ябырыла: «Соңгы өч елда, ди ул, анда ваһһабчылык җәелдерелде, традицион руханилар урыннарыннан алынды, ә бөтен мәдрәсәләрдә — Казанда, Түбән Камада, Чаллыда — чит илләрдән килгән дин белгечләре укыта» («Труд», 19.04.01).

Мөхәммәд ибне Габдел Ваһһаб нигез салган бу юнәлеш Ислам динендә мәҗүсилектән калган гадәтләргә каршы көрәшә. Габдел Ваһһаб үзе беркемне дә экстремизмга чакырмаган. Сугыш чукмарлары аның исеменнән файдалана икән, әлеге дин галименең моңа бернинди дә катнашы юк.

Бездә ислам диненең мең елга сузылган үз традициясе бар, без борын-борыннан Хәнифә мәзһәбендә торабыз. Яисә торганбыз, дияргә кирәктер... Халкыбыз инде Болгарга Ибне Фадлан килгән чорлардагы җаһиллеккә төшкән, безгә, мөгаен, ислам динен яңадан кабул итәргә кирәктер. Инде соң булмаса...

Ә Тәлгат мөфтигә килгәндә исә, аның шулай ярсып Татарстандагы «ваһһабчылыкка» каршы көрәшүенең сәбәбе аңлашыла. Татарстанның үз мөфтияте бар, мондагы мәчетмәхәлләләр хәзер Уфадагы нәзарәткә буйсынмый, шуңа да Тәлгат мөфтигә алар «ваһһабчы» булып күренә икән. Гомумән, бу мөфтинең күзенә әллә нәрсәләр күренә...

Халыкка дин яктысы сирпү урынына, мулла-мунтагайлар җаһил мәхәлләләр өчен көрәшеп ята. Әле шул меркантиль мәнфәгатьләрен, ваһһабчылык белән көрәш дигән булып, бөтен Рәсәй алдына чыгарып селкиләр.

Моның нәтиҗәләреннән кемнәр файдалануы билгеле инде — хәзер гарәп мөдәррисләрен Татарстанга кертмиләр, дингә кайтырга теләмәгән мәхәлләләргә ислам вакыфларыннан акча килми (акча килмәгәч, бәлки, муллалар ызгышмый башлар?), миссионерлар тозагына яңадан-яңа татарлар эләгә.

Кыйбласыз, имансыз калган мәҗүси татарларны кемнәр генә үз җәтмәсенә ауларга теләми. Аллага шөкер димәсәң, арабызда католик татарлар да бар икән. Менә күптән түгел генә бөегебез Такташның оныгы Искәндәр Такташ шул динне кабул иткән. Сәбәбен ул үзе бик кызык аңлата: «Шәхсән мин тамырларыма кайттым. Татар-монголлар арасында несториан мәзһәбендәге христианнар да булган. Ә минем бабаларым Чыңгыз нәселеннән. Тәңрем мине бабаларым диненә

кайтырга өндәгәндер дип уйлыйм» («Казанские ведомости», 18.04.01).

Һади Такташ үзенең Чыңгыз нәселеннән булуын белмичә үлеп киткән икән, мәрхүм...

Биредә Чыңгыз нәселен барлау безнең максат түгел. Тик шунысын әйтеп китү урынлы булыр: татар дәүләтләрендә тәхет тотар өчен чыңгызыйларның мөселман динендә булуы төп шарт булган, бүтән дингә күчү белән алар ханлык хокукын югалтканнар. Әлбәттә, Искәндәргә хан булу мөмкинлеге янамый, шуңа күрә нинди диндә булу — һәркемнең үз вөҗдан эше.

Шулай да бик кызык күренеш күзәтелә — моннан берничә еллар элек А.Расихның кызы Фәридә Рәсүлеваның да христиан диненә күчүе турында хәбәр ишетелгән иде. Мәгълүм ки, Атилла ага үзе атаклы ишан Зәйнулла Рәсүлинең оныгы иде... Шундый затлы нәселдән чыккан кешеләрнең дә токымы хак динебездән читкә тайпыла икән, бу инде халкыбызның рухи торышын бик ачык күрсәтә дип уйлыйм.

Ләкин болар әле күңелләргә тамыр җибәргән агулы агачның тамырлары гына булган икән... 11 сентябрьдә Америкадагы коточкыч шартлаулардан соң без бөтенләй яңа вазгыять алдында калдык.

Күпләр бу вазгыятьне ике мәдәният — христиан һәм мөселман цивилизацияләре арасында сугыш башлану дип аңлатырга ашыкты. Америка президенты дошман көчләргә «тәре походы» игълан итте. Бу көрәшнең ислам диненә түгел, ә ислам террорчыларына каршы юнәлдерелгән булуын шәрехләсәләр дә, тарихтан хәбәрдар кешеләр тәре походларының кемнәргә каршы оештырылган булуын яхшы белә.

Америкадагы шартлаулардан соң берничә сәгать үтүгә үк, бу террорны гарәп экстремистлары башкаруын дөньяга игълан иттеләр. Мәскәүдәге фаҗигаләрнең сәбәбен дә шулай тиз генә «чечен эзеннән» тапканнар иде бит...

Исламны шулай итеп террорчылар, бандитлар дине дип расларга тырышучыларның саны артты. Диннән хәбәре булмаган кешеләр моңа ышана да... Коткы тарату чараларының төкәнмәс технологияләре булган заманда моңа ышандыру артык кыен да түгел...

Әмма террорны нindидер дингә генә бәйләп аңлату мәсьәләне бик гадиләштерү булыр иде. Гомумән, вату-җимерү, үтерү — кешенең табигатенә хас нәрсә. Менә шул кыргый инстинктны дини яисә идеологик чаршаулар белән капларга омтылу — һәр чорның террорчыларына да хас әйбер. XIX гасыр ахырындагы урыс бомбистларын искә төшерик. Җитмешенче еллардагы Италиянең «Кызыл бригадаларын»

яки хәзерге замандагы баскларның «ЭТА» оешмасы, «Ирландия революцион армиясе» кылган террористик актларны хәтерлик... Боларның ислам диненә нинди катнашы бар? Тик нигәдер христиан террорчылары дигән атаманың ишетелгәне юк...

Шунысын да онытмаска кирәк: аерым кешеләр кылган җинаятьләрдән дә куркынычрак дәүләт терроры дигән нәрсә дә бар бит әле. Чечняда меңләгән тыныч халык кырылды, аларның төгәл саны әле ачыкланганы юк, — бу шул дәүләт терроорының бер нәтиҗәсе түгелмени? Америка Гыйракка каршы сугыш оештырды — анда гарәпләрнең карты-яше, баласы-чагасы һәлак булды. Дөнья җәмәгатьчелеге авызына су капкан кебек торды. Шул ук АКШ Ливияне, Суданны, Югославияне бомбага тотты. Әллә андагы кешеләр дөнья цивилизациясенә керми микән? Чыннан да, көчленеке — замана икән шул...

Рәсәйнең бөек мәмләкәтләр сафыннан төшеп калуы дөньяның сәяси котыпларын үзгәртте. Ләкин дәүләтләр тышкы дошмансыз яши алмый.

Менә Көнбатыш хәзер яңа дошман — ислам экстремизмы куркынычын уйлап тапты. Янәсе, безне Төньяк белән Көньяк бәрелеше көтә. Рәсәйнең бу бәрелештә урыны тәгаен. Ул христиан-яһүд цивилизациясенең бер өлеше. Тик шунысы бар: тышкы дошманны игълан итү белән, «эчкеләрен» дә эзләү башлана. Америкада инде әнә үз мөселманнарына каршы погромнар да булып үтте, төрле кысрыклаулар башланды.

Рәсәй сәясәтенең дә мондый юлдан кереп китү ихтималы бар. Мәчетләр-мәдрәсәләр салыну, халыкта бераз дини җанлылык башлану күптән карагруһ көчләрнең ачуын кузгата иде. Мәдрәсәләрдә шәкертләр намаз укырга өйрәнү урынына, бәлки, автомат җыярга өйрәнеп яталардыр? Әнә бит Тәлгат мөфти үзе үк, Татарстан мәдрәсәләрендә ваһһабчылык тамыр җәйгән, ди. Ә ваһһабчылык инде ул күпләрнең аңында террорчылык, экстремизм белән тәңгәлләштерелә.

Тарихтан беләбез — Рәсәйдә бераз иркенлекләрдән соң татарны янә кысулар, җәберләүләр башлана. Һәм бу җәбер иң беренче нәүбәттә безнең динебезгә килеп бәрелә. Бүгенге Аксак Каратуннар инде соңгы һөҗүмгә әзер. Ул чагында мәчет диварларында ярым айлар белән бергә, Тәлгат мөфти теләгәнчә, хач та, Даут йолдызы да урын алыр. Тик андый мәчеткә керүче булыр микән соң?

*Октябрь, 2001*

# КОЛЛЫКТАН КАЛГАН ХОЛЫК

Урамда бер танышым очрады. Күптән күрешкән юк иде, туктап шактый гына сөйләшеп тордык. «Татар өчен тагын авыр заманнар килә», — диде ул көрсенеп, — күрәсеңме, Мәскәү ничек кыса... Сез, язучылар, нигә эндәшмисез? Нидер эшләргә кирәктер бит инде? Кычкырырга, урамга чыгарга... Шәймиев тә койрыгын кысты бугай...» Мин әлеге танышыма бик игътибар белән карадым. Тыныч, ипле кеше. Туксанынчы еллардагы шаулы митингларда да очратканым булмады, бүтән милли җыеннарда да... Күпчелек татар кебек, бу да милли дәгъвалардан читтә торучы кавемнән, үз халкының хөр яшәвен теләсә дә, ул-бу булмагае, Алла сакласын дип, эшеннән тизрәк өенә ашыгучы. Татар азатлыгы өчен бүтәннәр көрәшергә тиеш: язучылар, президент... Милләтнең һаман да бәйсез булмавына ул фәкать аларны гаепли, җылы өендә телевизор карап утырганда аларны хәкарәтли, экраннан балаларга әкият сөйләп утыручы Батулланың йөзенә төкерә...

Ә соң син үзең?! Халкыңның аз гына азатлык юлына борылуында өлешең бармы? Кыл гына булса да кыймылдаттыңмы?

Ярый, бу татар әле нидер чамалый, халкыбызның юкка чыгу упкынына якынлашуын аңлый, үзенчә борчыла да... Үз эченә бикләнгән икән, анысы инде аңлашыла: йә куркак, йә инде татарның татар булып калуына ышанмый, киләчәгенә кул селтәгән...

Икенче төрле татарлар да бар әле: җаһилләр. Болар күпчелек. Тирә-якка карасаң, йөрәк жу итеп китә... «Яшәсен» дә «яшәсен» дип кычкыруыбыз юкка гына түгелме соң? Боларның яшәве ни дә, яшәмәве ни... Исем бар, җисем юк. Тарихыннан, мәдәниятеннән хәбәрсез, телне ярым-йорты белә. Үз гомерендә кулына бер китап тотып карамаган. Дөньялыкта яшәвенең бөтен мәгънәсе — корсак кайгысы... Рабсила. Кол... Коллар бервакытта да милләт хасил итә алмый. Ул, берәр мөмкинлек булып өскә күтәрелсә дә, шул коллык психологиясеннән арына алмый, тагын да өстәгерәкләрнең күтен ялый башлый... Ә үзеннән астагыларны изә. Соңгы еллардагы үзгәрешләр аркасында бу төркем бик нык артты, аларны күрәсегез килсә, телевизордан «Татарстан» каналын ачып, Дәүләт Советының сессиясендә утыручыларга гына күз салыгыз.

Колның хыялы нидә? Ул, үзе хуҗа булып, коллар белән идарә итәргә хыяллана.

«Татарга нигә әлифба алмашып маташырга? Латинга күчү

балаларның башын гына бутаячак. Урысча укырга кирәк, урысча укысаң гына кеше буласың...» — Районгдагы бер кәттә генә түрә миңа шулай сөйләп торган иде. Әйтерсең гомер-гомергә урысча укыган бөтен урысның барысы да министр... (Кеше булу дигәндә ул, әлбәттә, нииндидер тирәлекне күздә тота иде, аныңча, җир сөргән, мал караган, тимер эшкәрткән хезмәтче — кеше түгел...) «Мәнә син татарча укыгансың, — дидем мин, — зур гына түрә булгансың бит әле». Ул кулын гына селтәде, аның нужасын үзем генә беләм, янәсе...

Шайтан алгыры! Бер авыз сүз урысча белмәгән алман кызының Рәсәй тәхетенә Икенче Кәтәринә исемендә менеп, иң мәгърифәтле патша буларак тарихка кергәнен сөйләп торыйммыни аңа? Гомумән, Рәсәй патшаларының күбесе җүнләп урыс телен белмәгән... Ә инде эреле-ваклы түрәләргә килсәк... Кояш астында үз урыныңны табу өчен бөтенләй бүтән сыйфатлар таләп ителә. Тел дә кирәк, әлбәттә. Әмма аның төп вазифасыннан тыш бүтәнрәк максатларда ешрак файдаланылуы турында алда әйткән идем инде.

«Республиканы губирнага әйләндерәләр, дип куркыталар. Татарстан дип әйтәләрме, Казан губирнасымы — безгә один чурт», — ди бер «эш аты» һәм силос ябышкан кожаныңа сугып ала: «Барыбер шушы нәстәнең җилкәдән төшәсе юк...» Аны сыер савучы хатыны ашыктыра: «Телевизордан концерт башлана. Салават җырлый...»

Әйе, маңгаеңа язылса, Сарытау губирнасында да тирес чыгарасың, силос ташыйсың, тик анда, өеңә кайткач, телевизорны кабызуга татар җыры яңгырамый, радиодан җомга көннәрендә Коръән аяте ишетелми... Үз җөмһүриятеңнең кирәклеген, әлбәттә, шушы абзый-апаларның фикер йөртеше кимәлендә аңлату бу... Хәер, абзыйның үзенә татар җыры да «нипачум» — авыр эштән соң ике йөз грамм булса, аның җир йөзендәге бөтен ихтыяҗы төкәнә...

Шунысын да әйтергә кирәк: безнең телевидениедә илебезнең әлегә республика икәнен күрсәтеп торучы шул бер концертлар гына калды да бугай инде. Экран кабынуга бер җырчы килеп чыга, кем әйтмешли, эте дә, бете дә микрофон тоткан. Көйләре бертөсле, сүзләре дә татарча сымак... Житди, сәяси тапшырулар урысча уза... Әллә безнең татар үз язмышы турында татарча сөйли дә белми башлаган?..

Дөрес, авыл хуҗалыгы турындагы тапшырулар татарча... Табигый, чөнки авылларда татарлар гына калды да бугай... Хәбәрче микрофонын бер апаның авызына терәгән, сорау бирә: «Мәнә ишегалдына кергәч, унике баш каз күрдем. Аларны асрау кыендыр инде. Мәнә быел ничә каз

бәбкәсе үстердегез?» Җитәкче сөйли: «Вот шушы решение-не выполнять иттек...»

Авыл кешесе!

Әле аның Казанда иң югары урында утыручылары да болардан әллә ни ерак китмәгән. Алар объектлар турында сөйли, саннар белән башыңны әйләндерә, ләкин күпме генә тыңласаң да, республика сәясәте турында, аның дөньядагы урыны, перспективасы хакында сүз ишетә алмыйсың... Дәүләти аң юкмы, әллә ул үзен иләмән (государственный муж) итеп хис итмиме? Алар моны үзләре дә сизә, күрәсең: мин сәясәтче түгел, мин хуҗалык кешесе, дип акланалар.

Бездә бер генә сәясәтче бар — ул да булса Шәймиев.

Ул үзе шуңа омтылды, Путинның «власть вертикале» дигән сәясәтенә кадәр үк Республикада шундый хакимият урнаштырды. Идарә итәр өчен «вертикаль» дигәннәре бик җайлы, әлбәттә. Аннары буйсыну хисе (буйсынасы килү!) җан иясенең геннарына салынган.

Мондый хакимияттә чын ватандашлар җәмгыяте оеша алмый. «Власть вертикале» ул заманча колбиләүчелекне тудыра, яңа коллар тәрбияли. Күптән түгел генә без үзебез-не гади «винтиклар» итеп сизми идекмени? Ун ел аз вакыт шул, без яңадан үз урыныбызга кайтып төштек... Ләкин шул аралыкта үсеп аякка баскан буын да бар бит? Алар «винтик» булырга ризамы? Риза түгелләр икән, димәк, яңа репрессияләр кирәк булачак. Сталинның үз власте верти-кален ничек урнаштырганын яхшы беләбез.

Хәзер Шәймиев тә Рәсәйнең бер регионында Хуҗалык башлыгы гына булып калачак. (Калса әле...) За что борол-ся, на то и напоролся, ди бөек халкыбызның мәкале... Власть вертикален алга сөргән илдә бер генә сәясәтче була!

Шәймиевкә үпкәләү урынсыз, ул безгә күктән иңмәгән, монда безнең җирлектә тәрбияләнеп, безнең халыктан чык-кан кеше. Авызың чалыш булганга көзгегә үпкәләүдән ни файда? Без үзебез шундый — басынкы, кыюсыз, наив һәм надан... Тарихны белмибез. Ә аның кабатлана торган га-дәте бар. Юкка гына, тарихны иңләгән киләчәген билгән, дип әйтмәгәннәр бит. Егерменче елларда да татарда милли-мәдәни күтәрелеш булып ала, утызынчы елларда тагын маң-гайга сугалар. Аннары 37 нче ел килә. Аның кабатлану ихтималы хәзер дә юк түгел. Бәлки, алай ук канлы булмас та ул (шулай юаныйк!), Мәскәүнең кулы озын, ысуллары күп...

Шәймиев, партаппарат төпкелендә шәкелләшкән шәхес буларак, күнегелгән юлны сайлады: чиновниклар санын арт-тырып, аларга таянды. Алар, әлбәттә, сәяси вазгыять тот-рыклы булган чагында Шәймиев хакимиятенең терәген

тәшкил иттеләр. Ләкин җилнең юнәлеше үзгәргәч, аларның кайсы якка борыласын чамалавы кыен түгел... Чиновникларның күпчелеге асларындагы кәнәфи хакына суверенитеттан баш тарту гына түгел, теләсә нинди режимга хезмәт итәргә әзер. Дөрес, аларның барысы да диярлек бүгенге дәрәҗәләренә, мал-мөлкәтләренә Бабай аркасында ирешкән, әмма мәгълүм ки, аска су керсә, андый нәрсә тиз онытыла. Алар каударланып яңа хуҗа эзли башлыйлар. Кол һәрвакыт үзенә Хуҗа таба ул...

Ә бит нәкъ менә шулар суверенитетның бөтен нәтиҗәләреннән тулысынча файдаландылар. Республиканың кайбер икътисади өстенлекләре аркасында килгән байлыкның күп өлеше аларның кесәсендә сөзелеп калды.

Ирек мәйданында «Азатлык!» дип без шулар өчен кычкырып йөрдекмени? Туксанынчы елларда мәйданга чыккан кешеләр шулай уйлый. Аларның бит күбесе татар зыялылары-интеллигенциясе иде. Матди яктан суверенитет безгә нәрсә бирде? Без хәерче хәлдә калдык, кайсыларыбыз хәтта люмпенлашты. Дөрес, минем дустым Газинур Морат: «Суверенитетны ипигә ягып ашап булмый», — дип яза. Янәсе, азатлыкны матди категорияләр белән үлчәргә ярамый. Ярый! Суверенитетка төкереп тә бирмәгән, әмма шул шау-шудан файдаланып, дәүләт (димәк, халыкныкын) малын умырып калган «яңа татар» чит ил машиналарында яныңнан узып киткәндә, син нәрсә уйлап каласың икән, дускай? Кыршылган пәлтә кесәңдә тирләгән бармакларың белән хосусый автобуска тәңкәләр санаганда башыңа нинди фикерләр килә?

Татар зыялысы романтик инде, әлбәттә. Мал тупларга да сәләтсезрәк. Ул монда да юану таба. Үзебезнекеләр бит, янәсе, маллары бирелә кала. Югыйсә Мәскәүдән яһүд олигархлары күптән Татарстан малын үзләренә умырып алган булырлар иде. Үзеңнекеләрне ашатудан баш тартсаң, ятларны туйдырачаксың...

Мәскәүнең бездәге законнарга бәйләнүе төбендә дә шул әлеге дә баягы мал бүлешү матавыгы ята бит. Суверенитет шаукымы аркасында Мәскәү акулалары татар байлыгын үзләштерә алмый калган иде, хәзер алар соңгы һөҗүмгә күтәрелде. Авыз ачып торсак, Республикабызны Казан губирнасы ясап, губернатор тәхетенә тагын бер Абрамовичның килеп утыруы да бар.

Дәүләтчелекнең язмышына куркыныч туганда, Балтыйк буе илләрендәге халык булса, мәйданнарга йөз меңләгән кеше ташып чыгар иде. Ә бездә — тынлык. Кабер тынлыгымы? Татарның иң кайгылы көне — Хәтер көнендә Сөембикә манарасы янына һәр елны бер-ике йөз кеше җыела. Һаман

шул ук таныш йөзләр. Гэбэшниклар инде безнең һәрберебезне артыбыздан таныйдыр...

Соңгы ун елда гына Татарстанда 40 мең коттедж салынган. Гаиләләре өч-дүрт кешедән генә торса да, 100 меңнән артык кеше килеп чыга. Шуларның күпмесе генә шушы мәйданда бар икән? Ә бит нәкъ шулар суверенитетны тештырнаклары белән якларга тиеш. Чөнки, мәсәлән, ГКЧПдан соң Шәймиевне һәм суверенитетны яклап мәйданга кыршылган пәлтәлеләр чыкмаса, дәүләт байлыгы бүтәнчәрәк тә бүленергә мөмкин иде.

Шулай да барлык татарга шаһгалилек чире йокмагандыр бит? Мускулларны да яза алмаслык сәлперәймәгәнбездер ич? Алда безнең зур сынау тора. Өзеп әйткәндә, тиздән Милләтебезнең исән калу-калмау мәсьәләсе хәл ителәчәк. Мондый вазгыятьтә татарга татарның үзеннән башка ярдәм итүче булмаячак.

*Декабрь, 2001*

# ТОТСА МӘСКӘҮЛӘР ЯКАҢ...

Элеккерәк елларда шагыйрь Зөлфәт дусларча гына Гариф Ахуновка пародия ясарга ярата иде. Мәрхүм язучыбыз Мәскәүдәге бер чыгышын болай башлап киткән, имеш: «Наш мнуганасианальный татарски наруд...»

Рәсәйнең Дәүләт Думасында халык санын исәпкә алу турындагы канунны беренче укылышта тикшерүләрен ишеткәч, Зөлфәтнең шул пародиясе искә төште... Тарихта трагедияләр фарс булып кабатлана, диләр иде, бу очракта киресенчә хәлне күзәтәбез түгелме соң... Такташның сүзен бераз үзгәртеп әйткәндә, «кем уйлаган безнең шаярулар» дәүләт күләмендәге сәясәткә әверелер дип...

Хуш, безнең халыкны алты милләткә бүлмәкчеләр икән: татарлар, мишәрләр, керәшеннәр, нугайбәкләр, Себер һәм Әстерхан татарлары...

Күпләрнең, мөгаен, бу төркемдәге нугайбәкләр турында мәгълүматлары юктыр. Шуңа күрә кыска гына тарихи аңлатма биреп үтүне кирәк табам. Аларның этник тамырлары турында төрле чыганаклар бар. Күп галимнәрнең фикеренчә, алар — Казан ханлыгы тар-мар ителгәннән соң чукындырылган нугай кабиләсе. (Нугайларның татар халкын барлыкка китерүдәге рольләре хәзер инде безгә мәгълүм, юкка гына Үзәк Азия халыклары татарларны әле дә нугай дип атамый.) Нугайбәкләрнең башка керәшеннәрдән аермасы

шунда гына: алар (араларында бәкләр, морзалар күп булгангамы?) казак сословиесендә булалар һәм Рәсәйнең яңа яуланган җирләрен күчмә халыклар һөҗүменнән саклыйлар, баш күтәргән җирле халыкны (мөселман динендәге кан кардәшләрен) бастыруда катнашалар. 1842 елда аларны Уфа провинциясенең Бәләбәй өязеннән хәзерге Чиләбе өлкәсенә күчерәләр. Анда Нугайбәк крепосте төзелеп, әлеге татаркерәшен казаклары элекке вазифаларын башкаруны дәвам итә. Аларның французлар белән сугышта зур юл үтүе дә мәгълүм. Шул яудан алар яңгыравык авыл исемнәре алып кайталар: Фершампенуаз, Кассель, Париж... Ләкин бу нугайбәкләр хәзер инде урыслашып беткән диярлек. Ә 1897 елгы халык санын алу буенча алар 12 мең кеше саналган. Хәер, 1842 елда яңа җирләргә аларның барысын да күчермиләр, хәзер Бакалы керәшеннәре дип аталган төркем — шуларның бер кисәге...

Нугайбәкләргә болай озак тукталуымның сәбәбе, алар турындагы мәгълүматларның аз булуында гына түгел, әлбәттә. Күргәнебезчә, тарихи чыганакларны игътибар белән күзәтсәң, әлеге нугайбәкләрнең килеп чыгышы бүтән татарлардан берни белән дә аерылып тормый икән...

Татарларны вак төркемнәргә бүлгәләү һәм шул юл белән урыслаштыру сәясәтен Рәсәйдә борын-борыннан үткәргәннәр. Менә бер генә мисал. 1619 елда патриарх Филарет, Болганчык елларда Ялган Дмитрий ягында сугышканнары өчен, Мещера казакларын (гади генә әйткәндә, мишәрләрне) Донга күчерергә боерык бирә. Аларны урыс телле халыклар белән катнаштыралар, чукындыралар, үз телләрендә аралашуны катгый тыялар. Ләкин тарихи хәтерне андый дәһшәтле юллар белән дә тиз генә юкка чыгарып булмый икән. Элеккеге хәрби (XX гасырның соңгы атлы атакасында катнаша) Е.Подоксик әле сугышка кадәр генә әбисе Федора Давыдовнаның шартлатып төркичә сөйләшүен яза («Русский еврей» журналы, № 15, 2000). Безнең тел шундый кысылган килеш тә, кухня теле кимәлендә тагын 400 ел яшәргә сәләтле икән! Донга күчерелгән әлеге мишәр казаклары реестрга кадәр шушындый фамилияләр йөрткәннәр: Алимов, Баскаков, Бирюков, Мелехов... Менә Шолоховның «Тын Дон» романы каһарманына әлеге фамилия кайдан килеп ирешкән икән... Мәлик, Мәлих төркичә «хуҗа», «патша» дигәнне аңлата. Безгә бу сүз гарәп теленнән кергән. Әлеге романда башта бик күп төрки сүзләр кулланылып, соңыннан редакторлар аларны урысчага әйләндерүләре турында да истәлекләр бар.

Ләкин бу турыда Дон казакларының хәзер кайсысы гына белә? Алар инде хәзер чын урыслар. 400 елдан артык яше-

рен каршылыкка очраса да, корткычлык сәясәте барыбер үз нәтиҗәсен бирә, димәк.

Каршылык булмаганда, андый сәясәт нәтиҗәсен бер кеше гомерендә дә күреп була. XX гасырда миллионлаган кан-кардәшебезнең урыска әверелүен үз күзләребез белән күр-мәдекмени? Күрдек, хәзер дә бик кызыксынып күзәтәбез...

Әлбәттә, безне бүлгәләргә тырышуның төп сәбәпчесе им-перия көчләре булса да, гаепне үзебездән дә эзләргә кирәк. Урыс тарихында татар исемен төрлечә болгату аркасында күп кенә карендәшләребезнең милләт атамасыннан кыенсы-нуы беркемгә дә сер түгел. Урыс әдәбиятында, кинофильм-нарда, матбугатта татарны кысык күзле вәхши итеп сурәтл-әүләре һәркемнең дә күңелен тырныйдыр. Сиксәненче ел-лар ахырында бер төркемнең «без татарлар түгел, болгар-лар!» дигән шигарь белән чыгуын шуның белән дә аңлатып була. Ләкин аек булыйк, «мин татар түгел» дип кенә үзеңә карата мәсхәрәле караштан котылып булмый. Горур булырга, үзеңне, үз исемеңне хөрмәт итәргә кирәк, шул чакта гына башкалар да сине хөрмәт итәр. Әлбәттә, татар милләтенең оешуында болгар компоненты катнашуын беркем дә инкяр итәргә җыенмый. Ләкин бит безнең милләт булып шәкелләшүдә кыпчаклар, Үзәк Азия төркиләре, фин-угыр кабиләләре дә катнашкан. Бу табигый дә, чөнки гасырлар дәвамында бер милләт тә саф килеш кенә саклана алмый. Шунысын да онытмыйк: күп халыкларга үз атамалары та-рихи аңлашылмаучылык аркасында тагылган. Мәсәлән, XVI гасыр башында Мөхәммәд Шәйбани хан Көнбатыш Себердән килеп Урта Азияне, ягъни Төркестанны басып ала. Аның гаскәриләрен, бабалары, күрәсең, Үзбәк хан заманында ис-лам динен кабул иткәнгәдер, үзбәкләр дип атаганнар. Шуңа күрә Шәйбани корган дәүләт тә Үзбәк иле дип аталган. Соңыннан бу дәүләткә кергән төрле төрки кабиләләр бар-ласлар, карлуклар, сартлар, дөрбәннәр һ.б. үзбәк дигән исем белән тарих сәхнәсенә менә. Ә чын үзбәкләр югыйсә баш-калар белән чагыштырганда бик аз микъдарда булган. Гер-ман кабиләсе булган франклар Галлияне басып ала һәм тора-бара галларны да франк, ягъни француз дип атый башлый-лар. Хәер, нигә ерак китәргә, IX гасырда скандинав телле варяглар славяннар белән җитәкчелек итә башлый. Алар-ны урыслар дип тә атаганнар. «Рус» аларның үз телләрендә «елга юлбасары» дигән мәгънәне аңлаткан. Варяг-лар бераздан бөтенләй славянлашалар, ә исемнәре бөтен бер халыкка йогып кала. Мондый мисалларны бик күп китереп булыр иде. Тик әле мин бер французның да, бер урыс-ның да: «Мин француз түгел, мин урыс түгел», — дип елап йөргәнен ишеткәнем юк.

Бәлки, бөтен хикмәт үз дәүләтебез булмаудадыр? Мескенлек комплексы изелгән, кол халыкта гына үзен әледәнәле сиздереп тора.

Без татар исеме белән дөньяга танылганбыз икән, хәзер инде сукранмыйча гына шул яңгыравыклы исемгә лаек булып калыйк.

Шул ук елларда керәшен кардәшләребездән кайберәүләр дә: «Без татар түгел, без аерым халык», — дип чыгышлар ясый башлады. Янәсе, алар Казан ханлыгы ауганнан соң татарның чукындырылган бер өлеше түгел, ә православие динен аңарчы ук кабул иткән, бүтән татарлардан аерым мөстәкыйль бер этнос. Кайбер шундый хәсрәт галимнәрнең язмаларын укыгач, гаҗәеп «ачышларга» да тап буласың: керәшеннәр, Иисус Христос туасын белеп, чабаталарын киеп куйганнар да, безнең эрага кадәр үк чукынып өлгергәннәр. Мондый мәгънәсезлекләрне читкә куеп торсак, әлбәттә, тарихи чыганаклардан монгол яуларына кадәр үк кайбер кыпчак кабиләләренә христианлыкның үтеп керүен беләбез. Мәсәлән, Кончак ханның улы Юрий исемен йөрткән. Ләкин бу христиан кыпчаклар күптән инде урыс, украин милләтләрендә эреп югалганнар. Ә безнең керәшеннәрнең чукыну тарихы исә тарихта яхшы өйрәнелгән, ул чорлардан бик күп документлар сакланып калган.

Керәшеннәр, телләрен югалтмаулары аркасында һәм мөселман кардәшләреннән изоляциядә яшәүләре сәбәпле, безнең кайбер чын төрки йолаларыбызны, саф моңнарыбызны саклап калганнар. Бу хәл, билгеле, безнең уртак мәдәниятебезне баета гына.

Үзара дәгъвалар алышудан туктап, башны күтәребрәк карасак, күрәбез: дөньяда ике конфессияле халыклар шактый. Абхазларны, осетиннарны искә төшерик. Алар, күрше халыкның җимергеч көче янәшәсендә яшәгәнлектән, бу дини аерымлыкларга игътибар итмиләр, дини каршылыкка кереп батсаң, бөтен милләт өчен нинди зур фаҗигаләр киләсен яхшы беләләр. Әлбәттә, андый утны үрләтеп җибәрергә теләүче көчләр житәрлек. Ливандагы мөселман һәм христиан гарәпләр арасындагы, Һиндонезиядәге бәрелешләрне искә төшерик. Безне бу бәладән уртак Тәңребез сакласын.

Себер һәм Әстерхан татарлары белән дә без бер милләт икәнне раслап утыру биредә бер мәгънәсезлек булыр иде. Хәтта Кырым татарлары белән дә без бер милләт идек. Аларның телләре бездән җәгърафик ераклыкта урнашу һәм төрек теленең тәэсире аркасында гына ерагайган. Аннары кырым кардәшләрнең әле XVIII гасыр ахырында гына Рәсәй тарафыннан яулануын онытмыйк. Барыбызның да тамырлары бер — алар кыпчак-нугай компонентына барып тоташа.

Мишәрләр турында монда әйтеп тә торасым килми. Мин, мәсәлән, үземнең мишәр икәнлегемне Казанга килгәч кенә белдем.

Сорау туа: Рәсәйнең шундый икътисади авыр хәлендә Мәскәү сәясәтчеләре быел халык санын алганда нигә татарны бүлгәләү мәшәкатенә кереште соң әле? Тарихтан билгеле, Рәсәйдә беркайчан да сәясәт икътисади нигезгә корылмады, киресенчә, сәясәт икътисад белән җитәкчелек итте. Шуңа Рәсәй бүген дә хәерче хәлендә... Мәскәү сәясәтчеләре бүген — кызылы, агы, сорысы, көрәне барысы бер булып урыс идеясе турында авыз суын корыта. Үткән гасырларда бу идеяне өч кит тәшкил иткәнне дә беләбез: самодержавие, православие, народность. Шигаре: бердәм һәм бүленмәс Россия. Бу очракта, әлбәттә, милли республикалар бетерелергә, ил губерналарга бүленергә тиеш. Ләкин Рәсәй дөнья алдында цивилизацияле ил булып кылана. Республикаларны бетерер өчен сылтау кирәк. Сылтау табылган: әгәр дә республиканың төп халкы 50 проценттан ким икән, ул яшәргә хаклы түгел, имеш. Әгәр Татарстанда шундый нәтиҗәгә ирешсәләр, бүтән республикаларны юкка чыгару Мәскәү өчен чүпкә дә тормаячак.

Югыйсә Мәскәүнең этнология белгечләре яхшы белә: һәр милләт аерым төркемнәрдән тора. Урысларның үзләрен дә бик әйбәтләп төрле халыкларга таркатып булыр иде. Мәсәлән, поморлар белән казаклар арасында тел берлегеннән башка бернинди уртаклык юк. Ә киржаклар, чалдоннар? Саный китсәң, бик күп алар. Чуашлар, мәсәлән, ике төркемгә бүленә: анатрига һәм вирьялга. Анатриларда татар тәэсире көчле булса, вирьяллар марига якын. Алар хәтта антропологик яктан да бер-берсенә охшамаган. Мордва милләтенә берләшкән мукшылар белән эрзялар хәтта бер-берсенең телен дә аңламый.

Һәр вәкиле үзенең нинди кабиләдән чыгуын әле дә онытмаган башкортларны гына искә төшерик. Бөрҗәннәр, юрматылар, үсәргәннәр, тамьяннар... Һәммәсе утызга җыела бугай. Ләкин башкортта узаң бик көчле, мондый бүлгәләүләргә бирешмәсләр. Аларны да хәзер теге 50 процент мәсьәләсе борчый. Мәгълүм ки, башкортлар үз республикаларында 21 процент тирәсе генә... Ә бит бичәләрне, тиз арада гына көчләп, унар бала таптырып булмый. Менә алар бу тупиктан чыгу юлын тапканнар: янәшәдә генә татарлар яши ләбаса! Аларны татар телле төньяк-көнбатыш башкортлар дип игълан итәргә! Татарлар 28 проценттан артык, менә барысы бергә 50 процент тирәсе була да инде. Ләкин башкорт идеологларына бу гына да аз тоелган, күрәсең, алар Татарстанның көнчыгыш районнарында яшәүче татарлар-

ны да башкортлар дип игълан иттеләр. Бөтә башкорт корылтае халык санын исәпкә алу буенча чыгарган карарында Минзәлә «башкортлары» арасында милли үзаңны уяту җәһәтеннән аңлату эшләре җәелдерергә чакыра.

Шулай итеп, татар халкын алда зур сынаулар көтә. Бердәм татар милләте булып калырбызмы, әллә бүлгәләнеп XXI гасырны кичә алмыйча бүтән халыклар эчендә эреп югалырбызмы? Үз йөрәгенә таянып, иманы белән күзгә-күз калып, бу сорауга һәр татар үзе җавап бирергә тиеш.

*Февраль, 2002*

# ТАТАР ЗИРАТЫ

Чит якка әләксәм, бераз тын алганнан соң, мин андагы зиратны карап йөрергә яратам. Күптәнге хакыйкать халыкның яшәеш кимәлен, мәдәният дәрәҗәсен белергә теләсәң, андагы зиратка күз сал. Көнбатыштагы ыспай мазарлар, пөхтә каберләр, әлбәттә, анда ятучыларның токымнары ниндирәк хәлдә яшәвен тагын бер мәртәбә исбатлап, тәкрарлап тора. Юкка гына Клаузевиц: «Зират — тормышның дәвамы», — димәгәндер.

Шулай түгелмени?! Һәр кеше, җәсәденең җан өчен бер кием генә булуын аңлаган хәлдә дә, нәфсе колы буларак, аның эзсез-нисез юкка чыгуын теләми, үз балаларының гына булса да, кабере янына килеп үзен яд итүне өметләнә!

Кеше өчен бу табигый өмет...

Ләкин татар шул аерым кеше!

Менә ничә дистә еллар инде этнопсихологлар безнең үзенчәлекне, бүтән милләтләрдән аерымлыкларны эзлиләр. Әллә нинди нечкәлекләргә керергә кирәкми дә югыйсә, халыкның үзенчәлеген тууга һәм үлемгә мөнәсәбәте ачык билгели.

Татарны башка халыклардан үз зиратына, мазарлыкларына битарафлыгы аерып тора.

Хәтерлим әле, мин бала чакта, «авыл мулласы»ның рөхсәте белән, зиратыбызга колхозның ат көтүен керттеләр. Чөнки сөрелерлек җир сөрелеп, елкыларга утларлык җир калмаган иде. Ат тояклары астында каберләр ишелеп, эзләре калмый башлагач, икенче елны кемнәрдер көтүнең зиратта йөрүен туктатты. Бәлки, бу каршылык каберләр өчен борчылудан да булмагандыр, чөнки бүтән елларда пайлашып урам белән анда печән чабалар иде. Йорт башына ярты арба печән тия иде...

Мондый мөнәсәбәтне, әлбәттә, мохтаҗлыктан, ул вакыттагы колхоз системасының дәһшәте белән дә аңлатып буладыр...

Ләкин безнең авыл уртасында иске зират бар... Анда инде бер кабернең дә эзе юк! Юан агачка терәлгән бердәнбер таш тора. Анысын да революциягә кадәрге мулла — Фатих хәзрәт үзенең абыстаена дип кайдандыр кайтарткан булган, әмма әлеге таш үзенә билгеләнгән урынына утыртылганчы мулланың үзен дә, гаиләсен дә коммунистлар таш капчыкка тыкканнар. Ә кабер ташы шул килеш калган — абыстайның туган елы язылган, вафатын Алла белә...

Минем дә Якуп, Салих, Зәбир бабайлар шул болын кебек җәелгән зират эчендә яталар.

Хәзер анда яңа мулла печән чаба.

Бер таш билге юк...

Әлбәттә, безнең урман-дала якларында таш табу да кыен булгандыр... Әмма күрше чуашлар юлын тапкан бит — алар мазарлыгында имән тәреләрнең, мәҗүси баганаларның төбе... (Сугыш вакытында безнең авылдан бер вәхши фронтовик утын мәсьәләсен урманга бармыйча гына шунда хәл иткән.)

Каберләр өстенә таш билгене бездә әле ун-унбиш ел элек кенә куя башладылар.

Юк, монда хикмәт мохтаҗлыкта, ярлылыкта гына да түгелдер... Гадәттә, татар үз якынын җирләп кайткач, аның каберен оныта... Ул, әлбәттә, җидесен, кырыгын, елын үткәрә, соңыннан да рухына Коръән укыта, әмма башка халыклар кебек кабергә барып, аны пөхтәләп, җыештырып йөрми.

Авылдагы татар зиратларын гадәттә чытырман баскан була.

Мин бу турыда күптәннән уйланам.

Хикмәт безнең борынгы замандагы күчмәлектән килмиме икән?

Әнә бит А.Марцеллин һуннар турында нәрсә язып калдырган: «Аларның берсе дә Ватаннарының кайда икәнен әйтә алмый, — ди ул. — Ул бер җирдә яралган, икенче җирдә туган, тагын да еракта аякка баскан». Каберләре дә Бөек Даланың төрле төшләрендә сибелеп калган...

Гел алга-алга омтылган кавемнең, кире кайтып, әби-бабаларның каберенә сыгынырга мөмкинлеге булмагандыр?

Ләкин төркиләрнең уртак тарихы бу фикерне кире кага. Күлтәгин, Билгә каганнарга куелган язулы ташларны искә төшерик (VIII гасыр). Дәшти Кыпчактагы курганнар, илбасарлар тарафыннан күпмесе юкка чыгарылып та, әледәнәле табылып торган таш бабалар, балбаллар...

Инде килеп, Болгар заманыннан калган, күпмесе чиркәү нигезләрен тәшкил иткән кабер ташлары...

Данлы-шанлы чакларыбызда без дә бабаларыбыз җирләнгән җирне һәрчакта яд иткәнбез, олылаганбыз икән ләбаса...

Рухы төшкәндә, киләчәгенә ышанычы калмаганда гына халык үз зиратына битарафка әверелә, бөек шәхесләренең каберләрен югалта.

Юкка гына илбасарлар, яңа илләрне яулап алуга ук, җиңелүчеләрнең архитектурасын, әдәбият-сәнгатен юкка чыгару белән бергә, зиратларны да җир йөзеннән вәйран итәргә теләмиләр. Бакчасарайда хан сарае тирәсендә аунап, җимерелеп яткан чалмалы кабер ташларын күреп йөрәгем әрнегән иде. Дуңгызлар абзарына таба җәелгән тротуарларда куфи язулы ташлар андагы килмешәк халыкның аяк табанын яндырмый иде шул.

Зираттагы таш билгеләр — халыкның киләчәк буынга теркәп калдырган васыяте, әманәте дә ул...

Аларда милләт язмышының коды яшерелгән.

Һәр өммәтнең үз зираты. Утызынчы елларда «халыклар дуслыгы» дигән булып, кайбер кызыл бушбугазлар уртак зиратлар ясарга теләгәннәр. Янәсе, «туганнар каберлеге». Ләкин идеология никадәр генә көчле булмасын, һәр халык аерым үз зиратына ятарга тели. Үз җиренә...

Соңгы елларда Польша-Литва татарлары турында күп яздылар. 1988 елда миңа (тагын Ләис Зөлкарнәй белән Айрат Садыйк бар иде) Польшага барып чыгарга туры килгән иде. Белеш журналистлардан андагы татар авылларын күрсәтүне үтендек. Менә алда Крушеняны белән Боһоники авыллары. Әлбәттә, авылдагы телен югалткан унлап татарга караганда безгә аларның зираты (ягъни үткәне!) кызыграк иде. Шунда юнәлдек. Борынгы зират... Яңа каберләр... Мәрхүм булган татарларны бөтен Польшадан монда алып кайтып җирлиләр икән... Пөхтә, чиста... Безнең Яңа бистә зиратындагы кебек һәр каберне чылбырлап чардуганнар кормаганнар.

Финляндиядә яшәүче татарларның зираты — Һельсинкиның үзәгендә... Шундый ук кырыс матурлык, ыспайлык...

Истанбулда Йосыф Акчура кабере өстендә нәни генә Сөембикә манарасы... Янәшәдә генә Гаяз Исхакыйның тыйнак кабере... 10/87... Күзгә төртелеп тормый торган таш билге...

Теге алман дөрес әйткән: зират — тормышның дәвамы ул...

*Апрель, 2002*

# КАЗАН

Башкалабызның меңьеллыгына әзерләнәбез. Әлеге тантананы үткәрү өчен оешкан комиссияне Рәсәй президенты В.Путин үзе җитәкли. Менә ул татарларның III Корылтае вакытында Казанга килеп шул комиссия белән дә очрашты. Бүленгән акчаның нинди максатларда тотылуы белән дә кызыксынган, диләр. Мондый хәлгә безнең агай-энеңең күңеле була инде. Янәсе, безне дә санга сугалар. Юбилей сылтавы белән Казанга да федераль казнадан шәп кенә акча тамачак, янәсе. Ләкин тамызылган нәрсә мул була алмый, юбилейга дип бүленгән акча, әле тулаем Казанга кайтып җитә алган очракта да, Татарстаннан суырылган салымнарның бик аз өлешен генә тәшкил итәчәк.

Шушы зур юбилейга әзерлек мәшәкатьләре күләгәсендә тагын бер түгәрәк дата күз уңыннан читтәрәк кала шикелле. Чөнки ул кызмача килеш җырлап-биергә сәбәп була алмый, Казанның чит ил баскыннары тарафыннан тар-мар ителүенә 450 ел! Димәк, бөек кала ярты гомерен генә хөр, азат килеш яшәп калган икән...

Казан юбилеена әзерлек комиссиясен Рәсәй президентының үзе җитәкләве һич тә очраклы хәл түгел. Империя тарихында зур урын билап тора шәһәребез. Әлеге тарих нәкъ менә Казан егылу белән башлана да инде — Тын океанга чыгарга, Түбән Идел аша Үзәк Азиягә үтеп кирәргә бүтән сәяси киртәләр калмый.

Казанның юбилеен Рәсәй күләмендә тантаналы рәвештә үткәрү ул империянең бүген дә исән һәм дәһшәтле икәнлеген дөньяга күрсәтү өчен дә кирәк.

Без бүген 450 ел элек булган һәлакәтебезне искә төшерәбез. Тыныч кына, басынкы гына... Хәтер көнендә берике мең кеше җыелып янә Сөембикә манарасы янына килербез. Купчелек татар дидекемез халык бу аянычлы көннең хатирәсен искәрмәс тә, искәрсә дә, ул тирәгә бармас — чөнки монда сыра сатмыйлар, Мәскәүдән шабашкага килгән «Отпетые мошенники» ише ансамбльләр дә сәхнәдә үрле-кырлы сикерми.

Ватаннарын саклап соңгы тамчы каннарына кадәр сугышкан бабаларыбыз рухына дога кылучылар аз, бик тә аз. Алар әле купчелек иләтнең ачуын да китерә: әллә кайчангыны искә төшереп йөриләр шунда... Кызын урыска биргән, улын марҗага өйләндергән татар әбие (чалбар кигән, иренен буяган — шәһәрчә «мәдәниләшкән») алар артыннан төкереп кала әле. Колхозга кайтып эшләргә куша. Әйе, татар шунда туңкаеп бәрәңге яфрагыннан коңгыз чүпләргә,

әче таңнан кара төнгә кадәр эшләп шушы әбиләрне туендырырга тиеш, ул шуның өчен генә кирәк. Шул михнәттән котылса, ул татар булудан туктый, урысча гына сөйләшә, үз асылын югалтмаганнарга мәсхәрә белән карый башлый. Мондый сәнәктән көрәк булучылар безнең эреле-ваклы түрәләр арасында аеруча күп. Тикмәгә генә борынгылар «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә» дип әйтмәгәннәрдер. Балда-майда йөзеп, алтын-көмеш белән томаланса да, Кенәри утрауларында виллалар салдырса да, аның асылы һәмишә борнаган чабата булып кала бирә.

Мәкаль борынгы, димәк, безнең бу мәшһүр сыйфатыбыз күптәннән килә. Татар түрә булса, туганын танымый, дигәне дә бар ич әле. Туганыннан, ягъни халкыннан ваз кичә!

Бабаларыбыз рухына дога кылганда шуны да онытмаска кирәктер. Шуңа да татар дәүләтенең егылу сәбәпләрен эзләгәндә үзебезнең тарих көзгесенә күз ташлап алу да комачау итмәс. Безнең күп милли тарихчыларыбыз җиңелүнең сәбәбен бәк-морзаларның бер-берсе белән тыныша алмавыннан, шәхси мәнфәгатьләре хакына дәүләт гамен аяк астына салып таптауларыннан күрә. Татар башын татар ашый. Шушы гыйбарә элеккедән — әле безнең бәйсез, мөстәкыйль чаклардан ук хәзергәчә авыр богау сыман арттан сөйрәлеп килә түгелме соң?

Әлбәттә, чит мәмләкәтнең дә көчле басымын инкяр итеп булмый. Әле Бату хан яуларына кадәр үк төньяк-көнбатыш урыс кенәзлекләре Болгар җирләренә теш кайрый башлыйлар. Шул чакта ук илбасарлыкта, юлбасарлыкта данлыклы урыс-варягларның дружиналары болгар шәһәрләрен талый. Әледән-әле ачлыкка дучар булган славян халкына икмәкләтә ярдәм итеп торуына карамастан, Болгар иленә бу һөҗүмнәр даими рәвештә ясалган. Юкса элеккечә «колмак та суда батмаган, таш та су өстенә калыкмаган». Мөгаен, Бату гаскәрләре Болгарны да, урыс кенәзлекләрен дә үзенә буйсындырмаган булса, Владимир-Суздаль кенәзлеге болгар җирләрен XIII гасырда ук яулаган булыр иде. Бөтен дөньяны тетрәтеп торган Урда гаскәре урысларның көнчыгышка сузылган нәфесен кыскарта. Ләкин Җучи олысында үзара болганыш башлангач (XIV гасырның 60–80 еллары — «великая замятня») урыс-улаклар (ушкуйникларны татарлар шулай атаган) көймәләрдә килеп Болгарны һәм бүтән Идел буе шәһәрләрен талый башлыйлар. Алар хәтта Сарай шәһәренә дә һөҗүм итәләр! Варяглык традицияләре терелә.

Мәскәү кенәзлеге көчәйгәч, Урта Идел урысларның, хәзергечә әйтсәк, «милли интересларының сферасына» әверелә. Урыс башлы татар морзалары кутәргән бу дәүләт инде үзенең тар кысаларына гына сыя алмый. Урыс елъязмачылары,

аннан соң тарихчылары Казан ханлыгын ниндидер «юлбасарлар оясы» дип күрсәтергә тырышса да, чынбарлык бөтәнне сөйли. Ибраһим хан заманыннан башлап урыслар Казанга гел һөҗүм итеп торганнар, Казан исә сакланган гына.

Ара-тирә Муром, Кострома тирәсенә яулары да урыс походларына җавап рәвешендә генә булган.

Әлеге экспансияне Мәскәү хөкүмәте идеологик яктан да бик яхшы нигезләгән. Борынгы татар ханнары биргән өстенлекләр аркасында симергән, баеган катлау — дин әһелләре халыкны гел «поганый татарлар»га каршы котырткан. Әле 1523 елда ук Сура елгасының бу ягында — Казан дәүләте җирендә Васильсурски кальгасын коргач, митрополит Даниил: «Тем городом мы всю землю Казанскую возьмем», — дип күрәзәлек итә.

Казанга хәлиткеч һөҗүмне оештыручы исә митрополит Макарий була. Әле 1536 елда ук ул Новгородта һәм Псковта зинданда утыручы татар хатын-кызларын, бала-чагаларны көчләп чукындыра, чукынудан баш тарткан ирләрне исә буып үтерергә боера.

Әлбәттә, дини фанатизм нинди генә көчле булмасын, Казанга һөҗүмнәрнең асылын икътисади мәнфәгатьләр билгеләгән. Мәскәү тирәсендәге торфлы, уңдырышсыз җирләр генә ярлы дворяннарны канәгатьләндерми башлый, ә сәүдәгәрләргә исә Шәрекъ илләре белән сату-алу итәр өчен Идел буен тулысынча үз кулларына төшерү ихтыяҗы туа. Урыс идеологлары татар җирләрен «всем угодная подрайская землица» дип атыйлар, аны дус булган хәлдә дә басып алуны таләп итәләр. Әмма кыр-бакчаларны «оҗмах җире» ясар өчен анда күпме маңгай тирен түгәргә кирәклекне алар белмәгәннәр, күрәсең. Казан алыну белән, әлеге бәрәкәтле җирләр ташландык хәлгә килә, алар Мәскәү документларына «пустошь» дигән сүз белән теркәлгән.

Казанның җиңелү сәбәбен дәүләтнең эчке структурасыннан да эзләү урынлы. Ханның хакимияте бередә зәгыйфь, ягъни дәүләт чын-чынлап үзәкләштерелмәгән була. Һәр морза-бәкнең, огъланның артында үз чирүе тора һәм алар һәрберсе үз мәнфәгатеннән чыгып эш йөртә. Мондый хәлдә, әлбәттә, үзенең аз санлы гаскәренә генә таянган хан тәхетендә ышанычлы утырмаган (хан алмашынуга карап ул гаскәрне йә касыймнар, йә кырымнар тәшкил иткән). Бәк-морзаларның партияләргә бүленүе турыдан-туры сәүдә өлкәсенә бәйләнгән. Мәскәү белән сәүдә итүчеләр урысларга тугрылыклы Касыйм ханнарын чакырсалар, Шәрекъ белән алыш-биреш итүчеләр Кырым ханнарына илчеләр юллаган.

Сәүдәгә бәйле рәвештә кайбер бәкләрнең сәяси симпатиясе кинәттән капма-каршы якка да үзгәрә алган.

Казан аксөякләренең мондый башбаштаклыгы дәүләтнең көчәеп китүенә зур киртә булган, билгеле. Мәскәү кенәзлегендә вазгыять бөтенләй бүтән — анда олуг кенәз бердәнбер тулы хокуклы хуҗа, деспот, ә башкалар исә, баена, ярлысына карамастан, аңа холоплар булып буйсынырга тиеш... Әле ул үз тәхетен юри генә ташлап китсә дә, баярлар күз яшьләрен түгеп, ялынып, аны кире чакырырга баралар. Йә, безнең татар тарихында сез мондый күренешне күз алдына китерә аласызмы? Бездә ханнарны тәхеттән куганнар йә үтергәннәр.

Бәкләрнең мөстәкыйльлеге чит илләр белән мөнәсәбәттә дә күренә. Хан белән беррәттән алар чит патшаларга хатлар, ярлыклар язганнар... Мәсәлән, 1540 елларда Бөек Литва кенәзе Сигизмундка Сафа Гәрәй хан белән беррәттән үз чапкыннары аша бәк-морзаларның да ярлык җибәргәннәре мәгълүм. Алар арасында хан аталыгы Ямгырчы, Булат би, Кадыш би, Мамай огълан, Кодакчы морза, хәтта хан хатыны да була. Нугай Урдасында да шул ук хәл — морзаларның һәрберсе Мәскәү патшасына хат яза, дәүләт серләрен сөйли, ахырдан кием сорый, кәгазь җибәрүен үтенә (тагын да хат язар өчен, күрәсең). Мәскәү кенәзлегендә исә олуг кенәздән башка беркем дә тышкы сәясәткә тыкшыну гына түгел, чит илгә мөстәкыйль рәвештә хат та яза алмаган. Язган очракта да Посольский приказга күрсәтергә тиеш булган. 1536 елда Шаһгалинең Казан бәкләренә мөстәкыйль хат язуы беленгәч, (ул анда үзен тәхеткә чакыруны үтенә), урысларга эттәй тугърылыклы булуына да карамастан, аны Белоозерьега сөрәләр, ә якын кешеләрен төрмәләргә тыгалар. (Макарий чукындырган татар хатыннары нәкъ шул Шаһгали сараеннан булалар да инде.)

Урыслар үзләренең диссидентлык тарихын Литва кенәзлегенә Иван Дүртенченең дәһшәтеннән качып киткән Андрей Курбскийдан башлыйлар. Татар диссидентлыгының тамырлары тирәнрәк. Хан белән килешмәгән бәк-морзаларның урыс ягына качулары Алтын Урда чорында ук башлана. Биредә аларны кочак җәеп каршы алалар, туенырга шәһәрләр дә бирәләр. «Диссидентлар» исә туган илләренә каршы корткычлык эшенә керешәләр, яңа хуҗалары әмер итүгә алгы сафларда яуга кузгалалар.

Казан бәкләре дә әледән-әле Мәскәүгә кача. Зөя тамагына кальга салганда урыслар арасында Казан мөһаҗирләреннән биш йөзләп кеше була: Костров, Чапкын Үтәш углы, Бурнаш һәм башка бәкләр...

Шунысы да мәгълүм: урыс ягында йөргән бәкләрнең шактые Казан өчен хәлиткеч вакыт җиткәч Ил-йорт өчен көрәшкә кутәрелә... Урыс калгаен кертмәскә дип кала капкаларын ябып куйгач, татарларны урыс патшасына тугъры-

лыклы булырга ант иттерергә килгән Чапкын бәк илнең бәйсезлеген саклар өчен оешкан хөкүмәтне җитәкли башлый. Ә хан тәхетенә чакырылган Ядкәр-Мөхәммәд әле бер ел элек кенә Мәскәүләр белән Казан өстенә яуга йөргән була.

Бәлки, йортның һәлакәт алдында калуы үзара гауга-талашларны, шәхси мал кайгысын оныттыргандыр?

Шулай фидаилек белән хыянәт янәшә йөри. Чолганган каладан дошман ягына качып чыккан хаин Камай морза илен сату бәрабәренә соңыннан өстәмә җир биләмәләре ала. Аның улы Кадрәк тә урыс ялчысы буларак тарихта билгеле шәхес.

Бу дәһшәтле яуда Мәскәү гаскәре белән Шаһгали татарлары, Енәкәй морза төмәннәре дә (Темников мишәрләре) катнаша. Тик аларны хыянәтче диеп булмыйдыр. Чөнки алар яшәгән җирләр Мәскәү кенәзлегенә кергән (Туктамыш хан Темников — Норовчат җирләрен әле XIV гасыр ахырында ук Мәскәүгә бүләк иткән була). Урта гасырларда бер халыкның ике дәүләткә бүленеп үзара сугышуы табигый. Мәсәлән, Литва кенәзлегендәге урыслар литва-поляклар белән беррәттән Мәскәү урысларына каршы гел сугышып торганнар...

«Мишәрләр Казанга каршы сугышкан», — дип кайбер дуслар үзара гәпләшкәндә чәнчеп алырга яраталар. Хәлбуки, Касыйм татарларын мишәрләр тәшкил итми. Казан хөкүмәтенең 1551 елда Үтәмеш Гәрәй ханны анасы белән Мәскәүгә тапшыру турындагы ярлыгында ханлыктагы социаль катламнар һәм халыклар санап үтелә. Анда мишәрләр дә телгә алына. Табигый, болары инде илбасарларга каршы Ватан сугышына күтәреләләр.

Казан олуглары, төрле дипломатик юллар белән, ничек тә илнең бәйсезлеген саклап калырга теләгән. Сугышның алар файдасына бетмәсен яхшы аңлаганга, Мәскәүнең һәр шартына күнәргә әзер була алар. Тик дәүләт кенә исән калсын! Мәскәүгә гел илчеләр йөреп тора. 1551 елның 8 июлендә Җанбарыс морза җитәкчелегендәге илчелек Шаһгалине хан итеп танырга, Үтәмеш ханны исә әнисе Сөембикә белән урыслар кулына бирергә килешеп кайта. Ханны биреп, илне сакларга телиләр! Сентябрьдә исә Казан ханлыгы, мөстәкыйль дәүләт буларак, Мәскәүгә соңгы илчеләрен җибәрә. Аны олы карачы Нургали бәк Ширин үзе җитәкли. Алар урыс хөкүмәтеннән Тау ягын Казан ханлыгына яңадан кушуны сорыйлар, урыс патшасының исә үзара шартнамәне үтәячәгенә ант итүен үтенәләр.

Казандагы әсирләрне тулысынча азат иткәнгә кадәр дигән сылтау белән урыслар илчеләрне Мәскәүдә тотык итеп калдыра. Татарның «Илчегә үлем юк» дигән мәкален Мәскәүдә ишетмәгәннәр, күрәсең.

Тау ягын Казан ханлыгына кире кушуны сораганга урысларның җавабы кыска була: «Что государю бог дал, того ся ему не попустит!»

1994 елда Мәскәү белән шартнамәне әзерләүчеләр Казан ханлыгының тарихын исләренә төшерделәрме икән? Төшергәннәрдер, чөнки гасырлар үтсә дә, Мәскәү сәясәтенең үзгәргәне юк.

Чөнки «тот прав, у кого больше прав».

Казанны сугышмыйча гына илбасарга тапшырсалар, халкыбызның язмышы бу кадәр аянычлы булыр идеме?

Әлбәттә!

Явыз Иванның Мәскәү кенәзлегенә үз ихтыяры белән кушылган Новгородны пыран-заран китереп канга батыруын онытмыйк. Әле бит алар бер диндәге, бер телдә сөйләшүче халык. Татар Казанын, үзе бирелгән очракта да, җир йөзеннән себереп түгәчәкләр иде... Дин-иман мәсхәрәләнәчәк иде. Теге өч каһарман — Ислам, Кәбәк, Галикәй бәкләр — аларның шул ниятләрен белеп Бишбалтадан Казан капкаларын бикләргә ашыкканнардыр да...

Әллә хан улын кызганып, кала нигезенә эт күмеп калдыручы вәзир барысына да гаепleme?

Казан илчеләре бүтән кардәш дәүләтләрдән дә ярдәм сорап караганнар. Бу заман бит Госманлы Төркиясенең иң куәтле чагы. Әмма Сөләйман Кануни солтанныңниндидер шимали илдә гаме булмый. Ул Аурупаны, Африканы яулау белән мәшгуль. Нугай бәге Йосыф исә энесе — урысларга әшнә Исмәгыйльнең ризалыгыннан башка Казанга ярдәм итәр өчен зур гаскәр туплый алмаган. Кырымда Сәхиб Гәрәйне яңа гына бәреп төшергән Дәүләт Гәрәй хан тәхеттә ныгый гына әле. Дөрес, егерме елдан соң ул Рәсәйгә бәреп керә, Мәскәүне яндыра, йөз меңнәрчә кешене кыра, Казан белән Әстерханны урыслардан азат итүне таләп итә: «Жгу и опустошу Россию единственно за Казань и Астрахань...» Ләкин икенче сугышта Кырым ханы җиңелә һәм үзенең дәгъваларыннан баш тартырга мәҗбүр була.

Казан үзенең көчле һәм дәһшәтле дошманы белән бергәбер кала. Бөек Каза килгәндә Казан халкы Азан тавышы белән соңгы яуга күтәрелә. Татар халкының горурланырга хакы бар — бабаларыбыз соңгы тамчы каннарына кадәр Ватанны саклаганнар. Казанның егылуы сәбәбен гел үз халкыбыздан гына эзләгән Һади Атласи бу турыда менә ничек яза: «Болар, тоткын булып яшәүгә караганда, йорт өчен үлүне артык күргәннәр, шул уй белән орышка керешкәннәр иде. Аларның уйлары үзләренчә изге булган кеби, үлүләре дә изгеләрчә иде...»

Урыс патшасы үтсен өчен Нургали капкасыннан алып

Хан сараена кадәр араны көч-хәл белән үлекләрдән арындыралар. Иван Казанны ялмап алган янгынны сүндерергә боера һәм сугышчыларына талар өчен өч көнгә каланы бирә.

Төп чиркәүне саласы урынга тәре утырта...

Татар Казанының тар-мар ителү көнен искә алырга теләмәгән кешеләргә урыс Казанына нигез салынуның 450 еллыгын билгеләп үтәргә мөмкин.

Бик төгәл дата...

Аракы эчеп, җырлап-биеп, Мәскәү җырчыларын чакырып...

*Сентябрь, 2002*

## КАҢГЫРЫШ

Бөтендөнья татарларының III Конгрессы да үтте. Бу мәҗлестә катнашучыларның сокланулы мөнәсәбәтләре татар гәҗитләрендә чагылды: Конгрессның әһәмиятен сүз белән генә аңлатып бетерә торган түгел, нәтиҗәләре дә киләчәктә күренәчәк икән.

Ышанабыз! Кеше матур киләчәккә һәрвакыт ышанырга тиеш.

Шулай итеп бөтен дөньядан килгән татар вәкилләре бергә җыелып өченче тапкыр киңәш-табыш итте. Тиздән Рәсәй күләмендә халык исәбен алу алдыннан мондый җыелу хуплауга лаек, әлбәттә. Тик читтән килгән вәкилләрнең кем булуларын гына ачыклыйсы бар. Үз төбәкләрендә яшәгән татарларның чын юлбашчыларымы алар, әллә җирле хакимият тирәсендә буталучы буш куыкларммы? Әнә Башкортстаннан килгән рәсми делегация вәкилләре үзләренең милли-мәдәни хәлләрен ал да гөл итеп күрсәтсәләр (чөнки алар хакимиятнең катгый күзәтүе астында сайланган), иҗтимагый оешмалар тарафыннан юлланган вәкилләр башкачарак сөйли. Шуңа күрә аларны бомба белән куркыттылар да. Янәсе, алар яшәгән кунакханәгә террорчылар шартлаткыч куйганнар. Хәзер бездә шулай: авызны томаларга кирәк булса, кайдандыр бер террорист килә дә чыга...

Шулай да Рәсәй Президенты В.Путин белән очрашуда Бәләбәйдән Нурмөхәммәд Хөсәенов Башкортстан татарларының зарын яңгырата алды. «Башкортстанда татар булып яшәве җиңел түгел», — дип, бөтен дөньяга аваз бирде. Шулайдыр. Татар гимназиясенең бинасы кашына татарча «Хуш киләсез» дип язып элгән өчен генә дә судка биреп интектергәч, хәлләр ал да гөл түгелдер. Татар мәктәпләрен

башкортлаштыру, төрле коткы тарату юллары белән көчләп татарларны башкортка әйләндерү омтылышлары турында инде әйтәсе дә юк.

Ләкин Н.Хөсәеновның ачынып әйткән сүзләренә В.Путинның реакциясе миңа сәер тоелды: «Самое острое из того, что он сказал, — быть татарином в Башкирии нелегко. А русскому в Татарстане? А чеченцу в Москве?» Мондый чагыштыруны ишеткәч, нәрсә уйларга да белмисең. Чеченнәрнең Мәскәүдәге хәлләре безгә билгеле. Чеченнәрнең генә түгел, алар аркасында бөтен «Кавказ милләтле чырайларның» анда әледән-әле кеше хокукларын бозып торалар. Ә Татарстанда яшәүче урысларга ни булган? Алар элеккечә үк биредә үзләрен бердәнбер хуҗа итеп хис итәләр һәм безгә дә шуны даими сиздереп торалар. Соңгы ике елда инде без күп милли казанышларыбызны югалттык. Бу хәлгә Мәскәүнең генә түгел, Татарстанда яшәүче урысларның да өлеше зур. Моны, билгеле, В.Путин да бик әйбәт белә. Шуңа күрә «быть татарином в Башкирии нелегко, татарину в Татарстане тоже» дип әйтелсә дөресрәк булыр иде.

Мондый басым безнең халыкның халәтенә тәэсир итми калмады. Куллар элеккечә салынып төште. Элекке эйфория төтенгә әйләнеп таралды. Халык бик гади төшенчәләр белән фикер йөртә, көндәлек вазгыятькә карап хәрәкәтләнә. Икенчел халык булып яшәргә өйрәнгән татар бигрәк тә...

Улым Баязит быел мәктәпкә керде. Ераграк булса да татар-төрек лицеена илттем. Анда инде ата-аналарның теләге белән урыс классы да ачылган икән. Менә шунда 33 бала җыелган, ә татар сыйныфында 13...

Мәктәп каршында ике хатынның сөйләшкәне колакка чалынды. «Татарча укуы кыен, андагы «катлама» дигән сүзләрне чурт та аңламый». Икенчесе аны җөпләде. «Татарча укысаң, вузга керүе кыен булачак...»

Бер хезмәттәшем дә баласын мәктәпкә илтте. Алар мәктәбендә «национальный класс» бар икән. Ягъни анда этник татар балалары укый. Урыслашкан балалар. Ә класс җитәкчесе бер авыз сүз татарча белмәгән һәм белергә дә теләмәгән марҗа.

Ә без татар мәктәпләренең саны артты, милли класслар ачыла дип күңел юатабыз. Совет заманында, татар балаларының 7 проценты үз телендә белем ала, дип сөйлиләр иде. Хәзер дә шуңардан әллә ни артмагандыр.

Малайны «татар мәктәбе»нә биреп, икеле-микеле уйлар белән ишеккә атладым. Коридорда балалар чыр-чу килә. Ник бер татар сүзе ишетелсен!

Юк, төп гаепне үзебездән эзләргә кирәк.

Безне нинди юл көтә? Тиздән татарча белмәгән татарлар

күпчелекне тәшкил итәчәк бит. Ләкин аларны чын татар дип атап булырмы соң? Милләтнең нигезе тел һәм мәдәният ләбаса. Аны саклар өчен үзебезнең үзенчәлекле мәгариф челтәрен киңәйтергә кирәк. Бу мәсьәләгә Конгрессста җитәрлек игътибар ителдеме соң?

Шунысын гына әйтү дә җитә: Конгресска килгән вәкилләрнең шактые урыслашкан татарлар иде. Үзара фикер алышканда драматург Мансур Гыйләҗев әйтеп куйды: «Конгресс татар» түгел, «Конгресс потомков татар» булды бу...»

Мондый вазгыятьтә милли университет, әлифбаны латин хәрефләренә күчерү мәсьәләләренең күз уңыннан читтә калуына гаҗәпләнәсе юк. Чөнки күпчелек делегатларга әлеге мәсьәләләр бөтенләй ят.

Алайса нигә аларны, шулкадәр чыгымнар тотып, Казанга җыйдылар? Бергә каңгырышып алыр өчен генә түгелдер ич?

Безнең бөтен Рәсәйгә таралган күпсанлы халык икәнне Мәскәүгә янә бер мәртәбә искәртер өчен әлеге корылтай да кирәк булгандыр шәт. Ләкин шушы Конгресска бәйле рәвештә мин үзебезнең халыкта ниндидер бердәмлек тантанасын, бәйрәм рухын тоймадым. Татарстан суверенитеты хәрабәләре өстендә уздырылган мәҗлес иде ул. Бәлки, соңгы мәҗлес...

Татар Конгрессының Рәсәй дәүләт гимны белән башланып китүе дә зур нәрсә турында сөйли. Ярый, Татарстан үзенең Рәсәй итәге астында булуын танысын да ди, ә Америкадан, Австралиядән яисә Үзбәкстаннан килгән татар ни өчен әле бу Сталин мирасы булган музыкага торып басарга тиеш?

Татарстан кануннарының Рәсәйнекенә тәңгәл түгеллеге хакында Дәүләт советына туктаусыз протестлар яудыручы прокурорның президент Шәймиев артында канатларын җәеп утыруы да үзенчәлекле уйларга этәрә.

Гомумән, әлеге Конгресс татар түрәләренең режиссерлыгында куелган көпшәк спектакль сыман тәэсир калдырды. Делегатлар монда тавышсыз статистлар гына иде. Барысы да алдан билгеле финалны — Рәсәй патшасы белән очрашуны көттеләр.

Татарның корылтайлар җыюы бүген генә башланмаган. Казан җимерелер алдыннан соңгы корылтайның җыелуы тарихтан билгеле. XX гасыр башында инкыйлаб аркасында бу идея яңадан калкып чыга. Ике-өч тапкыр шулай җыелып алалар. Ләкин Мәскәүдә империячел хакимият ныгу белән мондый корылтайлар уздыруга чик куела.

Безнең аянычлы язмышыбызның сәбәпләрен шул вакытлардан ук эзләргә кирәктер. 1917 елда үткән II гомуми мөселман съездында Мамлиев белән Токымбәтов дигән кешеләр

чыгышларын урысча ясыйлар, ягъни Фатих Әмирхан әйткәнчә, «купшыланалар». Мөхтәрәм язучы әлеге хәл турында «Оят булды» дигән мәкалә яза. «Купшыландылар дим шунлыктан, чөнки бу ике егетнең һәр икесе кирәксенгән вакытларында бик аңларлык итеп татарча сөйли алалар». Әлбәттә, мондый кыланышка каршы төшүчеләр дә була. Токымбәтов исә үзенең нотыгын нинди телдә дәвам иттерү хакында тавышка куйдыра. Һәм... корылтай нотыкны урысча дәвам итәргә дип карар чыгара. «Йа Алла, — дип дәвам итә Ф.Әмирхан, — мәҗлестә булмаган кешеләр нинди бәхетлеләр: бу позорны карап утыру һәм оят, һәм ачы иде!»

Монда милли мохтариятьне игълан итүче тарихи корылтай турында сүз бара! Дөрес, соңрак Гомәр Терегулов бик ярсулы чыгыш ясый: «Үз ана телләрендә сөйли дә белмәгән кешеләр съездларга вәкил булып килмәскә бурычлылар иде!»

Менә бит — гаммәви урыслашуыбызның тамырлары бик еракларга һәм үзебезнең бабаларыбызга ук барып тоташа икән ич.

Зиннур Хөснияр, балаларны дингә күндерү максатында, «Аллага шөкер» дигән китап нәшер итте. Шуны Конгресс делегатлары арасында сатарга җыенгач, уңайсыз хәлгә тара ул. Делегатларның күбесе: «Китапның урысчасы юкмы?» — дип сорый икән. Димәк, үзләре татарча белгәннәрнең дә балалары инде үз телен белми. Хәер, белмәгәч, үз телең булмый бит инде ул, ят тел була...

Татар милләтен хәзер аннан тарталар, моннан йолкыйлар. Башкорт конгрессы вәкилләре Башкортстанның татар районнарында куна-төнә ята. «Халыкның күзен ачабыз», — ди Конгресс җитәкчесе Ә.Сөләйманов. Ягъни мондагы татарлар сукыр, һәмишә үзләренең башкорт икәнлекләрен белми яшиләр, имеш. Әсфәндияров дигән берәү Пермь, Свердловск өлкәләрендәге татар авылларында яшәүчеләрнең башкорт икәнлекләрен «фәнни» исбатлап китап чыгарган. Ул китапларны әлеге төбәкләрдә бушлай тараталар.

Безнең Конгресс җитәкчеләре исә Төркиядә, Америкада тантаналы мәҗлесләр үткәрә. Америкада яшәүче 200–300 татарның исән калу тәҗрибәсен өйрәнәләр микәнни?

Үзәк Азиядә бүленеп калган миллионга якын кардәшләребез турында Конгресста сүз булмады диярлек. Алар Казан матбугатына языла алмый, үз телләрендә укый алмый. Бик тиздән бөтенләй үзбәкләшеп, казакълашып бетәр, мөгаен.

Корылтайда яңгыраган чыгышларда да мескенлек комплексы үзен әледән-әле сиздереп торды. Гел Мәскәүгә карау, гел Мәскәүне күздә тотып сөйләү... Бөтен хикмәт үзебездә бит, егетләр! Үзәгебез нык булганда гына, көчле каршылык-

ны тойганда гына, Мәскәү үзенең бик еракка киткән ниятләреннән баш тартачак.

Зөлфәт Хәким бик көчле чыгыш ясады. Рәсәйдә милли сәясәт юк, дип бик нык борчылды инде. Сөйләгәнемне аңламас дип уйлап, ахры, Рәсәйнең милләтләр буенча портфельсез министры Зоринга да ачыргаланып мөрәҗәгать итте: «Нет в России национальной политики!»

Нишләп булмасын! Бик оста, бик нечкә үткәреләул политика. Татарстанның милли бәйсезлек яралгыларын буу шул сәясәтнең нәтиҗәсе түгелмени? Рәсәйдәге милли сәясәт күп гасырлар элек шәкелләшкән һәм аның асылында инородецларны урыслаштыру һәм христианлаштыру идеясе ята.

Конгрессста катнашучылар резолюцияләрне бертавыштан кабул иттеләр. Документлар бик яхшы әзерләнгән иде, шуңа да өстәмәләр ишетелмәде, ахрысы. Аннары яңа җитәкчене беренче тапкыр күреп истә калдырырга тырышучылар булды. Делегатларның уянып китүе, бер организмга әверелүе концерт вакытында күренде бугай. Безнекеләр җырларга-биергә, тамаша карарга ярата. Андый чакта күңелсез резолюцияләр, бөтенләй искә төшмәслек булып, баштан чыгып оча.

Ә Путин белән очрашуда Бәләбәй татары гына түгел, бүтән яклардан килүчеләр дә чыгыш ясаган. Кострома татарының президентлар каршына куйган проблемасы турында Казандагы урыс матбугаты бик озак яратып язар әле. Костромадагы татар зиратына бер христианны күмгәннәр, моңа мәчет картлары каршы һәм бу мәсьәләне кичекмәстән хәл итәргә кирәк икән...

Ташландык зиратка кемне күммәсләр?

Хәер, бу очракта инде Фатих Әмирхан сыман мәкалә язып кына котылып булмас. Шагыйрь сүзләрен үзгәртеп әйткәндә, мәсьәлә бик зур, сыйдырмый мәкаләләр үлчәве...

*Сентябрь, 2002*

# КАРАЧКЫ

Урамда бер бөкре Казан шагыйре очрады. Исәнләштем инде. Ә бу моңа каршы: «Ну, как там татарский фашизм?» — ди. Артыма авып китә яздым. Мондый мәгънәсезлеккә ничек җавап бирәсең... Нәкъ шул мәлдә әлеге бәндәнең язучылар корылтаендагы чыгышы искә төште. Урыс шагыйрьләренең Казанда китап чыгару мөмкинлеге булмау турында сөйләгән иде ул. Ягъни урыс исеме астында урыслашкан

башка миллэт вэкиллэре китап чыгарып ята икэн. Нэшриятта кемдер урысча язучыларны «чиста» урысларга һэм «корамаларга» аерып утырырга тиеш микэнни? Бу очракта әлеге чыгыш теге көрән идеологияне гамәлләштерергә чакыру була түгелме соң? Каракның бүреге яна, диләр, дөрес икән...

Уңышсызлыкның сәбәбен Рәсәйдә гел читтән эзлиләр. Икътисадтагы булдыксызлыкка яһүдләр гаепле, әллә кайчангы татар явы аркасында авыл хуҗалыгы аксый. Ул гына да түгел, хәтта сүгенүне дә урысларга татарлар керткән, имеш. Әлеге бөкре шагыйрь дә үз булдыксызлыгын яһүдләрдән, татарлардан күрә. Мәгълүм эпиграмма моңа бик туры килеп тора:

Поэт горбат,
Стихи горбаты.
Кто виноват?
Евреи виноваты...

Сүз дә юк, икътисадта, сәясәттә, мәдәнияттә яһүдләрнең тәэсире бик зур. Чагыштырмача аз булуларына карамастан, алар һаман өстә. Булдыклылар, димәк. Тик бишмәтеңә ямау салганда аларны сүгеп утырудан ни мәгънә? Үрнәк алырга, гыйбрәт алырга кирәк.

У.Черчильдән бервакытны: «Англиядә нигә антисемитизм юк?» — дип сораганнар. «Без аларны үзебездән акыллырак дип санамыйбыз», — дип җавап биргән ул.

Күптән түгел Мәскәүдә булдым. Менә поезд бүгенге заман Бабилына килеп керде. Тәрәзәдән карап барам. Таш диварларга зур дегет хәрефләр белән әллә ниләр язылган: «Жидам — смерть!», «Убирайтесь в Израиль!» Чү, монысы свастика түгелме соң? Куркыныч булып китте. Кемдер миннән көләргә дә мөмкин, тапкансың, янәсе, аптырар нәрсә... Бер төркем хулиганнарның куач (дегет буйый торган пумала) күтәреп йөргүеннән өркегән берәү... Кашки шулай булса иде. Ачыктан-ачык фашистик коткы таратучы партияләр бар хәзер Рәсәйдә. «Жидлар китергән демократиядән котылып авторитар режимны тергезергә кирәк», — дип мөнбәрләрдән сөйлиләр. Һәм шул партияләр законлы рәвештә теркәлә. Ә бүтән халыкларның үз милли-мәдәни ихтыяҗларын кайгырткан фиркаләре теркәлә алмый. Чөнки партияләр турындагы закон буенча бөтенрәсәй күләмендәге партияләр генә яшәргә хокуклы.

Димәк, мондый фашистик идеологиянең тарафдарлары бөтен Рәсәй күләмендә таралган һәм, әлбәттә, хакимияттә дә җитәрлек...

Башта Һитлерга да, «клоун» дип, көлеп кенә караганнар.

Футбол буенча дөнья чемпионатында Рәсәй командасы

японнардан җиңелгәч, Кремль янында ук нинди чуалышлар булуын әле күпләр хәтерлидер. Йөзләрчә яшүсмер «Россия! Россия!» — дип акыра-акыра кибет тәрәзләрен ватты, машиналарны яндырды. Корбаннар да булды. Бу мәһшәрне телевизордан күреп кемнең генә эчене салкын йөгермәде икән? Бәлки, кулларын уып сөенеп утыручылар да булгандыр. Ә мин курыктым. Куркам... Бу толпаны бит теләсә кемгә өстереп була. Кулларына идеологик күсәк тоттырганнар инде.

Сабый баланы — таҗик булганы өчен! — үтерүчеләрне кем дип атарга?

Боларга дошман кирәк... Ул дошман да күптән ачыкланган. Хәзер һәр җирдән ислам фундаменталистларын, мөселман террористларын эзлиләр. Халыкара вазгыять тә моның өчен бик уңайлы.

Ләкин Татарстанда яки Башкортстанда террорчылар юк. Чукынып китәсеңмени, юк алар! Ләкин бит төрле дини, милли оешмалар бар, аларның бүтән мөселман илләре белән бәйләнешләре булуы мөмкин. Шул илләрдән акча алып, террорчылар әзерләп ятмыйлармы икән? Узган гасыр башындагы «панисламизм», «пантюркизм» дигән карачкылар урыс аңының тузанлы почмакларыннан янә тартып чыгарыла. Кайбер дин әһелләренең чыгышлары әлеге учакка ут өсти. Берничә ел элек мөфти Тәлгат Таҗетдин мөфти Равил Гайнетдинне унике-ундүрт яшьлек балаларны укырга җибәргән өчен Согуд Гарәбстанындагы фондлардан әллә ничә миллион доллар акча алып ятуда гаепләде. Бу турыда «Совершенно секретно» газетасы (№ 6, 2002) язып чыкты. Мәкалә «Терро-филантропия» дип атала. Гәҗит Тәлгат мөфтинең үзеннән дә гаеп тапты. Аның диния нәзарәте дә балаларны Мисырга, Иорданиягә, Төркиягә һәм Мароккога җибәрә икән. Ул илләр дә радикаль исламны таратып яталар, имеш.

Мөселман илләрендәге вакыфларның, җәмгыяте хәйриянең безнең җәмәгатьләргә ярдәм итүе Мәскәүнең эчен пошыра. Бу аңлашыла да. Татар баласы урысча гына белем алырга, урыс мәктәбендә православие сеңдерелеп, тәмам шул массада эреп бетәргә тиеш.

Гәҗит безнең илдә бик актив эшчәнлек алып барган дини оешмаларның исемлеген дә китерә. Менә алар: «Төрки дөньяны өйрәнү фонды», «Төрки яшьләрнең халыкара берлеге», «Фәтхулла оҗагы» фонды, «Толеранс» фонды, «Серхат» оешмасы, «Уфук» мәгариф фонды, «Нурҗылар» оешмасы. Баштагы ике оешмадан башка минем боларның берсе турында да ишеткәнем юк. Исемнәре дә мәгълүм булмагач, нинди актив эшчәнлек алып баралар икән соң алар?

Бөтен бәлане ислам диненә сылтау гадәте Мәскәү авторларының шулкадәр башын бутаган ки, алар дөньяви оешмаларны да үзләренең кара исемлекләренә керткәннәр. Мәсәлән, «Халыкара төрки яшьләр берлеге»нә чуаш яшьләр союзы да, гагаузларның яшьләр оешмасы да керә. Белгәнебезчә, бу халыклар христиан динен тота. Авторга төрки яшьләрнең үзара аралашуы ошамый. Ул алардан корткычлык, крамола эзли: «Объединения вряд ли только в культурном смысле. Скорее всего подразумевается предоставление независимости тем республикам России, где «доминирует тюркское население», — дип үзенең фаразын да белдерә. Мин, әлбәттә, мөстәкыйльлеккә омтылуда бернинди дә гаеп күрмим, үзен хөрмәт иткән һәр халык бәйсезлеккә омтылырга тиеш. Әмма «...яшьләр берлеге»нең программасында мондый маддә юк бит. Ә гәҗитнең исә бу оешманы Рәсәй бөтенлеге өчен куркыныч бер карачкы итеп күрсәтәсе килә.

«Төрки дөньяны өйрәнү фонды» дигәне төрекчә «Turk dunyasl arastlrmalarl waklfl» була инде. Бу оешма турында мин яхшы беләм. 1994 елның башында вакыф житәкчесе профессор Туран Язган чакыруы буенча төрек мәдәнияте белән танышыр өчен ай ярым Истанбулда яшәп тә алган идем. Анда төрек телен өйрәтү курслары бар. Аңа төрле илләрдән төрки халык вәкилләрен чакыралар. Шулай ук һәркем үз халкының гореф-гадәте белән дә таныштыра. Төрек мәдәниятеннән күпмедер хәбәрдарлык аласың. Безнең белән бергә Алтай түркләре, тувалар, гагаузлар бар иде. Тувалар Будда динендә. Мин монда ураза аена туры килдем. Вакыф кунакларының күбесе, хәтта үзбәк малайлары да ураза тотмый һәм моңа беркем дә кырын карамый иде. Төрекләр үзләре дә бик дини халык түгел сыман тәэсир калды. Әллә вакыф тирәсендәгеләр генә шундый идеме?

Шунысын да онытмаска кирәк: ислам дине төрки мәдәниятнең асыл нигез ташын тәшкил итә.

Төрки халыкларны төрек культурасы белән таныштыру да бик табигый эш югыйсә. Моңардан нииндидер ислам радикализмы эзләү үзе үк көлке тоела.

Беркөнне без Косоводан килгән укытучылар белән очраштык. Ул вакытта әле Югославиянең бу өлкәсендә сугыш бара иде. Укытучылар зарландылар да зарландылар. Дәреслек житми, эш хакы түбән — айга сигез марка... Очрашуда гел бер уй миемне борып торды — кайда ишеттем соң мин мондый зарларны? Бераздан гына аңыма барып житте — Рәсәй төбәкләреннән Казанга жыелган татар теле укытучыларына охшаган бит болар! Бер үк төрле сүзләр, бер үк төрле зар. Күз карашларына кадәр охшаган. Алардан гажизлек

бөркелә. Хәзер инде Косово төрекләре үзгәргәндер. Алар серблардан кулларына корал тотып бәйсезлек алды.

Советлар заманындагы кебек, күрәсең, төрекләр белән безнең бөтен мәдәни бәйләнешне өзмәкче булалар. Һәм бу юнәлештә эш бара да инде.

Ислам радикализмын карачкы итеп, кайбер көчләр барлык төрки оешмаларның эшчәнлеген туктатып, хәтта төрек лицей-мәктәпләрен дә ябарга телиләр. Үзбәкстанда шундый лицейларның ябылуы турында әлеге гәҗит бик канәгатьләнеп хәбәр итә. Имеш, үзбәкләрнең иминлек комитеты 2000 елда бу мәктәпләрнең дәүләткә каршы эшчәнлеген ачыклаган да, аларны япканнар. Ягъни автор Кәримовның тоталитар хөкүмәтеннән үрнәк алырга чакыра.

«Фондларны ябуы кыен, — дип зарлана «Профи» аналитик төркеме җитәкчесе А.Собянин. — Алар «хөкүмәткә бәйсез оешмалар» кысасында эшлиләр. Документларында мәгърифәтчелек, белем бирү, халыкның әхлак сыйфатларын яхшырту кебек мәсьәләләр язылган. Әгәр мәхкәмә аша берәр төрле фондны ябу турында карар чыгарсаң, хөкүмәткә бәйсез халыкара оешмалар тавыш куптарачак. Шуңа күрә Мордовия, Татарстан, Удмуртия, Оренбург, Саратов һәм Идел буе федераль округының бүтән өлкәләрендә яшәүче татар халкы арасында радикальләшү күренешен күзаллау кыен түгел».

Татарларның зур дөньяга чыгып бүтән милләтләр белән «тел-лөгать алмашып», мәдәни бәйләнешләрдә яшәвеннән курку күптәннән килә. Урыс философы Г.Федотов 1929 елда ук болай язган: «Халыкларны тотып торучы көч — урыс мәдәнияте. Аның аша алар дөнья цивилизациясенә чыгалар. Әгәр дә Россия халыклары Мәскәүдә яисә Петербургта түгел, ә Парижда һәм Берлинда (яки Истанбулда һәм Каһирәдә. — *Р.З.*) укый башласалар, ул чакта алар безнең белән калмаячак. Урыс интеллигенциясенә авыр җаваплылык төшә...»

Радикаль ислам һәм халыкара террорчылык белән куркытуның артында безгә әллә кайчан таныш булган империячел идеология ята. Менә шуны гамәлгә ашыру өчен, күрәсең, теләсә нинди карачкыдан да чирканмыйлар. Аны әледәнәле тарих чүплегеннән күтәреп чыгып безнең алда селкетеп алалар. Селекмәсләр иде, җилкәгә төшкән «җаваплылык» авыр...

*Октябрь, 2002*

# КАРА ШИФОН, ТАШКЕНТ һәМ КАНАТСЫЗ РОМАНТИКА

Яшь чак — җүләр чак. Ниндидер маҗараларга тарасы килү, яңа җирләргә китү теләге, сәяхәт җиленең тозлы тәмен иреннәрдә тою өмете нәкъ менә бала чакта, яшүсмер чакта көчле була. Күңел каядыр алгысына.

Романтика!

Әлбәттә, яшьләрнең дә төрлесе бар. Прагматик, рационалист яшьләр хәзер аерата күптөсле. Хәер, бу миңа гына — гомер тавыннан түбән төшә башлаган кеше өчен генә шулай тоеладыр.

Җүләр романтиклар беркайчан да артык күп булмый. Ә шул хисне — яңалыкка омтылу хисен, балаларча самимилекне соңгы минуткача югалтмаучы кешеләр бөтенләй сирәк.

Тормыш җиле кага, дөмбәсли, сикәлтәле юлларда бездән ком белән бергә матур хисләр, гүзәл өметләр дә коелып кала.

Мин яшь чакта совет пропагандасы безне гел романтик булырга чакыра иде. Тайга, учак ялкыны, гитара... Бөек төзелешләр. Каядыр китәсе килә иде, шайтан алгыры!

Бетмәс-төкәнмәс кинофильмнар, маҗаралы китаплар аркасында без сугышны да тоташ романтика итеп күз алдына китерә идек. Кайсы гына малайның, Марат Казей яисә Валя Котик төсле, дошман тылына чыгып «тел» алып кайтасы килмәде икән? Чын, без алардан көнләшә идек. Нәкъ менә хәзер сугыш булмавына офтанучылар күп иде.

Ләкин белмәгәнбез — Рәсәйдә һәр буынның үз сугышы була икән.

Укылган китапларның тәэсире миндә озаграк саклангандыр — әле студент чакта да мин романтиканы каядыр читтә, мин белмәгән-күрмәгән якларда дип күз алдына китерә идем. Чөнки күз алдындагы тормыш бигрәк соры, өстәвенә ялганга корылган... Р.Стивенсон романнарындагы кебек каядыр хәзинәләр атавына китәсе, төрле куркыныч хәлләргә тарып җиңеп чыгасы килә иде.

Дөньяның ачы-төчесен күп күргән Хәсән Туфан язганча:

> Читтәге кебек тоелды
> Ямьле як һаман сиңа:
> Янәсе, Урта Иделдә
> Бармыни романтика?

...Җәйге каникул. Мин авылга китәргә әзерләнә идем бугай. Кәеф шәп чак — кесә тулы борчак. Борчак кына түгел, кесәдә байтак акча да бар. Без әле берничә көн генә элек Киров өлкәсенең Котельнич районыннан шабашкадан

кайтып кердек. Анда сыер фермасының идәнен алмаштырып шактый гына акча эшләдек.

Җәен кышлыкка түл җыю гадәте элеккеге мәдрәсә шәкертләреннән үк килә. Татар әдәбиятыннан укып беләбез: алар Акчуриннарның, Дибердиевларның киез фабрикаларында эшләгәннәр, кайсылары казакъ далаларына мулдәкә булып киткән. Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы, К.Тинчуринның кайбер хикәяләре шушы «җәйге яллар» нәтиҗәсендә туган.

Яисә без үсмер чакта яратып укыган Д.Лондон әсәрләрен генә искә төшерик. Аның романтика тулы хикәяләре асылында авторның тормыш тәҗрибәсе ята бит! Ул «алтын бизгәге» белән дә авырган яки, бераз акча эшләмәмме дип, берәр корабка диңгезче булып та ялланган...

Романтика чәчәге кешенең ялангач, шыксыз тормыш сахрасында үсеп чыга...

Әлбәттә, бу серле чәчәк шытсын өчен, кеше күңелен ниндидер шифалы сулар сугарып торырга тиештер, мөгаен...

Миңа калса, фәрештәләрнең канат очы җанына орынган булса, берәр конторада күңелсез кәгазьләргә чумып утырган клерк та тормышка романтик күзләр белән карый ала.

...Шунда бүлмәгә группадашым Ралиф килеп керде. Тулы гына гәүдәле булуына карамастан, ул кулларын селтәп бик тиз йөри. Киң тупсалы чыраендагы кечкенә көләч күзләр гадәттәгечә хәйләкәр...

Шунысын да әйтергә кирәк: без, «шабашка»га барганчы, Үзбәкстанда экспедициядә булган идек. Максатыбыз шәрекъ белән якыннанрак танышу иде, ахрысы. Чыннан да, гаҗәп матур табигатьле, бай тарихлы яклар, борынгы шәһәрләр — Ташкент, Сәмәрканд, Бохара... Күк якын — баш очында йодрык-йодрык йолдызлар, төрки тарихның гасырлар аша искән җилләре иреннәрне көйдереп алгандай була.

Шунда Ралиф белеп кайткан: Ташкентта шифон дигән материал бик дефицит, имеш. Үзбәк кызлары шул үтә күренмәле тукымадан күлмәк тегеп кияр өчен әллә ниләр бирергә ризалар икән. «Ә безнең Казанда шифон тулып ята!» — дип сүзен төгәлләде дустым.

Эшкуар!

Мин дә урынымнан сикереп тордым. «Шабашка» эшләп тапкан акча бар — башлангыч капитал... Юл уңса, кесәгә күпме акча кереп утыра! — Без, кулга каләм алып, ах та вах килеп керемне санный башладык.

Әмма мин үземнең бизнесмен талантына бер дә ышанып бетми идем. Маңгай тире белән тапкан акчаны юкка сарыф итеп кайту булмасмы?

«Өстәвенә янә бер мәртәбә Азияне күрәбез! — диде Ралиф, минем уйны сизгәндәй. — Тәвәккәл таш яра...»

Мондый сүзгә каршы килеп кара... Менә ул мин хыялланган романтика!

Башта вокзалга төшеп ике очка да билетлар алдык. Ташкентта дүрт көндә эшне бетерәбез дә, баеп, кире Казанга кайтып китәбез, янәсе.

Аннары, кибеткә кереп, бер ай дәвамында иртә таңнан кара төнгә кадәр эшләп тапкан акчага хәйран күп шифон алдык. Һәрберебезгә иллешәр метр туры килә иде шикелле. Бәясе метрына унжиде сум иде бугай.

Илдә әле бик сирәкләр генә базар мөнәсәбәтләре турында белгән заманда без шулай бизнес сукмагына аяк бастык. Хәер, «бизнес» дигән сүзнең үзен ишеткәнебез дә юк. Безнең башкарасы гамәлне гап-гади генә «спекуляция» дип атыйлар. Җинаять кодексында аның үз маддәсе дә бар иде кебек. Тотылган очракта, төрмәгә утыртмасалар да, университеттан куып чыгарачаклары көн кебек ачык иде.

«Арты кычыткан Әчтерханга киткән» дип әйтергә ярата иде бабай мәрхүм...

Ләкин эшнең алдын-артын, нинди нәтиҗәләргә китерәсен уйлап торсаң, романтика буламыни ул?

Ташкентка килеп төшкәч, без кунакханә эзләргә тотындык. Тик кайсы гына миһманханәгә бармыйбыз, буш урын юк. Ахырдан янә тимерьюлчылар кунакханәсенә кайттык. «Бәлки, ришвәт төртеп карарбыз?» — диде Ралиф. Чыннан да, акча күрсәтүгә, безне шәп кенә ике кешелек бүлмәгә урнаштырдылар. Документ та сорап тормадылар хәтта.

Икенче көнне үк Алай базарына киттек.

Әмма сәүдә эше без уйлаганча гына гади нәрсә түгел икән. Юкка гына хәзер чат саен менеджмент, маркетинг дип тел чарламыйлардыр шул. Без исә үзбәк хатыннарының милли психологиясен, зәвыгын бөтенләй искә алмаганбыз, имеш. Алар кычкырып торган төсне, аллы-гөлле киемнәрне яраталар икән. Ә безнең Казаннан алып килгән шифоныбыз кара төстә иде. Тәкъдим итүгә үк, базардагы хатыннар: «Кара икән!» — дип тауарны кире сузалар. Ташкентның бөтен базарларын әйләнеп чыкканбыздыр, валлаһи. Моннан киткәнче каһәр төшкән шифоннан котылып булмасын аңлагач, аны без бераздан үз бәясенә сатып карадык. Бүген китәсе дигән көнне без инде аны үз бәясеннән дә берничә сумга киметеп тәкъдим итә башладык.

Барыбер сатып бетереп булмады.

Китәргә берничә сәгать кала, нигәдер Ташкентның үзәк универмагына кердек. Төрле тукымалар сата торган бүлектә

әрдәнәләп шифон төргәкләре өелгән иде. Нинди генә төсләр юк. Аллы-гөлле, яшелле-сарылы, салават күпере кебекләре...

Башта без шактый озак аңгыраеп басып тордык. Аннары бер-беребезгә карап шаркылдап көлеп җибәрдек. Һич туктап булмый көлүдән!

Хәзер дә хатын-кыз өстендә шифон күлмәк күрсәм, кычкырып көләсем килә башлый. Үз-үземнән, билгеле.

Ралифтан исә көлеп булмый. Ул хәзер шактый еллар инде үз районында зур гына түрә булып утыра. Романтикага да, башкасына да үз җирендә ирешеп буласын күптән аңлаган ул. Нәкъ Хәсән Туфан әйткәнчә:

...әгәр дә
Кирәксә мәйдан сиңа,
Рәхим ит татар иленә,
Канатлы романтика!

*Ноябрь, 2002*

# ӘЛӘК

Сиксәненче еллар башында шикаятьчеләр, әләкчеләр өчен бер рәхәт вакыт булып алган иде. Өстәге төрле оешмаларга имзалы, имзасыз яуган хатларның санын-исәбен шайтан үзе дә белмәгәндер. Шулай да күбрәк Мәскәүгә язалар иде. Мәскәүнең кулы озын, янәсе, килер дә тәртип урнаштырыр...

Күз алдына китерегез, бөтен СССР күләмендә пайтәхеткә юлланган шикаятьләр агыла...

Шулай да аларның иң күбесе Татарстаннан булган, диләр... Менә бит урыс телен әйбәтләп укытуның нәтиҗәсе... Безнең агай-эне электән үк бер-берсен Мәскәүгә чагарга яраткан, әмма ул чакта җасусларның саны бермә-бер ким булган... Чөнки урыс телен яхшылап өйрәтмәгәннәр...

Кызганыч, хан заманнарында Казан морзаларының Мәскәү кенәзенә язган хатлары сакланмаган. Ә менә нугай аксөякләренеке ничектер әле дә исән-имин... Шуларны укып казаннарның да ни язганнарын белеп була. Чөнки бу «язучылар»ның чыгышлары, нәселләре бер үк. Алар Мәскәүгә тугрылык сакларга ант итәләр дә көндәшләренә зарар салу белән мактаналар. Шуның өчен бер күлмәклек һәм... кәгазь сорыйлар. Күлмәклеге аңлашыла, хәзерге җасуслар да өч тиенлек үз файдалары хакына яисә күкрәккә тага торган бер тимер кисәге өчен (шатлан, татар, аны хәзер тәре итеп

ясый башладылар) рәхәтләнеп милләт мәнфәгатен сата. Ә кәгазь нәрсәгә? Ул морзалар әлеге кәгазьләргә Мөхәммәдьярлар, Гарифбәкләр гүзәл шигырь язсын өчен борчылмаганнардыр ич. Юк, ул кәгазь аларга янәдән бетмәс-төкәнмәс әләк-ялаларын язар өчен кирәк булган.

Ә үзләре шул ук вакытта чыдам дала атларын көтү-көтү Мәскәүгә чүпрәк-чапрак бәясенә сатарга куганнар. Ул замандагы сугыш атларын хәзерге яңа буын танклар белән генә чагыштырып буладыр.

Бетәргә хөкем ителгән халыкның Аллаһ әүвәл акылын алыр, дип тикмәгә әйтмиләр шул.

Болар инде үткән эш... Бүген ишегалдына исә XXI гасыр кереп килә. Холык-фигылебез урта гасырлардагы кебек булса да, мөмкинлекләр бүтән. Җасуслык кылам дисәң, гаммәви мәгълүмат чаралары кул изәп чакырып тора... Колач киңәйде — хәзер инде бөтен милләт өстеннән, Татарстан җөмһүрияте өстеннән Мәскәүгә, урыс президентының үзенә яза башладылар. Иң әүвәл имлябызны латин хәрефләренә күчерүгә каршы Мәскәү зыялылары исеменнән хат басылып чыкты. Боларның ни сәбәпле ул әләккә кул куюлары аңлашыла, югыйсә үзләре дә, балалары да татарча язу гына түгел, сөйләшә дә белмиләр. Әлеге дә баягы тәрегә охшаган тимер кисәген селкеп кызыктырганнардыр... Әле күптән түгел шул бичара латин имлясына каршы хатны янә мөфти Т.Таҗетдин да В.Путин исеменә җибәргән. Күрәсе иде, бу дин эшлеклесенең чапан астында нинди орденнар шыпырт кына пышылдаша икән?

Махсус службаларның (элеккеге КГБ) янә ат өстендә булуын әнә шундый доносларның күбәюе үк күрсәтеп тора. Тоталитар дәүләт стукачларсыз яши алмый. Үзләре аларны информаторлар дип атыйлар бугай.

Төрмәдә дә шул ук хәл. Тик аерма шунда: стукачка биредә һич тә үз-үзен белгертергә ярамый, ә безнең аңлашылмаган демократик дәүләттә алар доносларын ачыктан-ачык гәҗиттә бастыралар һәм моны әлеге дә баягы «милләт мәнфәгате» белән аңлаталар.

Ярар, бер-беребезне «хуҗа»га чагу безнең каныбызга сеңгәндер инде. Моның белән беркемне дә шаккатырып булмый. Инде бүтәннәр — дус-иш, тугандаш яисә яхшы күрше диеп йөргәннәребез — безнең өстән, ягъни татар милләте өстеннән Мәскәүгә, аның да иң өстенә — Рәсәй президентына әләк-шикаять яза башлады.

Үз-үзен яратмаган халыкны кем яратсын?

Ләкин икенче сәбәп тә ачык — мондый әләкләрне ике куллап көтеп торучылар бар! Әле сорап та алмыйлар микән...

Әлеге дә баягы элекке Нугай урдасы җирләреннән башкорт зыялылары В.Путинга атап җибәрелгән мөрәҗәгатен укып һәркем үз-үзенә зур ачыш ясагандыр. Бу пасквильдән күренгәнчә, Рәсәйнең иң куркыныч дошманы татар булып чыга. Хәер, бу да яңалык түгел инде. Карендәшеңнең аркасына пычак кадап, «өлкән агай»га ярарга тырышу шулай ук элеккедән килә. Менә нәрсә яза алар (онытмагансыздыр, Мәскәүгә андый хатларны урысча язарга кирәк): «Мы отмечаем, что укрепление демографического потенциала башкирского народа объективно соответствует политическим интересам как Российского государства, так и русского народа, поскольку башкиры являются необходимым противовесом для развернувшейся татарской экспансии в Волго-Уральском регионе». Ягъни «татар экспансиясе»ннән котылу өчен Башкортстандагы татарларны башкорт дип теркәргә Мәскәү ярдәм итәргә тиеш. Моны бит үзләрен Кара Сакал, Салаватларның варислары дип игълан итүчеләр яза. Гомумән, Уфадагы бу эшлеклеләрне аек баштан аңлавы да кыен. Алар безне йә урысның ялчысы дип гаепли, йә урыска дошман итеп күрсәтә. Тик татарны каһәрләргә генә булсын. Кайдан килә шулкадәр нәфрәт? Югыйсә татар үлер-үлмәс мәҗрух хәлендә, төрле яктан мирасыбызны талап бетерделәр, без ул мародерларны хәтта чын исемнәре белән дә атарга кыенсынабыз...

Инде типтәрләр, мишәрләр асылда башкорт булып чыкты (мин башкорт! — Һу-һу...). Әллә соң уптым бөтен татарны башкорт итеп игълан итикме? Ике аваз өчен җан талашып яшәү туганнар эшемени... Әнә Мөдәррис Әгъләм язган ич:

Безнең яшәү — һәр көз өлгерүдә,
Һәрбер язда — яшел үләндә...
...Ә халкыбыз бөек булып калыр
башкорт дигән исем белән дә.

Тик шунысы бар: исем җисемгә дә тәэсир итә шул.

Озак та үтмәде, гәҗитләрдә В.Путинга юлланган тагын бер мөрәҗәгать басылып чыкты. Моңарга Казанның урыс культурасы җәмгыяте, нинди-дер партияләр, һәм, иң мөһиме, Святитель Гурийның православный братствосы кул куйган. Болар Татарстанда урыс теленең, урыс чиркәвенең кысрыклануына зарланалар. Татар гимназияләре күп икән дә, урыс телен һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәнүче бер генә урыс мәктәбе дә юк икән! Бу хатка кул куючы кешеләр Казандагы бөтен мәктәпләрдә (татарныкы дип аталган гимназияләрдә дә) урыс теленең өстенлек итүен белмиләр дисез мәллә?

Беләләр, әлбәттә. «Татар» дигән сүзнең яңгыравы гына да аларны чыгырдан чыгара. Җилнең кайдан исүен яхшы сизә алар — без, теге еллардагы кебек, үз исемебездән куркып, оялып яшәргә тиеш! Күпме чиркәүләрнең гөмбәзе алтынга буяла, яңа монастырьлар ачыла, ә алар татарларны православие динен кысрыклауда гаеплиләр. Хәер, монда ниятләр ераккарак төбәлгән. Православие диненең әһелләре, күрәсең, Казанны яңадан миссионерлык башкаласы итмәкче булалар. Тәмам җаһилләшкән татарны да, ниһаять, христианлаштыру аларга хәзер җиңел бурыч булып тоеладыр. Гомумән, Мәскәү түрәләре православиене совет чорындагы коммунистик идеология урынына файдаланмакчылар, ахрысы. Бөтен мәктәпләрдә православие динен укыту турындагы күрсәтмәне дә Рәсәйнең Мәгариф министрлыгыннан юкка гына бирмәгәннәр, күрәсең. Святитель Гурий братствосы да теге гасырларда нәкъ менә инородецларны чукындыру өчен пәйда була бит. Гурий үзе исә, 1555 елда Казанда епархия тәшкил ителгәч, Явыз Иван тарафыннан бирегә архиепископ итеп билгеләнә. Безнең илдә татарларны көчләп чукындыруны башлап җибәргән кеше нәкъ менә шул Гурий инде. Аңа чикләнмәгән дөньяви хокуклар тапшырыла. Ул, шуннан файдаланып, яхшы җирләрдән мөселманнарны куа, яңадан-яңа монастырьларга, чиркәүләргә нигез сала. Шуңа күрә әлеге мөрәҗәгатьнең астында Гурий братствосының имзасы булу күп нәрсә турында сөйли.

Югыйсә алар элекке заманнарда җирле халыкка иксезчиксез җәбер китергәннәре өчен кичерү, ярлыкау сорарга тиешләр иде.

Әнә Рум папасы католиклар чиркәве исеменнән Аурупадагы инквизиция өчен дә гафу үтенә, гарәпләрдән тәре походлары ясаганга да ярлыкау сорый. Ә бит болар Казан ауганчыга кадәр берничә гасыр элек булган хәлләр...

Тәүбәгә килмәгән халык үзе дә бәхетле була алмый. Тик ул бит үз бәхетсезлеген чит халыкларга да көчләп тага!

Гомумән, бу мөрәҗәгать доносның классик үрнәгедер, мөгаен. Менә тагын бер мисал: «С 24 октября зрителям (телевидение тарафыннан. — *Р.З.*) предлагается письменно обращаться к президенту России — требованием остановить войну в Чечне. Сейчас этот сепаратистский призыв, совпадающий с требованием террористов, транслируется постоянно в виде рекламного ролика».

Димәк, сугыш кирәкми, дип авыз ачсаң, син террористлар тегерменәнә су коючы буласың? Менә шушы юлларда мөрәҗәгать авторларының чын йөзе ачыла да инде.

Җыеп әйткәндә, бу доносның төбендә безнең милли

дәүләтчелекне юкка чыгару теләге ята. Мәскәү тарафыннан бездәге шундый карагруһ көчләрне кымшандырырлык өметле ишарәләр ясала да инде.

Ә безгә нинди юлны сайларга соң? Без яхшы, без күркәм, без сиңа тугърылыклы дип күз яше коеп, Мәскәүне ышандырырга азапланырбыз, бәлки?

Беренчедән, үзләре үк әйткәнчә, Мәскәү күз яшьләренә ышанмый.

Икенчедән, Җыраучы Җәкәү XIX гасырда ук болай язган:

Тор гадел,
Йөр шиксез,
Бул изге,
Кыл яхшы,
Үйла туры,
Сөйләш чын, —
Буяр әләк!

*Декабрь, 2002*

## ИСЕМЕМНЕ КЕМНӘР КУШКАН...

Исемнең җисемгә муаффәкате бик матлуб вә могътәбәр бер эштер.

*Г.Тукай*

Баязит улым мәктәптә укый башлагач, шәрикътәшләренең исемнәре белән кызыксындым. Ул исемнәр бакчасында Алиналар, Аэлиталар, Анжеликалар һәм һаман шул Робертлар, Альбертлар... Ата-анасының нинди кош икәнен баласының исеменә карап белеп булган кебек, шул ук исемнәр милләтнең дә асыл җисемен ачып сала. Безнең татарның күндәмлеге, аумакайлыгы, яраклашучан холкы, кайсы милләт арасында яшәсә, шуңа әверелү гадәте турында күп язылды инде. Аның шул сыйфатлары балаларга исем кушуда аеруча ачык күренә. Нинди генә исемнәр юк бездә! Кимнар, Вилләр, Эльслар, Мэльслар... Элек коммунистик идеология белән бәйле исемнәр тикмәгә генә таралмаган бит, алар безнең халыкның урыстан да узып коммунизм дигән оҗмахта җайлырак, уңайлырак урын алып калырга теләвен күрсәтә. Моның өчен, әлбәттә, кызылның үзеннән дә кызылрак, урысның үзеннән дә урысрак булырга кирәк. Уларына Иван дип куштырган татарларны да беләм мин...

Профессор Камил Фасеев сөйләгән бер вакыйга истә калган. Алтмышынчы елларда ул, зур гына түрә булган чагында, бер авылга барып төшә. Тамак ялгарга дип бер өйгә алып керәләр. Хуҗаларның яңа гына балалары туган икән. Әни кеше — укытучы, аталары — колхоз идарәсе тирәсендә болгана. «Нинди исем куштыгыз соң?» — дигән сорауга, укытучы хатын горурлык белән: «Травиата!» — ди. «Мәгънәсен беләсезме соң?» — дигәч, ире алдында белемен янә күрсәтү форсатына сөенгән хатын мәгълүм операны телгә ала. «Анысы шулай, — ди Фасеев, — тик травиата ул җиңел холыклы хатын дигәнне аңлата бит...» Ире авыз эченнән сүгенә-сүгенә хатынын авыл советына куа. Нишлисең, укытучы! Газиз кызына гади татарның гади авызына җайлашкан исем кушмас ич. Травиата — матур яңгырый, шайтан алгыры! Мәгънәсенә килгәндә исә... аерым мизгелләрдә һәммә хатын-кызның да холкы җиңеләеп алучан...

Колак ишетмәгән исемнәр кушу бездә үткән гасырда барлыкка килгән чир генә түгел. Моңа «Исемнәремез хакында» дигән ярым җитди мәкаләсендә Тукай да игътибар иткән: «...безнең Тимер, Алтынбай, Япанчы кеби гүзәл милли исемнәремез урынына» ди ул, мәгънәсен үзләре дә белми торган гарәп исемнәре тутыралар. Нәтиҗәдә исем җисемгә туры килми. Тукай мисал да китерә: «...ава-түнә җөргән исерек татарны күргәнегез бармы? Күргәнегез булса, менә бу кеше Сәйфетдин инде, ягъни бу — диннең кылычы».

Ерак гасырларда чын төрки-татар атын ташлап, гарәп-фарсы исемнәрен кушкан булса, XX гасырда безнең халык алардан да арынып аурупа-урыс исемнәренә тиенде. Арабызда хәзер Роберт бабайлар, Венера әбиләр йөри...

Хәер, бу беркемгә дә яңалык түгел инде. Күпме язылган... Мин тагын нигә кабатлыйм соң? Тагын Тукайдан өзек китерәсем килә: «Мин бу сүзләрне без татар балаларына надан тугач ук әллә нинди истикъбалемез өчен яман фаллы вә мәшьум исемнәр тагылганына эчем пошканнан яздым».

Ә син соң үзең? — диярләр. Үз исемең дә бит татар авызына бик ятышлы түгел — Ркаил...

Нәрсә аңлата соң бу исем? Билгеле, аның мәгънәсе белән мин кечкенәдән үк кызыксындым. Әллә күпме Коръән тутырган (безнең якта берәр мәрхүмнең рухына Коръәншәрифне тулаем укып чыгуны шулай атыйлар) Миңназыйм бабай аны фәрештә исеме дип аңлаткан иде. Җәбраил бар, Микаил, ниһаять, Газраил бар, Ркаил дә булырга мөмкин ләбаса. Озак еллар мин шуңа шөкрана итеп горурланып йөрдем. Ләкин Хәсән Туфан белән очрашкач, күңелгә шик

керде. «Мондый исемне беренче тапкыр ишетәм», — диде ул. «Коръәннән!» — дип чатнатып җавап бирдем мин. Туфанның тавышы сүрән иде: «Анда очратканым булмады кебек...» «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаган, Коръәнне бик шәп белгән карт шагыйрь әйтә бит моны... (Ләкин соңрак язучы, галим Адлер Тимергалин үзенең «Миллият сүзлеге»ндә минем исемгә охшаш фәрештә исемен теркәп китә.)

Шуннан соң мин исемем мәгънәсендә сүз куертмауны кулайрак күрдем. Нәрсә аңлатса да, инде балигъ булгач бүтәнгә алмаштыру уңайсыз ич. Аннары яңгырашы да әйбәт, истә кала. Японнар тикмәгә генә «Исем — уңышның яртысы» димәгәннәрдер.

Шунысы да мәгълүм булсын: миңа бу исемне әти яшьли үлгән энесе истәлегенә кушкан. Ягъни Зәйдулла бабай аны үзенең утызынчы еллар уртасында туган оныгына тәгаенләгән булган. Беренче оныгына да (минем әтигә) Рафаил дигән исемне ул куйган... Ул елларда мулла-мунтагай токымнарының, зыялыларның, совет властена ярарга тырышып, балаларына аурупачыл исем кушулары безгә мәгълүм. Мәсәлән, безнең авыл мулласының шул вакытларда туган оныклары Альберт, Радик, Альба исемнәрен йөртә. Ә Рафаил исеме татарда бигрәк тә киң тарала. Шунысы кызык: бу исемне үз баласына беренче кушучы кеше шагыйрь Сәгыйть Рәми икән! Әлеге вакыйга инкыйлабка кадәр үк була һәм үз вакыты өчен нәни генә гауга да куптарып ала. 1915 елның мартында туган улына шагыйрь борынгы итальян рәссамының исемен сайлый. Әмма Уфа мулласы Абызгилдин мөселман баласына бу ят исемне кушарга теләми.

Чакырылган бүтән муллалар да мондый исем кушудан баш тарталар. Шул вакытта Уфага Петербург имамы Муса Биги килгән була. Модернист имам әлеге исемдә бернинди гөнаһ та күрми. Рафаил С.Рәми белән М.Бигинең җиңел кулыннан татар арасына таралган икән. Ф.Бәйрәмованың татар җәдидчеләренә булган дәгъвасында күпмедер хаклык та бар, күрәсең...

Тик С.Рәми улы Рафаилнең гомере генә озын булмый, җиде яшендә тифтан үлеп китә. Икенче улына инде шагыйрь Рәми дип ерак бабасының исемен куша.

...Исемемнең шушы тарихын сөйләгәч, Марсель Галиев әйтеп куйды: «Синең исемең — Рабоче-крестьянская армия имени Ленина дигән атаманың аббревиатурасы булырга тиеш». Монысы инде миңа бөтенләй ошамады. Беренчедән, 1937 елда советка каршы коткы таратуда гаепләнеп төрмәгә ябылган, шунда һәлак булган Зәйдулла бабам андый мәгънәсез исем кушмас. Икенчедән, Кызыл Армия беркайчан да

Ленин исемендә булмаган, аны РККА, ягъни Рабоче-крестьянская Красная Армия дип йөрткәннәр.

Бәлки, беренче оныгына рәссам исеме биргәч, икенче оныгын бабам Рокуэл Кент хөрмәтенә бераз үзгәртеп Ркаил дип атагандыр?

Исемнәр белгече Гомәр Саттар үзенең мәгълүм китабында минем исемне французча Рокайл — энҗе кабырчыгы мәгънәсендә аңлата.

Менә бит, серле исемгә лаек булу — үзе бер байлык ул. Атаклы язучыбыз Нурихан Фәттахның исә фаразы бөтенләй ерак чорларга алып китә. «Шәҗәрә» исемле китабында (ТКН, 1990, 299 б.) ул болай яза: «Соңгы елларда ил иҗекләре катнашында ясалган яңа бер исем еш телгә алына башлады. Ул да булса, Ркаил. Мондый исемне минем әле беркайчан да ишеткәнем юк иде. «Нинди исем бу? Каян алынган?» — дип сорагач, яшь шагыйрь Ркаил Зәйдуллин «Коръәннән» дип җавап бирде. Коръәндә андый сүз бар микән — әйтә алмыйм. Әмма әлеге сүзне «река» һәм «ил» сүзләренә таркатсак, урысча һәм татарча «елга» барлыкка киләчәгенә иманым камил». Ягъни бу исем борынгы Мисырга ук барып тоташа, имеш.

Һәрхәлдә, монысы М.Галиев фаразына караганда минем күңелемә ныграк хуш килде.

Сибгат Хәким кайчагында миңа, шаяртып, Ркацители дип эндәшә иде. Хәзер инде, шактый мул тәҗрибә туплагач, кайберәүләр Аракаил дип тә зурлыйлар. Бәлки, миңа исемне алмаштырырга да вакыт җиткәндер?

Югыйсә исем белән кешенең холык-фигыле, гамәле арасында нииндидер күренмәс бәйләнеш булуы хакында психологлар да язалар. Борынгылар исем кушуны юкка гына бәйрәмгә, тантанага санамаганнардыр. Исемнең тылсымлы көчен алар яхшы белгән. Мәсәлән, борын заманда төрки халыкларда бала озак авырса, аның исемен алмаштырганнар. Шулай итеп чирне адаштырабыз дип уйлаганнар.

Татарның асылына ят исемнәр кушу — шул ук чир түгелме соң? Безгә бу чирне ничек тә адаштырырга иде дә... Мәсәлән, мин студент чагында ук Венер Якупов дигән егетне белә идем. Хәзер ул Вәлиулла хәзрәт Ягъкуп... Исеме җисеменә таман. Юкса Венер исемле кеше ничек хәзрәт була алсын...

Сүзләрнең бөтенләй без күрмәгән мәгънәсен ача торган Батулла бар бит әле! Ул үзенең бер китабын бүләк итеп миңа болай язып биргән: «Ркаил! Синең исемең саф үзебезчә. Ырык (ыруг), аел (көмеш яисә алтын пәрәшкә), ягъ-

ни ай кебек елкылдап торучы затлы аел. Икесен бергә кушкач «Ркаил» килеп чыга, ягъни ыруг (милләтнең) аелы!»

Бу фараз миңа тагын да күбрәк ошады.

Бүтән фикерләр булса, мин кабул итәргә әзер. Тик Марсель Галиев кебек тузга язмаган гипотезалар гына тәкъдим итмәгез.

Сүземне Тукай белән башладым, аның белән тәмамлыйм: «Аллаһы Тәгалә исемемезне, җисемемезне вә рухымызны ислах әйләсен».

*Февраль, 2003*

## ӘБДЕЛМӘН ҺӘМ МАГНИЦКИЙ

Бу исемне безнең якта әлегә кадәр хәтерлиләр. Гаҗәп, әмма хакыйкать — халык тискәре каһарманнарны ныграк хәтерендә саклый. Әбделмән дә, Шәкүр карактан кала, безнең төбәктә иң тирән эз калдырган кеше булгандыр, мөгаен. Яшь чакта хәтерлим, картлар авыз суы корытып аның турында төрле риваятьләр сөйлиләр. Имеш, Әбделмән тирә-якта данлыклы купец булган, аның белән губернатор үзе дә ирексездән бүреген салып күрешә икән. Имеш, ул ниндидер сугышта батырлык күрсәтеп, ак патша аны иксез-чиксез җирләр белән бүләкләгән. Бу сүзләрдә хаклык та булгандыр: авылыбыздан ерак та түгел бер урманны әлегә кадәр «Әбделмән утары» дип атыйлар. Күршедәге Урман асты Чурачыгы дигән чуаш авылын да аңарда крепостнойлыкта булган, дип сөйлиләр иде. Шул чуашларны туган авылы Шыгырданга алып килеп, ул ничәнчедер мәчет тә салдырган, имеш. Булыр да, Шыгырданда инкыйлабка кадәр җиде мәчет эшләгән. Ләкин Әбделмәнне иң данга күмгән шөгыле ялган акча ясау булган... Шуның аркасында аны соңрак Себергә дә сөргәннәр.

Әйе, халык хәтеренә Әбделмәннең исеме нык уелып калган. Үсә төшкәч, мин аның турында бәет барлыгын да белдем. Хәер, ул бәет түгел икән, чөнки әлеге әсәр «Татар халык авыз иҗаты» сериясенең «Тарихи җырлар» китабына кергән. Аның үзенең көе дә бар, аны миңа күренекле фольклорчыбыз Флора Әхмәтова көйләп тә күрсәтте. Бу үзенчәлекле көйне ул Себердән отып кайткан.

Күрәсең, Әбделмән Себердә дә Әбделмән булып калгандыр.

Әмма бу җыр бигрәк тә Сембер, Нижгар, Пенза, Сарытау якларында таралган. Монысын мин шул китаптан укып белдем.

Әбделмән куписның тройка аты,
Шыгырдан илләрендә җигәргә;
Унике пот ярым кәгазь акчам иде,
Алла насыйп итмәде биләргә.

Әбделмән куписны бик бай диләр,
Алтмыш таш тартадыр тирмәне;
Үзе кешегә яхшылык итмәгәнгә,
Үзе дә яхшылыгын күрмәде.

Бу юлларны укыгач, минем күз алдына тагын балачагымның ак сакаллы картлары килә. Менә алар урамда бүрәнә өстенә тезелеп утырганнар, мин шулар тирәсендә ышкылам. Шуңа күрә инде миңа күрше-тирә малайлар «бабай» дип кушамат та тагып өлгергәннәр иде.

— Аның акча ясау станогы ничектер капкасына бәйле булган икән, — дип, Зиннәтулла бабам сүзне дәвам итә. — Капка ачылып ябылган саен, итәккә бер кәгазь акча килеп төшә...

Калганнар шаккатып тел шартлата.

Әбделмәнне хөкем итүче юк, нинди гаярь булган бит: түрәләрне, димәк, урысларны төп башына утырткан.

Әлеге кеше, шулай итеп, минем күңелгә әкият каһарманы сыманрак булып кереп калды.

Ә чынбарлыкта кайсы замандарак яшәде икән соң ул? Белгечләр әйтүенчә, Шыгырданга Курмыш ягындагы Маклак авылыннан килгән йомышлы татарлар XVII гасыр ахырларында нигез салалар. Димәк, Әбделмән шуннан соңрак яшәгән булып чыга.

Фамилиясен, нәсел-нәсәбен дә белмәгәч, бу кеше минем өчен бер сер булып калды.

Һәм күптән түгел генә мин шушы иске таныш белән очраштым бит! «Москва» журналында (№ 12, 2001) М.Магницкий турында мәкалә укып утырганда «купец-татарин Абдулмень Еремеев» дигән сүзләргә килеп төртелгәч, шатлыгымнан көлеп җибәрдем, валлаһи. Мәгълүм булганча, Магницкий — безнең Казан тарихында билгеле шәхес. 1819 елда ул Казан мәгариф округының попечителе булып билгеләнә. Шул ук елда Александр Беренчегә җибәргән тәкъдиме белән мәшһүр: «Казанский университет по непреложной справедливости и по всей строгости прав подлежит уничтожению».

Е.Евтушенко үзенең «Казан университеты» дигән поэмасында аңа бер бүлек багышлаган. Анда мондый юллар да бар:

Царь на Руси не так уж страшен, —
Страшнее царские царьки.
И, метуясь в охранном раже,
Зверел Магницкий от тоски.

Хәер, әлеге хакыйкать бер Магницкийга гына кагылмый бугай.

Рәсәйнең менә шушы атаклы кешесе белән татар Әбделмәннең юлы ничек кисешә соң?

Хикмәт шунда: Казанга килергә ике ел кала Магницкий Сембергә губернатор итеп билгеләнә. Аңарчы да ул зур урыннар биләгән, фельдмаршал А.Суворовның секретаре булган, Парижда Рәсәй илчесе булып эшләгән, анда Наполеон белән аралашкан. Хәер, Магницкийның гомер юлын сөйләү монда безнең максат түгел. Менә ул 1817 елның июнендә Сембергә губернатор буларак килеп төшә. Беренче эш көнен урындагы түрәләрне кабул итү белән башлый. Бу күренешне күз алдына китерәсеңдер, укучым? Ярдәм йөзеннән Магницкийның үз сүзләрен терким: «увидел такую коллекцию, какой сроду не видывал: точно четвероногие стали на задние лапы и надели ошейники. На всех лицах были видны пошлость и страх».

Әйе, берни дә үзгәрмәгән...

Магницкий шушы түрәләргә бик үзенчәлекле сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Господа, строгим к вам быть нельзя, и не буду убеждать вас не брать взяток, потому что это противно вашей натуре, но скажу вам одно: берите, но не дерите».

Рәсәйне әйбәт белгән губернатор! Бүген нәни генә кәнәфие булган һәрбер кемсә күзеңә карап ришвәт өмет иткәндә, өстәге түрәләрдән мондый сүзне ачыктан-ачык кем генә әйтә алыр икән? Ришвәт хәзер Рәсәй яшәешенең асылын тәшкил итә. Бу хәлне инде яшереп торучы да юк. Гади кешегә «дерут!» дип урамга чыгып сөрән саласы гына калды...

Түрәләр чыгып киткәч, ишекне тибеп ачып (урысча «без доклада»!), яңа губернатор янына татар сәүдәгәре Әбделмән Еремеев килеп керә. Ул күп сөйләнеп тормыйча гына Магницкийның өстәленә бер төенчек китереп сала. «Сез галиҗәнапларга нәни генә бүләк, — ди. — Егерме мең сум гына. Җүнле булсаң, ел саен бишәр мең китереп торырмын. Байлыгың юк, жалуниең кечкенә, ә чыгымнар күп; шушы нәни генә бүләкне олы итеп кабул кыл».

Магницкийның, әлбәттә, җен ачуы чыга. Кара син, татар башы белән губернаторга шундый тәкъдим ясасын әле!

Ул Әбделмәнне кабинетыннан куып чыгара. Акчасын

алып кала тагын, аны мохтаҗлар һәм ятимнәр файдасына тапшыра.

Шуннан соң Әбделмәннең өендә тентү үткәрәләр: анда 300 мең ялган акча табыла! Ул заман өчен күз күрмәгән сумма. Ләкин акча ясау станогын таба алмыйлар. Бер чиновник Әбделмәнне кисәтеп өлгергән икән, шуның өчен аңардан йөз сумга да тиенгән. Түшәк эченнән Петербург һәм Мәскәүнең зур түрәләре тарафыннан Әбделмәнгә язылган хатлар килеп чыга. Алар анда җибәрелгән акчалар өчен Шыгырдан татарына рәхмәт яудыралар.

Боларның барысын да Магницкий эчке эшләр министрына тапшыра. Әбделмәнне төрмәгә ябалар.

Әбделмән куписның аргамагы
Олы юлкайларда юргалый;
Әбделмән купистан допрос алганда
Губернатор башын боргалый.

Ә без халык авыз иҗатына хыял җимеше итебрәк кенә карарга күнеккәнбез... Югыйсә бу җырның һәр юлында тарихи чынбарлык икән ләбаса:

Таштан салдырдым мин ак мәчет,
Шыгырдан иленә дан өчен;
Шыгырдан халкына әйтә дә узыгыз:
Коткарсыннар Алла хак өчен.

Төрмәдә дә Әбделмән тиз генә бирешергә уйламый. Петербургка шикаятьләр яудыра, Магницкийны гаепли: «Этот человек самый опасный, замышляющий зло против целой России».

Әбделмәнне ничек хаклы димисең: ришвәткә каршы көрәшү Рәсәйнең асылына кизәнү ич!

Сембер губирнасын үз кулында тотып торучы Шыгырдан татарын җиңүе белән Магницкий гомере буе горурланган, күрәсең. П.Т.Морозовның «Мое знакомство с М.Л.Магницким» (М., 1877) дигән китабында шушы вакыйгага җиде бит багышланган.

Магницкийның «куркыныч» кеше булуын тиз аңлыйлар. Ике елдан соң ул урыныннан китә. Үзенең язуы буенча, ул китәсен ишеткәч, чиновниклар шатлыктан Сембердәге бөтен шампан шәрабын эчеп бетерәләр, Магницкийга бер шешә дә калмый.

Шулай да ул заманнар мәрхәмәтлерәк булган шул. Хәзер берәр губернатор Магницкий кебек кыланса? Кул астындагылар эт тугрылыгы күрсәтеп кырга керсәләр дә, аларның башында бөтенләй бүтән ният ятуы да мөмкин ич... Шул ниятләрнең тормышка ашуына әледән-әле шаһит булып торабыз.

Хуш, Әбделмәннең фамилиясе нигә Еремеев соң? Моңа җавап гади: Шыгырдан авылы әле XIX гасыр башында да хөкүмәт өчен керәшен булып исәпләнгән икән. «Хәзер аларның барысы да мөселман», — дип ачынып атаклы миссионер Е.Малов үзенең көндәлегенә теркәп куйган. Күрәсең, үзләрен христиан күрсәтеп, шыгырданлылар хөкүмәттән берәр төрле льгота алганнардыр. Аларны белгән кеше өчен бу сәер фараз түгел.

Шыгырданда бүген дә Еремеевләр шактый.

*Июнь, 2003*

# АРАКЫ

Уйлап карыйм да — безнең балачак татар тормышының бер борылыш чоры булган икән. Шуны искә төшерү дә җитә: безнең авылда «Ильич уты» 1965 елда гына яна башлый. Ленин үлеп 41 ел үткәч... Димәк, мин чыра яктысында туганмын. Бүгенге кампитрлар заманында бу бигрәк тә сәер яңгырый. Хәер, нигә аптырарга, без инде теге гасыр кешеләре. Хәзерге прикольный буынга тарихи экспонат булып та күренәбездер.

Татар яшәешенең борылышы... Без үскәндә инде татар, өлкән туганнан калышмыйча, егылып аракы эчә башлаган иде. Аракы, шәраб, сыра, керчемә (монысын балдан ясыйлар бугай)... — без шундый мохиттә шәкелләштек.

«Бомба» дип аталган шәраб алып... сигезенче сыйныфны тәмамлаганны «билгеләвебез» һаман да хәтердә әле. Ундүрт яшьлек малайлар! Өйгә кайту истә калмаган... «Банкет». Балалар олылардан күреп кылана шул. Хәер, әтинең яңакка чылтыратканы истә... Катырак дөңкергә кирәк булган югыйсә...

Элгәре авылда бер эчкече булса, аны кеше исәбенә дә кертмәгәннәр. Хәзер авызына бер тамчы капмаган кешегә шулайрак кимсетеп карыйлар.

Аракы яшәешебезнең аерылгысыз өлешенә әверелде. Бәхетне дә литрлап кына үлчисе! Ренат Харис әйтмешли:

Безнең Россиядә литр —
универсаль берәмлек.
Үлчәм дә ул, акча да ул,
Ул керү билеты да

йөрәккә, склад-мазарга,
түрә кабинетына...
Минутны, ваттны, амперны,
байтны һәм градусны
бездә литр алмаштыра!

Әлбәттә, эчүчелекнең тарихы ерак гасырларга барып тоташа. Америка тикшеренүчеләренең исбатлавынча, кеше моннан 50 мең ел элек үк исерткеч эчемлекне татып караган. Сөйләшә дә белмәгән авызы белән... Борынгы Мисырда, имеш, эчүдән баш тарткан кешеләргә мумияне күрсәтә торган булганнар: «Моңа кара да, эч, тормыштан ләззәтлән. Үлгәннән соң шундый хәлдә калырсың...»

Ләкин эчкечелек кешегә генә хас сыйфат түгел. Телевизордан бал кортларының тормышын күрсәткәннәр иде. Аларның да күпмедер проценты беткән әлкәшләр икән. Аерым чәчәк таҗларыннан әчегән ширбәт табып, шуны эчеп лыкыналар да, өйгә кайтырга чыгалар. Аларның очышын күреп гыйбрәт алмый мөмкин түгел. Кайтып җиткәннәре дә тишеккә туры килә алмыйча оя тактасына килеп бәрелә, туры килгәннәрен ишек сакчылары (ментлар!) җиргә бәреп төшерә. Болар бит тырыш, акыллы бал кортлары! Синең ише, минем ише кеше генә түгел...

Хәтта филләр елга бер шулай гүләйт итеп алалар икән. Андый чакта ул тирәдә чуалмаска кирәген аборигеннар яхшы белә...

Елъязмалардан мәгълүм, урыслар инде X гасырда ук аяк терәп эчкәннәр. Алар хәтта, шәраб эчүне тыйган өчен, мөселманлыктан да баш тарталар: «Веселие Руси есть питие».

Халыкның эчүчелеккә бирелүе урыс хөкүмәте өчен һәрвакыт файдага гына булган. Новгород кенәзлегенең Тверь кенәзе Ярослав белән 1265 елда теркәлгән шартнамәсендә үк исерткеч эчемлекләрне чиктән үткәргән өчен тамга бәясе түләтергә каралган. Шулай да Рәсәйдә эчкечелек белән һәрвакыт «көрәшеп» торганнар. Мәсәлән, Мәскәү митрополиты Фотий 1410 елда монахларны аракы сатудан һәм сүгенүдән тыя. Ләкин төштән соң үзләренә эчәргә рөхсәт итә. Монастырьларда аракы кайнату эше нык алга киткән булган, алар хәтта аракы сатуда дәүләт белән ярышканнар. Аракы сату — зур керем чыганагы.

Тиккә генәме, әле кайчан гына Татарстанда аракы бизнесы белән бәйле кешеләрне чебен урынына кырдылар. Исән калганнары милли каһарманга әверелде. Исегездәдер, Чистай аракы заводы башлыгын соңгы юлга нинди купшы мәрсияләр белән озаттылар... Икмәк заводы директорларына үлсәләр дә андый бәхет тими.

Аннары шунысы да бар — эчеп беткән халык белән идарә итүе дә җиңелрәк.

Хәер, урысның патшалары да егылганчы эчкән. Василий III патша вакытында хәтта илчеләрне кабул иткән мәҗлесләрдә дә... туйганчы лыкынганнар. Илчеләр соңыннан үз хөкүмәтләренә шикаять яза торган булганнар: «Бернинди сылтау табып та эчүдән баш тартырга ярамый». Атаклы Петр патша, сарай мәҗлесләрендә, берәрсе аек килеш чыгып таймасын дип, ишеккә каравыл куя торган була. Ул үзенең иң якын шешәдәшләре арасында 12 «кардинал»дан торган «Исерек коллегия» оештыра. Гади халык турында да онытмый «мәгърифәтле» патша: Петербург матросларына, солдатларга, верфь эшчеләренә, йөкчеләргә, төзүчеләргә көн саен түләүсез берәр чәркә аракы бирергә боера. Боларга, әлбәттә, иң начар, чистартылмаган аракы өләшкәннәр. Халык аны «патша мадерасы» дип атаган. Сталин сугыш вакытында солдатларга көн саен «фронт 100 граммы» өләшүне менә кайдан үзләштергән икән...

Татар халкы гомум рәвештә соңгы сугыштан соң эчә башлады, дип язалар. Монда фронттан көн саен 100 грамм эчәргә өйрәнеп кайткан яугирләрнең дә роле зур булгандыр.

Ә борынгы заманнарда бабаларыбызның исерткеч эчемлекләргә мөнәсәбәте нинди иде икән? Бу турыда шактый гына чыганаклар бар. Әхмәд ибн Фадланның мәгълүм язмасында болгар ханының аш мәҗлесе тасвирлана: «Аш тәмам булганнан соң, падишаһ эчәр өчен бал ширбәте сорап алды. Үзләре моны «сөҗү» диләр». Ярый, бирелә аксөякләр табыны турында сүз бара. Ә безнең ише кара халык? Язмада бу турыда да сүз бар: «Монда тагын башы хөрмә агачына охшый торган вә яфраклары башына җыелып та, башка урыннары яфраксыз булган бик озын бер агач күрдем. Моның нинди агач икәнлеген белмим. Бу агачның бер җиреннән тишәләр дә, шуның астына савыт куялар. Мәзкүр савытка тишектән балдан да ләззәтле бертөрле су агып торадыр. Бу суны күбрәк эчүчеләр хәмер эчүчеләр рәвешендә исерәләр». (Гарәпчәдән Риза Фәхреддин тәрҗемәсе.) Каен суын әчетеп исерткеч ясадылар микәнни?

Бирелә X гасыр турында сүз булды, ә хәзер 1333 елда Алтын Урдага килгән Ибне Баттута язмаларына мөрәҗәгать итик: «Әмир аш әзерләткән икән. Аш соңында вак савытлар белән ак су төсендә эчемлекләр китерделәр. Халыклар шуны эчте. Эчемлекне татып карадым — ачы тоелды, эчмәдем. Мәҗлестән чыккач, соравыма каршы: «Дукыйдан (арпа. — *Р.З.*) ясалган эчемлек, исеме — буза», — дип

җавап бирделәр. Бу халыклар, Әбү Хәнифә мәзһәбендә булганлыктан, мондый эчемлекләрне эчәләр».

Буза сүзеннән урыс телендә «бузатер», «бузить» дигән сүзләр ясалган.

Ибне Баттута Үзбәк хан урдасында узган гает бәйрәмен дә тасвирлый. Бик кызыклы күзәтүләрне калдырып, үзебез кызыксынган мәсьәләгә кагылышлы юлларны күчерәм: «Кымыз төялгән арбалар күз күреме җирдә тезелеп торалар иде. Хан әмере буенча, бу кымызны җәмәгатькә тараттылар. Миңа да бер арба китергәннәр иде, ләкин мин аны төрк күршеләремә бирдем.

Моннан соң, җомга укыр өчен, мәчеткә җыелдык. Хан килмичә озак торды. Халыкларның бәгъзеләре: «Ул җомга калдырмас, килер», — диләр, бәгъзеләре исә: «Ул исергәндер, килмәс», — диләр. Бераз вакыт үткәннән соң, ул аватүнә килеп керде вә шәрифкә (дин башлыгына. — *Р.З.*) сәлам бирде дә көлде».

Әлбәттә, биредә Үзбәк ханның ислам динен әлеге тасвирланган вакыйгадан 13 ел элек кенә кабул итүен дә онытмаска кирәк. Гомумән, бу вакытта Дәште Кыпчакта ислам дине ныгымаган була.

Соңрак муллалар үз мәхәлләләрендә эчүчелеккә каршы, хәзерге тел белән әйткәндә, көрәш җәелдереп җибәрәләр, исерткеч эчемлекләр эчүнең шәригатьтә хәрам икәнлеген һәр мөселманның аңына сеңдерергә тырышалар.

Казан ханлыгын яулап алганнан соң, урыслар татар авылларына кабаклар (аракы кибетләре, трактирлар) салырга күпме тырышмасын, мөселман җәмәгате моңа теше-тырнагы белән каршы тора. Безне аракы белән «манчу» нияте бары тик утызынчы елларда, муллаларны кырып бетергәннән соң гына тормышка аша.

Хәзер инде бигрәк тә «манчыдылар»! Кечкенә генә татар авылына килеп керәсең, — клубы юк, почтасы юк, йортлары күтәрәмгә калган, — ә үзәктә «24 часа» дигән кибет-трактир гөрләп тора. Иртәме, кичме — пей не хочу... Кайсыдыр мәрхәмәтле «бизнесмен» кан-кардәшен, начар сыйфатлы «самопал» эчереп, бакый дөньяга озату белән мәшгуль...

Хәер, мондый «бизнес» белән шөгыльләнүчеләр инкыйлабка кадәр дә булган икән. Атаклы язучыбыз Заһир Биги XIX гасыр уртасында Казан өязе Субаш авылында булган бер фаҗига турында язып калдырган: «Мәлгуньнәрнең берсе яшерен рәвештә үз өендә Субаш мөселманнарына аракы сата торган булган. Мәчеттә вәгазь вакытында имам бу эшнең хәрам, изге шәригать таләпләренә каршы килгәнлеген җәмә-

гатькә сөйләп биргән». Шуннан ни?.. Субаш кешеләренең күбесендә мулланың бу вәгазе ризасызлык тудырган. Ә «бизнесмен» исә үзенең иптәшләре белән мулла йортына ут төртә, хәзрәт үзе, хатыны, өч сабый баласы белән тереләй янып үлә. Чөнки ишек тә, тәрәзәләр дә тышкы яктан кадаклап куелган була!

Бу янгында тагын ике мәчет, туксан биш йорт, терлек-хайваннар, әллә никадәр кеше һәлак ителә.

Кайбер язучылар элекке заман татарын идеаллаштырып, ул тәүфикълы, итагатьле булган дип язарга яраталар. Янәсе, татар иң укымышлы халык иде, һәр өйдә түрдә китап торган... Көтү һәрчак көтү ул... Аны бер чиктә тоту өчен көтүче кирәк.

Әлбәттә, «көтүчеләр»нең кайберләре үзләре дә шайтан юлыннан тайпыла алмаганнар. Шайтан сидегенең котыртуы көчле — әллә нинди затлы башларны да җиңә ул... Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстафадел-әхбар...» дигән хезмәтендә шул ук унтугызынчы гасырның уртасында Борнай мәчетендә имам булып торган бер кемсә турында язып калдырган: «шактый гына көннәр Мәчеткә чыкмагач, өенә барып сораганда, «авыру» дип җавап бирәләр. Мәчетнең һәм мәхәлләнең тәрбиячесе Садыйк ибне Борнай бай аның хәлен белергә бара. Ул исергәнче шәраб эчеп, «дару эчкән идем» дип гафу үтенгән. Соңыннан бераз вакыт мәчеттә үз вазифасын үтәсә дә, Черек күл буенда исерек килеш егылып ятуы (урыс ягында! — *Р.З.*) әлеге байга ишетелеп, ат һәм арба белән хезмәтчеләрен җибәреп, өенә китереп куйганнар. Бу хәлдән соң мәхәллә халкы бердәм җыелыш ясап, мәчеткә дөрес юнәлеш бирмәве һәм вазифасына лаек булмавы белән гаепләп, аны эшеннән чыгарды».

Без бүген үзебезне мөселман санасак та, күңелебезгә иман нуры үтеп керә алмады әле. Шаять, иншалла, ислам дине халкыбызда ныгыса, вөҗүдебезне басып торган әлеге шайтан котыртуыннан да арынырбыз.

Ә болай... Җомга намазына килгән Үзбәк ханның нигә тиктомалдан көлеп җибәрүен яхшы аңлыйм мин. Миңа да бик таныш халәт...

Соңынан көлүче генә хаклы диләр түгелме соң? Ә соңыннан бары тик тарих кына көлә...

*Июль, 2003*

# УТЛЫ КИСӘҮ

Диндә ирексезләү юк.

*Коръән, 2:256*

Мәнсез кибарьлекнең чүплегенә
Хакыйкатьне мөмкинмени күмәргә?
Алладан ул иңгән икән, безгә
Шул Исламда яшәргә һәм үләргә.

*Гете*

Автобуста барганда зыялы гына ике кешенең әңгәмәсенә ирексездән колак салдым. «Ислам — агрессив дин», — дип сүзен дәвам итте берсе. Икенчесе аны җөпләде: «Әйе... Мондагы мәдрәсәләрдә дә террорчылар әзерләп ятмагайлары. Форсаттан файдаланып, ябарга кирәк барысын да...»

Мондый фикерләрне торган саен ешрак ишетергә туры килә. Әлбәттә, үзенә ят мәдәнияткә тискәре караш, аны кураллмау хисе гомер-гомергә булган. Ләкин 11 сентябрьдән соң исламга карата нәфрәт дөньякүләм колач алды. Дәүләт башлыклары, дипломатлар ислам белән террорчылык арасында уртаклык юк, дип күпме генә тәкрарласа да, «Ислам террорчылары» дигән гыйбарә монның киресен раслый. Бөтендөнья сәүдә үзәге шартлаганчы ук, Америка нәфис фильмнарында, комиксларда террорчы дип кемне сурәтләделәр? Гарәпләрне. Шулай итеп виртуаль дөнья чынбарлыкка әверелде.

Исламга каршы коткы тарату коточкыч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Билгеле, иң әүвәл традицион христиан культуралы илләрдә яшәүче мөселманнарга кыен булачак. Әнә Франциядә яулык бөркәнеп килгән өчен ике мөселман кызны мәктәптән куганнар. Бик мөһим вакыйга да түгел сыман... Әмма вөҗдан ирекен кешелекнең иң зур казанышларыннан дип санаган ил өчен бу гайре табигый вакыйга. Ә бездә? Паспортка яулык бөркәнеп төшәргә теләгән хатын-кызлар күпме мәхкәмә юлын таптады. Кемнәрнедер нигә шулкадәр ярсыта икән соң ул яулык дигәннәре?

Террорчылык белән тәңгәлләштереп, ислам диненнән ваз кичкән яшьләр турында да ишетәбез... Мөселман булу бүген җан хөрлеге дә, күпмедер кыюлык та сорый икән! Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә, исламга ышану кулда утлы кисәү тотуга бәрабәр булачак заманның киләчәген хәбәр итә...

АКШ сәясмәне С.Һантингтон ислам дөньясына каршы киң көрәш фронты җәелдерергә өнди. Хью Фицжеральд дигән тагын бер публицист исә болай яза: «Ирекле, белемле,

кин кырлы мәнфәгатьләре булган көнбатыш кешесенә мөселман дөньясында яшәү үлемгә тиң: сәнгать юк, бары тик каллиграфия белән мәчетләр генә; әлбәттә инде, сынчылык һәм кешене сурәтләү тыелган; әдәбият юк, асылда, музыка да юк (Луи Армстронг юк), Бах юк, Моцарт юк, берни дә юк, җенесләрнең тигезлеге юк, секска сәер һәм нindидер четерекле мөнәсәбәт... юмор хисенең бөтенләй булмавы».

«Иректә һәм белемле» кешегә мондый көлке дәлилләр белән бәхәсләшеп торуы да уңайсыз.

Әлеге публицист, исламның сәяси аспектларын купайтып, аны Көнбатыш цивилизациясе өчен афәткә тиңли, мөселманнарның көнбатыш илләренә күчүләрен туктатырга чакыра. Кыскасы, автор яңа тәре походына өнди.

Соңгы вакыттагы халыкара хәлгә игътибар итсәк, аның кайбер сүзләре тормышка ашуын да күрәбез. Исламны вәхши дин дип күзаллау, Аурупа өчен караңгылык дәвере булган урта гасырлардан ук килә. 1454 елда Гутенберг матбагасында Византия белән Госманлылар солтанатының көрәшен тасвирлаган китапчык басылып чыга. Шушы әсәр әдәбиятта мөселман диненә карата ялган ташкынын башлап җибәрә. Аурупа көчәеп, Шәрекъкә үзенең колониаль капшагычларын сузгач, бу сугыш мәдәни көнбатышның кыргый Шәрекъкә каршы изге көрәше, дип игълан ителә. Хәер, без үзебез дә Казан ханлыгының Рәсәй тарафыннан яулануын прогрессив күренеш дип күп еллар өйрәнмәдекмени? Югыйсә Мәскәүнең Казанга ташлануы шул ук тәре походы иде бит... Үз халкының җиңелүен, дәүләтенең җимерелүен тәрәккыять дип кабатларга мәҗбүр булудан да зуррак мәсхәрә бармы икән?

Гомумән, хәзерге тарих фәнендә ауроцентризм хакимлек итә. Дөньяның кендеге Аурупада икәнлегенә без инде ышанып бетә яздык. Нишлисең, тарихны җиңүчеләр яза. Без исә... заманында бабаларыбызның дөньяны тетрәтүләрен инкяр итмәсәк тә, аларның мәдәният мәсьәләсендә Аурупа халкыннан шактый ук түбән баскычта торуларын шик астына алмадык. Ә югыйсә хакыйкать бит: заманының техник казанышларына ия булмасаң, кылыч болгап кына таш диварлы кальгаларны яулап булмый...

Егерме еллар элек башкорт язучысы Яныбай Хамматовның «Төньяк Амурлары» дигән романын укыган идем. Роман урыс-француз сугышында катнашкан башкорт яугирләре хакында... Шунысын да әйтергә кирәк: «башкорт» исеме белән бу сугышта татар (мишәр) полклары да катнаша. «Француз сугышы бәете»н исегезгә төшерегез. Тик нигәдер тарихыбызның бу сәхифәсенә тарихчыларыбыз игътибар итмәгән тикшеренүләр юк, әлеге вакыйгалар язучы-

ларның да күз уңыннан төшеп калган... Башкорт язучысы, татар сүзен телгә алмаса да, шул заманны тасвирлый. Бер бүлектә башкортларның бөек алман шагыйре Гете өенә кунакка килүе сурәтләнә. Башкортларның җитәкчесе К.Илмурзинның Гете белән фәһемле әңгәмәсен укыгач, көлеп җибәрүем исемдә... Янәсе, кәкре аяклы яугир һәм... Гете! Веймарда фәлсәфи гәп куерталар. Ышандырмый, шайтан алгыры...

Тик соңрак, Гетеның иҗаты белән ныграк танышкач, мондый очрашуның чыннан да булганлыгын белдем. Ант әгәр, Гетеның бер хатын (5.1.1814) укыганда йөземә кызыллык йөгерде. «Пәйгамбәрлек турында сөйләгәндә, шуны әйтергә була: элек пәйгамбәрләргә авыз ачарга да рөхсәт ителмәгән нәрсәләр бүген инде гамәлгә ашты. Безнең протестант гимназиясендә намазга чакырырлар һәм Коръәннең сурәләрен укырлар, дип берничә ел элек кенә кем фаразларга җөрьәт итәр иде. Ләкин бу хәл булды, һәм без башкортлар намаз укыганда шунда идек, муллаларын күрдек, театрда аларның кенәзләрен сәламләдек. Мине аерым хөрмәтләп, алар миңа ук-җәя бүләк иттеләр, мин аны камин өстенә элеп куйдым. Ә безнең кайбер дини хатын-кызларыбыз китапханәдән Коръәннең тәрҗемәсен сораттылар».

Хатын-кызлар гына түгел, Гете үзе дә ислам дине белән кызыксына башлый. Тора-бара шул кызыксыну мондый нәтиҗәләргә китерә: «Үзебезне рухландыру өчен нинди генә шәкел сайласак та, без барыбыз да Исламда яшибез» (Адель Шопенгауэрга хат, 1831). Ә 1820 елда Цельтерга язган хатында ул болай ди: «Шулай итеп, без исламда калырга тиеш (ягъни Аллаһ иркенә тулысынча буйсынуда)... Шушы сүзгә мин берни дә өсти алмыйм».

Гете дигәч, без аның «Фауст» әсәрен искә төшерәбез... Яисә «Инде Вертер язылган»... Бөек шагыйрь турында язучылар аның дини карашларын читләтеп үтәләр. Германиянең мәдәни символына әверелгән кеше ничек ислам диненә өстенлек бирә алсын? Ә менә шәех Габделкадыйр әл-Мурабит, 1995 елда Веймарда Гетеның язма мирасын өйрәнгәннән соң, аны мөселман дип танып, фәтва игълан иткән.

Бөек фикер ияләре арасында Гете гына мондый карашка ия булмаган. «Урыс революциясе көзгесе» дип, мәктәптә безнең башларга тукылган Лев Толстойны хәтерлик әле. Аның дини карашлары турында язганда, чиркәү тарафыннан чыгарылган анафеманы телгә алырга яраталар. Әмма Толстойның ислам дине белән кызыксынуы күләгәдәрәк кала. Әдипнең күп кенә мөселманнар белән хат алышуы да мәгълүм (хосусән, Гайнан Вәиси белән). Әлеге хатларда Толстойның ислам диненә мөнәсәбәте бик ачык күренә. 1909 елда

Елена Векилова дигән хатын олуг әдиптән киңәш өметләнеп хат юллый. Аның ике улы бар икән, берсе Петербургта Технология институтында, икенчесе Мәскәүдә хәрби училищеда укый. Шулар православие диненнән ислам диненә күчәргә аналарыннан рөхсәт сорыйлар. Толстой болай дип җавап бирә: «Мөселманлыкка православиегә караганда өстенлек бирү мәсьәләсендә, аеруча сезнең улларыгызның игелекле дәлилләрен искә алганда, мин чын күңелдән мондый күчешкә теләктәшлек кенә итә алам. Әйтүе ничек кенә сәер булмасын, миндә, христиан идеалын, асыл мәгънәдәге христиан тәгълиматын барыннан да өстен күргән кешедә, үзенең тышкы шәкеле буенча мөселманлыкның чиркәү православиесеннән чагыштыргысыз дәрәҗәдә югары булуы бернинди дә шик уятмый. Әгәр дә кешегә ике генә юл күрсәтелсә: чиркәү православиесендә калыргамы яисә мөселманлыктамы, һәр акылы камил кеше өчен сайлауда шик булырга мөмкин түгел һәм һәркем троица, изгеләр һәм аларның сурәтләре, катмарлы богослужениесе булган катлаулы һәм аңлаешсыз дин белеме урынына бер тәгълиматны, бер Алланы һәм аның пәйгамбәрен икърар иткән мөселманлыкны сайлап алачак».

Ничек инде бу урында ислам диненә күчкән күренекле француз философы Роже Гародиның сүзләрен искә төшермисең: «Ислам Мөхәммәд пәйгамбәрнең ирке белән туган яңа дин түгел. Ислам — Аллага буйсыну ул. Коръәндә, Ибраһим — иманлыларның атасы, дип әйтелә. Муса, Гайсә, Мөхәммәд бер үк Алланың илчеләре. Алар кешеләргә һәр төрле тормышның төп канунын искә төшерәләр — Бар нәрсә белән бердәмлектә булу...

Укыган саен Коръән миңа якынрак була бара. Әйтерсең ул бүген генә язылган һәм туп-туры миңа мөрәҗәгать итә».

Һәр заманда да баскынчылар, икътисади мәнфәгатьләрне яшерер өчен, төрле идеологик чаршаулар корганнар. Яуланасы халыкны вәхшилектә гаепләп, аның динен мәсхәрәләп, җиренә корал белән аяк басканнар. Тик явызлык явызлыкны гына тудыра. Бүгенге кыл өстендә торган яшәештә мондый вазгыять аеруча куркыныч.

Ә Аллаһ сүзе безне мәрхәмәтле булырга өнди: «Әй, адәм балалары! Хактыр ки, Без сезне бер ир, бер хатын итеп яралттык. Бер-бере белән аралашсыннар дип, Сезне кавемнәр вә кабиләләргә аердык. Хактыр ки, гөнаһ кылудан курыккан кеше Аллаһ каршысында иң олы абруй казаныр». (Коръән, 49:13)

Ә иң олы гөнаһларның берсе — нахак сүз гөнаһы...

*Ноябрь, 2003*

# ИШАН КЫЗЫ

Элекке Советлар Союзына кергән төрки халыклар белән безнең мәдәни багланышларыбыз хәзер юк кимәлдә. Югыйсә үткән гасыр башында аларга татарның йогынтысы гаять зур булган. Хәзер дә Үзәк Азиядә миллионнан артык татар яши, дип әйтәләр... Ләкин андагы иҗтимагый тормышта аларның роле инде бүтән. Үз дәүләтләренә ия булган төрки кардәшләр хәзер безгә үзләре баласытыбрак карый.

Казакълар белән бәйләнешебез аерата көчле булган. Унынчы елларда хәтта «Казакъ әдәбияты мөстәкыйль булырга тиешме?» дигән сорау тирәсендә бәхәсләшеп тә алганнар. Ягъни казакъ әдәбиятының татар әдәби теле нигезендә үсеп китү мөмкинлеге дә күздә тотылган. Хәзерге башкорт әдәбияты кебек...

Мәдрәсәләрдә, бигрәк тә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә, йөзләгән казакъ яшьләре укыган. Киләчәктә бөтен казакъ шигърияте̇ндә дан казаначак Мәгъҗән Җомабай да шулар арасында була. Галимҗан Ибраһимов 1918 елда аның «Чулпан» дип аталган беренче җыентыгын Казанда Кәримовлар матбагасында нәшер итә.

Мәгъҗәннең язмышы шул чордагы бик күп милли зыялыларныкы кебек тәгәлләнә. Ул, 1929 елда милләтчелектә гаепләнеп кулга алынганнан соң, төрмә-сөргеннәр кичеп, 1938 елда атып үтерелә.

Мәгъҗән теленең сафлыгына, чын төрки аһәңнең яңгырашына шаккатасың. Хәтта татарчага тәрҗемә итү дә кирәкми, бу — Тукайлар, Дәрдемәндләр, Бабичлар теле. Юкка гына Мәгъҗән Дәрдемәндне үзенең шигырьдәге иң төп остазы дип санамаган.

1920–1922 елларда шагыйрь Кызылъяр педагогия училищесының директоры булып эшли. Шул ук вакытта монда Гөлсем Камалова дигән татар кызы да укыта.

Зыялы казакъ егете татар кызына гашыйк булмый каламы соң? Гомумән, ул елларда татар кызына өйләнү үзбәк, кыргыз, казакъ егетләре арасында зыялылык билгесе саналган... Без әлегә кадәр, әниләре татар дип, Айтматовлар, Назарбаевлар белән горурланабыз бит... Гәрчә алар үзләре татарга битараф булса да...

Хәер, Мәгъҗәннең Гөлсемгә булган хисләре самими, эчкерсез, чын йөрәктән булгандыр... Чөнки нерв җепләре зыңлап торган мәхәббәт шигырьләре тумас иде:

Кара күз, сихерле сүз, Гөлсем ханым,
Һәр җирдә үткәрсәк тә гомер таңын,
Кайвакыт күзегезгә күзем төшсә,
Уйный ла алгысынып нигә җаным?!

Кара күз, сихерле сүз, ханым Гөлсем,
Күктә кояш көлмәсен, Гөлсем көлсен!
Гөлсем — кояш, күктә акрын йөзә бел ә,
Сөйдереп көйдергәнен кайдан белсен!

Шагыйрь биредә үзенең сөйгәнен «ханым» дип атый. Димәк, Гөлсем бу вакытта инде кияүдә була. Мәгъҗәннең аңа багышланган шигырьләре шуңа күрәдер дә өметсезлек хисләре белән өртелгән. Ләкин аларда шактый ук ачык эротик күренешләр дә урын ала. Чибәр татар кызы шагыйрьнең мәхәббәтенә хәерхаһ булганмы, әллә бу «Җаным! Җаным! Тизрәк тисен түшкә түш, Күз йомулы еш-еш сулышны алып...» дигән юллар Мәгъҗән хыялы гынамы, хәзер инде гөманнарга гына кала. Мәгълүме шул: тиздән Гөлсем туган иленә кайтып китә:

Белдем бүген, мине ташлап китәсең,
Көмеш сулы Агыйделне үтәрсең.
Кара күзем, үтереп кит син мине! —
Тере килеш нигә ташлап китәсең? —

дип сызлана шагыйрь.

Гөлсем Камалова — XX гасыр башындагы татар хәятында шактый ук эз калдырган хатын-кыз.

Мәгълүм ки, 1912 елда Балканда Төркиягә каршы сугыш башланып китә. Рәсәй матбугатында шунда ук шовинистик шау-шу күтәрелә. Янәсе, болгар, серб, каратау туганнарга «төрек игосына» каршы көрәшләрендә ярдәм итәргә кирәк! Бу шау-шуга хөкүмәт тә рух өстәп, ярдәм итеп тора. Шуның нәтиҗәсендә йөзләгән урыс яшьләре Балканга китеп төрекләргә каршы сугыша башлый.

Гөлсем бу вакытта Петербургта урыс аксөякләренең кызлары укый торган Бестужев курсларында белем ала. Алар арасыннан да шактый гына урыс кызлары Болгариягә шәфкать туташлары булып китә.

Гөлсем дус кызларын җыеп ала да Төркиягә, яраланган төрек сугышчыларын дәваларга «Һилал әхмәр» («Кызыл ярым ай») җәмгыяте хозурына китәргә тәкъдим ясый. Тегеләр ризалаша. Ул вакытта урыс мәктәбендә укучылар да милли тәрбия алган була шул. Урыс матбугаты кузгаткан

карагруһ коткы аларны каршы юнәлештә тәвәккәл адым ясарга этәрә. Шулай итеп, Гөлсем Камалова, Мәрьям Паташева, Рокыя Юнысова, Мәрьям Якупова Истанбулга китеп баралар.

Шулай да кем соң ул Гөлсем Камалова? Кайсы төбәктән, кайсы нәселдән? Рәсәй пайтәхете Петербургта теләсә нинди татар кызы укый алмаган бит...

Гөлсем — мәгълүм Чистай ишаны Закир Камаловның төпчек кызы.

Гөлсемнең әнисе Фатыйманы ишан икенче хатынлыкка алганда кызга әле ундүрт яшь яңа гына тулган була. Шулай да яшь абыстай, тернәкләнеп китеп, ишанга сигез кыз, бер ул таба. Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге Фатыйма язучыбыз Атилла Расих әнисенең әтисе белән бертуган. Ә әнисе инде мәгълүм Зәйтүнә Мәүлетова — Тукайның яшерен мәхәббәте...

Ул заманнарда кыз алып, кыз бирүнең үз тәртибе, үз кагыйдәләре булган. Муллалар үзара кодалашкан, байлар үзара туганлашкан. Хәер, без соңгы елларда янә шул эзгә кайтып төштек, гәҗитләрдән министрның спикер белән, банкирның «глава» белән кодалашканын гел укып торабыз...

Мал мәхәббәттән алда йөри.

Хәер, алай дисәң, Закир ишан Фатыйманы, ятимлегенә, фәкыйрьлегенә карамастан, бер күрүдә гашыйк булып яучы җибәрә. Дөрес, кыз укымышлы нәселдән була.

Ишан кызлары берәм-берәм татарның күренекле, бай кешеләренә кияүгә чыгып бетә. Әсмасына Петербург мулласы Муса Биги өйләнә. Курсистка Гөлсем иптәш кызлары белән аларга еш барып йөри. Менә 1912 елның апрель ахырларында Бигиләргә Уфадан Габдулла Тукай килеп төшә. Бу хәбәрне ишетүгә үк Гөлсем, әлбәттә, дуслары белән апаларына йөгерә. Ләкин шагыйрь, үзенең сәер холкы аркасында, кызларның чибәрлеген бәһаләп өлгерми. Авыруга сабышкан булып, аларны кабул итми. «Беләсез бит, хатынкыз таифәсе, хосусан, пайтәхет кеби җирдә гали мәктәпләрдә укучы аурупалашкан ханымнар бик нәзакәтле һәм кешене тикшерүчән булалар», — дип, үзенең бу «кыргыйлыгын» дусларына аңлата ул.

Күргәнебезчә, казакъ шагыйре мондый комплекслардан җәфа чикмәгән.

1912 елның ноябрь көннәрендә Балкан сугышын үзенең «Вакыт» гәҗитендә сурәтләргә Оренбургтан килгән Фатыйх

Кәрими кызларны Йосыф Акчура янына алып килә. Ф.Кәрими, хәзергечә әйтсәк, хәрби журналист була. Ә бүген республика дидекемез Татарстанның берәр гәҗите яисә телевидениесе сугыш учакларына берәр хәрби журналист җибәрә алганы бармы? Без андагы хәлләрне бары тик Мәскәү объективы аша гына күрәбез. Ә ул һич тә объектив түгел...

Йосыф Акчура — «яшь төрекләр» партиясенең җитәкчеләреннән берсе, кызларны атаклы Әнвәр паша белән дә таныштыра. Бергәләп рәсемгә дә төшәләр. Дүрт атнадан «яшь төрекләр» хакимияткә килеп, Әнвәр Төркия белән идарә итә башлаячак. Татар арасында Әнвәр пашаның ул елларда исеме шулкадәр атаклы була, безнең халыкта әлеге исемнең таралып китүе нәкъ менә шушы төрек иләмәненә бәйле.

Татар кызлары гадәти шәфкать туташлары гына булмый. Бераздан Гөлсем Камалова Төрек иминлек фондына хатын-кызлардан иганә җыю кирәклеге турында тәкъдим белән чыга.

Билгеләнгән көнгә университетка Истанбулның күренекле хатын-кызлары җыела. Алар фондка үзләренең йөзек-беләзекләрен, башка кыйммәтле бизәнү әйберләрен алып киләләр. Җыелышны премьер-министрның хатыны ачып җибәрә. Фатыйма Галия ханым, Халидә Әдиб кебек мәгълүм язучылар белән бергә биредә Гөлсем Камалова да чыгыш ясый. Аның ялкынлы сүзләрен барлык төрек гәҗитләре дә диярлек бастырып илгә тараталар.

Гөлсем, күрәсең, тумыштан әйдәмән була. Менә А.Расихның билгеләмәсе: «Гөлсем апа буйчан, көчле табигатьле кеше... аерата чибәр хатын иде. Озынча йөз, сөрмәле кара эре күзләр, күкрәктән чыккан калынрак тавыш». («Ишан оныгы», ТКН, 199 б.)

Икенче Балкан сугышы Төркиянең янә бер җиңелүе белән тәмамлана. Татар кызлары илгә кайтып китә. Әлбәттә, патша охранкасы аларның кайда йөргәнен бик яхшы белгән. Кызларга югары уку йортларында юл ябыла.

Гөлсемне Сембердәге миллионер Акчуриннарның берсендә кияүдә булган Шәмсениса апасы кунакка чакыра. Милләтпәрвәр кызны кунак итәр өчен Акчуриннар зур мәҗлес җыялар.

Чибәр дә, кыю да, укымышлы да туташны күреп кем гашыйк булмас... Абдулла Акчурин Гөлсемнең кулын сорый.

Элек яшьләрне кавыштыруда җиңгиләр бик җентекле эш йөрткән. Биредә дә Шәмсенисаның кулы уйнамый калмагандыр...

Революция Акчураларның да бай оясын чәчеп ташлый. Гөлсем дә, мөгаен, шушы өермәдән качып Казагыстанга барып чыккандыр. Аның кебекләр белән ул елларда бөтен Үзәк Азия тулган була.

Совет власте елларында Гөлсем дә, аның белән бергә Төркиядә булган дус кызлары да күзгә-башка бәрелмичә генә күләгәдә яшәргә тырышалар. Мәрьям Якупова, мәсәлән, Термездан ерак түгел бер кышлакта, гаилә дә кора алмыйча, гомерен фаҗигале рәвештә тәгәлли...

Югыйсә бу кызларның тормышы үзе бер мавыктыргыч роман бит. Язылмаган роман... Инкыйлабка кадәр татар хатын-кызларының тормышы дигәндә, без һаман Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» романын искә төшерәбез. Шуның тәэсирендә туган ялгыш фикер әле дә үзен сиздереп куя: имеш, ул заманнарда татар хатын-кызлары бәхетсез, хокуксыз булган, аларны ирләр изеп, кимсетеп торган... Татар кызларының күпләп чит милләт вәкилләренә кияүгә чыгуында да әлеге әсәрнең өлеше бар, минемчә...

Бу җәһәттән Дәрдемәнднең Шәриф Камал белән бер сөйләшүе искә төшә. «Әйбәт хикәяләр язасың, Шәриф, — ди аңа шагыйрь. — Тик алар гел караңгы тормыш турында. Татар ярлы-ябагайдан гына хасил түгел». «Мин үз күргәнемне язам инде, — дип җавап бирә яшь язучы. — Бүтәнне мин белмим».

Без дә шулай түгелме: язарга азыгыбызны гел үзебезнең аяк астыннан гына эзлибез. Ә татар хәяты киң ул, бай ул.

*Ноябрь, 2003*

# КӘНИЗӘКЛӘР

Тукталышта бер таныш хатынны очраттым. Күренеп тора: аның кәефе әйбәт, йөзе балкып тора... Мине кочаклап та маташты... Димәк, сөенече бар, шуны минем белән дә уртаклашасы килә... Исәнләшергә дә онытып:

— Кичә генә Франциядән кайтып төштем, — диде ул.

Миң, әлбәттә, шаккатырга һәм соклану авазлары чыгарырга тиеш идем. Югыйсә чит илләрне урап кайткан кешеләргә күнегә башладык бугай... Сирәк-мирәк очрап тора алар безгә. Телевизордан исә бай туристларны гел күреп торабыз.

Парижның инде мин бөтен тыкрыкларын беләм бугай. Дөрес, кесәдә еш кына Мамадышка барып килерлек тә акча булмый... Акчадамыни хикмәт, гомер бер генә — бөтен мөмкинлектән файдаланып, эстетик ләззәт ала белергә кирәк. Менә хәзер дә мин таныш ханымның шатлыгында коенам. Рәхәт!

— О, Париж! Изумительный шәһәр, — ди ул. Күзләре йомыла, иреннәре җәелә.

— Сент-Женевьев-де-Буада булдыңмы? — дип сорыйм мин аңардан.

Парижда булучыларга мин гел шул сорауны бирәм. Буа сүзе күңелгә якын, күрәсең.

Тик ханым Парижны үтешли генә күреп калган икән. Ул ниндидер бер кечкенә шәһәргә туйга барган. Иң зур сөенече шул: апасының кызы французга кияүгә чыккан! Интернет аша табышканнар.

— Күпләр кияүне Америкадан эзли, үзебезнең Аурупага җитәме инде, — диде ханым. Ул инде Аурупаны үзенең Актанышы кысаларында күз алдына китерә иде.

— Бер сеңлем исә Италиядә кияүдә, — дип мактанды ул. — Анда да кереп чыктык. Изумительно!

Мин дә аның сеңелләре өчен сөенергә тиеш идем, әлбәттә. Гаҗәеп заманда яшибез шул... Өеңдә кампитр каршында утырган килеш, әллә кайлардагы аурупалардан кияү табып булсын әле!

Әлеге татар кызларын да аңлап була, бу өметсез, киләчәге анык булмаган Рәсәй эчендә җан асрауга караганда, бәхет эзләп каядыр китеп олагуың яхшы лабаса. Таныш-белеш кызлары алардан үлеп көнләшәдер, мөгаен. Чит илдән кияү табу һәркемгә дә тәтеми. Ераклардан «бәхет эзләүче» кызлар күп очракта үзләре тәвәккәлләп чикне узып чыга... Ә мөмкинлекләр күп: төрле-төрле рекламалар, белдерүләр чит илләрдәге рәхәт тормышка кызыктыра, эшкә чакыра: стриптизерша булып, официантка яисә хәтта ки фотомодель булып... Дөрес, бу атамалар һәрвакытта да бары тик бер генә һөнәрне күздә тота... Бик борынгы һөнәрне...

Чибәр-чибәр кызларыбыз, моны белгән хәлдә, бер-берсе белән ярыша-ярыша, шундый вербовка белән шөгыльләнүче агентлыкларга үзләрен тәкъдим итә.

Боларның күбесенең әти-әнисе, туганнары бар. Алар да кызларының нинди максатта сатылганлыкларын яхшы белә, мөгаен. Белмәмешкә салышалар. Чит илләрдән килгән долларларга, бәлки, тормышны рәтләп булыр?

Чит илләрдәге фәхеш йортларының тоткыннарына әверелгән кызларыбыз турында күп язылды, күп сөйләнде инде. Ләкин «стриптизерша» булып китәргә теләүчеләр моңа карап кимеми, арта гына... Ул кызлар ата-аналарының ай буе бил бөгеп алырга җыенган хезмәт хакына бер «мәхәббәт төнендә» ирешәчәкләренә ышана бит!

Әхлак тарафдарлары хәзерге заманны, милләтне шушы хурлыкка төшергән режимны сүгә. Сүгәргә була... Әмма тарихка күз салсаң, бу күренешнең безнең заманга гына хас булмавын да күрәсең...

Колониаль коллыкка төшкән халык беркайчан да мул, рәхәт яшәми. Чагыштырмача рәтле тормышка тиенсәң дә, җан хөрлеген кайдан аласың?

Читтә, каядыр офыклар артында, безгә дигән бәхет булырга тиештер ләбаса. Тәңре өчен һәркем дә бертигез. Димәк, һәркемнең кайда да булса, кайчан да булса бәхетле булырга хакы бар.

Бәлки, татар элек бәхетле булгандыр? Юкка гынамы шигырьләребезгә дала исе бәреп керә, кылганнар йөгерә, һайһулап җайдак чабып уза, меңләгән атлар өер булып хәтфә үлән утлап йөри... Ире-ек! Бәхет шул бит инде, уйласаң...

Тик борынгыларның тормышы моннан караганда гына бәхетле, хөр күренә. Шул ук күчмәләрне алыйк. Алар бит һәрвакыт барымта, карымталардан интегеп, табигать шартларына бәйле булып яшәгәннәр. Йот елларында исә ырулары белән ачлыктан кырылганнар. Чөнки төркиләрнең яшәеше мал-туарга бәйле булган. Ә йот елында исә җепшеклектән соң кинәт суытып, даланы бозлавык каплый. Тибенгедә йөргән маллар ашарларына үлән таба алмыйча аякларын суза.

Йот килүен ишетүгә үк, яһүд, әрмән сәүдәгәрләре кыпчак даласына ябырылган. Чөнки кешеләр инде, хет сабыебыз котылсын дип, балаларын юк кына бәягә коллыкка сатып җибәргәннәр.

Аларны гаепләп буламыни? Ачлык патша бернинди мәрхәмәтне дә, мәхәббәтне дә санга сукмый...

Атаклы фарсы шагыйрьләре кыпчак, болгар кызларына мәдхия укып шигырьләр язган. Ул кызлар меңә шул коллыкка сатылган кәнизәкләр була да инде. Ә без хәзер, авыз суы корытып, шул шигырьләр белән горурланабыз. Бер урысның «Сезнең кызлар әйбәт бирә» дип әйткәненә сөенгән аңгыра татар шикелле...

Бүгенге урыс матбугаты Октябрь фетнәсенә кадәрге Рәсәй тормышын бик мактап сурәтләргә ярата. Янәсе, патша вакытында халык мул яшәгән, тәртип-низам булган. Хәлбуки, рәхәт тормышта фетнә күтәрмиләр. Татарның исә аянычлы хәятын классик әдәбиятыбыздан укып беләбез. Ачлыккабөлгенлеккә төшкән халыкның кулында бердәнбер тауар калган — кызлар...

XIX гасыр ахырында, XX гасыр башында татар кызларын Урта Азиягә алып китеп сатучы махсус кешеләр пәйда була. Моның белән гадәттә әрсез карчыклар шөгыльләнгән. Тешләрен карага буяган бу әбиләр бөтен татар авылларын айкап йөргәннәр. Җылы якларда җәннәт тормышы вәгъдә итеп, салым җитмәсендә чәбәләнгән игенченең кызын юк кына бәягә алып, аларны көтүләре белән үзбәкләргә илтеп сатканнар... Кара тешле карчыклар алдамаганнар: җәннәт тормышы хур кызларына сусаган нәкъ менә шул сарт байларына тәгаенләнгән булган.

Ә «хур кызлары»н үлгәнче кимсетелүләр, хурлаулар көткән. Менә шул кәнизәклеккә сатылган кызларның бәетеннән бер өзек:

Унҗиде кыз чыгып киттек, урыннар юк ятарга,
Без мескеннәрне озаттылар базарларда сатарга.
Персиян мылтык корадыр ак куянны атарга,
И әткәем, оят кирәк газиз кызыңны сатарга.
Хайван саткан барышниктай күп кыз җыйган башыгыз,
Кемгә төшәр икән безләрнең күз яшебез?

Шигрин күне кебек кысыла барган милли хәятыбызга карыйсың да ачынасың: кемгә төшсен, үзебезгә — татарга төшкән ул күз яше...

Инде 1921 елгы ачлык вакытында меңләгән татар кызы янә шул Урта Азиягә китеп югала. Кайда алар хәзер? Токымнары, нәселләре кайда?

Татар кызлары, бүтән милләтләр чәчәк атсын өчен, алар астында тирес булды.

...Котсыз еллар артта калды кебек. Авылдан авылга ярлы татар кызларын кәнизәклеккә алып китәргә йөргән кара тешле карчыклар да бүген күренми. Алар урынына һәр йортның түрендә телевизорлар тора, гарептәге гарип матурлыкны мактый, аллы-гөлле утлар эчендәге җәннәт тормышы турындагы мифны кешенең миенә дыңгычлап тутыра. Шәһәрләрдә төрле агентлыклар безнең кызларны хур кызы итеп шул

җәннәткә чакыра. Кара тешле карчыкның төшенә дә кермәгән мөмкинлекләр!

Милләтебезнең киләчәге турында борчылабыз икән, без иң беренче нәүбәттә хатын-кызларыбыз турында кайгыртырга тиеш. Әлбәттә, без үзара тигезлеккә күптән ирештек. Хәзер татар хатын-кызы әфлисун төсендәге роба киеп ирләр белән беррәттән рельслар ташый, шпаллар күчерә. Беррәттән дию дөрес тә булмас, андый эшләрдә ирләр бик күренми дә бугай инде...

Ә ниндидер бер оешманың офисына килеп керсәң, буянган-бизәнгән ханымнар чәй эчеп гәпләшеп утыра. Барысы да диярлек марҗа... Алардан башка монда бернинди мәсьәләне дә хәл итеп булмый.

Безнең хатын-кыз физик эштән алҗып кайта, салмыш ире белән талаша, кибеткә чаба, ашарга әзерли. Ана назын татымаган балалары урамда кыл әп сара...

Хатын-кыз ир-ат белән тигез түгел. Хатын-кыз бездән гүзәлрәк, нәзакәтлерәк, милләтнең яшәеше өчен дә җаваплырак... булырга тиеш.

Хатын-кыз — гаилә учагын саклаучы, яңа, чын татар баласын тәрбияләүче булса гына милләтебез исән кала алыр...

Тик хатын-кызны тәгаен үзенә лаек урынга менгерерлек ир-атлар булуы да шарт бит...

Менә шундый уйларга бирелгәч, яңа буялган калай түбәгә кунган чыпчыкны искә төшерәсең инде. Томшыгын алса, койрыгы ябыша, койрыгын кубарса, томшыгы...

Шуңа күрә кызларыбызның бәхетне читтән эзләргә омтылуы аңлашыла да... Бүтән милләт вәкилләренә күпләп кияүгә чыгу да шул ук мөһаҗирлеккә бәрабәр бит. Рухи мөһаҗирлек...

Кискән икмәк кире ябышмый... Бездән киткәннәр беркайчан да татар тудырмый.

Аларның кайберләре рәхәт тормыш та корыр, бәлки... Ләкин үз тамырларыңнан аерылу сагышы бавырыңа боз булып утырганда нәрсә ул рәхәт тормыш?

*Апрель, 2004*

# КАРА КАРЛЫГАЧ

Ун ел элек «Төрки дөньяны өйрәнү вакыфы» чакыруы буенча ай ярым Истанбулда яшәп алган идем. Аксарайдагы борынгы мәдрәсә бинасында байтак кына төрки халыкларның вәкилләре җыелды. Казакъ язучысы Батырхан Дәрембәт белән аеруча якынаеп киттек. Бервакыт ул миңа Бирнияз дигән яшь бер казакъ шагыйренең татар кызына төшкән фаҗигале мәхәббәте турында сөйләде. Кыз Казанның мәшһүр гаиләсеннән була. Шагыйрь аны хатынлыкка сорап өйләренә бара. Ләкин кызның туганнары казакъ егетенең үтенечен кире кагалар. Бу гарьлекне күтәрә алмый шагыйрь, сөеклесе белән үз өендә яшерен һәм соңгы очрашу вакытында кызны да, үзен дә атып үтерә...

Менә шундый фаҗигале мәхәббәт... Әлеге вакыйга, әлбәттә, бөтен Казанны ду китергәндер. Әмма мин, ватанга кайткач, кайбер өлкәннәрдән күпме генә сорашсам да, мәхәббәт корбаны булган Казан кызы турында (Батырхан «мәшһүр гаиләдән» диде бит!) мәгълүмат ишетә алмадым. Хәер, узган гасырның егерме бишенче елында булган әлеге канлы мәхәббәт тарихын белүчеләрне тапмавым да табигый. Ул заманнардан соң халык башыннан күпме давыллар, фаҗигаләр узган. Һәрхәлдә, күңелне шулай юатырга калды.

Белешүем, сорашуым җитмәгән, күрәсең. Ниһаять, Дилбәр Саипова-Әхмәрованың «Салих Сәйдәшев» дигән китабы (ТКН, 2001) белән танышып утырганда бу бәхетсез кыз турындагы берничә юлга төртелдем. Әлеге Зәйнәб исемле кыз татар мәдәниятендә тирән эз калдырган шәхес — Шиһаб Әхмәровның бертуган сеңлесе булган икән!

Шиһаб Әхмәров татар мәдәнияте тарихында «Мәктәб» журналына нигез салучы буларак билгеле. «Мәктәб» — педагогика буенча беренче татар гыйльми журналы. 1913 елда дөнья күргән бу басманың беренче саны Тукайның шигырьләре белән ачыла. Бу тикмәгә генә түгелдер, чөнки Шиһаб Тукайның якын дусты да була. Алар Казанга да бер үк елда киләләр һәм «Болгар» кунакханәсенең янәшә номерларына урнашалар. Биш ел дәвам иткән әлеге дустанә мөнәсәбәтләр турында соңыннан Ш.Әхмәров тирән эчтәлекле истәлекләр язып калдыра. Тукайны соңгы тапкыр рәсемгә төшерүне дә ул оештыра.

Бөтен гомерен милләт язмышына бәйләгән бу шәхес хәзерге Чүпрәле районының Яңа Задур авылында туып үсә. Атаклы Буа мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлап Казанга килүгә үк, дәрте ташып торган егет матбугат дөньясына омтыла, төрле гәҗит-журналларга мәкаләләр яза. Дәүләт Думасы депутатларының бер төркеме нәшер иткән «Дума» дигән гәҗитнең хәбәрчесе буларак берара Петербургта да яшәп ала.

1912 елда Шиһаб Әхмәров Мәхүбҗамал Сәйдәшева дигән тол хатынның Әминә исемле кызына өйләнә. Туй бик күңелле үтә. Кәләш өенә кияү матур фаэтонда килеп төшә. Кияү егетләре арасында, әлбәттә, Габдулла Тукай да була. Туйдан соң Шиһаб Әхмәров «Болгар» кунакханәсеннән Сәйдәшевлар яши торган йортка күчә.

Шиһаб та, Әминә дә бик туган җанлы булулары белән аерылып торалар. Бәлки, бу заманда туган-тумачаның бергә җыелып, укмашып яшәве табигый хәл саналгандыр. Хәзер генә без якын кардәшләребезнең дә хәл-әхвәлен онытканда бер телефон аша гына белешәбез. XX гасыр башында туган-тумачалар гына түгел, милләт үзе дә шактый ук бердәм булып берегеп яшәгән, төрле төбәкләрдәге зыялылары да туганлык җепләре белән уралып беткән...

Әминәнең әнисе Мәхүбҗамал абыстай белән энесе Салих янына яшь кияү авылдан әнисе Зөләйха апаны, энесе Хәйрулла белән сеңлесе Зәйнәбне дә алып килә.

Монда шунысын да әйтеп үтү кирәк: каенише Салихның музыкаль сәләтенә Шиһаб Әхмәров беренче булып игътибар итә һәм аңа кирәкле юнәлеш тә бирә: «Аны ныклап музыкага һәм нота грамотасына өйрәтү өчен өйгә ул елларда танылган пианист, «Тукай маршы»ның авторы Заһидулла Яруллинны чакырдым. Гаҗәп нечкә музыкант Заһидулла ага Салихның талантын бик тиз күреп алды. Алар дуслашып киттеләр һәм шул көннән Салих даими рәвештә музыка дәресләре ала башлады», — дип яза ул истәлекләрендә.

Нәни Сәйдәшне халык йөрәгенә илтәсе юлга Шиһаб Әхмәров җитәкләп чыгара.

Сеңлесе Зәйнәбне исә ул гимназиягә укырга урнаштыра. Авылдан яңа гына килгән гади татар кызының гимназиядә укуы — ул заман өчен шаккатырлык нәрсә! Октябрь фетнәсенә кадәрге татар кызларының авыр хәле, наданлыгы турында ниләр генә язылмады безнең совет әдәбиятында. Имеш, алар, абыстай өенә сабакка йөрсәләр дә, хәреф танырга гына

өйрәнгәннәр, яза белмәгәннәр (янәсе, егетләргә хат язмасыннар!). Казанга килеп гимназиягә керерлек булгач, димәк авылда ук Зәйнәб тиешле белем алган түгелме соң?

Салих белән яшьләре бер чама булганга, алар үзара дус, сердәш булып үсәләр. Аларның милли тәрбиясенә Ш.Әхмәровның көн саен диярлек өйгә килеп йөрүче дуслары да йогынты ясагандыр. Дуслары исә бу өйдә даими җыелалар, әдәбият-сәнгать турында фикер алышалар, милләтнең киләчәге хакында бәхәсләшәләр. Шунысы да билгеле: Ш.Әхмәровның өен жандарм идарәсе агентлары даими күзәтә, төрле очрашу-утырышулар турында губернатор канцеляриясенә яшерен хәбәр итеп тора. Татарстан Дәүләт архивында мондый документлар шактый саклана икән.

Зәйнәбнең дә, Салихның да күңелендә әлеге очрашулар матур тәэсир, гыйбрәтле истәлекләр калдырган, әлбәттә. Атаклы урыс язучысы В.Гроссманның «Жизнь и судьба» романындагы бер әдәби каһарман әйтмешли, Октябрьгә кадәрге татар зыялылары, хәзергеләрдән аермалы буларак, чын, фидакяр, асыл булган шул! Хәер, без инде зыялы да түгел, ә совет интеллигенциясенең гарип калдыгы гына...

Октябрь фетнәсе Әхмәровлар гаиләсенә әллә ни зур үзгәрешләр китерми. Дөрес, 1919 елда Салих Сәйдәш Кызыл Армиягә алына, әмма музыкант һөнәреннән аерылмый, сәяси бүлек каршындагы драма труппасының кыллы оркестры белән җитәкчелек итә. 1922 елда Оренбургтан Казанга кайтып төшкәндә, Шиһаб Әхмәровның гаиләсе инде Икенче Тау (хәзерге Волков) урамындагы ике катлы йортта яши. Гаилә тагын да ишәйгән — Шиһаб белән Әминә итәгендә инде өч бала: өлкән уллары Үзбәккә Гөлнара белән Җанбәк өстәлгән. Ә Зәйнәб Казан дәүләт университетының медицина факультетында укый. Ул инде Казанның иң гүзәл, иң затлы туташына әверелгән. Андый кызга күз ташлап йөрүче егетләрнең күп булуы гаҗәпмени? Кайсысы якын килергә җөрьәт итмичә генә гыйшык утында яна, ә берәү инде аның игътибарын да яулаган. Ул ара-тирә Әхмәровлар өенә дә килә. Үз дәрәҗәсен белеп кибарәнә сөйләшә. Гади кеше түгел, Казакъстанның Татарстан Үзәк Башкарма комитеты каршындагы хәрби вәкиле, үз илендә танылып килүче шагыйрь. Миңа Төркиядә Батырхан сөйләгән канлы вакыйганың төп сәбәпчесе Бирнияз шул була инде.

Тик әле үзләренә тиздән нинди зур фаҗига киләсен беркем дә сизенми. Яңа тормыш корабыз дип һәркем алгысы-

нып яши. Гаилә башлыгы китап нәшриятында эшли, Үзара кредит җәмгыяте идарәсендә мөһим вазифа башкара. Аның ул вакыттагы тагын бер игелекле эшен искә алырга кирәк: ул ерак татар авылларында яшәүче игенчеләрне Иделнең уң як ярындагы буш җирләргә күчерүне оештыручыларның берсе була. Мәгълүм ки, урыслар басып алгач, татарлар зур елга буйларыннан читкә куылалар. Егерменче елларда исә бер төркем милләтчеләр тарихи гаделлекне кире кайтару гамәленә керешә. Нәтиҗәдә Идел ярында Бакчасарай, Кызыл Байрак, Берек, Шура кебек авылларга нигез салына. Берничә елдан соң Ш.Әхмәровны кулга алганда, чекистлар бу гамәлне дә сылтау итәләр. Әхмәровларга бер йорт аша гына Костромадан күчеп килгән Мухиннар гаиләсе яши. Аларның Валентина исемле кызлары Зәйнәб белән бергә университетта укый, еш кына ахирәте янына керә, алар бергәләп дәрес әзерлиләр, пианинода уйныйлар. Өстәвенә Валентина Ш.Әхмәровның улы Үзбәкне урыс теленә өйрәтә. Гел-гел килеп йөри торган бу чибәр марҗа кызына күз төшмәсә үзе гаҗәп булыр иде! Бигрәк тә хисчән аһәңдәрнең матурлыкка ымсынган күзләре... Салих Сәйдәш тә күрше кызына дөньясын онытып гашыйк була. Әлбәттә, ул туганнарыннан хисләрен яшерергә мәҗбүр... Кяфирәне яратуын әнисе сизә калса, Аллам сакласын. Ә кыз сәбәп белән дә, сәбәпсез дә гел аларга керә, гел күз алдында... Аларның бу мәхәббәтен баштагы мәлдә Зәйнәб кенә белә, Зәйнәб кенә аңлый.

Чөнки аның үз йөрәгендә мәхәббәт уты дөрли! Бергә үткәргән ул язгы кичләр, пышылдап сөйләнгән шигырьләр барысы да киләчәктә бәхет, шыпырт куанычлар вәгъдә итә сыман... Менә алар Бирнияз белән икәү фотога төшәләр. Зәйнәб озын итәкле күлмәктән, чем-кара чәчләре күпереп тора, бәхетле күзләр, төз борын, җыйнак иреннәр. Какча Бирнияз ярым хәрби киемнән, йөзендә нindидер сабый өстенлеге... Рәсемдә бил каешына аскан наганы күренми... Ул югыйсә һәрвакыт корал белән йөргән. «Революцион» заманда бу табигый саналган. Йа Ходаем, рухлары балигъ булмаганнар кулына корал бирмә...

Әлеге фото артына Бирнияз Зәйнәбкә багышлап шигырь яза. Мәхәббәт шигырьләренең күбесе кебек наив, буталчык һәм зәгыйфь ул. Ләкин шул ук вакытта ниндидер хәвеф тә сизелә:

## ЗӘЙНӘБЕМӘ — ЖАНЫМА

Янымдагы минем гомерем ае —
Жаннан артык, жаным Зәйнәбем.
Жирдән күккә алып очар идем,
Фәрештәдәй тик бер бәндә мин.

«Жаным» барда миңа үлем бармы?
Гомер сөрәм, кызык күрәмен.
«Жаным» юкта, жарык* күрү кайда,
Жылый-жылый мәңге үләмен.

Йа Ходаем! Серле пакь йөрәкнең
Кабул булды изге догасы:
Аман чикте «Тәңрем», жаным-жарым —
Иркә баладай гомер сөрәсең!

Бирнияз

*Казань, 10/1 — 23 г. — 11 ч.ночи*

Казакъ әдәбиятының белгечләре беләләр микән бу шигырь турында?

Дөньяда күпме ир белән хатын тигез мәхәббәт канаты астында яшәп, бәхетле булып дөньядан киткән. Без алар турында белмибез, шагыйрьләр алар хакында гүзәл кыйссалар язмый. Без белгән мәхәббәт тарихлары барысы да фажигале бетә. Фәрхад-Ширин, Ләйлә-Мәжнүн, Ромео-Джульетта, Хәлил-Галиябану... Гашыйклар корбан булганда гына мәхәббәтнең бөеклеге, илаһилыгы артамы? Мәхәббәт, нindидер бер коточкыч сихри аждаһа сыман, үзенә ара-тирә корбаннар сорый мәллә?..

Дилбәр ханым Саипова-Әхмәрова китабында Зәйнәбнең фажигале үлеме турында берничә юл гына таптым. Бәлки, кайбер мәгълүматлар язылмый калгандыр?

Үзбәк ага белән Дилбәр ханым Казан үзәгендәге бер иске йортта яшәп ята икән. Йорт диварында Ш.Әхмәров белән С.Сәйдәш хөрмәтенә куелган истәлек такталары. Мондый өйләрне күрүгә, күңелгә нindидер тарихи моңсулык бәреп керә. Казанның үзәге бик тиз үзгәрә бит хәзер. Бераздан бу йорт та сүтеләсе икән. Тиздән безнең башкалабыз да Йошкар-Оладан яисә Чабаксардан берни белән дә аерылып тормаячак. Тимер-бетон арасында тарихыбызны оныту, бәлки, жиңелрәк булыр...

---

* *Жарык* — яктылык.

Профессор Үзбәк Әхмәровны мин ишетеп тә, күреп тә белә идем. Туксаннан ашуына карамастан, егетләрчә хәрәкәтчән, хәтере тере. Дилбәр ханым исә озак еллар университетта инглиз теле укыткан, гомерен Сәйдәшнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышлаган.

Мин килгәндә Үзбәк ага эчке бүлмәдә энесе Җанбәк белән сөйләшеп утыра иде. Нигәдер урысча сөйләшәләр, күрәсең, җиңгәсе Валентинаның тырышлыгы бушка китмәгән. Югыйсә мин килүгә, алар икесе дә үзебезчәгә күчте. Чын әдәби телдә сөйләшәләр, хәтта хәзерге матбугатны да укып барырга тырышалар икән.

Шик юк, Шиһаб әфәнде улларына исемне татар ханнарының хөрмәтенә кушкан... Мин аларның кыяфәтен дә ханнарныкына охшаттым. Бераз кысыграк күзләр, ат өстенә очып менәргә әзер җыйнак гәүдә, җитез хәрәкәтләр... Һәрхәлдә, миңа шулай тоелды — ханнар күреп үскән кешеләрме соң без...

Музейга кергәндәй, түргә үттем. Өй эче чыннан да музей сыман иде: диварларда борынгы фотолар, иске җиһазлар... Күңелемә кадерле кадими шәүләләр орынгандай булды. Бар әле, бар икән Казанда андый фатирлар. Бүтән мин мондый борынгы зыялы мохиткә эләгә алмам, мөгаен...

«Бирнияз Зәйнәб апаны хатынлыкка сорарга килгәч, әти аның үтенечен кире какты, — диде Үзбәк ага. — Егетнең йөзенә бәреп әйтмәсә дә, далага, казакъ арасына сеңлесен биреп җибәрмәячәген белдерде. Апага Сабир исемле бер татар егете дә гашыйк булып йөри иде. Әти, бәлки, кияве итеп шуны күздә тоткандыр...» Егет гарьләнеп өйдән чыгып китә. Гарьләнерсең дә, казакъ хөкүмәтенең хәрби вәкиле, шагыйрь... Ә аны дала көтүчесенә тиңлиләр.

Нигәдер ул елларда һәм соңрак та казакъ, үзбәк, кыргызларның өстен катлау яшьләре ничек тә татар кызларына өйләнергә телиләр... Казакъның А.Букейхан, Ә.Байторсын, М.Чокай кебек милли юлбашчылары хәтта маржалар белән язмышларын бәйли. Мәдәният көнбатыштарак, дип уйлаганнардыр, мөгаен. Үзебезнең бөек төрк мәдәниятенә без әле дә түбәнсетебрәк карамыйбызмыни?..

Хәзерге безнең кайбер гаярь милләтчеләрең дә гаиләләренә йә урыс катнашкан, йә бәгъзеләренең балалары урыслашкан түгелме соң? Өйдә авыз йомып тору гарьлеген милләт мөнбәреннән дөньяга чыгару җиңел иде шул... Хәзер

мөнбәр дә юк, ул күңел төпкелендәге кимсенү тагын кайда бәреп чыгар?

Ул елларда Ш.Әхмәров йортында кардәш-ыруның авылдан шәһәргә укырга дип килгән берничә кызы да яшәгән. Беркөнне шуларның Сәгадәт исемлесе белән Зәйнәб «Шәрекъ клубы»на хәйрия кичәсенә барырга җыена. Соңрак Үзбәкстанда яшәгән Сәгадәт ханым бу фаҗигале кич турындагы истәлеген гомере ахырында Әхмәровларга юллаган хатында яза. Кичәгә барыр алдыннан бик гасаби була Зәйнәб, һич җыенып бетә алмаган Сәгадәтне ашыктыра. Татарда «әҗәл ашкындыра» дигән әйтем бар бит...

«Шәрекъ клубы»нда Сәгадәт Зәйнәбне югалта... Күрәсең, кичәгә бару Зәйнәбкә Бирнияз белән очрашу өчен сылтау гына булган. Ул, ахирәт кызын клубта калдырып, Бирнияз яшәгән өйгә йөгерә. Нигә мондый яшеренлек? Абыйсы аңа Бирнияз белән очрашуларны катгый тыйган булгандыр. Һәм менә Зәйнәб, күрәсең, сөйгәне белән араны тәмам өзәргә дип, соңгы яшерен очрашуга бара. Очрашуның чыннан да соңгы икәнлеген, әлбәттә, башына да китерми.

Истәлекләргә караганда, Шиһаб Әхмәров кырыс һәм таләпчән гаилә башлыгы булган. «Гаиләнең барлык әгъзасы да аңа берсүзсез буйсына иде, — дип искә ала әтисен Үзбәк ага. — Салих абый да аның кырыслыгыннан, әзлекләлегеннән шүрли иде...»

Казакъ егетен никадәр сөйсә дә, Зәйнәб, билгеле, абыйсының хәлиткеч карарына каршы төшәргә җөрьәт итмәгән.

Ни турында сөйләштеләр икән егет белән кыз соңгы кичтә? Бу хакта фараз итеп кенә була. Бирнияз, әлбәттә, кавышырга үгетләгәндер, ялваргандыр, янагандыр. Зәйнәб бәгыреннән умырылган газаплы сүзләр белән аерылышу мәҗбүрияте сөйләгәндер...

Ул, мәңгегә хушлашып, ишеккә атлаган булса кирәк. Аның гәүдәсен бусагада табалар.

Икенче пуляны Бирнияз үзенә юллый. Бәлки, сөйгәне белән теге дөньяда кавышырга өметләнгәндер...

Бу фаҗигагә бөтен Казан тетрәнә. Андый чакта безнең халык йә бәет, йә берәр җыру чыгаручан. Әлеге очракта да бераздан шәһәрдә «Наган көе» дигән җыр тарала.

Аның истә калган ике юлын Үзбәк ага җырлап та күрсәтте:

Атмачы, наган, йөрәгем курка
Шул наган тавышына...

Озак та үтми бу җыр бөтен татар дөньясына тарала. Казанга ул, сүзләре шактый үзгәреп, чын мәхәббәт җыры булып кайтып төшә:

Кара карлыгач микән,
Сары сандугач микән
Аны үстергән әнкәсе?

Җәүдәт Фәйзи үзенең «Халык җәүһәрләре» китабында әлеге җырны беренче мәртәбә 1925 елда «Наган көе» булarak «Атма, бәгърем, наган, йөрәгем яна шул наганның тавышына» дигән сүзләр белән ишеттем, дип яза.

Авыр югалтудан тетрәнеп калган Әхмәровлар Салих белән Валентинаның кавышуына киртә куймыйлар. Шиһаб Әхмәров инде якыннарының язмышына беркайчан да тыкшынмаска сүз бирә.

Тик... бу гаиләне нинди дә аңлашылмас афәт сагалый. Салих белән Валентинаның дә бәхете озакка сузылмый. Бала тапканнан соң каны бозылып Валентина вафат була...

Бер-бер артлы килгән шушы ике авыр югалтуны Салих Сәйдәшнең ничек авыр кичергәнен без чамалыйбыз гына... Юк, татар моңын җуймаган кешеләр ул кайгыны янә бер мәртәбә кичерә дә ала!

Валентина вафатыннан соң нәкъ дүрт ай үткәч, 1927 елның башында Сәйдәшнең дусты, танылган артист Нури Сакай кинәт үлеп китә. Әлеге үлемнән Сәйдәшнең кайгылы күңеле кинәт ерылып киткәндәй була. «Сакай маршы» дип аталачак матәм көен ул театр баскычына утырып бер сәгать эчендә яза. Димәк, шушы моңсу көй, кайгылы аһәңнәр аның күңелендә инде йөргән: дустын югалту сагышы Зәйнәб белән Валентинаны да сагынып сулкылдаган авазлар белән бергә кайнап яңгырый бу матәм маршында... Кавышалмаган җаннарның иңрәве булып, мәңгегә-мәңгегә хушлашу догасы булып, югалту ачысын кан тамырларына таратып яңгырый ул көй, һәм ерак елларның шәүләсен күңелләргә бөркеп кара карлыгач күктә канат җилпи.

*Май, 2004*

# БАШНЫ ИЕП, МУЕН БӨГЕП...

Что скажут серые зипуны?
*Ф.Достоевский*

Чувашиягә кайтып барганда, улым үзенчә урынлы сорау бирде: «Нигә безнең район Комсомол дип атала?» (Ул, Казанда туса да, әти-әнисе туып үскән җирне үзенеке дип саный.) Мин аптырап калдым. Районга Комсомол исеменең совет власте елларында бирелгәнлеге аңлашыла. 1939 елда шушы исемгә «лаек» була ул. Тик «комсомол» дигән сүзнең мәгънәсен сабыйга ничек төшендермәк кирәк? Ул бит Ленин бабайның да кем икәнен белми торган буыннан. Безне генә ул кече яшьтән мәктәпләрдә: «Без — Октябрь баласы, Октябрьдә туганнарның Ленин була бабасы», — дип җырлатып, Мәскәүдә кумелмичә яткан мәетнең нәкъ менә безнең бабай булуына ышандыра яздылар.

Хәзер Комсомол дип йөртелүче район үзәге элек Кишәл дип аталган. Күп кенә кешеләр әле дә аны шулай дип атый. Авыл Казан ханлыгы чорыннан ук билгеле. Бу тирәләрдә Казан морзаларының биләмәләре булган. Һәм ул чагында ул, мөгаен, Кошиле дип аталгандыр. Хәер, мин бик ерак тарихка кереп киттем бугай. Кыскасы шул: 1921 елның 27 гыйнварында шушы Кишәл волостенда совет хезмәткәрләренә каршы фетнә куба. Урмай, Тукай кебек татар авылларыннан сәнәк-балта күтәргән ир-атлар, Кишәлгә килеп, погром оештыралар. Фетнәнең сәбәбе, әлбәттә, бүтән җирләрдәге кебек үк була. Безнең мәгълүматлы укучы, мәсәлән, Көнчыгыш Татарстанда купкан сәнәкчеләр фетнәсе турында шактый беләдер. Хәрби коммунизм вакытында совет хөкүмәте авыл кешесен, сыңар телем икмәгенә кадәр тартып алып, соңгы чиккә җиткерә.

Кишәл фетнәчеләре кайтып киткәч, волостьтагы совет хезмәткәрләренең җидесе үтерелгән булуы ачыклана. Боларның күбесе комсомоллар икән. Әлбәттә, хакимият фетнәне нәтиҗәсез калдырмый — ике көннән соң ук җәза отряды килеп, хөкемсез-нисез 48 кешене аталар, 10 кешене өлкә ЧКсына алып китәләр. Әлеге вакыйга халык күңелендә тирән эз калдырган. «Җәза отряды авыл урамында нинди ир-ат күрсә, шуны атып йөрде», — дип искә алалар иде картлар, мин үскәндә. Билгеле, үтерелүчеләрнең күбесе фетнәгә

катнашмаучылар була. Гаебен сизгән кеше, җәза отряды килүен белгәч, урамда иркенләп йөрми инде ул...

1939 елда, Шыгырдан милли татар районын бүлгәләп, Кишәлдә яңа район үзәге төзелгәч, нәкъ менә шул фетнәчеләр тарафыннан үтерелгән комсомолларны искә төшерәләр дә инде. «Халык соравы буенча» район үзәгенә Комсомол исеме тагалар. Бер уңайдан Шыгырданга да Чкалов исеме кушыла.

Туксанынчы елларда Шыгырдан «Сталин лачыны» исеменнән арынды, ә менә «комсомол» атамасы шул килеш калды. Бу авылда яшәүчеләр әлеге атаманы үз итеп өлгергән, күрәсең. Элек фетнә күтәрүче Урмай белән Тукай кешеләре үзләрен нәкъ элеккечә атасалар да...

Баш күтәрүләр, фетнә-болалар һәрвакыт булып торган. Тарихтан беләбез. Әле кайчан гына аларның Октябрь инкыйлабына кадәр булганнарын халык күтәрелеше, хәтта революция дип зурласалар, коммунистлар хөкем сөргәндәгеләрен контрреволюцион чыгышлар, советка каршы фетнәләр дип тамгаладылар. Аларны җитәкләүчеләр дә, заманына карап, йә милли каһарманнар, йә халык дошманнары булып тарих дәреслекләренә керде.

Белгәнебезчә, Пушкин урыс бунтын дәһшәтле һәм мәгънәсез дип атаган. Дәһшәтле, әлбәттә. Бола вакытында шәфкатьлелек, миһербанлылык югала. Әмма мәгънәсез микән соң? Халык бит һәрвакытта өстен катламның төрлечә изүенә түзәрлеге калмагач күтәрелеп чыга. Хакимият һәрчакта да баш күтәрүчеләрне бандитлар дип атый...

Күптән түгел генә Башкортстанда Салават Юлаевның тууына 250 ел тулганны бәйрәм иттеләр. Бәйрәм генә түгел, тоташ тантана! Югыйсә Әби патша заманында Пугачев фетнәсендә катнашканы өчен аны, телен, борынын кисеп, маңгаена «вор» (хәзерге мәгънәдә — бандит) дигән сүзне тамгалап, гомерлек каторгага сөргәннәр. Хәзер ул башкортларның милли каһарманы. Хәтта аны, кайдандыр шигырьләрен табып, халык шагыйре дип тә игълан иттеләр.

Татар-башкортларның Пугачев фетнәсенә кушылуы ул чын-чынлап милли-азатлык көрәше иде. Салават та бүтән көрәштәшләре белән нәкъ менә илен-җирен басып алучыларга каршы сугыша. Аны зурлау бүгенге Рәсәй сәясәтенә туры килеп бетми, шуңа күрәдер, мөгаен, әлеге тантаналар уңаеннан Башкортстан халкына Казакъстан Президентыннан котлау килсә дә, Рәсәй Президентыннан андый ихтирам булмаган.

Мәскәү милли республикаларны юкка чыгарырга ниятләр корган заманга Салаватның юбилее тәнгәл килүе үзе үк гыйбрәтле фал...

Салават — башкортларның милли-азатлык символы.

Ә татарның андый символы бармы соң? Сөембикәме? Юк, ул безнең тоткынлыгыбыз символы... Марсель Гали дөрес әйтә: аның җәсәден Касыймнан кайтарып Казанда кадерләп җирләргә кирәк. Бәлки, шул чакта гына аның каргышы безнең өстән китәр.

Уфадагы тантанада чыгыш ясаган Мостай Кәримнең (урыны җәннәттә булсын) сүзләре дә гыйбрәтле. Ул Салаватны чынбарлык һәм мифның кушылмасы дип атый. Мифларны фаш итәргә кирәк түгел, алар халыкка зарур, ди. Халыкның рухы мифларсыз салкын һәм өшәнгән була. Мостай Кәримнең телмәрен мин урысча укыдым, шуңа күрә аның ахырын биредә тәрҗемәсез генә күчерәм: «Тулпару Салавата мчаться и мчаться, покуда жива Великая Россия. России предначертано быть вечной. Быть вечным предначертано и Салавату Юлаеву». Дөрес әйткән бит зирәк карт! «Бөек Россия» шигаре астында ил өстеннән мәңге бетмәс төрле тәҗрибәләр ясалып торганда, Салаватлар, әлбәттә, туып торачак...

Гомумән, Мәскәүдә кем генә түрә булса да, халык белән төрле тәҗрибәләр ясарга тотына. Әлбәттә, шул ук халыкның тормышын яхшырту максатыннан эшләнә бу гамәлләр. Тик ахыргы максатка ирешү өчен әлегә популяр булмаган кануннар кабул итәргә кирәк икән... Бик иске җырның яңа сүзләре түгелме соң? Безнең ата-бабаларыбызны да киләчәктә коммунизмда яшәячәкләренә ышандырып, алны-ялны белмичә эшләткәннәр ич...

Хәзер дә безне буш вәгазьләр белән юандыралар. Янәсе, бик тиздән Рәсәй дөньяның алга киткән илләре белән бер сафта булачак. Ләкин әүвәл билне кысыбрак буарга кирәк.

Ай саен бәяләр арта. Утка, суга, торакка, транспортка... Хәер, нигә санарга? Сулаган өчен дә салым түлибез бит! Халыкның яртысыннан артыгы хәерче хәлендә. Ярлылар белән байларның кереме арасындагы аерма 40 тапкырга җиткән! Миллионерлар бу нисбәткә керми, билгеле...

Түрәләр белә — Рәсәй халкы түзем... Без һаман да элеккечә көнелне юатабыз: түзәрбез, сугыш кына була күрмәсен! Тамагыбыз бераз тук булса, өстебезне күпмедер капласак, шул җиткән... Татарның әлеге форсаттан янчыгында дис-

тәләп мәкале әзерләнгән: «Сабыр төбе — сары алтын», «Сабыр иткән — морадына җиткән». Ниһаять, «Иелгән башны кылыч кисми!»

Халык зирәк, сүз дә юк. Калкынган башларны гасырлар дәвамында кисеп тормаганнармыни? Тик шунысы да бәхәссез: иелгән баш та кылыч төшәр өчен бик җайлы.

Чыдауның да бер чиге була. Халыкның тәмам бөлгенлеккә төшүе, түрәләр катламының симерүе ахыр чиктә җәмгыятьне төрле тетрәнүләргә китерә.

Ә хәзергә тынлык әле. Кешеләр үзара гына сукрана, берберсенә зарлана. Аларның зарларына төкереп янәшәдән төмсә пыялалы затлы машиналар үтеп китә. Берәүләр байлыкны кая куярга белми, икенчеләрнең ипи алырга акчасы юк. Ачу, көнчелек кеше күңелендә озак бөялә. Давыл алды тынлыгы түгелме соң ишегалдында?

Рәсәйнең Дәүләт Думасы митинглар турында канун кабул итте. Анда бик кырыс кагыйдәләр. Аңлашыла, түрәләр якын киләчәктә үзләрен халык авазыннан араламакчы. Ләкин буа бер ерылса, ыргылган суның юлын кәгазь белән генә бүлеп булмасын Рәсәй тарихыннан яхшы беләбез ләбаса.

Байлыгы арткан саен, кеше чынбарлыктан аерыла бара. Халык алар өчен сарык, быдло. Алар өчен тормыш мәңгелек бәйрәм булып тоела. Һәм мондыйлар, кемдер уйлаганча, ун-унбиш кенә кеше түгел. Мәсәлән, Лондонның атаклы Челси төбәгендә 200 мең рәсәйленең күчми торган милке бар икән. Рәсәйле, дидем, әлбәттә, аларның күбесе мәскәүләр.

Мәскәү дәүләт эчендә аерым дәүләт булып яши. Салымнарның күбесе анда агылганда бу табигый да. Империяләр таркалыр алдыннан башкалалар шулай алтынга чумып, провинцияләр тәмам хәерчеләнгәннәр. Рум империясен, Багдад хәлифәтен искә төшерегез...

Билгеле, кузгалган халыкны бастырыр өчен дәүләтнең мөмкинлекләре чиксез. Җәза отрядлары әзер. Ил байлыгын җиңел генә үзләштергән яңа «аксөякләр» шуларга өмет баглыйлардыр да... Ләкин инде хәзер азатлык һавасын сулап өлгергән буын аякка басты. Алар бабалары хәленә төшәргә теләмәсләр шул. Идеологик уенчыклар белән дә алдап булмас аларны.

Кодрәтле урыс диңгезе уянган очракта бичара татарга нишләргә соң? Шашкан дулкыннар астында сытылып, корабыбыз төпкә китмәсме? Милләт мәнфәгатьләре турында

онытkан байларыбызны да туплаган маллары гына коткара алмас бит... Диңгез малны гына түгел, җанны да сорый ул!

Мин бу сорауларга җавап таба алмыйм. Чөнки егерменче гасыр башындагы кебек бербөтен татар милләте юк инде хәзер. Күрәсең, безгә башны иеп, муен бөгеп бүтәннәр артыннан иярергә генә кала. Ә ул юлның кая илтәсен без түгел, алдагылар да белми.

*Июнь, 2004*

## ПЕТР ПАТША ЯРЛЫГЫ

Җәй башында без — бер төркем язучылар — Уфага әдәбият сөючеләр белән очрашуга бардык. Машиналар алга җилдерә, без татарча атамалы авыллар аша алга омтылабыз. Бу яктагы җирләрнең киңлеге, дала исе хәйран калдыра, кан тамырларында әллә кайчан онытылган сәер хисләр уяна. Күз күреме ераклыкта берән-сәрән атлар утлап йөри. Ә бит кайчандыр бу җирләр меңнәрчә ат өерләрен күргән, шул аргамакларның тояк тавышыннан дала яңгырап торган... Нугай даругасының түрәсе Алдар тархан үзе генә сигез мең ат өеренә хуҗа булган...

Мәгълүм ки, Казан ханлыгы вакытында хәзерге Башкортстанның күп өлеше Нугай Урдасы кул астына керә. Иксезчиксез җирләрне нугай морзалары үзара бүлешеп идарә иткән. Нугайлар белән Казан ханлыгының сәяси мөнәсәбәтләре галимнәр тарафыннан шактый ук өйрәнелгән. Безнең атаклы ханбикәләребездән Нурсолтанның, Фатыйма, Сөембикәләрнең нугай кызлары булуын искә төшерү дә җитәдер.

Казакъ, үзбәк кардәшләребез безнең үзебезне дә әле хәзергә кадәр нугайлар дип атый.

Нугайлар кыпчакларның бер гонсыры, һәм заманында алар Алтын Урданың төп халкы була. Шушы бөек халыкның берничә кыйпылчыгы шул ук исем белән хәзер Әстерхан өлкәсендә, Төньяк Кавказда яши. Калганнары төрле төрки халыклар арасында эреп беткәннәр.

Димәк, хәзер татар белән башкорт дип аталган ике халыкны бер үк тамыр — кыпчак тамыры туендырып тора икән...

Безнең телебез, динебез уртак, тарихыбыз бер, бәгъзе бәндәләр арага чөй кагарга тырышса да, борынгы мәкаль әйтмешли, «ике бармак арасына ит үсмәс...»

Шушы уртак тарихта бик күп гыйбрәтле хәлләр, гаярь шәхесләр булган. Шуларның берсе Алдар тархан — XVII–XVIII гасырларда Рәсәй тарихына үзенең исемен төрлечә язып калдырган кеше...

Урыс хөкүмәтенең әле татар ханлыклары тар-мар ителгәнче үк дала яугирләрен үз хәрби максатларында файдалануы мәгълүм нәрсә. Төркләрне бер-берсенә каршы көрәштерүдә урыс элек-электән оста булган...

Төрекләргә һәм Кырым татарларына каршы яуларда да Петр патша бүтән татарларны һәм башкортларны җәлеп итә.

Шунысын да онытмаска кирәк: башкорт дигән исем ул заманнарда этник берәмлектән бигрәк, хәрби катламны, ягъни казаклыкны аңлаткан. «Башкорт полкларында» төрле татар кавемнәре дә (мәсәлән, мишәрләр) сугышкан.

1696 елның 27 маенда Петр патша гаскәрләре төрек кальгасы Азакны (Азов) чолганышка ала. Һөҗүм башланыр алдыннан кальга коменданты Хәсән-Арслан Петрга бер кызыклы тәкъдим ясый. Әйдә, ди ул, башта ике яктан да бер батыр чыгып үзара хәнҗәр белән сугышсын. Төрки халыкларда бу гадәт, күрәсең, элеккедән килгән. Куликово сугышы алдыннан татар батыры Чәләби белән урыс монахы Пересвет алышын искә төшерик. Алар икесе дә һәлак була.

Төрекләр кальга алдындагы мәйданга бер чиркәсне чыгаралар. Аның белән сугышыр өчен Петр патша Алдар батырны сайлап ала. Урыс елъязмачысы бу сугышны бик шагыйранә тасвирлый: «... окропилась земля, как утренняя роса, кровью каждого — сына башкирского и сына черкесского; пали они на землю, подымая клубы пыли, крепко лунцевали друг друга».

Җирдән Алдар батыр үзе генә күтәрелә.

Көтмәгәндә урыс гаскәрләренә Днепрның (татарча Үзи) уң ягыннан Кырым татарлары һөҗүм итә. Азакны кулга төшерү тагын кичектерелә. Генералиссимус Шеин Алдар батырны, яугирләре белән бергә, кырымнарның тылына тел алырга җибәрә. Алар бер бәкне кулга төшерәләр, әмма әлеге бәрелештә Алдар батырның өч кенә яугире исән кала. Әлеге батырлыгы өчен Петр патша Алдарны тархан ярлыгы белән бүләкли. Татар ханнарына хас бу гадәт әле һаман онытылмаган була. Мөгаен, бу урыс патшасы биргән соңгы тархан ярлыгыдыр: «Тархану Алдарбею Исекееву — детям его, племянникам и внучатам — за бытие им, Алдаром, в Крымском и Азовском походах и за три полученные им раны,

также и за убийство сразившегося с ним Черкешенина, за поимку языка Крымчанина... и объявление Его Величеству блажения и вечной славы достойная память Государю Императору Петру Первому».

Әлеге патша грамотасы безнең ханнарның барлык ясаклардан азат итүче ярлыклары белән тәңгәл. Аларның хәтта язылу рәвешләре дә охшаш. Сәхиб Гәрәй ханның мәгълүм ярлыгыннан өзек китерик. Ул аны 1523 елда Шәехәхмәт һәм аның нәселенә биргән: «Буш вакытларында тыныч торып, кичен, иртән эш хәрәкәтләрендә безгә һәм безнең нәселебезгә дога һәм алкыш кылсыннар. Аларга һичбер төрле көчләү, кысынкылык, мәшәкать һәм борчу тидермәсеннәр. Бәс шулай дия торып та, ярлыкны тыңламыйча көчләү, кысынкылык, мәшәкать һәм рәнҗү тидергән кешеләрнең үзләренә яхшы булмас дип, ал нишанлы ярлык бирелде». (Хәзерге телгә күчермә.)

Ике айга якын камап торганнан соң, урыслар, ниһаять, Азакны алалар. Әлеге җиңүдән соң Петр патша үзен дә онытмый — капитан дәрәҗәсен ала.

Ә Алдар тарханга исә патша ярлыгына аркаланып, нәселнәсәбенең ямышы өчен борчылмыйча, мал-мөлкәт эчендә дөньяның артына тибеп кенә яшисе!

Ләкин һаман яңа җирләр яулау турында хыялланучы Петр патшаның күзе комсыз — ул әле моңарчы чагыштырмача бәйсез яшәп яткан башкорт иленә тырнакларын батыра. Яхшы җирләрне заводлар салу өчен тартып алалар, моңарчы күрелмәгән салымнар халыкны изә башлый. Далага урыс колонистлары белән бергә христиан миссионерлар да килә. Тән ирке дә, дин ирке дә кысыла. Тарихка «башкорт фетнәләре» дип кергән милли-азатлык көрәше башлана.

«Аурупага тәрәзә ачарга» маташкан Петр патша төрки халыкларны гына түгел, үз урысларын да йомычка урынына да күрми.

Безнең кайбер могтәбәр кешеләребезнең Петр патшаны кешелек тарихында иң зур шәхес итеп санаулары мәгълүм нәрсә. Шулар өчен Лев Толстойның әлеге патшага биргән бәяләмәсен тәрҗемә итмичә генә күчерәм: «С Петра I начинаются особенно близкие и понятные ужасы русской истории. Беснующийся, пьяный, сгнивший от сифилиса зверь четверть столетия губит людей, казнит, жжет, закапывает живыми в землю, заточает жену, распутничает, мужеложствует».

Хәер, тарихи белемнәре мәктәп дәреслегеннән ары китмәгән ул кемсәләр бу язмаларны укыйлармы инде?

Урыс хөкүмәте, әлбәттә, фетнәчеләргә каршы җәза гаскәрләре җибәрә. Алар авылларны яндыралар, ирләрне кырып, бала-чага, хатын-кызларны коллыкка куалар, малларны талыйлар. 1707 елның көзендә кенәз Ураковның җәза отряды патша ярлыгына ышанып хафасыз яткан Алдар тарханның авылларына бәреп кенә. Аларның, юлда очраган һәрнәрсәне талап-яндырып, Уфага таба юнәлүләре икән. Алдар тиз арада 3 мең кешелек гаскәр туплап каратель ләрне куа чыга.

Менә шул чакта Алдар ханлык вакытларын искә алгандыр. Татар ханы биргән тарханлык ярлыгы булса, аның малына кагылу түгел, җәйләүләрен дә әллә ничә чакрымнан урап үткән булырлар иде. Ә Рәсәйдә бер кул икенчесенең ни кылганын белми.

Алдар тархан башбаштак Рәсәйгә каршы сугыш ача. Хәзер ул Казан ханлыгын торгызып, бәйсез дәүләт төзү уе белән яна башлый. Ләкин ханлык төзү өчен Чыңгыз нәселеннән булган хан кирәк. Ниһаять, Алдар тархан Күчем ханның токымы Морат Солтан белән бәйләнешкә кереп, аңа Казан тәхетен вәгъдә итә. Морат Солтан төрекләрдән ярдәм сорау нияте белән Истанбулга китә, анда Әхмәт солтан белән очраша.

Тик ярдәм булмый. Биредә Истанбулдагы урыс илчесе Л.Толстойның да эшчәнлеген искә алырга кирәк. Төрекләрне солых хәлендә тотар өчен ул солтанның якыннарына бер миллион ярым сум акчаны ришвәт итеп өләшә.

Морат Солтан Кубан буйларына кайтып, андагы нугайларны урысларга каршы күтәрә. Алар хәтта Терек каласын да алалар. Тигезсез көрәштә әсирлеккә алынып, Морат Солтан Казанга кайтарыла. Монда аны кабыргасыннан асып үтерәләр.

Бу арада инде баш күтәрүчеләргә Казан тирәсендәге татар авыллары да кушыла. Җитәкчеләр Казаннан ерак та түгел Саурыш авылына урнашалар. 1708 елның 1 мартында бирегә Алдар тархан да килеп җитә. Ул, мөгаен, Морат Солтанның язмышыннан хәбәрдар булгандыр, үзе белән тагын бер «ханны» — Хаҗи Солтанны ияртеп килә. Чынлыкта бу ябай бер башкорт була. Билгеле, бүтән җитәкчеләр аны хан итеп танырга теләмиләр. Күрәсең, күзнең кысыклыгы гына хан булу өчен җитенкерәми әле...

Хан мәсьәләсендә бәхәсләр башланып, Казанга һөҗүм һаман кичектерелә. Нәтиҗә чын татарча була — Петр патша Казан иленә бояр Хованский җитәкчелегендә 5 полк юллый. Алар баш күтәрүчеләрне тар-мар итә. Алдар тархан исән калган кешеләре белән җәйләвенә кайтып китә. Тәхеттән мәхрүм калган Хаҗины үзе белән алганмы, юкмы, билгесез...

Мөгаен, Петр патша кайчандыр үзе өчен зур гаярьлек күрсәткән тарханны кичергәндер. Алдар утыз еллап үз җирендә тыныч кына яши. Хәер, тыныч булдымы икән ул еллар?

Даланы урыслаштыру өчен яңадан-яңа проектлар туа тора, җирле халыкны изү һаман көчәя. Илбасарларның бер тәкъдимнамәсеннән өзек китерәсем килә: «Бирердә яшәүче халык үзенең хәзерге көче белән түгел, бәлки сан ягыннан туктаусыз арта баруы белән куркыныч. Аларда бала туу процессын киметергә, мөселман авыллары янына урыс бистәләрен күчереп утыртырга, мондагы мөселманнарга корылтайлар үткәрергә ирек бирмәскә, старшиналарны бер ел срокка гына сайлап куярга һәм аларга салым түләү тәртибен кертергә кирәк. Мондагы авылларның һәркайсында мулла яки абызлар булып Казан өязеннән күчеп утырган татарлар тора. Аларның һәркайсы укымышлы, зирәк. Аларның һәр сүзенә пәйгамбәрләргә табынган шикелле ышаналар. Шуңа күрә татар муллаларын һәм абызларны Уфа провинциясеннән куып чыгарырга, мәдрәсәләрен ябарга, шәкертләрен тылмач итеп файдаланырга кирәк...» (Кирилов белән Румянцев проекты.)

1736 елның 11 февралендә шушы проект нигезендә хөкүмәт указ игълан итә. Менә аның кайбер маддәләре: «Хөкүмәт рөхсәтеннән башка мәчет төзү һәм мәдрәсәләр ачуны тыярга; крепостьлар һәм заводлар төзүне тизләтергә; Уфа провинциясенә урысларны, һич югы, сөргенгә хөкем ителгән христианнарны көчләп булса да күчереп утыртырга; татар һәм башкортлар арасында никахлашуны рөхсәт итмәскә».

Хәзер татар белән башкорт мөнәсәбәтләре катлаулы дип күп сөйлиләр. Аны катлауландырырга тырышкан яшерен циркулярлар бүген дә иҗат ителә, күрәсең...

1739 елның гыйнварында Уфа провинциясендә хөкүмәт халык исәбен алырга ниятли. Рәсәйдә бу гамәл һәрвакыт сәясәткә әверелә. Карательләр кырганнан соң исән калган

кешеләрне санар өчен авылларга кораллы отрядлар җибәрелә. Халык әлеге солдатларның килүен үч алырга һәм көчләп чукындырырга җыену дип уйлый. Тагын фетнә куба. Моңарчы керәштән читтәрәк торган, инде картаеп барган Алдар тархан да янә яуга күтәрелә.

Әлбәттә, Алдар тархан мәйданга чыккач, яңа «хан» да пәйда була. Аны Морат Солтанның туганы Солтан Гәрәй дип игълан итәләр. Олыс старшиналары җыелып, 1740 елның башында аны хан рәвешендә ак җәймә өстендә күтәрәләр. Борынгы гадәтләр онытылмаган була әле. Халык яңа ханны Карасакал дип йөртә. Хәер, кайберәүләр аның да солтанлыгын шиккә алып, нәсәпсез бер башкорт ул дип теш агартырга маташа.

Ләкин тиздән инде Алдарда хан кайгысы булмый, ул хөкүмәт гаскәрләренә әсирлеккә төшә. Аны бик нык җәзалаганнан соң, озакка сузмый гына Минзәләдә дарга асалар.

Бәйсез Казан ханлыгы турындагы соңгы өметләр Алдар тархан белән бергә тәмам юкка чыга.

*Август, 2003*

## КАЗАН ЯТИМНӘРЕ

Пычрак киемле, ач күзле өшәнгән балаларга игътибар иткәнегез бармы? Бар, әлбәттә... Аларны хәзер төрле төшләрдә очратырга була: вокзалларда, урам чатларында, тиздән сүтеләсе йортларның тәрәзләрендә арык шәүләләре чагылып китә... Күрмәмешкә салышып узсаң да, алар сукыр чебендәй күзгә керә — чабудан тарталар, кара-кучкыл учларын җәеп хәер теләнәләр...

Кемнәр алар? Нигә соңгы елларда боларның саны артты?

Гражданнар сугышыннан соң шулай бөтен Рәсәйне ятимнәр баскан була. Аларны тотып, мәҗбүри рәвештә балалар йортларына җибәрү белән ЧК үзе шөгыльләнгән. Үзе дә шундый балалар йортында яшәп алган Нәби Дәүли истәлекләрендә әлеге заман турында шактый тәфсилле язылa. Шунысы гаҗәп — ятимнәр әлеге йортларда үзләренең тамырларыннан аерылмаганнар, аларны милли төркемнәргә бүлгәннәр, һәркем үз телендә укырга мөмкинлек алган!

«Казан ятиме» дигән гыйбарәне ишетмәгән кеше юктыр.

Тик кайдан килеп чыккан соң бу сүз? Мәгънәсе ни? Күптән түгел бер Мәскәү гәҗите аны болайрак аңлатты: янәсе, Казан алынгач, бирегә урыс түрәләрен мәҗбүриләп җибәрәләр. Алар, билгеләнгән урыннарына килгәч тә, гел зарланып Мәскәүгә яза торган булганнар. Анысы җитми, монысы юк. Шуннан Мәскәү кәнсәләрендәге түрәләр Казанга җибәрелгән коллегаларын ирония белән «казанская сирота» дип атаганнар, имеш.

Гаҗәпкә калырсың, валлаһи, бу Мәскәү галимнәренең тапкырлыгына, хыял байлыгына!

Югыйсә «казанская сирота» гыйбарәсенең мәгънәсе тарихтан аз гына хәбәрдар булган кешегә дә күптән билгеле. Казан алынганнан соң күпмедер исән калган татарларның ир-ат затыннан булганнарын патша кырып бетерергә боера. Арба тәгәрмәченнән түбән булганнарын гына исән калдырырга рөхсәт итә. Менә шул малайларны, хатын-кызларны урыс илбасарларына өләшәләр. Бераздан алар бөтен Рәсәйгә тарала. Менә кемнәрне урыслар «казанская сирота» дип атаган!

Рөстәм Кутуйның шул исемдәге тетрәндергеч балладасы да бар...

Арба янында арып
бара бер гарип.
Борын эченнән
Җыр көйли, димме? —
Юк, мин ишетәм:
— Әти! Әтием! —
елый
Казан
ятиме.

*(Тәрҗемә минеке)*

Коллыктан изелгән татар балалары ятимлек ачысын аннан соң да даими татыганнар. Ятимлек белән хәерчелек янәшә йөри. Ләкин үксез балаларны туганнары читкә җибәрмәскә тырышкан. Инде аларның да асрарлык хәле булмаса, ятимне читкә, бигрәк тә кяферләр кулына биреп җибәрергә теләмәгәннәр. Бөек ятим Тукайны искә төшерик. Аны алып киткән кеше бит Казанның бүтән почмагында түгел, нәкъ менә Печән базарында «Асрамага бала бирәм, кем ала?» дип кычкырып йөргән.

Югыйсә Тукай белән хәзер бүтән милләт горурланыр иде.

Хәзерге детдом режимын үткән кешеләр арасында та-

тарлар юк. Хәер, алар бер милләттән дә түгел. Алар — урысча сөйләшүче «детдомовецлар»...

Иң тетрәндергәне — әлеге ятимнәрнең күбесенең әтиәнисе исән! Алар балаларын йә үзләре ташлаган, йә аларны ата-ана хокукыннан мәхрүм иткәннәр. Эчкечеләр, наркоманнар, фәхешләр... Безнең заманга хас фаҗига. Тарихтан моңа мисаллар табып булмый.

Караучысыз калган балаларны чит илдәге гаиләләр сатып алу турында күп сөйлиләр, күп язалар. Бигрәк тә Америкадан асрамага алучылар байтак икән. Бу аңлашыла да, чөнки андагы җәмгыятьнең нигезен мөһаҗир токымнары тәшкил итә.

Шул рәвешле чит илгә киткән балалар турында нинди генә сүзләр, гайбәтләр йөрми. Имеш, аларны төрле әгъзаларын авыру байлар өчен сатып алалар икән... Имеш, алар төрле маньякларның җенси корбаны булачаклар икән... Әлеге имеш-мимешләрне инкяр итеп тә, икърар итеп тә бирәдә бер сүз әйтә алмыйбыз. Бу — тикшерү органнарының эше. Гәрчә балалар сатуның корал белән сәүдә итү, наркобизнес кебек төшемле гамәлләр рәтендә булуы ачык...

Тик шунысы да билгеле — Америкада, мәсәлән, асрамага бала алган гаиләләрне махсус комитет даими күз уңында тота икән... Бер караганда, бирәдә адәм типкесендә калган, гомерлек бәхетсез булачак ул балаларның чит илләрдәге гаиләләрдә тәрбияләнеп, чын кеше булып үсүе кешелеклелек ягыннан дөресрәк түгелме соң? Генофондыбыз саегая дип зарланып утыру көлке бит, билләһи... Монда калган ул караусыз балалар җәмгыятебездәге нинди төркемне хасил итәчәге хәзердән үк билгеле ич югыйсә.

Күптән түгел бер авылда булган кызганыч хәлне сөйләделәр. Күп балалы эчкече ир белән хатын, тиз генә акча эшләү өмете белән, бер балаларын сатарга йөргәннәр... Тик, Аллага шөкер, безнең авылларда әле андый бизнесменнар пәйда булмаган икән... Сата алмаганнар. Әмма шундый атаана кулында калган баланың язмышы да күңелдә әрнү генә уята ала.

Шунысын да онытырга ярамый: балалар белән сәүдә итү борын-борыннан бик төшемле «бизнес» саналган.

XIII–XIV гасырларда әлеге гамәл кыпчак далаларында киң тарала. Әлбәттә, тере тауар арасында үзара сугышларда әсир төшкән балалар да күп була. Әмма тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, ачлык елларында тәмам бөлгенлеккә

төшкән кешеләр үзләре үк балаларын килмешәк сәүдәгәрләргә сатып җибәрә торган булганнар. Хәтта үз-үзләрен коллыкка сатучылар да очраган. Шул рәвешле меңәрләгән төрки үсмерләр Иранда, Мисырда солтан гаскәрен тәшкил иткәннәр. XIV гасырда шундый колчуралардан торган мәмлүкләрне җитәкләгән кыпчак Бәйбарс хәтта солтан тәхетенә менә. Аның нәселе XIX гасырда гына киселә.

Килгән сәүдәгәр егерме кешелек төркемне сатып алса, аңа бүләк рәвешендә тагын берәүне бушлай биргәннәр. 1137 елда Әзәрбайҗан сәүдәгәренә шундый бүләк рәвешендә Илдәгиз исемле бер ябык кына малайны тәкъдим итәләр. Малай чыннан да бик өшәнгән күренгәндер инде, сәүдәгәр аны алудан баш тарта. Ләкин малай үзен сатып алуны күз яшьләре белән үтенә. Сәүдәгәр теләр-теләмәс кенә риза була. Дон далаларыннан кәрван Иранга таба кузгала.

Арбада йоклап барган малай бер төнне кайдадыр егылып төшеп кала. Кәрванны туктатып, аны табып алалар. Әмма икенче төндә дә шундый хәл кабатлангач, кәрван башы юлны дәвам итәргә боера. Тиешле җиргә туктап казан аскач, юлда төшеп калган малай аларны эзләп таба.

Әзәрбайҗанга килеп җиткәч, сәүдәгәр Илдәгизне Арран вәзиренә көч-хәл белән берничә тиенгә сатып җибәрә. Дөресрәге, вәзир аны кызганып үзенә ала, аш пешерүчеләргә малайлыкка бирә. Шунда Илдәгиз искиткеч аш-су остасы булып таныла. Даны бөтен тирә-юньгә таралган үсмерне солтан сараена алалар. Илдәгиз бераздан атабәк дәрәҗәсенә ирешә. Кол булып сатылуына утыз ел да үтми, ул инде бөтен төньяк-көнбатыш Иран белән идарә итә башлый. Аның нәселен тәхеттән фәкать 1225 елда Хәрәземшаһ Җәләлетдин генә бәреп төшерүгә ирешә.

Илдәгизләр, Бәйбарслар тарихта үзләренең тирән эзләрен салып калдырган кешеләр. Тик без алар белән горурлана алабызмы соң? Илдәгиз Әзәрбайҗан тарихында якты исем калдырса — чыннан да әкият каһарманы булырлык кеше бит! — Бәйбарс — гарәпләрнең милли каһарманы. Ул — монгол яуларын туктатучы, тәре йөртүчеләрне тармар итүче иләмән.

Тагын бер сорау да туа — бүген арабыздан тибәрелгән, сатып җибәрелгән сабыйлардан андый шәхесләр пәйда була аламы соң? Аларның бит күбесе алкоголик, наркоман балалары... Тумыштан ук гарип, авырулар.

Кан бозылган безнең. Күңелебез каткан. Югыйсә, ара-

быздa кагылып-сугылып йөрүче ул сабыйларны күрмичә, күрергә теләмичә узып китмәс идек.

Колакта һаман Рөстәм Кутуй шигыре:

— Әти! Әтием! —
елый
Казан
ятиме.

Казан алынганнан соң без икенче бөек афәтне кичерәбез түгелме соң? Бу юлы кемнән җиңелдек без?

*Июль, 2004*

# ИЛӘТ

Көзге бер шыксыз көндә, Путинның административ реформасына мөнәсәбәттә митинг булуын ишеткәч, мин дә мәйданга киттем. Митингны «Созидание» дигән оешма үткәрә икән. Аның ниятенә милли оешмалар, демократлар, хәтта коммунистлар да кушылган. Шундый зур көчләр катнашкач, халык шактый җыелачак инде...

Театр янындагы мәйданда йөз-йөз илле кеше кайнаша иде.

Милиционерлар да унлап кына, димәк халыкның күп булмасын белгәннәр...

Миңа, туксанынчы еллардагы кайнап торган Казанны күргән кешегә, моңсу булып китте.

Пар чыгып беткән, димәк...

Югыйсә бит «губернаторларны билгеләү» турындагы канун ахыр чиктә турыдан-туры милли республикаларны юкка чыгаруга юнәлтелгән. Без хәтта символик рәвештә сакланган дәүләтчелегебездән дә колак кагачакбыз... Нигә халык үз язмышына шулкадәр битараф?

Туксанынчы елларда телләрдән төшми торган «суверенитет» сүзе хәзер беркайда ишетелми инде. Бәйсезлек турындагы хыяллар томан кебек таралды да бетте.

«Суверенитет» белән ишелеп муллык килер дип күпләр көтте. Дөрес, кемнәрдер форсаттан файдаланып калдылар. Әмма халыкның хәле үзгәрмәде. Бәйсезлек ул — җаваплы-

лык, язмышыңны үз кулыңа алу дигән сүз. Аның өчен көчле рухлы милләт булырга кирәк. Ләкин көтү булып, Мәскәүдәге көтүче кушканны үтәп йөрү ансатрак та, рәхәтрәк тә икән. Көтүдәгеләрнең бер генә хыялы бар — уҗымга керү.

Беркемне дә гаепләп булмый, милләт дәүләтчелеккә лаек түгел икән, ул аны иртәме-соңмы югалтачак. Ә дәүләтчелеген югалткан халык милләт булудан туктый. Рәсәйдә бер генә сәяси милләт булырга тиеш, дип язалар бит Мәскәү сәясмәннәре... Без инде шунда иләт булып калырбыз. Ягъни население.

Патша вакытындагы милли идеяне (самодержавие, православие, народность; соңгысын милләтчелек дип аңларга кирәк) үзләштергән Кремль әһелләре үзләренең максатларын артык яшермиләр дә. Милли республикаларның булуы эчләрен пошыра. Путинның администрация башлыгы урынбасары В.Сурков менә ни ди: «Западным политикам нужно знать, что Россия является единственной федерацией в мире, субъекты которой могут иметь статус национальных республик. Думаю, в Вашингтоне понимали бы нас лучше, если бы в состав США входили бы, например, Афро-американская Республика или Испано-еврейский Автономный Округ». («К.П.» 29.09.04.)

Әлбәттә, В.Сурков АКШның эмигрантлар иле икәнен яхшы белә. Ә без — үз дәүләте булган, Мәскәү тарафыннан яулап алынган халыкның балалары.

Шулкадәр гомер эчендә урыслашып бетмәвебез өчен гафу үтенергә генә кала. Әмма бу вакытлы хәл. Ассимиляция дәвам итә. Инде хәтта байтак кына мәчетләрдә урысча вәгазь укый башлаганнар.

Ләкин ислам диненең татарларга йогынтысы бик аз. Гает бәйрәмнәрендә берәр Казан мәчетенә барып чыгыгыз — анда күбрәк әзәрбайҗаннарны, үзбәкләрне күрерсез.

Аның каруы ил өстендә православие дине канат җәя. Ул инде Рәсәйнең дәүләт диненә әверелде. Патриарх Алексий Икенчене кайберәүләр дәүләтнең төп җитәкчеләреннән берсе дип саныйлар. Аның инде һәр сүзен боерык дип кабул итүче түрәләр дә бар.

Без — төрле зилзиләләрдән, афәтләрдән исән калган халык. Явыз Иван геноцидын да, Петр патшаның изүен дә, Канашевич җәберләвен дә, Сталин золымын да кичереп, зур югалтулар белән бүгенгә килеп җиткәнбез. Бәлки, яңа сынауларны да имин үтәрбез, иншалла...

һәрхәлдә, Яңа елга кергәндә шуңа ышанасы килә.

Сөенечле хәлләр дә бар бит әле дөньяда! Тиздән Казаныбызның меңьеллыгын бәйрәм итәчәкбез. Камил Исхаковның зур тырышлыклары нәтиҗәсендә Казанская икона Божьей Матери Рәсәйгә кайтты. Татар малаеның әлеге иконаны (дөресрәге, шуның копиясен) кайтарып өчен янып йөрүенә Рум папасы да хәйран калган, хәтта Камил әфәндегә кулын үптергән, имеш. Казанга кайткач, безнең мэр болай сөйләгән: «Меня и посла России в Ватикане первыми подвели к Римскому Папе по его просьбе. Все расценивали это как чудо, как знак свыше. Я был потрясен до глубины души. Папа — исключительно светлый человек, вокруг него сияние, свет, аура доброты». («З.П.», № 40, 04.)

Ничек сөенмисең үзебезнең милләттәш өчен, ничек горурланмыйсың?! Рум папасының кулын үбү католикларга гына тәти бит ул.

Дөрес, безнең мэрның нияте иконаны турыдан-туры Казанга алып кайту булса да, Мәскәүдә аның бу теләгенә каршы төшкәннәр. Һе, җайлы гына биреп җибәрерләр сиңа андый нәрсәне... Ләкин татар халкының сөенеченә күрә, хәл бик өметсез түгел икән әле. «Әнә Богородицкий монастырен яңадан корыгыз, аннары иконаны бирү-бирмәү турында уйлап карарбыз», — дигән патриарх. Хәйләкәр. Шул рәвешле теге иконаны Мәскәүдә калдырырга теләгән инде ул. Чөнки монастырь корыр өчен 30 миллион доллар акча кирәген белгән.

Ләкин безнең мэрга андый вак-төяк кенә киртә була аламы соң! Монастырьны Казанның 1000 еллыгына өлгертербез, дип, бөтен халык алдында вәгъдә бирде ул. Аның өчен тәмәке фабрикасын, педуниверситетның тулай торагындагы студентларны кайдадыр күчерергә дә зур-зур чиркәүләр генә салырга кирәк икән. Казан халкы бай бит ул. Әнә торак бәяләрен гел арттырып торалар. Ул акчаларны бүтәнчә кая куясың?

Мондый да тырышлыкка шаккаткан патриарх Казан башлыгына гадәттә православныйларга гына бирелә торган билге тапшырган. «В благославение за усердные труды во Славу Русской Православной церкви» дип атала ул!

Шайтан алгыры! Белегез безнекеләрне...

Шулай итеп, Казан үзәгендә кара рясалы йөзләрчә монах яшәячәк. Ә Рәсәйнең төрле почмакларыннан табынырга килүчеләр меңнәрчә булачак.

Билгеле, элекке комсомол хезмәткәре Камил Исхаковны мин Аллага да, чуртка да ышана дип уйламыйм. Кемдер раслаганча, христиан диненә дә күчмәгәндер. Ул инде, мөгаен, киләчәктә шул табынучылардан, туристлардан Казан бюджетына миллионнарча сум акча керер дип өметләнә. Ә сәяси капитал? Мәскәү күңеленә ошау уен-муен түгел. Бигрәк тә Татарстан башлыгын Путин үзе билгеләргә торганда.

Ә Путинның чын православный булуын укып та, телевизор карап та беләбез. Күптән түгел аның Архиерей соборында катнашучы дин әһелләрен Зур Кремль сараенда кабул итүе турында яздылар. Чита епископының кытайлардан зарлануына каршы (янәсе, кытайлар бик оешкан, хезмәт сөючән халык, урыслар эшләргә тиеш урыннарда алар тир түгә), Президент болай дигән: «Ә сез кытайларны православиегә дүндерергә омтылмадыгызмы? Шул турыда уйлагыз». («А и Ф», № 41, 04.)

Бу сүзләрне укыгач, миңа рәхәт булып китте. Менә бит, һәрнәрсә үз урынында. Совет вакытындагы кебек икейөзләнеп халыклар дуслыгы турында сафсата сатасы түгел. Тарихтан беләбез — мондый тәкъдимнәрне безнең бабайлар күп тапкыр ишеткән.

Шунысы да мәгълүм: Казан Октябрь түнтәрелешенә кадәр миссионерларның үзәге булган. Шуңа күрә башкалабызның меңьеллыгына тагын бер чиркәүне — татарларны чукындыручы православие әһелләре хөрмәтенә салынган Московский чудотворецлар чиркәвен торгызырга җыену бик табигый. Аның ачылу тантанасына Алексий II белән Путин үзе киләчәк икән.

Казанның меңьеллыгы уңаеннан миссионерлар әзерли торган Духовная академия яңадан эшли башласа да, моңа беркем гаҗәпләнмәс.

Гомумән, бүген патша вакытындагы колониаль Казанның рухын кайтару эше бара. Әнә Киров урамын Мәскәү урамы дип алмаштырдылар инде. Югыйсә анда ханлык чорында Кораиш бистәсе урнашкан булган. Олуг Мөхәммәд белән яңа дәүләткә нигез салучы Кораиш бәкнең биләмәләре... Ләкин юбилей тантаналарында аның исемен телгә алучы булмас...

Нигә ул чагында Казанның меңьеллыгы дип лаф орабыз? Минемчә, безгә беркемнән кыенсынмыйча городыбызның 450 еллыгын билгеләргә кирәк иде. Быел булачак тантана-

ларның асылы барыбер шул датага кайтып кала түгелме соң?

Әнә татар заманыннан калган берничә атаманың берсе «Ташаяк» бар иде. Хәзер ул урам Ярмарочная дип атала.

Ташаяк ярминкәсенә килеп, кесәсендә сыңар тиене дә булмау сәбәпле уенчык атка атланырга кызыгып торган ятим Апуш хәлендә түгелме соң без?

Һи-и, туксанынчы елларда нинди шаулап алган идек! Ул көннәрне инде сагынып кына була... Югыйсә бит акыллы агайлар кисәтте: бу вакытлы җебетү генә, тиздән тагын туңдырачак...

Алар хаклы, фасыллар гел алмашынып тора.

Берни дә мәңгелек түгел.

Халык үз дәүләтчелегенә лаек икән, ул аңа барыбер ирешәчәк.

Теге гасырның бишенче елларында иркенәеп алгач та, бераз вакыт үткәч, татар өчен бозлы җилләр исә башлый. Панисламизм, пантюркизмда гаепләп Буби мәдрәсәсен ябалар, кыюрак гәҗит-журналлар чыгудан туктый, Дәүләт Думасында татарларга каршы чыгышлар яңгырый, татар берберсе өстеннән донос яза.

Шул чагында үләренә бер ай чамасы гына калган Тукай сөргендәге Гаяз Исхакыйга аталган шигырен дөньяга чыгара:

Кайт әле монда ватанга, кайт әле, саргайтмале!
Күз карашыңнан керер җир тапмасынчы кер, рия!

Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истилах,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.

Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

Нәкъ бүгенге көнебез турында бит, валлаһи! Шул ук шигырьдә язылганча, без дә «чупансыз, ягъни чабансыз калып аерылышкан яшь көтү» хәлендә.

Тик мин кемне чакырыйм?

Безгә Алладан ныклык сорап ялварырга гына кала.

*Декабрь, 2004*

# ТАТАР ҖАНЫ БИЕКЛЕГЕНДӘ

Һәр милләттә йөзек кашы булырдай кешеләр бар. Татар тарихында да андыйлар аз түгел. Ләкин халык язмышында зур үзгәрешләргә сәбәп булган егерменче гасырга күз ташласак, татар аңына, татар рухына Тукай кадәр дә зур йогынты ясаган бүтән бер шәхесне очрата алмабыз. Ә бит уйлап баксаң, Тукай әлеге гасырның башында ук япь-яшь килеш дөньядан китә. Һәм аның татар рухи тормышында шундый зур роль уйнарлык мөмкинлеге дә булмый төсле. Егерменче гасыр безнең бөтен холык-фигыльләребезне, яшәү рәвешебезне үзгәртте. Әмма менә хәзер, инде яңа гасырны ваклаганда, шикләнмичә әйтергә мөмкин: егерменче йөз Тукай йолдызы астында үткән, шул йолдыз, Тимер казык кебек, юлыбызны яктыртып торган.

Аның пәйда булуы табигый. Татар дөньясының бөтен төбәкләрендә мәдрәсәләр эшләп тора, матбугат барлыкка килә, татар буржуазиясе күпмедер икътисади мөмкинлекләр ала... Империя киңлекләрендә азатлык җилләре исә башлый. Тукай — биле язылган милләтнең сөрәнчесе, моңарчы күңел төпкеленә яшерелгән аһны дөньяга түгүче...

Шуңа да аның беренче шигырьләре үк халык күңелендә аваздашлык таба.

Ул һәр күзәнәге, бөтен асылы белән татар шагыйре. Һәм нәкъ менә аны гына чын мәгънәсендә безнең бердәнбер халык шагыйребез дип атап буладыр.

Тукай — Татар Галәменең кеше гомере кимәленәчә кысылган нәни генә күчерелмәсе кебек...

Аның нәкъ безнең милләткә төс булган фаҗигале гомере, үксез хыяллары, ятим хисләре татар җанын җуймаган һәркемнең әлегәчә күңелен кузгата.

Юкка гына ул үзен «бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы» дип атамаган.

Әдәби иҗатның дәрәҗәсен табигый сәләт кенә түгел, ә шагыйрьнең язмышы һәм Алла биргән күңел биеклеге дә билгели. Тукай балачагында кичергән кагылулар, рәхимсезлекләр бүтән бер генә татар шагыйренә дә хас түгелдер. Хәер, «асрамага бала бирәм, кем ала?» дип, шәһәр базарында йөртү күренешен дөнья әдәбияты тарихында да очратып булмый.

Мондый язмышка дучар булган кешенең бәгыре гомер-

леккә катарга тиеш иде сыман. Ләкин Тукай иҗатыннан даими шәфкатьлелек, җылылык бөркелә. «Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?! Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем».

Җанда милләтнең җылы кулын тою, әлбәттә, бәгырьдәге һәр ташны эретә аладыр...

Ләкин милләт исеме белән сату итүчеләргә, бушбугазларга Тукай аяусыз. Эремәгән ташлар үз вазифасын башкара... Шунысын да әйтергә кирәк, ул ниндидер гомуми дошманга һөҗүм ясамый, аның уклары үз мәрәйләренә һәрвакыт төгәл тия. Әлеге сыйфаты белән дә Тукайга бүген тиңнәр юк.

Шагыйрь куркак була алмый.

Татарның мәгълүм кешеләре арасыннан Тукай хакында берәр фикер әйтмәгән кеше аз калгандыр. Сәяси вазгыять үзгәргән саен кайберәүләр кулындагы бизмән дә төрле якка авышкалап алган. Егерменче елларда, мәсәлән, аны вак буржуазлыкта, милләтчелектә, Аллага ышануда гаепләүчеләр булса, соңрак аңардан революционер, атеист ясарга тырышучылар да табылды. Ләкин бөек шагыйрьне гадәти кешеләргә таман үлчәүләр белән үлчәп булмый. Гадәти кешеләргә хас кысалар кысан аңа.

Тукай әсәрләрен укыганда егерменче гасыр башындагы татар хәятының энциклопедиясенә тап булгандай сөенәсең... Аның бәяләмәләренә, карашының киңлегенә шаккатмый мөмкин түгел.

Һәр кавемгә бер пәйгамбәр җибәрермен, дигән Тәңре безне генә читтә калдырмагандыр.

Әлбәттә, һәр бөек шагыйрь дә, үлгәннән соң, күпмедер кимәлдә мифология каһарманына әверелә. Тукай турында мифлар әле дә туып тора. Бүген, аның турында сөйләгәндә, шактый акчасы калуын искә төшерергә яраталар, әдәпсез шигыре барлыгын телгә алалар. Заманга яраклаштырырга омтылалар, күрәсең.

Хәлбуки, Тукай һич тә андый яраклаштыруларга мохтаҗ түгел. Аның иҗаты болай да һаман заманча яңгырый! Чөнки татар тормышы әле дә шул — хәвеф белән өмет арасында бәргәләнә...

Аның кайбер әсәрләре нәкъ бүген язылган кебек. Соңгы шигырьләреннән — Г.Исхакыйга атап язган «Мөхәррииргә»не искә төшерик:

Алты елда үзгәреп китте ләгать һәм истилах,
Сәүдәгәрлектер зыялылык вә сәүдәдер зыя.
Җанлырак тормыш та бетте, шанлырак бер эш тә юк,
Бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия.

Йәгез, тирә-юнебезгә игътибар белән күз салыйк әле, нәкъ Тукай сурәтләгән мохиттә яшәп калдык түгелме соң?

Һәйкәллек, бронзалаштыру, билгеле, безне Тукайдан бераз аерып куйды. Әмма татар яшәешен аңлыйм дисәң, Тукайның үзенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

«Көндез... интеллигентлар белән катышам. Кич белән күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, итчеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам», — дип яза ул бер хатында.

Тукай — нәкъ татар җаны биеклегендә!

Аны шомартырга да, илаһилаштырырга да кирәкми.

Кайчагында без Тукайның фани дөньяда бары тик егерме җиде ел гына яшәп алуын онытабыз. Ә иҗат юлы аның җиде елга гына сузыла! Әлбәттә, яшьләргә хас тәртәдән чыгулар, үздәрлек, максималистлык аңа да ят түгел. Ул хәтта үзенә якын кешеләргә дә тәкәллеф саклап тормый. Шуңа карап аның һөҗү уклары тигән шәхесләрне заманында кимсетүләр дә булды. Мәсәлән, Камил Мотыйгыйны, Зариф Бәширине искә төшерергә мөмкин.

Ул заман матбугатында бер кызык күренеш күзгә чалына: татар язучы-журналистлары бер-берсен тәнкыйтьләгәндә итагать саклап тормый, хәтта шәхескә тукынудан да тайчанмый, шул ук вакытта тормышта алар үзара дустанә мөнәсәбәтләрне саклыйлар. Матбугатта Тукай Сәгыйть Рәмигә нинди генә кушаматлар такмый, ә үзе беркөнне тота да Әстерханга аның янына кунакка китеп бара.

Тукай үзе дә ара-тирә үтергеч һөҗүләрне татыган.

Шунысы фаҗигале: татар матбугатында инде күнегелгән үзара талашлар инкыйлабтан соң аянычлы төс ала, ә утызынчы елларда фаҗигагә әверелә.

Фаҗиганең башы һәрвакытта да итагатьсезлектә...

Шунысын да онытмаска кирәк: каләмдәшләренә, замандашларына таләпчән булган Тукай үзенә дә, үз иҗатына да аяусыз. «Уянгач беренче эшем» дигән васыять тәэсирен калдыручы соңгы мәкаләсендә ул: «1913 ел, менә мин уяндым. Инде мәңге йокламаска дип уяндым. Күрдем. Атланганым ишәк икән. Үзем бер җүләр вә фитърәтем (яратылышым. — *Р.З.*) җиһанга килмешәк икән. Чыннарым — ялган, суларым төтен икән»... — дип яза.

Тукай үзенең иҗат дөньясын бүлмә белән чагыштыра да сөрән сала: «Һу, монда чүп-чар!»

«Менә Алла юл ачты, «бүлмә» себерергә бушадым. Себереп тә чыгардым. Әй, җир йөзендәге төрк баласы, галимме син, хәкимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм».

Ләкин, сөенечкә, шагыйребезнең бар язганы — үзе чүп-чар санаганнары да! — томнарга тупланып безнең кулга килеп иреште. Мин ара-тирә шул томнарны актарып утырырга яратам. Шигырьләре — шаһ әсәрләре генә түгел, көндәлек вакыйгаларга туры китереп язылган нәни мәкаләләре дә хәзер бөтенләй яңа яктан ачылып китә, татар яшәешен тирәнрәк аңлагандай буласың.

Әйе, Тукайның шул «чүп-чар»ы да заманча яңгырый. Һәм эш монда шагыйрьнең даһилыгында, көрәзәче булуында гына түгелдер. Татар дөньясы үзе үзгәрми! Шуңа Тукай һаман да актуаль.

Билгеле, Тукай заманындагы татарлар белән хәзерге татарлар арасында аерма зур, дип әйтүчеләр дә булыр. Татарның шактый өлеше урыслашты, телебездән, мәдәниятебездән читләште. Әмма милләтне тел, мәдәният, тарих кына берләштереп тора. Кемдер шулардан аерылган икән, ул йә дүңгәләк кебек читкә тәгәри, йә бүтән мәдәниятькә ирешеп, шул милләт вәкиленә әверелә. Минем сүзем алар турында түгел. Татар булып калучыларны нәкъ менә Тукай заманындагы хис-кичерешләр, омтылышлар, нәтиҗәсез үзара көрәшләр билгеле.

Шуңа да милли чыраебызны күрергә теләсәң, Тукай томнарын ешрак кулга алырга кирәк. Наданлыкны тормыш мәшәкатьләренә сылтау да мөмкин түгел, хәзер Рәсәйдә бәйрәмнәр күп, димәк буш вакыт та бар.

Менә Тукайның «Бәйрәм, без вә урыслар» дигән мәкаләсе. «Безнең ватандашларымыз урысларның атлаган саен бәйрәмнәре була. Алар якшәмбене чынлап бәйрәм итдекләре кеби, әллә нинди исемнәр илә әллә нинди бәйрәмнәр итәләр».

Ә хәзер исә, хәзер! Совет бәйрәмнәре, дини бәйрәмнәр, яңа Рәсәй бәйрәмнәре. Шәһәр көннәре, республика көннәре. Күптән түгел генә тагын бер бәйрәм өстәлде: 4 ноябрь — «Халык бердәмлеге көне»! Ул Мәскәүне поляк илбасарларыннан азат иткән көн икән... Һәм, әлбәттә, урысларның нindидер дини бәйрәмнәре дә шуңа туры килә. Килмәгәе...

Аның каруы Мәскәү мөфтие Равил Гайнетдин барлык әһле мөселманны телевидениенең Беренче каналы аша сөендерде: полякларны куган ополчение башлыгы Кузьма Минин этник яктан татар, имеш! Дөресрәге, аның Миңлебай исемле әтисе чукынган татар икән. Сөендек. Мөфти кадәр мөфти дә чукынган татар белән горурлангач инде...

Мин бит авыл баласы. Авылда бәйрәмнәрне аерата көтеп алалар. Чөнки мондый көнне кеше рәхәтләнеп үз хуҗалыгында эшли ала, урманга бара, салам, печән кайтара. Авылда эш тавык чүпләп бетермәслек.

Тукай: «Соң, без күп эшләгәч, алар (ягъни — урыслар. — *ред.*) күп кәеф сөргәч, безнең алга баруымыз, аларның артка калулары тиеш ләбаса!»

Монда, әлбәттә, төрле нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Әмма Тукайның нәтиҗәсе болай: «Алар мәгыйшәт сәфәрендә бергәләшеп, бер йөк тартып алып бармакчы булсалар, һәммәсе дә алга тарталар; без, йөкне төрлебез төрле якка тартып, һаман бер урында әйләнәбез».

Латин имлясына күчү турында бәхәсләр шалт итеп исемә төште. Унбиш ел дәвамында бер фикергә килә алмыйча интектек бит, әй. Рәсәй Дәүләт Думасы әлеге мәсьәләгә нокта куйгач кына бәхәсләшүчеләр җиңел сулап куйды шикелле.

«Безнең эшле көнебез дә көлке, бәйрәм итүебез дә көлке».

Моңа өстәп тагын ни әйтәсең?

Билгеле, мин Тукайның һәр язганын асыл хакыйкать дип исбатларга җыенмыйм. Аның фикерләре белән килешергә мөмкин, килешмичә бәхәскә керергә дә була. Шунысы хак: аның һәр җөмләсендә, һәр сүзендә тере кан тибә. Моны замандашлары да таныган, без дә икърар итәбез.

«Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле».

Кызганыч, ул заман һаман да килмәде. Килер микән?

Ә андый тикшеренүләргә иң беренче нәүбәттә ул — бердәнбер халык шагыйребез газиз Тукайҗан лаек.

*Ноябрь, 2005*

Бер юаныч бар: кеше үлгәч тә бөтенләй юкка чыкмый.

Юк, мин теге дөнья турында әйтмим.

Җан күчеше — реинкарнация хакында да хәбәрем юк.

Кеше яшәвен балаларында, туруннарында дәвам итә.

Төс-кыяфәттә, холык-фигыльдә...

Димәк, ул үзе дә үткән буыннарның дәвамы.

Кем булган минем ерак бабам?

Әлбәттә, һәркемнең үз бабаларын зур итеп, затлы итеп күрәсе килә.

Хәзер күпләрнең морза нәселеннән булуы ачыкланды.

Элегрәк бер Әмирхан Еникинең генә морза икәнен беләидек.

Үзең әллә кем булмасаң да, кайсыдыр бабаңның ханлык заманнарында ак ат өстендә кылыч болгап дошманнарына каршы яу чабуын күз алдына китерү — рәхәт, тит-ти-ти...

Ул бит пачти син инде!

Син — морза!

Ул гынамы...

Мәрхүм Марат Мөлеков — хәтерлисездер әле, татар иҗтимагый үзәгенең җитәкчеләреннән иде — бер мәҗлестә утырганда, бераз кызып алгач... — ә кызгач безнең татарның хыялы тагын да куера, офыклары тагын да киңәя, тарих ишекләре дә алагаем ачыла — шәҗәрәсенең очын безгә күрсәтеп алган иде. Ул бит Себердә туган. Менә... менә...

— Минем ерак бабам — Күчем хан! — диде ул, күзлек пыялалары елтырап алды, күзе тагын да кысылды.

Сөенә-сөенә ышандык. Безнең өчен һәр Себер татары — Күчем хан.

Һи-и, табын тирәсендә кемнең кем икәне тиз ачыла.

Мәгълүм эшмәкәр Морат Сиражин белән утырабыз шулай бер мәҗлестә. Тимер-бетон әйберләр эшләп чыгаручы фирманың җитәкчесеме соң ул...

— Беләсезме, — диде ул, — минем нәсел очы бит Бохара әмиренә барып тоташа.

Горурландык.

Әллә кемнәр бар татарда.

Монархистлар партиясе төзергәме әллә? Хан токымнары бар бит. Тик тәхеткә дәгъвачылар күп булыр шул.

Хәер, тәхет үзе юк.

Кәнәфи генә.

Шулай да ничек куанмыйсың?! Әле кайчан гына барыбызның да бабалары ярлы крәстиян йә юксыл эшче иде.

Хәзер андый гыйбадлык белән беркемнең дә исен җибәрә алмыйсың. Ерак бабаңның гап-гади игенче икәнен ачыклау үзеңне дә бизәми.

Күтәрми.

Игенче булса-булсын, чурт с ним, һич югы, кулак итеп күз алдына китерәсе килә.

Менә шундый матавык.

Совет чорында без бәхетле яшәгәнбез, әй! Кем анда ниндидер бабайлар турында уйлап баш ватсын? Безнең барыбызның да бабасы бер генә — Ленин бабай гына иде.

Ә ул үзе дә, партиянең кайсыдыр съезды делегаты анкетасын тутырганда, әтисенең әтисе турындагы сорауга «белмим» дип язып куйган.

Менә бит нинди үрнәк!

Әлегә кадәр Ленинның әлеге бабасы турында төгәл генә ап-ачык язучы юк. Югыйсә әнисе ягыннан бабасының яһүд булуын күптән бөтен дөньяга шәрран ярып әйткәннәр иде.

Мәрхүм профессор Рәфикъ Нәфиков бер очрашу вакытында әлеге кешенең Нижгар ягыннан чыккан тегүче булуын, Әстерхан ягына барып чыккач, бер калмык кызына мәхәббәте төшеп, өйләнер өчен кырык яшьләрендә чукынуы турында сөйләгән иде. Кырык яшендә генә чукынгач, ул урыс була алмый инде.

Мишәр булмадымы икән? Нижгардан бит.

Хәер, кайберәүләр аны чуаш дип тә фаразлый...

Тик бүген шул Ленинга берәүнең дә ияләнәсе килми.

Зерә...

Мишәр әйтмешли, дөнья куласа ул, әйләнә дә бер баса... Форсаттан файдаланып, ачыкларга иде бабасының кем булуын. Ленин кабат даһиларның даһиена әйләнгәч — Русиядә вазгыять гел үзгәреп тора: бүген пан, иртәгә пропал... — безне аның шәҗәрәсенә янә якын китермәячәкләр.

Мишәр дигәннән... мин үзем дә мишәр.

Белмәгән кешеләргә: мишәр — татарның бер тармагы гына ул, аерым милләт түгел...

Шул... ләкин аерымлыклар да бар...

Моңа гаҗәпләнәсе дә түгел, авыл белән авыл арасында да аерымлыклар була. Мәсәлән, безнең күрше авыллар: Тукай — гомер-гомергә усалрак, Урмай — җиңел холыклырак, безнекеләр исә — Чичканнар — басынкырак саналган.

Төс-кыяфәттә дә аерымлыклар бар. Югыйсә гасырлар дәвамында бер туфракта яшәп, бер үк суны эчкәнбез бит... Кыз алып, кыз биреп гомер иткәнбез.

Тик...

Татарның укымышлырак кешеләре нинди авыр заманнарда да шәҗәрәләрен кәгазьгә төшерергә тырышкан. Бабам кулындагы Коръәннең соңгы битендә дә шундый язу бар иде: Зәбир — Салих — Якуп — Зәйдулла — Зиннәтулла... Аннары әти дәвам иткән: Рафаил — Ркаил... Мин өстәдем: Баязит...

Гомумән, гади халык кәгазьсез дә бер-берсенең нинди нәселдән, нинди төптән чыгуын яхшы белгән. Әлеге белем, әлбәттә, иң әүвәле көндәлек тормышта кирәк булган, әлеге дә баягы кыз алып, кыз биргәндә ике якның да җиде бабасына, җиде әбисенә кадәр тикшергәннәр. Кан катнашмасын! Берәрсенең нәселе яманатлы булса, аның белән ярәшмәскә тырышканнар. Табигый сайланыш... «И-и, аларның төпләре белән шундый...»

Төп!

Бездә бу сүзнең нәсел, токым, ыру, җык дигән мәгънәләре онытылып бара икән ләбаса. Югыйсә әлеге сүз Кавказ тавы итәкләрендә кышларга яраткан бабаларыбыздан чеченнәргә йогып калган. Соңгы елларда шул үз сүзебезне тейп яңгырашында еш ишетергә туры килде.

Нинди төптән мин? Бәләкәй чактан ук шушы сорау бимазалады нигәдер. Унике яшьләрдә идемме, авылыбыз мулласы Ибраһим бабай янына киттем. Акрын гына кар төшә иде. Беренче Бөтендөнья сугышында ук германда әсирлектә булган әлеге карт — ул урталай бөгелеп — нәкъ «г» хәрефе инде! — йөри иде, кәҗә сакал, тар озынча чырай, чәнечкеле кечкенә күзләр, — авыл тарихын бик әйбәт белә, дип кем әйткәндер... Бабай микән?

— Безнең авылга дүрт кеше нигез салган, — диде ул. — Берсе Чынлы авылыннан, икенчесе — Чүтидән, өченчесе — Шыгырданнан, дүртенчесе Нижгар ягыннан булган. Башта алар авылны Тигәнәле дип атаганнар. Авыл тигәнә кебек чокыр урында утыра бит. Читкә чыккач та «кайсы авылдан?» дип сораганга, «Тигәнәледән» дип җавап биргәннәр. Тик мондый авылны беркем белми икән. Аптырагач: «Кондырлы елгасының теге ягында Чичкан җирләре, без исә бу якта», — дип аңлата башлаганнар. Ул Чичкан дигәннәре Чурачык авылының бер бае булган, имеш. Менә шулай әлеге исем безгә ябышып калган...

Белеп сөйләгән Ибраһим карт!

Күп еллардан соң архивлардан эзләп таптым: XVll гасырның икенче яртысында Цивиль (чуашча — Шерби) янындагы Чурачык авылыннан Кондырлы буена биш чуаш гаиләсе күчеп килә: Чечкен, Колбарис, Паймәкәй, Тәктәнеш, Йылымныкылар. Чурачыкның базар урамын әле дә Йылым урамы дип атыйлар әле чуашлар.

Халык хәтере шундый ул!

— Синең нәсел бабаң Чынлыдан килгән, — диде Ибраһим мулла.

1667–1671 елларда Зөя шәһәрендә язылган чикләрне билгеләү турындагы бер документта безнең якның Морат, Бикшик, Шераут (Шорт) кебек авыллары белән бергә Чичкаево дигән атама да теркәлгән. Мөгаен, урыс писаре Чичканны шулай бозып язгандыр. Анда яшәүче йомышлы татарлар да телгә алынган: Уразка Сулаев, Мамаска Алкаев, Сюбейка Поняев... Дүртенче исем юк.

Бәлки, ул кире киткәндер, бәлки, үлгәндер...

Ә телгә алынган исемнәрнең сәер яңгырашына гаҗәпләнәсе түгел, әле хәзер дә урыслар безнең исемнәрне ничек кенә язмый... Пенсия яшенә җиткәч, документларны тәңгәлләштерергә дип ары-бире чабып йөргән кан-кардәшләрне даими күреп торабыз.

1795 елда Буа өязенең Бикшик волостена кергән Чичкан авылында 15 йорт булган, 52 ир-ат, 68 хатын-кыз яшәгән.

Авылга нигез салган әлеге өч ир-атның кайсысы Чынлыдан булды икән?

Ә Чынлылар үзләре кайдан килгән?

Чүпрәле районындагы Зур Чынлының зиратында Хәйрулла хаҗи тарафыннан (язучы Шамил Усмановның әтисе) абыйсы каберенә куелган кабер ташында болай язылган: «Чылны къәрйәсене мөәссәс (нигезләүче. — *Р.З.*) бабаларыбыз Төмин вә Рәзән тарафындан 1600 тарихында килмешләр. 1018 сәнәи һиҗри».

Төмин — хәзергечә әйткәндә Темников, Рәзән инде, әлбәттә, Рязань...

Ташта килүчеләрдән кайберәүләрнең исеме дә теркәлгән: Әлмөхәммәд, Ишмөхәммәд, Ындырчы, Агънай, Алташ, Алмакай...

Авыл тарихы белән кызыксыну, төбенә төшә башласаң, бик тирәнгә һәм еракка алып китә ул.

Соңгы вакытта урыс милләтчелеге бик көчәйде. Ә өстен кавемнең милләтчелеге гадәттә бик тиз шовинизмга әверелә:

«Россия для русских!» дип мәйданнарда кычкыралар да инде.

Иманым камил, әлеге бәндәләр үз авылларының (һәр шәһәр кешесенең төбе авылда) тарихы белән дә, нәселләренең очы белән дә кызыксынмаган.

Югыйсә белерләр иде: Русия — татар зиратлары өстендә калыккан ил ул...

Ә без... шагыйрь әйтмешли, «шушы җирдән, шушы туфрактан без».

Төпле кеше булу өчен безгә шул җитә.

*Февраль, 2007*

## БЕЗГӘ ДИГӘН БИШТӘР

«Булдырабыз!» — дигән шигарьне дә ишеттек, ниһаять. Кемнәрдер сөенеп кул чапты, кемнәрдер уңайсызланып башын түбән иде. Югыйсә шигарь шәп бит! Үзе кыска, үзе саллы. Һәм ни сәер, хакыйкатькә дә туры килә. Шәһәр үзәгендә адым саен затлы бина — банклар, казинолар, супермаркетлар... әллә нәрсәләр... Шәһәр читенә чыгыгыз — һушны алырлык коттеджлар. Метро үзе ни тора! Дөньяда бердәнбер. Иң кыйммәткә төшкәне һәм иң кыскасы... Меңьеллыкны ничек бәйрәм иттек, майт якасын. Соранып йөри торгач, илебезнең урыслар кулына күчүе символы — Казан иконасын кайтардык. Казан мэрының атаклы елмаюына Рум папасы да, Мәскәү патриархы да каршы тора алмады.

Үзенең һаман да кол икәнен раслатыр өчен татар гына шулай бар көчен, йөз суын түгә ала.

Булдырабыз!

Мәчетләр буш, татарныкы дип аталган мәктәпләрдә урысча укытыла, меңләгән кан кардәшебез нәсрани динен кабул итә.

Ә без яңарыш! алгарыш! ди-ди мактанышабыз, атлаган саен бәйрәмнәр үткәрәбез. Упкынга җырлый-бии якынлашабыз.

Шамакайлана-шамакайлана үз йөзебезне җуябыз.

Хикмәтле сүз бар бит: пессимизм кәефне генә боза, ә оптимизм һәлакәткә китерә.

Әлбәттә, булдыклы кешеләрнең кәефен дә бозасы килми. Мыжыкларны үземнең дә җенем сөйми.

Әмма...

Мин җырлый да, бии дә белмим. Кул чабарга да ярат-мыйм. Уйланырга кала. Шул уйларны кәгазьгә төшерергә...

Йөз кәррә кабатланулар булса да...

«Юк белән маташасың! — диде миңа бер танышым. — Ил Русия дип атала икән, анда яшәүчеләрнең барысы да урыс. Тарих тәгәрмәчен кирегә әйләндереп булмый».

Әйе, тарихтан мин дә бераз хәбәрдар.

Мәсәлән, инглиз-сакслар, Британия утрауларын басып алгач, кельт мәдәниятен иҗтимагый тормыштан бөтенләй кысрыклап чыгаралар. Бераздан кельт телендә сөйләшү кешенең җәмгыятьтәге дәрәҗәсе түбән булуны аңлата башлый. Әлбәттә, иң әүвәл инглиз теленә кельт аксөякләре күчә.

Ләкин мин тарихны гына түгел, татар мәкальләрен дә шактый беләм. Мәсәлән: куласа — әйләнә дә бер баса.

Соңгы елларда кельт тамырлы халыкларда милли үзаң уянуга шаккаталар. Уэльста кельт теленең бер тармагы булган валлича яңадан-яңа мәктәпләр ачыла, радио-телевидениедә тапшыруларның саны арта. Шотландиядә дә шул ук хәл.

Хакимлекне Тәңре бер халыкка да мәңгегә бирмәгән. Тарих сәхнәсендә рольләр гел алмашынып тора. Димәк, халыклар белән дә ниндидер өстен көч идарә итә. Режиссер! Бер халыкның гына гелән тәхет биләве аның эчен пошыра, күрәсең.

Татарның да бик хаким чаклары булган. Кан хәтерендә әле ул безнең һаман бар. Уфа һәм Минзәлә епископы Андрейның Дин эшләре буенча Департаментка 1917 елның 20 февралендә җибәргән доносында мондый юллар гыйбрәтле: «Нужно твердо помнить завещание великого Ильминского, что татары в их собственных глазах — царственная нация и что мы никогда этого не должны забывать, как бы они красиво не говорили о лояльности по отношению к русским».

Озак та вакыт үтмәгән бит югыйсә! Коммунистлар идарә иткән XX гасырда, интернационализм идеяләре белән алдап, җелегебезне суырганнар, әйтерсең... Үзебезне шаһ милләт итеп санау кайда, без асылыбыздан кимсенә башлаганбыз...

Әби патша Казанга килгәч, аның каршына берничә татар кызын китерәләр (кулларына чәк-чәк тоттырдылар микән?). Кызларның күзендә шулкадәр горурлык һәм нәфрәт була, патшабикә аларның карашын күргәч: «Бу халыкны җиңеп булмый», — дигән, имеш. Әлеге «тарихи очрашу» хакында Туфан Миңнуллин хикәя дә язган иде. Нинди җилләр кызларыбыз күзендәге әлеге горурлыкны сөртеп алды икән?

Жилләр генәме... Тарихның сикәлтәле юлларында зилзилә-давыллар безне төрле тарафларга чәчеп ташлады. Җан асрау кайгысы гына калганда, кешедә горурлык хисе дә юкка чыга.

Рәсәйнең хәзерге җитәкчеләре тарих дәресләкләрен янә тәртипкә китерү турында сөйли башладылар. Татар тарихын да, кануннар кебек үк, Мәскәүнеке белән тәңгәлләштерә башладылар да бугай инде. Соңгы ун-унбиш елда шактый ук хакыйкать өскә чыккан иде шул. Хәер, ул чакта да Рәсәй империясендә халыкларның дус яшәве (янәсе, урыс булмаган халыклар кимсетелмәгән), диннәр арасындагы татулык хакында сүзләр өзелеп тормады. Ә бит тарихи чыганаклар бөтенләй киресен сөйли. Биредә мин Мәскәү хөкүмәтенең татарларга каршы гасырлар дәвамында максатчан рәвештә геноцид сәясәтен үткәрүе турында тагын бер чыганакны искә төшерәсем килә. Оренбург каласына нигез салучыларның берсе Иван Кириловның Галиҗәнап император кабинетына 1735 елда язган рапортыннан бер өзек ул: «В службы башкирцы и мещеряки, и ясашные к назначенному городу Оренбурху хотя помалу напряжены будут, однако же которое время там пробудут, в то жены без плода останутца. А коего убьют, тот и вовсе не возвратитца, как изстари сию политику во всем государстве над татарами во время швецкой, и польской и турецкой войны делали: везде их перед войски в первых на пропажу посылали, вменяя в службу, а самим делом, что они в домах не надобны».

Ирексездән, Тукайның «Без тынычта аттан артык эшлибез, без сугышта арысланнан көчлебез» дигән сүзләре искә төшә. Чараң булмагач, нишлисең... Тик шунысы ачыклана, сугыштагы арысланнарның күбесе әлеге сугышларда кырылып беткән (аларны шуның өчен алдан куганнар да инде), ә атлар, эшли-эшли, алашага әверелгән...

Ләкин һәммә татарның да, бигрәк тә аксөякләрнең, мондый хәлгә риза буласы килми, әлбәттә. Аларның кайсылары урыс хөкүмәтенә каршы төрле фетнәләрдә кырылып бетә, кайсылары хаким милләт ягына күчә. Күпмедер вакыт үтү белән әлеге сатлыкларның варислары тамырларыннан бөтенләй аерылалар, үзләрен урыстан да чынрак урыска саный башлыйлар. Ф. Достоевский «Язучы көндәлеге»нә болай дип язып куя: «Если были кто (из предков), на Куликовом поле, право, было бы приятно...» (1880 ел). Әлбәттә, бөек язучы Мәскәү гаскәре сафларында булуны күздә тоткан... Ә бит

аның ерак бабасы Арслан Чәләби морзаның бары тик Мамай гаскәре ягында гына сугышу ихтималы була. Чөнки ул Куликово сугышыннан соң тугыз ел үткәч кенә, үзенең 30 яугире белән Мәскәүгә килеп, чукынып, шунда хезмәткә кала.

Достоевскийның шәҗәрәсен ныклап тикшергәннәр. Ә тикшерелмәгәннәр күпме? Аларның исеме — легион... Хәер, хәзер дә шул ук күренеш дәвам итә. Мал хакына безнең бүгенге морзаларыбыз да чукынырга әзер түгелме соң... Юкка гына аларның барысын да уптым «яңа урыслар» дип атамыйлардыр.

Булдырабыз! Әлбәттә, бу шигарьне мәйданга ташлаучы да иң әүвәл матди якны, малга-байлыкка ирешүне күздә тоткан. Динебезнең, телебезнең, мәдәниятебезнең югала баруы өстен сыйныфны һич тә борчымый. Чөнки алар үзләре бабаларыбыз мәдәниятеннән инде аерылган. Фани оҗмахлар вәгъдә итүче яңа үрләрне яулаганда ул комачау гына итә.

Аны һаман без — түбәндә калучылар гына өстери әле. Тик без генә ерак китә алырбызмы?

*Февраль, 2006*

## КАДЕРСЕЗЛЕК

Былтыр башкортлар Мәҗит Гафуриның тууына 125 ел тулу бәйрәмен бөтен республика күләмендә зур итеп уздырдылар. «Бөек башкорт шагыйре»нең исеме ул көннәрдә телләрдән төшмәде. Чү! диярсез, ул бит әле татарныкы да... әлегрәк, һич югы, аның турында «татар-башкорт әдибе» дип язалар иде түгелме? Кем нәрсә язмас... Октябрь инкыйлабына кадәр Гафурины татар шагыйре дип кенә белгәннәр. Ул да үзен татар дип санаган... Татар булып тугач нишләсен? Милләт дип язганда да шагыйрь гел татарны күздә тота — укып карагыз әсәрләрен... Аны хәтта берара татар милләтчелегендә дә гаеплиләр.

Башкортостандагы тантаналарда безнең вице-премьер Зилә Вәлиева да катнашкан. Уфада туып үскән хәлдә дә — аның инде башкорт бәйрәмнәрен күргәне бар! — шагыйрьне болай олылап булуына ул да шаккаткан. Ә бездә? Мәҗит Гафури мәктәп дәреслекләренә кергән, татар мәдәнияте тарихында үзенчә эз калдырган шәхес ләбаса. Исеме Тукай

белән янәшә тора иде моңарчы. Нигә бездә аның турында бер сүз дә чыкмады? Баксаң, аны юбилейлар исемлегенә бөтенләй кертмәгәннәр икән! Кемнәр яза ул исемлекне?

Соң булса да уң булсын, дип Казанда да Мәҗит Гафурига багышланган кичәне үткәрергә булдылар. Әлеге кичәнең сценарием мин яздым, Ринат Әюпов аны яшь тамашачылар театрының сәхнәсенә куйды. Башкортлар оештырган тантаналар белән безнең кичәне чагыштырырлык түгел иде, әлбәттә. Барыбер күңел булды. Уфадан кунак булып шагыйрь Тойгын белән бер галим килгән иде, алар ни уйлап киткәндер, әйтә алмыйм. Шулай да башкортларга рәхмәт әйтәсе килә. Алар булмаса, без Гафурины бөтенләй искә алмас идек.

Бөек шагыйребез Шәехзадә Бабичның да 100 еллыгын күршеләребез бөек бер милләт бәйрәме итеп үткәрде. Без инде Бабичны хәзер үзебезнеке дип санамыйбыз да бугай. Ул да үзен татар шагыйре санап ялгышкан, күрәсең...

Һәй, дип кул селтәрләр берәүләр, исең киткән иске чикмәнгә... бездә шагыйрьләр күп, башкортка да классик шагыйрьләр кирәк, нигә тар күңелле булырга? Кан кардәшләребез ич, телебез-динебез бер, дигәндәй...

Чыннан да, бәлки, без башкорт кардәшләргә рәхмәт кенә укырга тиешбездер? Татарның үз тарихына, мирасына битарафлыгын әнә бөек француз Монтескьё XVIII гасырда ук әйтеп калдырган. М.Гафурилар, Ш.Бабичлар Башкортостанда туулары белән бәхетле. Нәҗип Думавины яисә Миргазиз Укмасыйны әдәбият белгечләреннән башка кем хәтерли хәзер? Ә бит талант җәһәтеннән Думави Гафуридан һич тә ким түгел. Башкорт кардәшләр! — дип оран саласы килә кайчак, алыгыз аларны да (мин биредә үзебез онытып исемнәрне күп саный алам), олылагыз, зурлагыз, сезгә карап без дә аларны, бәлки, искә төшерербез.

Хәер, уфаларга минем оранның кирәге дә юк, алар акрынлап Дәрдемәндләрне, Г.Ибраһимовларны... инде «үзләштереп» яталар. Кол Гали кебек борынгы шагыйрьләр турында инде әйтеп торасы да юк. Бәлки, алар хаклыдыр? Ахыр чиктә без бөек төрк халкының кыйпылчыклары ич. Борынгы телебездә халык будун, йәгъни бөтен дип аталган. Башкортлар үзләренчә «бөтенәя» бара...

Төркиядә «Төрки әдәбиятлар» дигән бик күп томлы антология чыкты. Борынгы әдәбият кыйсемендәге исемнәр башкорт белән безнең бермә-бер тәңгәл килә.

Нигә бүлешергә? Татарныкы дип аталган мираска дәгъва итәләр икән, димәк, алар үзләрен безнең белән тәңгәл күрә! Димәк, бер үк халык, ягъни бер үк «бөтен»? «Регионнарны эреләндерү» дигән Мәскәү сәясәтен хуплап, безгә, бәлки, ике республиканы берләштерергәдер?

Исемгә килгәндә исә... Татар бит ул тыйнак, тәкаллефсез, толерант... без үз исемебезгә ябышып ятмыйбыз. Дәлил кирәксә, әнә хәзерге башкорт язучыларының шәҗәрәсен тикшерегез... Тикшермәсәң дә билгеле, чын башкортлар үзләренең кайсы кабиләдән чыкканлыгын һәмишә бик әйбәт белә.

Янә Мөдәррис Әгъләмнең шигыре искә төшә:

Болгар булып,
Алтын Урда булып,
Казан булып оран салганбыз.
Исем алышынган,
Тик барыбер
Бөек халык булып калганбыз.

Безнең яшәү — һәр көз өлгерүдә,
Һәрбер язда — яшел үләндә...
...Ә халкыбыз бөек булып калыр
Башкорт дигән исем белән дә...

Әлбәттә, кире бәндәләр шагыйрь белән дә бәхәскә керергә мөмкин. Янәсе, чын-чынлап бөек дип, дәүләтле халыкны гына атарга мөмкин. Янәсе, исем үзгәрсә, җисем дә үзгәрә...

Чү, чү, чү!

Ә җисем үзгәрсә начармыни? Борынгы бер йола исемә төште шушы урында. Исем алмаштыру турында... Әле мин сабый чакта да, кеше каты авырып китсә, аның исемен алмаштыралар иде. Әҗәлне адаштыралар, янәсе. Газраил, мәсәлән, Бәдретдинне алам дип төшә, һәм, менә сиңа: аның урынында Котбетдин ята. Нишләсен Газраил, зарлана-зарлана кире китәргә мәҗбүр...

Без дә авыру хәлендә түгелме соң?

Милләтнең дәрәҗәсен билгели торган шәхесләрне онытабыз икән, димәк, без дөньядагы урыныбыз турында уйланмыйбыз. Ә урын түрдә дә булырга мөмкин, әбрәкәй янында да...

Фирдәүси өчен җиде шәһәр бәхәскә кергән, имеш. Һәркайсының бөек шагыйрьне үзенеке итәсе килгән.

Бәлки, башкортлар үзләренеке санаган мәрхүм язучыларыбызның рухы сөенеп кенә ятадыр?

Нобель бүләге иясе, итальян Эудженио Монталедан үз-үзен шагыйрь буларак бәяләүне сорагач, ул: «Мин үземне уртача шагыйрь, дип исәплим, — дигән. — Әгәр дә мин уртачадан югарырак икән, Данте нинди булырга тиеш?» Аңардан тагын уртача белән бөек арасындагы аерманы белергә теләгәннәр. «Бөек язучы үз халкыныкы гына була алмый», — дип җавап биргән ул.

Башкортлар үзләштергән саен безнең бөек язучыларыбыз күбәя, димәк!

Хәер, башкортны бездән аерым халык дип санамаучылар да бар. Кичекмәстән, нәфрәтебезне белдерик: алар безнең бүтән халык культурасына йогынты ясаган бөекләребезнең санын киметмәкче...

Ләкин... Дантены телгә алгач... Ул, әлбәттә, бөек — Аурупаның бөтен әдәбиятларына да йогынты ясаган шагыйрь. Ләкин алманнар да, инглизләр дә, французлар да аны үз шагыйрьләре дип игълан итми. Данте — иң беренче нәүбәттә бөек итальян шагыйре!

Гомумән, мәдәни илләрдә язучыны, шәҗәрәсеннән чыгып, анда-монда тарткаламыйлар. Кайсы телдә яза, кайсы мәдәниятә хезмәт итә — ул шуныкы! Леонардо да Винчиның әнисе Дәште Кыпчакта тотык булып, Кырымда җәнәүз сәүдәгәренең кулына төшә. Сәүдәгәр исә аны Италиядә бер байга сата. Хуҗа бераздан әлеге кәнизәккә өйләнә. Шушы тарихи фактны сылтау итеп Леонардога украиннар, яисә тагын кемнәр анда, дәгъва итә алмый бит...

Ә бездә...

Ягез, Мөхәммәт Сәфәргалиевнең исеме кайсыгызга таныш? Ул безнең олуг тарихчыбыз, Казан галимнәре Мәскәү кушуы буенча тар «болгарчылык» белән шөгыльләнгән вакытта Алтын Урда турында саллы хезмәт яза. Әлбәттә, мондый кеше Казанга сыя алмый, ул Саранскига китәргә мәҗбүр була. Быел аның йөзьеллыгын Мордовиядә зурлап үткәргәннәр. Сәфәргалиев укуларында Мордовия башлыгы, Идел буе федераль округындагы Рәсәй президентының вәкиле катнашкан. Галимебез турында Саранскида телефильм төшергәннәр. Бездә исә галимгә багышлап фәнни конференция үткәрү түгел, һич югы, матбугатта нәни генә мәкалә дә чыкмады. Мукшы иптәшләргә рәхмәт кенә әйтәсе кала..

Тик...

Сәфәргалиев үзе дә мукшы булган икән! Янәсе, аның туган авылы Мөәмин-Каратай татарлашкан мукшылар авы-

лы икән. Монысын үзебезнең татар галимнәре ачыклаган. Доцент Р.Нәбиев һәм аның ике иптәше менә нинди «фәнни ачыш» ясаганнар: «...деревня Мукмин-Каратай, где родился М.Г.Сафаргалиев еще в конце XIX века, называлась Мукшень-Каратай. Каратаи, относя себя к мордовской общности, в большинстве своем пользовались тюркским языком и исповедовали ислам». И-и, без бигрәк юмарт инде. Мондый бүләктән кем баш тартсын?! Әбәзәтелне, мукшы! — дигәннәр мордва галимнәре дә һәм үз дәлилләрен дә китергәннәр: Сәфәргалиев озын буйлы, эре гәүдәле булган. Татарга мондый кыяфәт кайдан килсен? Татарлар кыска буйлы, чандыр гәүдәле... Кыскасы, вак халык... Шундый дәлилдән соң да Сәфәргалиевнең мукшы түгеллегенә ышанмый кара!

Галимнең туганнары без мукшы түгел дип Мәскәүгә дә язганнар ди, имеш, тик мондый дәлилдән соң аларның сүзенә кем колак салсын?

Гомумән, тарихи шәхесләрне үзләштерү мәсьәләсендә мордваларның мөмкинлеге зур, урысның яртысы мукшыдан азган, тарихтан беләбез... Мәскәү кенәзлеге үзе дә борынгы мордва җирләрендә тернәкләнеп китә.

Татар тарихчысы М.Сәфәргалиевтә күпмедер мукшы каны булырга да мөмкин. Безгә кем генә катнашмаган! Дөньяда «саф» халык бар микән? Иң мөһиме — Сәфәргалиев үзен татар санаган, гомере буе татар тарихын төрле ялганнардан араларга теләп яшәгән...

Исән чакта кыерсытылган кешенең әллә үлгәч тә исеме типкедә буламы? Үз милләте тарафыннан бит...

Хәзерге Алтын Урда турындагы язмаларның күбесе М.Сәфәргалиев хезмәтенә ияреп язылганлыгын да онытмыйк. Бәлки, шуңа да кемнәргәдер аны күтәрү кирәк түгелдер...

Онытылып бара торган исемнәрне мин бирегә дилбегә буе саный алам. Берничәсен генә атап үтим. Сибгат Хәким. Мари чигендә туган, иҗатында да чирмеш аһәңнәре бар. Тамырларын ачыклап, марилар үзләренеке дип игълан иткәч, без дә, бәлки, селкенеп алырбыз. Нури Арслан. Казагыстанда туган, соңгы еллар иҗатында дала киңлеге сизелә иде. А-у, казакълар, шундый зур шагыйрь бар иясез... Нәкый Исәнбәт... Энциклопедик белемле әдип. Гаҗәеп бай архивын сатып алырга Татарстан хөкүмәтенең матди мөмкинлеге юк... А-у, Исәнбәт кайда туган әле?..

Тукайдан шигырь юллары искә төште:

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадрен белү?!
Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!

Һай, ялгышкан Тукай, нык ялгышкан. Чын кеше үлеп тә берни аңлата алмый татарга. Менә шул — мискинлек...

*Июль, 2006*

# ИЛӘМӘННЕҢ БИЛӘМӘСЕ

Мәскәү сәясәтчеләре мәктәпләрдә «Патриотик тәрбия дәресләре» кертү турында сөйли башлады. Ышанам, укытачаклар андый сабакны да... Мәктәптә мәҗбүриләп өйрәтмәсәләр, Россия дигән ватанны ничек яратмак кирәк?

Без мәктәптә укыганда — теге гасырда ук инде! — андый дәрес керми иде, ләкин коры җирнең алтыдан бер өлешен биләгән СССРны чын күңелдән яратырга ныклап өйрәтteләр. Пионер сборларында, комсомол җыелышларында даими сеңдерделәр безгә Советлар Союзының бөеклеген! Америкада, Аурупада яшәүчеләрне кызганып елыйсы килә иде. Кытай яисә Африка илләре турында инде әйтеп тә тормыйм. «Я другой такой страны не знаю, где так вольно дышит человек!» Әлеге илләрнең бездән көнләшүе, безне яулап алырга теләп гел коралланып ятулары турында да һаман колак итен ашадылар. Һи-и, без аларга бирешәбезме соң?! Әнә елга ике тапкыр Кызыл мәйданда үткән парадларны гына карагыз. Мондый гаскәр беләнме... Инде без үзебезне дә ярымсолдатлар итеп сизәбез — өлкән сыйныфларда НВП (начальная военная подготовка) дәресе керә башлады. Тутыга башлаган автоматларны күз ачып йомганчы сүтеп җыябыз, идрит-кудрит. Һи-и, безме...

Тик минә иксез-чиксез ватанны гына күзаллавы кыенрак. Төрекмәнстан чүлләре, Себер урманнары, Украина далалары... Барысы да минем ватан икән бит. Күпме тырышсак та нәни йөрәгебез бу кадәр киңлекләрне үзенә сыйдыра алмады.

Хәер, аны зур йөрәкләр дә сыйдыра алмый, күрәсең. Мөһаҗирлектә үлгән бөек урыс язучысы В.Набоков яза: «Хәзер, әгәр дә Яйлының кайнап торган үләнен, яки Урал үткелен, яки Арал диңгезе артындагы тозлакларны күз алдына китерсәм, Неваданың әремле җирләренә яисә Күк тауларның рододендрон чәчәкләренә мөнәсәбәттәге кебек үк,

мин патриотик һәм ностальгия җәһәтеннән битараф калам; тик теләсә кайсы кыйтгада Петербург губерниясен хәтерләткән урманны, кырны, һаваны бирегез миңа, һәм шул чакта бөтен җаным мәтәлчек ата...»

Империячел чиргә дучар булмаган һәркем өчен дә шулайдыр — ватан ул синең тәпи баскан җирең, беренче авазың яңгыраган киңлекләр, борын-борыннан кардәшләрең, кандашларың билгән ил-йорт.

Ватанлык хисе — самими, назик тойгы, ул бернинди сабак укытуларга мохтаҗ түгел. Чын, кадерле кичерешләрне кеше чәчеп, сибеп йөрми. Ватанны ярату турында күкрәк кагып, авыздан төкрек чәчеп сөйлиләр икән, мондый кешедән шикләнергә кирәк. Димәк бу — ватанпәрвәрлекне һөнәр итеп алган. Анысы да бер хәл, һәркем үзенчә ризык таба. Ләкин бит әле ул бүтәннәрдән дә күкрәк төюне, төкрек чәчүне таләп итә.

Гадәттә, гади кешеләрнең патриотик хисләрен сугыш вакытында махсус кыздыралар. Яу кырына яңадан-яңа корбаннарны җибәрү өчен бөек идея зарур. Әгәр дә инде тыныч вакытта «патриотизм сабагы»н укыта башлыйлар икән, димәк, дәүләтнең нигезе какшаган, аска су кергән...

Шунысы гыйбрәтле: патриотизм, ватанпәрвәрлек турында өстәге катлам гына гәп куертырга ярата. Әмма сүз кибгеннән арындырып, гамәлләренә, кыланмышларына карасаң, аларның риясызлыгына ышану мөмкин түгел. Менә ул телевизор экраныннан «Бөек Россия, фәлән-төгән...» — дип лаф ора, шушы минутта сөйләгән сүзенә үзе дә ышана шикелле... Ә кәчтүм Версачедан, кулында «Ролекс» сәгате... Ул гынамы, аның балалары чит илдә укый, акчасы чит ил банкларында саклана, утырган машинасы — иномарка... Иң мөһиме — аның бизнесы транснациональ корпорацияләр белән бәйле.

Үз мәнфәгате Ил Гаме белән кисешкәндә аның кайсысын өстен куячагы турында сүз куерту урынсыз.

«Патриотизм — адәм актыкларының соңгы сыену урыны», — дип бер акыл иясе шулар турында әйткән.

Ул кешеләрнең самими хисләренә ут төртеп, шул утны империя киңлекләренә җәелдерергә тели.

Бер күзәнәкле кешеләр мондый коткыга бирелә дә... Алар югары сәясәтнең мәкерле пәрәвезеннән хәбәрсез. Нәкъ менә Ватан тарафыннан кыерсытылган, җәберләнгән, һәр вак чиновник тарафыннан түбәнсетүдән бүтәнне күрмәгән бәндә патриот булырга тиеш! Чөнки ул шушы хис аркасында гына үзен чын кеше итеп тоя ала.

Гомер-гомергә шулай булган... Шакир Мөхәммәдевнең йөз ел элек язылган «Япон сугышы яки доброволец Батыргали ага» әсәрен генә искә төшерик. Япон сугышы башлангач, «Шушма башы» дигән патриотик гәҗитне укый-укый, Рәсәй өчен кан коярга хыялланган Батыргали агай «иң әүвәл үзенең залындагы көзге алдында торган Мәкәрҗәдә алган бик кыйммәтле һәм нәфис япон вазаларын идәнгә күтәреп бәрде». Шул ук көнне гәҗит Җомагыл исемле җитмеш яшьлек бер башкортның (Николаевский солдат!) алты улы белән сигез кызын ташлап, ирекле рәвештә Порт-Артурга сугышка китүен хәбәр итә: «Ай, яшьләр, и мөселманнар! Җомагыл картка карап гыйбрәт алыгыз!»

Нишләп Казан татары урыска тугрылыкта ниндидер башкорттан калышсын. «Бу хәбәрне укыганда, — дип яза автор, — Батыргали агайның тамырларындагы каннары кайнап, үзен-үзе белмәенчә гайрәтеннән йөрәге «дөп-дөп!» сикермәктә иде. Әгәр дә мөмкин булса, ягъни Порт-Артурга шул сәгатьтә алып барсаң, берничә минут кына әүвәл японнарның посудаларын кырган кулындагы таяк илә японнарның адмиралы Тогоның башын сугып ярырга әзер иде. Шулкадәр ватан мәхәббәте кузгалган иде».

Менә шулай патша вакытында ук безнең татарымызның патриотизм хисләрен кузгата белгәннәр. Хикәядә японнарга каршы сугышып кулын өздергән татар солдатының образы да бар. Ватан алдындагы бурычын үтәү турында нинди горурланып сөйли ул. Шуның өчен аның күкрәгенә Георгиевский крест та тагып куйганнар.

Октябрь фетнәсеннән соң бөекмәмләкәтчелек идеясе бераз тоныкланып, бөтендөнья революциясе шигаре өстенлек ала. Әлбәттә, бу бер үк медальнең икенче ягы гына. Дөнья белән идарә итәргә җыенганда Рәсәй патриотизмын байрак итеп күтәреп булмый ич. Ләкин икенче бөтендөнья сугышы башлангач, Сталин яңадан сыналган юлга кайтып төшә. Патриотизм дигән сүз астында урыс милләтчелеге ятканын бик яхшы белә ул. Яугирләр җилкәсенә янә погоннар куна, патша вакытында ук булган «Александр Невский» ордены янә гамәлгә куела, православие руханиларына өстенлекләр кире кайтарыла. Авыр сугышлар барганда Алма-Атада «Иван Грозный» фильмын төшереп яталар.

Бөек Җиңү хөрмәтенә уздырылган банкетта Сталин урыс халкы өчен тост күтәрә:

— Потому что он является наиболее выдающейся нацией из всех наций, входящих в состав Советского Союза.

Бөек юлбашчы шулай дигәчме?.. Хәтта урыс сүгенүе дә патриотик горурлык уята башлый, әлбәттә. Алай итеп бүтән бер халык та сүгенә алмый! Андый тел байлыгы башка беркемдә юк.

Шундый бөек халыкка читләрнең йогынтысы булырга мөмкин түгел. Хәтта моңарчы «Норд» дип аталган папиросны «Север» дип үзгәртәләр. Француз булкасы Мәскәүнеке дип атала башлый.

Ул гынамы, дөньядагы бөтен фәнни казанышларны урыс галимнәре уйлап тапканы ачыклана. Электр лампочкасын сез моңарчы Эдисон уйлап тапкан дип йөрдегезме? Шалиш! Яблочков уйлап тапкан аны. Хәер, татар совет шагыйрьләре «Ильич лампочкасы» дип язгач, мин — надан озак вакыт аны Ленин бабай үзе уйлап тапкан дип йөрдем. Ә самолет? Бертуган Райтларгамы соң андый казаныш?! Әлбәттә, Можайский — беренче конструктор. Пар машинасының да авторы Уатт түгел, үзебезнең Ползунов. Радионы да гамәлгә кертүче Маркони түгел... үзегез беләсез кем икәнен...

Яшьлегендә шигырьләр язган Сталин «иностранец» сүзенә уңышлы рифма таба: «засранец».

Хәерче халык үз ватаны белән горурланырга, чит илләрдәге халыкка өстән карарга тиеш хәзер.

Хәерче булмагае, ул бит — җиңүче!

Ватанны яратмасаң, рәхим ит — Колымага. Ватан киң, теләсә кайда сыйдыра ала.

«Германиядә халык әйбәт яши иде», — дип ычкындырган беркатлы фронтовикларны меңәрләп җыеп алалар.

Сталиннан соң да бездән гел ватанпәрвәрлек таләп иттеләр. Венгриягә бәреп кергәндә дә, «Прага язын» бастырганда да, Әфганстанда «интернациональ бурыч» үтәгәндә дә.

Хәзер дә шул сабакны укытырга телиләр.

Тик укытучылар кем соң?

Әнә тагын берсе телевизордан йодрык болгый. Үз телендә миңа акыл өйрәтә: «В России должен появиться свой православный Ватикан-государство с Патриархом Московским и Всея Руси во главе!» Шул чагында күңелемә үземнең шигырь юллары килә: «Иләмәннең биләмәсе бүген — туган тел ул. Минә минем Ватан. Соңгы көне булып сүреләм дә, өр-яңадан таңы булып атам».

*Ноябрь, 2006*

# НӘФЕС

Һәр кем куркса тәңредин ул ойалур,
Дөнйасыны биреб ул гокба* алур.

*Мөхәммәдьяр*

Нәфессез кеше булмыйдыр. Күрәсең, табигать безгә әлеге сыйфатны туганда ук бирә. Димәк, көн итәр, дөнья көтәр өчен ансыз булмый...

Берничә ел элек әни авылдан энекәшнең өч яшьлек кызын үзе белән кунакка алып килгән иде. Шундый мөлаем сабый. Тик шундый бер гадәте бар икән — гадәт — өч яшьтә! — күзе кызыккан вак-төяк әйберләрне букчасына җыя... «миңа!» дигән корт кергән. Кем өйрәткән аны моңа? Беркем дә... Нәфес.

Шушы хәлдән соң мин сабый балаларны ныграк күзәтә башладым. Ходаем! Сабыйлардан да эгоистрак җан иялəре юк икән җир йөзендә.

Нәфеслерәк...

Сез кибеткә бәләкәй, әле аңы ачылып бетмәгән балагызны ияртеп кергәнегез бармы? Ул һәрнәрсәгә нәни куллары суза, кибет киштәләрендәге һәрнәрсәне үзенеке итәсе килә! Алып бирмәсәң, акырып елый.

Әлбәттә, аң кергәч, алар мондый нәфесләреннән ояла башлыйлар. Нәфесләрен басалар.

Кеше булу — күңел төбендәге нәфесне басуда йә, һич булмаса, аны ачыктан-ачык күрсәтмәүдә күренә.

Кешелек мәдәниятен төрле чикләүләр хасил итә.

Әлбәттә, әлеге чикләүләр тәрбия белән килә. Балачагымда иң күп кабатланган сүз «ярамый!» иде.

Ярамый!

Тик бу сүз торган саен сирәгрәк ишетелә төсле.

Ф.Достоевский әйтмешли: «Если нет Бога, то все дозволено».

Уенчыклар кибетендә ун яшьләрдәге малае белән кергән бер хатынны күрдем беркөн. Малай зур бер уенчык ат каршында каткан да калган, Әйтәсе дә юк, матур уенчык — чын аттан аз гына кечерәк. Малай әнисенең җиңеннән тарткалый: алыйк та алыйк, ди. Башта аның тавышы ялвару-

---

* *Гокба* — теге дөнья рәхәте, ахирәт.

лы иде. Күренеп тора, анасының бу кадәр акчасы юк, ул да, кешегә сиздермәскә тырышып, улының чабуыннан тарта, кибеттән тизрәк чыгып китәсе килә. Әһе, тиз генә чыгарсың, бар... Ялварулы тавышның ярдәме тимәсен аңлагач, малайның күзенә зәһәр тулды. Ул инде атка ия буласы килүен кычкырып әйтә. Әйтерсең тирә-юньдә беркем юк! Ул да булмады, малай актыгы идәнгә ятып ауный башлады, кычкырып елыймы шунда — әллә нинди авазлар чыга...

Мондый күренешкә йөрәгем түзмәде — тизрәк ишеккә ашыктым.

Бу малайдан нинди кеше чыгар? Кеше... Кеше чыкмас инде, күренеп тора...

Ләкин аны да аңлап була. Аның атлы буласы килә! Шул максатка бару юлында ул теләсә нинди адым ясарга әзер. Тик әле аның мөмкинлекләре азрак: елау, ялвару, идәндә аунау, истерика... Тик бит үсә-үсә мөмкинлекләр арта барачак, ысуллар күбәячәк.

Андыйлардан Алла сакласын.

Хәер, калдырыйк балалар дөньясын...

Башны күтәребрәк карыйк.

Аңышмыйча да калганбыз, инде буй үстергән әлеге малайлар баскан икән бит дөньябызны. Шулар идарә итә икән ич җәмгыятебез белән дә...

Юк, алар хәзер нәрсәгәдер ирешер өчен истерикага бирелми, аларның йөзе тәвәккәл, күзләре — боз.

Светофорга — нигә карамыйча, океан артыннан килгән елгыр машиналарда алар үтеп киткән чакта, тизрәк юл читенә чыгып «Алла сакласын!»ны кабатларга гына кала безгә. Җилкә аша төкереп алырга...

Төкермичә тор әле! Син төкергән җир әлеге «дөнья хуҗалары»ның шәхси милеге булуы бар... күрсәтерләр күрмәгәнеңне...

Күрсәтәләр дә инде — күзләре төшкән һәрнәрсәне кул астына алалар, аяк астына салалар. Юк, мин аларны хурламыйм, аларның атамалары матур — бизнесменнар, инвесторлар, әллә кемнәр.

Йөзьяшәр елан юхага әйләнгән кебек, болардагы нәфес бик тиз арада сөмсезлеккә, комсызлыкка әверелгән.

Соңгы ун-унбиш елда моңа бөтен мөмкинлекләр дә булды.

Мин совет заманын сагынып еларга җыенмыйм. Ләкин

шул Алласыз режим вакытында да нәфеснең азынуына катгый чикләүләр бар иде.

Мин инде Сталин дәверендә бер кесә ашлык өчен унар елга төрмәгә утыртуларын — югыйсә ул ашлык нәфес колы булудан түгел, ачлыктан, мохтаҗлыктан кесәгә кергән — искә алмыйм. Бик күп нәфесләрне авызлыклый торган ОБХСС аббревиатурасын гына хәтергә төшерәсем килә.

Әйтмичә булмый — кешелек җәмгыятен тәртиптә тота торган бер генә көч бар — курку хисе. Кеше кулын җәеп хәрәмгә үрелгәндә дә Аллаһ ачуыннан, йә... гап-гади мәхкәмә (суд) хөкеменнән куркырга тиеш.

Хәләл көч белән — акыл көчен әйтәм, әлбәттә — берничә елда кайсы җәмгыятьтә миллиардер була аласың?

Шәхес иреге түгел, нәфес иреге булган илдә!

Болар барысы да иске хакыйкать. Кешеләрнең нәфесе азган заманнарны тарих күп белә. Безгә яхшы мәгълүм Рум империясен генә искә төшерик. Көч хокукы ярдәмендә бөтен байлык, дөнья рәхәте патрицийларга гына тәтегән. Әмма алар плебейларны да онытып бетермәгән. Бушлай ипи өләшкәннәр, тамаша күрсәткәннәр.

Икмәк һәм тамаша!

Хәзерге идарәчеләр дә моны әйбәт белә, күрәсең. Икмәкне бушлай өләшмәсәләр дә, арзанлы тамашаны телевизордан даими карап кинәнәбез. Сикерәләр, җырлыйлар, көлдерәләр. Үзебезнең мескен хәлне онытып эч катканчы көләбез.

Шунысы да бар: татар нәфесе бүтән халыкларныкыннан күпмедер аерыла да төсле. Безнең нәфесне җан иясенә охшатсаң, ул ваграк гәүдәле һәм әрсезрәк сыман. «Татар түрә булса, чабатасын түргә элә», «Татар ашар да качар» дигән мәкальләр бар бит әле. Чыннан да татар берәр түрәлек урынга тиенсә, тизрәк умырып калырга тырыша. Чаманы югалта. Кыскасы, бер көнлек мәнфәгать белән яши. Белмим, изелгән халык вәкилләре, бәлки, барысы да шундыйдыр. Югыйсә бит аларда бернинди милли төсмер юк. Ләкин коллык вирусы бик озак яшәүчән... буыннан буынга күчеп...

Казан ханлыгына караган чыганакларның күбесе юкка чыккан булса да, Аллага шөкер, Нугай морзаларының Мәскәү патшасына язган ярлыклары безнең көннәргә килеп җиткән. Менә Касай (Касыйм) морза үз ярлыгында Казанны урыслар алуга сөенечен белдерә дә, сөенгән өчен үзенә көбә, кеш тун сорый. Калган морзаларның да ярлыгы ни дә булса сорау белән тәмамлана. Бер-берсе белән ярыша-ярыша со-

раналар. Үзләре юк кына бәягә меңләгән сугыш атларын Мәскәүгә озата. Урыс гаскәре Казанны алырга нугай татарларының атына менеп килгән! Соңрак нугайларның үзләрен дә шул атларга утырып пыран-заран китергәннәр.

Кешенең нәфесе азса, ил язмышы онытыла.

Хәзерге байларның да төп малы чит ил банкларында сакланмыймыни? Балалары чит илләрдә укый, ул-бу була калса, үзләре дә шунда таярга әзер.

Нугай морзаларының балалары да бераздан Мәскәүгә күчә, чукына. Князь Юсуповлар, Урусовлар, тагын әллә кемнәр — шуларның токымы.

Хуш, без көнбатыштагы кебек рәхәт яшәргә теләдек. Юлбашчылар безгә бәхетле капитализм төзибез дип вәгъдә итте. Әмма ул капитализм, аннан элгәреге социализм кебек үк, беркемнекенә дә охшамаган булып чыкты.

Җен чүлмәктән чыкты,
Җеннең исеме нәфес иде.

Тик бөтен кешеләр дә бертөсле түгел. Самими, гади, шагыйранә кешеләр бар.

Алга — уртак дип аталган малны эләктереп калырга ыргылган әрсезләр артыннан өлгермәүче гариплләр бар.

Гарип күңелләләр бар.

Болар — әлбәттә, булдыксызлар.

Бүгенге булдыклыларга кирәкләре юк аларның. (Мин аларның байлыгын тәшкил итүче кара халык — эшче куллар турында сөйләмим, алар кирәксез кирәклеләр.) Дөрес, кырылалар, тик һаман бөтенләйгә юкка чыкмыйлар. Әнә затлы байлар кибетенең ишек төбендә каешланган бишмәт кигән бер карчык икмәк сатып алыр өчен акча теләнеп тора. Искәргәнегез бармы икән, хәерчеләр арасында нигәдер әбиләр күп... Ә кибеттән ыспай киемле егет сөяркәсе белән чыгып бара. Әбинең кыяфәте аның кәефен бозадыр. Хәер, белмим, ни-ни, әлеге «безнең заман геройлары»н сурәтләргә алынмыйм. Кем белә, хәерче әбине күргәч, үз-үзе алдында аның бәясе тагын да күтәреләдер: мин кем дә, бу бет кем? Шунысы хак: ул кесәсендә актарынып та тормый, чөнки анда доллар-лар төргәге. Ә хәерче әби долларның ни икәнен беләмени?

Сөяркәсе Парижга сәфәре турында сөйли, сөенеп көлә. Үтеп китәләр. Бөтенләй бүтән дөнья!

Ну алай ук ярамый бит инде. Ни дисәң дә, без бит мөселманнар. Пәйгамбәребез мохтаҗларга хәер бирергә кушкан.

Хәзерге байларның уена да килмәгән зәкят дигән фарыз да бар әле. Ягъни керемеңнең ничәдер процентын (процент дигәч, колагы тора, әлбәттә! тик үз ягына... үз ягына) савап-лы эшләргә тотарга... борынгы байлар кебек. Алар, юләрләр, зәкят үтибез дип мәдрәсәләр тоткан, гәҗит-журналлар, ки-таплар чыгарган. Шуны истә тотыптыр инде, Туфан ага Миңнуллин да әнә сыра корольләре Хәйруллиннарга мөрә-җәгать иткән бит: янәсе, әйдәгез, сәләтле татар балалары өчен махсус бер мәктәп, татар лицее ачыгыз әле, исемегез тарих-ларда яңгырар иде. Алар «исәр» язучыга бик гаҗәпләнеп караганнардыр. Нинди тарих?! Нинди мәктәп?! Хәзерге байларның девизы: «Здесь и сейчас!» Бәлки, гаҗәпләнмәгә-ннәрдер дә... Әдипнең ни әйткәнен аңламаганнардыр гына. Аларның башы бит бөтенләй башка нәрсәләргә көйләнгән.

Сөякнең җелеген суырганда, сарыкның язмышы турын-да кем уйлана?

Алай да бу елны хәйрия елы дип игълан иттеләр әле. Дәүләт исәбеннән хәер бүленгәндә, бәлки, хәерчеләргә дә өлеш чыгар...

Беләм, беләм, шушы язманы укыгач, мине берьяклылык-та гаепләүчеләр дә булыр. Безнең байлар арасында ярдәм-чел, шәфкатьле кешеләр дә бар, диярләр. Бигрәк тә нинди-дер юллар белән үзләре хәер алган кешеләрнең ачуы килер. Байлар өстәленнән ризыкка тиенү өчен дә өстәмә сәләт, әрсезлек кирәк. Бу — үзе дә бер булдыклылык, мөгаен.

Бардыр, бардыр, ярдәмчел, шәфкатьле байлар да бардыр... ил кадәр илдә. Андыйлар белән таныш кешеләргә сокла-нырга гына кала.

Әбиемнең дога кылганнан соң бердәнбер теләге бар иде: «Ходаем, соранырга язмасын»...

*Апрель, 2007*

# МИРАС

Француз язучысы Шарль Монтескьеның XVIII гасыр башында язылган «Фарсы хатлары» дигән әсәрендәге та-тарларга кагылышлы сүзләрне күпләр хәтерлидер: «Бу җиңүчән халыкның гаҗәеп батырлыкларын данга күмәргә тарихчылары булмаган. Күпме үлемсез казанышлары оны-тылырга дучар ителгән. Татарлар тарафыннан без белмәгән күпме мәмләкәтләргә нигез салынган! Бу гаярь халык, бер-

кайчан да җиңелмәсенә ышанган хәлдә, вакытлы дан белән мавыгып, үзенең үткәндәге җиңүләрен мәңгеләштерү турында уйлап та карамаган».

Бу юлларны укыганда чын татарның йөрәге кысылмый калмас! Сүз бит безнең бөек үткәнебез, сибелеп, таралып беткән мирасыбыз турында...

Әлбәттә, шул олуглыкны, бөеклекне, шаккатмалы казанышларны килер буыннарга — безгә! — тапшырырга хәлләреннән килмәгән бабаларыбызга дәгъва да белдерергә мөмкин. «Вакытлы дан белән мавыгып», күзләренә ак-кара күренмичә үзара алышкан, киләчәккә үрелеп карардай җитәкчеләре булмаган... Ләкин үткәннәргә үпкәләп утырудан ни файда?

Инде дәүләтләре пыран-заран килгәч, яшәүләре шик астына куелгач, алар барыбер исән калу юлларын тапкан бит... Шуңа да рәхмәт! Югыйсә без булмас идек... Үзебез дә әллә кем түгел. «Татар» дигән авыр чылбырның бер буыны була алырбызмы? Әллә ул чылбыр бездә өзелеп калырмы?

Өзелмәсә, килер буыннарның дәгъвасы безгә нинди булыр? Каһәрләмәсләрме?

Мираска мөнәсәбәттә элгәреләребездән бик ерак китмәгәнбез ләбаса.

Милли язмышыбызга битарафлыкны гына мирас итеп без тулаем үзләштергәнбез, мөгаен.

Үз мирасыбызга лаеклы варис була алмасак, аңа бүтәннәр тиенер. Аны төрле яктан йолыккалыйлар да инде.

Дәүләте вәйран булып, татарга җир өстендә көн беткәч, үткән бөеклегенең шәүләсе җир астында калган әле. «Кара археологлар», курган казучылар җир астындагы күпме хәзинәне таратып бетерсә дә, алар һаман табыла тора.

Ә бит безнең эзебезне дә тәмам юкка чыгару җәһәтеннән махсус шөгыльләнгәннәр!

1893 елда археолог А.Спицын иске Әстерхан (Хаҗи-Тархан) туфрагына аяк басканда, аның мәдәни катламын пыран-заран китергән булалар инде. Шул тирәдә яшәүче урыс крестьяннарыннан ул Алтын Урдада сугылган 240 акча сатып ала.

Алтын Урданың Бәлҗиман шәһәре хәзерге Саратов өлкәсенең Дубовка поселогы тирәсендә урнашкан була. Археолог Ф.Баллодның язуынча, әле 1915 елда гына аның хәрабәләреннән 15 мең пот сөяк, 92 йөк кирпеч, 100 пот бакыр әйберләр, 150 пот тимер-томыр, 11 пот кургаш чыгарыла. Гасырлар буена күпме таланганнан соң!

Үзебезнең Болгар, Биләр җирләрендә табылып, дөньяга таралган хәзинәләр турында мин инде сүз куертып тормыйм.

Шулай да алар һаман табылып тора! Күптән түгел генә телевидение 1986 елда табылган Каратун (Апас районы) хәзинәсе турында сюжет күрсәтте. Алтын Урдада сугылган йөзләгән тәңкә (16 кг) археологик экспедиция җитәкчесенең өендә сакланган да, аны милиция ярдәмендә милли музейга кайтарганнар, имеш. Хәбәрче, авыз суларын китереп ,аның бүгенге бәясен дә тамашачыга җиткерде — хәзинә хәзер 50 мең доллар тора икән... Әйтерсең тарихчы галимебез аны сатарга җыенганда тотылган...

Ә уйлап баксаң, әлеге хәзинәне егерме ел исән-имин саклавы өчен галимгә рәхмәт кенә әйтергә кирәктер! Бу табылдыкның барлыгы, кемдә саклануы тарихчылар өчен сер түгел иде бит. Күрәсең, нәкъ менә хәзер кемнәргәдер галимнең исеменә күләгә төшерергә кирәк булган.

Урлашу милли бер сыйфатка әверелгән чорда хәзинәләрнең музейда саклану шартларына ышанып бетмәү дә табигый. Былтыр Эрмитажның үзеннән йөзләгән тарихи әйбернең урлануы (үз хезмәткәрләре тарафыннан!) хакында бөтен дөнья шаулады.

Каратун хәзинәсенең музейда юклыгын нигә егерме елдан соң гына исләренә төшергәннәр? Ә бүтән мәгълүм хәзинәләр? Сакланамы алар бүген музейда?

Галимҗан Ибраһимовның томнарын актарып утырганда мин мондый мәгълүматка юлыктым: «Якын арада Казанның Үзәк Музәханәсенә XIV йөздән калган борынгы алтын әйберләрне куйдылар, — дип яза әдип. — Болар үткән ел (ягъни 1924 елда. — *Р.З.*) Чистай өязендә Танаур авылы янында Палатников дигән крәстиян тарафыннан табылганнар. Бу хәзинә табылган җирдә борынгы заманда болгарларның «Җүкәтау» исемендә шәһәрләре булган. Бу әйберләр шуннан калганнар. Табылганнар арасында — ике алтын динар (1340 елныкы), дүрт алтын беләзек, сөрмә савыты, кечкенә футляр, дүрт кыйммәтле таш, йөз җитмеш дүрт энҗе һәм тагы шундый кайбер нәрсәләр. Болар һәммәсе бик матур, кыйммәтле эшләнгәннәр. Беләзекләрдә гарәп хәрефе белән, ләкин ноктасыз язулар бар. Хәзергә чаклы боларны укый алмадылар әле».

Әлеге хәзинә турында мин үземә таныш тарихчылардан сораштырып карасам да, алар берни дә әйтә алмады. Урта гасырлар тарихына караган хезмәтләрдә дә Җүкәтау хәзи-

нәсе хакында мәгълүмат тапмадым. Бәлки, ул кыйммәтле табылдыклар музей запасникларында ятадыр?

Кашки... Мондый зиннәтләрнең тарихчылар күз уңыннан читтә калуына ышанасы килми. Исән микән алар, сакланганмы? Беләзекләрдәге нинди сүзләр безгә ирешми калды икән?

Музейлардагы мирасыбызны нинди белгечләр барлап тора? Югыйсә милли дип аталган музейның төп байлыгы булып Әби патшаның каретасы санала алмый... һич тә...

Сүз дә юк, андый хәзинәләр — милли мирас! — Г.Ибраһимов әйтмешли, музәханәләрдә сакланырга тиеш... һичшиксез. Ун еллар элгәре Болгар чорыннан калган затлы сырганың нииндидер Мәскәү аукционына куелуы билгеле булып, җәмәгатьчелек бер шаулап алган иде. Аны да иң әүвәл бер мәшһүр археолог өйдәге сейфында саклаган, имеш. Ул вафат булгач, варислары, әлбәттә, аны сатарга булган. Кире кайтара алдылармы икән тарихыбыз кыйпылчыгын? Юктыр, юктыр...

Күз уңында пәйда булып та, шулай юкка чыккан — миллэтебез өчен бөтенләй югалган! — хәзинәләрнең исәбе-хисабы юк.

Ә бит алар арасында бик тә гыйбрәтлеләре, тарихыбызны бөтенләй икенче яктан ача торганнары да булган.

«Тузга язмаганны сөйләмә» дигән халык мәкален һәркем белә. Мәкаль бит юкка гына барлыкка килми. Димәк, кайчандыр элгәреләребез тузга да язган?

Борынгы Новгород урысларының тузга язулары тарихчыларга билгеле. Археологик эзләнүләр вакытында анда йөзләгән язулы каен тузы табылган. Новгородның туфрагы шундый хикмәтле, имеш, тузлар анда череми-таркалмый имин килеш сакланган.

Безнең тупракның андый үзенчәлеге юк, мөгаен... Тузга язу турындагы хәбәр мәкаль аша гына килеп җиткән.

Сүзнең кодрәтенә рәхмәт! Тукай әйтмешли, аны туплар да вата алмый, ул утта да янмый...

Тик «Татар тотып карамыйча ышанмый» дигән мәкаль дә бар бит әле.

Әйе, табылган бездә дә язулы тузлар. Кемнәрдер аны тотып та караган...

1930 елда, Саратов өлкәсенең Терновка авылында бульдозер көрәгенә эләгеп бер сандык килеп чыга. Сандык калын имән такталардан ясалган, сум тимердән ике коршау белән уратылган, зур йозакка бикләнгән була.

Табучыларны күз алдына китерәм мин! Алар инде сан-

дык алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән белән шыплап тулган дип сөенгәннәрдер, бичаралар. Хәер... шулай булса да әлеге байлык үзләренә тәтемәс иде. Утызынчы ел! Хәбәр кенесәгате белән тиешле органнарга барып җитә.

Йозакны көч-хәл белән кисәләр. Сандык эчендә нәрсә күргәннәр дисез инде? Бозау тиресе белән тышланган, битләре туздан булган китап... Сүгенгәннәрдер, әлбәттә, чекистлар... сүккәннәрдер борынгы мәгънәсез татарларны. Кем инде шундый нык сандыкка китапише пүчтәк нәрсә бикләп калдыра?

Хәер, китап янында алтын тәңкәләрнең дә булуы ихтимал. Чекистларның бер гаепсез кешеләрне кулга алганда да, өйдәге кыйммәтле әйберләрне үзләштергәнен хәзер яхшы беләбез.

Ә туз китап аларга нәрсәгә? Ярый, рәхмәт, галимнәргә тапшырганнар, мәсхәрәләп аяк астына ташламаганнар...

Н.Н.Поппе дигән галим 1941 елда шушы табылдык турында бердәнбер хезмәт нәшер итә: «Золотоордынская рукопись на бересте». Ул әлеге китапны XIV гасыр ядкяре дип хисаплый. Галим уйгур хәрефләре белән язылган әлеге китапның аерым сүзләрен генә укый алган. Мәсәлән: Төгәл Котлыг (кеше исеме), көлгән, килмәсен, углан, чикмән, угыз, тархан... Китапның эчтәлеге турында фикер йөртеп булмаса да, аның татар телендә язылуы шик уятмый.

Гасырлар дәвамында җир астында килеш тә зыян-зәүрәт күрмәгән сандыкта, әлбәттә, юк-бар нәрсә язылган китапны сакламаганнардыр. Әлеге тузлар шул чорның мөһим документы булса кирәк...

Сум тимер белән коршауланган сандык үзе дә теләсә нинди музейны бизәрлек гаҗәеп экспонат түгелмени?

Ләкин... ләкин... Хәсрәтле Дәрдемәнд кебек «Дәригъ, мәхзүн күңел...» — дип кабатларга туры килә... инде ничәнче кат...

Күренекле галимебез Марсель Әхмәтҗанов яза: «Борынгы татар шәһәре Увәк янында табылган тузга язылган китап — милли мәдәниятебезнең уникаль сәхифәсе ул. Килер вакыт, татар угыллары аны соңгы иҗегенә кадәр өйрәнеп чыгарлар әле. Ни үкенеч, бүген бу ядкяребез белән кызыксынган кеше түгел, аның кайдалыгын белүче дә юк».

Бу сүзләргә ни өстисең? Галимнең оптимизмына кушыласы килә, әлбәттә: «соңгы иҗегенә кадәр өйрәнеп чыгарлар әле». Тик соңгы җөмлә әлеге өметне бөтенләй җимереп ташлый түгелме?

Исән микән тузга язылган әлеге уникаль сәхифәләр? Туз

кебек нәзберек әйберне, көн күзенә чыкканнан соң, исән-имин саклау өчен аерым шартлар кирәк. Андый шартларда сакланса, тарихчы галимнәребезнең бу хакта мәгълүматы булмас идеме?

Әлеге язмада мин җир астыннан чыккан хәзинәләр турында гына борчулы уйларым белән уртаклаштым. Әмма сүз ахырында җир өстендәге язма мирасыбыз турында да әйтмәсәм, фикерем тулы булмас кебек.

Әлегә җир өстендәге язма мирасыбыз... Мәгълүм ки, коммунистлар хакимияте вакытында төрле төбәкләрдә бик күп кулъязма китаплар ияләре белән аңлы рәвештә кабергә күмелгән. «Сулавы шундый иркен» булган илдә пыран-заран килеп хәкарәтләнмәсен өчен «иске» язуны танымаган варислар шулай кадерләп җирләгән аларны. Чып-чын инкыйраз дәвере. Үз бәхетсезлеген аңламаган бичара иләт!

Уйласаң, бәлки, ул кулъязмаларның язмышы бәхетледер дә әле. Аларны, җан ияләре кебек, ясин чыгып кадерләп ләхеткә төшергәннәр бит...

Ә күпме татар совет язучысының кулъязмалары чекистлар табаны астында, әбрәкәйләрдә, буржуйка мичләрендә юкка чыккан...

Бу очракта әле, һич югы, Сталин репрессияләрен ләгънәтләп була...

Ә хәзер? Мондый мисалларны да беләбез: язучы вафат була, ә аның татарча белмәгән балаларына, оныкларына өйне чүпләп торган ниндидер кәгазьләр нигә кирәк? Аларның урыны чүплектә!

Кайчакта көфер уй да килә: үз балаларын шулай тәрбияләгән (дөресрәге, тәрбияләмәгән) каләм иясенең язма мирасы шулай юкка чыгарга лаектыр да, бәлки? Үз баласы да укымагач, нигә аның язганнарын кайдадыр Никтудым авылында яшәүче Гайнетдин яисә Казанда «интеллигент» булып эшләүче Альберт Марленович укырга тиеш әле?

Әмма бу рәвешле үз милләтенең киләчәгенә ышанмаган кеше генә фикерли ала. Мәдәниятле илләрдә күренекле кешеләрнең үз кулы белән язылган бер кәгазь кисәге дә зур кыйммәткә ия...

Безгә кичекмәстән татар әдәбияты музее оештырырга вакыт җиткән, минемчә. Бу мәсьәләдә, һич югы, чуашлардан үрнәк алырга мөмкин...

Әдәбиятыбызның бүгенге хәленә күз салсаң, киләчәген күзалласаң, музейның кирәклеген тагын да ныграк аңлыйсың...

Мәдәниятле илләрдә...

Нигә алай ерак китәргә, без сүгә-сүгә яраткан Рәсәйгә генә күз салыйк. Әле күптән түгел чит илдәге кайсыдыр аукционнан А.Чеховның артык әһәмияткә ия булмаган берничә хатын зур суммага сатып алдылар.

Ә без… Тагын әрнеп Монтескьеның сүзләрен кабатлыйм: «Күпме үлемсез казанышлары онытылырга дучар ителгән». Бөек французның әлеге сүзләренннән соң өч йөз елга якын вакыт үткән — без һаман шул!

Вакытлы дан үткән дә, борынгы җиңүләр генә күптән хәтердән җуелган…

*Май, 2007*

# ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ

Ә батырлык?
Ә батырлык — ансы соңыннан.

*М.Әгъләм*

Җәлил… Җәлилчеләр…

Еллар инде аларны бездән һаман ерагайта бара… сурәтләре тоныклана. Башларын фашист балтасы астына куюларына да алтмыш елдан артык вакыт үткән. Нәкъ шул көнне — 25 августта — бер төркем зыялылар Җәлил һәйкәле янына җыела. Искә алабыз.

Кемнәрнеңдер ачуы да килә: «Күпме шул сугыш турында сөйләргә була инде!»

Җәлилнең батырлыгын шик астына алучылар да бар. Өстәмә дәлилләр таләп итүчеләр… Хәзер бит барыбыз да акыллы, барыбыз да белемле. Тик батырлыкны кулга тотып карап буламыни?

Җәлилчеләрне империя суды рейхның иминлеген какшатуда, герман армиясен таркатуда гаепли. Һәм үлем җәзасына хөкем итә.

Мич башында яткан өчен үлемгә хөкем итмиләр.

«Җәлилчеләрнең башлыгы Муса түгел, ә Курмаш», — дип язып чыгучылар да булды.

«Җәлил әле дә исән икән, кайдадыр Латин Америкасында яшәп ята, имеш», — дип сөйләнүчеләрне дә ишеттек.

Мондый яла ягулар, нахак сүзләр Җәлилнең аянычлы

үлеменнән бирле сөйрәлеп килә. Искә төшерик, сугыштан соң ук аны ватанга хыянәт итүдә гаеплиләр — тагын гаеп! — китапларын юкка чыгаралар.

Шагыйрьнең якты исемен дөньяга чыгаруда иң беренче адымнарны дуслары ясый. Әйе, яхшы кешенең дошманнары гына түгел, дуслары да күп була.

Бүген Җәлил исеме тирәсендә тел чайкауларның төбендә бер генә сәбәп ята, минемчә. Безнең замандашыбыз аның искиткеч фидакяр батырлыгын башына сыйдыра алмый!

Альтруизм, ниндидер идея яисә ил-ватан хакына гомерне корбан итү бүген көлке гамәл булып тоела. Ул гына да түгел, андый батырларның булуына гавам хәзер ышанмый да!

Һәркем үзен генә кайгыртканда, акча хакына ата — улны, ана кызны белмәгән заманда, андый батырлыкларга урын юк, күрәсең.

Хәзерге күзлектән караганда — ә без шундый күзлек кигәнебезне сизмичә дә калганбыз! — Җәлилгә һәм аның иптәшләренә ни җитмәгән? Алар Германия буйлап иректә хәрәкәт иткәннәр, татарча газета-журналлар, китаплар чыгарганнар, татар легионының хәтта ял йортлары, пансионатлары булган. Шундый рәхәт тормышта ниндидер яшерен оешма төзү, режимга каршы көрәшеп маташу, йә, сабыйлык түгелме?

Җәлилчеләр батырлыгының серен аңлар өчен, минемчә, Шагыйрьнең (җәлилчеләрнең күбесе азмы-күпме шагыйрь булган) кешелек сыйфатларына төшенергә кирәк. Шагыйрь өчен Намус, Иман, Вәгъдә, Ватан һич тә коры сүзләр түгел, шул сыйфатларны югалтса, ул шагыйрьлеген, димәк, үз асылын җуя. Ә үз асылыңны югалту — җисми үлемнән яманрак.

Әлбәттә, Җәлил Сталин режимының дәһшәтен дә, аның халкыбызга нинди афәтләр алып килгәнен дә белгән. Ләкин Идел-Урал буе — аның Ватаны, анда халкы... ул икенче бер илбасар чабуына тотынып аңа каршы бара аламы? Гитлерның да милли легионнар төзеп (ничарадан бичара) уен гына уйнавы аңа сер булмаган, билгеле.

Шулай да мин аның батырлыгын сәяси вазгыятькә бәйләп түгел, ә нәкъ менә күңел тибрәнешләре белән, чын кешедә бернинди шартларда да җуелмый торган гап-гади сыйфатлар белән аңлатырга телим.

Ул бит салкын акыллы сәясәтче — стратег та (хәер, алар андый батырлык кыла алыр иде микән?), дуамал, кыю яугир дә булмаган.

Ул — Шагыйрь.

Хәзер аның шигырьләрен «уртача» дип бәяләүчеләр дә бар. Кемгәдер шулай тоела икән, аның эше. Ләкин Шагыйрьлек һөнәр түгел, ул — Язмыш. Кайчакта шигърияттнең бөеклеге сәнгатьлелек ягыннан түгел, нинди шартларда язылу белән бәяләнә.

Җәлил үзенең даны өчен баш бәясе белән түләде. Һәм бу данны үлчәгәндә бүтән бизмән белән якын килеп булмый.

Совет елларында Җәлил белән төрмәдә яткан итальян Р.Ланфридининың «Татарлар елмаеп үлделәр...» дигән сүзен әләм итеп күтәреп күпме шигырьләр, җырлар язылды. Шыпырт кына ул сүзләрдән дә көлүчеләр бар иде. «Үлем алдыннан идиотлар гына елмая», янәсе. Менә җәлилчеләр белән Корьән тотып хушлашкан Госман мулланың истәлеге чыкты. Ул анда Алишның Корьәнгә кулын салып елап җибәрүе турында яза. Моңардан да усал көлүчеләр табылды. Шуңа да бу урында мин Илдар Юзинең бөек дүртьюллыгын күчерәсем килә:

Киткән алар — бу дәһшәткә
Түзәргә кирәк ничек? —
Читләр алдында — елмаеп,
Корьән алдында үксеп...

Иманым камил — Җәлил бервакытта да эчтән дини иманын югалтмаган кеше. Сталин репрессиясе елларында аның бер тапкыр да каләмдәшләре өстеннән донос язмавын (белгечләр шулай раслый) — ә бит ул заманда бик азларның гына кулы чиста калган! — Язучылар союзын җитәкләгәч, 1939 елда бугай, татар язучыларының матди яктан авыр хәлен җиткереп Сталинга хат юллавын бүтәнчә ничек аңлатасың?! Кеше бер-берен ашаган заманда да нәкъ менә дини өндәмәләр: кеше хәленә керү, кеше күз яшеннән курку! — аның күңел түрендә торган.

Истәлек авторлары аның тыйнак холыклы, саф күңелле, тиз ышанучан булуы турында яза. Җәлилне искә төшереп язучылар шактый. Моңарчы татар укучысына билгеле булмаганнары да бар.

Җәлил хакында җылы сүзләрне мин урыс язучысы — шулай ук бөек тоткын! — Варлам Шаламовның «Егерменче еллар» дигән истәлекләрендә, «Идегәй»не һәм бик күп татар шагыйрьләрен урысчага тәрҗемә иткән, шуның өчен Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә ия булган Семен Липкинның бер чыгышында таптым.

Әлеге хатирәләрне укучыга тәкъдим итәр алдыннан В.Шаламов турында берничә сүз әйтмичә ярамастыр.

Күптән түгел Мәскәү телевидениесе аның әсәрләре нигезендә төшерелгән «Завещание Ленина» дигән фильм күрсәтте. Атаклы «Колыма хикәяләре»н укымаучылар да шушы фильм аша әлеге язучының сынмас рухлы, көчле иманлы кеше булуына ышангандыр, мөгаен. Егерме елдан артык коммунистлар каторгасында җәфа чигеп тә асылын югалтмаган шушы шәхес белән безнең Җәлилнең егерменче елларда ук юллары кисешүе (хәтта Мәскәү университетының тулай торагында бер бүлмәдә яшәп алганнар) үзе үк символик мәгънәгә ия...

Варлам Шаламов: «Тулай торактагы бүлмәбездә консерваториянең виолончель классында укучы студентның ятагы бушап калды. Виолончель бүлмәдә түбән тоннардагы автомобиль сиренасы кебек яңгырый иде. Безгә ул дәрес әзерләргә комачаулый, һәм без музыкантның, ниһаять, консерватория тулай торагында урын алуына сөендек.

Яңа бүлмәдәшебез кечкенә буйлы, төз, сыгылмалы гәүдәле, урыс телен начар белүче татар егете иде. Кичләрен, бүлмәдә яшәүче биш кешенең һәрберсе китап һәм конспектларга каплангач, беркемгә дә кычкырып сөйләшергә ярамый иде, яңа бүлмәдәш исә караватка куен дәфтәрләрен тезеп сала да кулларын селти-селти нидер үзалдына пышылдый башлый. Бу егет Муса Җәлилов иде, булачак Җәлил. Бераздан аңа барыбыз да күнектек, еш кына шигырь укуын да, урысча, әлбәттә, үтенә идек. Җәлилов ялындырмый, бик теләп Пушкинны укый, тик басымнарда һәм әйтелештә ялгышкалый иде:

Сижу за решэткой в темнице сирой...

— Пушкин! Яхшы! Хәзер менә монысын тыңлагыз! — Җәлилов яңа шигырь укый, күзләре җемелдәп китә.

— Монысы синекеме, Муса?

— Әйе.

Кемнең өлешенә нинди сынаулар тиясен егерменче елларда әле әйтеп булмый иде.

Яңа дустым белән, вакытны аңларга һәм анда үз урынымны табарга теләп, «Мәскәүнең бормалы урамнарыннан» бер генә төн атламаганмындыр мин. Урамнар буйлап шигырь уку теләге генә йөртмәде безне. Без хәрәкәт итәргә, яшәргә теләдек».

Семен Липкин:

«Мин аны күптән, 1930 елдан ук беләидем. Һәм, дөресен

әйткәндә, беркайчан да (югыйсә без аның белән, аеруча мин аның «Джим» поэмасын тәрҗемә иткәндә еш очраша идек), бу кеше киләчәктә каһарман булыр, дигән уй башыма килеп тә карамады. Ул шат күңелле, кечкенә буйлы. Ләкин үз буеннан озынрак тоела, чөнки ул төз, сылу гәүдәле. Җырларга ярата, күп җырлар белә. Аннан соң матбугатта үз әсәрләрен чыгару җәһәтеннән ул бик тыйнак, соңыннан үзләрен берни белән дә күрсәтә алмаган бәндәләр аны узып китә. Мәскәүдә яшәү чорында ул, минемчә, урыс телендә бер генә китап нәшер итә алды. Матбугат йортларында үз мәнфәгатьләрен яклый алмаса да, соңыннан ул фидакярләрчә Ватан мәнфәгатен яклады.

Тагын бер вакыйга исемә төшә. Без аның өенә кайтып барабыз — ул Столешников тыкрыгында яши иде. Юлда «Тормышка путевка» фильмында Мостафа ролен уйнаучы артист очрады. Һәм бу артист бик затлы (безнең белән чагыштырганда бигрәк тә) киенгән иде. Затлы киенүе бер хәл, кулына көмеш саплы таяк та тоткан. Шул таягын тоткан килеш бик вәкарь белән атлый. Без Кузнецки күпергә килеп җиткәч, каршыга трамвай килеп чыкты. Һәм әлеге артист таягын күтәргәч, трамвай кинәт туктады. Вагон йөртүче, димәк, бу кешене шулай хөрмәт иткән. Муса соңрак әйтте: «Менә мин болай булдыра алмыйм». Һәм өстәде: «Ләкин бу бит бик вак бәхет». Мин шушы гыйбарәне аның Моабит төрмәсендә язылган шигыреннән таптым. Һәм уйладым: «Соңыннан батырлыкка әвереләсе сыйфатлар аңарда шул вакытларда ук өлгерә башлагандыр».

*Июнь, 2007*

## ЯГЕЗ, БЕР ЧУКЫНЫЙК?

Патриарх Алексий II Аурупа шурасының Парламент ассамблеясында чыгыш ясаган! Мәскәүнең телевидение каналлары, радио, газеталар берничә көн дәвамында шул турыда шау килде. Патриархны дәүләт җитәкчесе кимәлендә кабул иткәннәр! Без сөенергә тиешле бу хәбәрне җиткергәндә, дикторларның горурланудан тавышы калтырады хәтта... Һәр мәсьәләнең төбенә тоз коючылар сорарга да мөмкин: «Нигә әле дин әһелен дәүләт башлыгын хөрмәтләү турындагы протокол нигезендә кабул итәләр?» Диктор сөенче алуын дәвам

итә: моңарчы мондый хөрмәткә дин әһелләреннән Рум папасы гына лаек булган икән. «Туктагыз әле, дияр «тоз коючы», — дикторның туктарга исәбе юк, әлбәттә, — Рум папасы бит ул бер үк вакытта Ватикан дәүләтенең башлыгы да. Ә безнең Русия дөньяви дәүләт санала түгелме соң?»

Саналса ни... Тукай әйтмешли, шигырь башка, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка...

Ә «тоз коючы» һич тынычлана алмый, Рәсәйнең төп Кануны, ягъни Конституциясе буенча, ди... Буенча, буенча... без нәрсәдер буенча моннан 27 ел элек коммунизмга да шуып керергә тиеш идек. Ә ул һаман минем борын төбенә Конституцияне суза. Укыйм: «Маддә 14.1. Россия Федерациясе — дөньяви дәүләт. Бер генә дин дә дәүләтнеке яки мәҗбүри дип игълан ителә алмый. 2. Дини оешмалар дәүләттән аерылган һәм закон каршында бертигез».

Әйе, акка кара белән язылган.

Тагын бер тапкыр кычкырып укыйм.

Ләкин телевизор мине ишетми. Аның шундый сәер гадәте бар.

Менә экранда митрополит Кирилл пәйда була. Кара син кыяфәтен... үз-үзен тотышын... Теле телгә йокмый. Алексий алай-болай җан тәслим кылса, — нишлисең, патшалар да үлә, — аның патриарх тәхетенә шушы Кириллны күтәрәчәкләр, дип юкка гына гөман итмиләрдер урыс сәясмәннәре. Тыңлавы рәхәт шушы попларны, валлаһи газим. Караганда күз ял итә: бигрәк сымбат гәүдәләләр, бигрәк кибарәнә чырайлылар. Ә ничек сөйлиләр, ничек сөйлиләр, шайтан алгыры — денсез кешенең өч бармагы берләшеп маңгайга кунып алырга кыҗрый башлыйдыр... Хәер, бу юлы Кирилл бөтенләй бүтәнчә сайрый. Тәрҗемәсез генә күчерәм: «Усиливающаяся нестабильность мировой финансовой системы требует от России выработать собственную логику валютно-денежных отношений, чтобы серьезные изменения на мировом финансовом рынке не обернулись глубоким кризисом отечественной экономики».

Яңа гына министр итеп куелган Эльвира Нәбиуллина сөйли, диярсең. Чыннан да дәүләт эшлеклесенең чыгышын хәтерләтә бит. Шуңа күрә мин аны татарчага тәрҗемә итеп тормадым да. Чөнки бездә дәүләт эшлеклесенең трибунадан татарча сөйләвен күз алдына да китерүе кыен.

Аурупа шурасында Патриархтан православиене мәктәпләрдә укыту мәсьәләсенә дә мөнәсәбәтен сорадылар. Югыйсә

аның нинди фикердә булуын бездә кем белми. Чит илләрдә дә белергә телиләр, күрәсең. Православие нигезләре гомуми мәктәпләрдә укытылырга тиеш, дип җавап бирде ул. Нинди динне өйрәнү-өйрәнмәү мәсьәләсен бала үзе хәл итсен, янәсе. Мондый мантыйк белән еракка китеп була. Бала ихтыярына куйсаң... әнә минем малай математиканы укырга теләми. Урыс телен дә өнәп бетерми, ташбаш!

Бала ихтыяры дигән сафсатаны ишеткәч, мин һәрвакыт бәхетсез Үтәмешне искә төшерәм. Мәгълүм булганча, Казанның Гәрәйләр нәселеннән булган әлеге соңгы ханын 1551 елда әнисе белән Мәскәү кулына бирәләр. Ә бер елдан, Казан алынгач, аны, әнисеннән тартып алып, «үз теләге белән» чукындыралар. Александр исеме тагылган сабыйга җиде яшь тә тулмаган була.

Бер диннән дә хәбәрсез хәзерге сабыйларның башларын, дәүләт кодрәтен җиккәндә, теләсә кайсы якка борып куеп була! Аларның бит әле ата-аналары гына түгел, әби-бабалары да дәһри дәүләттә туып үскән, атеистик тәрбия алган кешеләр.

Православие диненең әһелләре бу турыда бик яхшы белә, әлбәттә. Аларның максаты урта гасырлардагыча — Рәсәйдәге барлык инородецларны чукындыру. Һәм алар бу максатны бик яшереп тә маташмыйлар. Ислам дине әһелләре аларга көндәш була алмый.

Дөрес, православиенең дәүләт диненә әверелә баруын күреп борчылучылар бар. Ун академик бу турыда хат белән РФ Президентына да мөрәҗәгать итте. Шуннан соң нәрсә булды, дисезме? Бөтен гаммәви мәгълүмат чараларында диярлек әлеге атаклы галимнәрне хәкарәтли башладылар. Бер юаныч бар: бер төркем мөселман эшлеклеләре әлеге галимнәрне, атеистик карашларын уртаклашмаган хәлдә яклап чыкты. Хатка кул куючылар арасында Мөфтиләр шурасы рәистәше Нәфыйгулла Аширов та бар иде. Шуннан соң шовинистик көчләрнең уклары гел аның башына яуды. «Мөселман руханиларына мин күптән «На фиг такого Нафигуллу» дигән шигарь белән чыгарга тәкъдим итәм», — диде урыс миссионеры диакон Андрей Кураев бер әңгәмәсендә.

Христиан руханиларының исемнәрен без дә үзебезчә шул рәвешле төрләндерсәк, урысларның моңа мөнәсәбәте нинди булыр иде икән? Ә без нәрсә... исебез дә китмәде!

Сүз дә юк, зыялы кеше, үзе динсез булган хәлдә дә, бүтәннәрнең вөҗдан ирегенә хөрмәт белән карарга тиеш.

Христиан балаларына православие нигезләрен өйрәтергә

телиләр икән, өйрәтсеннәр, Алла хакы өчен. Ул чакта, балаларның традицион рәвештә нинди динд булуларына карап, мәктәпләрне аерырга кирәк. Бер дин дә явызлыкка өндәми. Бары тик явызлар үз мәнфәгатьләрендә аны корал итеп кенә файдаланмасын.

Бик җайлы бит югыйсә — монда урыс мәктәбе, православие нигезләрен өйрәнәләр, анда татар мәктәбе, мөселман диненнән сабак алалар.

Юк шул, христиан дине әһелләре мондый бүленешкә риза түгел! Чөнки, диләр алар, ОПК («Основы православной культуры») әле ул «Закон Божий» түгел. Октябрь түнтәрелешенә кадәр Русиянең барлык дөньяви мәктәпләрендә дә «Закон Божий» дәресләренең укытылуын беләбез. Ләкин ул чакта татарларның алардан аерым үз мәктәп-мәдрәсәләр системасы булган. Кайберәүләр урыс мәктәпләрендә дә белем алган, билгеле. Күпмедер вакыт иптәш малае белән шундый мәктәпкә йөргән Мирсәй Әмир үзенең истәлекләрендә болай яза: «Учитель артыннан бөтен бала бергәләп безгә аңлашылмый торган чиркәү телендә ниндидер урыс догасы укый. Безнең дә кушылып китәсе килә бит шунда. Хәтта «амин» дигән җирендә кушылып киткәнебезне сизми дә калабыз. Тагын да хәтәррәге — укып беткәч, бөтен бала берьюлы «чебен куа» башлый. Аларга ияреп, төртенеп карыйсы килә бит! Учитель өйрәткәнчә, өч бармагымны, очларын тигез китереп, бергә укмаштырганмын, уң кулымны чак тыеп торам».

Исем үзгәреп кенә җисем үзгәрми. ОПК исеме астында безнең балаларга шул ук «Закон Божий»ны укытмакчы булалар. Дөрес, дәреснең исемен алмаштыруга каршы төшүчеләр дә бар. Мәсәлән, телевидение журналисты Максим Шевченко мәктәпләрдә ОПКны түгел, нәкъ менә «Закон Божий» укытуны яклап көрәшергә чакыра.

Әлеге предмет ОПК исеме белән Русиянең берничә өлкәсендә мәҗбүри укытыла да башлады инде. Йөзләрчә, бәлки, меңнәрчә кан кардәшләребезнең баласы православие диненең нигезләрен өйрәнә. Аларның киләчәктә нинди дин тотачагына шикләнмәскә мөмкин.

Президент Минтимер Шәймиев, мин җитәкчелек иткән чакта Татарстан мәктәпләрендә әлеге дәрес укытылмаячак, дип белдерде. Без, әлбәттә, Минтимер агага озын гомер һәм урынында тагын озак еллар утыруын телибез. Ләкин халкыбыз тарихындагы бу иң әһәмиятле мәсьәлә бер кешенең генә — хәтта ул Шәймиев булса да — ихтыярына бәйле

булырга тиеш түгел. Юкса, бик тиздән балаларыбыз мәҗлескә җыелгач, ягез, бер дога, диясе урынга, ягез, бер чукыныйк, диячәкләр.

«Әлеге предмет христианнарның дөньяга карашы турындагы файдалы әңгәмәгә әвереләчәк, — дип юата безне миссионер Андрей Кураев. — Чөнки ул христианның, әдәби персонажмы ул, тарихтагы бөек эшлеклеме яисә гади бер күршеме, гамәлләрен аңлар өчен кирәк».

Минем күршедә генә базарда йөкче булып эшләүче Сашка яши. Мин, мәктәптә ОПК укымасам да, аның һәр гамәлен туганнарча яхшы аңлыйм. Аңлый алмый торсам, ул аны панель стена аша булса да бик нечкәләп аңлата.

«Әгәр дә ОПК курсы шундый әңгәмәгә әверелә икән, ата-аналарының ихтыярын исәпкә алмыйча гына ислам динле балаларга православиене көчләп тагу турында сүз баруы да мөмкин түгел. Әгәр сабак нәкъ шул рәвешле укытыла икән (ягъни «полезный разговор» рәвешендә! — *Р.З.*), мондый дәресләргә каршы ислам исеменнән теләсә нинди протест ФСБ (Федеральная служба безопасности, элекке КГБ. — *Р.З.*) аналитиклары өчен сигнал булырга тиеш. Кемнәр урыс культурасын ошатмый һәм аның белән танышуга каршы — бу турыда алар уйларга тиеш».

Кураевка рәхмәт, турысын әйткән дә биргән. Нигә койрык болгап, эз яшереп маташырга. КГБ аббревиатурасын ишеткәч тә аяк буыннары дерелдәвен кем генә хәтерләми? Аның да исеме үзгәреп тора (ЧК, ГПУ, НКВД), тик әле беркемнең дә ФСБны бүтән нәрсә белән бутаганы юк.

Хәер, тарих ераккарак китә. Борынгы заманнарда ук татар авылларын чукындырырга барганда, поплар янында һәрвакыт йә гаскәр, йә жандармнар йөргән. Попларның чукынудан баш тарткан мөселманнарга каты җәза бирүне сорап хөкүмәткә язган меңнәрчә шикаятьләре архивларда саклана.

Инҗил янәшәндәге кешене үз-үзеңне яраткандай яратырга куша югыйсә.

Ләкин ул кеше нәкъ сиңа охшарга тиеш дигән сүз түгел әле.

Мәдәнияте белән дә, кыяфәте, гамәлләре белән дә синнән аерым, сиңа охшамаган кешене хөрмәт итәргә өйрәнәсебез бар.

Ярату мәҗбүри түгел...

Урысларның үзләре әйтмешли, көчләп яраттыра алмыйсың.

Үз-үзен яратмаган кешенең (әллә халыкның дикме?) «мәхәббәте»ннән Ходай сакласын!

*Октябрь, 2007*

# КИТАП БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Наиболее тяжким преступлением
является не преследование авторов,
не предание книг костру,
а пренебрежение книгами, их НЕ чтение.

*Иосиф Бродский,*
Нобель премиясен алганда
сөйләгән телмәреннән

Моннан биш-алты еллар элек бер зур түрәнең: «Үз гомеремдә бер китап укымасам да шушы дәрәҗәгә ирештем бит әле», — дигән сүзләренә каләм әһелләре аһ иткән иде. Түрә, әлбәттә, нәфис әдәбиятны күздә тоткан. Аның сүзләренә нигә шулкадәр шаккатканнардыр. Әдәби әсәрләрнең бит төрлесе бар: шигырьләр (аларның нindiләре юк!), психологик проза, детективлар, хатын-кыз романнары... чытырман! Белербелмәс кереп китсәң, адашып калырга да мөмкин. Ә чын әдәбиятны күздә тотсак, классикларны диикме соң... — ул бит түрә булырга өйрәтми. Түрә булырга комачаулый торган бөтенләй бүтән сыйфатлар мактала анда. Шуңа теге абзыйның сүзләрен бераз үзгәртәсе килә: гомерендә бер китап укымаганга шундый дәрәҗәгә ирешкән ул!

Дәрәҗәсе зур булса да, мин аны... җәллим бераз. Балачагында йотлыгып китап укымаган, шушы гаҗәеп ләззәттән мәхрүм һәркем күпмедер кызганыч тоела миңа. «Зәңгәр шәл»дәге ат карагының мәшһүр монологын янә бераз үзгәртеп кабатлыйм: «Их, белмисез сез китап укуның тәмен!»

Чыннан да, китапның тәэсире балачакта аерата көчле була бит. Ул күрәзәче кебек киләчәгеңне юрый, аннан төшкән яктылык барасы юлларыңны яктырта гүяки. Синең өчен дөньяның офыклары киңәя, сер, могҗиза арта, әсәрдәге каһарманнарның кайсысы синең иң якын дустыңа әверелә, гаделлек өчен көрәштә син шулар янәшәсендә... Шулар тәэсирендә тирә-юнеңә игътибар белән карыйсың һәм аңлыйсың: дөнья шактый катлаулы икән бит... һәм бик үк гадел дә түгел икән...

Һәр яңа китап — яңа дөнья, аңа ирешү шатлыгын балачакта гына күздән яшь килерлек итеп тоеп була! Хәзинәләр тулы әкияти сарайның ишегенә орынгандай тышлыгына кагыласың... ачасың... бармак битләре җылы кәгазь битенә тиеп рәхәт чигә, тигез булып төшкән хәрефләрдән килгән кипкән кара исеннән борын канатлары кытыкланып дерелдәп

куя, һәр юл сине әллә кая чакыра, тиздән-тиздән өр-яңа вакыйгаларга уралып, күңелеңне җилкән итеп син хыял диңгезендә йөзәчәксең!

Шушы халәтне кичермәгән кеше ничек җәл булмасын?!

Олыгая төшкәч, китапның тәэсир итү көче кими, әлбәттә. Инде хисләр дә ул кадәр җете түгел, хыял диңгезе дә шактый саеккан... Игътибар иткәнегез бардыр: олыгайган кеше хәтта дуслаша да алмый! Китаптан да без инде үзебез ирешкән, үзебез дөрес дип тапкан тормыш фәлсәфәсен генә эзлибез. Андые табылмаса, китапны ялкау гына читкә этәрәбез, табылса... ул бит инде безгә болай да билгеле!

Җиде-сигез яшьләрдә миңа «Мең дә бер кичә» китабын бүләк иттеләр. Зур форматлы, калын китап. Фолиант! Сәяхәтче Синдбадлар, сихерле лампага ия Галәветдиннәр (болар мультфильмнар аша хәзерге балаларга да билгеле: Галәветдин аларга Аладин буларак таныш). Аннары «Татар халык әкиятләре»... «Безнең тарих-әкиятләрдә», — дип, бер әңгәмә вакытында Нурихан Фәттах миңа юкка гына әйтмәгән. Әкиятләрдә ерак гасырлар аша телләрдән телләргә күчеп, хыял дөньясына чорналып, борынгы чынбарлыгыбыз килеп җиткән ләбаса. Каһарманнары да бит бер укуга, бер ишетүгә истә кала торган: Алпамшалар, Камыр батырлар, Шомбайлар...

Әкиятләр, беренче карашка, гади тоелсалар да, аларда әллә ничә катлам бар, сабый, бик тирәнгә төшеп җитә алмаса да, күңеле белән моны сиземли, шул сер аның хыялына яңа гайрәт өсти.

Югыйсә без хәзер балаларга «Сара мәктәпкә бара», «Алмаз елый утырып» кебек тезмәләр тәкъдим итәбез дә, аларның бу Алмазларга, Сараларга битараф булуына гаҗәпләнәбез.

Нигә бүген бөтен дөнья Гарри Поттерга ябышты?

Әкият җитми балаларга... һәм үзебезгә дә!

Бөтен дөнья... дип бераз арттырдым бугай. Аннары мин бөтен дөньяны иңләргә дә җыенмыйм, моңа мөмкинлегем дә юк.

Үзебезнең татар дөньясында ни хәлләр соң?

Әле егерме еллар элгәре генә, татар — китаплы халык, дип мактана идек бит. Хәер, ул чакта без яшәгән Советлар Союзы да иң күп укый торган ил санала иде. Китапларның, гәҗит-журналларның ул чактагы тиражларын искә төшерсәң, мөгаен, бу сүз дөрес тә булгандыр.

Йа Хода, китапларны кулдан-кулга йөртеп укыган, гәҗит-журналларга чират торган заманнар да бар иде бит.

Әле күптән түгел «Азатлык» радиосы хәбәрчеләре Казан

урамнарында үткән-сүткәннәргә «Кол Гали кем ул?» дип сорау биреп йөргән. Ник берсе-бер дөрес җавап бирсен?!

Авыл җирендә дә хәлләр шундый ук койты.

«Хәзер заманасы бүтән, акча эшләү заманы, кешенең «әкиятләр» (ягъни әдәби әсәрләр) укырга вакыты юк», — диләр.

Бу сүздә дөреслек тә бар кебек. Тирә-якка күз ташласаң, әллә дөньясы акылдан шашкан мәллә дип тә уйлап куясың. Һәркем каядыр йөгерә, ыгы-зыгы килә, күзләре ут яна, терсәкләре тырпайган — ничек күбрәк умырып калырга, алдарга, таптап китәргә, «калҗа»га алданрак барып җитәргә... шул уй хакимлек итә сыман башларда. Китап уку кайгысымы аларда? Киресенчә, китап укыган кеше болар каршында — җүләр. Кеше бәясе монда кесә калынлыгы белән үлчәнә.

Мәдәният министры белән бер әңгәмә вакытында телевидениедән тамашачыларга өч сорау бирделәр: янәсе, кем кая йөри — спорт ярышларынамы, театргамы, музейларгамы? Табигый, җавап бирүчеләр арасында театрга, музейга йөрүчеләр саны берән-сәрән генә иде. Белмим, бәлки, ул кешеләр телевизор карамыйдыр... йә без музейга йөрибез дип чылтыратуны үзләре өчен түбәнлек дип саныйлардыр. Әмма бер-бер артлы спорт комплекслары корыла икән, димәк, ихтыяҗ бар. Димәк, хикмәт һич тә вакыт юклыкта түгел. Спорт ярышларына барган өчен акча түләмиләр бит, киресенчә, үз кесәңнән чыгарасы. Һәм билет бәяләре дә театрныкыннан, музейныкыннан кыйбатрак.

Кимәл шундый! Уйландыра, күңелне тибрәтә торган тамаша кирәкми хәзер халыкка. Һәм, мондыйлар, әлбәттә, беркайчан кулына китап та алмаячак.

Китапның да төрлесе бар, билгеле. Яхшысы, начары. Ләкин гомерендә кулына китап тотмаган кеше өчен алар барысы да макулатура.

Дәүләт нәшрияты әлегә татар китапларын чыгара тора, шөкер. Моны күпсенүчеләр дә бар. Янәсе, татар әдәбиятын, бөтен дөньядагы кебек, базар шартларына куярга кирәк. Китап — шул ук тауар дигән сүзләр еш ишетелә хәзер. Хуш, әлеге әһелләр максатларына ирешә дә ди (һәм ирешәчәкләр, иманым камил!). Ул чакта «Идегәй»ләрне, Каюм Насыйриларны, Әмирхан Еники, шул ук Дамир Исхаковларны кем нәшер итәр? Шагыйрьләр турында мин әйтмим дә инде. Татарча укучылар калса, монда да шул урыслар кебек үк, Маринина, Дашкова кебек авторларны гына укыячаклар бит. Ә мондый әсәрләр инде әдәбият дип саналмый.

Китап, тауар буларак, беркайчан да аракы белән ярыша алмаячак. «Татспиртпром», әнә «Татнефть»тән кала, Татарстан бюджетын хасил итүчеләрнең икенчесе икән. Нефтехимия дә аңардан калыша!

Китапны тауар итәргә тырышканчыга кадәр иң әүвәл татар баласына китап уку культурасын йоктырырга кирәк.

Хәзер мәктәп укучыларының китап уку-укымавы турында беркем дә кызыксынмый. Чөнки укытучылар үзләре дә китап түгел, гәҗит-журналлар да укымый! Ә бит белгечләр кисәткәнчә, 12–14 яшькә кадәр укырга күнекмәсә, аннан соң инде кеше беркайчан да китапны якын итә алмаячак.

Укытучылар укымый, дигәч, бу язмага күзе төшкән кайберәүләре әлеге ямьсез хакыйкатькә чәчрәп китеп каршы төшәр, мөгаен. Һәм хезмәт хакының азлыгына зарлана башларлар. Шул-шул. Шуңа укытучы һөнәренең дәрәҗәсе дә юк. Шуңа да аны күбрәк иң булдыксызлар сайлый да. Ә егетләр, гомумән, мәктәп тирәсенә якын бармый.

Дәүләткә укымышлы, дөньяга үз карашы булган шәхесләр түгел, ә «Саша любит Машу, Маша любит Дашу»ише мәгънәсез җырларга селкенүче зомбилар кирәкме әллә? Китапны алмаштырган телевизордагы тапшыруларны карагач, ирексездән шулай уйлап та куясың.

Татар әдәбиятының киләчәгенә исә өмет көннән-көн сүрелә бара. Инде Татарстан китап нәшриятының карары белән, нәшер ителгән китапларының яртысын каләм хакы исәбенә алып, язучы үзе сатарга тиеш икән. Мөмкинлеге булганнар элек тә үз китапларын үзләре урнаштыра иде анысы. Мәсәлән, район яисә берәр оешма башлыгы белән сөйләшеп, күпмедер нөсхәне шуларга саталар иде. Аннары сатып алучылар аны, кирәкме-түгелме, бүләк-мазар итеп шунда эшләүчеләргә, килгән кунакларга тарата, мөгаен.

Ничарадан бичара...

Шунысы ачык: беркемне дә көчләп укыта алмыйсың.

Ел әйләнәсендә гәҗит-журнал хезмәткәрләре төрле төбәкләргә чыгып үз басмаларына язылырга өнди, химаячеләр эзли. Шул ук китап язмышы!

Татар үз гәзит-журналларын да укырга теләми. Иң гаҗәбе — бу безнең бүгенге генә бәлабез түгел. Татар матбугат басмалары күпләп мәйданга чыккан 1907 елда ук (моннан нәкъ 100 ел элек!) Мәҗит Гафури болай язган: «Ни өчен ала торган җаридә (гәзитә)ләреңезне туктатасыз, бер җәһәттән, үзеңез укып файда аласыз, икенче, җаридәләрнең

тукталмавына сәбәп булып, милләткә бер файда иткән буласыз бит, дип сорасаң, юк, әфәндем! бер дә укырга вакытым юк, җәридәләрне алсам да тик яталар дип, кыска вә үкенечле җавап бирәләр.

Соң алай булса, башка милләтләр ничек укырга вакыт табалар, алар да сезнең кеби дөнья көтәләр, кәсеп итәләр, ләкин сезнең кеби вакытым юк дип тормыйлар, хәтта арбачыларына кадәр вакыт табып җәридәләр укыйлар, дөньядан хәбәрдар булып торалар.

Сезнең вакытыгыз булмаса, абыстай илә уйнап-көлеп бер сәгать эчә торган чәеңезне ярты сәгатьтә эчеп тә (хәзер инде бүтән «абыстайлар», һәм «чәйләр» дә ярыйсы ук үзгә. — *Р.З.*), ярты сәгатьне җәридә укырга сарыф кыйлсаңыз булмасмы?

Бер дә үзегез укымыйсыз икән, фәкать милләтнең алга китүенә матбугатның иң зур сәбәп икәнлеген аңлап, матбугатымызга файда китерер өчен генә бер-ике граммофон нотасына биргән акчаңызны (шыгрым тулы хәзерге концерт залларын искә төшерергә була. — *Р.З.*) бер-ике җәридәгә җибәреп мөштәри (яздырып алучы) улсаңыз булмаймы?

<...> Мөселманнарның аз вакыт эчендә буйлә матбугатка малик (ия) булуларыннан бәгъзе кешеләр (кемнәр икәне билгеле! — *Р.З.*) гаҗәпләнә, хәтта курка да башлаган иде. Юк инде, сезләр: мөселманнар уянды, җәридәләре артты, безгә ашатмай башларлар (татарны фәкать эш аты буларак файдаланырга тырышуны Гафури бик яхшы аңлаган. — *Р.З.*), дип (үзегезне) куркытмаңыз! Безем бу вакытта тормыш вә хәрәкәтемезгә караганда, безгә матбугат дәгел, әллә нәрсә бирсәләр дә, сезне куркытырлык дәрәҗәгә киләчәк дәгелмез, сез әле болай булып торганда, хәвефсез мөселманнарның башыны ашаячаксыңыз! Алар алай аңларлык бер фикер вә хәрәкәткә килмәгәннәр. Матбугат галәме вә гәзитәләр сезгә караганда шулай зур куркынычлар чыгара торган нәрсә булса да, безем мөселманнар каршында бик әһәмиятсез, бер дә кирәкмәгән бер нәрсәдер».

Бу сүзләргә берни өстәп булмый. Диагноз төгәл. Шунысы гына гаҗәп: йөз ел үткән, ә без китап дип, гәҗит-мәҗит дип һаман тырмашабыз әле...

*Сентябрь, 2007*

# ЭЧТӘЛЕК

## Хикәяләр

Йорт иясе . . . 4
Каты күзле хатын . . . 22
Тәре . . . 28
Яңгыр астындагы ябалак . . . 37
Үксез . . . 48
Яшел чирәмдә сары клиндер . . . 54
Кыз-хатын . . . 60
Ычтапан . . . 80
Дару . . . 88
Бала . . . 95
Итек . . . 100
Мылтык . . . 104
Алла . . . 107
Ак эт . . . 115
Шүрәле . . . 118
Ачкыч чыпта астында . . . 123
Сөембикә . . . 126
Кызыл сыер . . . 133
Бу бишенче курс . . . 136
Коршау . . . 143
Илбәк . . . 204
Мәгарә . . . 215

## Эсселар

Ташка ордым башны . . . 222
Син, мин, Мөхәммәтәмин... . . . 226
Премия . . . 232
Гасыр бусагасында . . . 240
Үзеңнеке — үзәктә . . . 245
Инкыйраз . . . 248
Хан капкасы кай төштә?.. . . . 252
Авызлар йомылганда . . . 256
Кармазин . . . 259
Көчленеке — замана . . . 263
Коллыктан калган холык . . . 267
Тотса Мәскәүләр якаң... . . . 271
Татар зираты . . . 276
Казан . . . 279
Каңгырыш . . . 285
Карачкы . . . 289
Кара шифон, Ташкент һәм канатсыз романтика . . . 294
Әләк . . . 297
Исемемне кемнәр кушкан... . . . 301

Әбделмән һәм Магницкий . . . . . . . . . . . . 305
Аракы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 309
Утлы кисәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 314
Ишан кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Кәнизәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
Кара карлыгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
Башны иеп, муен бөгеп... . . . . . . . . . . . . 335
Петр патша ярлыгы . . . . . . . . . . . . . . . 339
Казан ятимнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Иләт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
Татар җаны биеклегендә . . . . . . . . . . . . 353
Төп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 358
Безгә дигән биштәр . . . . . . . . . . . . . . . 362
Кадерсезлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365
Иләмәннең биләмәсе . . . . . . . . . . . . . . . 370
Нәфес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 374
Мирас . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 378
Җәлил эзләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 384
Ягез, бер чукыныйк? . . . . . . . . . . . . . . . 388
Китап белән хушлашу . . . . . . . . . . . . . . 393

Литературно-художественное издание

**Зайдулла** Ркаил
(**Зайдуллин** Ркаил Рафаилович)

ГОЛОВУ БИЛ О КАМЕНЬ

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Зәйдулла** Ркаил
(**Зәйдуллин** Ркаил Рафаил улы)

ТАШКА ОРДЫМ БАШНЫ

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Р.Н.Нуриева, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.11.2008. Форматы 84×108 $^{1}/_{32}$.
Шартлы басма табагы 20,16. Шартлы буяу-оттиск 20,69.
Нәшер-хисап табагы 22,42. Тиражы 3000 д. Заказ Т-1422.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru.
e-mail: tki@tatkniga.ru.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААЖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.



Ркаил Зәйдулла (Зәйдуллин Ркаил Рафаил улы) — узган гасырның сиксәненче елларында әдәбиятка килгән шагыйрьләрнең берсе. Аның беренче шигырьләре үк өлкән каләмдәшләренең игътибарын җәлеп итте. 1980 елда «Күрәзә» җыентыгы өчен ул Татарстан комсомолының М.Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды.

Шул ук вакытта Р.Зәйдулла бүтән жанрларны да чит итми. 2002 елда аның «Саташкан сандугач» пьесасы Г.Камал исемендәге театр сәхнәсендә куелды. Шагыйрьнең прозасын да әдәби җәмәгатьчелек хуплап каршы алды. Аның хикәяләре Татарстанда гына түгел, Русия һәм Төркия матбугатында да дөнья күрде. Нәни хикәяләре тупланган «Татар тажы» дигән җыентыгын исә Татарстан Язучылар берлеге Ф.Хөсни исемендәге премия белән бәяләде. Шулай ук Р.Зәйдулла — Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» бүләге иясе дә.

Нинди генә жанрда эшләмәсен, Р.Зәйдулла иҗатына милли рух, милли гамь хас.

ISBN 529801724-4
9785298017244